1

Нурихан Фэттах

СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

РОМАН

Беренче китап

Сүз башы

Яшәү өчен җирдә борын-борынгыдан көрәш барган. Ачлык белән дә, табигать китергән бәла-казалар, көтелмәгән афәтләр белән дә көрәшергә туры килгән кешегә. Ләкин төрле ыру-кабиләләр, илләрнең бер-берсенә каршы сугышуы, бер-берсен юк итеп, җиңүче булып калу өчен көрәш алып баруы тарих хәтерендә, мәңге җуелмас җөй сыман, аеруча нык сакланып калган. Кан коюлы рәхимсез яуларда нилэр генә уйлап чыгармаганнар. Әйтик, бер кабиләдә үтерелгән дошман башын җыю белән мавыкканнар. Икенче бер кабиләдә һәр көнне яуда әсир төшкән яшь, таза сугышчының канлы йөрәген кояшка корбан итеп бирә торган булганнар.

Комсыз патшалар, ханнар, корольләр боерыгына буйсынып илләр белән илләр, халыклар белән халыклар бәрелешкән. Кешеләр чебен урынына кырылган, авыллар, шәһәрләр җир белән тигезләнгән.

Дөрес, сугышлар күп төрле булган. Берәүләр, әйтик, коллыктан котылу өчен көрәшсәләр, икенче берәүләр ярсып илбасарларга каршы ташланганнар.

Ни генә булмасын, беркайчан да җирдә оҗмах булмаган.

Бер-берсенә карата дошманлык тойгысына караганда шулай да янәшә тыныч яшәргә омтылыш кешедә һәрвакыт көчлерәк булган. Ачлыктан, туфаннан, яулардан исән калган Кеше менә безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Ул Кеше — син һәм мин. Җирдә бүген кемнәр исән, кем сулый, уйлый ала, кем сөя, сөелә белә — барысы да без — кешеләр.

Ачлыктан, туфаннан һәм Чыңгыз хан, Аксак Тимер яуларыннан, Освенцим һәм Дахау мичләреннән исән калган безнең токым бәхетле дә, бәхетсез дә. Бәхетле шуның өчен, — чөнки без бар. Без яшибез. Бәхетсез шуның өчен, — чөнки безнең белән бергә дөньяда әле һаман үлем куркынычы, сугыш куркынычы яши.

Юкка-барга бер-берсенә яу чапкан борынгы кабилә кешеләре белән чагыштырганда, бүгенге кеше аңлырак та, белемлерәк тә. Бүгенге кешенең академияләре, институтлары, галимнәре, инженерлары бар. Ләкин шул ук вакытта галимнәр, инженерлар уйлап тапкан үтерү, җимерү кораллары да бар. Хәзерге «уклар», ясалма «ми» куелган бүгенге «ташлар» белән авылларны-шәһәрләрне генә түгел, бөтен ил-дәүләтләрне җир белән тигезләргә була. Бүгенге көндә аерым илләр мәнфәгате генә түгел, бөтен кешелек язмышы кыл өстендә тора. Бер кешенең мәгънәсез боерыгына буйсынып кнопкага басу белән дә бөтен җир шарының көле күккә очарга мөмкин!

Шулай булгач, өстән таш яумый дип, бездә сугыш инде күптән бетте дип, тынычланырга әле иртәрәк. 1945 нең май аеннан бирле кырык еллап вакыт узса да, фронт һаман дәвам итә. Фронт бары чигерелгән, фронт бары күчерелгән генә. Ут сызыгы кайчагында Анголадан үтә, кайчагында Вьетнамнан үтә. Ләкин, каян гына үтмәсен, ул һәрвакыт безнең күңелләргә килеп тоташа.

Шулай булгач, җирдә иминлек өчен, тынычлык өчен көрәш ул — синең белән минем өчен, безнең бүгенгебез һәм киләчәгебез өчен көрәш дигән сүз.

Менә шундый алга киткән, менә шундый куркыныч заманда тарих нигә кирәк тә, тарихи романнар нигә кирәк? Тарих ул — искелек, тарих ул — артталык. Аңлы, белемле кайберәүләрнең шулайрак та фикер йөртүләре ихтимал. Чыннан да шулаймы соң бу? Юк, алай түгел! Тарих — искелек, тарих — артталык. Ләкин тарих — ул гыйбрәт, акыл һәм тәҗрибә! Ашыга торган, ашкына торган хәтәр заманда боларның барысы

да кеше өчен иң кирәкле сыйфатлар. Шулай булгач, җирдә иминлекне, тынычлыкны яклап, кара көчләр белән көрәшү ул безнең бүгенгебез һәм киләчәгебез өчен генә түгел, безнең үткәнебез өчен дә көрәш дигән сүз.

Һәрбер аңлы, намуслы кеше алдында бүген: дөньялар имин булырмы, мең еллар буена тупланган цивилизацияне, сәнгать җәүһәрләрен, кешелек акылын саклап калып булырмы дигән котылгысыз сорау торганда, мин җавап эзләп, киңәш-гыйбрәт эзләп, тарихка борылып карыйм. Мең мәртәбә үлеп, мең мәртәбә терелгән, мең мәртәбә таркалып, мең мәртәбә яңадан кушылган һәм бернинди җил-давылга, бернинди карбуранга карамыйча, бернинди янау-куркытуларга, ачлык, туфанга карамыйча, һәрбер җан иясе кебек һаман яктыга, һаман кояшка үрләгән тырыш, чыдам халыкның тарихы миндә һәрвакыт ышаныч, ныклык һәм горурлык тойгысы тудыра. Ирексездән Тукайның «халык зур ул, көчле ул» дигән сүзләрен искә төшерәсең. Шушы ук сүзләрне үз халкыңа карата гына түгел, гомумән, барлык халыкларга карата кулланасы килә: әйе, халык зур ул, көчле ул. Гасырлар буена үлемне җиңеп, бүгенгәчә дәвамын саклап килгән халык һәм халыклар моннан соң да вәхшилекне, үзара дошманлыкны һәм мәгънәсез сугышларны җиңә алыр дип әйтәсе килә. Кеше һәм аның акылына булган ышаныч шуңарга ныклы нигез бирә.

Төрки халыкларның борынгы тарихын чагылдырган һәм «Сызгыра торган уклар» дип аталган әлеге романымны язганда минем күңелне менә шундыйрак уйлар, борчулар биләде.

АВТОР.

Беренче баб

I

Барыс елының[1] сигезенче ае, икенче көне иде. Иртән иртүк, кояш чыгар-чыкмас борын, атларын кызу атлатып, Туман каган урдасына, Көнчыгыш капка алдына бер төркем яшьләр килеп туктады. Арадан берсе — алай[2] башы, алгарак чыгып, йокылы-уяулы торгакларга[3]:

— Атсыз күлне боз тоткан! — дип кычкырды.

Бүген төнлә шактый суыткан иде. Иртәнгә таба күлне боз тотуы ихтималы турында торгаклар үзләре дә кичтән үк чамалап куйганнар иде. Ләкин алар шул чамалау белән генә тынычландылар — беркемнең дә иртән күл буена барып, үз күзләре белән карап килергә башы җитмәде. Тучи бәк тәгин углан әнә бик күпләрдән өлгеррәк булып чыккан. Кара син аны, нинди кычкыра — яу килгәнмени!

Капка янында сакта торган кораллы ирләр кыймылдашып куйдылар, тәгин угланга якынрак килделәр. Артык сикереп төшмичә, шулай да беркадәр кызыксыну белдереп, сораштыра башладылар: кайчан күрдең, кай төшендә күрдең? — диделәр. Куанычыннан авызы ерылырга гына торган яшь углан күл ягына төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләде.

Атсыз күлдә беренче тапкыр боз күренүне сөннәр изгегә юрыйлар иде. Күлне боз тоту ул көз бетеп кыш башлануны белдерә. Кыш башлану белән исә бер үк төрле көндәлек тормышта күптән көтелгән үзгәрешләр, күңелле һәм тынгысыз мәшәкатьләр башланачак. Урдадан бер-ике чакрым чамасы ераклыкта урнашкан Атсыз күлне боз тоту

[1] Барыс елы — уникe еллык төрки календарьда өченче ел. Уникe елның һәр елы берәр хайван исеме белән аталган һәм ел санын исәплəгәндә: барыс елы, куян елы... дип санаганнар.
[2] Алай — гаскәри берләшмә, төркем.
[3] Торгак — кораллы сакчы.

белән, барыннан да элек, Сөн иленең башы Туман каган[1] беренче ауга чыгачак иде. Аннан соң корбан, җыен, ярышлар китә, күршеләргә яу чабулар башлана. Кыш буена эш җитәрлек сөн иренә! Шуңа күрә дә беренче боз тоту турында хәбәр алып килгән беренче кешегә каган үз кулы белән бүләк бирә. Шуңа күрә дә ике як бите уттай янып торган яшь тәгин углан шулай таң тишегеннән капка төбенә килеп җиткән, куанычыннан нишләргә белми елмая иде.

Тәгин углан[2] алып килгән яңалыкны торгаклар иң элек каравыл агасы Туңгак алыпка әйтергә булдылар. Туңгак алып капка янындагы каравыл өендә йоклап ята иде — аны шундук уяттылар. Яңа бозны карау өчен Туңгак алып күл буена үзе китте. Тиз арада ул аннан әйләнеп тә кайтты. Әйе, күлне чыннан да боз тоткан иде. Каравыл агасы, көнчыгыш офык ягына карангалап, беравык уйланып торды, шуннан соң ул тәгин угланның үзен генә ияртеп капка аша үтте. Угланның унике егете — җан сакчылары тышта капка янында торып калдылар.

Җир өстендәге караңгылык инде таралган иде, көнчыгыштан ачыкланып таң яралып килә — шулай булгач, озакламый каган да йокыдан торырга тиеш иде. Ак урданы[3] әйләндереп алган тышкы бөҗраның эченә кергәч, үзәккә таба сузылган туры юлдан алар юри салмак кына, ашыкмыйча гына бардылар.

— Син соң нишләп әле болай, олуг тучи бәк... Атсыз күлне боз тотканын карарга дип кайттыңмени? — диде Туңгак алып.

Аның тавышында яшь угланга карата хөрмәт һәм шулай ук аталарча кырыслык сизелде.

— Шатлыктан онытып җибәргәнмен — йөзбашы[4] Күчәр мине синең янга җибәрде, Туңгак алып, — диде углан ашыгып.

— Минем янга килгән өчен иң элек каганны күрергә булдыңмы? — диде каравыл агасы.

— Аның өчен түгел, Туңгак алып, — диде яшь углан. — Төнне без Атсыз күл буенда кундык, шуңа күрә менә...

— Йөзбашы Күчәр ник җибәрде минем янга?

— Теге яктан ниндидер шикле кешеләр чыкты.

— Бик шиклемени? — дигән булды Туңгак алып.

— Кем белә инде аларны... Йөзбашы Күчәр сиңа әйтергә кушты. Мин аларны Таштугайга кадәр озатып куйдым да, әни янына кереп чыктым.

— Таштугайда Исәнтәйне күрдеңме соң?

— Күрмәдем. Алар аны сорадылар. Банхуа диделәр. Хатыны авырлы.

— Хатыннары да бармени? — диде Туңгак алып.

— Бар. Бер хатын, өч ир кеше, — диде углан.

Туңгак алып тынып калды. «Шикле кешеләр» турында сораштыру аңа күңелсез була башлады, ахрысы. Ул тынгач углан да беренче булып сүз башларга кыймады.

---

[1] Каган — борынгы һәм урта гасырларда төрки халыкларда ил-дәүләт башы. Патша, хан.

[2] Тәгин углан — каганның тәхеткә хокукы булган углы.

[3] Урда — каганның, бәкләрнең ныгытылган һәм кораллы ирләр тарафыннан саклана торган торагы. Шулай ук «башкала» мәгънәсендә дә кулланылырга мөмкин.

[4] Йөзбашы — борынгы төркиләрдә, шул исәптән сөннәрдә, гаскәр унлы берәмлекләргә (төркемнәргә, алайларга) бүленгән булган. Иң кечкенә берәмлек — ун кешелек төркем (алай) булган һәм аның башы (командиры) унбашы дип аталган. Йөзкешелек төркемнең командиры — йөзбашы, меңкешелек төркеменең командиры — меңбашы дип аталган. Ун мең кешелек берәмлек төмән булган һәм аның башлыгы төмәнбәк дип аталган. Барлык гаскәр сү, су яисә чиру дип аталган. Гаскәр, чиру башлыгы — сүбашы, субашы булган.

Бераз шулай тын гына баргач Туңгак алып угланның өй хәлләрен сораштыра башлады. Әниең тазамы, мал-туарыгыз исәнме, илегез тынычмы, диде.

Әкрен генә сөйләнгәләп алар һаман үзәккә таба баруларында булдылар. Тапталган киң юлның ике ягында да, билгеле бер тәртиптә һәм бер-берсеннән билгеле ара калдырып утырган бай киез өйләр торып калды. Бу өйләрдә каганның күп санлы туган-тумачалары, якын кешеләре яши иде. Тын гына йокымсырап утырган ак киез өйләр арасында кыршылып беткән иске тун кигән берән-сәрән картлар, карчыклар күренде. Болар — иртүк торып казан асарга, учак ягарга тотынган коллар-каралар иде.

Юл буендагы өйләр беткәч, ачык җир башланды. Ачык җир бер ук[1] чамасы сузылды. Шуннан соң икенче бощра башланды. Тышкы бощрага караганда бу икенче бощра кечерәк иде. Шул ук вакытта монда сак та көчлерәк иде — сөңге башакларын югары каратып торткан төнге торгакларның атлары бер-берсенә терәлеп диярлек торалар.

Туңгак алып белән тәгин угланны монда да капка аша берсүзсез үткәреп җибәрделәр. Тышкы бощраның Көнчыгыш капкасыннан килә торган туры юл, эчке бощра аша үтеп, үзәккә таба сузылды. Монда да юлдан читтә биек ак өйләр торып калды. Бу өйләрдә каганның дәрәҗәлерәк туган-тумачалары, имчеләре, күрәзәчеләре, ашчылары һәм башка якын кешеләре яши иде.

Икенче бощра капкасыннан үтеп, бер ярты чакрым чамасы җир килгәч, каравыл агасы Туңгак алып белән тәгин углан өченче бощра каршында туктап калдылар. Алар каршысында җәяүле ирләрдән торган җанлы койма калкып чыкты. Җанлы койма артында очлы такталардан җыйналган биек текмә күренде. Арырак, иң уртада, түбәсе күккә тиярдәй булып, Туман каганның Ак өе калкып утыра иде.

Каравыл агасы Туңгак алып белән яшь угланны өченче бощра аша үткәреп җибәрергә беркем ашыкмады. Шулай ук алар үзләре дә бернинди ашыгу билгесе күрсәтмәделәр — төнге торгаклардан бер читтәрәк туктап калган көе, тавыш-тынсыз гына көтә башладылар. Кояш әле чыкмаган. Шулай булгач, Кояшның җирдәге углы — Сөн иленең патшасы бөек каган да әле күзләрен ачмаган булырга тиеш...

II

Еракта, дулкын-дулкын булып яткан караңгы калкулыклар артында, күптән көткән кояш күренде. Таусыз, урмансыз шәрә җир астыннан югары таба бөркелеп иң элек аксыл-тоныкл яктылык таралды. Аксыл яктылык бераздан ялкынланып янган ут төсенә керә башлады. Төнне уяу уздырган торгак ирләр, изге бер тынлык саклап, чыгып килгән кояш ягына борылдылар.

Кояшның чыгып килүе турында бөек каганга хәбәр бирелде: тышкы ишек сакчысы эчке ишек сакчысына пышылдады, эчке ишек сакчысы каган белән бер өйдә төн куна торган карчыкка пышылдады. Карчык кол кызны уятты. Кол кыз биек өйнең түрендә, ефәк чатыр эчендәге түшәктә төн уздырган ахирәте Табылдыкны уятты. Табылдык каганны уятты. Ул аңа шулай ук киенергә дә булышты. Аннан соң, ярым йокылы күзләрен көчкә ачып, идәндәге озын киез өстеннән абына-сөртенә атлаган авыр таза ир кешене ул җитәкләп ишек янына алып килде. Алып килде дә, эчке ишек сакчысына тапшырды. Ишек төбендә төн уздырган кортка ашыгып киез ишекне күтәрде.

[1] Бер ук — атылган ук ераклыгына тигез ара.

Эчке ишектән чыккач, каган бераз җир караңгы аралыктан барды. Тышкы ишек сакчысы — шулай ук кортка кеше — каган ишеккә килеп житәр-житмәс борын, ике кат киез япманы күтәреп куйды.

Тышкы ишектән чыгу белән, Туман каганның җылы битенә коры салкын килеп бәрелде. Шул ук мәлдә ул, күнегелгән бер гадәт белән башын калкытып, күк читенә күз ташлап алды.

Корткалар җиргә ак киез җәйделәр. Бөек каган ялан аяклары белән йомшак, салкын киезгә басып, берничә адым алга атлады, җиргә тезләнде.

— Кояш әтекәем, кояш әнекәем! — диде ул, югары үрләп килгән изге яктылыкка эндәшеп. — Илемә-көнемә, малыма-туарыма тереклек биргән, җирдәге киекләрне, судагы балыкларны яраткан олуг Тәңрем! Бүген дә, иртәгә дә — мәңге мине изгелегеңнән ташлама!

Ул, шулай дип әйтү белән, тун чабуларын тотыштырып, аягына басты.

— Аман булсын туар көн! — дип кычкырдылар текмә артындагы кораллы ирләр.

— Аман булсын! — диде каган.

Шулай итеп, изге Сөн илендә изге көн туды. Биек текмә — койманың Көнчыгыш капкасы янында байраклар күтәрелде, капка ачылды. Беренче булып капкадан уң кул карачы[1] Бүзбала керде. Башка көннәрдә ул алай капка ачылу белән үк кереп җитми иде, каган үз йомышларын үтәп, урын-җир җыештырылганчы, өйдәге кыз-кыркын таранганчы, киенгәнче беравык көтеп тора иде. Бүген ул әнә иртәләгән. Бер-бер ашыгыч эш килеп чыкты микәнни?

Туман каган җылы өйгә кереп китәргә дигән уеннан кире кайтып, ишек төбендә тоткарланып калды һәм уң кул карачы Бүзбаланы көтеп тора башлады.

Бүзбала килде, бик кыенлык белән бөгелә торган авыр, симез билен бөгеп, бөек каганны туган көн белән котлады, аннары, артык сүз озайтып тормыйча, сөенечле хәбәр китергән тәгин углан турында әйтте.

Каганның салкын йөзендә җылыну билгесе күренеп китте. Бүген төнлә күлне боз тоту ихтималы турында ул да исеннән чыгарган иде. Күңелле хәбәр бу! Әнә нинди изге көнгә туры килгән! Беренче боз көне кайбер елларда иске ай азагына туры килә, шунлыктан кышы да игелекле булмый. Кайбер елларда иске ай белән яңа ай алышынган төндә катырып җибәрә — алай булганда да ел бик уңай килми. Быел менә ичмасам изге дисәң дә ярый. Иртәгә яңа айның өченче көне, аның инде ныгыган, яшь, көчле чагы. Беренче ау өчен моннан да кулай көннең булуы да мөмкин түгел.

— Хәбәр китерүче керсен, — диде каган Бүзбалага.

Аз сүзле Бүзбала, аны-моны әйтеп тормыйча, кире борылды. Борынборыннан килгән йола шундый иде: каганның йоклый торган чагы булмаса, ашыгыч я сөенечле хәбәр китергән кеше, кем булуына да карамастан, аның янына керә ала иде. Күп тә үтмәде, уң кул карачы Бүзбала тәгин углан белән каравыл агасы Туңгак алыпны ияртеп, биек ак өйгә килеп керде.

Түбәдәге төнлек киезе әле ачылмаган иде, учакта шулай ук ялкынланып ут та янмый. Шунлыктан иркен өй эчендә иртәнге җылымса караңгылык саклана иде. Өстен-башын алыштырырга өлгермәгән каган, кымыз салынган алтын кәсә тотып, керүчеләргә каршы атлады. Туңгак алып, ил башын котлап бил бөкте. Яшь углан ашыгып шулай ук идәнгә егылды, тезләнде һәм ярым шәрә ир кешенең аякларына кулын тидерде. Аның кулы кайнар иде. Каган, нидер сизенеп, күзләрен ныграк ачты, яшь угланга иелебрәк карады.

[1] Карачы — каганның идарә итүдә ярдәмчесе.

— Углым! Албуга! Син түгелме соң? — диде ул гаҗәпләнеп.

— Мин бу, әти! — диде Албуга куанып.

Ата кеше углына торырга булышты, яратып аны күкрәгенә кочты. Шуннан соң ул үз кулы белән углына кымыз бирде дә бүлдермичә аның эчкәнен көтеп торды.

— Үзең күрдеңме, берәрсе әйттеме? — диде ул.

— Үзем күрдем, әти! — диде тагын углан сөенеп. — Йөзбашы Күчәр мине урдага җибәрде. Капкадан керергә соңга калдым да, егетләрем белән күл буенда кундым. Синнән мактау сүзләре ишетәсем килде, әти.

— Бүләк аласың да килдеме? — диде күңеле йомшаган каган.

— Килде, әти! — диде Албуга.

— Ни телисең — сора, — диде ата кеше.

Борылып ул түргә, өйнең уртасына таба атлады. Башкалар да аның артыннан иярделәр. Шул чакны тыштагы төнлек киезен кемдер ачып куйды. Югарыдагы түгәрәк ачыклыктан өй эченә иртәнге яктылык бөркелде. Каган туктады, борылып углына карады һәм аның куанычлы йөзендәге үзгәрешне күреп, аптырабрак калды. Шат күңелле яшь углан, киек күргән аучы кебек, тынып, сагаеп калган иде. Бу вакытта ул, әйтерсең, үзенең кемлеген дә, кайдалыгын да оныткан иде. Аның уттай янган тынгысыз күз карашы өй эчендәге ниндидер нәрсәгә — гадәттән тыш кызык, серле нәрсәгә юнәлгән иде.

Ата кеше ирексездән углы караган якка борылды. Аның өлкән бичәдән туган өлкән углы ятак янында урын-җир җыештырып булашкан кол кыз Табылдыкка карап тора иде. Өйгә чит ирләр керүен күрми калган Табылдык исә өстен-башын алыштырып өлгермәгән иде. Иртәнге ярым-караңгыда ярым-йокылы килеш ул кырык яшьлек каганга түгел, унсигез яшьлек угланга да аеруча сылу, күркәм булып күренде.

Тагын углан әллә үзенең кайдалыгын исенә төшерде, әллә янындагы ирләрнең күз карашларын сизенде — куркытылган болан кебек тиз генә карашын читкә борды. Шундук ул яңадан атасы алдына тезләнде, бөтенләй үзгәргән, юашланып калган көчсез бер тавыш белән, тыны бетеп:

— Әти! — диде.

Аның бу ялварулы «әти!» сүзенең ниндидер үтенеч, өмет белдергәнен ата кеше бик яхшы сизенеп алды. Аның йөзе үзгәреп китте. «Юк, булмаячак! Атаңның авызыннан тартып алырга иртәрәк әле сиңа!» — дип уйлады ул кинәт кенә өлкән углына карата көнләшү һәм дошманлык хисе тоеп. Төньяк таулар-урманнар артында яшәүче кыпчаклардан яу белән алып кайткан Табылдыкны ул барлык кызларыннан-кырнакларыннан артыграк ярата иде. Ул аны дөньядагы барлык хатын-кыздан артыграк ярата иде. Ул үзенең ятагы янына килде, күтәрелгән чыбылдык итәген төшерде. Кол кыз чыбылдык артында күренмәс булгач, ул янә углына борылып карады.

— Нәрсә... углым? — диде ул, тынычланырга тырышып.

Яшь углан, корышкан телен әйләндерә алмыйча, шактый озак тынып торды.

— Синең белән ауга барасым килә, әти, — диде ул төшенке генә.

— Барырсың, — диде ата кеше.

III

Туман[1] каган иң оста, иң дәртле аучылардан санала иде. Ау дигәндә ул ашавын-эчүен дә, йокысын да оныта ала. Шулай да ул бүген алай

---

[1] Туман — тарихи шәхес. Сөн дәүләтенең баш кешесе, ханы, патшасы. Борынгы язмаларда исеме сакланып калган беренче каган. Туган елы билгеле түгел. Үлгән елы — безнең эрага кадәр 209 ел.

ашавын-эчүен онытып торырга булмады. Туңгак алыпны ул аучыларны юлга әзерләргә дип чыгарып җибәрде, ашчыларга иртәнге ашны тизрәк өлгертергә кушты. Барысын да чыгарып җибәреп, өйдә ул үзенең углы белән генә калды. Киенгән арада Албуганың әнисе, туганнары турында, мал-туар турында сорашты. Тәгин углы белән ул ягымлы, йомшак булырга тырышты. Шулай да, үз гомерендә беренче тапкыр, ахрысы, аның янында читләшү сыман бер сәер тойгы кичерде. Табылдык инде икенче якка чыгып киткән иде. Ләкин ата кеше, әлерәк кенә булган нәрсәне яңадан күз алдына китереп, тагын бер мәртәбә ятак ягына карап алды.

Иртәнге йомышларын йомышлап, киемнәрен алыштыргач ул кымыз эчеп куйды, дөрләп янган учак янына килде, углына да кымыз бирде, аны да учак янына чакырды. «Күңеле булсын — бүләк итеп бирергә кирәк сөенчегә»,— дип уйлады ул бераздан йомшый башлап. Ләкин мондый йомшаклыкка үзе үк каршы төште: «Иртәрәк әле»,— диде үз-үзенә. Аннан соң бүген изге ау көне. Ау эшенә хатын-кыз кысылмаска тиеш.

Алар шулай учак янында вакыт уздырдылар. Яшь углан, туңган кеше сыман, кулларын җылытыштырды, ата кеше учактагы утыннарны әвеш-түеш китерде. Ике арада уңайсызлык барлыкка килгәнен икесе дә сизеп утырдылар.

— Син, углым, кайсы якка басарга уйлыйсың? — диде ата кеше, сүз югында сүз булсын дигәндәй.

— Көньякка, әти!

— Басарсың.

— Алайса мин китим, әти? — диде Албуга, урыныннан кузгалып.

— Китмә, минем белән ашарсың,— диде каган, ләкин, нидер уйлап, болай гына әйтеп куйды: — Китәсең килсә, кит,— диде.— Аучы кеше аучылар янында булыр инде ул.

Яшь углан аның ни өчен шулай тиз арада кире уйлавын бик дөрес сизенде — әтисе бит иртән үзенең якын кырнаклары белән генә ашый! Кызарынып, аяк-кулларының авырлыгын тоеп ул ишеккә юнәлде. Әйе, әтисе белән аның арасына нидер, кемдер үтеп керде. Моның кем яисә нәрсә икәнлеген аңлау өчен иң яхшысы үзең генә калырга кирәк иде. Ишектән чыгып китәр алдыннан ул шулай да түзмәде, артына — учак ягына түгел — биек, калын чыбылдык ягына борылып карады. Анда беркем юк иде. Кол кызның чыбылдык ярыгыннан карап калуын ул, билгеле, күрә алмады.

Аучылар тышкы бөҗра читендә, киң яланда җыелырга тиешләр иде. Атасы өеннән чыккач та тәгин углан туры шунда — аучылар җыелышырга тиешле урынга ашыкты. Ул килеп җиткәндә инде төрле яктан атлы, кораллы ирләр туплана башлаганнар иде.

Иң элек шонкарчылар җыелып бетте. Барлыгы алар утыз кеше иде. Шонкарчылар яшел белән тышланган озын тун, башларына — кара төлке тотылган, ак белән тышланган очлы бүрек кигәннәр иде. Иңбашларына аларның тырнаклары, томшыклары бәйле бөркетләр утыртылган иде.

Шонкарчылардан соң туктаусыз алга ыргылган йөнтәс баракларын[1] көчкә тыеп, үзләренә билгеләнгән урынга этчеләр җыелды. Алар да барлыгы утыз кеше иде, барысының да өс-баш киемнәре бер төсле: кызгылт-сары белән тышланган озын тун, киң кара билбау, башларында — кызыл төлке тотылган, сары белән тышланган колакчынлы бүрек иде.

Шонкарчылар яланның — көнчыгышына, этчеләр көнбатыш ягына тезелделәр. Сөңгечеләр көньякка җыелды. Аларга кушылыр алдыннан

---

[1] Барак — ау этләренең көчле бер токымы.

Албуга ашады, киемнәрен алыштырды, кулына сөңге алды. Сөңгечеләр йоны тышка каратып тегелгән кыска тун кигәннәр. Алар барысы да диярлек кыскарак буйлылар, киң күкрәкле, нык беләкле кырыс ирләр. Болар яхшы аучылар гына түгел, болар яхшы сугышчылар да иде.

Сөңгечеләр янында тәгин угланны Туңгак алып үзе каршылады.

— Каганның боерыгы шундый — ул сезнең белән барачак, — диде Туңгак алып, аңлатырга кирәк табып.

Сөңгечеләр тәгин угланга — калку буйлы, таза, ләкин бик яшь угланга беренче кат күргән кебек гаҗәпләнеп карадылар. Аларның усал, сынаулы, хәтта мыскыллы күз карашын тоеп, Албуга кызарынгандай итте, сөңгесен кысыбрак тотты.

— Кабан дуңгызы эчен айкасын диде микәнни каган?

— Марал таптап китсен диде микән әллә? — диештеләр ачулы ирләр, ризасызлык белән.

— Карга күтәреп китсен дигәндер! — диде кемдер усал итеп.

Монысы инде яшь угланның яңагына китереп суккандай булды.

— Юк! — диде ул кычкырып. — Мин барыбер сезнең белән барам!

Бу бераз гына балаларчарак килеп чыкты. Тавышы да бик көчсез булып, чәрелдәвек булып яңгырады. Шулай да сөңгече ирләр тынып калдылар — тәгин углан белән сүз көрәштерүнең әле беркайчан да изгегә юралганы юк иде.

— Барсын әйдә, барсын... үзе теләгәч, — диделәр икенче яктагы ирләр, аны яклаган булып.

— Тезелегез! — диде Туңгак алып сөңгечеләргә.

Сөңгечеләр, һәркем үз урынын белеп, бер сафка тезелде.

— Кая телисең, шунда бас! — диде Туңгак алып тәгин угланга.

Албуга «карга күтәреп китсен» дигән ирне күрмәсә дә, аның кемлеген чамалап калган иде. Ул әлеге ир турысына борылды һәм күрәләтә бер үртәү, киреләнү белән:

— Мин аның урынына басам! — диде.

Барысы да төртеп күрсәтелгән ир ягына борылып карадылар һәм барысы да диярлек «ах!» итеп җибәрде. Хәтта Туңгак алыпның да йөзенә аптырау билгесе чыкты. Тәгин углан төртеп күрсәткән ир атаклы сөңгече, атаклы сугышчы Салчак алып иде. Тезмәдә аның урыны уңнан санаганда уникенче — шуңа күрә дә ул сөңгечеләр арасында иң бәхетлесе иде.

Салчак алып агарынып китте, нидер әйтмәкче булды, нидер эшләмәкче булды. Ләкин берни әйтә дә, эшли дә алмады. Мыек чылгыен селкеткәләп, авызын кыйшайтып, уйлангандай итеп торды да, кинәт кенә юашланып, килешеп:

— Ярар, — диде. — Мин сиңа ачуланмыйм... син дә миңа ачуланма, тәгин углан.

Шундук ул тезмәдән алга чыкты, читкә китеп барды.

Сөңгечеләр каршысына — төн ягына укчылар тезелде.

Ул арада аучылар янына каган үзе килеп җитте. Аучылар, каганны котлап, барысы да бер авыздан:

— Алас! Алас![1] — дип кычкырдылар.

— Аман булсын изге көн! — диде аларга каган.

Каган аучыларга якынрак килде, тезмәдәге ирләрне, аларның коралларын, киемнәрен, этләрне, бөркетләрне берәм-берәм күздән кичерде. Сөңгечеләр янында ул озаграк тукталды. Салчак алыпның ятим бала кебек бер читтә торуын ул күрми калмады, билгеле. Уникенче урында үз улын күреп ул гаҗәпләнгәндәй итте. Шул ук мәлдә аның күне-

---

[1] Алас — борынгы төркиләрдә исәнлек теләүне белдергән эндәш сүз. «Алас» шулай ук күккә, аллага ялваруны да аңлаткан һәм хәзерге «Ура!» мәгънәсендә дә килә алган.

лендә яңадан ят, теге сәер тойгы калкып чыкты. Өлкән углы Албуга аңа тагын атасының биләмәсенә, беркем кулын сузмаска тиешле ящерен биләмәсенә сорамыйча аяк баскан шикелле тоелды.

— Сине кем монда куйды, улым? — диде ул тыелып кына.

— Мин, бөек каган! — диде Туңгак алып ашыгып.

— Мин сезнең белән туйга бармыйм, ауга барам,— диде каган. Туңгак алыпның бу эшен тупламыйча.— Салчак алыпны үз урынына куй. Син, улым, минем янда булырсың.

Атасының мондый карарына тәгин угланның хәтере калды. Ирләр арасында атасы аны — үз улын, тәгин улын хур итте, мыскыл итте сыман тоелды. «Әти, син үзең әйттең ич!» дип кычкырасы килде аның. «Мин сиңа сөенечле хәбәр китердем!» — дип тә әйтәсе килде. Ләкин ул берни әйтә алмады. Атасы каган белән телләшергә ул әле бик кечкенә иде.

— Ярар, әти,— диде ул, үпкәсен эченә йотып.

IV

Аучылар барлыгы йөз егерме кеше булды. Алардан тыш төп-төгәл мең кешелек каралар җыелды. Болары төрле эшчеләр, сугымчылар, ашчылар, өйчеләр иде. Беренче ауга, каган авына шуннан да азрак яисә күбрәк кеше алынмый.

Иң алдан аучылар китте. Алардан бераз калышып каралар кузгалды. Алар көнчыгышка карап бардылар. Арттан бик үк көчле булмаган салкын җил исте. Югарыга күтәрелгән саен кечерәеп күренгән аксылсаргылт кояш яктысында, бер болытсыз чалт аяз күк йөзе астында иксез-чиксез дала җәелеп ятты. Йөзләгән, меңләгән тояклар таптавына җавап итеп каты җир өсте гүләп-дөпелдәп торды.

Кояш төшлеккә җиткәнче алар шактый кызу бардылар. Кояш түбәнәя башлаганда аучылар тирә-ягында тәбәнәк таллар, карама куаклары, камышлар үскән елга буена килеп чыктылар. Аркача дип аталган бу елга моннан ике көн ераклыктагы Кара-тау арасындагы Кылычкыя төбеннән, куе урман арасыннан агып чыга иде. Бу тирәдә ул тигез җирдән җәелеп, тынычланып ага һәм монда инде аның ярлары да текә түгел, агымы да кискен, шау-шулы түгел иде. Елганың чит-читләрен бүген төнлә юка боз элпәсе каплап алган иде.

Аркача буенча Туман каган бераз туктап тын алырга булды. Сөңге сабы белән төрткәләп ул бозның ныклыгын тикшереп карады. Боз әле юка иде. Туман каган Аркачага беренче корбан бирде — юлда килгәндә үзе атып алган киек каның үзе тишкән бәкегә тамызды. Башкалар да юлда очраган беренче суга корбан бирделәр: берәүләр суга берәр кисәк пешкән ит я булмаса берәр чеметем кипкән эремчек ыргыттылар, икенче берәүләр киемнәреннән җеп, йон ише нәрсәләр өзеп ташлады.

Шул эшләрне башкаргач, аучылар яңадан атларына атландылар, уңга борылдылар да, елганың сул як яры буйлап көньякка таба кузгалып киттеләр. Урдадан чыгу белән көньяк-көнчыгышка карап китсәләр, турыдан алар таулар янына тизрәк барып җиткән булырлар иде. Ләкин ул чагында төньяк-көнбатыштан искән җил аларга гел аркан булыр иде һәм Кара-таудагы киекләр дә аучылар килеп җиткәнче качышып беткән булырлар иде. Шуны исәпләп аучылар шулай бормалы юлдан киттеләр дә. Алар көньякка борылу белән, җил дә үзгәрде — ул хәзер арттан түгел, уңнан исә башлады. Әле елга агымына, әле җил юнәлешенә яраклашып, алар бик әкрен бардылар. Ничек кенә барсалар да, Кара-тауның, Кылыч-кыяның алар артына, көнчыгыш ягына барып чыгарга тиешләр иде.

Төнне аучылар елга буенда — тал, карама куаклары арасында үткәрделәр. Ут якмадылар, казан асмадылар — коры-сары белән тамак ялгадылар да, асларына тире, киез кисәкләре җәеп, туп-туры җир өстенә сузылып йокыга талдылар.

Аучыларның эзләренә басып диярлек арттан мең кешелек каралар килде.

Икенче көнне дә алар туктаусыз юлда булдылар. Еракта, каршыда күкселләнеп биек таулар күренде. Моңарчы тип-тигез булган җир өсте әкренләп үзгәрә барды. Әледән-әле түгәрәк калкулыклар, шәрә таш кисәкләре чыгып торган текә ярлар, иске күл урыннары — батынкы үзәнлекләр очрый башлады. Елга ярлары биегәйде, тарайды, кысан ярлар арасында таштан ташка сикереп аккан суның тавышы ерактан ук ишетелеп торды.

Кара-тауга ярты көнлек юл калгач, аучылар елганың уң ягына чыктылар һәм бераз җир көнчыгышка карап бардылар. Көн кичкә авышканда яңадан уңга борылдылар. Кичкә таба әкренәя башлаган җил әле уңнан, әле каршыдан исте. Билгеләнгән урынга — текә калкулык итәгендәге урман буена аучылар кич караңгы төшкәндә генә килеп җиттеләр. Монда алар аеруча сак кыландылар: кычкырып сөйләшү, көлү, тояк тавышлары — барысы да тынып калды.

V

Төптән бер-берсенә кушылып, бер-берсенә берегеп үскән өч биек калкулыкны Өч-тума дип атыйлар иде. Калкулыкларның уртадагысы башкаларына караганда биегрәк тә, зуррак та иде һәм аның түбәсендә җил-яңгырдан ергаланып, шәрәләнеп беткән кара ташлы кыялар тырпаеп утыра. Кылыч-кыя менә шул иде. Төньяк, көнчыгыш итәкләре каен, карагай, карама урманы белән капланган. Көнчыгыштан көнбатышка таба сузылып киткән әлеге тауларның-калкулыкларның төньяк сыртлары арасында үтеп чыга алмаслык тирән чокырлар да, текә кыялар да, аулак урыннар да җитәрлек иде. Елына бер тапкыр — кышның беренче көннәрендә генә ауга килә торган каганнан башка монда беркайчан беркем аяк басмый. Шуңа күрә дә монда барлык төр ерткычлар, киек, кошлар курыкмыйча үзләренә оя ясыйлар, бала чыгаралар, бала үстерәләр иде. Хәер, аларның иреге бер елдан артыкка сузылмый иде.

Аучылар икенче көнне кояш белән бергә тордылар. Каган, ак киезгә тезләнеп, туып килгән яңа көнне котлады. Ирләр, күзләрен ачу белән. Кылыч-кыя ягына карамаска тырыштылар. Бары тик урман, тау ияләренә атап корбан биргәч кенә, курку катыш кызыксыну белән, серле, караңгы агач араларына, тау башларына күз ташлап алдылар, ул яктан килгән көчсез тавышларга колак салдылар. Үзара сөйләшү, урман, кыя ягына бармак төртеп күрсәтү тыелды.

Аучылар ашаган-эчкән арада көнчыгыш яктан күп санлы каралар килеп җитте. Алар төнне ачык далада, Өч-тумадан шактый еракта уздырганнар иде. Каралар килгәч Туман каган йола буенча, бөтен ау эшен Туңгак алыпка тапшырды. Каравыл агасы Туңгак алып, «ау агасы» дип атала башлады. Ауда һәркем бары аңа гына — ау агасына гына буйсынырга тиеш иде. Каган, башкалар кебек үк, атка атланды, кулына сөңге алды. Ау агасы Туңгак алып атын җитәкләп аны бүген төн кунган калкулык итәгенә алып китте. Шунда ул аны ачыграк, биегрәк урынга куйды да, үзе дә атка атланды һәм ау багаларына кыска-кыска боерыклар бирде. Боерык алгач, ау багалары үз кешеләрен тиешле урынга алып китә башладылар.

Иң элек өч йөз кешелек куркытучылар кузгалды. Алар, атка атланган килеш, тавыш-тынсыз, тик шулай да кызу юртып, сулга — Өч-туманың көньяк итәге ягына юнәлделәр. Алар, ачык җирдән барып, калкулыкларны көньяктан әйләндереп алачаклар. Шуннан соң, бер-бер артлы тезелеп барган килеш, тезмәне өзмичә, буташтырмыйча, уңга борылачаклар һәм шулай итеп Өч-туманың көнбатыш ягына, җилле ягына — далага барып чыгачаклар.

Өч йөз кешелек куркытучыларның иң арттагы кешесе калкулык сырты артында күздән югалгач та, уң яктан алга таба тагын өч йөз кешелек икенче төркем кузгалып китте. Алар, агачлар арасына кермәскә тырышып, дала буйлап шулай ук көнбатышка таба юнәләчәкләр. Алдан билгеләнгән урында — Өч-туманың аргы ягында, ак ташлары күренеп торган тирән чокырлы Коры елга башында — җил сындырган ялгыз тирәк янында ике төркем бергә кушылачак. Алар бергә кушылу белән, Өч-тума боҗра эчендә калачак. Куучылар, атларыннан төшеп, бик каты кычкырып, шау-шу ясап, барлык киекләрне, ерткычларны көнчыгышка — каган басып торган якка куачаклар. Шул чагында...

VI

Каган янында калган кешеләр шактый озак көттеләр. Беркем берни сөйләшмәде. Бары тик якындагы агач араларын күзәттеләр дә, тирә-яктагы тавышларга колак салдылар.

Шулай түземсезләнеп көтеп торганда, биек агач башына менеп кунаклаган яшь бер углан, ныгып җитмәгән чәрелдек тавыш белән:

— Күренә! — дип кычкырды.

Күп тә үтмәде, алда, кара урман белән капланган калкулыклар артында аяз күккә төтен баганасы күтәрелде. Бу исә ике төркем бергә кушылды дигәнне аңлата иде.

Аучылар урыннарында кузгалышып куйдылар. Шул ук вакытта диярлек сул якта, калкулык артында сузып-сузып ана болан мөгерәгәне ишетелде. Аның тавышы тынарга да өлгермәде, якындарак аңа бога болан җавап бирде. Бу, билгеле, чын болан тавышлары түгел иде. Бу — ике тезмәнең бергә кушылуын белдереп, барлык куркытучыларга, барлык аучыларга җиткерелә торган шартлы хәбәр иде.

Шартлы хәбәр алынгач та әле каган янында калган аучыларга озак кына көтәргә туры килде. Кешеләрнең киеренкелеге соңгы чиккә җитте. Каган үртәлә, тынычсызлана башлады. Ау агасы билгеләгән урынны яратмыйча ул икенче урынга да күчеп карады. Ау агасы куйган урыннан кузгалырга ярамаганлыгын исенә төшереп яңадан элекке урынына барып басты. Урын сайлау анда үзеннән-үзе каушау тойгысы гына уятты.

Урман ягында көчсез генә эт өргән тавышлар ишетелү белән, барысы да сагаеп калдылар. Эт өргән тавышларга тоныкк кына булып агач шакылдаткан, кычкырган, чинаган тавышлар өстәлде. Бу тавышлар әле еракта килә, ләкин шулай да алар әнә киләләр инде!

Еракгагы шау-шуларга колак салып торганда, якында гына, куе урман арасыннан, агач ботакларын сындырып, зур ана болан атылып чыкты. Аның якын-тирәдә генә ашанып йөргән чагы булгандыр ахрысы, — авызына капкан агач сабагын ул чәйнәп тә бетерә алмаган иде. Күзе-башы акаеп, ул туп-туры кешеләргә таба чабып килде. Ләкин тиз арада аларны күреп алды, туктагандай итте һәм, башын бик каты чайкап, уңга борылды да әле генә куркыныч булып тоелган урманга кире кереп китмәкче булды.

«Мин атмыймын — җәям ата, мин үтермим — ук үтерә!» дип пышылдады Туман каган, нык тартылган керешне ычкындырып.

Агулы ук тимере боланның туп-туры күкрәгенә, йөрәк турысына барып тиде. Ук сабы тыгыз ит эченә яртылаш диярлек батып керде. Болан исә аптырап туктагандай итте, алгы аякларын күтәрде һәм, үзенә һөҗүм итүчеләрне таптарга, сөзәргә, изеп китәргә чамалап, яландагы кешеләр ягына бер укталып алды да, үзенең куркыныч кешеләрдән көчсезлеген исенә төшереп, тагын ышанычлы урман ягына ыргылды. Шулай да ул ерак китә алмады — әллә абынып, әллә авыртуга түзә алмыйча, сөрлегеп китте һәм гөрселдәп җиргә ауды. Куркып, ашыгып янә алгы аякларына басты һәм, соңгы көчен җыеп, як-якка чайкалып, тагын берничә адым урманга таба — үзен коткарырга тиешле урманга таба йөгерде.

Аңа башка ук атучы булмады — ул барыбер егылачак иде. Кешеләр, аның үлеменнән тәм тапкандай, аны бары читтән күзәтеп кенә тордылар. Үзен үлемнән саклап калырга тиешле агачлар арасына килеп керү белән, зур гәүдәле ана болан яңадан егылды һәм шуннан соң инде аягына баса алмады.

Ауда беренче киекне каган үтерергә һәм үтергәндә дә бер генә ук атып үтерергә тиеш иде. Болай булганда ау яхшыга юрала. Болан җиргә егылгач та Туман каган елмаеп куйды. Якындагы ирләр, котлап, хуплап, җиңелчә шаулашып алдылар. Ау агасы каганны шулай ук беренче табыш белән котлады һәм, йолага туры китереп, агач күбәтә белән аңа кымыз бирде. Туман каган кымызны эчте, күбәтәне җиргә ташлады һәм шуның белән аның беренче авы, беренче атуы төкәнде дә. Моннан соң инде ул турыдан-туры ауда катнаша алмый иде: үз алачыгында утырып, я булмаса атка атланган килеш, ул ауны читтән генә күзәтергә тиеш. Ләкин күптән инде каганнар бу борынгы йола белән исәпләшмәскә тырышалар иде. Туман каган да үз алачыгына кереп утырырга ашыкмады.

Болан егылган җирдән берничә адым читтәнрәк, агачлар арасыннан көтмәгәндә аю атылып чыкты. Аның килеп чыгуын кешеләрдән элек атлар сизеп алдылар. Сизеп алдылар да, куркышып як-якка тартылып куйдылар. Ау агасы, ау башланганлыгын белдереп, быргы уйнарга боерды. Быргычы быргысын кычкыртып өлгергәнче Туман каган атын урманга таба борды, кулына сөңгесен алды һәм быргы тавышы яңгырап киткәндә генә, арт аякларына басып, үкереп килгән ерткычка саллы сөңгесен тондырды. Аю гөрселдәп җиргә ауды.

Ау агасы янындагы быргычының тавышын як-яктагы башка быргычылар күтәреп алдылар һәм тиз арада урман-таулар арасында, агачтан агачка, таштан ташка бәрелеп, дәртле авазлар яңгырады.

Шулай итеп ау башланды.

VII

Өч яктан да кысыла барган куркыныч боҗра эченнән бер генә ерткыч та, бер генә киек тә үтеп чыга алмады. Алар барысы да, котлары алынып, шау-шу иштелмәгән якка — каган алачыгы торган үзәнгә ашыктылар. Берәр киек, ерткыч, тезмәне өзеп, ачык җиргә чабып чыкса, аны куып кире боҗрага керттеләр. Инде шулай да берәр усалрагы, башсызрагы ераграк чабып китә ала икән, аны барыбер кулдан ычкындырмадылар — я ук атып, я бөркет җибәреп алдылар. Бары тик тәңре углы бүрене генә беркем дә тоткарламады. Бүре ул сөннәрнең изге абалары — ерак туганнары, ата-бабалары санала иде.

Киекне шулай ук теләсә кайда да атмадылар. Аларны ничек тә ояларыннан, качкан җирләреннән куалап ачыграк яланнарга алып чыгарга тырыштылар. Алдан ук билгеләнгән яланнарда, тигезрәк җир-

ләрдә сакта аучылар торды. Сөңгечеләр эре ерткычларны гына үтерделәр, ваграк җәнлекләрне, кошларны укчылар атты.

Аучыларның эзләренә басып диярлек килгән күп санлы эшчеләр, сугымчылар үтерелгән, яраланган киекләрне, кош-кортларны шундук тунарга, йолкырга тотындылар — итен иткә, тиресен тирегә аердылар. Икенче берәүләр — ташучылар, җилкәләренә күтәреп, билгеләнгән урыннарга итләр ташыдылар, тире, эчәк-бавыр ташыдылар. Шул ук вакытта башка каралар суына, туңа башлаган итне, тирене, эчәк-бавырны каган алачыгы янындагы үзәнгә китерә тордылар. Сөңгечеләр, укчылар артыннан килгән теркәүчеләр үтерелгән, туналган, ботарланган киекләрне, ерткычларны санап, исәпкә алып бардылар — бер генә табыш та теркәүчеләр күзенә чалынмый калмады, бер генә тире дә, мөгез дә, эчәк-бавыр да юкка чыкмады.

Каган алачыгы янындагы тигез җирдә туналган итләрдән, тиреләрдән таулар өелде.

Баш өстендә, кара болыт булып, кан исе сизгән каргалар очып йөрде. Тирә-якка, карга-козгын каркылдаулары белән бергә, ерткычларның җан ачысы белән чинаган, кычкырган, үкергән тавышлары яңгырап торды.

Туман каган, дәрте кузгалып, шактый күп киек үтерде. Аның мондый комсызлыгына эче поша башлаган ау агасы аңа алачыкка кереп утырырга боерды. Туман каган карышып тормады. Җылы алачык түрендә кымыз эчә-эчә ул ау күренешен күтәрелгән ишек аша гына күзәтеп утырды.

Ау кызганнан-кыза барды. Киекләр, ерткычлар ачык алан ягына күпләп килә башладылар. Тауның көнчыгыш ягында сакта торган аучылар, аларның барысын да атып бетерә алмыйча, әкренләп кире чигенергә мәҗбүр булдылар. Ерткычлар, киекләр, үкереп, чинап, агачлар арасында ары-бире чаптылар. Аюлар, аучылардан качып, агач башларына үрмәләделәр. Тау тәкәләре, ботак-сатакка эләгеп калдылар. Елгыр төлкеләр, аяк асларында качып калмакчы булып, җиргә, үлән арасына постылар. Үзеннән көчсезрәк, куркаграк ерткычлар арасында калып та, беркемне дә бугазлый алмаган карт юлбарыс, җирне-күкне тетрәндереп, бар көченә үкереп җибәрде.

Юлбарыс тавышы ишетелү белән, көчсез киекләр, ерткычлар гына түгел, куркусыз ирләр дә калтырап төште. Ярсып ашкынган йөрәкләр кысылырга мәҗбүр булды, ычкынырга әзер керешләр тукталып калды. Батыр ирләр бер-берсенә карашып алдылар, пышылдап кына дога сүзләре әйттеләр. Бозрада юлбарыс барлыгын белдереп, шундук ау агасына хәбәр бирелде.

Өч-туманы ел буена күзәтеп торган махсус аучылар-сакчылар күптән инде урманда, Кылыч-кыя янындагы чытырманлыкта юлбарыс барлыгы турында хәбәр иткәннәр иде. Шуңа күрә, бозрада юлбарыс булса, аучылар аны атмаска, бары тик каган ягына куалап китерергә генә тиешләр иде. Ауда беренче киекне каган гына үтерә алган кебек, ерткычлар патшасы юлбарысны да бары ул гына үтерә ала иде.

Ау агасы быргы кычкыртып барабан кагарга боерды. Шул ук вакытта ул каган янына кеше җибәрде. Ләкин каган үзе дә бөтенесен ишетеп тора иде. Ул алачыктан атылып чыкты. Аңа шундук атын китереп тоттырдылар, коралларын бирделәр. Аның янына дүрт таза сөңгече басты. Сөңгечеләрнең бишенчесе, исәпкә керми торганы, тәгин углан Албуга иде.

VIII

Каган алачыгы торган үзәннән бер ук чамасы ераклыкта, уң якта, урман бетеп, ачык җир башланган төштә зур гына сазлык бар иде.

Кылыч-кыя төбеннән агып килә торган Аркача суы, шул урынга җиткәч, әйтерсең, кайсы якка агып китәргә белмичә, шулай җир өстенә таралып, җәелеп ята иде. Ул бары әлеге сазлыкны үтеп киткәч кенә шаулап аккан чын елгага әйләнә. Сазлык өсте куе камыш урманы белән капланган. Камышлыкта һәр төрле кошлар, киекләр мыжгып тора иде.

Куркытып ояларыннан, аулак урыннарыннан чыгарылган ерткычларның кайберләре, сыену урыны эзләп, әлеге камышлыкка ташландылар. Ау агасы бөҗра эчендәге юлбарысны да шул якка куарга боерды. Каган да туп-туры камышлык ягына ашыкты.

Урман янында гына ачыклык калдырып, аучылар сазлыкны төрле яктан әйләндереп алдылар. Каган килеп җитү белән, сазлык янындагы бөҗра сакчылары көчәйтелде. Иң алга сөңгечеләр басты, алардан читкә укчылар урнашты, укчылардан да арырак шонкарчылар куелды. Каган үзенең ирләре белән җилгә каршы — сазлыкның көнчыгыш ягына урнашты. Ау белән, яу белән күзе чыккан Туман каганның әле беркайчан да атып тидерми калганы юк иде. Аның әле кулы нык, күзләре үткер. Шулай да, юлбарыс белән очрашканда шаярырга, саксыз кыланырга ярамаганлыгын аңлап, ау агасы аның янына тагын өч-дүрт таза ирне куйды. Тәгин угланның куркыныч урында булуы гына аның бераз эчен пошырды, ләкин ул аңа берни әйтмәде — яшь угланның күңелен кырасы килмәде.

Урман эчендәге шау-шу көчәйгәннән-көчәя барып, камышлыкка таба юнәлде. Әле сулда, әле уңда ярсып этләр өрде. Куркытучылар шак та шок китереп төрле тавышлар чыгардылар, кемнәрдер ачы итеп бар көчләренә чинап җибәрде.

Менә бер заман сазлык эченә күпләп киекләр керә башлады. Коры камыш сабакларын сындырып алар куерак, куркынычсызрак урыннарга омтылдылар. Шул ук вакытта сазлык уртасыннан пырылдап, канатларын сызгыртып үрдәкләр күтәрелеп чыкты.

Күп тә үтмәде, бөтен камышлык куып кертелгән киекләр белән мыж килеп тора башлады. Сазга, камышка күнекмәгән, бер-берсен якында күреп котлары алынган боланнар, тау-тәкәләр ничек тә моннан таярга тырыштылар һәм, саз кырыена килеп җитү белән, туп-туры аучыларга килеп төртелделәр.

Шул чакны аучылар тезмәсе өстеннән көчле җил исеп киткәндәй булды: барысы да, дөньяларын онытып, урман белән сазлык кушылган якка борылып карадылар. Ул яктагы күзәтчеләр, быргы кычкыртып, юлбарысның камышлыкка килеп керүен белдерделәр. Чыннан да, урманга якынрак торган аучылар аның көчле, сиртмәле аякларында җиңел-җиңел сикереп, ала-кола буе белән сузылып, сазлык ягына ыргылуын күреп тордылар. Ерткычлар патшасы алдында тез чүгеп бөтен тирә-як кинәт тынып калгандай булды. Бөҗра эчендәге киекләр, бар кайгыларын, куркуларын онытып, барысы берьюлы шып булдылар.

Камышлыкка юлбарыс кереп күп тә үтмәде, урманнан җәяүле аучылар төркеме килеп чыкты. Куе урман аша, тирән чокырлар, кыялар аша үткән, киек аулап арыган, хәлдән тайган, яраланган, канга баткан аучылар, боерык булганны да көтеп тормастан, сазлык буендагы ирләр янына килеп кушылдылар. Ләкин урманда әле башка аучылар да калган иде.

Анда-монда тоткарланып калган аучылар җыелган арада, ау агасы, атын кызу юырттырып, бөтен сазлыкны әйләнеп чыкты, кемнең кайда, ничек торуын барлады, кайберәүләрне бер урыннан икенче урынга күчереп куйды. Ау агасы яңадан сазлыкның көнчыгыш ягына — каган янына килеп җиткәч, тезмә буенча яңа боерык бирелде. Менә бер заман аргы якта югарыга аксыл-зәңгәр төтен күтәрелде — аучылар коры

камышка ут төрттеләр. Төтен баганалары шулай ук сазлыкның уң ягында да, сул ягында да калкып чыкты. Озакламый бөтен камышлыкны ут-ялкын чорнап алды. Кызу искән җил белән төтен сазлыкның көнчыгыш ягына — каган көтеп торган якка үрләде.

Шашынып, юка бозны шатыр-шотыр ватып ерткычлар төтен алдыннан чаптылар. Атларның, кешеләрнең борыннарына, күзләренә ачы төтен керде, әледән-әле күз алларын төтен каплады. Ләкин беркем дә артка чигенмәде, беркемнең дә кулы кылтырамады. Сазлык янындагы ярты чакрым чамасы озынлыкта коры җир өсте атылган, кадалган, чабылган киекләр белән тулды.

Юлбарыс, уттан, төтеннән качып, ике мәртәбә сөңгечеләр каршысына килеп чыкты. Икесендә дә аны кире куып җибәрделәр. Өченчесендә ул туп-туры Туман каган янына килеп чыкты. Килеп чыкты да, үзенең язмышы кем кулында икәнлеген аңлаган сыман, ат өстендә кыя таудай утырган алып иргә карап, бар көченә ырылдап җибәрде һәм, ни булса да булыр дигәндәй, ярсып алга ташланды. Ул шундый зур иде, шундый куркыныч иде — каган атланган Кура-мал куркып кинәт читкә сикермәкче булды. Ләкин каган аны вакытында тыеп калды. Тезген тоткан сул кулы белән атын тыеп, уң кулы белән ул сөңгесен юлбарысның күкрәгенә турылап тондырды. Сөңге сабының ерткыч күкрәгенә яртылаш диярлек батуын ул үз күзләре белән күрде. Шул ук мәлдә, ул сул кулын бушайткандай итте. Шуны гына көткән Кура-мал читкә ыргылды.

Каты яраланган ерткыч ярсып яңадан аякларына басты, яңадан алга ыргылмакчы булды, ләкин күкрәгенә кадалган сөңге сабы, түң җиргә төртелеп, бары аның ярасын гына тирәнәйтте. Ерткычның төтен тулган канлы күзләреннән чишмә булып яшь акты. Авыртуга түзә алмыйча ул үкереп җибәрде.

Боларның барысы да күз ачып йомган арада булды. Сихерләнгән сыман ирләр юлбарыска карап торганда камышлыкны ярып, бик зур кабан дуңгызы килеп чыкты. Килеп чыкты да, сөңге сыман очлы тешләре белән каршыдагы атның корсагына китереп төртте. Кура-мал шашынып чинап җибәрде һәм алгы аякларын күтәреп, каядыр сикермәкче булды. Юлбарыс аркасында уяулыгын югалткан Туман каган мәтәлеп җиргә барып төште. Шул ук мәлдә төтен эченнән ярсып икенче кабан дуңгызы килеп чыкты.

Ирләр аны күреп алдылар, кычкырып җибәрделәр. Ләкин беркемнең дә каганга ярдәмгә килергә җае юк — Туман каган җиргә ауган аты белән кабан дуңгызы арасында калган иде. Моңарчы бер читтәрәк торган Албуга шул чакны, сөңге сабын ике куллап тоткан килеш, төтен арасыннан килеп чыккан икенче кабан дуңгызы өстенә сикерде. Каушаса, туры чамалый алмаса, аның да этисе янына я булмаса кабан дуңгызы алдына барып төшүе ихтимал иде. Ләкин ул дөрес һәм төгәл чамалады — сөңге тимере, кабан дуңгызының таштай корсагы аша чыгып, таштай каты җиргә төртелде. Яшь аучы егылган ат аша, этисе аша, тигез җиргә барып төште.

Якындагы ирләр барысын да күреп тордылар. Колак төбендә генә мактап кычкырган, гаҗәпләнү белдергән тавышлар ишетелеп китте. Ирләрнең берсе ат корсагын тишкән кабан дуңгызына сөңге ыргытты. Берничә ир, атларыннан төшеп, каганга ярдәмгә ташландылар. Төрле яктан күтәреп алып, аны аягына бастырдылар да, тиз-тиз генә читкә, куркынычсызрак урынга алып киттеләр. Ул арада этисе янына агарынган, коты алынган Албуга килеп җитте.

— Углым! — диде ата кеше, яшь егетне күкрәгенә кочып. — Мин күрдем. Беркайчан да онытмам, батыр углым!

IX

Кояш таулар аша үтеп дала ягына чыккач, ау тәмам булды. Камышлык янды, көлгә әйләнде. Ут шулай ук урман буендагы аерым куакларны да өтеп алды. Шулай да аны ары җибәрмәделәр. Өч-тумадагы барлык киек-җанварлар кырып салынды. Урман-таулар арасы бушап, тып-тын булып калды. Ләкин озакламый анда яңа киекләр, ерткычлар киләчәк. Алар анда үзләренә оя корачаклар, аулак урыннар табып үрчи башлаячаклар. Бит алар монда әле генә кан елгасы акканын белмиләр һәм алар аны беркайчан белә алмаячаклар, чөнки моннан бер генә киек тә, бер генә тычкан, йомран да үтеп чыга алмады. Шулай булгач, мондагы үтереш турында аларга кем җиткерсен?!

Каган алачыгы торган үзәндәге табыш таулары үскәннән үсте. Каралар камышлыктан кәки[1] ташып хәлдән тайдылар.

Иң яхшы итләрне, тиреләрне теркәүчеләр каганга калдырдылар. Кемнең нәрсә, күпме үтерүенә карап, аучыларга шулай ук яхшы иттән, тиредән өлеш чыгарылды. Ау агасына да итнең, тиренең яхшырагы бирелде. Теркәүчеләр, сугымчылар, тунаучылар — ауда катнашкан барлык кешеләр үзләренә тигән өлешне алдылар. Эчәк-бавырны, койрык ише калдык-постыкны коллар бүлеште. Аларга шулай ук нык ертылган, бозылган я булмаса кечерәк, затсызрак тиреләрне дә бирделәр. Монда шулай ук тирә-яктан чин ярлылары да килеп җиттеләр. Аларга аягы сынган, корсагын кабан дуңгызы тишкән үле атларны бирделәр. Сөн колларыннан да фәкыйрьрәк киенгән бу ярлылар ат үләксәләрен шундук ботарлап ташладылар, бүлешеп алдылар.

Ау төкәнү белән, үзән уртасында Туман каганның йөз егерме кеше сыешлы киез өе торгызылды. Батыр аучыларны каган бүген сыйларга, кунак итәргә тиеш иде. Бөек каган, урдадагы сыман, киез өйнең түренә урнашты. Аның уң ягына тәгин углан, сул ягына ау агасы Туңгак алып утырды. Башка аучылар, ярым түгәрәк булып, каршыга һәм ике якка урнаштылар.

Ачыккан, алҗыган ирләр түземсезлек белән аш-су башлануын көттеләр. Пешкән ит китерер алдыннан Туман каган иң зур батырлык күрсәткән ирләргә үз кулы белән буза бирергә тиеш иде. Быелгы ауның беренче батыры кем булыр икән? Ирләр, пешкән иттән бигрәк, шул турыда карар көттеләр.

Беренче сүзне йола буенча, каган түгел, ау агасы әйтте. Ул, билгеле, иң элек каганны мактады. Бер атуда юлбарысны егып салган өчен аны барлык ирләр арасында иң батыры, иң булдыклысы дип атады. Үзен мактаганга каганның күңеле булды. Шулай да ул үзенең аттан егылып төшүен дә, чак-чак кына кабан дуңгызының очлы тешләренә эләкми калуын да оныта алмады. Бу хакта эндәшми калуны ул яхшысынмады. Ау агасыннан соң каган үзе сөйләде.

— Ирләр күреп торды: беренче киекне мин аттым, юлбарысны мин үтердем, — диде ул. — Шулай да ау агасы бер нәрсәне әйтми калдырды. Кабан дуңгызыннан мине кем коткарды?

— Тәгин углан! — диделәр ирләр барысы бер авыздан диярлек.

— Әйе, минем өлкән углым! — диде ата кеше сизелеп торган бер горурлык белән.

— Әйе, Албуга! — диде Туңгак алып та. — Мин әле ул турыда да әйтмәкче идем.

— Менә шул-шул! — диде каган. — Быелгы ауның беренче батыры минем углым Албуга булыр! Беренче бузаны мин аңа бирәм!

Ирләр, яшь алыпны мактап, шау-гөр килеп алдылар. Албуга, кызарынып, шатлыктан ерылган авызын көчкә тыеп, атасы кулыннан ал-

[1] Кәки — ит.

НУРИХАН ФӘТТАХ ◆ СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР ◆

тын кәсә алды. Алды да, елмаеп, горурланып, өй эчендәге ирләргә күз йөртеп чыкты. Аның әле беркайчан да атасы алдында, алып ирләр алдында бу кадәр данга ирешкәне, бу кадәр макталганы юк иде, беркайчан үзен шундый бәхетле итеп тойганы юк иде.

Буза тулы алтын кәсәгә ул бер күз төшереп алды да, каушап, тирән итеп тын алды.

— Әти... бөек каган! Ирләр! Сезнең исәнлеккә эчәм, — диде Албуга. Бирелгән бузаны ул тамчысын да калдырмый эчеп бетерде. Эчеп бетерде дә, инде тагын нишләргә, дигәндәй, тып-тын калып, ирләргә, әтисенә карап тора башлады. Ашчы тиз генә аның алдына кайнар ит китереп куйды. Төрле яктан өзек-өзек сүзләр ишетелде.

— Егылмады!

— Буыны нык! — диештеләр ирләр.

— Булдырды! — диде ата кеше дә.

Ул аңа яңадан урынына утырырга булышты, ашчы китергән табакны аның алдына җайлабрак куйды. Бәхетле яшь алыпны мактап әйтелгән сүзләр әле уңда, әле сулда ишетелгәләп торды. Ләкин бу инде чынында аны мактау да түгел иде, бу бары ата кеше алдында бер ялагайлану да, аннары бер башланган сүзне дәвам иттерү сыманрак кына иде. Андый мактау сүзләре инде яшь алыпның үзенә дә ишетелми башлады. Аның аяк-куллары хәлсезләнеп калды, башы авырайганнан-авырая барды, күз аллары томаланып, өй эчендәге кешеләр әлҗемөлҗе килә башладылар.

«Егылмаска, егылмаска!» диде ул үз-үзенә күңеленнән.

X

Ачыккан, алҗыган ирләр туйганчы ит ашадылар, буза, кымыз эчтеләр. Иң батыр аучыларны каган үзе сыйлады. Йөз егерме аучының барысына да бүләкләр бирелде.

Ашап туйгач күңел ачу башланды. Ирләр шаулашып һавага чыкты. Уртада зур түгәрәк калдырып, түгәрәк эченә учак яктылар. Учак яктысында яшь ирләр көч сынаштылар, көрәш уеннары башлап җибәрделәр. Уеннарның, көрәшләрнең барысы да диярлек ау күренешләрен кабатлады. Көрәштән, уеннан соң биюләр башланып китте.

Казаннарда туктаусыз итләр пеште, бурдаклардан[1] туктаусыз эчемлекләр акты. Уен-көлке, күңел ачу төн урталарына чаклы сузылды. Төн уртасы авышкач аучылар, көндезгедән дә ныграк арып-алҗып, татлы йокыга талдылар.

Икенче көнне, таң атып кояш җир астыннан чыккач та, аучылар тәгәрәшеп йоклап яткан үзәнгә Кара-тау ягыннан килүче арба күренде. Дөяләр җигелгән арбаны ян-яктан, арттан, алдан унлап-унбишләп сакчылар урап алганнар иде. Дөягә атланган малай да, атка атланган ирләр дә, кыяфәтләренә караганда, җунгошеннар булырга тиеш иде.

Өч-туманың көнчыгышка таба сузылган сөзәк итәге өстенә — калкулык сыртына килеп менгәч тә, атлар да, дөяләр дә туктап калдылар. Калкулыкның төньяк итәге сирәк урман белән капланган. Сирәк урман артында, киң үзән уртасында ап-ак булып ялгыз өй калкып утыра иде. Өйне күрү белән, атка атланган ирләр үзара сөйләшеп алдылар, арба эчендәге кемгәдер нәрсәдер әйттеләр.

Өсте ябулы арбаның алгы ягындагы кечкенә тәрәзәдән киң битен күрсәтеп, ниндидер ир кеше алга, үзәнгә карады. Сакчы ирләргә ул нидер җавап кайтарды. Ирләр тагын үзара сөйләшеп-киңәшеп алдылар.

[1] Бурдак — сөт, су, кымыз ише сыеклык өчен кулланылган тире савыт (капчык).

Бераз көтеп торгач, арбадагы кеше кузгалырга боерды. Кузгалып киткәнче ирләрнең берсе арба тәгәрмәчләренә арттан юан гына агач кыстырды — тауга түбән төшкәндә дөяләр чабып китеп, арбаны аударулары бар иде.

Юлчылар калкулыктан, сирәк агачлар арасыннан тыелып кына, ашыкмыйча гына төштеләр дә тигез җирдә туктап калдылар. Шул чакны аларның күз алдында искитмәле күренеш ачылды: җир өстендә, сүнгән учак тирәсендә, баш-аяк килеп, төрлесе төрлечә бөгәрләнеп я булмаса аяк-кулларын сузып җибәргән килеш, аучы ирләр йоклап ята иде. Шундый ук аунап-йоклап яткан ирләр арырак та күренә — әйтерсең, әле генә монда бик каты сугыш булган да, җиңүчеләрме, җиңелүчеләрме — үлекләрен җыеп алырга да өлгермичә, каядыр китеп барганнар. Якын-тирәдә бер генә сак та, бер генә уяу кеше дә күренми иде.

Арба эчендәге кеше, тәрәзәдәге пәрдәне күтәрә төшеп, тирә-якны күзәтеп барды. Җирдә яткан кешеләргә бик үк якын килеп җитмичә туктарга кушты. Арба туктагач ул арткы киезне күтәреп җиргә төште. Урта буйлы, бик таза һәм бик ямьсез бер кеше иде ул. Зур башлы, киң маңгайлы һәм тумыштан ук кыешрак авызлы бу ир уртасы кайсыдыр ягы белән түбет кешесен дә, җунгошенне дә, шулай ук сөн кешесен дә хәтерләтә иде. Ләкин ул чынында түбет кенә түгел, җунгошен генә дә, сөн генә дә дә түгел иде бугай. Күз карашы аның нурсыз, котсыз һәм комсыз иде. Авызының кыеклыгы, иреннәренең калынлыгы аның шөкәтсезлеген тагын да көчәйтә сыман. Аннары аның йодрыклары бик зур иде. Менә шул зур, авыр йодрыклары һәм күрер күзгә ямьсез кыяфәте булмаса, ул алай башкалардан бик үк аерылып та тормас иде, ахрысы.

Арбадан читкәрәк китеп, йодрыкка йомарланган куллары белән биленә таянган килеш ул озак кына каранып торды. Ялгыз ак өйдән арырак ул уңда-сулда тагын ашык-пошык корылган кечерәк алачыклар, киез өйләр күреп алды. Тагын да арырак исә, җир өстендә кара тап булып яткан сазлык күренде. Елга буенда еракта бик күп атлар утлап йөри, шунда ук кешеләр дә бар иде. Димәк, барысы да йоклап бетмәгәннәр.

— Менә шундый инде алар — хулар... — диде ул үз янындагы ирләр белән сөйләшкән сыман итеп. — Туярларын белмичә ашыйлар-эчәләр дә, хайван кебек йокыга авалар. Шуннан башка аларны берни кызыксындырмый. Сөңге ал да берәм-берәм када да чык!

— Алар уянмыйча анда бару килешмәс, — диде сакчы ирләрнең берсе.

Алар чин телендә сөйләштеләр.

— Агачлар арасында көтеп торырга туры килер, — диде ямьсез ир.

Дөягә атланган малайга ул борылырга кушты. Үзе, арбага утырып тормастан, җәяү генә китмәкче булды. Атларыннан төшкән ирләрнең берсе тәгәрмәчләргә кыстырылган күсәкне тартып алды һәм зур, тупас тәгәрмәчле арба, тешкә тия торган ачы тавышлар чыгарып, борыла башлады. Бу көтелмәгән шыгырдау тавышы иртәнге тынлыкка чумган тирә-якны сискәндереп җибәрде.

Якында гына зур таш артында йоклап яткан кораллы ир кинәт башын калкытты. Кызыл саплы, тимер башаклы сөңгесен ул ике куллап кочаклап тоткан иде. Ул, ахрысы, төнлә торгак булган. Сөңгесен кулыннан ычкындырмыйча шундук аягына басты һәм якында гына кораллы ирләрне, җитмәсә чин кыяфәтендәге ирләрне күреп бар көченә кычкырып җибәрде.

Йокылы-уяулы килеш аның бик нык коты алынган иде бугай. Кычкыра-кычкыра ул артына чигенде дә, борылып йөгерергә үк тотынды.

Бөтен үзән берьюлы диярлек башын калкытты. Аннан-моннан арба ягына уклар очты.

Атлы, кораллы ирләр тизрәк агачлар арасына кереп яшеренергә тырыштылар. Зур йодрыклы ямьсез ир куркып җиргә егылды.

Аның янына кораллы сөн ирләре йөгереп килде. Бил каешыннан тотып аны җирдән торгыздылар, аягына бастырдылар.

— Исәнтәй ич бу! — диде сөннәрнең берсе шаккатып.

— Исәнтәй, исәнме? — диде икенчесе күләргә чамалап.

— Исән, исән! — диде Исәнтәйне бил каешыннан тотып торган ир. Исәнтәйнең бөтен тәне дер-дер калтырана иде. Кораллы ирләр алдында ул шулай да елмаймакчы булды. Ләкин елмаю барып чыкмады — ачылган эре тешләре, бер-берсенә тиеп шак-шок килде дә, кыек авыздан «ы-ы...ыгы!..» дигән мәгънәсез авазлар гына ишетелде.

XI

Кичтән күпме генә эчмәсен, төннең кайсы вакытында гына йокларга ятмасын, Туман каган иртән барыбер кояш белән бергә тора һәм, борын-борыннан килгән ата-баба йоласын бозмыйча, яңа көнне котларга чыга иде. Ләкин бу бары урдада чакта гына — тыныч, көндәлек тормышта гына шулай. Урдадан читтә төн кунарга туры килгәндә ул еш кына үзенең күп төрле йолаларга бәйле икәнлеген онытып җибәргәли иде. Башкалар кебек ул да бии, җырлый, кайчагында хәтта куркыныч уеннарда, ярышларда да катнаша иде.

Кичәгенәк ул алай бернинди уенда, җырда-биюдә катнашмады — көндез бик арыткан иде. Үзенең үлемнән котылу сөенеченнәнме, юлбарыс атып алу куанычыннанмы, үз алдына йомылып, басылып ул берөзлексез буза эчте. Шул ук вакытта ул үзенең тәгин углы турында да уйланды. Элеккегә караганда ныграк ярату белән, якынлык тойгысы белән уйланды. «Урдага кайту белән Табылдыкны бүләк итеп бирәм!» — диде ул үз-үзенә, билгеле бер карарга килеп. Аның өчен шуннан да зур бүләк юк та, булмас та. Үзенне үлемнән саклап калган углына бер кыз жәл булмас. Куансын, күңеле булсын. Инде яше дә җиткән — озакламый болай да өйләнергә тиеш.

Утыра-утыра аның — ата кешенең — хәзер үк батыр углы өчен берәр төрле изгелек эшлисе килә башлады. Ничек итеп күңелен күрим икән дип уйлангалап утырганда ул кинәт Албуганың йоклап киткәнен күреп алды. Каган аны тышка саф һавага алып чыгарга, алай да уянмаса, урынга илтеп салырга кушты. Тәгин угланны ирләр күтәреп тышка алып чыктылар, уятып карадылар — ауда шундый зур батырлык күрсәткән яшь алып берни белми йоклавында булды. Аны яңадан өйгә кертеп урынга яткырдылар.

Каган үзе дә озакламый йоклап китте. Кояш чыккан вакытта да ул йоклап калды. Шулай да төнге торгак соңлап булса да аны кереп уятты, җитәкләп диярлек тышка алып чыкты. Каган, иртәнге кояшны котлагач, яңадан урынына барып ятты. Ләкин бер торгач инде яңадан йокыга китә алмады.

Шул чакны өйгә Туңгак алып килеп керде.

— Исәнтәй килгән, — диде ул.

— Ни калган аңа монда? — диде каган.

— Сине күрмәкче була.

— Күрәсем килми!

Туңгак алып тавыш-тынсыз гына ишеккә юнәлде, ләкин ул чыгып җитәргә дә өлгермәде, аны шундук кире чакырып алдылар.

— Кем килгән дисең? — диде каган.

— Исәнтәй... Банхуа... — диде Туңгак алып.

— Ник аны яхшылап аңлатмыйсың? Бар, чакыр!

Өстенә сөннәрнеке кебек озын итәкле тун кигән, биленә киң каеш буган, сул колагына зур алтын алка таккан Исәнтәй-Банхуа, каган өенә килеп керү белән, идәнгә егылды. Туман каган ярым шәрә килеш үзенең биек ятагында утырып тора иде.

— Тор, — диде ул керүчегә.

Исәнтәй тормады, бары башын гына калкытты һәм каганга, иленә-көненә исәнлек-саулык теләде.

— Сөйлә, — диде каган боерып.

Исәнтәй гадәтенчә елмаеп, читләтеп, уратып үзенең урдага баруы, юлда меңә көтмәгәндә каганның үзенә юлыгуы турында сөйләргә керешә.

— Кыскарак тот! — диде каган түземсезләнеп.

Исәнтәй сүзен кыскартмады, бары тик ныграк елмайды да башын гына югарырак калкытты. Каганга ул үзенең ниндидер сүз әйтергә җыенуы турында сөйли башлады.

— Бузаң бармы? — диде каган, артык тыңлап торырга тәкате калмыйча.

Исәнтәй, ясалма елмаюын сүндереп, кинәт тынып калды.

— Арбада бар түгел, — диде ул бик нык кайгырып. — Өйдә бар.

— Кызларың бармы?

— Бар. Күп бар! — диде Исәнтәй куанып.

— Кирәгең ни?

— Кызны, бузаны монда китеримме, бөек каган? — диде Исәнтәй чамадан тыш ягымлы елмаеп.

— Китермә. Үзем барып алырмын, — диде Туман каган.

Аның инде күптән шушы Исәнтәйнең оясын үз күзләре белән күрәсе килә иде.

XII

Исәнтәй-Банхуаның атасы Чжао ягында туган, Чжао ягында үскән ярым сөн, ярым түбет кешесе иде. Чыгышы белән дала кешесе булса да, ул инде күптән үз халкыннан аерылган, аның телен, йолаларын онытып бетергән. Үзе шулай җиңел генә җунгошеңгә әйләнә алганга, элекке тамырдашлары, тугандашлары сөннәрне дә ул җиңел генә җунгошеңгә әйләнергә тиешләр дип, сөннәр тулысынча Чжао йортына буйсынырга тиешләр дип исәпли иде. Шунлыктан ул, урман-кырлардагы киекләр кебек, бер урыннан икенче урынга күченеп йөргән сөннәрне бөтен җаны-тәне белән яратмый иде.

Ул яшь чакта Чжао йорты бай иде, көчле иде, Чжао ваны[1] әледән-әле сөннәргә каршы яу чаба, аларның җирләрен басып ала, күпләп-күпләп мал-туарын, кешеләрен кулга төшерә иде. Ул чакларда Исәнтәй-Банхуаның әтисе Банлу Чжао гаскәрендә мең башы булып хезмәт итә һәм иң турылыклы сугышчылардан санала иде.

Шулай бер кышны, сөннәр белән сугышта бик кыен хәлдә калгач, бөтенләй көтмәгәндә аңа, башын саклап, сөннәр ягына чыгарга туры килде. Дөресрәге, сөннәр аны камап алдылар һәм корал ташлап кул күтәрергә мәҗбүр иттеләр. Банлу белән бергә биш йөзгә якын Чжао ире, коралларын ташлап, сөннәргә бирелде. Банлуның җиңелүе аркасында ул сугышта Чжао ваны да җиңелде. Туманның атасы — сөннәрнең ул чактагы каганы Банлуның бу «изгелеген» буш итмәде. Ягымлы, булдыклы, батыр Банлуны ул үзенә якынайтты, аңа үзенең түбет кырнагыннан туган ямьсез генә бер кызын бирде. Кызның бирнәсе итеп, бер көтү мал-туар белән бергә, әсир чжаолардан йөзләп ир бирде.

[1] Ван — дәүләт башлыгы, патша.

Шул ук вакытта аңа илнең төньягында, Тула суының түбән агымында көтүлекләр билгеләде, үзенчә кала корып, җәен-кышын, язын-көзен дигәндәй, балчык өйдә яшәргә рөхсәт итте.

Бер көзне, моннан егерме еллар элек, сөннәр көнчыгыштагы урман кешеләренә каршы яу чапканда, Банлу да үзенең ярты меңлек алае белән каган чирүенә кушылды. Урман кыргыйларына каршы яуда аның ирләре батырларча сугыштылар. Сөннәр җиңде, һәм Банлуның бу яхшылыгын карт каган буш итмәде. Банлу үзен көньякка, таулар арасына күчерүне сорады. Мондагы салкын далага күнегә алмыйм, таулар миңа якынрак диде, картлык көнемдә туган җиремә — Чжаога якынрак җирдә яшисем килә, диде. Туманның атасы карт каган монысына да риза булды. Ул аны Сөн җиренең көньягына — Таштугай үзәненә күчерде һәм шунда аңа балчыктан, агачтан өйләр салып, Чжао йолаларын саклап яшәргә ирек бирде.

Таштугай үзәнендә Банлу бик шәп яшәде. Елына өч-дүрт тапкыр ул урдага барып кайтты, каганга бүләкләр илтте, яу чабарга сөннәргә кирәк булса, бер мең кораллы ирне атка атландырып, каган катына озатты. Еш кына каган аны үзе дә чакыртып ала һәм таулар артындагы Күк асты иленә катнашы булган берәр катлаулы, четрекле эш килеп чыкса, иң элек аның сүзенә колак сала торган иде.

Карт каган үлеп, аның өендәге алтын тәхеткә өлкән углы Туман менеп утыргач, Таштугай үзәне өстендә кояшлы көннәргә караганда болытлы көннәр күбрәк була башлады. Үзенчә кала корып, мал-туар асрап, меңләгән якташларын — җунгошен качакларын коллап, баеп яткан Банлуны Туман каган бик үк яратып җиткермәде. Алтын тәхеткә утыруының беренче көненнән үк ул аңа кырын күз белән карады. Берәр сылтау табып ул аның таш-балчык өйләрен, коймаларын туздыртырга, байлыгын тартып алырга диебрәк уйлаштыра башлады. Ләкин карт Банлу көтмәгәндә үлеп китте. Бар нәрсәгә баш булып аның улы Банхуа-Исәнтәй калды.

Исәнтәй эшне атасыннан остарак башкарды. Иң элек ул яшь каган белән дуслашу, татулашу ягын карады. Моның өчен ул булдыра алганын да, булдыра алмаганын да эшләде. Урдага ул өч-дүрт айга бер түгел, бер айга өч-дүрт тапкыр, кирәк икән — биш-алты тапкыр барды. Һәм барган саен каганга, аның бичәләренә, яраткан кол кызларына-кырнакларына бүләкләр алып барды. Бүләкнең дә әле андый-мондыен гына түгел, теге яктан, Йән, Вәй, Чжао якларыннан чыкканын, затлырагын табарга тырыша иде. Каган да, башкалар да беркайчан бүләктән баш тартмадылар. Урда белән Таштугай үзәне арасындагы салкынлык, шулай итеп, кул белән сыпырып алгандай юкка чыкты куйды.

Каган белән ике арадагы мөнәсәбәтне җайлагач, Исәнтәй үз биләмәсендәге эшләрне җайга салырга тотынды. Барыннан да элек ул атасының элекке якташларын ныклап торып үз кулына алды. Монда кыргыйлар арасында сезне мин якламасам, башка беркем якламаячак, диде, Таштугайдан китсәгез, сөннәр сезне икенче көнне үк тотып ашаячаклар, үзләре ашамаса, этләренә биреп ашатачаклар, диде. Күптән инде Сөн илендә яшәгән, сөн телен, сөн гадәтләрен-йолаларын яхшы белгән элекке җунгошеннәрнең мондый куркытуларга әллә ни исләре китмәде китүен, шулай да әлерәк кенә Чин ягыннан качып чыккан-һәм Сөн илендә үзенә сыену урыны тапкан ярлы-ябагай аның кармагына җиңел генә эләгә торды.

Күп тә үтмәде, Банлу углы Банхуа-Исәнтәй Сөн илендәге Чин качакларының үзенә күрә бер яклаучысына һәм шул ук вакытта алар каның эчүчегә әверелде. Аның барлык эшен «якташлары» эшләде: аның өчен алар көтү көттеләр, җир тырнап иген иктеләр, күлдән, елгадан балык тоттылар. Хатын-кызлар җәен-кышын аның өчен йон эр-

ләп, тула бастылар, тукыдылар, тире-яры иләп кием тектеләр. Ирләрнең күбесе балта эше белән шөгыльләнде — төрле йорт кирәк-ярагы, эш, сугыш коралы җитештерделәр, утын ташыдылар. Артык шауламыйча, кирәкле кешеләре белән генә киңәшеп-серләшеп Банхуа таулар арасында тимер, бакыр ташлар эзләтте.

Җае чыгу белән ул үзенең ирләре, хатын-кызлары җиткергән затлы әйберләрне каганга бүләк итеп тә, сатып та җибәргәләде. Урдага барган саен каганның бичәләре, чибәр кызлары аңа үзләренең вак-төяк үтенечләрен белдерделәр: шундый-шундый нәрсә таба алмассыңмы, диделәр, икенче килгәндә фәлән нәрсә алып кил әле, диделәр. Хатын-кыз йомышын ул аеруча теләп башкарды.

Дала аксөякләренә кирәк булган барлык нәрсәне ул җиңел генә таба алмый иде, билгеле. Кайбер нәрсәләрне аның ышанычлы кешеләре, чик аша чыгып, теге яктан алып кайттылар.

Каган үзе дә, аның якыннары да шома, елгыр Исәнтәйнең мондый эшләрен бик яхшы белеп тордылар. Ләкин Исәнтәйгә аркылы төшәргә, аңа аяк чалырга дигән уй беркемнең дә башына килеп карамады. Киресенчә, аның мондый изгелекләрен хуп күрделәр. Ни өчен дигәндә, бар нәрсәгә өлгер, булдыклы Исәнтәй хатын-кызның гына түгел, ирләрнең дә күңелен күрә белде. Ирләрнең, аеруча Туман каганның күңелен күрү өчен тун, бүрек, итек, корал ише нәрсәләрдән тыш тагын ике генә нәрсә кирәк иде. Кадерле икенең берсе — дөгедән кайнатылган утлы буза булса, икенчесе — утлы бузадан да утлырак яшь кызлар иде. Дөге бузасын Исәнтәйгә ярлы чиннәр кайнатты. Шул ук буй җиткән яшь, чибәр кызларны да Исәнтәй үзенә буйсынган, көн-төн үзенә бил бөккән ярлы-ябагайдан сайлап, җыеп алды. Бөтен Күк асты илендә атаклы Чжао гүзәлләрен аңа кайчагында теге яктан да алып чыктылар: ефәк кебек, алтын савыт-саба, дару, җимеш кебек итеп. Бик кирәк булса, билгеле.

XIII

Олуг кунакны тиешенчә каршылау өчен Исәнтәй тиз арада Таштугай үзәненә кайтып китте. Өч-тума ягыннан Таштугай үзәненә чаклы күп булса бер көнлек юл иде. Атларны, дөяләрне кызулатыбрак барганда, юлны тагын да кыскартырга була иде. Туман каган, Исәнтәйнең үкчәсенә басып бармас өчен, беразга монда тоткарланырга кирәк тапты. Үзе белән кунакка ул бары аучыларны гына алырга булды. Башка барлык ирләргә, караларга кайтып китәргә боерылды.

Исәнтәйнең биек таулар арасындагы таш-балчык-агач каласына каган икенче көнне кояш баер алдыннан гына барып җитте. Исәнтәй аны үз каласыннан ике-өч чакрым читтә, Таштугай үзәне киңәеп, ачык далага килеп кушыла торган бер яланда каршылады. Өстенә ул кызгылт-җирән ефәк белән тышланган яхшы, яңа тун кигән иде. Түбәсе сары ефәк белән капланган ике тәгәрмәчле арбасы янында аның егермеләп атлы-коралы ире тора иде.

Кунаклар килеп җитәргә бер йөз адым калгач ул, арбасыннан төшеп, җәяүләп, ашыгып, каганга таба атлады. Елмаеп, кырыкка бөгелеп иң элек каганның өзәнгедәге каюлы итек башын үпте, аннары атның тезгененнән тотып алды. Сөнчә киенгән, сөнчә коралланган егермеләп ирнең барысы да, атларыннан төшеп, җәяүләп шулай ук кунаклар каршысына килделәр, ирләр атланган атларның алтын-көмеш тәңкәләр, аеллар белән бизәлгән тезгеннәреннән тотып алдылар.

Исәнтәй арбасы торган җирдә әле тагын кемнәрдер бар иде, ахрысы. Туман каган да, башкалар да кичке эңгер-меңгердә аларның кемнәр икәнлеген тиз генә аера алмады. Арба янына килеп җиткәч барысы да аңлашылды. Болар җиргә чүгәләбрәк утырган кызлар төрке-

ме булып чыкты. Яшь кызлар аллы-гөлле ефәк киемнәр кигәннәр, төзәнгәннәр, бизәнгәннәр. Аларның барысы да кулларына кымыз тулы кәсәләр тоткан иде.

Кунак ирләр якынлашу белән кызлар барысы да бердәм булып аякларына бастылар һәм беравыздан диярлек күңелле җыр башлап җибәрделәр. Җырчы кызларның берсе — буйлырагы, сылурагы җырлый-җырлый алга чыкты. Кымызны иң элек Исәнтәй үзе эчте, аннары каганга бирде. Каганның юлдашларын башка кызлар белән башка ирләр сыйлады.

Исәнтәй, мондый очрашуга чиксез куанганлыгын белдереп, каган алдында, уң кул тучи бәк[1] тәгин углан белән каравыл агасы Туңгак алып алдында бишкә бөгелде, бер алларына, биш артларына чыкты, туктаусыз елмайды һәм каушавыннан әле абынып китте, әле туныньң итәгенә басты. Каушамаслык та түгел шул — кунак булып аңа каган үзе килә! Карт Банлу элекке каган белән нинди дус-әшнә булган югыйсә, шулай да беркайчан да каган аңа кунак булып килмәгән. Менә аңа, күктән тәңре үзе төшкән кебек, аның таулар арасында кысылып калган ярлы куышына кунак булып беренче тапкыр бөек каган килә!

Кымыз белән сыйлангач җәяүле ирләр яңадан атларына атландылар. Исәнтәйгә иярләнгән яхшы ат китерделәр.

Алар бераз тигезлектән бардылар да, тар гына елга ярына килеп җиттеләр. Юл яр буйлап китте, аннары, калкулыкка туры килеп, кинәт үргә менә башлады һәм шуннан соң әле түбән төшеп, әле югары күтәрелеп, я булмаса берәр калкулык итәге буенча янтаеп, каядыр көньякка — чүмәлә-чүмәлә калкулыклар арасына таба үрмәләде. Тар юлны бер яктан шаулап-шарлап аккан елга, икенче яктан — таулар кысрыклаган иде.

Тауларның төньяк итәкләре, тау араларындагы чокыр-чакырлар монда да куе урман белән капланган иде. Агачлар арасыннан зур-зур шәрә ташлар чыгып тора. Тау итәкләрендә, тар гына тигезлекләрдә, юл буйларында каяндыр өстән, кыя башларыннан кителеп төшкән өй тәүмәлеге ташлар тәгәрәшеп ята.

Таулар, урманнар белән кысрыкланган тар, караңгы җирләр, ниһаять, артта калды. Шарлап аккан су тавышы да ишетелмәс булды. Үзән киңәйде, ачылды, яктырып китте. Елганың уң ягындагы таулар кинәт кенә бик еракка чигенде, анда — елга аръягындагы таулар, куе үлән үскән киң болыннар, ак болыттай булып утлап йөргән сарык көтүләре һәм киез өйләр күренде.

Исәнтәйнең каласы елганың сул ягына, биек таулар, кыялар белән елга арасында кысылып калган утрау сыман бер шәрә калкулык өстенә салынган иде. Калкулыкны таш-балчык койма әйләндереп алган. Койма эчендә агач, таш өйләр, сырлы чирәп түбәләр. Тау астында, торак турысында елга аша салынган агач күпер. Елганың ике ягында да бер-берсенә сыенып, бергәрәк укмашып утырган балчык катыш камыш алачыклар, ярлы киез өйләр... Болар барысы да ерактан ук бик сәер булып, матур да, шул ук вакытта чит һәм ят булып күренде.

---

[1] Тучи — төрки сүз. «Акыл иясе, олуг» дигән мәгънәгә туры килә. Сөннәрдә уң кул тучи бәк һәм сул кул тучи бәк булган. Каганның өлкән улы уң кул тучи бәк итеп билгеләнә торган булган. Уң кул, сул кул — уң як һәм сул як. Борынгы төркиләрдә җир өсте һәм гомумән дәүләт территориясе дүрт якка бүлеп каралган. Шундый бүленеш тәртибе административ һәм хәрби бүленешкә дә күчерелгән. Алгы якның кайда булуына карап, уң кулның һәм сул кулның да яклары төрлечәрәк булган. Борынгы заманда, барлык төркиләрдә көнчыгыш як изге саналган. Өйләрнең ишекләре көнчыгышка караган. Уң кул, уң як бәкләр, гаскәрләр һ. б. дәрәҗәлерәк, көчлерәк саналган.

— Кая салырга белгән торакны! — диде Туңгак алып каганга ярым пышылдап.

— Әйе, теге яктагы кебек... Чиндәге кебек,— диде каган да караңгы чырай белән.

— Беркаян да якын килерлек түгел! — диде Туңгак алып.

— Нидер уйлап, чамалап эшләгән бу моны.

— Туздырырга кирәк бу таш ояны!

— Карап карарбыз,— диде каган.

Хуҗа буларак, Исәнтәй бераз гына алдан барды. Каган белән Туңгак алыпның сүзләрен ул аермачык ишетмәде, шулай да, бик тырышып тыңлаганлыктан, кайбер сүзләрен чалып алды. Аларның нәрсә турында пышылдауларын ул бик яхшы сизенде. Аның йөзе кара янып чыкты. Ләкин андагы үзгәрешне беркем күрмәде дә, сизмәде дә.

XIV

Таш, балчык коймалар белән әйләндереп алынган калкулык астында, юлның ике ягында да олы кунакларны төркем-төркем ярлылар — ирләр, хатын-кызлар, бала-чагалар каршылады. Чуар киемле шундый ук ярлылар тәбәнәк алачыклар арасыннан чыга тордылар, юл буендагы төркемнәргә кушыла тордылар. Кулларын болгап, елмаеп алар котлау сүзләре кычкырдылар.

Атлылар, шау-шулы халык төркеме арасыннан үтеп, үр менә башлады. Ерактан бик үк биек булып тоелмаган койма, янына баргач, шактый калку булып чыкты. Аннары ул балчыктан, таштан гына да өелмәгән — юан-юан карагай бүрәнәләр белән аралаштырып үстерелгән иде. Төньяктагы капканың тигез итеп юнылган, шомартылган юан баганалары яшелгә буялган, капка башына түбә ясалган, түбә өстендә кораллы сакчы өчен кечкенә куыш бар. Калын карагай такталарыннан җыелган капканың күгәннәре бакырдан иде.

Исәнтәй белән бөек каган якынайгач та авыр капкалар шыгырдап ачылып китте. Беренче капка артында, биш-алты адым ераклыкта, икенче капка күренде. Тау башындагы торакны әйләндереп алган койма ике катлы иде.

Алар ишегалдына керделәр. Ике кат койма эчендәге кысан җирдә балчык өйләр, каралтылар калкып утыра. Иң уртага, бердәнбер буш урында йөз кеше сыешлы киез өй корылган иде.

— Монда синең борылыр җирең дә юк икән,— диде каган Исәнтәйгә.

— Бөек каган өчен урын табылыр! — диде Исәнтәй.

— Капкаларны ачык калдырырга, барлык җиргә үз кешеләребезне куярга туры килер,— диде Туңгак алып, караңгы чырай белән як-ягына каранып.

— Шулай эшләрбез! — диде Исәнтәй, бик тиз килешеп.— Мин үземнең караларны, кораллы ирләрне яланга чыгарам, торакны сезгә тапшырам. Сез барыгыз да — минем кунак!

Янындагы кешеләргә ул тиз арада кирәкле боерыкларны бирде. Койма эчендәге кораллы ирләр, кирәкмәгән каралар чыгып беттеләр. Туңгак алып капкаларны, койма өстендәге каравыл өйләрен, барлык аулак җирләрне үзе карап-тикшереп чыкты, һәр җиргә үзенең ирләрен куйды. Койманың тышкы ягына да аның сакчылары басты.

Туман каган ишегалды уртасындагы киез өйгә юнәлде. Кунаклар килүгә өй эчендә бөтен нәрсә җайлап-әзерләп куелган иде. Идәнгә яңа киезләр җәелгән, уртага учак ягылган, өй әйләнә бай бизәкле ефәкләр эленгән иде. Шулай да өй эчендә дала кешесе өчен ятрак тоелган ниндидер ачы-төче исләр дә сизелгәләде. Күрәсең, шундый ят исләрне бетерү өчен өйдә әрем яндырып хуш исле майлар бөркелгән иде.

Хужа каганны түргә, алтынланган биек урынга утыртты. Аның уң ягына тәгин углан утырды. Башка ирләр каган белән тәгин углан тирәсенә, ак киезгә утырыштылар. Табын янында Туңгак алып юк иде— каганның иминлеген саклап ул сакчылар белән тышта, каравылда калды. Аш-су килгәнче кунакларны ялыктырмас өчен, алар янына хужа шундук үзенең кызларын кертте. Һәр ир янына бер кыз утырды. Кызларның күбесе таныш булып чыкты — баягынак далада алар сөн ирләрен җырлап кымыз белән сыйлаганнар иде. Сый монда да кымыздан башланды. Кызлар елмаеп кымыз агыздылар һәм шул арада җыр башлап җибәрделәр.

Ачыккан ирләргә озакламый ит килә башлады. Итне дә кызлар китерде. Кунакларга алар ит бүлеп бирделәр, тегесен-монсын алырга булыштылар. Иттән соң буза килде.

Батыр ирләр туйганчы күңел ачтылар.

Албуганың әле беркайчан да каган этисе белән, алып ирләр белән менә шулай кунакта, эчке туенда утырганы юк иде. Мондый туйларда каган белән бер табактан ашый торган һәм каган үлгәч, аның белән бергә күмелә торган иң якын ирләр генә катнаша ала иде. Бик сирәк булса да, мондый мәҗлесләргә каган шулай ук үзенең иң яраткан угылларын да ала иде. Менә этисе аны беренче тапкыр шундый эчке мәҗлесенә алды. Мондый бәхет теләсә кемгә тәтеми. Албуганың башка ир туганнары мондый нәрсәне төшләрендә дә күрә алмыйлар.

Монда ул үзен ничек тотарга да белмәде. Башка туйлардагы кебек, тын гына, тыйнак кына утырса, ирләр алдында ул үзен җебегән, булдыксыз итеп күрсәтер сыман тоелды. Инде алар кебек — бер ашаганда бер сарык ашап бетерә торган, бер эчкәндә бер чапчак буза эчеп бетерә торган ирләр кебек — алдына килгән бар нәрсәне авызына бушата торса, шулай ук тиз арада җебеп төшәр сыман тоелды. Атасы каган алдында, алып ирләр алдында аның чын ир дә булып күренәсе килә иде, шулай ук ул теге кичтәге кебек исереп егылудан да курыкты. Бүген аңа һич тә егылырга ярамый. Бүген монда бик күңелле булырга тиеш иде!

Аның янына тәбәнәк буйлы, уймактай кечкенә авызлы яшь бер кызны утырттылар. Албуга уңайсызланып кып-кызыл булды. Кызның йөзенә туры карамас өчен күзләрен түбән иде. Кыз исә, киресенчә, вак кына тешләрен күрсәтеп, әледән-әле елмайган булды, калтыранган нәфис куллары белән эчемлек тулы кәсә сузып, яшь егетне эчәргә кыстаган булды. Тәгин угланга ул никтер беренче караштан ук ошамады. Кыз аның үзеннән дә яшьрәк иде бугай. Ул аңа нишләптер бик кызганыч тоелды.

Өлкән углының оялуын, кыюсызлануын ата кеше бик тиз күреп алды. Бу аңа ошады да, ошамады да. «Яратмады»,— дип уйлады ул углы турында. Шул ук вакытта урдада калган Табылдык исенә төште. «Аны уйлый микәнни?» — диде үз-үзенә. Үзенең углы өчен ул нинди дә булса яхшылык эшләргә тиештер ич! Табылдыкны бирсә дә була. Була, ник булмасын! Туктале, монда Исәнтәйнең берәр гүзәлрәк кызы юк микән? Нигә аңа үзенекен өзеп бирергә? Табылдыкка торырлык берәр кызы юк микәнни бу юлбасар Исәнтәйнең?

Кызмача каган үзенең сул ягына утырган Исәнтәйгә борылды да пышылдыйм дип уйлап:

— Минем углыма кыз кирәк, Исәнтәй,— дип кычкырды.

Исәнтәйнең туктаусыз балкыган йөзе сүрелеп калды.

— Мин санадым — җитә,— диде ул.

— Күрмисеңмени — күңелсезләнеп утыра,— диде каган, тәгин углан ягына ымлап.— Аңа син иң яхшысын китер, иң гүзәлен. Илдә югын! Минем углымның күңеле шат булырга тиеш!

— Аңладым,— диде Исәнтәй бик нык уйланып.

— Аңласаң, китер. Мин аңа бүген барлык ирләр «аһ» итәрлек кыз бүләк итеп бирергә тиешмен.

— Бар бер кыз,— диде Исәнтәй, теләр-теләмәс кенә.— Мин аны, бөек каган, синең үзеңә бирергә дип уйлаган идем. Урдага алып барып. Сиңа әйтәсе сүзем дә бар.

— Сүзеңне урдага баргач әйтерсең. Кызыңны китер! — диде каган тыңларга теләмичә.

Исәнтәй китеп барды. Өйдән чыккач та ул каядыр каралты-куралар ягына юнәлде. Монда аның ат абзарлары, утын сарайлары урнашкан. Шунда ук абзарлар, утын сарайлары арасында зур гына яшерен өе дә бар иде. Өйнең ишек төбендә, тышкы якта аның үз кешесе сакта тора иде.

Яшерен өйгә җитәрәк хуҗа кеше адымын әкренәйтә төште. Үзенең ишек сакчылары, койма, капка торгаклары, эшчеләре янына ул шулай качып-посып, сиздермичә генә барырга һәм аларны берәр ярамаган эштә тотарга ярата. Инде чыннан да тота-нитә калса, гаепләнене үтергәнче тукмый иде.

Әле дә ул ишек янына песи кебек кенә атлап килде дә шомарып беткән баганага сөялеп торган коралллы сакчының якасыннан эләктереп алды. Берни сизмәгән сакчы сискәнеп китте, бүре авызына эләккән бәрән сыман, кызганыч бер өн белән шыңшыгандай итте дә шып булды. Хуҗа сакчы ирнең битен үзенә таба борды һәм:

— Йокламыйсыңмы? — дип кычкырды.

— Юк, юк, йокламыйм! — диде сакчы, аклана башлап.

Исәнтәй бәйләнеп тормады — эше кызу иде.

— Килүче-китүче булмадымы? — диде ул усал пышылдап.

— Юк.

— Керүче булмадымы?

— Юк.

— Кара аны, күзеңне ачып тор! — диде хуҗа янап.

Ул әкрен генә ачып ишектән керде һәм шундук кире борылды. Сакчы, сукмакчы була ахрысы дип уйлап, тиз генә кулын бите турысына күтәрде.

— Әйдәле минем белән,— диде хуҗа тыныч кына.

Ишектән кергәч алар тар, караңгы аралыктан бардылар. Ялгыш монда берәр чит кеше килеп керсә, бер-ике адым атлау белән, бәрелеп я маңгаен тишәр, я күзен чыгарыр иде. Үз өендә Исәнтәйгә бернинди ут та, юл күрсәтүче дә кирәкмәде. Башта ул турыга барды, аннан соң сулга борылды, уңга борылды һәм суган-сарымсак, кыздырылган ит-май исе аңкыган, ишеге ныклап ябылмаган аш пешерү бүлмәсе яныннан үтеп китте. Ярым ачык ишек турысыннан узганда ул тар ярыктан эчкә күз ташламый булдыра алмады. Олы яшьләрдәге ир кеше, бил тиңентен чишенеп ташлап, хатынынаң аркасын кашытып тора иде. Исәнтәй, гадәтенчә, аларның сүзләренә дә колак салды.

Аш пешерә торган бүлмәне узып өч-дүрт адым атлагач та, каршы якта алар икенче бер ишек алдында туктап калдылар. Ишектән тар гына тасмадай булып яктылык төшә иде. Исәнтәй, тынын кысып, шактый озак тыңлап торды. Эчтә бернинди тавыш-тын ишетелмәде. Үзе белән килгән коралллы сакчыны хуҗа ишектән читкәрәк бастырды да, пышылдап кына:

— Чакыргач та атылып кер! — диде.

Шуннан соң ул әкрен генә ишек шакыды. Эчтән җавап бирүче булмады. Исәнтәй тагын шакыды, ныграк итеп шакыды. Бераздан кемдер ишек янына килде, үртәлеп, тотлыгып:

— Кем бар анда? Ни кирәк? — дип сорады.

— Бу — мин. Ач әле, син кирәк,— диде хуҗа ягымлы итеп.

Эчтәге ир кеше үзалдына мыгырданып алды, көттереп булса да

ишекне яртылаш ачты. Исәнтәй ялт кына бүлмә эченә күз төшереп алды һәм ярым шәрә яшь хатынның ашыгып юрган астына кереп барганын күреп калды. Җир идәндәге түгәрәк табында ашалып-эчелеп бетмәгән ашамлыклар, эчемлекләр, вак-төяк савыт-саба тора иде.

Ишек ачкан яшь ир кеше дә ярым шәрә иде. Кара чәчле, озынча битле, калку гәүдәле бу кеше, алыптай таза булмаса да, киң күкрәкле, тыгыз тәнле иде. Шуның өстәвенә анда яшь көч, дәрт, омтылыш һәм шулай ук ачу-ярсу ташып торганлыгы сизелә. Төн уртасында ишек ачтыручының хуҗа кеше булуына да карамастан, ул аны үз бүлмәсенә кертергә ашыкмады — бер кулы белән ишек яңагына, икенче кулы белән ишек бавына тотынган килеш ул тынгысыз, усал күз карашын Банхуаның ямьсез, җирәнгеч йөзенә текәде.

— Җиде төн уртасында ир белән хатын яткан өй ишеген ачтырып керү бернинди йолага да, әдәпкә дә сыймый,— диде ул ярсуын тыярга тырышып.

— Үз өемдә үз бүлмәмә керергә ярыйдыр ич? — диде Банхуа йомшак, ягымлы, үтергеч бер өстенлек белән.

Яшь ир кеше мондый сүзгә каршы ни әйтергә дә белми аптырабрак калды. Шул ук мәлдә Банхуа аның ишек яңагындагы шәрә кулын читкә этәрде, эчкә керде. Яшь ир кеше, биек ятакта юрганга төренеп яткан хатынын яман күздән сакларга тырышкан сыман, арты белән чигенеп, түргә узды, һәм керүчедән күзен алмыйча, көтә башлады.

Ачык ишеккә арты белән баскан килеш, авыр кулларын артына яшереп, Банхуа да беравык көтеп, уйлангандай итеп торды.

— Басып керүем өчен ачуланма,— диде ул килешүчән бер ягымлылык белән.— Ашыгыч эш чыкты. Каганның... синең сеңелеңне күрәсе килә.

Ярым шәрә ир кеше кинәт билен турайтты, күкрәген киерде, аптырап, ярсып һәм нидер эшләмәкче булып, хуҗага таба тартылып куйды.

— Хәзерүкме?! — диде ул гырылдап.— Каян белгән ул? Син әйткәнсең аны!

Ялт кына иелеп ул түшәк астыннан, яшь хатынның башы турысыннан хәнҗәр тартып чыгарды.

— Син әйткәнсең, син! — дип кычкырды ул, хуҗага ташланып.

Юрган кырыеннан утлы күзләрен елтыратып яткан яшь хатын кинәт чырылдап җибәрде, куркып каядыр почмакка шуышты. Шул чакта аның өстендәге юрганы ачылып китте. Исәнтәйнең бер як күзе алдында үткер хәнҗәр очы ялтырады, икенче күзе алдында, акылын-зиһенен томалап, тере балыктай ап-ак булып, оятсыз шәрә гүзәллек чагылып калды. Бөтен нәрсә кинәт күз алдында чайкалып китте. Шулай да ул җебеп төшмәде — хәнҗәрле кулны тиз генә тотып алды, кысып алды, каерып алды да, чыгырыннан чыккан яшь ирне җиңел генә итеп идәнгә чүктерде. Андагы көч, андагы җитезлек мондый яшь ирләрнең берсенә түгел, унысына җитәрлек иде.

— Син... кунак... Минем өемдә, минем ашымны ашап, миңа каршы корал күтәрәсеңмени?! — диде ул үтергеч бер нәфрәт белән.

Кунак аның андый сүзләрен генә аңларлык хәлдә түгел иде. Аның күзләре акайган, бөтен тәнен тыелгысыз ярсу һәм өметсезлек калтырата. Банхуа хәнҗәрле кулны ычкындыру белән, ул яңадан хуҗага ташланмакчы булды. Хуҗа сакчыга эндәште. Сакчы бер-ике сикерүдә кунак каршысына килеп тә басты, идәндә яткан хәнҗәрне аягы белән читкә шуыштырды һәм яшь ирнең шәрә тәненә үз хәнҗәрен якын китерде. Яшь ир, каршылык күрсәтеп азаплануның мәгънәсезлеген аңлап, лып итеп идәнгә утырды һәм авызын кыйшайтып, йөзен чытып, тавышсыз гына еларга тотынды.

Почмакка поскан ярым шәрә кызга хуҗа киенергә кушты.

XV

Олы кунаклары янына кызны Исәнтәй юындырып, өр-яңадан киендереп китерде. Алар ишектән килеп кергәндә туйның кызган чагы иде. Ирләр, кызлар, аягүрә басып, күмәк уеннар, биюләр башлап җибәргәннәр. Шуңа күрә Исәнтәй белән ят кызның килеп керүен күрүче дә булмады. Хуҗа, шаулашкан, биегән ирләргә, кызларга орынмаска тырышып, читтән генә түр янына — каган ягына үтте. Шактый кызмача каган нәрсәгәдер күңеле булып, тыела алмый көлеп тора иде.

Исәнтәй, үзенең килүен белдереп, кыюсыз гына тамак кырды. Каган борылды, ләкин хуҗа кешегә ни кирәген тиз генә төшенә алмады — Исәнтәйне нинди йомыш белән чыгарып җибәрүен ул инде онытткан иде, ахрысы.

— Мин сиңа илдә юк кыз китердем, бөек каган,— диде Исәнтәй, түбәнчелек белән баш иеп.

— «Илдә юк» кыз юк ул, Исәнтәй! — диде каган никтер тагын көләргә тотынып.— Илдә юк булса, миндә бар — урдага кил, мин сиңа күрсәтермен. Син ялганчы, Исәнтәй! Шуның өчен, беләсеңме, мин сине нишләтермен? Мин сине үзең салган агач күпердән шаулап аккан суга ыргытачакмын! Син — икейөзле, угры, Исәнтәй!

— Син миңа боердың, бөек каган,— диде Исәнтәй, агарынып.

— Мин синең балчык оянңы туздырачакмын, сатлык Исәнтәй! — дип кычкырды каган Исәнтәй ягына борылып та карамыйча.

Исерек каганның холыксызлыгы турында Исәнтәй ишетеп белә иде.

— Тәгин угланга син күркәм кыз китерергә боердың, бөек каган,— диде ул тагын да барлык батырлыгын җыеп.

— Кая соң ул синең күркәм кызың, ялганчы Исәнтәй? — диде каган, як-ягына каранып.

— Менә ул! — диде Исәнтәй, кызны каганның каршысына ук китереп.

Каган кызга өстән генә, читтән генә бер күз карашы ташлап алды. Кызны ул чыннан да беренче мәртәбә күрә иде һәм ул чыннан да сылу иде бугай. Бөтен өй эченә кычкырып ул яшьләр арасыннан үзенең оялчан углын чакыртып алды. Уен-көлке туктады һәм барысы да түр ягына борылдылар.

— Каган сөйли — мине тыңлагыз! — дип кычкырды Туман каган.— Ирләрем-алыпларым. Улларым-егетләрем! Сез минем якыннарым, сез минем сакчыларым. Сездән башка мин уксыз җәя кебек, башаксыз сөңге кебек. Мин булмасам, сез булмас идегез, сез булмагасыз, мин булмас идем. Минем тәгин углым Албуга булмаса, мин инде тәңре катына очкан булыр идем. Сезнең күбегез күреп торды — үзенең кыюлыгы, куркусызлыгы аркасында ул мине үлемнән коткарды. Шулай булгач, ул сезне дә үлемнән коткарды. Албуга минем иң турылыклы углым. Шуның өчен мин аңа «илдә юк» күркәм кыз бүләк итеп бирәм!

— Яшә, Туман каган!

— Яшә, Албуга! — диделәр ирләр шаулашып, алкышлап.

— Каяле, тагын бер күрсәт әле «илдә юк» кызыңны! — диде каган, Исәнтәйгә эндәшеп.

Исәнтәй ымлап кызга якынрак килергә кушты. Кыз яктыгарак чыкты, башын югарырак күтәрде һәм эчке бер өстенлек белән, үзенең тел тидергесез гүзәллегеннән горурлану, масаю һәм чак-чак кына мыскыл белән, шулай да ягымлы күренергә тырышып, башта каганга, аннары бүтән ирләргә тылсымлы күз карашы йөртеп чыкты.

Каган кинәт тынсыз калды. Йөзендәге, бөтен кыяфәтендәге исереклек галәмәте, батырлык, кыюлык, бөеклек һәм шуның ише ялган нәрсәләр юкка чыкты. «Күз күрмәгән», ләкин күзе күргән гүзәллек алдында, чын тормыш һәм табигать алдында ул бик кечкенә бөҗәк булып кал-

гандай тоелды. Тик торганда аны кинәт очкылык тота башлады. Өй эче әкренләп тына барды, кызмача шау-шу, гамьсез күңелләлек күз алдында юк булды.

Каган, сакланып кына диярлек, углының кулыннан алды, икенче кулы белән шулай ук сакланып кына кызның кулыннан тотты да яшьләрне бер-берсенә якын китерде һәм карлыгып калган калтыравык бер тавыш белән:

— Менә, углым, миннән бүләк сиңа,— диде. Шуннан соң ул Исәнтәйгә борылды һәм, әле генә үзе кычкырган тотнаксыз сүзләре өчен уңайсызланган кебек, әйтеп куйды.— Син, Исәнтәй, кайгырма — балчык ояңа берни булмас,— диде.

Исәнтәй елмайды, шундук бил бөкте һәм каганның тун чабуын үпте. Болай булгач, исән калдың, Банхуа!

— Бүләгеңне алдым, әти,— диде Албуга куанып.

— Алмыйча! Мондый бүләктән баш тартып кара! — диде каган, никтер үкенгән сыман һәм бер дә юктан кычкырып көләргә тотынды.

— Бай бул, әти. Тәңре сиңа күп яшь бирсен, байлык бирсен,— диде углы, гүзәл чин кызыннан күзен ала алмыйча.

— Әйдәгез әле, эчик бер шушы куанычтан,— дип кычкырды каган өй эчендәгеләргә.

Ирләр эчтеләр, кызлар чыр-чу килгән булды. Ләкин күңел ачу элеккечә җанланып китә алмады. Һәркем үзенең янында гына, янәшәсендә генә утырган бәхетле яшьләр турында уйлады. Үзләренең дә шундый гүзәл, шундый бай кызлары булмаудан көнләшеп, кызыгып, күп ирләрнең эче пошты. Исәнтәй кызлары исә — үзләренең дә әлеге ят кыз сыман була алмаулары өчен әрнеп, сыкранып тешләрен кыстылар. Барлык ирләр, барлык кызлар арасында бары бер генә кеше—яшь һәм тәҗрибәсез углан гына беркемнән көнләшмәде дә, бер нәрсәгә сыкранмады да. Бу вакытта бар дөньяда иң бәхетле, иң өлешле кеше иде ул. Бер кызарды, бер агарды углан, елмайды, кашларын җыерды һәм, берни эндәшмичә, бары үзенең бүләгенә генә карап алды. Бу кыз аңа нишләптер бик таныш тоелды. Ул инде аны кайдадыр күргән иде бугай.

Икенче баб

I

Бу якка алар берәмләп тә, икешәрләп-өчәрләп тә чыктылар. Адым саен аларны үлем сагалап торды. Ачлыктан соңгы чиккә җитеп алар агач төпләрендә, юл буйларында ятып калдылар. Кайберләре аларның тирән су чыкканда батып үлделәр, кайберләре озын тарлавыкларда, тау-таш араларында адашып калды. Егылып күзләре йомылдымы, шундук аларны ач бүреләр ботарлап ташлады, ерткыч кошлар чукып бетерде. Чик аша чыгу аларга аеруча кыенга туры килде. Йөрү тыелган төштә күренү белән, бернинди кызганусыз аларга ук аттылар, таш аттылар я булмаса көтмәгәндә китереп сөңге белән тондырдылар.

Ләкин алар бернигә карамыйча, караңгы төннәрдә, коеп яуган яңгырларда, качып-посып, шуышып төн ягына — көн ягындагыга караганда кояш җылырак, ягымлырак балкыган шикелле тоелган серле якка омтылдылар. Көч җитмәслек авыр эшләрдән, кансыз хуҗалардан качып киткән коллар, юлбасарлар, качак сугышчылар — ирләр, яшьләр, хатын-кызлар — куркыныч таулардан да куркынычлырак чик сакчыларын үтеп, тигез җиргә — эрем, кылган ише каты үләннәрдән башка берни үсмәгән, балчык өйләре, калалары, сугарулы дөге кырлары булмаган ачык, иркен дала ягына аяк басу белән, шомлану катыш сөенеп, иң

артларына әйләнеп карадылар һәм, күз яшьләрен түгеп, Олуг Күккә рәхмәтләр белдерделәр.

Җил-кояш кискән тупас йөзле, тупас телдә сөйләшүче сөннәр качакларга ачтан үлмәслек кенә ашарга бирделәр. Шуннан соң аларны тентеделәр, белгән бар нәрсәләрен сөйләттеләр дә ары озаттылар. Туган илләре Җунгода күргәннәрен алар елый-елый сөйләделәр, үлгән, үтерелгән, югалган ата-аналарын, балаларын уйлап, андагы тәртипләргә, андагы түрәләргә ләгънәтләр яудырдылар.

Арада, билгеле, бүтәннәргә охшамаган качаклар да булды. Сорашканга алар теләмичә генә җавап бирделәр һәм дала хуҗаларына күрәләтә ят итеп, хәтта дошман итеп карадылар. Андыйларны сөннәр шундук кулга алдылар һәм ныгытып тикшерү өчен янә ары озаттылар.

Бу якка чыгу белән, качаклар ничек тә үз ватандашлары тирәсенә елышырга тырыштылар. Кайберләре, киресенчә, ялгызлыкка омтылдылар — берәр су буенда куыш корып, балык тотып, шуның белән җан асрарга тырышты. Кайберләре, далага таралып, сөннәргә ялчылыкка керде. Шулай да күпчелек утрак авылларда, калаларда торып калды. Таштугай үзәнендәге Банхуа катавы[1] качакларны үзенә тартып торган шундый калаларның берсе иде. Теге яктан чыккан теләсә нинди качак барыннан да элек Банхуаны белеште. Чик буендагы сөн ирләре моңа инде күнегеп беткәннәр иде.

Барыс елының җиденче ае, егерме сигезенче көнендә, таң алдыннан, Тарлавыкка якын җирдә яшәүче сөн ирләре башкаларга бик үк охшамаган берничә качакны тотып алдылар. Алар барлыгы дүрт кеше иде — өчесе ир, берсе хатын-кыз.

Киемнәренә, коралларына, үз-үзләрен тотышларына караганда, ирләр теге якның чик сакчылары булырга тиешләр иде. Хатын-кызның яшьме, картмы, матурмы, ямьсезме икәнлеген белерлек түгел. Ни өчен дигәндә, ул авырлы иде һәм озын тун итәгеН алгы яктан ямьсез итеп күтәртеп аның таудай корсагы калкып тора. Шуның өстенә аның битебашы иске чүпрәк белән чорналып беткән, чүпрәк аша кызыл кан саркып чыккан иде. Чин хатынының мондый кыяфәтен күргәч, беркемнең дә күңелендә аның кемлеге, ниндилеге белән кызыксыну теләге тумады. Чыннан да, авырлы чин хатыны белән сөн ирләре бөтенләй кызыксынмадылар. Шулай да сөннәрнең берсе болай гына:

— Бите нишләде? — дип куйды.

— Бу минем хатыным. Төнлә урман аша үткәндә битенә ботак төртелде. Канын көчкә туктаттык, — диде тылмач аша качакларның берсе — яшьрәге, чандыррагы.

Үзләренең бу якка чыгуларын алар бик җиңел аңлаттылар. Яуда үләсебез килмәде, үзебезнең башлыкларны үтердек тә качтык, диделәр. Аларның сүзенә беркем шикләнү белдермәде. Качакларга барлык коралларын салып калдырырга кушылды. Алар, бернинди каршылыксыз, бар булган нәрсәләрен — укларын-җәяләрен, пычак, хәнҗәрләрен шундук чыгарып салдылар. Сөн ирләре аларны баштан аяк капшап чыкты. Берсенең куенындагы чакма ташын, икенчесенең кадак сыман очлы тимерен, энәсен һәм шуның ише вак-төяк нәрсәләрен алдылар.

Авырлы хатын, еш-еш мышнап, бер читтәрәк басып торды. Аны тентеп карарга беркемнең дә башына килмәде. Тентегәннән соң ирләрдән сорау алдылар. Чин качаклары әлләни яңалык әйтмәде — алар әйткәнне бу якта инде беләләр иде.

Качакларның барысы өчен дә авырлы хатынның ире — яшь, чандыр ир сөйләде. Сорау алу беткәч ул бик түбәнчелек белән үзенең үтенечен белдерде:

---

[1] Катау — ныгытылган торак, кала.

— Хатынымның хәле начар. Банхуага кадәр озатып куярга кылавыз[1] бирмәссезме? — диде.

Сорау алучы сөн ире — өлкән яшьләрдәге, хәйләкәр кысык күзле йөзбашы Күчәр «Банхуа» исеме чыгу белән тынып калды. «Корсаклы» хатынның Банхуа-Исәнтәй өчен китертелә торган кыз булырга тиешлеген ул инде болай да чамалап алган иде. Качакларның туры Банхуага барырга җыенуларын белгәч, ул моңа бөтенләй шикләнмәде. Исәнтәй белән яшерен килешү нигезендә, аңа бара торган мондый «авырлы» хатыннарны ул бөтенләй тикшерми иде. Моның өчен Исәнтәй аны буш итми.

Хәйләкәр йөзбашы Күчәр сөн ирләре алдында Банхуа-Исәнтәйне сүгеп, мыгырданып алды. Шуннан соң ул авырлы хатынга озак кына карап торды.

— Вакыты җиткәнмени? — диде ул үзен Чәнси дип атаган яшь иргә.

— Вакыты җиткән,— диде Чәнси тылмач аша.

— Ярар, китсеннәр,— диде йөзбашы Күчәр.

Шуннан соң ул өй эчендәге яшь кенә бер иргә — бай киемле, ачык йөзле, алыптай таза угланга күтәрелеп карады.

— Олуг тучи бәк! — диде ул аңа.— Мин сине кылавыз итеп җибәрәм. Егетләрең белән бергәләп бу качакларны Таштугай үзәненә, Исәнтәйгә кадәр озатып куярсың. Шуннан урдага кайтып Туңгак алыпка әйтерсең. Шикле күренәләр болар, үзе яхшылап тикшерер, сорау алыр.

— Хатын өчен арба җигәрбез! — диде тучи бәк тәгин углан, боерыкны үтәргә әзер икәнлеген белдереп.— Ирләре атта йөри белә микән?

Йөзбашы Күчәр тылмач аша аның соравын кабатлады. Чин ирләре атта йөри беләләр иде.

Шулай итеп, йөзбашы Күчәр качакларны Туман каганның өлкән углы Албуга карамагында Туштугай үзәненә озатты. Үзенә эш таба алмый интеккән, кая да булса яуга, сугышка омтылган һәм нинди дә булса батырлык эшләү турында хыялланган яшь тәгин угланны чик буена, йөзбашы Күчәр өстеннән күзәтеп торырсың дип, Туңгак алып җибәргән иде. Әледән-әле үзенең эчен пошырып, иреген кысып торган тыңгысыз тучи бәк тәгин углан йөзбашы Күчәр өчен монда, билгеле, артык кеше иде. Шуңа күрә ул аннан беразга булса да котылып торырга тырышты.

II

Хатыннары, балалары, мал-туарлары белән таулар арасында яшәүче чик буе сөннәренең ялгыз өе Тарлавык авызында, киң генә бер ачык урында утыра иде. Ләкин бу әле дала түгел. Далага чыгу өчен шактый үр менәргә кирәк иде.

Ташлы юлдан алар бераз вакыт җәяүләп бардылар. Тигезрәк, ачыграк җиргә менеп җиткәндә көн яктыра төште. Еракта, каралҗым тау шәүләләре артыннан кысылып кына кояш чыгып килгәне күренде. Юлчылар тигезлеккә килеп менгәч, туктап артларына борылдылар. Түбәндә, аяк астында гына исәпсез-хисапсыз таулар, кыялар диңгезе күреп, ирексездән алар аһылдап куйдылар. Шундый куркыныч, дәһшәтле һәм мәһабәт иде бу артта калган ташлы таулар!

Бу таулар аша бормаланып тар гына ташлы сукмак үтте. Язгы ташу һәм җәйге яңгыр вакытларында ул сукмактан — кыялар арасында кысылып калган тар аралыктан шарлап, дөбердәп сулар ага. Тарлавык буенча түбән таба тагын бер көн чамасы барсаң, аста, таулар артын-

---

[1] Кылавыз — юл күрсәтүче.

да — батынкы, җылы үзәндә Җунго башлана. Киресенчә, таулар арасыннан үргә үрләсәң, кояш чыгып килгән каралҗым таулардан да, кыялардан да өстәрәк, биектәрәк киң тигезлек — Бөек дала җәйрәп ята. Анда — Сөн иле. Анда салкын, анда бары бозлы җилләр генә исә.

Астан югарыга таба үрмәләүче качаклар да, өстән түбәнгә төшүче сөннәр дә әлеге Тарлавыкны берничек тә читләтеп үтә алмыйлар. Чөнки бу тирәдә ике ил арасында башка юл юк. Тарлавык — ике якны килештерә дә, сугыштыра да торган бердәнбер юл. Үлем һәм тереклек юлы.

Менә ул, ниһаять, артта, аста калды.

Авырлы хатын өскә менеп җиткәч тә җиргә егылды. Аны инде болай да чин ирләре ике яклап җитәкләп-күтәреп диярлек алып менделәр. Авыр юлга чыгар алдыннан качакларны өйгә алып кереп, ашарларына, эчәрләренә бирделәр. Авырлы хатынны атлар җигелгән ике тәгәрмәчле арбага утырттылар. Ирләр атка атланды. Иң алдан сөн ирләре китте, алар артыннан — Чәнси, Чәнси артыннан җигүле арба кузгалды. Арба артыннан ике чин ире барды. Юл иркен булса да, бер-бер артлы тезелеп бардылар. Бераздан тигезлек яңадан үр белән алышынды. Тик шулай да бу инде артта калган Тарлавык түгел иде — монда юл да сөзәгрәк, тау итәкләре дә яссырак, ягымлырак иде. Ачык, шәрә калкулыкның икенче ягына чыккач, имән, каен, карагай катыш урман башланды. Бер калкулык аша чыгып, тигезлектән бераз җир бардылар да, яңадан икенче калкулык итәгенә менделәр. Һәм таулар-калкулыклардан бер менеп, бер төшеп, тирән чокырлар, киң үзәннәр аша алар көне буе шулай бардылар да бардылар.

Качаклар үзара берни сөйләшмәде, шулай ук сөн ирләре белән дә гәпләшүче булмады, чөнки сөннәрнең телен чиннәр белми иде. Алар шулай эндәшмичә, сөйләшмичә, ярым йокылы килеш дигәндәй шактый озак бардылар. Бер ачыклыкта, тауга-үргә чабып барган ниндидер киекләрне күреп, яшьләр кинәт җанланып киттеләр. Албуга белән берничә егет һай-һулап киекләр артыннан ташландылар. Шактый озак куып барганнан соң алар кыр кәҗәсе атып алдылар.

Тәгин углан белән өч-дүрт егет киекләр артыннан куып киткән арада башкалар, туктап тормыйча, юлларын дәвам иттеләр. Аучылар үзләренең юлдашларын арттан куып җиттеләр. Авырлы хатын утырып барган арба белән тигезләшкәч, Албуга арбага төртеп күрсәтте дә:

— Хатының исәнме? — диде Чәнсигә.

Чин качагы, билгеле, берни аңламады, шуңа күрә ул җавап та кайтармады, «белмим» дигән сыман бары баш кына какты. Арбадагы хатын, якында гына ят тавыш ишетеп, ахрысы, сискәнеп китте һәм тыелып кына кычкырып җибәрде. Албуга Чәнсигә эндәшкәндә ул арбада йокымсырап бара иде бугай. Аның ирексездән ычкынган куркулы тавышы тәгин угланга бик яшь булып, матур булып ишетелде. Бу аңа бик сәер тоелды. Ләкин ул моңа бөтенләй диярлек игътибар итмәде — атын юырттырып, ары китеп барды. Бары тик соңыннан гына ул, үзе дә сизмәстән, әледән-әле яшь матур тавышны исенә төшерде һәм шундый тавышлы хатынның шундый ямьсез булуы аңа гаҗәп тоелды.

Төштән соң таулар артта калды. Алда, як-якта иксез-чиксез тигезлек башланды. Менә тигезлек тә бетте. Сөннәр, үзләре генә белгән ниндидер комлы калкулыклар янына җиткәч, килгән юлдан уңга — көнчыгышка таба борылдылар һәм качаклар алдында тагын күкселләнеп биек таулар күтәрелде.

Көн кичкә авыша барганда алар әлеге күксел таулар-калкулыклар арасына килеп керделәр. Юл ташлы, урманлы үзән уртасыннан барды. Сөн ирләре туктап калдылар. Чиннәргә дә туктарга кушылды. Сөннәр, җиргә төшеп, атларын утларга җибәрделәр. Качаклар да атларыннан

төштеләр һәм кылавызларның күзләренә карап, нәрсә әйтерләр икән болар, дигән сыман көтеп тора башладылар.

Алай башы тәгин углан, качакларга үз артыннан иярергә кушып, җәяүләп, якындагы сөзәк калкулыкка менеп китте. Ирләр авырлы хатынны ике яктан култыклап, аның артыннан иярделәр. Кораллы егетләр аста торып калды.

Тау башына менеп җиткәч, тәгин углан калкулыкның икенче ягына карады да каядыр еракка төртеп күрсәтте. Алар басып торган калкулык өстендә бернинди агач та, куак та юк, шунлыктан, кайсы якка борылып карасаң да, бөтен тирә-як монда уч төбендәгедәй ап-ачык булып күренә иде.

Качаклар ул күрсәткән якка җентекләп карый башладылар. Аста, еракта, куе урманнар, калкулыклар артында, киң үзән буендагы тау башында алар дүрткел койма һәм койма эчендә чирәп түбәле таныш сыман өйләр күреп алдылар. Бу нәкъ Җунгодагы кебек иде. Чин ирләренә шундук җан кереп китте, бер-берсен бүлдереп алар шундук ни турындадыр сөйләшергә дә керештеләр.

— Банхуа! — диде Албуга елмаеп, коймалы тау ягына күрсәтеп.

— Банхуа! Банхуа! — диделәр чин ирләре, аңлаганлыкларын белдереп.

Шуннан соң тәгин углан җир өстендәге каты үләннәрне төптән тигезләде дә, шунда яткан бер кечкенә ташны куптарып, икенче урынга алып куйды. Ташны ул «Банхуа» дип атады. Тагын икенче бер таш алып, ул аны «Банхуа» дигән таштан читкәрәк куйды. Икенче ташны ул «Без» диде. Моны чиннәр дә аңласын өчен, бармагын башта үзенә, аннары чиннәрнең күкрәгенә төртеп чыкты. «Банхуа»дан да, «Без»дән дә бик читкә ул өченче таш, өченче таш янына дүртенче таш куйды. Аста утлап йөргән атларны күрсәткәч, атта чабып барган сыман итеп ул «Без» ташыннан ерактагы өченче, дүртенче таш янына таба китте. Ерактагы ташлар янына ул юри әйләнгеч ясап барды һәм шулай бик еракан «Банхуа» ташы янына килеп җитте. Килеп җиткәч, арып, хәлдән таеп җиргә егылды.

Аның һәрбер хәрәкәтен игътибар белән күзәтеп торган Чәнси дә, башкалар да елмаеп куйдылар. Ләкин алар аның ни әйтергә теләвен аңлап елмайдылармы, аның кыланышыннан гына елмайдылармы — тәгин углан белә алмады. Шунлыктан, ул, ныграк аңлашылсын өчен, «Без» ташыннан «Банхуа» ташына таба җәяүләп «йөреп» китте һәм аягүрә басып, кулы белән яңадан ерактагы дүрткел койма ягына төртеп күрсәтте. Моның белән ул: Банхуа торагына шушыннан җәяүләп турыга гына барыгыз, моннан юл кыскарак, димәкче булды.

Качаклар, чыннан да төшенгәнлекләрен белдереп, баш кактылар һәм сөн иренең хәрәкәтләрен кабатлап, Банхуа торагы ягына төртеп-төртеп күрсәттеләр. Шулай итеп, алар тулысынча аңлаштылар.

Тәгин углан сикереп урыныннан торды, саубуллашып түбән төшеп китте. Китеп барышлый ул тагын бер мәртәбә авырлы хатынга карап алды. Хатын, аңа арты белән торган килеш, битендәге чупрәген сүтеп азаплана иде. Куе, каты үләннәрне шыштырдатып яныннан гына китеп барган егеткә ул көтмәгәндә борылып карады һәм тагын да ничектер куркып, җиңелчә генә кычкырып җибәрде.

Албуга да кычкырып җибәрә язды. Баягы ямьсез хатын урынына тере күз карашлы яшь чибәр кыз күреп ул шаккатты. «Әллә күземә күренә инде?» дип уйлады ул шомланып һәм абына-сөртенә тизрәк атлады, егетләре янына ашыкты.

Төшеп җиткәч ул, арбага сөялеп, беравык тын алып торды. Нишләптер аның буыннары калтырый, йөрәге ашкынып тибә иде.

— Ни булды?

— Синең төсең качкан! — диделәр егетләр.

— Берни булмады,— диде ул.— Ашыйсы килә, арытты. Шуңадыр.

Алар килгән юллары белән кире киттеләр, аулак, тыныч бер үзәндә учак яктылар да, баягынак көндез атып алган кыр кәҗәсен пешерергә әзерләнә башладылар. Төнне алар шул үзәндә үткәрделәр. Икенче көнне тагын углан үзенең юлдашлары белән әнисенең урдасына юнәлде.

III

Үзләрен озатып килгән яшь сөн ирләре күздән югалгач та качаклар, эчке бер куаныч белән, өмет һәм ышаныч белән, яңадан, җентекләп «Банхуа» ягын күзәтергә тотындылар.

Дүрт качакның башлыгы Чәнси иде. Теге якта ук килешенгәнчә, ирләрнең икесе дә берсүзсез аңа буйсынырга тиешләр. Буйсынырга тиешле ирләрнең берсе — урта яшьтәгесе, ни әйтсәң шуны тыңлый торган, басынкы һәм күндәм кеше. Икенчесе аннан яшьрәк тә, калкурак та һәм, күндәм ирнең капма-каршысы буларак, шактый кире һәм үзсүзле иде.

Ирләр, тулы иректә калгач, өчесе дә бер тирәгәрәк утырыштылар да, үзара киңәшә башладылар. Көн инде караңгыланып килә. Караңгы төшкәнче алар «Банхуа»га барып җитә алырлармы, әллә таныш булмаган урман-таулар арасында адашып йөрерләрме? «Банхуа» моннан караганда әллә ни ерак та түгел кебек, ләкин шулай гына тоелмый микән ул? Аннан соң, «Банхуа»га исән-имин барып җиткән очракта да, төн уртасында капкадан кем кертер икән аларны! Урта яшьләрдәге басынкы кыяфәтле ир төнне шунда гына уздырырга киңәш итте. Арыган килеш урманда адашып йөргәнче, ачык җирдә төн уздыру яхшырак булыр, диде ул. Яшьрәк ир дә аны яклады. Әйе шул, шушында гына куныйк, диде.

Алар шулай сөйләшкәндә-киңәшкәндә Чәнси, ни турындадыр уйланып, газапланып утырды. Алҗыган тынгысыз күзләрен кыскалап ул ирләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап алды, аннары, кинәт исенә төшеп, читтәрәк, ирләргә катышмыйча гына утырган авырлы хатын ягына караштырды. Соңгы сүзне, билгеле, ул әйтергә тиеш иде.

— Ярар, шушында кунарбыз,— диде ул килешеп.

Төн куну өчен иң элек җайлы урын табып, җылы куыш әмәлләргә һәм коры-сары җыештырырга кирәк иде. Аннан соң тамак ялгап алганда да начар булмас.

— Ашап алырга кирәк,— диде озын буйлы яшь ир.

Башкалар риза булдылар. Сөн ире калдырган итләрне, эремчекләрне бүлешеп ашап бетерделәр, аннан соң тире капчык авызыннан түгә-түгә әйрән эчтеләр. Авырлы хатын да ирләр белән бергә ашады. Аңа беркем сүз кушмады. Өч ир янында үзенең четрекле хәлен аңлап, күрәсең, ул үзе дә бернигә катышмаска, берни эндәшмәскә тырышты.

Ничек уздырырлар алар мондый төнне? Йоклый алырлармы, әллә бер-берсеннән куркып, бер-берсен сагалап, я булмаса суыкка чыдый алмыйча, төне буе аяк өсте чыгарлармы? Һәркемнең күңеленә шундыйрак уйлар килде һәм караңгылык куера барган саен, мондый сорау котылгысыз булып тоела башлады.

Ашап туйгач, урта яшьләрдәге күндәм ир беренче булып аягына басты.

— Танышыйк әле —ниләр бар икән монда? — дип сөйләнде ул үз алдына һәм түбәнгә, калкулыкның урманлы ягына төшеп китте.

Бераздан Чәнси дә аягына басты.

— Тизрәк кыймылдарга кирәк,— диде ул янындагы озын буйлы яшь иргә эндәшкән сыман итеп.— Үлән йолкырга, корыган ботак-сатак җыярга кирәк.

Озын буйлы, таза яшь ир бер әйтү белән генә урыныннан сикереп тормады. Кузгалып китүдән аны нидер тотып, тоткарлап тора иде сыман. Зур кулларын тез өстенә куйган килеш ул хәрәкәтсез калып, «Банхуа» ягына карап тик утырды. Ул, ахрысы, урман буена төшеп җиткән теге ирнең күздән югалуын көтә иде.

Ул шулай җиргә береккәндәй кузгала алмый утырганда коры үлән җыеп булашкан Чәнси авырлы хатын янына килде. Күз иярмәс җитез бер хәрәкәт белән ул хатынның кабарынкы бил турысыннан, тун чабуы астыннан кыска хәнҗәр тартып чыгарды. Шул ук мәлдә, коточкыч бер омтылыш белән, ул барыс кебек ыргылып, әлеге яшь ир өстенә ташланды. Озын буйлы ир, үз артында шикле кыштырдау ишетеп, артына борылып карамакчы булды, ләкин карый алмады — киң аркасын авырттырып, бар нәрсәне онытгырып очлы тимер килеп кадалды. Озын буйлы яшь таза ир, ыһ та итә алмады — кискән агач кебек шундук җиргә ауды.

Барысын да үз күзләре белән күреп торган хатын, куркып, кычкырып җибәрде һәм шулай ук һушы китеп җиргә ауды.

Яшь таза ир белән эшен бетергәч, Чәнси ашыгып урман ягына төшеп китте. Урманда сынган коры ботак тавышлары буенча ул теге ирнең кайдалыгын бик тиз чамалап алды. Коры-сары күтәреп, ашыкмыйча гына агачлар арасыннан чыгып килгән ирне дә ул сиздермичә артыннан килеп кадады.

Шуннан соң ул кабаланып өскә, калкулык сыртына ашыкты. Һушы китеп егылган хатын ул менгәндә инде исенә килгән иде. Ырылдауга охшаш бер өн чыгарып, куанып, тилереп ул хатынны аягына бастырды, билен юан күрсәтү өчен мендәр кыстырып тегелгән тунын салдырды да, шашынып аны кочагына алды.

— Ник?! Ник?! — диде яшь сылу кыз күз яшьләрен тыя алмыйча.

— Без икәү! Бар дөньяда без икәү генә! — диде Чәнси.

IV

Туман каган Исәнтәйдә бер генә көн кунак булды да, урдага кайтып китте. Икенче көнне аның артыннан ук Исәнтәй кузгалды. Чин качагы Чәнсине ул тагын урдага алып китте. Чәнсинең, имеш, каганга гына әйтәсе ниндидер бик кирәкле сүзе бар иде.

Теге кичне калкулык башында яшь сылу кыз белән икәүдән-икәү генә калгач Чәнси, бөтенесен онытып, бөтенесенә кул селтәп, яңа тормыш башлап җибәрергә дә уйлаган иде. Яңа тормыш дигәне аның әлеге кызга өйләнеп, берәр җирдә үзенә куыш корып, беркемгә буйсынмыйча яшәп яту булыр иде. Башка качаклар ничектер яшиләр, җайлашалар — ул да шулай җайлашыр, күнегер иде. Баштарак аңа шулай тоелды да. Янында яшь, сылу хатыны булгач, аңа инде дөньяда башка берни дә кирәкмәс кебек иде.

Икенче көнне таң алдыннан туңып уянгач ул башкачарак уй йөртә башлады: Күк җибәргән салкыннан сөекле хатын янында гына җылынып булмый. Җылыну өчен, җаныңны асрау өчен бу дөньяда сөекле хатын кочагыннан тыш тагын өй дә, учак та кирәк иде. Шуның өстәвенә аларның бер кабымлык ризыклары калмаган иде.

Тегендә Банхуаны бик мактап телгә алдылар, аның белән киңәшмичә бер адым ясама — юкса шундук абынырсың, диделәр. Һәм ул үзенең абынмаска тиешлеген, еракта калган карт әнисен, туганнарын уйлап, башын иеп, кызын җитәкләп Банхуаның капка төбенә килде. Килүен килде, тик менә шулай да бик каты ялгышты бугай...

Банхуа аңа беренче караштан ук ошамады. Аның өендә, үз-үзен тотышында, телендә — бөтен нәрсәдә кыргыйлык, далалык, кансызлык сизелә иде. Банхуаның аңа — шундый кыенлыклар күреп килгән ерак ватандашына бөтенләй исе китмәде. Бары тик юлдаш кызының гүзәллеген күргәч кенә аның котсыз кыяфәтендә җирәнгеч бер җанлану билгесе чагылып китте. Беренче караштан ук Банхуа Чәнсигә астыртын, хәйләкәр һәм куркыныч кеше булып тоелды.

Урдага барганда ул юл буена үзенең язмышы турында, Банхуа һәм гүзәл кыз турында уйланып барды.

Атсыз күл буена алар кичтән килеп җиттеләр. Өй корып төнне шунда күл буенда уздырдылар. Иртән таң атып ашагач-эчкәч урдага таба юнәлделәр.

Каган урдасының биек ак өе, аның тирәсендә божра-божра булып урнашкан кечерәк өйләр ерактан ук серле һәм ягымлы булып күренде. Күл буенда, шулай ук урдага таба юл өстендә бернинди көтүчесез утлап йөргән атлар, дөяләр очрады. Урдага якыная барган саен, каядыр ашыгучы я булмаса туктап, үзара гәпләшеп торучы, җил кискән каракучкыл йөзле кешеләр күренеп калды.

Урдага алар йола саклап, Көнчыгыш капка ягыннан килделәр. Тышкы божрага бер ук ераклыгы калгач, аларны атлы сакчылар туктатты. Банхуа-Исәнтәй үзенең ят кунагы белән арбада утырып килә иде. Сакчы аларга арбадан төшәргә боерды. Ат өстеннән генә иелеп ул арба эченә күз салды, шуннан соң аларның кем янына ни йомыш белән баруларын сорады. Исәнтәй үзенең туп-туры каган янына баруын әйтте. Исәнтәйне яхшы белгәнлектән, аларны тиз арада үткәреп җибәрделәр. Ләкин дөяләр җигелгән арба артыннан килүче кораллы ирләргә ары бармаска кушылды. Мондагы тәртип буенча, үзенең кораллы ирләрен Исәнтәй Атсыз күл буенда ук калдырып килергә тиеш иде. Исәнтәй аларны юри ияртеп килде. Кораллы сөн ире ачулана башлагач, ул ягымлы елмаеп:

— Оныткан. Кичер,— диде.

Куеныннан чыгарып ул сөн иренә чигелгән чакма таш янчыгы чыгарып бирде. Ачулы сөн ире бүләкне зур, тупас учына алып йомды да тынып калды. «Тагын бер дус артты»,— дип уйлады Исәнтәй үзалдына.

— Күрдеңме? Менә шундый инде алар...— диде ул үзенең юлдашына.

Капкага җитәрәк аларны тагын туктаттылар. Монысында инде аларны озата килүче сөн ире дә атыннан төште. Өчәүләп алар якындагы ялгыз өйгә юнәлделәр.

Өйнең түбә өстендәге япмасы ачылган, шунлыктан өй эче якты гына иде. Ишектән кергәч тә сулда, учак каршысында зур ак киез җәелгән, җир идәннең калган өлешендә тапталып, шомарып беткән үгез тиресе ята иде. Киезнең як-ягында кораллы ике сөн ире утырып тора, уртадагы калку урын буш иде.

Өйгә килеп керү белән Исәнтәй исәнлек-саулык алышты, шуннан соң учак янынарак кыю гына узды, янып торган учакка куеныннан алып берничә бөртек дөге ташлады — Ут-анага йолык [1] бирде. Чәнсине дә үз янына чакырып ул киезнең түргә каршы ягына чүгәләгәндәй итте. Аларны озата килгән сөн ире ишек төбендә туктап калды. Ирләр, берни сөйләшмичә, беравык тын гына утырып тордылар.

Шул чакны ишек ачылып китте һәм өйгә ашыгып, җилләнеп бай киемле, таза, тыгыз тәнле сөн ире килеп керде. Мондагы барлык ирләрдән озынрак буйлы, эрерәк сөякле бу сөн ире бераз гына шадра битле иде. Аның сул колагында, барлык сөн ирләренеке кебек, зур алтын алка ялт-йолт килә. Бу — Туңгак алып иде. Озын аяклары белән бер-ике

[1] Йолык — корбан.

генә атлап ул туп-туры түргә узды да, ак киез өстендәге йомшак урынга утырды. Ул утыргач башкалар аягүрә бастылар.

— Коралларын алдыгызмы? — диде Туңгак алып өйдәге сөн ирләренә эндәшеп.

— Юк,— диделәр киез янындагы ирләр бер-берсенә карашып.

— Алыгыз,— диде Туңгак алып.

Исәнтәй белән Чәнсигә булган барлык коралларын, очлы нәрсәләрен чыгарып идәнгә куярга кушылды. Исәнтәй дә, Чәнси дә үзләрендә булган нәрсәләрен киез өстенә тезеп куйдылар. Сөн ирләре, ышанып җитмичә, иң ахырда аларны берәм-берәм капшап, тентеп чыктылар. Шуннан соң каравыл агасы Туңгак алып ярым йокылы тыныч бер тавыш белән Чәнсигә тезләнергә, баш орырга боерды. Моның өчен аңа ак киез янындагы үгез тиресенә басарга кушылды. Ул шунда басты, тезләнде дә Туңгак алып алдына баш орды. Бу баш ору ант бирү белән бер иде — үгез тиресенә баскан килеш баш орган кеше ялган сөйләсә, аңа тәңренең каргышы төшәчәк, аның җиде буыны корыячак иде[1]. Исәнтәй барысын да аңлатып барды.

Туңгак алып качакка сөйләргә кушты. Чәнси чәрелдек нечкә тавыш белән сөйләргә кереште. Ул үзенең кем булуын, бу якка ничек, ни өчен чыгуын гына әйтте. Кыска гына итеп шул турыда белдергәч, тылмач аша:

— Каганга сөйлисе сүзләрне дә әйтергәме? — диде.

— Юк,— диде Туңгак алып.

Карар күзгә таудай булып, кырыс, усал булып күренсә дә Туңгак алып качакка бөтенләй каты орынмады. Ул аның белән бик тыныч, ягымлы сөйләште. Чәнсинең баштагы куркуы, шомлануы — барысы да тиз арада юкка чыкты.

Беренче танышлыктан соң Туңгак алып Исәнтәйгә күтәрелеп карады да ымлап аңа сорау алырга кушты. Мондый чакта нинди сораулар бирелгәнен белгәнгә күрә, Исәнтәй, Туңгак алыпның әйткәнен дә көтмәстән, качактан сорау ала башлады.

— Син, качак, Чәнси, Сөн иленә үзең теләп чыктыңмы?

— Үзем теләп чыктым.

— Чин качагы Чәнси, Сөн илендә үзең теләп каласыңмы?

— Үз теләгем белән калам.

— Мәңгегәме?

— Мәңгегә.

— Каганны изге дип, Тәңрене алла дип таныйсыңмы?

— Таныйм,— диде Чәнси, маңгаендагы салкын тирләрен сөртеп.

V

Сорау алу беткәч аңа аягына басарга кушылды. Баскач сөн ирләренең берсе аны үз артыннан ияртеп китте.

Ишектән кергәч тә уң яктарак өйне икегә бүлеп киез пәрдә эленеп тора иде. Чәнсине иярткән сөн ире, пәрдәне ике якка аерып, шунда кереп китте. Исәнтәй дә алар артыннан атлады.

Бу кысан, тар бүлмәдә шактый караңгы иде. Алдан барган сөн ире, качакның уен сизенгән сыман, өйнең тышкы яктагы икенче ишеген ачып җибәрде һәм киезне өскә кайтарып куйды. Караңгы бүлмә яктырып китте. Шул ук мәлдә бүлмә эченә бөркелеп коры суык тулды.

— Чишен,— диде качакка сөн ире чин телендә.

Чәнси аптырап калды. Ләкин сөн иренең чин телендә әйткән сүзен-

---

[1] Үгез тиресенә басу — борынгы төркиләрдә үгез изге саналган, шунлыктан аның мөгезе дә, тиресе дә изге исәпләнелгән һәм, ышану буенча, сихри көчкә ия булган.

нән бигрәк, аның шушы салкында чишенергә кушуы гаҗәпкә калдырды. «Бу нәрсә бу?» дигән сыман, яклау эзләп ул үзенең «якташына» күтәрелеп карады. Таштай җансыз Банхуа аңа берни эндәшмәде.

— Чишенергә! Анадан тума,— диде сөн ире кабатлап.

Чәнси, әле һаман ышанырга теләмичә, сөн иренә карады. Сөн ире дә, Банхуа кебек үк, тыныч, гамьсез бер кыяфәттә көтеп торуында булды.

Чин качагы, монда беркем берни аңлатмаячагын, беркем ярдәм итмәячәген аңлап, барлык батырлыгын җыеп, әкрен генә чишенә башлады. Тегендә, туган җирендә, әле җылы, кояшлы, чәчәкле көз иде. Монда да көз. Кояшлы, бозлы көз. Бүген иртән күлдәге бозны күреп ул шулай иртә суытуына шаккаткан иде. Тегендә, аның туган җирендә әле яланөс йөриләрдер!

«Нишләтмәкче булалар икән соң болар мине?» дип уйлады ул, читят, салкын тышка күз ташлап. Шулай да аңа уйланып, җылы көннәрне искә төшереп күп юанырга туры килмәде. Аның артык әкрен кылануын күреп, сөн ире ашыктыра башлады. Чәнси өс киемнәрен салып аяк астына куйды да, «Менә булды да!» дигән сыман елмайгандай итеп, янындагы ирләргә күтәрелеп карады. Никтер аңа бөтен куркыту, чиркәнчек алдыру шуның белән бетәр һәм хәзер менә аңа киенергә кушарлар сыман тоелды.

Ләкин аңа беркем дә киенергә кушмады. Киресенчә, үзләренә ияртеп аны тышка алып чыгып киттеләр. Каты җиргә басу белән, аның аяк табаннарына очлы, вак ташлар кадалды, бөтен тәнен чыдап булмаслык суык өтеп алды. Ирексездән ул ыңгырашып куйды. «Сатлык!» дип уйлады ул Банхуа турында. «Якташы» аңа мондый нәрсәләрнең берсе турында да алдан әйтеп куймаган иде.

Ачык ишек аша аңа баядан бирле якында гына ниндидер тавышлар ишетелеп торгандай тоелган иде. Шул өзек-өзек тавышлар ишетелгән яктан тәтен дә күтәрелә сыман иде. Шәрә килеш берничә адым атлагач та ул бөтенесен үз күзләре белән күреп шаккатты. Өйдән якында гына бик зур учак янып тора. Өстенә җылы тун, аягына итек, башына бүрек кигән сөн ире белән Банхуа аны шулай анадан тума килеш туп-туры учак янына алып килделәр. Чәнсинең йөрәге жу итеп китте. Күз алдына шундук гүзәл юлдашы килде, теге көнне ук кадап үтергән ирләр килде. «Белделәр микәнни? Шуның өчен яндырып үтермәкче булалар, ахры?» дип уйлады ул коты алынып. Туңу тойгысы шундук юкка чыкты, бөтен тәнен кайнар дулкын өтеп алды. Тыела алмыйча, ул бар көченә кычкырып җибәрде.

Шул ук вакытта ул учак тирәсендә кайнашкан ниндидер бүре сыман ирләр, ир сыман бүреләр күреп алды. Курку тойгысы беразга кызыксыну тойгысы белән томаланды. Үзенең учакта куырылып үләчәген дә онытып, ул, нәрсә уйларга да белмичә, бүре-кешеләргә текәлеп калды. Ныклабрак карагач, ул аларның баштанаяк бүре тиресенә төренгән чын кешеләр — камнар [1] икәнлегән аңлап алды.

Ул арада бүре-кешеләрнең берсе, ырылдап, үз телендә нидер сөйләнеп, Чәнси янынарак килде. Башкалар, ыржайган тешле бүре авызларын ачып, аның ягына борылып карадылар. Шунда ук ике бүре-кеше колак тондыргыч итеп дөңгер [2] кагарга тотынды.

— Ут аша сикер! — дип кычкырды Банхуа Чәнсинең колак төбендә генә.

Чәнси барысын да аңлап алды. Юк, аны әле яндырып үтермиләр икән! Ул шулай дип уйларга да өлгермәде, каршысына килеп баскан бер дәү бүре-кеше, аның кулыннан эләктереп алды да, утка таба өсте-

---

[1] Кам — борынгы төркиләрдә дин-йола башлыгы.
[2] Дөңгер — барабан.

ри башлады. Учак зур иде, коры агачлар дөрләп, ялкынланып яна иде. Шуңа күрә аны читтән йөгереп килеп сикергәндә яхшырак булачак. Чәнси, йөгереп килмәкче булып, артына чигенде, ләкин, шуны гына көтеп торган сыман, ырылдап, кулларындагы артыш таякларын селтәп, шундук аны камнар уратып алды.

Чин качагы, ары-бире каранды, тирән итеп бер тын алды да, башка бернинди чара юклыгын аңлап, утка ыргылды. Бүре-кешеләр бар көчләренә: «Алас! Алас!» дип кычкырдылар. Шул ук вакытта каты итеп тагын дөңгерләр дөпелдәде.

Чәнси утнын икенче ягына сикереп чыкты да каты җиргә килеп төште, егылып китте. Вак ташлы җир өстеннән бер-ике мәртәбә тәгәрәп киткәч, бөтен тәненең авыртып сызлавына, пешүенә түзә алмыйча, ул аягына басты һәм, тагын көчле күрмәсеннәр дигән сыман, учак яныннан кача башлады.

Аны бүлеп китерделәр, тынычланырга куштылар. Уттан ул исән-сау чыкты, димәк, арыкланды. Шулай итеп, ут алласы аның күңелендә ниләр яшеренеп ятканын белә алмады. Ул белмәгәч, сөннәр дә берни белми булырга тиеш. Юк, берни белмиләр алар! Юкка гына куркытып азаплаланалар. Күрәсең, аны хәзер каган янына алып барырлар.

Ул шулай дип уйларга да өлгермәде, төрткәләп диярлек аны яңадан өйгә алып керделәр. Керү белән ул тизрәк киемнәренә тотынмакчы булды. Ләкин киемнәр куйган урынында юк иде. Ачык ишектән ул тышка күз ташлап алды һәм шул чакта үз киемнәрен дөрләп янган утка ташлауларын күреп алды. Аның ике күзе дүрт булды.

— Ы-ы! — диде ул Банхуага карап, тешләрен шыкылдатып.

— Әйдә киенергә!— диде аңа Банхуа.

— Ник әйтмәдең?! — диде Чәнси ярсып.

— Тиз бул, туңасың! — диде аңа Банхуа чин телендә. Шуннан соң ул, сөн иренә карады да, сөн телендә: — Менә шундый йомшак буынлы инде алар чиннәр! — диде күрәләтә мыскыл белән.

VI

Төркемләшеп алар өйнең җылы ягына керделәр. Ишектән керү белән Чәнсине шундук ике яктан ике ир тотып алды. Берсе ике куллап арттан аның башын кысып тотты, үткер энә белән аның сул колагын тишге. «Алка кидерәләр»,— дип уйлады Чәнси тыныч кына. Аның инде кычкырасы да, карышасы да килмәде. Ут аша сикереп тә исән калгач, инде нишләтсәләр дә аның өчен барыбер сыман иде.

Чыннан да, аның сул колагына бакыр алка кидерделәр. Шуннан соң икешәр кат өс киеме бирделәр. Ул тупас йон тукымадан, тиредән, күннән тегелгән озын, җылы киемнәр киде, билен буды. Киенгәч аңа агач табак белән күп итеп кымыз бирделәр. Җылынып, тынычланып ул җиңел сулап куйды һәм Банхуага:

— Инде беттеме? — диде елмаеп.

Банхуа җавап кайтармады.

— Син, чин качагы, изге ут аша чыктың — арыкландың, сөн киемнәре кидең — ир булдың,— диде сөн ире тылмач аша.— Хәзер син үз кулың белән битеңне карага буяп каганга буйсыну белдер.

Шул чакны киез чаршау артыннан кулына зур гына кара савыты тоткан картрак бер сөн килеп чыкты. Кара савытын ул Чәнсигә тоттырды һәм кулы белән ымлап, битне ничек буярга кирәклеген аңлатты. Чәнси сорашып, ы-мы итеп тормады — уң кулының бармакларын корым катыштырып ясалган кара сыекчага манды да башта уң як битен буяды, аннары сул як битен, маңгайларын, ияклэрен буяды.

— Бүгеннән башлап — ятканда-торганда, ашаганда-эчкәндә... төнлә дә, көндез дә... ялгыз да, бергә дә... өч көн буена син кара йөз! — диде түрдә тын гына күзәтеп утырган Туңгак алып телгә килеп, тантана белән.

Банхуа аның сүзләрен чин теленә әйләндерде.

«Кара йөзгә» табак белән тагын кымыз, пешкән ит кисәге бирделәр. «Болай булгач яшәргә була!» дип уйлады ул күңеленнән. Сөн ирләре аның ашаганын, эчкәнен көтеп тордылар да бер-бер артлы өйдән чыга башладылар. «Кара йөз»гә дә чыгарга кушылды. Өйдән чыккач алар өчәүләшеп капка ягына юнәлделәр.

Каган өенә кергәндә «кара йөз»гә бернинди тоткарлык булмады. Банхуа өйрәткәнне исендә тотып, ул бары тик ишектән кергәндә генә аеруча сак-уяу булырга тырышты. Ләкин ул сак-уяу булмаса да, ишек башына орынырга я булмаса бусагага басарга аңа, күрәсең, ирек бирмәсләр иде. Таудай биек өй ишегенең ике ягында да — эчтә дә, тышта да икешәр-икешәр кораллы ирләр тора. Йөзе кара кеше күренү белән, аның теләсә нинди ялгышын төзәтергә, кирәк булса, үзен урталай чабып ташларга әзер булып, алар аның һәр адымын күзәтәләр. Банхуа да аның колак төбендә генә бертөзлексез:

— Аягыңны күтәреп атла! Башыңны иеп атла! — дип тукып килде.

Туман каганның Ак өе, тыштан зур булган кебек, эчтән дә бик зур иде, иркен иде. Балчык өйдә туган, балчык өйдә яшәгән һәм таш, балчык өйләрдән, сарайлардан яхшырак берни була алмый дип инанган чин кешесе, каганның югарыдагы түгәрәк төннек аша турыдан-туры күк белән тоташкан якты сараена килеп кергәч чын-чынлап таң калды. Мондый иркенлекне, мондый байлыкны аның беркайчан да, беркайда да күргәне юк иде.

Биек түшәмне-түбәне өч багана тоттырып тора иде. Тигез итеп шомартылган, югарыга таба нечкәрә барган карагай баганаларның өчесе дә астан өскә чаклы саф алтын белән тышланган. Алтын калайга чүкеп төрле ерткыч сурәтләре, ау күренешләре, үсемлекләр төшерелгән. Югарыда, түшәмгә җитәрәк, баганалардан тармакланып як-якка ботаклар таралган. Ысылдап торган җылан рәвешендә ясалган алтын ботаклар үзара аралашып, кисешеп киң ябалдаш барлыкка килгән. Ботак-җылан башлары барысы да киез өйнең зур гәүдәсен тотып тора торган күп санлы кабыргаларга тоташкан. Уртадагы өч төп баганадан читтәрәк, өй әйләнә, түгәрәк буенча, кечерәк, тәбәнәгрәк баганалар тезелеп киткән. Кечерәк баганалар аралаштырып ал, яшел, ак, сары төсләргә буялган. Баганалар арасыннан, идәнгә чаклы төшереп, чигүле ефәк чаршаулар, япмалар эленгән. Биек баганаларның җылан-ботаклары кабырга башларына тоташкан турыдан тәбәнәк багана башларына кадәр күк төстәге ефәкләр тотылган. Шунлыктан анда түшәм дә, түбә дә тышкы күк белән бергә кушылган кебек булып тоела иде. Аяк астында, идәндә бик зур ак киез сузылып ята. Ак киезнең сул ягына бизәкле ал келәм җәелгән. Келәм өстендә — фил сөягеннән кырып ясалган, алтын болан, тәкә, барыс сурәтләре белән бизәлгән биек тәхет тора. Кая карама, күз карашы алтынга, ефәккә — байлыкка, гүзәллеккә барып төртелә иде.

Шуны күреп «кара йөз» кинәт телсез-өнсез калды. Өйнең аргы башындагы кешеләр аңа бик кечкенә булып күренделәр, аларның аяк тавышлары да, сөйләшкән сүзләре дә бөтенләй ишетелмәде — Чәнси кергән ишектән алар шундый еракта тоелдылар.

«Кара йөз» өй эченә аяк басу белән, кемдер аның кулыннан тотып алды, үз артыннан ияртеп аны каядыр читкә алып китте. Арттанрак атлаган икенче бер кеше аның аркасына төртеп алды — иелергә кушты. Аның кулына кымыз тулы агач савыт тоттырдылар.

— Эч! — диде Банхуа пышылдап.

«Кара йөз» башын калкыткандай итте, лэкин шундук кемдер тагын аның аркасына төртеп алды.

— Миңа кара — менә болай! — диде Банхуа усал пышылдап.

«Кара йөз» карады һәм аныңча тезләнеп, башын иеп агач савытны авызына якын китерде. Эчеп бетергәч, алар икесе дә берьюлы диярлек бер-берсенә күтәрелеп карадылар һәм өйнең түренә — каган утырган алтын тәхет ягына борылдылар.

VII

Алар янына ашыгып уң кул карачы Бүзбала килеп житте. Күз карашы белән генә ымлап ул аларны үз артыннан алып китте. Алар, кечерәк баганалар янында басып торган бай киемле ирләр турысыннан үтеп, түргә якынлаштылар. Ак киез белән учак арасындагы үгез тиресенә житкәч Банхуа-Исәнтәй «кара йөз»гә тирегә ике аяклап басарга кушты. Шуннан соң аңа баш киемен салырга, тезләнергә, тиренең икенче башына кадәр түше белән шуып барырга һәм ак киезгә йөзен орырга диелде.

Биек тәхеттә утырган каганны «кара йөз» баштарак күрә дә алмады. Ул бары аның кайдадыр якында, лэкин шулай да күз күреме житмәслек югарыда булуын гына тойды.

— Миңа буйсынган «кара йөз» мондамы? — диде каган бөтен өй эченә кычкырып.

Чыннан да аның тавышы Чэнсинең нәкъ түбәсе өстендә ишетелде.

— Монда, бөек каган,— диде Бүзбала.— Аның сиңа сүзе бар — сөйләсенме?

— Сөйләсен!

Сары ефәк белән тышланган озын тун кигән, билен алтынлы киң каеш белән буган, зур гәүдәле, зур башлы, зур йодрыклы Бүзбала, артына борылып, Исәнтәйгә ым какты. Шул ук мәлдә читтәге бер төркем ирләр арасында басып торган олы яшьтәге чандыр бер карт, алгарак чыгып, Исәнтәйгә каршы якта — үгез тиресенең икенче ягында туктап калды. Бу каган тылмачы иде, «кара йөз» сөйләгәндә ул Исәнтәй әйләндереп барган сүзләрнең дөреслеген тикшереп торачак.

Чин качагы чыпчык чыркылдагандай көчсез тавышлар чыгарып сөйләргә кереште. Исәнтәй аның сүзләрен Бүзбалага әйтте, Бүзбала каганга житкерде: «кара йөз», турыдан-туры каганга сөйләү түгел, сөйләгәндә хәтта аңа күтәрелеп тә карый алмый иде.

— Мин Чжао йортының меңбашы Чэнинең кече углы Чэнси торырмын,— диде качак сүз башлап.— Син инде беләсең булыр, бөек каган, моннан унөч ел элек синең көньяктагы күршең Чжао йортын комсыз Чин ерткычы кабып йотты. Шуннан ике ел элек ул Хань йортын басып алды. Шулай итеп алты йортны бер-бер артлы үз биләмәләренә кушты. Жиренең-суының киңлеге, көченең, байлыгының күплеге буенча Чин йорты барлык борынгы йортларны узып китте. Күршеләренә салган талау, кайгы, кыран буенча да ул жир йөзендәге барлык йортларны уздырып жибәрде. Чиннәрнең явызлыгын, ерткычлыгын берни белән тиңләп, чагыштырып булмый, бөек каган. Күршеләрен басып алып, Шихуанди бар нәрсәнең астын өскә китерде. Жиңелгән йортларның кораллы ирләрен ун меңләп, йөз меңләп терелэй жиргә күмдерде. Күпме хатыннар тол калды, күпме балалар атасыз калды, күпме кызлар кияүсез калды! Башка биләмәләрдәге барлык коралны жыеп алып, бер дә кирәкмәгәнгә ул өй тәүмәлеге кыңгыраулар, сыннар койдырды. Чыгышы буенча Чин йортыннан булмаган бик күп аксөякләрнең, олуг нәселләре-

нең тамырын корытты. Аксөякләр чебен урынына кырылдылар, бөек каган! Исән калганнары, туган җирләреннән, мал-мөлкәтләреннән аерылып, көчләп Сианйәнгә — Чин йортының башкаласына күчерелде. Бөтен җирне яңадан кискәләп-бүлгәләп, утыз алты өлкә ясадылар. Барлык өлкәләргә баш итеп Инчжән үз кешеләрен куйды. Алты йортның язулары, акчалары, үлчәүләре чүплеккә чыгарып ташланды. Җирдәге, судагы барлык нәрсә, бөтен тереклек комсызлыкның, ерткычлыкның соңгы чигенә җиткән бер кеше сүзенә буйсындырылды. Күк асты илендә хәзер, бөек каган, алай итсәң дә ярамый, болай итсәң дә ярамый. Уңга карасаң да, сулга карасаң да — гаеп, кычкырып сөйләшсәң дә, пышылдап сөйләшсәң дә — гаеп. Минем борынгы китаплардан укыганым бар, шулай ук галим кешеләрдән дә ишеткәнем бар: җирдә кеше үзенчә уйлау, үзенчә яшәү, үзенчә сөйләү өчен туган. Чиннәр иген игеп, шуның белән тамак туйдыра, җитен тукымадан кием тегеп, салкыннан саклана. Сөннәр мал-туар асрап, шуның ите-сөте белән тамак туйдыралар, киемнәрен тиредән тегәләр. Чиннәр үзләренчә, сөннәр үзләренчә сөйләшә. Олуг Күк... Тәңре каршында моның бернинди языгы юк. Ләкин Чин йолалары, Чин тәртипләре буенча бу — яманлык санала. Чиннәр карашы буенча, җирдәге барлык халыклар бер төрле тукланырга, бер төрле киенергә, бер телдә сөйләшергә тиешләр. Үзенчә киенгән, үзенчә тукланган, үз телендә сөйләшкән барлык халыкларны чиннәр угры дип беләләр, бернинди кызганусыз коллыкка саталар — таулар арасына тимер, бакыр ташы казырга я булмаса тоз чыгарырга сөрәләр. Борынгы галимнәрнең акыллы сүзләре язылган бамбук такталарын арбаларга төяп, урамнарга алып чыгалар, утын кебек итеп, ут төртеп яндыралар. Укымышлы кешеләрне терелэй җиргә күмәләр, бөек каган! Бер гаепсез кешеләрне асу-кисү чиннәрнең көндәлек эшенә әйләнде. Урамда, кырда-басуда үлеп яткан, череп яткан кешеләр, кеше сөякләре күреп инде беркемнең дә исе китми. Шул ук вакытта Инчжән бөтен Җунгоның бер почмагыннан икенче почмагына киң, туры юллар салдыра, үзе өчен илнең теләсә кайсы төшендә күз күрмәгән, колак ишетмәгән бай сарайлар салдыра...

VIII

— Мин боларны беләм. Мин белмәгәнне сөйлә,— диде каган «кара йөз»нең сүзен бүлдереп.

Чәнси туктап калды. Каганга сөйлисе сүзен ул алдан ук өйрәнеп, ятлап килгән иде. Шуңа күрә аңа каян да булса икенче төштән башлап китүе кыенрак хәзер. Ул, беравык уйланып торгандай итте дә, өзелгән сүзен шул ук төштән ялгап алып китте.

— Шихуанди, Күк асты илендә басып алырдай җирләр беткәч көньяк халыкларын яулау эшенә кереште,— диде ул.— Бүгенге көндә көньякның сазлы, дымлы урманнарында биш йөз меңлек Чин көчләре Аулак дип аталган ил белән канлы сугыш алып баралар. Шул турыда белә микән бөек каган?

Чәнси кыюланып башын калкытты һәм каганның йөзенә карап алды. Ул аның йөзендә кызыксыну билгесе күрде. Аңа бары шул гына кирәк тә иде. Шул ук мәлдә Исәнтәй-Банхуа усал гына итеп аның җилкәсенә төртеп алды, башын түбән идерде, ләкин «якташы»ның мондый кыланышына Чәнсинең әз генә дә хәтере калмады.

— Сөйлә,— диде каган, боерып.

— Сазлар, урманнар арасында яшәүче кабиләләр чиннәргә бик нык каршылык күрсәтәләр,— диде «кара йөз».— Менә икенче ел инде Чин көчләре, бер урында таптанып, бер ли[1] дә алга китә алмыйлар. Юл юк,

[1] Ли — озынлык үлчәү берәмлеге. Ярты чакрым чамасына туры килә.

арттан азык-төлек китереп булмый. Чиннең көче көннән-көн кими бара. Ачлык, таркаулык... Инчжэннең тәхете, бөек каган, сеңге очына гына эләгеп тора. Көньяктагы сугыш та, салына торган юллар, сарайлар да караларга бернигә кирәкми. Алар шулай ук безгә дә — җиңелгән биләмәләрнең аксөякләренә дә кирәкми.

Чәнси, барлык кыюлыгын җыеп, тагын бер мәртәбә каганга карап алды. Туман каган танымаслык булып үзгәргән иде!

— Сөйлә! — дип кычкырды ул, түземсезләнеп.

— Зур көч белән Җунгога басып керсәң, элекке йортларның аксөякләре баш күтәрәчәкләр, бөек каган! — диде «кара йөз», чыпчыктан кинәт бөркеткә әйләнеп.— Син кабызган беренче ялкын бөтен үзәнгә таралачак, чиннәрнең көлен күккә очырачак. Инчжэннәр, Лисылар, Чжангаолар тычкан урынына чыркылдап үләчәкләр. Сине, бөек каган, бөтен киләчәк буыннар ун мең ел буена мактап телгә алачак.

«Кара йөз» сөйләп бетерде. Туман каган озак кына тынып утырды. Өй эчендәге башка ирләр дә, иреннәрен кысып, киеренке тынлык сакладылар.

— Шулай да булсын — мин басып керермен,— диде каган бераздан.— Чин юкка чыгар. Чжао, Хань, Йән... ирек алыр. Мин нәрсә алырмын икән соң?

— Анысын син миннән яхшырак беләсең, бөек каган,— диде Чәнси.

— Беләм,— диде каган.— Шулай да синең туган йортың Чжаоны коткару өчен генә сөннәр кан коярга тиеш микән?

— Минем ишеткәнем бар, шулай ук борынгы китаплардан да укыганым бар: ил агасы үз күзе алдында торганны гына күрмәскә, күз алдында тормаганны да, ерактагыны да күрә белергә тиеш,— диде Чәнси, кыюланып.— Чинне аяк астына салып таптый алсаң, син Чжаоны, Ханьны, Йәнне генә коткармассың. Син үзеңне дә коткарырсың, бөек каган!

Туман каганның күз карашында усал очкыннар елтырап китте.

— Син мине коткарырга килдеңме, кара йөз?! — диде ул, урыныннан кузгалгандай итеп.

— Мине синең янга Чжао йортының аксөякләре җибәрде, бөек каган,— диде Чәнси түбәнчелек белән.— Алар әйттеләр, каганга безнең теләкне җиткер диделәр.

— Әйтеп бетер!

— Көньякта чиннәр Сиәншуй белән Лушуй суларын ялгау өчен арык казый башлаганнар,— диде Чәнси.— Арык казылып ике елга бергә ялганса, ачыккан Чин көчләренә үзәктән азык китерү җиңеләячәк. Ул чагында Инчжэн көньяк маньнарны җиңел генә тез чүктерәчәк. Көньякны басып алу белән Чин йортының көче бермә-бер артачак. Ул чагында Шихуандинең ике кулы да бушап калачак. Менә шул чагында инде ул биш йөз меңлек көчне төньякка таба борачак. Ни өчен дигәндә, Чин ваны күршеләре белән сугышмый тора алмый. Яңадан-яңа җирләр яулап алу теләге аның канына сеңгән. Чиннең төньягында аңа буйсынмаган, аңа баш бөкмәгән бер генә күрше бар: ул да булса — Сөн иле, бөек каган!

Туман каган бөтен өй эчен яңгыратып шаркылдап көләргә тотынды.

— Якын килеп карасын! — диде ул.— Сөннәрне әле беркемнең дә беркайчан да җиңә алганы юк. Булмас та!

Өй эчендә ирләр, мактау-хуплау белдереп, җиңелчә генә гөрелдәп алдылар.

Шулай да йорт башының мактанып әйтелгән, кычкырып әйтелгән бу сүзләрендә әчке бер каушау сизелде.

«Кара йөз»не чыгарып җибәргәч, каган үзенең якыннарын, киңәшчеләрен түргәрәк чакырды. Моңарчы читтә басып торган ирләр, барысы берьюлы диярлек дәррәү кубып, шулай да бераз гына тыелып, тыйнаграк булырга тырышып, ак киезгә ябырылдылар. Киез өстенә һәркем үз урынын белеп кенә, җайлап кына утырды. Уң кул карачы Бүзбала Исәнтайгә дә киезгә утырырга кушты. Чингә кагылышлы сөйләшүләрдә аның да сүзенә колак салгалыйлар иде.

Сөйләшү-киңәшү башланганчы каган ашарга китерергә кушты. Киез өстендәге ирләр алдына ашчылар табак-табак кайнар ит китереп куйды. Ачыккан ирләр, беркемгә карамыйча, шундук ашарга керештеләр. Иттән соң кымыз килде. Ашаганда-эчкәндә, йола саклап, беркем берни сөйләшмәде. Тамак туйдырып, күңелләр күтәрелеп киткәч, барысы да җиңелчә генә шаулашып, гөрләшеп алдылар һәм чин качагы алып килгән хәбәрләр турында сүз башлап җибәрделәр.

«Кара йөз» сөйләгән сүзләрнең бик күбесе мондагылар өчен билгеле иде. Ләкин шул ук вакытта аның сүзләре арасында таныш булмаган яңалыклар да бар иде. Һәркем иң элек менә шул яңалык турында баш ватты. Дөресме, түгелме? Чин качагы ялган сөйләми микән? Ялган сөйләсә, ник сөйли? Дөрес сөйләсә, каганга нинди киңәш бирергә?

Ак киездә иркенләп утырган ирләр, теш арасына кысылган итләрен казыштырып, майлы мыек очларын сыпыргалап, шактый озак шаулаштылар. Үзенең ирләре-туганнары, киңәшчеләре үзара шулай фикер алышканда каган, беркемгә, бернигә катышмыйча, чит кеше сыман тыңлап кына утырды. Чабыш алдыннан атларның аягын яздырып алган кебек, олы сөйләшү алдыннан ул да шулай кешеләргә үзара шаулашып алырга ирек куя иде.

Шулай да ул бүген тезгенне бушайтыбрак җибәргән сыман тоелды. Кызып үзара бәхәсләшергә тотынган ирләр ничектер моны абайламыйчарак калдылар. Абайлап алдылар да, тыела төштеләр. Башта ярым пышылдауга, аннан соң пышылдауга күчтеләр һәм, тәхет ягына текәлеп, барысы да тынып калды. Каганның йөзе бүген аларга бик сәер күренде. Ул инде чин качагын да, аның сөйләгән сүзләрен дә, хәтта өй эчендәге ирләрне дә бөтенләй исеннән чыгарып ташлаган иде бугай. Аны, әйтерсең, монда беркем дә, берни дә кызыксындырмый иде — күңеле белән ул кайдадыр икенче җирдә утыра кебек. Аның шулай онытылып утыруы исә туган-тумачалар, киңәшчеләре өчен бик үк куанычлы нәрсә түгел. Мондый чакта аның нәрсә уйлавын берничек тә чамалап булмый. Нәрсә уйлавын чамалап булмагач, аңа киңәш бирүе дә бик хәтәр, куркыныч нәрсә иде.

Уң кул карачы Бүзбала беренче булып тамак кырды, каганга күтәрелеп карады да:

— Тыңлар булсагыз, бөек каган...— дип сүз башлады.

Каган мәрттән кире кайтты, күрмәс күзләре белән Бүзбалага бер күтәрелеп карады һәм, бернинди кызыксынусыз, тыныч кына:

— Сөйләсеннәр,— диде.

Беренче булып Баргынтай баба сөйләде. Каганның холкын ул башкаларга караганда яхшырак белә һәм аңа кайчан нинди киңәш бирергә кирәклеген дә башкаларга караганда дөресрәк чамалый иде. Баргынтай бабаның киңәше шуңа кайтып калды: Чин ягыннан чыккан теләсә нинди качак сүзенә колак салу, шуңа таянып Чингә каршы олы көсәк күтәрү акылсызлык булачак, диде ул. Чин ваны Инчжән усал, холыксыз, шулай да ул көчле, нык куллы, диде.

Башкалар да, Быргынтай баба ягына авышып, шундыйрак фикерне куәтләделәр: «кара йөз»нең сүзләренә колак салмаска, чиннәр белән бозылышмаска, диделәр.

Каган ирләрне һаман бүлдермичә тыңлап утырды һәм бернинди күз карашы белән дә, бернинди ымлау-ишарәләү белән дә яклау да, каршы фикер дә сиздермәде. Озакка сузылган мондый билгесезлек кайберәүләрнең эченә әле боз булып, әле утлы ялкын булып йөгерде.

Каган, ниһаять, җанлану әсәре күрсәтте. Киңәшчеләр барысы да инде сөйләп бетергәч ул кинәт, яртылаш борылып, ак киезнең сул ягында, кырыенда гына утырган Исәнтәйгә карады да, туп-туры атап:

— Син, Исәнтәй, ни диярсең? — диде.

Исәнтәй сискәнеп китте. Ул монда бик кечкенә кеше иде, һәм беркайчан да каганның менә монда, биек өйдә — туган-тумачалар, өлкән киңәшчеләр, карачылар янында туп-туры аңа атап эндәшкәне юк иде. Ул ихлас бер сөенеч белән елмаеп алды. Аның ясалма елмаюын күреп күнеккән кешеләр шулай да аның бу ихласлыгына ышанып җитә алмадылар. Исәнтәй, тәхет алдында бер-ике тапкыр баш иде дә, мүкәләп каганга таба бераз якынайды.

— Син, бөек каган, миннән киңәш сора, мин әйтә,— диде ул, бик нык каушап һәм шуңа күрә сөн сүзләре тәртибен буташтырып.— Бер качак сүзгә ышанып, Чин иленә яу чаба кирәк имәс. Сөн — батыр, кыю, куркусыз. Шулай да сөннәр Чжао ире Лимуны оныта имәс. Лиму сөннәрне күп үтер, сөннәрне күп куды. Арьякны тартып алды. Синең кыюлыгың, батырлыгың белән сөннәр Арьякны Чжаодан кире тартып алды, бөек каган! Шуның өчен сине сөннәр мең ел макта. Тәңре сиңа күктән байлык, көч бирә. Чингә каршы яу чаба кирәкми. Нигә яу чаба? Чжаоны коткару өченме? Безгә андый яу кирәк имәс. Безгә башка төрле яу кирәк. Сөн бөтен Җунгоны яулап ала кирәк!

— Ә?! — диде каган үзе дә сизмәстән.

— Ә?! — диделәр башкалар да аңлап җитмәгәндәй.

— Төшендереп бир,— диде каган.

— Мин төшендереп әйтә,— диде Исәнтәй каганның йөзенә туры карап.— Чиннең хәле яман. Күк асты илендә үзара ызгыш-талаш кубарга тора. Син, бөек каган, Чингә басып кер күп көч белән, Чинне тапта, юлбарысны кадаган кебек. Инчжәнгә сөңге када!

Исәнтәй шулай диде. Соңгы сүзләрен ул, яуга ташланырга җыенган сугышчыдай, йодрыкларын йомарлап, омтылыш белән, тантана белән әйтте.

Ягымлы, тыйнак тылмачтан мондый нәрсә көтмәгән ирләр, кинәт йокыдан уянып киткән кебек, күзләрен ныграк ачып карадылар, колакларын ныграк торгызып тыңладылар. Курку-өркү, шомлану һәм ничек тә башкалар артына посып калырга тырышу сыман тойгылар аяк астына төште. Һәркемнең күңеленә бер генә уй: эләксә нык эләгә инде моңа, дигән бер генә уй килде. Кайберәүләр мондый «эләгү» өчен күңелләреннән сөенеп тә куйдылар. Балчык өйдә, балчык коймалар эчендә йомран сыман яшәп ятучы бу ямьсез, шома кешене сөн ирләре шулай да яратып җиткермиләр иде.

Шул чакны каган урыныннан торды.

— Бу турыда кич тагын бер мәртәбә сөйләшербез,— диде ул ак киез өстендәге ирләргә карап.— Кичке ашка миңа килерсез.

Ирләр, киңәшнең шуның белән беткәнен аңлап, урыннарыннан тордылар да ишеккә юнәлделәр. Каган, Бүзбалага эндәшеп, Туңгак алып белән Исәнтәйне өйдә калдырырга кушты.

Юк, болай булгач, «эләкмәде» Исәнтәйгә!

X

Тәхет янында өч ир кешедән башка беркем дә калмагач, Туман каган авыр итеп бер көрсенде дә, әкрен генә сүз башлады.

— Бу арада минем тынычлыгым качты,— диде ул.— Чин дә, Чжао да, качаклар да — беркем мине кызыксындырмый. Синдә кунак булган теге төннән соң минем күземә берни күренми, Исәнтәй, колагыма берни ишетелми. Күз алдымда, зиһенемне томалап, теге гүзәл чин кызы тора. Мин анда бер хата ясадым. Ничек төзәтергә шул хатаны — менә нәрсә борчый мине!

Ул тагын бер көрсенеп куйды һәм беркемгә дә төбәп кенә карамыйча, һәркемгә күз йөртеп чыкты. Тәхет ягындагы ирләрнең берсе дә каган авызыннан мондый сүз ишетербез дип уйламаганнар иде. Бу бөтенләй көтелмәгән нәрсә булып чыкты һәм шуңа күрә алар барысы да баягыча авыз ачарга да куркып, тын гына утыра бирделәр. Каган аларга икенче тапкыр күз йөртеп чыкты. Бузбала түзмәде, тизрәк акланырга кирәк тапты.

— Мин Исәнтәйдә кунакта булмадым, шуңа күрә мин берни әйтә алмыйм, бөек каган,— диде.

— Мин Исәнтәйдә кунакта булдым, шулай да синең анда хата ясавыңны хәтерли алмыйм,— диде Туңгак алып.

Туман каган өченче тапкыр көрсенеп куйды. Үзенең хатасы турында сүз башлавы аңа бик авыр иде, күрәсең.

— Мин синең хата беләм, бөек каган,— диде Исәнтәй телгә килеп.

— Белсәң, әйтеп бир: ничек төзәтергә шуны?! — диде каган.

— Мин әйтте: кызны сиңа бирергә кирәк, дидем. Мин әйтте: сиңа сүзем бар, дидем. Син әйтте: кызыңны китер, сүзеңне урдада әйтерсең, диде.

— Әйе, исемдә. Шулайрак булды,— диде каган килешеп.— Менә хәзер әйтәсе сүзеңне дә әйт, киңәшеңне дә әйт.

Исәнтәйнең каган белән шундый кыю, иркен сөйләшүе, җитмәсә, аларның икесенең генә ниндидер уртак серләре булуы, гомумән, бу әрсез бәндәнең монда ак киез өстендә иркенләп, җәелеп утыруы Туңгак алыпның чиктән тыш эчен пошырды.

— Барысы да аңлашылды, бөек каган! — диде ул Исәнтәйгә аркылы төшеп.— Син теге тәгин угланга бүләк итеп бирелгән чин кызын әйтәсең бугай.

— Шул, шул! — диде каган ашыгып.

— Ул көнне синең тәгин углың сиңа сөенечле хәбәр китерде — бер! Ауда сине үлемнән коткарды — ике! Син үзең, үз кулың белән кызны аңа бүләк итеп бирдең — менә булды өч! — диде Туңгак алып.— Кайда монда синең хатаң? Исәнтәйдә булган төнне син берниндә хата ясамадың, бөек каган.

— Белмим, белмим,— диде каган чын күңелдән, аптырап.— Барысы да исемдә. Мин аны үзем бирдем, үз кулым белән. Шулай да мин аны оныта алмыйм. Ятсам да, торсам да ул минем күз алдымда.

— Син аны ярата, бөек каган! — диде Исәнтәй кабаланып.

— Әйе, яратам бугай,— диде каган.

— Ярату хата була алмый! — диде Туңгак алып шактый тупас итеп.

Ул моны каганны яклаудан бигрәк, Исәнтәйгә каршы төшү өчен генә әйтте. Үз кайгысына чумып утырган каган Туңгак алып белән Исәнтәйнең үзара әйтешә башлавын бөтенләй сизмәде. Исәнтәй исә барысын да сизеп-тоеп утырды. Шуңа күрә дә ул каравыл агасы Туңгак алыптан ничек тә алгарак чыгарга тырышып, кыюланып, яңадан һөҗүмгә ташланды.

— Туңгак алып дөрес әйтә,— диде ул елмаеп.— Каган ярата — хата имәс. Каган илдәге барлык кызларны яратса да, хата имәс. Тәгин угланга биргән кызны каган кире алса, шулай ук хата имәс!

— Нишләп ул алай? — диде Туңгак алып.

— Биргән бүләкне кире алу йоласы юк,— диде Бузбала да, Исәнтәйне усал күз карашы белән өтеп.

— Әйтеп бетер, Исәнтәй,— диде каган тылмачны яклап.

— Ул кызны чин качагы... «кара йөз» алып килде...— сиңа бүләккә, бөек каган!

— Миңа?! — диде каган шаккатып.— Нишләп аны башта ук әйтмәдең?

— Син мине тыңламадың, бөек каган,— диде Исәнтәй үз-үзен шактый тыныч тотып.

— Әйе, тыңламадым.

— Аны сиңа Чжао аксөякләре җибәргән. Ул кыз әлеге кара йөзнең сеңелесе, бөек каган.

— Шулай ук мени әле ул?! — диде каган чын күңелдән гаҗәпләнеп.

— Аңлашылды! — диде тагын Туңгак алып нидер әйтергә җыенып. Ләкин бу юлы Исәнтәй аңа үзен бүлдерергә ирек бирмәде.

— Мин киңәш итәм, бөек каган: бүләк — сиңа, кыз синеке. Кызны кире ал! — диде ул.

— Ничек? — диде каган.

— Болай булгач, мин болай уйлыйм,— диде Туңгак алып та яуга ташланып.— Үзеңә дигән бүләкне... аңламыйча, ялгыш тәгин угланга биргәнсең икән, аны үзеңә кире ала аласың. Сине ялгыш юлга этәргән өчен, кызның сиңа дип китерелгән булуын белеп тә, башта ук аны сиңа бирдермәгән өчен... тылмач Исәнтәйнең башын чаптырырга кирәк.

Мондый сүз ишетеп Исәнтәй кинәт күз алдында бөрешеп калды, кызгану, ярлыкау өмет итеп, шундук каганның аяк астына егылды.

— Син моңа ни әйтерсең, Бузбала? — диде каган, уң кул карачыга борылып.

— Кызны болай гына тартып алсаң, уң кул тучи бәк белән арагыз бозылыр,— диде Бузбала.— Тәгин углан белән бозылышу ул өлкән бичә белән, атаклы Котлуг бәк белән, Куян ыруы белән бозылышу дигән сүз. Ак өйдән тынычлык китсә, бөтен илдән тынычлык китәр, үзара ызгыш-талаш китәр. Сөннең көче үзара талашта түгел — бердәмлектә. Өч таган таймас, тайса берсе дә калмас, дип белми әйтмәгәннәр. Куян, Алан, Сөйбү ул өч таган дигән сүз. Синең туган ыруың, бөек каган, Сөнәнкәләр менә шул таган астында, ышыкта, түрдә утыручылар. Үзеңне җил-яңгырдан, кар-бураннан саклый торган таганны кисеп аударуны берничек тә аклап булмый. Шулай да синең ул чин кызын үзеңә аласың килә икән, моны бик уйлап эшләргә кирәк, өч таган таймаслык итеп... Бер чин кызы аркасында илдән тынычлык, татулык китәргә тиеш түгел. Кызны кире алсаң, бар гаепне Исәнтәйгә аударып, аның башын чаптырырга кирәк булачак. Ул чагында инде беркемнең сине яманларга теле бармаячак.

— Кичер, бөек каган! — диде Исәнтәй.

Туман каган озак кына уйланып утырды.

— Үз кулым белән бирмәгән булсам, мин Исәнтәйнең башын чаптырган да булыр идем,— диде ул Бузбала белән Туңгак алыпка җавап итеп.— Юк, монда баш чаптырып кына котылып булмый. Бүре дә тук булсын, сарык та исән калсын — менә нәрсә кирәк монда! Кем эшли ала шуны?

— Мин! — диде Исәнтәй аны-моны уйлап тормыйча.

— Эшлә,— диде каган киң күңеллелек күрсәтеп.— Эшли алсаң, түрәмдә утырырсың, баш тылмачым булырсың. Эшли алмасаң...

— Эшлим! — диде Исәнтәй, дөрләп янган утка ташланган кеше кебек, барлык батырлыгын җыеп.— Син, бөек каган, Табылдыкны тучи бәк тәгин угланга бирә, чин кызын үзеңә ала! Бүләк урынына бүләк. Бүре дә тук, сарык та исән!

Каганның йөзе ачылып китте. «Ишеттегезме?» дигән сыман, ул Бүзбала белән Туңгак алыпка карап алды.

— Башың үзеңдә калыр, ахрысы, эттән туган Исәнтәй! — диде ул карачы белән каравыл агасының нәрсә дә булса әйткәнен көтмичә.

— Уйлап карарга була,— диде Бүзбала килешкәндәй итеп.

Туңгак алып берни эндәшмәде.

XI

Кичке аш вакытында Исәнтәй ак киезнең уң ягында, тәхеткә бишалты кеше кала гына утырды. Мондый яңалыкны туган-тумача, агайэне бик тиз күреп алды. Исәнтәйнең шулай кисәк кенә түргә үрләвен күпчелек бер төрлерәк юрады: алып килгән теге «кара йөз»е, күрәсең, бик кирәкле кешедер, диделәр, озакламый илдә, урдада үзгәрешләр булмагае, диделәр. «Нинди үзгәреш булыр икән соң ул?» дигән сорауга шундук җавабы да табылды: «Чингә каршы каган олы яу күтәрер — башка тагын ни булсын?!» диделәр. Иртәнге күлемдә каганның биек Ак өйдә өч кеше белән генә калып ни турында сөйләшкәнен беркем дә белә алмады.

Каган үзе дә иртәнге сөйләшү турында уйланды, ләкин ул бөтенләй икенче төрле уй-теләкләр белән уйланды, Исәнтәйнең киңәше анда ышаныч тойгысы уятты һәм аның борчулы күңеленә берөзлексез җылы өстәп торды. Шулай да бу әле бәхет түгел иде. Шунлыктан әлегә ул сөенә алмады. Әлегә ул бары ниндидер өмет барлыгын гына шәйләде.

Йорт башының уйчанлыгын барысы да күреп, тоеп утырдылар. Кичке аш басынкы гына, шау-шусыз гына үтте. Туман каган, эчен тырнаган нәрсәләрне томаламакчы булып, бузаны күбрәк эчеп ташлады.

Төнне ул бик начар йоклады. Таңга таба каган төш күрде.

Төш бик куркыныч иде. Эсселәп, шыбыр тиргә батып ул кинәт уянып китте. Уянып китте дә, йөрәгенең дөп-дөп тибүен тыңлаган килеш, өй эчендәге сыекланган җылы караңгылыкка текәлеп, кымшанмыйча ята бирде.

Көн яктысы төшкән ниндидер тау итәгендә, ниндидер тирән су буенда яшь җирән бога белән карт юлбарыс сугышты. Иң элек су буенда, яшел болында утлап йөргән сыер көтүе күренде. Яшь җирән бога әлеге көтүнең башлыгы имеш. Мөгезләре очлы, муены кыска, аяклары нык. Күзләре уттай яна. Үзе шундый зур, таза!

Каяндыр шул чакны камышлар арасыннан сак кына атлап, якягына каранып, юлбарыс килеп чыкты. Килеп чыкты да бу, искәрмәстән көтү өстенә ташланды һәм бер-бер артлы сыерларны ботарларга да тотынды! Бер сыерның канын гына суыра да, икенчесенә ташлана. Сыерлар тузына, качыша башладылар. Бары яшь җирән бога гына, баскан җиреннән әз генә дә кузгалмыйча, урынында торып калды. Авызы-борыны канга буялган карт юлбарыс ырылдап кинәт моңа таба ыргылды. Ләкин яшь бога әз генә дә курку сиздермәде — башын түбән иеп, күзләрен уттай яндырып, көтеп тора бу моның килеп җиткәнен. Юлбарыс шүрләгәндәй итте, туктап калды һәм якындагы тауларны калтыратып, бар көченә үкереп җибәрде.

Шулай кара-каршы килделәр дә болар, җирне-күкне дер селкетеп, ямьсез тавышлар белән кычкырып, сугышырга да керешеп киттеләр. Бик озак сугыштылар болар. Яшь җирән бога көтмәгәндә тегенең корсагына очлы мөгезләрен китереп батырды да, бар көченә ярсып

тегене баш өстенә күтәрде дә сырты аша җиргә орды. Шундый иттереп орды — еракта дөбердәп кыялар ишелеп төште, гөрселдәп җиргә мең яшәр карагайлар ауды. Яшь бога куанычыннан үкереп җибәрде.

Яралы юлбарыс, канлы эчәкләрен өстерәп, кыялы таулар ягына элдерде. Үзе чаба, үзе артына борылып карый да, яшь җирән богага яный имеш: бер сыерыңны калдырмый бугазлап бетерәм, үзеңне тере килеш кабып йотам, дип әйтә имеш. Моның шулай дигәнен ишетте дә яшь бога, борылып килеп, тегенең артыннан куа китте. Шулай да куып җитә алмады бу. Юлбарыс кыялар арасындагы үз оясына кереп качты. Кереп качты да, ояга керә торган юлны бик зур таш белән томалап куйды. Шулай итеп, котылды, исән калды юлбарыс!

...Туман каган, тынын кысып, өй эчендәге җылымса караңгылыкка карап ятты да ятты. Янында гына ефәк тышлы мамык ястыкларга, мендәрләргә күмелеп, берни белми йоклаган Табылдыкның тигез тын алуы ишетелде, кайдадыр тышта, еракта этләр өргәне ишетелде.

...Юлбарыс үз оясына кереп, тар сукмакны таш белән томалап куйгач та, югарыдан, текә кыялар арасыннан, канатлары белән бөтен яктылыкны каплап, каракош очып төште. Очып төште дә бу, очлы тырнаклары белән яралы юлбарысны эләктереп тә алды. Эләктереп алды һәм уктай атылып югары менеп тә китте.

Менә шул чагында Туман каган куркып кычкырып җибәрде. Юк, кычкыра да алмады — кычкырмакчы булып бары көчәнде генә. Яшь бога белән карт юлбарысның сугышын ул каяндыр читтән генә карап торган сыман иде. Юлбарысны каракош күтәреп киткәч ул нишләптер көтмәгәндә үзе юлбарыска әйләнде куйды!

Шулай итеп каракош аны... Туман каганны күтәреп алып китте!

Шулай итеп дөнья кайгылары онытылды.

Бу тегенди-мондый гына төш түгел иде, ахрысы. Бу ниндидер серле һәм хикмәтле төш булырга тиеш иде. Ләкин нәрсә булыр бу? Яшь бога кем дә, карт юлбарыс кем? Юлбарыс чыннан да Туман каган үзе булса, бу ни дигән сүз бу?!

XII

Төш юраууга, күрәзәгә һәм һәр төрле ырым-шырымнарга чын күңелдән ышана торган Туман каган бер генә зур эшен дә камнар, күрәзәчеләр белән киңәшмичә эшләми иде. Инде шундый куркыныч, бугалчык төш күргән икән, иң элек аны, билгеле, төш юраучыларга, күрәзәчеләргә сөйләргә кирәк иде. Баштарак ул шулай дип уйлады да. Ләкин, ныклап торып уйлана торгач, ул бөтенләй капма-каршы фикергә килде. Үзенең карт юлбарыска әйләнүен, юлбарысны каракош күтәреп алып китүен кемгә дә булса сөйләү дөрес булырмы? Бу бит төштә генә түгел, өндә дә үз-үзеңне ниндидер явыз каракошларга тотып бирү белән бер булачак! Синең шундый төш күрүеңне көнчел туганнарың, дошманнарың ишетеп калса, ул чагында алар сине терелэй тотып ашамаслармыни?!

Шулай булгач, нишләргә?

Бу бик авыр, бик катлаулы сорау иде. Моны хәл итмичә торып, моннан соң яшәргәме, яшәмәскәме? Яшәсәң, ничегрәк итеп яшәргә, дигән сорауны хәл итеп булмаячак кебек иде. Төшне беркемгә дә сөйләмичә, мәңге аны күңелеңдә яшереп калырга да булыр иде, билгеле. Ләкин бу инде йөрәк турысына килеп кадалган ук тимерен тартып алмыйча, шул көенчә яшәп ятарга азаплану белән бер булыр иде. Төш аркылы ата-баба, изге ияләр исән калганнарга киңәш бирәләр, аларны кисәтәләр, аларга туры юл күрсәтәләр.

Шулай булгач, теләсәң дә, теләмәсәң дә төшнең серен ачыкларга кирәк булачак. Туман каганның барлык киңәшчеләреннән дә якынрак бер киңәшче-сердәше бар иде. Ул да булса, Баргынтай баба иде. Баргынтай баба — аның үлгән атасының ана ягыннан үги агасы. Сөнәнкә ыруында ул каганнар тамырының иң карт кешесе, бөтен ыруга ата урынына калган кеше.

Торып иртәнге йомышларын йомышлагач, киенгәч, тарангач, Туман каган Баргынтай бабаны алырга кеше җибәрде. Баргынтай баба урданың уртанчы бөҗрасында яши иде. Көттермичә ул тиз арада килеп тә җитте. Каганның үзенә генә әйтәсе ниндидер сүзе барлыгын ул, билгеле, сизенми калмады. Шулай да иртәнге аш янында ул-бу турында берниндн сүз булмады. Бары тик ашап-эчкәч һәм өч аяклы түгәрәк өстәлне, табак-савытларны ашчылар Ак өйнең икенче ягына алып чыгып киткәч кенә каган Баргынтай бабага үз янына күчебрәк утырырга кушты.

Күк гөмбәзедәй биек, иркен өйнең ярты ягында Баргынтай баба белән икәүдән-икәү генә калгач, калын чыбылдык артыннан берәрсе тыңлап тормасын дигән сыман, тавышын әкренәйтеп, Туман каган аңа әлеге төшен сөйләде. Ул аңа барысын да түкми-чәчми сөйләде, тик ахырга таба гына аны тагын икеләнү биләп алды. Үзенең карт юлбарыска әйләнүен әйтергә аның шулай да кыюлыгы җитмәде.

Каганның нидер яшереп калуын Баргынтай баба сизеп утырды. Ләкин ул берни сорашмады. Бөтен ыруда иң карт кеше булса да, мондый икәүдән-икәү сөйләшүләрдә, киңәш-табышта аеруча сак булырга кирәклеген ул инде белә иде. Шуңа күрә зур гәүдәле, бай киемле ир уртасы каган алдында тезләнеп, башын иебрәк утырган чандыр карт беренче булып сүз башларга ашыкмады.

— Ник эндәшмисең, Баргынтай баба? — диде каган тынып утыру озакка сузыла башлагач.

— Изге төш бу, углым,— диде Баргынтай баба, башын калкытып.

Каган, җиңеләеп, ат сыман пошкырып куйды. Тезләре өстендә җансыз булып яткан авыр йодрыклары үзеннән-үзе язылып китте.

— Беркайчан да синең мондый изге төш күргәнең булмады,— диде күңеле күтәрелеп киткән карт.— Өндә син үзең карт юлбарыс үтерден. Төштә менә тагын карт юлбарыс! Изге бу, изге төш. Карт юлбарыс ул — карт, явыз Чин иле...

Баргынтай бабаның шулай дип әйтүе булды, Туман каган, әле генә җиңеләеп сулыш алгандагы кебек, янә дә ат пошкырган сыман көрсенеп куйды. Шул ук мәлдә аның ирексездән сул күз кабагы тартыша башлады. Бик нык эче пошса, үртәлсә, ачуланса һәм шул вакытта үзенең күңелсез тойгыларын эченә яшерсә, аның шулай сул күз кабагы тартыша башлый. Моны Баргынтай баба да, башкалар да беләләр һәм мондый чакта ничек тә аннан читтәрәк булырга тырышалар иде. Шулай да Баргынтай баба төш юравын батырларча дәвам итте.

— Берәм-берәм сыерларны бугазлаган сыман, бер-бер артлы алты йортны аяк астына салып таптаган Чин юлбарысы чәнчелер, иншалла! — диде ул.— Аның үзен кем егар, кем сөзеп эчеп айкар яшь җирән бога сыман? Синме? Күрәсең шулайдыр, углым.

— Бирсен тәңрем! — диде каган.

— Бу әле төш юрау түгел,— диде Баргынтай баба.— Бу — минем теләк, синең теләк. Дөньяда эшләр синең теләк, минем теләк буенча гына бармый. Барлык эшләр изге ата-бабаларның теләге буенча, тәңренең боерыгы буенча бара. Без бары тәңренең боерыгын үтәүчеләр генә. Синең төшеңдә аңлашылмаган нәрсәләр бар, изге каган.

Үз уйларына бирелеп утырган каган шундук башын калкытты. Бу юлы да ул шаулатып көрсенүдән үз-үзен тыеп кала алды.

— Карт юлбарысны Чин дип, яшь боганы Сөн дип уйласак, бу дөрес булмаячак,— диде Баргынтай баба, каш астыннан гына каганны күзәтеп.— Сөн иле, яшь богадай көчле булса да, аңа инде күптән мең яшь тулган. Сөннәр күп халыклардан элегрәк барлыкка килгәннәр. Сөннәр — тәңренең иң сөекле балалары. Шуңа күрә дә алар иксез-чиксез көтүлекләрне, тау-ташларны, урманнарны үз кулларына алганнар. Җунго әнә төрле яктан биек таулар белән, диңгез белән чикләнгән тар, кысан үзәнлектә торып калган. Инде карт юлбарысны бүгенге Чин йорты дип уйласак, монысы бөтенләй хата булачак. Чин әле аягына да баса алмаган сабый бала кебек кенә.

— Сүзләрең изге, Баргынтай баба,— диде каган тыңламыйча.— Яхшы сүзләрең өчен миннән сиңа кеш якалы тун, йөгәнле, иярле кашка бирерләр.

— Бай бул, изге каган!

— Инде турысын әйт: сөйләргәме юраучыларга бу төшне? — диде каган чандыр картның йөзенә туры карап.

— Төшең буталчык, углым,— диде Баргынтай баба,— Анаң Кортка-бикәдән башка беркемнең башы җитмәс бу төшне юрарга.

XIII

Анасы Кортка-бикә янына Туман каган үзе китте. Бер үзе. Бай киемнәрен дә кимәде, егетләрен дә алмады. Карт алашасына атланды да, күңелендәге каршылыклы уйларын җиңеп, тешен кысып, башын иеп анасы янына китте.

Туман каганның анасы Кортка-бикә урдадан биш-алты чакрым читтә, төн ягында кечерәк бер күл буенда яши иде. Каган урдасы кая гына күченеп китмәсен, кайда гына утырып калмасын, теләсә кайда, теләсә кайчан ул үзенең өлкән углыннан шулай биш-алты, кайчагында сигез-тугыз чакрым чамасы читтә, төньякта булырга тырыша иде. Бары тик су ягы кыенга туры килгәндә генә ул урдага, димәк, суга якынрак җиргә утыра, ләкин беркайчан да каганның биек Ак өен әйләндереп алган бокралар эченә керми иде. Каганы өеннән кала аның өе якын-тирәдә иң биек, иң зур өйләрдән санала иде. Каган өен, өч кат тыгыз бокра булып, атлы, кораллы торгаклар әйләндереп алган булса, аның өен дә шулай ук өч кат бокра булып тыгызланып, кечерәк, ярлырак өйләр әйләндереп алган иде. Тик ул өйләрдә бернинди торгаклар да, кораллы ирләр дә юк. Ул ярлы өйләрдә Кортка-бикәнең үз кешеләре — йөзләгән, меңләгән ырудашлары, коллары, төрле авырулар, ярлылар, аяк-кулсыз карт-корылар яши иде.

Карт атка атланган таза ир кешенең туп-туры үзләренә таба килүен аксак-туксак ирләр — элекке сугышчылар — ерактан ук күреп алдылар. Беравык алар аны танымыйчарак тордылар. Танып алдылар да, барысы берьюлы диярлек куанып кычкырып җибәрделәр. Титаклап бер-икесе шундук өйгә — Кортка-бикә янына йөгерде, калган бер-икесе — тазарак, төзегрәк күренгәннәре каган каршысына ашыкты. Атын үз көенчә генә атлатып килгән Туман каган тышкы бокрага барып җиткәнче алар аның каршысына килеп тә җиттеләр, атының йөгәненнән тотып та алдылар. Шунда берсе, олы кунакка ирдән төшәргә булышып, аның аяк табанына зур учын куйды, икенчесе, биектән сикергән баланы тотып алырга җыенган сыман, аны тотып алырга әзерләнеп торды, өченчесе дәрте сүнгән, юаш, карт алашаның сөякчел маңгаеннан, күкрәгеннән сөештергән булды. Каган җиргә баскач, аксак-туксакларның берсе юл күрсәтеп алдан китте, икенчесе, куанычыннан нишләргә белмичә, алаша белән туктаусыз сөйләнеп алдан титаклады.

Ярлы, караңгы өйләр артында каганга сәләмә туннарына төренеп өй буенда утырган ниндидер карчыклар, үзара ыгы-зыгы килеп кузна уйнаган бала-чагалар очрады. Мондагы ярлылык, мондагы күңелсезлек каганның ачуын китерде. Бу аксак-туксак ирләрне, авыру корткаларны, караеп, тишелеп беткән, кырык җирдән ямаулы өйләре-ниләре белән аның бөтенесен бер өемгә өеп ут төртеп яндырасы, я булмаса тау-ташлар арасындагы берәр упкынга илтеп аударасы килде. Анасы белән, билгеле. Тик менә төшне генә юрасын да...

Каганның анасы Кортка-бикә үзе болай бер дә ярлы түгел иде. Аның үзенә беркетелгән унике мең өйле иле, көтүләре, көтүлекләре бар. Теләсә ул үз өен дә, үзен әйләндереп алган башка өйләрне дә өр-яңа киездән кордыра алган булыр иде һәм теләсә аның тирәсендә бер генә сәләмә киемле карт-коры да булмас иде. Каганның анасы буларак ул биек Ак өйнең һәрвакыт түрендә, табынның мулында утыра алган булыр иде. Ләкин ул әнә теләми. Аның менә шундый ярлы булып, углы каган тарафыннан кыерсытылган булып күренәсе килә.

Моннан унҗиде-унсигез еллар элек ул бер дә андый түгел иде. Туманның атасы, Кортка-бикәнең ире каган үлгәч, Алан ыруының Бай-Тимер яклылар Сөнәнкәнекеләргә каршы баш күтәрделәр. Бай-Тимернекеләр урда аксөякләренең шактыен үз якларына аударып өлгергәннәр иде инде. Урдада бик каты суеш булыры көн кебек ачык иде. Менә шунда Кортка-бикә, каршы яктагыларның кайберләрен үз ягына аударып, кайберәүләренә иркәләп, кайберәүләрен куркытып, тиз арада дилбегәне үз кулына алып өлгерде һәм өлкән углы Туманны биек Ак өйнең түренә утыртуга иреште. Бай-Тимер җиңелде. Аның яклы бик күпләрнең башлары аяклары астына тәгәрәп төште.

Каган булгач, Туман ни теләсәм шуны эшләрмен дип уйлаган иде. Ләкин чынлыкта эшләр бик үк алай булып чыкмады. Әледән-әле аның эшенә, тормышына Кортка-бикә кысыла башлады. Ире каган исән чакта аны уч төбендә биеткән усал, үзсүзле, холыксыз хатын үзенең өлкән углын да уч төбендә биетмәкче булды. Һәм, чыннан да, тәхеткә утыруның беренче елларында каган ничек тә анасы теләгәнчә эшләргә, ул теләгәнчә яшәргә тырышты. Шулай да тора-бара аның вактөяк киңәшләре, еш кабатланган холыксызлыклары ачуын китерә башлады.

Көннәрдән бер көнне алар бозылышып киттеләр. Бик каты бозылыштылар! Туман каган әйтте: алтын тәхеткә мин синең итәгеңә ябышып яшәү өчен утырмадым, диде. Анасы әйтте: мин утырттым анда сине, мин! диде. Мин булмаган булсам, син инде күптән атаң янында җир куенында яткан булыр идең, диде. Атаң исән чакта мин бөтен Сөн илен үз кулымда тоттым, син каган булгач, миңа сигез мең өй бирдең дә, коры таякка калдырдың, диде. Дүрт мең өйлек Сөйбүләр аның бирнә буларак артыннан килгән үз байлыгы иде.

Шушы ызгышудан соң Кортка-бикә шулай да углының эшенә, тормышына кысылмый башлады. Ләкин шул ук вакытта ул урдадан аерылып, «башкаланып» чыгып китте. Урдадан аерым яшәсә дә ул углы яныннан бик үк читкә дә китмәде. Болай яшәү аның өчен бик тә җайлы иде. Әкренләп ул урданың барлык камнарын, күрәзәчеләрен, имче-томчыларын үз тирәсенә туплады һәм алар аша итәк астыннан ут йөртә башлады. Озакламый ул үзен Ана-кам дип белдерде һәм барлык дин-йола эшен үз кулына алды. Шулай итеп, ул барыбер җиңелмәде!

Хәер, Туман каган беркайчан да аны җиңәргә уйламады да. Нинди генә булмасын, ана — изге, үз анасына каршы кул күтәргән кешене яшен сугачак иде. Шулай ук Кортка-бикә дә үз углына каршы бер-

кайчан да бернинди яманлык эшләмәде бугай. Итәк астыннан ут йөрткәндә дә ул турыдан-туры каганга зыян ясамаска тырышты.

Анасы башкаланып яши башлаганнан бирле Туман каганның менә шулай аның биләмәсенә беренче мәртәбә аяк басуы иде.

XIV

Кортка-бикәнең тыштан караганда каганныкы кебек биек, иркен өе, янына килгәч, якын тирәдәге ярлы өйләрдән әлләни аерылып тормый иде. Кайчандыр кардай ак булган киезләр караеп, ямалып беткән. Өйнең итәкләре тетелгән, теләсә ничек ямап, тарттырып куелган. Өй янындагы казыкларда изге ата-бабаларның — Бүре, Аю, Куян кебек абаларның[1] җилдә-яңгырда шомарып, агарып беткән баш сөякләре ырҗаеп тора; казыктан казыкка сузылган кыл арканнарда очлы тешләр, усал тырнаклар тирбәлә, йомшак койрыклар җилферди. Ишек катындагы иң биек казык башында, канатларын киң җәеп, кара тугбөркет чайкала.

Өйнең үгез тиресе белән тышланган ишеген билсез карт ачты. Беренче ишектән кергәч, эчтә, бусага төбендә каганны икенче бер гарип каршылады. Кулыннан тотып ул аны бусага янындагы агач-ат[2] янына алып килде, утыртты. Икенче бер аксак карт, олы кунак килүен әйтергә дип, өйнең түр ягына таба атлады. «Ничек кылана!» — дип уйлады каган анасы турында, яратмыйча.

Каган углының үз янына килерен Кортка-бикә бөтенләй көтмәгән иде ахрысы. Әлерәк кенә ниндидер тире кисәкләре, канатлар, койрыклар белән булышкан җиреннән ул бар эшен ташлап, шулай да өстендәге сәләмә киемнәрен алыштырмыйча, илтотмыш бикә сыман, өенең уң ягында, биек ятагында аякларын бөкләп утыра иде. Шунда ук, Кортка-бикәнең аягы астында, сәләмә киемле, корышкан йөзле бернičә карчык тынып калган. Башына Корткы-бикә куян тиресе тотылган мескен бүрек, өстенә — җирән йон күлмәк, күлмәк өстеннән тире күртәнә[3], аякларына — кыршылып беткән болан итекләр кигән иде.

Ябыклыктан ияк очлары, яңак сөякләре күзгә төртелердәй булып торган чандыр карчык үзенең чак-чак кына каушап калган игелексез углына сынап, исе китеп һәм шактый ягымлы итеп карады. Туман каган исә, мышнап, кызарынып, авырлык белән генә анасы алдында билен бөкте, баш киемен салып, башын иде.

— Кичер, анам,— диде ул таштай авыр, кытыршы сүзләрен каяндыр төптән тартып чыгарып.

Анасының ни өчен үзен кичерергә тиешлеген ул үзе дә аңлап җитмәде, ләкин бу очрашуда, мондый очрашуда ул аңа бары тик шундый гына сүз әйтергә тиеш иде сыман.

— Ананның ничек яшәгәнен күрергә килдеңмени, балам? — диде Кортка-бикә җиңелчә мыскыл белән.— Менә, күр: мине ачлар туендыра, тунсызлар киендерә. Аксак-туксаклар минем көтүләремне көтә, тишек-тошык өемне җылыта. Мин инде күптән атаң янына киткән булыр идем — изгеләр җибәрми. Миннән алда алар сине көтәләр, углым!

Еллар буена җыелып килгән сүзләрен, ачуын-үпкәсен тизрәк әйтеп бетерергә тырышкан сыман, Кортка-бикә ашыгып, кабаланып сөйләде. Аның чатнап торган чәрелдек-яңгыравык тавышы каганга куркыныч һәм шомлы булып ишетелде. Анасының соңгы сүзләре аның йөрәгенә агулы ук булып кадалды. Ул, үзенең тирли башлавын тоеп, авыр кулын битенә якынайтты.

---

[1] Аба — мифик ата-ана, баба. Ыруның-кабиләнең нәсел башы. Абалар гадәттә берәр ерткыч кыяфәтендә булганнар.

[2] Агач-ат — агач утыргыч.

[3] Күртәнә — кыска тун, куртка.

— Мин сине чакырып кеше җибәрәм, син килмисең,— диде мышнап.

— Куалап җибәргәнеңне оныттыңмыни? — диде Кортка-бикә тыңламыйча.

— Мин сине куаламадым, анам. Син үзең киттең,— диде каган.

— Син мине чүплек башына чыгарып ташладың! — дип кычкырды Кортка-бикә кинәт ярсып китеп.— Син мине үлсен диден. Мин әле үлмәдем. Мине изгеләр яклый. Кул күтәреп бер дога кылсам, менә шунда сине җир йотачак, игелексез! Биек ак өйгә баш булу өчен син күпме туганнарыңның, күпме ырудашларыңның канын койдың?! Тәмугта сиңа барысы өчен дә җавап бирергә туры киләчәк.

— Анам! — диде каган түземлеген җуя башлап.

— Әйе, мин — синең анаң. Изге анаң! — дип кычкырды биек ятакта аякларын бөкләп утырган Кортка-бикә, нурсыз күзләреннән усал очкыннар чәчрәтеп.— Нишләп аны әле генә исеңә төшердең?

— Мин сине гел исемдә тотам, изге анам,— диде каган ялганлап.— Менә синең шундый көнгә төшүеңне ишеттем дә, үз күзләрем белән күрмәкче булып, янында килдем. Мин сиңа, изге анам, туену өчен... өч мең өйлек ил-көн, көтүләр, көтүлекләр бирмәкче булдым.

Ул моны әле генә уйлап тапты. Күрешми торган арада Кортка-бикә бик нык үзгәргән иде һәм берәр майлы калҗа ташламыйча торып, күрәсең, анын күңелен җиңел генә яулап алып булмаячак иде. «Майлы калҗа» чыннан да үзенекен итте. Тиле кортка, углының соңгы сүзләрен ишетеп, кисәк кенә тынып, юашланып калды һәм тыела алмыйча җылап җибәрде.

— Атаң исән булса, мин дә монда аксак-туксак белән бер табакган ашап, каткан киез өстендә йокламас идем,— диде ул, борынын тарткалап.

— Урдага кайт — янымда гына булырсың, изге анам,— диде каган.— Алдында алтын табаклар, баш астында мамык түшәкләр булыр.

— Юк, юк! — диде карчык йокыдан уянган сыман.— Мин инде бу өемне теләсәм дә ташлап китә алмыйм. Әнә, күрәсеңме, алар мине дүрт күз белән күзәтеп торалар! Мине алар җибәрми.

Ул очлы тешләрен ыржайткан баш сөякләренә ымлап күрсәтте. Туман каган ирексездән изге абаларга карап алды. Аңа чыннан да өйнең барлык төшеннән — астан, өстән, ян-яклардан кемнәрдер күзәтеп, сагалап торалардыр сыман тоелды. Анын тизрәк төп сүзгә күчәсе килде.

Углының уйларын сизенгән кебек, Кортка-бикә шундук кымыз китерергә кушты. Кымызны бары үзе генә эчә торган савытка — юка алтын калай белән тышланган, эчке ягы исә көмеш калай белән капланган баш сөягенә агызды. Кымызны Кортка-бикә, йола буенча, иң элек Ут-анага бирде, аннары үзе авыз итте дә углына тоттырды. Каган эчеп бетергәч ул, кулын селтәп, өй эчендәгеләрнең барысына да чыгып китәргә боерды. Шуннан соң, бөтенләй тынычланып, юашланып калган изге бер кыяфәттә:

— Төшеңне сөйлә, углым,— диде.

— Төшне?! — диде Туман каган шаккатып.

— Куркыныч төшеңне сөйлә, балам,— диде Кортка-бикә.

— Син... изге анам, каян беләсең аны? — диде каган.

— Мин барысын да беләм,— диде Кортка-бикә тыныч, серле бер өстенлек белән.— Миңа изге абалар җиткереп тора. Кара аны, бер нәрсәңне дә яшереп калдырма.

«Баргынтай баба җиткерде микәнни?» дип уйлады каган, әле булса исенә килә алмыйча. Ләкин, алай дисәң, Кортка-бикә беләч алар — дошманнар.

Углының икеләнүен Ана-кам шундук чамалап алды.

— Миңа ышанмагач, ник килдең монда? — диде ул усал гына итеп.

«Ул чыннан да изге!» дип уйлады Туман каган исе китеп.

XV

Төшне каган анасына түкми-чәчми сөйләде.

Тыңлап бетерү белән, Кортка-бикә сикереп урыныннан торды, шомарып беткән баганадагы шомарып беткән дөңгерен кулына алды һәм шундук бөтенләй икенче кыяфәткә керде. Күзләрен акайтып, бөтен тәне, өстендәге сәләмәләре белән калтыранып, дөңгердәге шөлдерләрен, тимер, сөяк кисәкләрен шакылдатып-шалтыратып, бар көченә: «Алас! Алас!» дип кычкырып җибәрде. Атка атланган килеш якякка тирбәлеп, чайкалып баргандагы сыман, кызу-кызу атлап ул өй эчен өч мәртәбә әйләнеп чыкты. Шуннан соң, кемнәр беләндер бик каты сугышкан шикелле, кемнәрнедер куа-куа, арып-алҗып, хәлдән таеп, яңадан үз урынына килеп ауды. Килеп ауды да, күзләрен йомып, кул-аякларын хәлсез салындырып, беравык мәрткә китеп ятты.

Ниһаять, ул башын калкытты. Берни эндәшмичә, беркемне күрмичә шактый тынып утырды. Каяндыр җир астыннанмы, калын киез артыннанмы сөйләшкән сыман, тавышын үзгәртеп, серле һәм шомлы итеп:

— Кем син, и адәми зат? — диде.

Анасының күз алдында шулай үзгәрә алуы игелексез угланны янә тетрәндереп җибәрде.

— Синең өлкәң углың каган бу, изге Ана-кам,— диде ул, дер-дер калтыранып.

— Син Кара-тау иясен... изге абаны аткансың,— диде Кортка-бикә бераз көттереп.— Кара-тау иясенә атап корбан бир.

— Бирермен, изге анам,— диде Туман каган.

— Ул төнне ятагыңда үзеңнән башка кем бар иде?

— Ы-ы,— диде каган төртелеп.— Яшь кыз. Табылдык атлы.

— Аны абаларга бирерсең,— диде Ана-кам боздай салкын, дәртсез бер тавыш белән.

— Бирермен...— диде каган әкрен генә һәм шул ук мәлдә сөекле Табылдыгын, аннан да бигрәк, гүзәл чин кызын уйлап, кинәт тирләп чыкты.

Болай булгач Куяннар белән чынлап та бозылышырга туры килер микәнни? Әллә соң киңәш сорап караргамы? Ярамас. Ул чин кызы турында авыз ачсаң, аны да үзенә тартып алырга күп сорамас бу... изге анаң! Юк, аны әлегә бирмибез абаларга!

Кортка-бикә, углын сынаган сыман, озак кына эндәшми утырды.

— Яшь җирән богадан саклан,— диде ул аннары каганның тынычланганын күреп.

Яшь җирән бога турында ишетү белән Туман каган икенче мәртәбә уяныи киткәндәй булды.

— Кем ул, кем яшь җирән бога?

— Ул синең баш балаң уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга булыр,— диде Ана-кам ап-ачык итеп.— Аны ничек тә үзеңнән ераграк тот.

— Ничек аңларга моны, изге анам? — диде каган коты алынып.— Ул минем сөекле углым! Ул мине үлемнән коткарды.

— Син кем өчен яшисең, Туман каган? — диде Ана-кам, корыган агач шыгырдаган сыман дәртсез, салкын бер гамьсезлек белән.

— Мин... ни... синең өчен, изге анам, Илем-көнем өчен, балаларым өчен!

— Ялган сөйлисең! — диде Ана-кам усал итеп.— Син үзең өчен генә яшисең. Сиңа тәңре көч бирде, ил-көн бирде, тәхет бирде. Көчең киткәнче тәхетеңне кулыңнан ычкындырма. Көчең киткәч, тәңре барысын да үзе тартып алыр.

— Нишләргә соң, изге анам? — диде каган, яшь җирән боганы күз алдында тотып.

— Барысы да тәңре ирегендә,— диде Ана-кам аның тел төбен аңлап.— Үзең бармак белән дә чиртәсе булма. Чин карасыннан дүрт курчагын ясат, дүрт якка күмдер. Курчак ясаучыны Кара-тау иясенә корбан итеп бир.

— Бирермен, изге анам! — диде каган төштәге сыман.

— Хы-хы!— диде Ана-кам явыз көлемсерәп.— Бүре дә тук булсын, сарык та исән калсынмы?!. Булмый ул алай!

— Син анысын да беләсеңмени?! — диде каган яңадан гаҗәпкә калып.

— Беләм, барысын да беләм! — диде серле карчык.— Син генә белмисең минем ниләр белгәнемне. Мин барын да күреп, ишетеп торам. Миңа изгеләр җиткерә!

Туман каган, исерек кебек тынып, басылып утырып торды да, авыраеп калган аякларын көчкә кузгатып, алпан-тилпән атлап ишеккә таба юнәлде. Аның тизрәк моннан — изге, куркыныч анасы яныннан чыгып китәсе килде. Ул нәрсә уйларга да белмәде, аның күңелендәге бөтен нәрсә бергә буталып, баш-аяк килде. Баргынтай баба белән сөйләшер алдыннан да, монда килер алдыннан да ул үзе ничектер башкачарак фикер йөрткән иде. Үзе яралы юлбарыс булган очракта да, яшь җирән бога, аныңча, өлкән углы Албуга түгел, бөтенләй икенче берәү — үзенә баш бирмәскә тырышкан берәр башбаштак булырга тиеш сыман тоелган иде. Баксаң, әнә ул ничек икән эшләр!

Кортка-бикә беркайчан да Куяннарны яратмады. Элек-электән ул аларны яманларга җай табып кына торды. Ире каган исән чагында ул Куяннарга каршы этлек эшләүдән дә тартынып тормады. Куяннан килен булып төшкән Күрекле бикәне дә, аның балаларын да ул бик үк өнәп бетермәде. Аларга карата нишләп шулай дошманлык саклагандыр ул — чынын гына беркем дә белми иде. Яшь чагында Котлуг бәк белән аның арасында нindидер серле, күңелсез нәрсә булган ахрысы,— имеш-мимеш шулай сөйли иде.

Менә хәзер бөек углы каганның төшен юраганда да ул Куяннарга карата әүвәлге шул дошманлыгын исендә тотмады микән? Анасының Куян ыруыныкыларга карата мөнәсәбәтен яхшы белгән Туман каган шулай дип уйлый ала иде, билгеле. Ләкин алай дип уйларга аның хәзер нишләптер башы җитмәде. Анасы камның изгелеге, серлелеге алдында аның тәмам зиһене томаланды. Ул бары шаккатты, аптырап, каушап калды һәм үзен өермәдәй бөтереп алган каршылыклы уйларына, тойгыларына баш була алмыйча, куркыныч язмыш алдында — күзгә күренмәгән, ләкин әледән-әле үзен сиздереп торган яшерен көчләр алдында ихтыярсыз сыгылып төште.

XVI

Урдага ул бик төшенке күңел белән кайтты. Аның нindидер кайгысы барлыгын өйдәгеләр барысы да күреп алдылар, тынып калдылар һәм, йорт башының күзенә күренүдән куркып, су сипкәндәй каядыр юкка чыктылар.

— Бүзбала кая? — дип кычкырды каган, түргә узып.

— Бүзбала! Бүзбала! — дип пышылдадылар анда-монда өйдәгеләр, карачыны эзләп.

Бүзбала ниндидер эш белән Атсыз күл аръягына, көтүчеләр янына киткән иде. Аны тиз генә алып кайтырга дип йомышчыны җибәрделәр. Йомышчы Бүзбаланы тиз арада эзләп тапты һәм серле пышылдап: «Атабыз ачулы!» диде. Бүзбала барысын да аңлап алды. Урдага кайткач ул каган янына үзеннән алда Табылдыкны кертеп җибәрде.

Каган янында үзенең нинди зур көчкә ия булуын белгән яшь, сылу кырнак, көлеп-елмаеп, тәхет янына кыю гына килде:

— Син арыгансың, хуҗам! Сине чишендермәгәннәр дә! — дип сөйләнде ул, кайгылы-ачулы ир кешенең өстен-башын чишендермәкче булып.

Каган аның сүзләрен, әйтерсең, ишетмәде дә — кыз килеп кергәндә ничек утырган булса, ул килеп үзенә орынгач та шул килеш кымшанмыйча утыруында булды.

— Абау, синең төсең качкан! — диде Табылдык куркып.

Ул йомшак кайнар кулы белән ир кешенең тез өстендә яткан җансыз кулын сыйпады, шаяртып, кытыклап, аның салынып төшкән мыек чылгыйларына кагылгалап алды. Ләкин яшь, сөекле кырнагы күпме генә тырышмасын, таш кыядай калкып утырган куркыныч ирнең таштай йөзе барыбер ачылмады. Яшь кыз курка калды, хуҗасының тезләренә утырды да, ике куллап аның юан муеныннан кочып, тирәнгә яшеренгән төпсез күзләренә карады. Кирәк чакта утлы очкыннар чәчрәтеп яна торган, кирәк чакта җылы нур таратып елмая торган тере күзләрдә Табылдык тетрәндергеч моң-сагыш һәм кайгы күрде.

— Чирләдеңме әллә, хуҗам? — диде яшь кыз, чын-чынлап куркуга төшеп.

— Юк,— диде каган авыр гына.

— Алайса ни булды?

— Берни булмады.

— Син мине яратмый башладың! — диде Табылдык һәм үпкәләп еларга да керешеп китте.

Каганның ниндидер гүзәл чин кызы турында уйлап кайгыруы турында ул инде белеп өлгергән иде. Хәзер дә каган, күрәсең, шул кыз өчен бетеренәдер, дип уйлады һәм аның яшь күңелен көнчелек ялкыны өтеп алды. Аның кайнар яшьләре таш кыяның таш йөрәген урыныннан кузгатты. Авыр кулын көчкә күтәреп, ул сирәк була торган бер ярату белән, иркәләү һәм саклык белән кызны күкрәгенә кысты.

— Мин сине генә яратам... беләсең ич,— диде ул сүзләрен бик авырлык белән сайлап.

Яшь кызга шуннан артыгы кирәкми дә иде — ул шундук елмаеп куйды, битеннән агып төшкән күз яшьләрен теле белән ялый-ялый йомшак чәчләре, кайнар яңаклары белән кырыс ирнең киң күкрәгенә сыенды.

Бик нык ашыккан булып шул чагында өйгә Бүзбала килеп керде. Ярыктан ул барысын да күзәтеп торган иде. Сөекле кырнагын иркәләп утырган каганны ул инде тынычланды дип уйлады һәм, түргә үк килеп җитмичә тезләнеп баш иде дә, тамак кырып:

— Мин монда, бөек каган,— диде.

Каган аны күрде, ишетте, шулай да, Бүзбала көткәнчә, Табылдыкны тез өстеннән төшерергә ашыкмады. Карачыга бу бик сәер тоелды — каганның әле беркайчан да тезенә гүзәл кызлар утырткан килеш үзенең карачысы белән сөйләшкәне юк иде. Яшь кырнак та, ике ир янында үзенең артык икәнлеген аңлап, аягына басмакчы булды. Каган аны ычкындырмады.

— Мин монда! — диде Бүзбала кабатлап.

— Күрәм,— диде каган тонык кына.— Бире кил, Бүзбала.

Бүзбала якынрак килде.

— Мин үтереп алып кайткан теге юлбарыс тиресен анам Кортка-бикәгә илтеп бирсеннәр,— диде каган, каядыр читкә карап.

— Ник? — диде Бүзбала гаҗәпләнеп.

Үзе кадап алган юлбарыс тиресе каганның иң зур куанычы иде.

— Кара-тау иясе булган ул.

— Ярар. Илтеп бирерләр.

— Аннан соң...— диде каган көчәнеп,— менә... Табылдык кырнакны да... Ана-камга... Кортка-бикәгә...

— Аһ! — диде Табылдык сискәнеп, күзләрен зур ачып.

Йомшак, кайнар билдән кысып тоткан тимер куллар да, таштай каты муеннан кочып алган яшь куллар да — дүртесе дә берьюлы бушап калды. Беркем беркемне тотмады, тоткарламады. Яшь кыз, кылыч белән чабылган дошман башы сыман, балта белән чабылган агач сыман, сынсыз калып идәнгә шуышып төште.

Каган да, Бүзбала да, бер-берсенә күзләрен күтәреп карарга кыймыйча, ачуланышкан кешеләр кебек, икесе ике якка төбәлеп тик тордылар. Яшь кыз кинәт исенә килде, сикереп урыныннан торды һәм алтын тәхетендә кымшанмыйча утырган ир кешенең алдына килеп капланды.

— Кызган мине, хуҗам! Ана-кам мине абаларга бирәчәк, ул мине утлы табада кыздырачак, ул мине тереләй җиргә күмәчәк! — диде ул такмаклап, өзгәләнеп.— Бөек хуҗам, коткар мине. Яратмасаң ярат-ма — миң тамчы да көнләшмим. Гүзәл чин кызының ялчысы булырмын, көн дә аның аягын юармын — яныңнан гына җибәрмә!

Туман каган Бүзбалага ым какты. Бүзбала, шуны гына көтеп торган кебек, тиз арада урыныннан купты, яшь, сылу кырнакны ике куллап күтәреп алды да каядыр китеп тә барды.

— Кызганыгыз, кызганыгыз! Бирмәгез Ана-камга, бирмәгез! — дип кычкырды Табылдык, Бүзбаланың каты кулларыннан ычкынмакчы булып.

XVII

Биек Ак өйдә мәет чыккандагы кебек күңелсез булып калды. Бу күңелсезлек кичке аш вакытында да сакланды. Башка көннәрдә үзе белән бер табактан ашаган туган-тумачаларын, якын ирләрен каган аерым сыйларга кушты. Үзе ул бушап, котсызланып калган өендә ашады. Аның янында бары өч кенә кеше бар иде: аларның берсе Бүзбала булса, икенчесе Туңгак алып, өченчесе Исәнтәй.

Ашаганда-эчкәндә каган «табын яме» өчен гадәттә берәр яшь кырнагын алып утыра иде. Соңгы бер ел буена диярлек аның «табын яме» Табылдык булды. Бүген кич ул күренмәде. Аш-суны да элеккечә кызлар түгел, олы яшьтәге хатыннар кертте. Бүзбала белән Туңгак алып моның серен белсәләр дә, Исәнтәй әле берни белми иде. Табылдыкның юклыгын ул үзенчә юрады. Күрәсең, каган аны, мин әйткәнчә, чин кызына алыштырып җибәргәндер, дип уйлады ул. Тик менә каганның күңелсез булуы гына бик үк аңлашылып җитми иде. Шулай да ул түзмәде, беренче булып шул хакта сүз башлады.

— Нишләп бүген гүзәл Табылдык күренми? — дип куйды ул үзалдына сөйләнеп.

Бүзбала белән Туңгак алып икесе берьюлы диярлек әрсез, әдәпсез тылмачка күтәрелеп карадылар. Туман каган, тамагына сөяк утыргандай, ашавыннан туктап калды, ләкин Исәнтәйгә бернинди шелтә белдермәде. Шулай ук ул аңа бернинди җавап та кайтармады.

Бары тик ашап туйгач кына ул Исәнтәйгә... өтеләнгән бер тылмачка үзенең кайгыларын сөйләп бирде. Бүзбала белән Туңгак алып каган-

ның Исәнтәйгә сөйләгән сүзләрен яратмыйча тын гына тыңлап утырдылар. Исәнтәйнең тәхет тирәсенә якынайганнан-якыная баруы аларның ачуын китерде.

— Менә шулай, син әйткәнчә барып чыкмады. Исәнтәй,— диде каган.— Табылдыктан да колак кактым, чин кызын да ала алмадым. Җитмәсә, менә тагын бу төш... яшь бога... курчак... Берсе өстенә икенчесе өстәлеп кенә тора!

Бүзбала белән Туңгак алыпны бөтенләй күрмәгәндәй, каган туры Исәнтәйгә карап сөйләде. Мондый катлаулы, четрекле мәсьәләдә аның Исәнтәйдән нинди дә булса төпле, акыллы сүз ишетергә теләве әллә каян күренеп тора иде. Бүген ул, бик сирәк очракларда гына булганча, чамадан тыш басынкы, юаш һәм аталарча ягымлы иде. Сабый бала кебек, ул ни әйтсәң дә каршы килмәс, нәрсә әйтсәң дә берсүзсез ышаныр төсле иде. Исәнтәйгә ул нәкъ шундый булып күренде дә. Үзенең көтмәгәндә югарыга үрли баруын аңлаудан кыюлыгы бермә-бер арткан Исәнтәй бу юлы да беренче булып яуга ташланды.

— Мин болай уйлыйм, бөек каган,— диде ул сораганны да көтмәстән сүз башлап.— Ана-кам изге абалар белән аралаша. Ул белеп әйтә. Курчак ясый торган ирләр миндә бар. Таштугайда. Тучи бәк тәгин угланның курчагын ясатуны, күрсәтелгән урынга күмүне мин үзем эшлим. Ана-кам белеп әйтә: син үзең аңа бармак белән дә чиртмәссең. Синнән боерык булса, тәңре катына да... мин үзем озатырмын, бөек каган!

Туңгак алып түзмәде, ярсып башын калкытты һәм оятсыз тылмачка карата чиксез бер нәфрәт белән:

— Исәнтәйнең кулы да озын, теле дә озын, ахрысы,— диде.— Синнән боерык булса, бөек каган, мин аның телен дә, кулын да кыскартыр идем!

Исәнтәй, йөзенә китереп суккандай, кызарынып китте. Ярдәм сораган сыман, ул каган ягынарак күченеп утырды.

— Киңәшеңне әйт, Туңгак алып,— диде каган ызгышучы ике якның берсенә дә катышмыйча, юаш кына.

— Турысын әйтимме, сиңа яраклы итеп әйтимме, бөек каган? — диде Туңгак алып тынычлана алмыйча.

— Ни уйласаң, шуны әйт.

— Мин турысын әйтәм! — диде Туңгак алып.— Ана-камның: үзеңнән читтә тот, дигәнен Исәнтәй сиңа ялгыш аңлатмакчы була, бөек каган. Үзеңнән читтә тотуны Ана-кам тәңре катына озатырга кирәк дип түгел, урдадан читтә тотарга кирәк дип уйлап әйткән. Уң кул тучи бәк тәгин угланны үзеңнән читтә тоту ул — аны урдадан читкә сөрү дигән сүз. Дүрт мөгезнең[1] берсе — уң кул тучи бәк тәгин углан ул синең улың гына түгел, ул бөтен Сөн иленең углы, аның киләчәге, аның ышанычы. Бер языгы булмаган килеш, бары күңелсез төш күргәнең өчен генә, ялгыш киңәш бирүчеләр коткысына бирелеп, син аны тәңре катына озата алмыйсың, бөек каган!

— Киңәшеңне әйт,— диде каган бүлдереп.

---

[1] Дүрт мөгез — сөннәрдә иң атаклы бәкләр шулай «дүрт мөгез» дип аталган. «Дүрт мөгез»дән башка тагын «алты мөгез» дә булган. «Алты мөгез»ләр «дүрт мөгез»ләргә караганда түбәнрәк дәрәҗәдә исәпләнгәннәр. Терлек мөгезе (башлыча үгез мөгезе) борынгы төркиләрдә изге саналган һәм көч-куәт, хакимлек символы булган. Борынгы патшалар, фиргавеннәр, каганнар чын үгез мөгезе беркетелгән яисә ясалма мөгезе булган махсус баш киемнәре — бүрекләр, таҗлар кигәннәр. Татар телендә сакланып калган «мөгезле», «мөгезсез» сүзләре шул борынгы заман карашларын чагылдыра.

— Киңәшем шул: син аны өйләндереп, ил-көн, җир-су биреп, анасы белән бергә ил читенә җибәр. Ул шунда яшәр. Кирәк вакыты җиткәч, кире чакыртып алырсың.

— Син аңлатып сөйләдең,— диде каган Туңгак алыпка.— Минем үземнең дә аңа... яманлык эшлисем килми. Ана-камга каршы килмәс өчен генә булса да мин аны... өлкән углымны читләштерергә тиешмен.

— Мин әйтеп бетермәдем, бөек каган! — диде Исәнтәй.

Ләкин Бүзбала шундук аңа каршы төште.

— Син, Исәнтәй, бөек каганга чин кызын кире алып бирергә сүз биргән идең түгелме соң? — диде ул күрәләтә мыскыл белән.

— Минем әле баш тартканым юк!— диде Исәнтәй аптырап тормыйча.

— Син баш тарта алмыйсың, Исәнтәй,— диде каган йомшак кына итеп.

Аның бу йомшаклыгында бу юлы боеру сизелде. Ул инде үзенең төп кайгысыннан — яман төш тәэсиреннән айныган һәм аны инде башка төрле кайгылар борчый башлаган иде бугай.

Исәнтәй каушап калды.

— Болай булгач... Табылдык булмагач...— диде ул нидер әйтергә җыенып.

— Сиңа — өч көн вакыт, Исәнтәй,— диде каган таләп итеп.

XVIII

Каган яныннан Исәнтәй каравыл агасыннан калышыбрак чыкты. Текмәгә чаклы аңа теләсә дә, теләмәсә дә каравыл агасы белән янәшә атлап барырга туры килер иде. Аның хәзер аны күрәсе дә, ишетәсе дә килмәде. Юл буенча ул уйланып барды. Туңгак алып аңа иң куркыныч, иң көчле, хәтта каганның үзеннән дә көчлерәк һәм куркынычрак дошман булып тоелды. Шуңа күрә дә аның бөтен ачуы, бөтен нәфрәте каравыл агасына каршы юнәлде. Ул аны ничек тә баш аркылы чөяргә, аяк астына салып таптарга тиеш! Туктале, каганның күңелен генә күрсен әле, Ак өйдәге ак киездә аяк терәп утыра гына башласын әле, күрсәтер әле сиңа Исәнтәй күрмәгәнеңне! Җиңел генә баш чапмакчы була! Иң элек кемнең башын чабарлар — анысын әлегә әйтеп булмый. Туктале, тукта!..

Текмә капкасына җиткәнче ул шулай дөнья җимерердәй булып үзалдына тузынып барды. Текмә тышында аны җигүле арбасы, хезмәтче ирләре көтеп тора иде. Ул үзенең түбәсе ябулы арбасына кереп утырды да, уртанчы бoҗра ягына кузгалып китте. Аның каган бүләк итеп биргән яңа өе шунда — Көнчыгыш капкага таба барганда сул якта иде.

Арбага кереп утыргач, ул төлке тунының биек якасын күтәреп куйды. Йомшак, җылы йонлы яка аның битен, колакларын иркәләде, шул ук вакытта төн җирдән тирбәлеп, җиңелчә шакылдап тәгәрәгән көпчәкләр тавышы аны тынычландыра төште. Ямьсез, күңелсез уйлар әкренләп онытыла барды.

Аның мәрхүм атасы да менә шулай якасын күтәреп ике көпчәкле арбага утырдыммы, тынычланып калам дип сөйләр иде. Җунго осталары эшләгән, җунгоча бизәлгән арбаның тынычландыра торган, юата торган ниндидер сихри көче бар бугай.

Гомере буена атасы аның үз туган иленә кайту турында, анда кайтып күңелле, бай, иркен тормыш башлап җибәрү турында хыялланды. Үзенең түбет хатынынннан туган бердәнбер углына ул җае чыккан саен тегендә, күксел таулар артында торып калган туган җире турында сөйләде, үзенең бала чакларын, сөекле әтисен, ягымлы әни-

сен исенә төшерде. Яшь Хуа ап-ак чәчәккә күмелеп утырган чия бакчаларын, күлдә яшел таллар арасында суга чумып уйнаган үрдәкләрне, җиңел күлмәк кигән, күбәләктәй җиңел, алсу таңдай гүзәл Җунго кызларын төшләрендә күрде. Әтисенең туган җире аның аңына мәңге җәй, мәңге кояш, яшеллек һәм тынычлык хакимлек иткән сихри ил булып сеңеп калды. Инде зур үсеп, яшьлек хыяллары челпәрәмә килә башлагач та ул әлеге сихри-гүзәл күренешләргә чын күңелдән табынып яшәде. Ак чәчәккә күмелеп утырган бакчалар артында, кояш яктысын чагылдырган тирән күл уртасында, түгәрәк утрау эчендә еш кына аның күңел күзенә алтын түбәле ак сарайлар күренде. Хәзер инде ул чия куаклары арасындагы күбәләктәй кызлар турында түгел, әнә шул алтын түбәле ак сарайлар турында хыялланды.

Теге яктан качып чыккан каралар, коллар, юлбасарлар аңа Күк асты илендәге коточкыч хәлләр турында сөйләделәр. Ләкин ул коточкыч нәрсәләр: ачлык, үлем, җәбер-золым, туктаусыз яулар-сугышлар — берсе дә аңа ныклап торып тәэсир итмәде. Андый сүзләргә ул чынында ышанмады да, ышанырга туры килгән очракта да, аларны үзенчә аңлады. «Анда ничек — мондагыдан җылыракмы, чияләр чәчәк атамы, күл уртасындагы алтын түбәле ван сарайлары исәнме?» — дип сорады ул коточкыч хәбәр сөйләүчеләрдән. «Җылы! Чияләр чәчәк ата. Алтын түбәле сарайлар да бар. Күп, бик күп алар. Тик алар барысы да биек коймалар белән әйләндереп алынган»,— дип җавап бирделәр аңа. «Сарайлар исән булгач, Җунго да исән»,— дип уйлады Исәнтәй-Банхуа, үз күңелен үзе тынычландырып.

Күксел таулар артындагы җылы, серле илдә аның күңел күзенә алтын сарайлардан, ак чәчәккә күмелеп утырган бакчалардан башка нәрсә күренмәсә дә, шулай да ул андагы барлык яңалыкны, барлык үзгәрешне биш бармагы кебек белеп торды. Күпчелек хәбәрне аңа качаклар алып килде. Ләкин аңа шулай ук качаклар белмәгән, белә алмаган хәбәрләр дә килеп җитте. Чжао аксөякләре каганга бүләк итеп җибәрәчәк кыз белән ышанычлы ирнең киләчәген ул моннан өч ай элек белгән иде инде.

Әйе, белгән иде. Тик ул гүзәл чин кызы белән әлеге ышанычлы ир килеп төшкәч нияр буласын гына белә алмаган иде. Тегендәгеләр алдан уйлаганча, каган урдасына Банхуа түгел, Чәнси үтеп керергә тиеш иде. Банхуа аңа кулыннан килгәнчә булышырга гына тиеш. Эшләр әнә бөтенләй киресенчә килеп чыкты. Төптән уйлап караганда, урдага үтеп керүнең, бозра эчендә киез өйдә яшәүнең аңа бөтенләй кирәге юк иде. Тегендә, таулар арасында, ни әйтсәң дә, тынычрак. Чияләр чәчәк атып утырган бакчаларың, түгәрәк күл уртасында алтын сарайларың булмаса да яхшырак иде анда! Дөрес, каган аның андагы энәсенә дә тимәде. Анда бар нәрсәгә баш булып өлкән углы калды. Аннан соң гүзәл чин кызының «абыйсы»... Чәнси анда.

Шулай итеп, «ышанычлы» Чәнси каган өенә түгел, Банхуа өенә үтеп керде. Исәнтәй моңа сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәде. Шулай ук Чәнси үзе дә мондый хәлгә әллә ни куаныч белдермәде. Бөтен нәрсәдә гаепне ул бары аннан — Банхуадан күрде һәм, үзенең кайдалыгын, кемлеген онытып, аңа инде янап алырга да өлгерде. Исәнтәй аның янавына көлеп кенә куйды. Теләсә ул аны җиңел генә юкка да чыгара алган булыр иде. Ләкин аның артында күзгә күренмәгән көч, байлык барлыгын һәм андагылар — көч, байлык ияләре белән исәпләшергә кирәклеген белгәнгә күрә ул тешен кысып түзәргә булды. Ул мондагыларга да, андагыларга да ярарга тиеш иде. Анда аның яман аты чыкса, иң элек качаклар аннан читләшә башлаячаклар, аннары аңа инде беркем дә бушлай ефәк, дөге, корал һәм гүзәл кызлар озатып тормаячак.

Менә шуңа күрә дә ул «кара йөз»нең үз өенә үтеп керүенә, аның янауларына бармак аша карарга, ничек тә аның белән ныклап торып бозылышмаска булды. Ләкин шулай да чын-чынлап бозылышмас өчен, иң элек бозылган, чуалган эшне төзәтергә кирәк иде. Тунгак алып турында онытып, ул әлегә шул турыда уйлый башлады.

XIX

Икенче көнне Исәнтәй дүрт тәгәрмәчле чуман арбага дөяләр җигәргә кушты. Монда киез өйдә булган барлык байлыгын диярлек ул арбага төятте, арбаның өстен чыбылдык белән яптырды. Шуннан соң ул үзенең ике тәгәрмәчле яхшы арбасына утырды да, Кортка-бикә авылына карап юлга чыкты.

Элеп киптергәндәй корышып беткән, тешсез, холыксыз, тиле-миле Кортка-бикәне Исәнтәй җаны-тәне белән яратмады. Аның җыерчыклы йөзен күрү белән, аның күңелендә даладан, даладагы барлык үлетередән җирәнү тойгысы уянды. Ләкин, шулай булса да, барлык сөннәр арасында менә шул корышып беткән кортка аның өчен иң кирәкле кеше иде. Каганның, бәкләрнең сылурак, яшьрәк бичәләреннән, хатыннарыннан ул Кортка-бикәне артыграк күрде һәм аның ямалып беткән, аксак-туксак белән тулы өендә ешрак булды. Ни өчен дигәндә, урдадагы, илдәге бик күпләрнең язмышы менә шул тишек-тошык кара өйгә, тиле-миле карчыкка килеп тоташа. Күпчелек каралар тәңредән, явыз ияләрдән килә дип уйлаган төрле үзгәрешләр дә кайчагында менә шул көч-куәт иясе Ана-камнан башлана иде. Сөн ияләренә, сөн йолаларына ныклап ышанмаган, җунго ияләрен, җунго йолаларын ныклап белмәгән һәм шуңа күрә күктәге аллалар көченнән бигрәк үз көченә, үз акылына ышанган динсез Банхуа-Исәнтәй йола һәм язмыш мәсьәләсендәге күп нәрсәләрнең серен күптән инде аңлап өлгергән иде.

Шулай да ул, сөн диненә ышанмаса да, барлык йолаларны бик тырышып үтәде. Төрле җыеннар, йола туйлары алдыннан ул үзенең ата-бабасына атап Кортка-бикәгә хәер китерде. Аннан ул бик теләп борынгы сөн гадәтләрен, йолаларын белеште, күрәзәчелек, багу, төш юрау серләренә төшенергә тырышты. Менә шулай чөке-чөке килеп сөйләнгәләгән арада ул Кортка-бикә авызыннан күп кенә яңа хәбәрләр һәм урдага, каганга, бәкләргә кагылышлы серләр дә ишеткәләде. Менә шундый файдалы дуслыкны югалтмау өчен ул берниен дә кызганмады.

Бу юлы да ул бүләккә дип ефәкнең Кортка-бикә яраткан төсләрен генә алды. Ефәккә өстәп дөге, киндер тукыма, аю тиресе, яхшы итеп эшкәртелгән, алтынлап төрле сурәтләр төшерелгән болан мөгезе алды. Ләкин иң кирәге ефәк тә, дөге дә, болан мөгезе дә түгел иде. Кортка-бикә өчен иң кирәге — чин качаклары кайнаткан куәтле буза иде.

Кортка-бикәнең аксак-туксак ирләре Исәнтәйне каганны каршылаганнан ким каршыламадылар. Аның таныш арбасы күренү белән, ерактан ук аңа каршы йөгереп килделәр. Өйләр янына барып җиткәнче алар аның аты, дөяләре, арбалары яныннан титаклап бардылар. Өйләр янына килеп җиткәч аңа арбадан төшәргә булыштылар.

Ана-камның үзәктәге өенә Исәнтәй җәяүләп китте. Дөяләргә җигелгән, бүләкләр төялгән авыр арбаны аксак-туксак ирләр әкрен генә арттан алып килделәр. Биек өй янында тышкы ишек сакчысы Исәнтәйгә бераз көтеп торырга кушты. Кайчан гына, ничек кенә килмәсен, Кортка-бикә аны шулай бераз көттермичә кертми иде. Исәнтәй үзен чакырганны башын түбән иеп, тыйнак кына, буйсынучан гына көтеп торды.

Ниһаять, аңа керергә куштылар. Бусагадан атлау белән, Кортка-бикәнең ятак өстендәге таныш йөзен күрү белән, Исәнтәй тезләнде, баш орды һәм мукәләп диярлек түргә якынлашты.

— Изге анам! Атама, анама багышлап мин сиңа хәер алып килдем. Барлыгы бер чуман әйбер: ефәк, дөге, тире, мөгез... Алырсыңмы шуларны? — диде ул, Ана-камга күтәрелеп карарга кыймыйча.

— Тагын ниләрең бар? — диде Кортка-бикә, бүләкләргә исе китмичә.

— Барысы да бар, изге анам,— диде Исәнтәй серле итеп.

— Алырмын, кертсеннәр.

Исәнтәй ялт кына артына борылды. Ишек сакчысы кортка, аның күз карашын аңлап, шундук тышкы якка башын тыкты, кемгәдер нидер әйтте һәм шул ук мәлдә диярлек ике таза ир — Исәнтәйнең ирләре хәергә китерелгән әйберләрне өйгә ташый башладылар. Аларга ишек төбеннән ары узарга ярамый иде. Авыр-авыр төргәкләрне, капчыкларны түргә чаклы Исәнтәй үзе ташыды. Барысын да ул учак янындагы, уртадагы ак киезгә өеп куйды да, янәдән артка, элекке урынына барып тезләнде.

Кортка-бикә, биек ятагыннан төшеп, төргәкләрне, капчыкларны берәм-берәм тоткалап карады.

— Хәерне күп китергәнсең, Исәнтәй! Баегансың ахрысы,— диде ул кеткелдәп.

Мондый мактау сүзләреннән Исәнтәйнең түбәсе күккә тиде. Гадәтенчә ул елмаеп алды һәм, үз-үзен белешмәстән, түргә таба омтылыш ясады.

— Изге анам! Баедым — бөек каган мине үз янына алды,— диде ул чиксез сөенеп.— Куанычым зур булганга, саранланып тормадым — кичер мине, изге анам!

— Синең урдага күченеп килүеңне беләм.

— Нинди теләкләрең бар — кулдан килгәннең барысын да үтәрмен, изге анам,— диде Исәнтәй ялагайланып.

— Ачы суыңны авыз итеп карыйсым килә... синең белән бергә,— диде карчык бөтенләй үз итеп, якын итеп.

Исәнтәйгә ул, буза салынган сабаны[1] алып, үзе янынарак күченеп утырырга кушты. Шуннан соң ул өстәл чыгарырга боерды. Исәнтәй эчемлек белән булашкан арада, теге яктан кемдер тавыш-тынсыз гына чыгып, карчыкның биек ятагы янына, буш урынга түгәрәк өстәл китереп куйды. Исәнтәй башын күтәреп караган иде, каршысында мәет кебек агарынган, ябыккан таныш сыман йөзне күреп гаҗәпкә калды. Таныш йөзле кыз да аны таныды һәм, оялыпмы, куркыпмы, йөзен шундук читкә борды.

Исәнтәй бөкесе ачылган буза тулы сабаны карчык янына куйды.

— Үзең агыз,— диде Кортка-бикә, алтынланган баш сөяген саба авызына якын тотып.

Исәнтәй агызды, авыр сабаны җайлап киез өстенә утыртып куйды. Ирексездән ул тагын теге кыз ягына борылып карады. Кыз урынында юк иде.

— Теге чин кызы да аның кебек сылумы? — диде Кортка-бикә көлемсерәп, киез ягына ымлап.

«Белеп тә өлгергән!» — дип уйлап алды Исәнтәй.

— Алай ук сылу димәс идем мин аны, изге анам,— диде ул бераз көттереп.

— Миңа аны бик чибәр диделәр.

Аның тавышында күрәләтә борчылу, пошыну сизелде. Яшь, сылу кызлар турында ул беркайчан да тыныч кына тыңлый алмый иде. Үз

[1] Саба — сыекча саклау өчен кулланылган күн капчык. Бурдакның бер төре.

углы каганның чибәр кырнакларына исә ул аеруча сагаеп, шикләнеп карый иде. Борын-борыннан килгән йола һәм ышану буенча, илдә балалар күп булсын өчен, терлек-туар туктаусыз үрчесен һәм ишәйсен өчен Сөн иленең каганы бар яктан да көч-куәткә ия булырга тиеш иде. Аеруча аның ирлек куәте булырга тиеш. Каган ул күктәге тәңренең җирдәге углы иде һәм ирлек куәте дә, башка төр көч-куәт тә аңа күктән, тәңредән иңдерелә иде. Каганның балалары күп булса, терлекләре үрчесә, аңа буйсынган ыруларның да — шулай булгач, бөтен Сөн иленең балалары күп булачак, терлек-туарлар ишле булачак иде. Ләкин бөтен илдә тигезлек, муллык булсын өчен, каган үзенең бичәләренә, кырнакларына тигез күз белән карарга тиеш. Ни өчен дигәндә, аның аксөяк ырулардан алынган бичәләре аша, кара сөякләрдән алынган кырнаклары аша бөтен илгә-көнгә изге көч тарала иде. Әгәр дә мәгәр ул бер хатынын ныграк яратып, башкаларын читкә тибәрсә, бер ыруга яхшылык, изгелек күбрәк төшәчәк, икенче ыру андый изгелектән мәхрүм калачак. Ил башы каганның алай эшләргә хакы юк.

Менә шуңа күрә дә Ана-кам Тәңре углы каганның көн саен кем белән кунуын белеп тора. Каган өендә аның беркем белми-сизми торган үз шымчылары — яшерен күзләре-колаклары бар иде.

Ләкин эш монда борынгы йолада гына да түгел. Йолага, дин кануннарына монда холыксыз карчыкның үз карашлары, үз теләкләре дә катышкан һәм бергә аралашып, ныклы бер кагыйдәгә әверелгән иде. Яшь, чибәр кырнакларны ул җаны-тәне белән яратмый. Кулыннан килсә ул барлык яшь, сылу кызларны үзе кебек корыган агачка әйләндереп бетерер иде. Шуңа күрә дә ул каганның иң яраткан кырнакларын, төрле сәбәп табып, үзенә чүпләп тора килде. Үзенә алгач ул аларны изге абаларга корбан итеп бирә.

Исәнтәй алып килгән эчемлекне авыз итеп карар алдыннан Ана-кам берничә тамчыны учакта йокымсырап яткан Ут-анага бирде, аннан соң, чак-чак кына чыраен сытып, алтын савытны авызына якын китерде. Исәнтәйгә ул яртылаш тулы савытны бирде. Исәнтәй дә бузаны бөтен йоласына туры китереп, башта Ут-ананы сыйлап ашыкмыйча гына эчте. Ул эчкән арада Ана-кам, күзләрен ярым йомган хәлдә, аяк-кулларына рәхәт җиңеллек таралганын көтеп утырды. Исәнтәй дә эчкәч, берни әйтмичә, шулай ук аның кебек күзләрен ярым йомып, үзендә изге җиңеллек барлыкка килүен көтә башлады.

Шулай озак кына көтеп утыргач, авыр тәненең җиңеләя башлавын тоеп, Исәнтәй:

— Изге анам, минем сиңа сүзем бар,— диде.

— Әйт, Исәнтәй,— диде Ана-кам ярым йомык күзләрен ачып карамыйча гына.

— Син үзеңнең өлкән колыңа олы бәтиенең дүрт курчагын ясап, дүрт җиргә күмәргә кушкансың. Моны ничек аңларга, изге анам?

— Мин аны колыма әйттем. Ул үзе ничек аңласа, шулай эшләр, Исәнтәй.

— Минем тагын бер үтенечем бар, изге анам,— диде Исәнтәй, карчыкка табарак елышып.

— Әйт, Исәнтәй,— диде Ана-кам.

— Әле генә монда булган карабашыңны мина сатмассыңмы, изге анам?

Карчык кинәт башын калкытты һәм үз каршысында эт кояшыдай балкып, майдай эреп утырган ир кешегә усал, ямьсез итеп карап тора башлады.

— Син... Исәнтәй! — диде ул зәһәр ысылдап.— Изге абаларга

корбан буласы беркемнең дә бу өйдән кире чыкмаганлыгын белмисеңме әллә?!

— Беләм,— диде Исәнтәй пышылдап.— Аның урынына мин сиңа икене... өчне бирермен. Өстәп тагын бүләкләр китерермен, изге анам!

— Күзең төштемени? — диде Ана-кам уйланып утыргандай иткәч.— Килеп йөрерсең, шунда бүләкләреңне дә алып килерсең.

Исәнтәйнең балкыган йөзе сүрелеп калды.

— Турысын әйтим микәнни соң?— диде ул үз-үзе белән киңәшләшкән сыман.

— Миннән сереңне яшерүнең кирәге юк.

— Синең колының аны бик яратты,— диде Исәнтәй әкрен генә, сүзләрен чамалап кына.— Аннан аерылгач ул кайгыга сабышты. Кайгыдан саулыгына, куәтенә көч килсә, яман булмагае. Менә ни өчен борчылам мин, изге анам!

— Чин кызын яратмый башлаганмыни минем колыным?

— Чин кызы аныкы имәс, изге анам,— диде Исәнтәй кыюсыз гына.

Ана-кам башын югары күтәрде һәм, Исәнтәйгә салкын, өшеткеч бер караш ташлады да, үтергеч итеп:

— Син, Исәнтәй, мине алдамакчы булып утырасың!— диде.— Мин барысын да беләм — синең кайда нинди сүз әйткәнеңне дә, менә монда нәрсә уйлаганыңны да! Ак өйгә кердем дә, ак киезгә утырдым да, әллә кем булдым дисеңме?! Минем колыныма киңәшләр бирә башладыңмы? Аңа киңәш бирер алдыннан иң элек син минем белән киңәшергә тиеш идең, Исәнтәй!

— Гаеп миндә, изге анам!— диде Исәнтәй ашыгып.— Моннан соң синең белән киңәшмичә берни эшләмәм.

— Синең, Исәнтәй, ак өйнең ак киезендә утырырга бернинди хакың юк,— диде карчык усал итеп.— Ак киездә утырырга хакың булмагач, киңәш бирергә дә хакың юк! Моннан соң синең бер генә киңәшең дә үтәлмәячәк, Исәнтәй!

— Кичер, изге анам!— диде тәмам каушап калган Исәнтәй.

— Мин барысын да белеп, ишетеп тордым, шуңа күрә аның баласы булмаган яшь кырнагын үз яныма алдырдым да,— диде карчык кызганнан-кыза барып.— Төшендеңме инде? Хәзер син шуны миннән кире алып, колынымның күңелен күрмәкче буласыңмы? Юк, сиңа ничек тә Ак өйнең ак киезендә, түрендә утырып калу кирәк!

— Мин аның боерыгын үтәргә тиешмен, изге анам,— диде Исәнтәй, маңгаендагы салкын тирләрен сөртеп.

— Син, Исәнтәй, аның боерыкларын түгел, минем боерыкларны үтәсәң генә теләкләреңә ирешерсең.

Исәнтәй, ниһаять, аңлап алды: бөтен куркуы, каушавы табан астыннан чыгып каядыр җиргә коелды. Ул үзенең ачышына ышанырга да, ышанмаска да белмәгән сыман, авызын ачып, сокланып, исе китеп корышкан карчыкка карап утырды. Юк, тиле-миле түгел бу карчык, башлы бу, усал бу карчык!

— Мин аңладым, изге анам,— диде Исәнтәй.— Моннан соң синең киңәштән башка бер адым да атламам. Изгелегеңнән ташлама мине!

— Мин сине ташламам!

Беравык алар тагын нидер көткән сыман тып-тын калып утырдылар.

— Чин кызы гүзәлме, Исәнтәй?— диде кинәт Кортка-бикә.

— Гүзәл, искиткеч гүзәл, изге анам!

— Син теләгәнчә булыр, Исәнтәй,— диде карчык, ниһаять, килешеп, ярым йомык күзләрен күтәреп карамыйча гына.

— Изге анам!— диде Исәнтәй ихлас бер омтылыш белән, карчыкның корышкан кулларын учына алып.

— Мин аны... син сораган кырнакны болай гына бирермен сиңа,— диде Ана-кам бөтенләй йомшап.— Тик кара аны, бәтиемнән тартып

алыначак гүзәл чин кызын сорап миңа киләсе булма! Мин аны сиңа да, башка беркемгә дә бирмәячәкмен. Ул минеке булачак, минеке!

«Синеке булырмы ул, башканыкымы — анысын әлегә әйтеп булмый. Хәзергә мин уйлаганча барып чыкса, миңа шул җиткән»,— дип уйлады Исәнтәй үзалдына. Ләкин шундук куркып карчыкның йөзенә игътибар белән карап алды — сизмәде микән аның нәрсә уйлаганын? Сизсә, харап эшләр!

Өченче баб

I

Өлкән бичә Күрекле бикәнең авылы урдадан төньяк-көнчыгыш якта, комлы калкулыклар арасында ялтырап яткан Тозлы күл буена урнашкан иде. Күлнең исеме генә Тозлы, чынында исә ул тозлы түгел иде. Моннан бик күп еллар элек Сөн баба күлнең суын беренче булып эчеп караган да, имеш, су аңа әчкелтем тоелган. «Тозлы күл ич бу!» дигән Сөн баба, төкеренеп. Шуннан, имеш, күлне дә Тозлы дип атаганнар. Ни өчен дигәндә, кояш чыгышы ягына карап барган саен әледән-әле анда вак тозлы күлләр очрый.

Бу якларның күлләрен, чишмәләрен дә, халыкта сөйләнелгән төрле имеш-мимешләрне дә Туңгак алып бик яхшы белә. Аның Аркача суының җир астыннан, кара ташлар арасыннан ургылып чыкканын да, ташлар арасыннан шаулап, сикереп акканын да күп мәртәбәләр күргәне бар. Кайсы елда кемнең бу якларда нинди киек атып алганлыгын, кем белән кем ызгышканын яисә татулашканын — ул барысын да, барысын да хәтерли ала. Хәтерләми мөмкин түгел — тормышы аның шушында, шушы җирдә үтә. Аның гына түгел, суның да, талларның-камышларның да тормышы аның күз алдында — кеше күзе алдында үтә бара.

Аркача суы тегендә җир астыннан бәреп чыга да, тоттырмас шук бала кебек, таулар-урманнар арасыннан чабарга тотына. Йөгерә-йөгерә ул иксез-чиксез иркенлеккә килеп чыга. Камышлы күл, сазлык аша үтеп киткәч, бер-ике төштә аңа кечерәк инешләр килеп кушыла. Шуннан соң ул киңәеп, ишәеп китә, көч җыя һәм, ярларына сыя алмагандай шаулап, һаман каядыр шуышуын белә. Кая бара, кая шуыша ул шулай? Кая булсын, билгеле, Тозлы күлгә!

Күлгә җитәрәк ул салмакланып, тыйнакланып кала. Тегендә, урта агымында ул яшь ирләрне хәтерләтсә, монда инде олы яшьтәге ирләргә охшап кала, аннары картая бара һәм күлгә кушылып юкка да чыга. Нинди кыска гомерле ул шулай да! Күп булса ул өч-дүрт көн яшәп кала. Ләкин аның бу өч-дүрт көнлек гомере туктаусыз алышынып, кабатланып тора, шуңа да ул мәңге хәрәкәттә, мәңге яшь булып тоела.

Камышлар, таллар менә озаграк гомерле. Алар беркая ашыкмыйлар, ашыга алмыйлар. Алар Җир-ана кендегенә береккәннәр.

Кеше кемгә ныграк охшаган соң — сугамы, талларгамы, камышларгамы? Кеше дә, Аркача су кебек, туып аягына басу белән, каядыр омтыла, нидер эшләмәкче була, нидер җимермәкче була. Иң ахырда сине я сугышта сөңге белән кадыйлар, я булмаса сиңа агулы ук тия. Үлгәч далада сине я ач бүреләр ашап китә, я тилгәннәр чукый. Көз көне саргаеп яфрагын койган таллар, камышлар кебек, күлгә килеп кушылган елгалар-инешләр кебек, син яңадан Җиргә кайтасың.

Ләкин барлык кеше дә шулаймы соң? Берәүләр тумыштан ук биек ак өйләрдә яши, алтын савытлардан ашап, затлы киемнәр кия. Икенче берәүләр тумыштан ук кол булып, кара булып туалар. Тумыштан ук биек ак өйләрдә яшәүчеләр башкалар арасында Кылыч-кыя кебек кал-

кып утыралар, бер ярыннан икенче яры күренмәгән Тозлы күл кебек, Диңгез-күл кебек, бөтен җирне иңләп-биләп яталар. Тумыштан ук кол булып, кара булып туган кешеләр, Кылыч-кыя итәгендә аунап яткан ташлар кебек, күлгә кушылып юкка чыккан инешләр, елгалар кебек, гомергә күренексез һәм кечкенә булып кала бирәләр.

Ул үзе — Туңгак алып — нәкъ менә шундый хәлдә түгелмени? Аның барлык көче, барлык күңел дәрте, йокысыз төннәре төпсез күлгә — биек Ак өйдәге аксөякләр буксәсенә төшеп, мәңге юкка чыга түгелмени? Бик теләсә дә инде ул беркайчан да кыя булып калка алмаячак, бөтен җирне биләп яткан мәгърур күл дә була алмаячак.

Атын җиңелчә юрттырып ул көне буена барды да барды. Әле тигез җирдән теркелдәде, әле сөзәк калкулык өстенә килеп менде, әле көтмәгәндә киң үзәнгә килеп чыкты. Унда-сулда көтүләр, ялгыз өйләр күренгәләп калды. Менә шулай далада, иркендә үзе генә калгач аның күңеленә төрле уйлар килде. Еш кына ул үзенең күңелсез, авыр үткән яшьлеген исенә төшерде. Мондый чакта ул үз-үзенә бик кызганыч булып тоелды. Шул чагында аның күңелендә моңарчы кайдадыр яшеренеп яткан горурлык тойгылары баш калкытты. Ул үзенең бөтен Сөн илендә атаклы алып булуын, каганның уң кулы, ышанычлы сакчысы булуын беркайчан да исеннән чыгармады, ләкин шул ук вакытта ул үзенең һаман да барыбер кол булып калуын да оныта алмады.

Әйе, кол булмаса, хәтәр юлга менә шулай җиңел генә чыгар идеме соң ул? Юк, күрәсең, чыкмас иде. Хәер, бу эшкә турыдан-туры Исәнтәйнең катнашы булмаса, бу хәтәр юлга ул сөенеп чыккан булыр иде. Бары каган боерыгын үтим дип уйласа, аның моңа алай ук эче дә пошмас иде, күрәсең. Бу эшнең Исәнтәй киңәше белән, Исәнтәй тырышлыгы белән эшләнгәнлеген белгәнгә күрә генә, өлкән бичә янына аны менә каган үзе түгел, бәлки Исәнтәй куалап җибәрде сыман тоелганга күрә аның ачуы килә түгелме соң? Әйе, шуңа гына бугай.

Юл буена ул шулай әле Исәнтәйгә үртәлеп, әле үзенең авыр язмышына ачынып барды. Тик шулай да Ак урда ерагаеп, өлкән бичә көтүлекләренә килеп кергәч, туктаусыз борчыган нәрсәләр үзеннән-үзе оныта барды. Күз алдына икенче күренешләр — якты, татлы күренешләр килде.

Юк, алай ук өлешсезләрдән түгел бугай әле ул бу дөньяда! Аркача су Тозлы күлгә килеп койса да, барыбер бөтенләй үк юкка чыкмый, Аркачаның суы күлне яшәтә. Күп төрле чишмәләр, инешләр килеп кушылмаса, комлы калкулыклар арасындагы Тозлы күл дә, башка күлләр дә инде күптән корып юкка чыккан булырлар иде. Туңгак алыплар, Салчак алыплар, башка йөзләгән, меңләгән ирләр, каралар булмаса, биек Ак өендә Туман каганнар тынычлап йоклый алмас иде. Изге каган Ак өендә тынычлап яши алмаса, Сөн иле дә — йөзләгән, меңләгән ирләр, каралар да, исәпсез-хисапсыз мал-туар да бу дөньяда яши алмас иде. Бит Тозлы күл дә суын үзендә генә саклап яшереп тотмый — ярларында аның таллар, камышлар үсә, суын терлек-туар эчә. Тозлы күлләр, елгалар, инешләр җирдәге барлык тереклекне туйдырып-туендырып торалар. Тереклекнең башы — суда. Менә ул бер-берсенә нинди нык бәйләнгән бу дөньяда барлык нәрсә! Шулай булгач, синең көч-куәтең, синең йокысыз төннәрең, синең кайгыларың, Туңгак алып, алтын тәхеттәге аксөякләргә генә түгел, үзеңә дә, үзең ише башка ирләргә дә, караларга да — барлык илеңә-көнеңә дә сарыф ителә түгелме соң? Әгәр син Туман каганның атаклы алыбы икәнсең, шул ук вакытта син бөтен Сөн иленең дә, барлык ил-көннең дә ышанычлы сакчысы буласың түгелме соң? Әйе, шулай.

Ул үзе дә күптән инде шушы якка килү турында хыяллана иде бит. Йомышын үти алмаган очракта да ул барыбер монда караңгы чырай

очратмаячак. Барыбер аны бай, жыйнак өйдә ягымлы йөз белән каршы алачаклар.

— На, Бахбай, тизрәк житик бикә урдасына!

II

Тозлы күл буена ул кояш баеганда килеп житте. Күрекле бикәнең авылы күлнең көнбатыш яр буена, ике калкулык арасындагы үзәнлек уртасына урнашкан иде. Туңгак алып авылга көньяктан — күл буенча бормаланып сузылган арба юлыннан килеп керде. Аның уң ягында өсте юка боз белән капланган, өстәл кебек тип-тигез күл ялтырап ятты, сул ягында биек калкулык кабарып утырды. Күлнең аргы ягында, еракта — дала белән күл чите тоташкан турыда, зур булып, кып-кызыл булып, кичке кояш баеп бара иде. Кызыл кояшның кызгылт нурлары, шома боз өстеннән чагылып, бу яктагы калкулыкка кадәр килеп житкән. Шуннлыктан бөтен тирә-як нурга күмелгән булып күренә һәм бу бераз гына серлелек, тантана тәэсире тудыра иде. Боз өстендә уйнап йөргән балалар, анда-санда утлап йөргән атлар, дөяләр бу серлелеккә, бу тантанага жылылык, якынлык тойгысы өсти сыман иде.

Авылга якыная барган саен Туңгак алып үзендә жиңелчә бер каушау, жилкенү тойды. Үземә йөкләтелгән бурычны үтәп чыга алырмын микән дип түгел, ничек каршыларлар икән, ничек очрашырбыз икән дип уйлаганга каушау һәм жилкенү тойды. Ул алга, калкулык артындагы ак өй түбәләре ягына карап барды. Аңа монда бар нәрсә таныш, якын иде. Ул, әйтерсең, монда каган йомышын үтәү өчен килми, киресенчә, бикә йомышын үтәп каяндыр кайтып килә иде.

Күкне, авылны каплап утырган калкулыклар озакламый артта калды. Алда, бозлы күлнең дәвамы сыман булып, соргылт киң жәймә белән капланган тар үзән сузылды. Үзән уртасында, күлдән бер чакрым ераклыкта, бер тирәгә укмашып, унлап-унбишләп киез өй күпереп утыра иде. Бергә укмашып утырган шул өйләр арасында, уртада, башкаларга караганда берсе биегрәк тә, нурлырак та булып күренде.

Күл буеннан читләшеп, үзәнгә таба борылгач та, калкулык буенда Туңгак алыпны өлкән бичәнең атлы торгаклары туктатты. Алар барлыгы биш-алты кеше иде һәм аларның барысы да күптәнге танышлар иде. Туңгак алыпны алар дусларча елмаеп, үз кеше итеп каршыладылар. Шулай да арадан берсе — унбашы болай гына, йола саклап кына Туңгак алыпның кемлеген, кая, ник баруын белеште.

— Өлкән бичә Күрекле бикә янына каган йомышы белән,— диде Туңгак алып.

Бикәгә хәбәр итү өчен унбашы шундук яшьрәк бер торгакны авылга жибәрде. Ул ерагайганчы Туңгак алып ирләр белән беравык гәп сатып торды. Меңбашы булса да, каганның каравыл агасы булса да, бикә ирләре белән ул масаймыйча, эреләнмичә сөйләште. Сөйләшә торгач сер итеп кенә ирләр мондагы кайбер яңалыкларны әйттеләр. Яңалыкларның иң зурысы чин кызы иде.

— Чибәр!

— Яңа туган ай кебек! Сабый бала кебек!— диделәр ирләр кызны мактап.

— Тәгин углан күзгә күренеп үзгәрде,— диде унбашы.

— Үзгәргәнен каян беләсең — аның хәзер күренгәне юк,— диде шунда икенче берсе.

— Үзгәрде! — диде унбашы.— Чин кызын алып кайткач та атын да, коралын да онытты.

— Егетләрен дә онытты. Аларга инде күптән Тарлавыкка китәргә вакыт җиткән — йөриләр теләсә кайда кангырап,— диде ирләрнең өченче берсе.

Шулай кыска гына очрашу вакытында Туңгак алып төрле хәбәрләр ишетте. Чин кызы, тәгин углан турындагы сүзләрне ул аеруча колак салып тыңлады. Шулай да монда озаклап сүз куертып та торып булмый иде — ул кузгалып китте. Торгакларның бер-икесе аны бикә өенә кадәр озата бардылар.

Өлкән бичәнең авылы, даладагы барлык бай авыллар кебек, берберсенә яны белән терәп куелган дүртәр тәгәрмәчле зур-зур арбалар белән әйләндереп алынган иде. Азык-төлек, кием-салым, тире-яры, сыутын төялгән, өсте ябулы бу арбаларның озын тәртәләре югары күтәрелеп, тышкы якка каратылган.

Авылны әйләндереп алган әлеге койманың көнчыгыш капкасы алдында Туңгак алыпны өлкән бичәнең баш багасы Кортага каршылады. Исәнлек-саулык сорашкач алар, капканы үтеп, туп-туры уртадагы биек ак өйгә таба юнәлделәр. Ак өйнең ишеге төбендә, җир өстендә сузылып яткан ак киез өстенә басып, ачык йөзү белән үзен көтеп торган бикәне күргәч, Туңгак алып бераз гына гаҗәпкә калды. Бу авылга, бу өйгә кем генә булып килмәсен, ул каганның өлкән бичәсе каршы алырдай зур, дәрәҗәле кеше түгел иде. Ул бары каганның йомышчысы гына иде һәм аны тик шундый ук дәрәҗәдәге кеше генә каршы алырга тиеш иде. Нидер булган бикәгә. Ни генә булса да, хәерлегә генә булсын, тәңрем.

III

Туңгак алып җиңел генә сикереп атыннан төште. Бераз җир ул бикәгә каршы җәяү барды. Өлкән бичәгә биш-алты адым кала тезләнде, баш орды. Шул ук мәлдә Күрекле бикә аягы астыннан аның янына зур ак киез төргәк тәгәрәп килде дә урталыкка сузылып ятты. Киез төргәген ике яктан ике кыз тәгәрәтеп китерде. Алар аны Туңгак алыпның аягы очына ук китереп җәйделәр.

— Түрдән уз, меңбашы Туңгак алып!— диде бикә елмаеп.

Ул уртадан калкурак буйлы, чандыр, чибәр, ягымлы бер хатын иде. Барлык дала хатыннарыныкы кебек аның да битен җил кискән, кояш ашаган, шулай да, үзен-үзе саклаганга, күрәсең, бите аның тупасланмаган, шактый яшь, сылу иде.

Туңгак алып киез өстеннән бер-ике адым гына атлады да тагын бикә алдына тез чүкте. Бикә аңа үзе каршы килде. Зур гәүдәле алып ир аның кечкенә, кайнар, йомшак кулын үпте. Бикә, егылган бала-чаганы торгызган кебек, кулыннан тотып, елмаеп аны аягына бастырды һәм беренче булып үзе өйгә таба кузгалып китте. Туңгак алып аның артыннан атлады.

Ишек янындагы казыкка җиткәч ул икеләнгәндәй итеп туктап калды, сораулы караш белән бикәгә, якындагы кешеләргә карады. Бикәнең һаман ягымлы йөзен күреп ул шундук үзенең коралларын сала башлады. Казыктагы чөйгә ул иң әлек, иплән кенә, җәясен, аннары ук тулы авыр ук савытын элде. Шуннан соң ул бил каешын, аркалык каешын, хәнҗәрен, пычагын, чакма таш янчыгын, сөңгесен, калканын — барлык сугыш коралларын элеп куйды. Авыр, очлы, куркыныч коралларыннан бушанып калгач, җаны-тәне белән, бөтен күңеле белән җиңеләеп ул бикә өенең ябулы ишегенә якынайды. Ул үзенең кораллары белән булашкан арада бикә дә, аның янындагы ирләр дә су сипкәндәй каядыр юк булганнар иде.

Бикәгә йомыш белән килгән ир кунакларны, түрә буенча, иң әлек аның — бикәнең багасы яисә берәр ир туганы каршы ала иде. Читтән

килгән ир кешегә, кунакка бикә белән сөйләшергә кирәк булса, шулай ук алар янында бикәнең баш багасы яисә берәр ир туганы булырга тиеш. Мондый чикләүләр, тыюлар һәм һәр төрле саклык чаралары каган бичәсенең исеменә тап төшермәү өчен, төрле имеш-мимешләргә юл куймау өчен кирәк иде.

Ләкин шул ук вакытта түрә белән исәпләшми торган, турыдан-туры түрәгә каршы килә торган борынгы йолалар да үз көчендә иде әле. Борынгы йола буенча бикә үз иреннән бөтенләй диярлек бәйсез иде. Ирләрне ул үз өендә каршы да ала, кунак та итә ала иде. Аксөяк кызларына, бөек каган бичәләренә үз ирләреннән тыш, болай гына, кирәк өчен генә тагын икенче ир тотарга да ярый иде.

Туңгак алыпны Күрекле бикә йола буенча каршылады. Аның алдында изүен ачык калдырып ул аңа үзенең күңеле дә ачык икәнлеген белдерде. Туңгак алып, өйнең тышкы ягындагы казыкта барлык коралларын калдырып, шулай ук аңа үзенең бу өй хуҗасына карата бернинди яман уе юклыгын сиздерде.

Шулай итеп алар бик тиз аңлаштылар.

Хәер, алар инде күптән аңлашканнар иде.

Моннан күп еллар элек кыпчакларның Тула суы буенда көченеп йөргән ыруларын җиңеп, илен-көнен туздыргач, яшь Туман каган аны — Туңгак алыпны әсир итеп алып кайтты. Алып кайтты да, берничә кызкыркын белән, үсмер малай белән бергә аны үзенең бичәсенә — ул чакта бердәнбер, яшь, гүзәл бичәсенә бүләк итеп бирде. Туңгак малай баштарак бикәнең көтүләрен көтте, соңыннан үсә төшкәч, яшьтәшләре арасында үзенең көчлелеге, булдыклылыгы белән аерыла башлагач, яшь бикә аны үзенә якынайтты. Ул аның ат караучысы да, кораллы торгагы да булды. Кол торгак, алып торгак су сөлегедәй сылу егет булып җиткәч, өлкән бичә аны тагын да ныграк якынайта төште. Бу вакытта Туман каганның Күрекле бикәсеннән башка инде өч бичәсе, кырыклап кызы-кырнагы бар иде. Шуңа күрә ул үзенең өлкән бичәсенә бик үк мохтаҗ түгел иде.

Кол егетне бикә, ахрысы, чын күңелдән яратты һәм, йолага таянып, икенче ир сайлап тормады. Үзеннән өлешсезрәк, булдыксызрак булган күп санлы яшьтәшләре кар-буранда, эсседә, яңгырда катып-калҗаеп, янып-пешеп көтү көтеп йөргәндә Туңгак кол, шулай итеп, тынычта, рәхәттә яшәде.

Бикә янында ул чыннан да бик күңелле яшәде. Шулай да мондый тормыш аны җиләтә башлады. Ул үзен икеләтә коллыкта, кысынлыкта итеп тойды. Аның каядыр иркенгә, ирекка чыгасы килде, ниндидер зурзур эшләр эшлисе, каядыр югарыга үрлисе килде. Ирекне ул каган коллыгыннан, сөннәрдән котылып, үз туган җиренә, туган ыруына китү дип аңламады. Үз ыруын ул бик аз хәтерләде. Хәтердә калганы да аңа ниндидер төштә күргән, кемдер сөйләгән томанлы истәлекләр генә булып тоелды. Ирекне ул өлкән бичә назыннан котылып, үзе теләгән берәр кол кызга өйләнү һәм үз оянны кору дип, үзеңчә яшәү дип аңлады. Аның инде күз атып, якын итеп йөргән кызы да бар иде. Ләкин бикәгә аның өйләнү турында сүз башларга кыюлыгы җитмәде. Бикә исә бу хакта башына да китереп карамады.

Шулай да ул аны үзенә бәйләп тә тота алмады. Кол егетнең күркәмлеге, батырлыгы турындагы, өлкән бичәнең аны башка барлык колларыннан артыграк күрүе турындагы имеш-мимешләр каганга да килеп иреште. Каган, билгеле, көнләшмәде. Аның бары андый булдыклы, яшь колны үз янына аласы гына килде. Бер кышны, яу чабар алдыннан, каган өлкән бичәсе карамагындагы ирләрне дә сугышка алдырды. Бу вакытта Туңгак алып бикәнең торгак агасы булып исәпләнелә иде. Барлык кораллы ирләр аңа буйсына иде. Шулай итеп бикә үзенең сөекле колын йөз кешелек алайга баш итеп, яуга җибәрергә мәҗбүр булды.

Яуда Туңгак алып үзен тиңсез батыр итеп күрсәтте. Аның батырлыклары турында соңыннан сөн ирләре бик озак сокланып, исләре китеп сөйләделәр. Менә шул яудан соң каган Туңгак алыпны үз урдасына алды. Алып колы белән аерылышу бик күңелсез булса да, өлкән бичә каган теләгенә каршы килә алмады. Ул бары Туман каганның аны — Туңгак алыпны — беркая да читкә җибәрмәвен генә үтенеп сорады.

Өлкән бичәсенең үтенечен каган бик яхшы аңлады. Бикә белән Туңгак алыпның бер-берсен яратуына ул әз генә дә аяк чалырга теләмәде. Каганны, урданы саклауда, каравыллауда менә шундый Туңгак алып кебек кешедән дә ышанычлырак колның булуы мөмкин түгел иде. Ул аны үзенең каравыл агасы итеп билгеләде. Шулай итеп, үз карамагына тапшырылган коралллы дүрт мең ир белән Туңгак алып көнен-төнен аның иминлеген, тынычлыгын саклый башлады.

Күп тә үтмәде, меңбашы Туңгак алыпка каган үзенең бер кырнагын бирде, өй бирде, беркадәр мал-туар бирде. Шул рәвешчә яшь алып үзенең барлык теләкләренә иреште. Кем аркасында? Әлбәттә, бикә аркасында!

Ул моны беркайчан да онытмады, оныта алмады. Каган биргән кызга өйләнеп, үз оясын корып җибәргәч тә ул барыбер аннан читләшмәде. Бикәне ул үзенең яшьлек дусты һәм сөеклесе итеп тә яратты.

IV

Иркен, бай өйдә, ялкынланып янган учак янәшәсендә алар икәүдән-икәү генә утырдылар. Бикә өйгә балаларын да, туган-тумачаларын да — беркемне дә кертмәскә кушты. Болан тиресеннән тегелгән каюлы йомшак итек кигән аякларын бөкләп, йомшак мендәр өстендә утырган бикә кунагын иң элек кымыз белән сыйлады. Кымыз эчкәннән соң ак киез уртасындагы тәбәнәк өстәлгә алтын табак белән бер бөтен сарык китереп куйдылар. Таралырга гына торган йомшак, кайнар итне бикә беренче булып үзе авыз итте, шуннан соң кунагын сыйларга тотынды. Көне буе ат өстендә килгән алып ир бик нык ачыккан иде — күз ачып йомганчы ул сарыкның бер як санын ялт иттереп куйды.

Ашаганда беркем берни сорашмады. Аларның очрашмаганына инде бер айдан артык вакыт үткән, шуңа күрә икесенең дә сөйләр сүзләре күп булырга тиеш сыман иде. Кунагы бирелеп ит ашаган арада бикә җайлап әле бер кисәкне, әле икенче кисәкне аның алдынарак этеп куйды. Иң ахырда кайнар шулпа китерделәр. Зур агач табакны ике куллап тоткан килеш, Туңгак алып шулпа эчте. Шуннан соң, тирләгән маңгаен сөрткәләп, ул беравык тынып, рәхәтләнеп утырды.

Сүзне бикә башлады.

— Ау ничегрәк булды соң?

Ул инде күптән сүз башларга җыенып утыра иде бугай — бу аның тавышыннан сизелде.

— Тәгин углан сөйләмәдемени? — диде Туңгак алып көттеребрәк.

— Сөйләде. Аның сөйләве — аныңча, синеке — синеңчә.

— Өйдәме соң әле ул? — диде кунак артык исе китмәгән сыман.

— Өйдә. Аның хәзер үз өе бар. Атасы аңа яшь кыз биреп җибәргән.

— Шулай шул, — дип куйды Туңгак алып гамьсез генә. — Ул кызны бик сылу диләр. Дөресме шул?

— Син әле аны күрмәдеңмени?

— Якыннан күрмәдем.

— Алайса, син Таштугайда булмадыңмыни?

— Мин анда капка сакладым.

Бикә эндәшмәде. Кулына пычак алып ул яңадан ит кискәләргә тотынды, сөягеннән аерылган бер кисәген кунагы алдына куйды да җиңелчә генә кыстап: «Ашале, аша» диештерде. Зур гәүдәле ир кеше алай кыстатып тормады — беркадәр тын алып утырганнан соң ул яңадан эшкә керешә. Озакламый алтын табакта тырпаеп шәрә кабырга сөякләре генә калды. Иттән соң бикә үзенең кунагына янә кымыз салып бирде.

— Яшь... «кияү» ничегрәк соң?— диде Туңгак алып өзелгән сүзне ялгап. Үзе сагаеп тынып калды.

— Ничек булсын — яшьләрчә,— диде бикә көлеп.— Таштугайдан кайтканнан бирле күзгә-башка күренгәне юк. Өеннән чыкмый. Алыштырган кебек — икенче кешегә әйләнде куйды.

— «Килен» ничегрәк соң?— диде Туңгак алып, шул ук җиңелчә шаян бер кызыксыну белән.

— Сиңа аның «килене» кирәгрәк, ахрысы?— диде бикә, хәйләкәр елмаеп.— Ничек булсын — ягымлы, моңсу. Телне белми. Яннарына телне белә торган бер карчык куйдым. Әлегә шуның аша аралашалар. Ул кызның Таштугайда бертуган абыйсы да бар икән.

— Шулаймыни?— дигән булды Туңгак алып.

— Кул эшләрен белә,— диде бикә.— Тавышы матур, җырлый, бии, гөсләдә уйный. Көне буе җырлап-биеп күңел ачалар.

— Тәгин угланны йөзбашы Күчәр урдага йомыш белән генә җибәргән булган. Ул шулай монда чин кызы белән гомер уздырмакчы була микәнни?— диде Туңгак алып.

— Мин дә әйттем: улым, дидем, олы җыен якынлаша — уенга, ярышка катнашырга уйламыйсыңмы? — дидем. Шуннан соң яланга чыга башлады. Ук аталар, атта узышалар. Бүген кызын дөягә атландырып алып чыккан. Ул чыккач атыш та булмаган, чабыш та булмаган. Егетләре гел теге кыз тирәсендә чуалалар икән. Үзара кычкырышып беткәннәр. Егетләрен тыңлата алмый җаны чыккан. Төштән соң Сөенечен... ул аны Сөенеч дип атады... Сөенечен минем янга китереп куйды. Көнли, курка. Менә шундый бездәге хәлләр!

— Башы-күзе әйләнгән икән!— диде Туңгак алып, ризасызлык белән.

— Кемнең башы-күзе әйләнгәндер — әйтеп булмый. Кызы да бик юха, сарылырга гына тора.

— Абыйсының килгәне юк микән?— диде Туңгак алып, иплән кенә, сүзне янә дә үзе теләгән юнәлешкә борып.

— Юк, килмәде,— диде бикә.— Баштарак үзе янына алдырырга дип караган бугай да, соңыннан тынган. Аннан соң ул әйтә икән: мине монда каганга бирергә дип алып килделәр, дип әйтә икән.

— Алайса, ул инде белә?— диде Туңгак алып, урыныннан кузгала төшеп.

— Кем? Нәрсәне?

— Чин кызының кире каганга кайтарып бирелергә тиешлеген.

— Каган сине шуның өчен җибәрдеме?

— Шуның өчен. Алдан синең белән сөйләшергә, киңәшергә җибәрде.

— Киңәшергә! Күз буяу өчен аңа минем ризалык кирәк. Күптән инде ул минем белән исәпләшми. Минем янга ул яшь кызларыннан арыгач ял итәргә генә килә.

Бикә үртәлеп, ашыгып-кабаланып сөйләде. Аның тавышында әледән-әле күз яшьләре сизелеп калды, тырышса да тыела алмады — күңеленә җыелып килгән барлык үпкәсенә, ихтимал, шулай ук сагыну тойгысына ирек биреп, борынын тарткалап кинәт сулкылдарга керешеп китте. Туңгак алып белән элекке очрашуында да ул шулай искәрмәстән күз яшьләре түгеп алган иде. Ул чагында ул үзенең күңеле йомшавын башкачарак аңлаткан иде: яшь хатыныңны ныграк яратасың бугай, мине оныттың, дигән иде, элекке колын шелтәләп. Бүген ул әнә бөтен-

ләй икенче төрле сүзләр сөйли. Бүген ул энә үзенең колына түгел, иренә үпкә белдерә. «Бикә дә картая башлады!» дип уйлады Туңгак алып үзалдына.

Авыр гәүдәсен көчкә кузгатып, ул бикә янынарак күчеп утырды, юатып, иркәләп авыр кулын аның чандыр аркасына куйды. Бикә тынычлана төште, күз төпләрен сөрткәләде дә, үзенең йомшаклыгын акларга тырышкан сыман:

— Мин инде ярты картайдым. Ябыктым, ямьсезләндем,— дип куйды.

— Бер дә картайган кебек күренмисең әле!

Әле-генә бетеренеп утырган бикә искәрмәстән елмаеп җибәрде. Туңгак алыпка ул чыннан да элеккечә яшь һәм чибәр булып күренде. Ул аның җиңел генә үзенә якынрак китерде, зур, дымлы кулы белән аның битеннән, маңгаеннан сыйпады.

— Каган яратмаган өчен миңа зарланырга җыенмыйсыңдыр ич син, бикә?

— Сиңа да зарланмагач, тагын кемгә зарланырга соң?!

— Мин — каганның колы...

— Иң элек син — минем колым!— диде бикә яңадан үртәлә башлап.

— Мин әле дә синең колың, бикә.

— Мин синнән шундый сүз көттем дә!

— Ирләрнең үзенә кол булуларын гына телисең дә инде син, бикә.

— Юк, барлык ирләрнең дә түгел — синең генә! — диде Күрекле бикә.— Яшьләрнең... үз улымның оялуын-кызаруын, шат йөзен күреп көнләшә башладыммы, яшьлегемне сагындыммы... гел сине уйладым. Бу көннәрдә эчем поша — үземне үзем кая куярга белмим. Урдадан еракта, беркемнең кулы җитмәстәй таулар арасында яшәргә иде икәүдән-икәү генә. Күңелгә шундыйрак уйлар килә. Син дә сирәкләдең.

— Китеп булмый. Эш, хезмәт.

— Шулайдыр,— диде бикә һәм никтер яңадан тынычсызлана башлады.— Киңәшергә сиңа мин кирәк түгел, миңа — син кирәк! Син алып килгән хәбәрләрне мин инде күптән белеп торам.

Туңгак алып кинәт билен турайтты.

— Алаймыни?— диде ул сагаеп.— Шулай да, нәрсәләр беләсең?

Бикә дә башын югары күтәрде, укалы, чигүле бүреге астыннан чыккан маңгай чәчләрен төзәткәләп куйды да, беравык көттергәндәй итеп утырды.

— Бик серле булып чыкты әле ул гүзәл чин кызы,— диде ул.— Алар янындагы теге чин карчыгы колыныма әйткән: каган синең кызыңны кире алачак дигән.

— Ул карчыкка кем әйткән?!— диде Туңгак алып, гаҗәпләнеп.

— Исәнтәй булырга охшый. Аның яныннан ниндидер кеше килгән.

— Исәнтәй! Монда да ул миннән өлгеррәк булып чыкты болай булгач,— диде Туңгак алып, йодрыкларын йомарлап.

— Ник аңа ачуланырга? Ул синең бурычны гына җиңеләйткән,— диде бикә көлемсерәп.

— Ул җиңеләйткәннән соң нишләптер миңа авыр була башлады,— диде Туңгак алып ачу белән.— Аның яхшылыгы да миңа яманлык булып тоела. Мин аннан бары явызлык кына көтәм.

V

— Миңа шунысы аңлашылмый,— диде бикә, яңадан сүз башлап,— бер кулы белән биргәнне икенче кулы белән тартып алгач, ил-көн алдында, агай-эне, туган-тумача алдында ул ни диячәк? Тиздән олы бәйрәм җитә. Шундый изге бәйрәм алдыннан шундый әшәкелек эшләсә,

аның барлык терәкләре юкка чыгачак бит! Уйлыймы шул турыда каган? Котлуг бәк белән, Куяннар белән бозылышу аның көчен дә, абруен да арттырмаячак. Бер гүзәл чин кызы аңа Котлуг бәккә, Куяннарга, Аланнарга торырлык куәт өстәмәячәк. Уйлыймы шул турыда каган?

Әле генә шундый ягымлы, юмарт күңелле хатын күз алдында илтотмыш бикәгә әвереледе. Хәзер инде аның белән гамьсез генә, теләр-теләмәс кенә сөйләшеп булмаячак иде.

— Каган эшне алай зурга җибәрергә уйламый, бикә,— диде Туңгак алып ашыкмыйча гына.

Ул бикәнең яраткан ире булып түгел, каганның илчесе булып сөйләште.

— Эшне зурга җибәрергә теләмәгән өчен дә ул синең янга мине җибәрде. Күп нәрсә синнән тора. Син каршы килмәсәң, тәгин угланны син килештерсәң, үгетләсәң, каган белән Котлуг бәк арасында да, Куяннар арасында да бернинди дошманлык барлыкка килмәячәк.

— Булмаячак андый эш!— диде бикә, никтер кызарынып.— Мин күп түздем. Илгә таркаулык килмәсен дип, Сөнәнкәләр Куяннар белән бозылышмасын дип, каганның читләтүенә дә, санламавына да — барысына да түздем. Бу юлы мин башымны иеп калмаячакмын. Мин — өлкән бичә! Мин — Котлуг бәк кызы! Минем урыным — түрдә, каганның уң ягында!

— Синең урыныңны әлегә беркемнең тартып алганы юк, бикә,— диде Туңгак алып, аның шулай кинәт тузынуын аңлап җитмичә.

— Әйе, әлегә тартып алганнары юк. Шулай да түрдә күбрәк кырнаклар, икенче, өченче бичәләр утыра.

— Кырнаклардан көнләшмисеңдер ич син, бикә?— диде Туңгак алып ясалма бер гамьсезлек белән.

— Беләсеңме, мин кемнән куркам?— диде бикә кинәт тавышын үзгәртеп.— Мин каганның Куяннар белән бозылышуыннан да, үзара тавыш-гауга чыгуыннан да курыкмыйм. Мин әлеге чин кызыннан куркам, Туңгак алып! Каган аны үзенә алса, ул чагында ул мине генә түгел, башка бичәләрне дә читкә тибәрә башлаячак. Күңелем сизенә. Мин ул кызны күргәч тә яратмадым. Ул күз явын ала торган ялтыравык таш кебек. Эчендә — агу, мәкер. Ул теләсә нинди ир кешене акылдан яздырачак. Ул каганның да күзен томалаячак. Ул чагында инде аның тирәсенә елышкан төрле килмешәкләр — Исәнтәйләр, «абыйлар», теләсә нинди чин карчыклары аңа үзләре өчен кирәкле сүзләр пышылдый башлаячаклар.

— Монда мин әллә нинди куркыныч нәрсәләр күрмим,— диде Туңгак алып басынкы гына.

— Ник алайса Исәнтәйдән шикләнәсең?

— Исәнтәй — башка, чин кызы — башка.

— Юк, башка түгел!— диде бикә.— Алар бер-берсенә бәйләнгәннәр. Алар әнә каяндыр гүзәл кызларны китертәләр, каганның Ак өенә үтеп керәләр, астыртын гына үз эшләрен эшли бирәләр.

— Шулай,— диде Туңгак алып килешеп, караңгы чырай белән.

— Шулай булгач, нидер эшләргә кирәк, Туңгак!— диде бикә, усал пышылдап, күзләрен уттай яндырып.— Иң элек шуны белеп тор: чин кызын ул кире ала алмаячак! Берәр сылтау табып, мин аны барыбер ат койрыгына тактырачакмын![1]

Ул моны нык итеп, үз-үзенә ышанып әйтте. Әле булса тыныч, килешүчән булып күренергә, артык кызмаска тырышып утырган илче үзгәреп китте.

---

[1] Борынгы төркиләрдә үлемгә хөкем ителгән кешене аркан белән ат койрыгына такканнар да атны дала буйлап куып киткәннәр.

— Каган мине монда боерык белән җибәрде. Әгәр мин аның боерыгын үти алмасам, ул минем башымны чаптырачак. Син әле минем үлемемне теләмисеңдер ич, бикә?— диде ул.

Бу билгеле, бикә уйлаган, бикә теләгән сүзләр түгел иде. Бу аны кимсетә торган, аны читләштерә торган, аны үтерә торган сүзләр иде.

— Синең яшисең килгәнне... минем яшисем килмимени, Туңгак кол?! — диде бикә кинәт кызарынып, усал итеп.

Туңгак алып кинәт эсселе-суыклы булып китте. «Менә нинди икәнсең син, бикә... картая башлагач» дип уйлады ул үзалдына тыныч кына. Ләкин тыштан ул тыныч кала алмады. Кызарынып шундук аягына басты, бикәдән, алтын табаклардан, ак киездән читкәрәк тайпылды. Бугазына килеп уралган ярсуыннан арына алмыйча, ул шактый озак бер сүз әйтә алмый торды. Шуннан соң ул кулларын күкрәк турысында кушырып, мыскыллы-көндәм бер кыяфәттә бикә алдына баш иде.

— Минем, бикә, коллыгымнан баш тартканым юк. Баш тартырга теләсәм дә, мин ирекле булмаячакмын,— диде ул.— Кол буларак мин бары каган теләгән генә белдердем. Син каганны яхшы беләсең: күңеле төшкәнне ул алмый калмаячак. Яхшылык белән бирмәсәң, ул көч белән алачак. Менә шунда күренер инде кемнең ил тараткан да, кемнең ил ныгытканы. Хуш, бикә.

Ул ишеккә таба атлады. Ашыгудан, кабаланудан ул аяк астындагы нәрсәгәдер сөрлегеп китте. Аяк астындагы ул нәрсә сөлге булып чыкты. Ләкин ул аны иелеп, аягыннан алып тормады — шул килеш, уралган сөлгесен өстерәп, ишек катына ук килеп җитте. Ул ишек бавы белән булашкан арада аның янына бикә килеп басты.

— Ашыкма!— диде ул, боерып.

Бер дә юктан ул кычкырып көләргә тотынды.

— Ашыкма!

Туңгак алып ярсып кинәт артына борылды.

— Минем боерыктан башка син моннан беркая китә алмаячаксың, колым!— диде бикә, үтергеч бер өстенлек белән.

— Нишләтмәкче буласың мине, бикә?— диде ир кеше, авыр гыжылдап, кулларын йомарлап.

— Чин кызы белән... ат коерыгына, ат коерыгына!..— диде бикә тотлыгып, тиле сыман никтер көлә-көлә.

Туңгак алып бикәнең кулларыннан тотып алды, тыелгысыз бер көч белән аны җиңел генә үзенә таба якынайтты.

— Кол, мин, кол, бикә! — диде ул, кычкырып.— Үзем үлгәнче мин сине... буып үтерәм, бикә!

Бикә агарынып китте һәм үзен буып алган алып иргә сәер итеп бер карады да, кинәт хәлсезләнеп, җансызланып калды. «Үтердем!» дип уйлады алып ир, коты алынып.

Кызганулы бер өн чыгарып ул ыңгырашып куйды, авыраеп калган хатынны шашып кочагына алды, битенә, күзләренә карады.

Бикә исән иде. Тәне элеккечә җылы, йомшак, затлы, нәфис киемнәреннән хуш исләр бөркелеп тора. Алып ир аны коточкыч куаныч һәм котылу-бушану тойгысы белән, тилереп, яратып үбәргә тотынды.

— Күреклем! Сөеклем! Ни булды?

Бикә җанланды. Тирән итеп бер тын алды да, балалар сыман сулкылдап җыларга тотынды.

— Китмә! — диде ул, алып ирнең муенына сарылып.

— Китмим! Кусаң да китмим!

— Кичер. Кызып киттем,— диде бикә, бөтен тәне белән калтыранып.— Мәңге минем якчым-сакчым бул. Синнән башка минем бер ышанычлы кешем дә юк.

Туңгак алып, кием-салым, мендәр күтәргән кебек, аны җиңел генә күтәреп кире табын янына алып килде. Бикә алтын кәсәгә кымыз агыз-

ды. Эчкәч алар икесе дә тынычланып калдылар. Бикә учакка утын өстәде дә яңадан ак киезгә алып ир янына килеп утырды һәм әле генә булып узган давылдан соң телгә килеп:

— Ярар, аңлаштык... бозылыштык, хәзер инде ачыктан-ачык сөйләшсәк тә була,— диде.

VI

Алар шактый озак сөйләштеләр, ләкин шулай да уртак фикергә килә алмадылар. Тышта этләр өрүеннән башка бернинди тавыш-тын ишетелми башлаганда, инде төн уртасы җитеп килгән бер вакытта, эчке яктагы ишек сакчысы биек ятак янына килде дә, калын чаршау астыннан кулын сузып, бикәне йокыдан уятты.

— Ишектә кеше бар.

— Нинди кеше?

— Торгак.

Төннәрен уяу-сак йокларга күнеккән Туңгак алып аларның якында гына пышылдауларын ишетеп, шундук күзләрен ачты. Тиз арада ул барысын да аңлап алды, бикәдән алдарак аягына басты һәм ишек янына килде. Бикә дә аның артыннан килеп җитте.

Бикә авылының тышкы бөҗрасын көндез дә, төнлә дә ир торгаклар каравыллый иде. Арбалар белән әйләндереп алынган кече бөҗра эчендә исә бары хатын-кыз сакчылар гына тора. Ишек янына килгән торгак та хатын кеше иде. Аның белән бикә үзе сөйләште.

— Әрәмә тугаена ниндидер кораллы алай килеп туктады. Шунда төн кунмакчылар,— диде тыштагы хатын-кыз торгак.

— Кемнәр икән?

— Белмим.

— Мин беләм,— диде шул чакны Туңгак алып, бикәгә пышылдап.— Каган кораллы алай җибәргән.

— Таң ату белән алар безне чолгап алачаклар!— диде бикә барысын да төшенеп.

— Таң атканда алар безнең капканы килеп кагачаклар, бикә!— диде Туңгак алып.

— Каган ашыга!

— Каган түгел. Исәнтәй ашыктыра. Аңа да минем баш кирәк, бикә!

— Ярар — нишлибез?— диде бикә, сулуы кабып.

— Миңа синең өеңнән чыгып китәргә туры килә.

— Куркыныч килгәндә алып ирләр иң элек үзләрен генә кайгырталар.

— Иң элек сине кайгыртып, бикә.

— Мин колыным турында, тәгин углан турында әйтәм!

— Мине оныттыгыз! — диде тыштагы торгак.

— Онытмадык,— Туңгак алып бикә өчен җавап бирде.— Андагыларга әйт: барлык ирләр аякларына бассыннар, яхшылап кораллансыннар. Без аларның борын төбендә генә, елганың бу ягында төн уздырачакбыз. Мин хәзер чыгам, мине көтсеннәр.

— Аңлашылды. Мин киттем,— диде ишек артындагы торгак.

Туңгак алып ятак янына килеп киенә башлады.

— Син... алар белән сугышырга җыенасыңмы?— диде бикә, ике куллап аның беләгенә тотынып.

Аның тавышында чиктән тыш каушау-борчылу сизелде.

— Кирәк булса... сугышырбыз да!

— Бөтен эшне харап итәсең! Кирәкми! Җибәрмим!

— Болай булгач, каган боерыгына буйсынырга туры килә.

— Мин риза!— диде бикә, кабаланып.— Мин колынымны күндерер-

мен. Ул мине тыңлар. Ул — акыллы. Туктале, әллә соң син сөйләшеп карыйсыңмы аның белән?

Туңгак алып киенүеннән туктап торгандай итте.

— Өлгермәм,— диде ул уйланып.— Синең сөйләшүең яхшырак булыр. Шулай да аңа әйт: ир булган ир кеше теләсә нинди чибәр кыз алдында җебеп төшәргә тиеш түгел дип әйтте диген; ир булган ир кеше иң элек аты, коралы турында, яу турында уйлый дип әйтте диген.

— Әйтермен!— диде бикә аны тыңламыйча.— Бар инде, бар. Шундый сүзләр сөйләгән ир кешене минем күрәсем килми башлый.

— Үз җаем белән тагын бер килеп чыгармын,— диде Туңгак алып.

— Авыл читендә синең өчен аерым өй корылган булыр,— диде бикә, аны ишеккә кадәр озата барып.— Кызларның берәрсе сине шунда озатып куяр. Озатып куючы синең янда калыр. Мин инде йоклый алмам.

— Мин дә йоклый алмам,— диде Туңгак алып, аны юаткандай итеп.

— Бар инде, бар тизрәк! — диде бикә, аны ашыктырып. Ләкин Туңгак алып ишектән чыгып китмәкче булгач, ул яңадан аның беләгеннән тотып алды.— Тукта, ярат мине!— диде.

Кочаклашып алар беравык тын гына басып тордылар. Тынычлангач, бикә кунагын ишектән үзе чыгарып җибәрде. Туңгак алып казыкта калдырган коралларын яңадан биленә такты, кулына алды һәм бер читтәрәк үзен көтеп торган бер кыз торгак артыннан капкага юнәлде. Башта ул торгак кыз белән авыл читендәге ялгыз өй янына барды. Торгак кызны шунда калдырып яңадан авыл янына кайтты. Күл буенда аны өч йөз-дүрт йөз чамасы кораллы ир көтеп тора иде.

Төннең икенче яртысын ул елга буенда, Әрәмә тугае дигән җирдә үткәрде. Алар йокламадылар. Иртән таң атар-атмас борын ул бикәнең кораллы ирләренә тавыш-тынсыз гына елга ярына таба якынлашырга боерды. Ләкин теге яктагыларның төнге сакчылары аларны күреп алдылар. Каган җибәргән ирләр тиз арада аякка басты. Һәркем үзенә каршы яктагы «дошманның» кемлеген яхшы белгәнгә күрә, теге яктан да, бу яктан да ук атучы булмады. Каган ирләре дә, бикә ирләре дә, коралларын әзер тоткан килеш, өстен боз каплаган елга аша бер-берсенә карашып тордылар.

Туңгак алып бикә ирләренең иң алдында басып торды. Ул теге яктагыларның алай башын танымакчы булды. Ләкин анда аңа таныш бер генә атаклы ир дә күренмәде. Кулларын авыз турысына куеп ул бар көченә:

— Башыгыз кем? Монда чыксын! — дип кычкырды.

Бераз көттереп теге яктагы төркем артыннан ала атка атланган берәү алгарак чыкты, яр буенарак килде. Бу Салчак алып иде. Каганның атаклы батырларыннан берсе Салчак турыдан-туры Туңгак алыпка буйсына иде. Үзе монда киткәндә Туңгак аны вакытлыча үзе урынына каравыл агасы итеп калдырды. Бер-берсен монда, Аркача суы буенда, күреп, алар икесе дә аптырап калдылар. Шулай да, Салчак алыпның йөзендә гаҗәпләнүдән бигрәк, каушау, уңайсызлану өстенлек итсә, Туңгак алыпны күбрәк ачу һәм ярсу биләп алган иде.

— Ни булды, ник килдең, Салчак алып?

— Каган җибәрде, олуг меңбашы,— диде Салчак алып, акланмакчы булып.

— Мин урдага кайтмый торып каган минем арттан беркемне җибәрмәскә тиеш иде!

— Мин берни белмим, олуг меңбашы,— диде Салчак алып, буйсынучан бер төс белән.— Чин кызын бирмәсәләр, миңа бикә авылын камап алырга, кызны көч белән тартып алырга боерылды.

— Кем боерды?— дип кычкырды Туңгак алып ярсып.— Исәнтәйме?

— Исәнтәй боерык бирә алмый, олуг меңбашы,— диде Салчак алып тыныч кына.— Боерыкны каган үзе бирде.

Туңгак алып тынып калды. Каганга каршы сүз әйтергә аның батырчылыгы җитмәде. Боерыкны бары каган гына биргәнлеген ул үзе дә бик яхшы белде, ләкин каганның шулай тиз арада үз фикерен, үз боерыкларын үзгәртә алуына аның ышанасы гына килмәде. Билгеле, монда Исәнтәйнең таяк тыкканлыгы көн кебек ачык иде.

— Кырнакны алып килдеңме?— диде ул, шактый озак тынычлана алмый торгач.

— Килдем.

— Аны минем янга чыгар. Үзең урдага кайтып кит,— диде Туңгак алып, боерып.— Барысын да мин үзем җайлармын. Миннән алда кайтып җитсәң, каганга шулай дип әйтерсең.

— Шулай дип әйтермен, олуг меңбашы,— диде Салчак алып, әллә ни куаныч белдермичә.

VII

Салчак алып Табылдыкны елга аша чыгарып куйгач һәм каган ирләре урда ягына таба кузгалгач, Туңгак алып бикә авылына кайтып китте. Авылга кайтканда ул беркем белән берни сөйләшмәде. Шулай ук үз яныннан гына барган Табылдыкка да берни эндәшмәде. Ул бары аңа бер-ике мәртәбә күтәрелеп кенә карады. Каганның сөеклесе, бөтен урданың күрке булган гүзәл Табылдык элеккегә караганда ябыккан, суырылып калган иде. Аннары, әллә төн йокламаганга, әллә борчылганга, курыкканга, йөзеннән кан качкан. Ләкин шул хәлендә дә ул матур иде!

Бәхетсез кырнакны кызганудан алып ирнең йөрәге сыкрап куйды. Үзе белән Табылдык арасында ул күзгә күренмәгән бер туганлык, якынлык җебе барлыгын тойгандай булды. «Менә нишләтә язмыш!»— дип уйлады ул, тирән бер сагыш һәм әрнү белән. Әле кайчан гына барлык хатын-кызлар арасында йолдыз булып балкыган, яшьлеген, матурлыгын аңлаудан сөенеп, кая басканын белми йөргән беренче гүзәл әнә суга төшкән тавык кебек бөрешеп калган. Күрәсең, ул әле шуның өчен дә куанадыр. Куанмыйча! Аны әнә Кортка-бикә тырнагыннан тартып алдылар да яшь-яшь үгланга... тәгин угланга алып баралар.

Туңгак алып үзалдына көрсенеп куйды. Үзе ул кол кызның язмышы өчен көрсенәм дип уйлады. Ләкин чынлыкта исә үз язмышын уйлап көрсенде бугай. Былтыр яз көне ул, башкалар арасында йолдыз булып балкыган менә шушы кырнакка күзе төшеп, чак-чак кына харап булмый калды. Ярый әле тойгыларын вакытында тыя алды. Аның белән дә бәйләнеп китсә, бу инде Күрекле бикә белән ике арадагы яратышу гына булмас иде. Аларны бик тиз сизеп алырлар иде. Сизеп алырлар иде дә, шундук койрыкларына да басарлар иде. Үз бичәләренең һәм шулай ук бик үк яратмаган кырнакларының башка ирләр белән чуалуына каган бармак аша караса да, үзе яраткан, бары үзе генә яратырга тиеш булган гүзәлләр янына беркемне дә, хәтта үзенең иң ышанычлы алыпларын да якын җибәрми.

Табылдыкны Туңгак алып туп-туры бикә өенә алып кайтты. Бикә чыннан да төннең яртысын йокысыз уздырган иде, ахрысы — болай да юка иреннәре аның тагын да ныграк кысылып, күзләре кечерәеп калган сыман иде. Туңгак алыпны яңадан исән-имин күргәч ул елмайды.

Өлкән бичә өенә Туңгак алып бу юлы коралларын салмыйча керде, шуңлыктан ул бикә алдында да үзен икенче төрлерәк тотты.

Бикә дә аны йомшак мендәрдә, ак киез өстендә утырган килеш каршыламады. Аның ике ягына ике ир кеше — якын туганнары утырган иде.

Каган илчесе Туңгак алыпка бикә кымыз бирергә кушты. Кырнаклар китергән кымызны йола кушканча әз-әзләп кенә, кулдан-кулга йөртеп эчтеләр. Ул арада бикә өлкән углы Албуганы алырга кеше җибәрде.

Албуга килде. Ишектән керү белән, исәнлек-саулык сорашты, түргә узып, уртадагы ак киезгә басты, аннары тезләнде.

— Углым, атаң Туман каганның илчесе килгән,— диде бикә, улының түбән иелгән күз карашын тотарга тырышып.

— Күреп торам, әни,— диде Албуга.— Ник килгән ул монда каган илчесе Туңгак алып?

— Туңгак алып... атаң бөек каганның боерыгын алып килгән, балам,— диде бикә, йомшак кына итеп.

Яшь углан шундук башын калкытты һәм тынгысыз күзләре белән әле әнисенә, әле Туңгак алыпка карап алды.

— Нинди боерык, әни?— диде ул тынын кысып, сагаеп.

— Син аны беләсең, углым,— диде бикә, әкрен генә.

— Белмим, беләсем дә килми!— диде кинәт углан, йодрыкларын йомарлап.

Ирләр кымшанмыйча, эндәшмичә, таштай катып утыра бирделәр. Иртәнге өй эчендә дөрләп учак янганы да ишетелерлек тып-тын булып калды.

— Балам, бөек каган сиңа яхшылык тели,— диде бикә, яшь егетне юатмакчы булып.

— Бөек каган миңа яхшылык теләсә, үзе биргәнне кире тартып алмасын!

— Син аңларга тиеш, улым,— диде ана кеше тагын да йомшаграк, үтемлерәк итеп.— Атаң синнән беркемне тартып алмый. Ул сиңа үзенең яраткан кырнагы Табылдыкны бирә.

— Табылдыкны?— диде Албуга беркадәр кызыксыну белдереп.

Ул як-ягына карап алды һәм якында гына башын иеп торган таныш сыман кызны күреп алды.

— Ул Табылдык... түгел, әни!— диде ул.

Үзе турында ачыктан-ачык яратмый әйтелгән сүзләргә хурланып Табылдык кинәт ыңгырашып куйды, кырт кына борылды да, борынын тартып чаршау артына йөгерде.

— Сөенечемне бирмим, әни — теләсә нишләтсеннәр!— диде яшь углан чиктән тыш кирелек, үзсүзлек белән.

Бикә күңелсез генә көлемсерәп куйды, маңгай чәчләрен төзәткәләде дә, башта Туңгак алыпка, аннары үз янындагы туганнарына карап:

— Ирләр чыгып торсыннар,— диде.— Улым, син минем янда кал.

VIII

Бикә өйдән ирләрне генә түгел, чаршау артындагы хатын-кызларны да чыгарып җибәрде. Улы белән икәүдән-икәү генә калгач, ана аңа үз янынарак күчеп утырырга кушты.

— Синең белән генә сөйләшәсе сүз бар,— диде ул беравык сүз таба алмагандай утыргач.

— Барыбер тыңламыйм!

— Тынламыйсың?!— диде ана исе китеп.— Инде син кырнакларны гына тыңлый башладыңмыни?

— Юк, алай түгел,— диде яшь углан, буталып.

— Шулай да тыңлыйсыңмы әниеңнең сүзен?

— Тыңлыйм,— диде углан, теләмичә.

— Мин сине, углым, гүзәл чин кызы өчен тапмадым. Мин сине анаңа, ырудашларыңа, иленә-көненә бәхет, куаныч өчен таптым. Шушы көненә чаклы мин сине җил-яңгыр тидерми карап үстердем. Үстерүен үс-

тердем дә, сиңа әнә хәзер кырнаклардан башка беркем дә кирәкми башлаган!

— Алай түгел! Алай түгел, әни!— диде яшь углан.— Мин ул кызны яратам. Сине дә яратам. Сине — әнием булган өчен. Аны — башкача. Үзең дә беләсең ич. Ник мине газаплыйсың?!

— Беләм,— диде ана кеше тыныч кына.— Синең кызлар яратуыңа минем бер сүзем юк. Ир булган ир кеше хатын-кызны ярату өчен туа, хатын-кыз — ирләр өчен туа. Тәңре безнең шулай яраткан. Тәңренең теләгенә беркем каршы килә алмый.

— Шулай булгач, әни?!— диде Албуга яктырып.

— Шулай булгач, ир булган ир өчен дөньяда кызлардан башка әле бүтән нәрсәләр дә бар,— диде бикә.— Ир булган ир кызлар кочагында гына җылынып ятмый — атын, коралын кайгырта, ил-көн язмышын кайгырта.

— Аңлатма, әни,— диде углан, сүрелеп.

Әнисенең үз теләгенә, үз тойгыларына, үз омтылышларына каршы килә торган теләсә нинди сүзе, теләсә нинди дәлиле аңа ялган булып, ышандыргысыз булып тоелды. Улының холкын биш бармагы кебек белгән ана да моны бик яхшы сизенде. Ләкин ул аны барыбер җиңәргә, күндерергә тиеш иде! Чак-чак кына каушап, дулкынланып бикә углы янынарак күченеп утырды. Кулын аның маңгаена куйды, аның каты, кара чәчләрен яратып сыйпалады, кызарынган, дымланган тере күзләренә карады да ярым пышылдап:

— Тыңла, углым — мин сиңа сүз сөйлим,— диде.

Яшь углан тынып калды.

— Син, улым, адәм баласы түгел. Син — Тәңре углы! — диде ана шомлы һәм дәһшәтле бер тантана белән.— Син минем карында чагында мин әле Туман каган бичәсе түгел идем. Әле дә исемдә, атам Котлуг бәк урдасында, Керүлән буенда, җиде төн уртасында яшен яшьнәп күк күкрәде. Кыш көне! Караңгылык юкка чыкты, төн урынына көн булды. Югарыдан, ябылып бетми калган төннек ярыгыннан өй эченә сөңгедәй сузылып алтын яктылык төште. Якты нур минем битемнән, күкрәгемнән сыйпады, минем каныма-бавырыма үтеп керде. Иртән таң атар алдыннан, җирән чәчле, җирән сакаллы ир булып, сөңгедәй сузылып, әлеге алтын нур югарыдан чыгып китте. Өч төн буе шулай кабатланды. Шул өч төннең берсендә, улым, син яралдың. Бу хакта мин бары үземнең мәрхүм әниемә генә сөйләдем — авыр туфрагы җиңел булсын! «Син изге бала, өлешле бала табарсың, кызым!» диде әни. Икенче көнне Керүлән буена, Котлуг бәк урдасына Туман углан килде. Мине аңа кияүгә бирделәр. Синең кемнән яралуыңны мин аңа әйтмәдем. Унсигез ел буена бу серне мин күкрәгемдә йөрттем. Аны хәзер син дә беләсең. Кайчан да булса мин аны сиңа барыбер әйткән булыр идем. Хәзер инде уйлап кара, улым: Тәңре углы, кырнаклар сихеренә бирелеп, җебеп төшәргә тиешме, әллә барлык адәм баласыннан өстен булып калырга тиешме?

Албуга, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, аптырап, таң калып әнисенә карап тик торды. Бераз гына ерагайган һәм кул җитмәслек биеклеккә күтәрелгән, тик шулай да аңлаешлы, кадерле әнисен ул беренче кат күргән кебек булды.

— Әнием!— диде ул телгә килеп.— Чынмы бу?! Мин — Тәңре улы!

— Чын, балам,— диде ана бернинди икеләнүгә урын калдырмыйча.

— Алып китсеннәр, әни! Кирәкми миңа чин кызы!— диде углан үз авызы белән, үз ирке белән.

Тик шулай да аның нурлы йөзе кинәт төссезләнеп калды.

— Балам! — диде ана ягымлы итеп.— Мин сине аңлыйм: яраткан кешеңнән аерылуы кыен. Шулай да син бирешмә.

— Мин бирешмәм, әни.

Әнисе өеннән чыккач ул үзенең Сөенече янына кайтып тормады. Авылдан читтә бүген алар егетләр белән ук атып, сөңге ыргытып, сугыш уеннары уйнарга тиешләр иде. Ул туры шунда юнәлде.

IX

Барлык Сөн иленең корбан бәйрәме елына өч тапкыр — беренче, бишенче, тугызынчы айларда — һәр өч айның беренче көненнән алып җиденче көненә кадәр уздырыла иде. Бәйрәмнең иң олысы кыш башында — тугызынчы айда, терлек-туар таза, көр чакта була. Олы ил туена төрле яктан: далалардан, чүлләрдән, тау-таш, урман якларыннан — якыннан, ерактан бәкләр, ыру башлары, алып ирләр, аксакаллар килә. Бөтен илнең корбан курасы уңда, Туман каган кышлавында — Сары су буендагы Изге-тау башына урнашкан иде. Изге-тау башындагы корбан курасы эченә исә моннан меӊ дә биш йөз ел элек, үзара туктаусыз ызгышкан таркау, ярлы терлекчеләрне берләштереп, көчле ил төзегән Сөн баба күмелгән. Шунда ук, җиргә ярым кадалган килеш, Сөн бабаның саплы тимер кылычы саклана иде.

Илнең төрле ягыннан җыелган бәкләр, ыру башлары, ил агалары менә шушы Изге-тауда Сөн бабага, җир-су ияләренә багышлап корбан бирәләр һәм шуның белән Сөн иленә, Сөнәнкә ыруына, ил башы каганга үзләренең тугрылыкларын белдерәләр иде. Шул ук вакытта монда — бөтен илгә кагылышлы зур эшләр тикшерелә, төрле уеннар, ярышлар уздырыла.

Башка еллардагы кебек, быел да алыстагылар иртәрәк кузгалдылар. Алгы яктан — Алтай, Тула буйларыннан, уртадан — иксез-чиксез далалардан, сул якның Ала-тау, Елан-тау итәкләреннән — бөек Сөн иленең барлык төбәкләреннән өчәр-дүртәр меӊ, бишәр-алтышар меӊ кораллы ирләре белән; үгезләргә җигелгән арбалары, арбаларга утыртылган киез өйләре белән; алдан теркелдәүче көтүләре белән бәкләр, агалар, ирләр, алыплар борынгы юллар, сукмаклар буенча уңга — көнчыгышка, Изге-тау ягына хәрәкәтләнделәр. Ай буена бөтен Сөн иле, бөтен дала туктаусыз кыймылдап, хәрәкәтләнеп торды.

Ерактагылар ашыгып Сары су ягына хәрәкәтләнгәндә якынрактагылар да тик ятмадылар. Чынында алар да башкалар белән бер үк көнне диярлек кузгалдылар, тик алар ерактагыларга караганда ашыкмыйчарак бардылар.

Изге-тау Сөнәнкә җирендә булса да, Куян ыруы тау буена беренче булып килеп җитте һәм, килеп җитү белән, биек өйләр сыман берсе артында икенчесе калкып утырган комлы калкулыклардан ике ук чамасы ераклыкта. Сары суның уң ягында урда корды.

Котлуг бәк урда корып бер төн узуга, төштән соң, Куяннар кебек үк атаклы аксөяк Аланнар килеп туктадылар. Алан ыруы башы Барыс бәк тә үз җирендә — Сары суның сул ягында Котлуг бәккә капма-каршы яр өстендә урда корды. Өченче көнне Сөйбү ыруы килде. Сөйбү ыруы да Сөн илендә аксөяк санала иде. Сөйбүләр Сары суның сул ягына — Аланнардан бераз алгарак, төн яккарак урнаштылар.

Дүртенче көнне Таслар, Алашлар, Сыбуклар килде. Һәркем, Сары су буена килеп җитү белән, берәрсенең әйткәнен, күрсәткәнен көтеп тормыйча, борын-борыннан үзенеке, үзләренеке булган изге урыннарына утыра тордылар. Яр буйларын куе тал, камыш сарып алган, өстен калын боз каплаган Сары суның ике ягында да тигез, ачык далада бернична көн эчендә йөзләгән, меңләгән өйләр калкып чыкты. Бер тирәгә укмашып, түгәрәкләнеп утырган өйләрне кыршау сыман әйләндереп, тышкы якка күп санлы арбалар тезеп куелды.

Иске айның соңгы көнендә, яңа айның беренче көне башланыр алдыннан Туман каганга буйсынган барлык ырулар диярлек килеп бетте. Бу олы туйга бары сул яктагы Алатлар килмәде дә, каганга калан түли торган түбет бәге, аннары дунху бәге килмәде.

Йола буенча, Сөнәнкә ыруының башы Туман каган Изге-тау янына иң соңгы булып килергә тиеш иде. Шуңа күрә Сары су буена кемнәр килүен, кемнәр килмәвен аңа җиткереп кенә тордылар. Яңа ай башына ярты тәүлек кала ул да үзенең күчмә урдасыннан кузгалырга булды.

Каган өчен уртада, Сары суның уң ягында, Изге-тауга якынрак бер җирдә буш урын калдырылган иде.

Дөяләр, атлар җигелгән, өй җиһазлары, азык-төлек, утын-су, бала-чага, карт-коры төялгән беренче арбалар тышкы боҗра янына килеп җиттеләр дә, капка аша үтеп, киң аралыктан үзәккә таба агылдылар. Барлык буйсынган ыру башлары, бәкләр, алыплар, ирләр, хатын-кызлар иң алдан яхшы атта килгән бай киемле каганны каршыларга чыктылар. Әле анда, әле монда быргылар кычкырды, дөңгерләр дөпелдәде. Юл буйларында, бер-берсенә кушылмыйча, аерым-аерым төркемнәр булып торган атлы кешеләр өстендә, озын саплы колгаларда төрле төстәге туглар, байраклар балкыды.

Каганның меңләгән кораллы ирләре, исәпсез-хисапсыз арбалары уртага таба туктаусыз агылдылар да агылдылар. Койрыкта әле һаман арбалар шыгырдады, атлар кешнәде, үгезләр үкерде. Туман каганның бу тикле атлары, арбалары, дөяләре, үгезләре, билгеле, Сары су буендагы буш урынга сыеп бетмәде. Изге-тау янындагы изге урында тик каганның биек Ак өе дә, бичәләренең, якын туганнарының өйләре генә утыртылды. Аннары иң кирәкле байлыклары төялгән арбалар да, йөзләгән кораллы ирләре генә калды. Башка барлык ирләр, атлар, дөяләр, малтуар икенче юлдан боҗраның тышкы ягына, буш далага озатылды.

Кортка-бикә гадәтенчә боҗра эченә кермәде, тыщта калды. Ана-кам буларак, ул болай да урдага керә алмый иде, ни өчен дигәндә, Сөн бабага корбан бирүне тулысынча ир затындагы камнар башкаралар иде.

Шулай итеп, аркылысы-буе берничә чакрымга сузылган киң боҗраның тышкы ягын ярлырак өйләр, арбалар, исәпсез көтүләр сарып алды. Әйтерсең, монда Сары су буена — Сөн баба мәңге йокыга талган Изгетау янәшәсенә бер кешесе, бер малы-туары калмыйча, бөтен Сөн иле җыелган иде. Ләкин шулай да бу бөтен ил түгел. Болар бары бәкләр, ыру башлары белән бергә килгән кораллы ирләр-сакчылар да, якын туган-тумачалар гына. Һәм аларның күпчелеге Туман каганның туганнары — энеләре, абыйлары, абзалары иде.

Туман каган боҗра эченә кичтән, яңа ай башында кереп урнашты. Икенче көнне иртән төньяк-көнчыгыш офыкта Сары су буена якынлашып килүче ниндидер атлылар күренде. Күзәтчеләр килеп, әлеге атлыларның дунху бәге Начин нойон икәнлеген әйттеләр. Изге-тау буена каган өй корганнан соң боҗра эченә беркем кертелми иде. Соңга калган өчен каган Начин нойонның башын чаптырып, бар байлыгын, иленкөнен басып кала ала иде.

— Начин нойонны нишләтәбез? — диде Туңгак алып каганга.

— Килсен, туктасын. Урда читенә, — диде каган.

Изге ай башында изге корбан туен аның баш чаптыру белән башлыйсы килмәде. Аның әле Начин нойоннан да зуррак, катлаулырак эшләре бар иде монда.

— Сөн йоласына өйрәтәсе иде үзен! — дип куйды Туңгак алып, каган белән килешмәгән сыман.

— Алатлар белән түбетләрне өйрәткәндә яхшы булыр иде дә... Алар инде икенче мәртәбә соңлыйлар, — диде каган.

— Юк, килмиләр, — диде Туңгак алып. — Алар чик буенда. Аларның койрык кыска.

— Көтеп карыйк,— диде каган, бу турыда сүзне озайтасы килмичә.
Алатлар белән түбетләрне төшкә чаклы көттеләр. Сары су буена башка килүче булмады.

X

Сары су буендагы изге урдада Туман каганның барлык бичәләре, туган-тумачалары төрле яктан чикләнгән кысан урында бер-берсенә бик якын урнаштылар. Иң уртада, үзәктә, гадәттәгечә каганның үз өе калкып утырды. Унда — көнчыгыш якта, каган өеннән бер илле адым чамасы ераклыкта өлкән бичә Күрекле бикә өе, алда — төньякта икенче бичә Сырга бикә өе, сулда — көнбатышта өченче бичә Тутыя бикә өе, артта — көньякта дүртенче бичә Кәринә бикә өе корылды. Бикә өйләреннән бер йөз адым чамасы читтәрәк, икенче боҗра булып, каганның йөзләгән кырнаклары, кол хатыннарының җыйнак, матур, шулай да караларныкыннан аз гына зуррак булган өйләре тезелеп китте. Кызкыркын өйләреннән дә читтәрәк, өченче түгәрәк булып, туган-тумача, карачы, ашчы, бузачы, агычы һәм шуныңише дәрәҗәле багаларның, хезмәтчеләрнең өйләре куелды. Алар артыннан ук кораллы ирләр — алыплар, торгаклар урын алды.

Моңарчы айлар буена бер-берсен бик сирәк күргән, я булмаса бөтенләй күрмәгән кешеләр шулай бер төбәккә җыйналгач, үзләрен бераз гына чикләнгән, кысылган итеп тойдылар. Бичәләр, йола саклап, бер-берсенә кунакка йөрделәр, исәнлек-саулык сораштылар, бер-берсен олы туй белән котладылар. Төрле анадан туган һәм бер атаныкы исәпләнелгән йөзләрчә балалар чыр-чу килеп бозда, яланда, өй араларында уйнап йөрделәр.

Бөтен Сары су буе бертуктаусыз шаулап, чыр-чу килеп торды. Олылар, балалар тавышына мал-туар тавышлары, анда-монда ишетелеп киткән быргы тавышлары кушылды. Коры, салкын һавада борыннарга таныш исләр килеп бәрелде. Һәркайда, һәркемдә бәйрәм шатлыгы, бәйрәм күтәренкелеге сизелде.

Яңа ай башына каршы кичтә Туман каган үзенең өлкән бичәсе өенә күченде. Күрекле бикә өенең тышкы ягына, ишек янындагы озын колгада чабып баручы алтын куян янында каган тугы[1] — тимер сөн кошы канатын җәеп җибәрде.

Бу көннәрдә күңелен борчу, кайгы һәм каршылыклы уйлар биләп алган булса да, Күрекле бикә үзенең изге ирен ягымлы йөз белән каршылады. Алар, ике арада әлерәк кенә берни булмаган кебек, башка вакытлардагыча мал-туар, ил-көн турында сүз алып бардылар. Каган өлкән бичә өенә аяк басып керү белән, бикәнең балалары — Албуганың бер сеңелесе белән ике энесе олуг аталары янына килеп бил бөктеләр, аңа озын гомер, бетмәс байлык, көч-куәт теләделәр. Ата кеше балаларның кайсын тезенә утыртты, кайсының башыннан, аркасыннан сыйпап куйды, һәркемгә үзе алып килгән бүләкләр, күчтәнәчләр бирде. Барлык аталы-аналы өйләрдәге кебек, өлкән бичә өендә дә үзара якынлык, җылылык урнашты.

Шулай да бу барыбер тулы, бөтен куаныч түгел иде — моны ата да, ана да, балалар да бик яхшы сизделәр. Беренче булып ата кеше тынычсызлык күрсәтте. Өлкән улының менә бу вакытта, атасы каган монда күченеп килгәндә өйдә булмавына ул шундук игътибар итте.

— Нишләптер минем олы колыным күренми,— диде ул Албуга турында.

— Егетләре белән Тарлавыкка китте.

— Олы туй алдыннан китмәсә дә ярар иде.

---

[1] Туг — байракның бер төре.

— Болай да өйдә күп юанды. Тегендә югалтып яталардыр, китим әле диде. Мин дә каршы килмәдем,— диде бикә аңлатып.— Синең урының кызлар янында түгел, ирләр янында дип Туңгак алып та тукып кына тора.

— Һы, Туңгак алып...— дип куйды Туман каган, мондый кеше турында беренче кат ишеткән кебек.

— Туңгак алыпны ул берсүзсез тыңлый,— диде бикә.— Теге чин кызын бирергә дә ул көндерде. Мин аны җибәрмәгән дә булыр идем, сизмичәрәк калдым. Ни әйтсәң дә, бала бит әле — акылы җитеп бетми. Күңеле дә кырылган чагы. Бер юлга атасы кичерер әле дип тә уйладым.

Күрекле бикә ашыкмыйча гына, тәмләп кенә сөйләде. Каган бик үк теләмичә генә тыңлады. Ике як өчен дә күңелсез булган нәрсәләрне аның хәзер кузгатып торасы килмәде. Шулай да ул, тупаслыгы аркасында, чак-чак кына эшне бозып ташламады.

— Теге кызны... Табылдыкны тапшырдылармы соң аңа? — диде ул җайлы гына, шома гына сөйләнеп утырганда.

— Китерделәр,— диде бикә көттеребрәк.— Ул аны үзе белән алып китмәде. Күрәсең киләме? Чакыртыйммы?

— Юк, юк!— диде каган, кулын селтәп.

— Минем өемдә шул кызларыңны бераз онытып торсаң да ярамасмы?— диде бикә күрәләтә үртәлеп.

— Бетте. Берсенең дә кирәге юк,— дигән булды каган бик тиз килешеп.

— Углың да кирәкмиме?— диде бикә бер кызудан, усал-мәкерле көлемсерәп.

Туман каган ялт кына өлкән бичәсенә карап алды.

— Кем әйтте аны сиңа?

— Иртәгә — күренмеш. Син берни әйтмәдең,— диде бикә.— Кичерәсеңме берлеккә, әллә артыннан кеше җибәримме?

— Җибәрергә кирәк.

— Ярар, җибәрермен.

Икенче көнне өлкән бичә Күрекле бикә өендә күренмеш[1] башланды. Башка вакытларда күренмеш каганның үз өендә була иде. Бу юлы ул әнә күренмешне өлкән бичәсе өендә ясарга, аңа үзенең хөрмәтен күрсәтеп, бикәнең көндәшләре, туган-тумачалары алдында, бәкләр, бикәләр алдында Котлуг бәк кызының мәртәбәсен арттырырга булды.

Күренмешкә каганның барлык хатыннары, туганнары, якыннары чакырылды. Түшләренә кыйммәтле ташлар, алтын-көмешләр тагып, бүрекләренә кош каурыйлары кадап, бай киемле туган-тумача, ялт-йолт килеп, өй әйләнә аяк өсте басып тордылар. Өй уртасында, бөтен идәнне тутырып, дүрткел ак киез балкып ятты. Ак киезнең көньяк почмагында, төньякка таба караган килеш, каен агачыннан кырып ясалган һәм алтын белән бизәлгән биек ак тәхеттә каган янында өлкән бичә утырды.

Күрекле бикә өстенә иң яхшы, затлы киемнәрен кигән; иң яхшы, затлы бизәнү әйберләрен таккан иде: башында ал ефәк белән тышланган, кара кеш тотылган бүрек, өстендә яшел ефәк тышлы җиңел тун. Туман каган, бикәгә капма-каршы буларак, бөтенләй диярлек киенмәгән — аның таза, итләч тәненең билдән югарыгы өлеше шәп-шәрә иде. Ул бары йонын тышка калдырып ат тиресеннән тегелгән җирән, тупас яргак[2] ыштан кигән иде дә, муенына кыл җеп белән бүре тешләре таккан иде. Ә башында — бик катлаулы, хикмәтле бүрек. Ул бүрекнең ике ягыннан да үгез мөгезләре очлаеп тора, мөгезләр арасына ак бөркет каурыйлары кадалган иде. Шул ук вакытта мөгезләрне, каурыйларны

[1] Күренмеш — кабул итү мәҗлесе.
[2] Яргак — тире кием.

бергә тоташтырган һәм башны уратып алган алтын кыршау бер-берсенә уралган өч елан сыман итеп эшләнелгән. Еланнарның өч башы, маңгай турысыннан чыгып, як-якка ысылдап торалар иде.

Кояш һәм ай углы каган бөтен Сөн иленең патшасы гына түгел, ул шулай ук иң беренче дин башлыгы да иде. Ләкин көндәлек тормышта дин-йола эшләрен анасы Кортка-бикә һәм башка күп санлы камнар, күрәзәчеләр башкарганга, чынында ул андый нәрсәләр белән шөгыльләнми иде. Ул бары изге бәйрәм вакытларында, аеруча тантаналы мәҗлесләрдә генә үзенең кемлеген, нинди көч-куәткә ия булуын күрсәтергә ярата иде.

Каганны, өлкән бичәне котлау өчен беренче булып Куян ыруыннан Котлуг бәк керде. Уң аягы белән ак киезгә баскан килеш, тәхет алдында тезләнеп ул үзенең каганга буйсынуын белдерде. Шуннан соң ул йорт башына, аның өлкән бичәсенә бүләкләр тапшырды.

Котлуг бәктән соң Алан ыруы бәге, Алан ыруы бәгеннән соң Сөйбү бәге керде. Алар барысы да Туман каганга буйсыну белдерделәр, бүләкләр бирделәр.

Бүләкләрнең барысын да ак киез өстенә, каган белән өлкән бичәнең аяк астына куйдылар. Өрсәң очып китәрдәй җинел, йомшак йонлы чибәр бүрекләр янына каен түзыннан, калын күннән бизәкләп ясалган авыр ук савытлары килеп ятты. Аның өстенә дөя йоны тукымасыннан тегелгән тупас дака[1] килеп капланды. Күп тә үтмәде, бер чабуы кайтарылып калган дака итәгенә кырып-йомшартып эшләнгән, эче-тышы кара катыш кызылга буялган зур агач табак килеп утырды. Табак янына гына алтын саплы, кынылы кылыч сузылды. Көтмәгәндә шул ук табак эченә, шапылдап, бәҗра сыман итеп җыйналган, төйнәлгән кыл-аркан килеп төште. Кыл-аркан хатын-кызлар өчен тегелгән чигүле күлмәк астына яшеренергә дә өлгермәде, барысын да киң күкрәге белән каплап, ялт-йолт килеп, алтынлап бизәлгән тимер калкан килеп ятты.

Ишек төбендә кунакларны сул кул карачы Тук-Сыртлан каршы алып, карап тикшереп торды. Тук-Сыртлан карачы яныннан үткән кунакны уң кул карачы Бүзбала каршы алды. Ул, каганга, бикәгә, өй эчендәге барлык кунакларга ишетелерлек итеп кычкырып, керүченең кемлеген, бүләккә нәрсәләр алып килүен әйтеп торды. Каганга буйсыну белдергән, бүләк китергән һәркемне үзләренең билгеле урыннарына озатып куя тордылар.

Котлау, бүләкләр тапшыру шактый озакка сузылды. Элегрәк, башка бәйрәм вакытларында каганның бичәләре, балалалары күренмешкә иң алдан кертеләләр иде. Бүген каган Тук-Сыртлан карачыга икенче төрлерәк эшләргә кушты. Ни өчен шулай кирәклеген аңлатып тормады — Тук-Сыртланга да, башкаларга да бу инде аңлашыла иде. Уң кул тучи бәк тәгин угланның изге бәйрәм алдыннан гына Тарлавыкка китеп баруын һәм нилектән китеп баруын урдада инде белмәгән кеше юк. Шулай ук кичәгенәк тәгин угланны кире борырга дип ашыгыч тартык [2] җибәрелүен дә күп кешеләр күреп калганнар иде.

Шулай итеп, барлык бәкләр кереп беткәч, Тук-Сыртлан карачы каган бичәләренең балаларын кертә башлады. Каган да, Күрекле бикә дә, ут йотып, тыннарып кысып, әледән-әле ишек ягына карап алдылар.

Менә соңгы бичә дә керде, соңгы балалар да керде. Бөтен өй эче дүрт күз белән көткән тәгин углан — уң кул тучи бәк Албуга күренмәде. Каган белән бикә бер-берсенә мәгънәле генә карашып алдылар һәм икесе берьюлы диярлек көрсенеп куйдылар.

[1] Дака — йоны тышка калдырып тегелгән тун.

[2] Тартык — каганга, бигә, бәккә буйсынган кешеләрне ашыгыч рәвештә каган (би, бәк) янына чакыртып алу өчен махсус җибәрелгән кеше, йомышчы.

Дәвамы киләсе санда

Нурихан Фәттах

СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

РОМАН

Беренче китап

XI

Күренмештән соң кунакларга ашарга китерделәр. Беркадәр вакыттан соң — ашагач, өсләрендәге бай киемнәрен кыршылып беткән тире туннарга алыштырып, туглар күтәреп, барабаннар кагып, бөтен ил-көн Туман каган өе яныннан Изге-тауга таба юнәлде.

Иң алдан акбүз атка атланып Туман каган белән Баргынтай баба барды. Алар артыннан күп санлы җәяүлеләр — камнар, багучылар, күрәзәчеләр, агай-энеләр атлады. Һәрбер ыру үзе белән җитәкләп корбан малы алып барды. Бернинди шаушу, ыгы-зыгысыз, изге бер тантана белән әкрен генә атлап барган озынча төркемнең башы тау итәгенә килеп җиткәндә, кышкы кояш инде бик нык зурайган, кызарган һәм кара җир астына таба төшеп бара иде. Шул ук вакытта юл уңаена арттан туктаусыз искән ачы җил дә, кешеләр изге җиргә килеп җиту белән, кинәт кенә туктап калгандай булды. Бу исә көннең озакламый төн белән алышыначагын белдерә иде.

Туман каган белән Баргынтай баба туктадылар, арттан килүчеләрне беравык көтеп тордылар. Озакламый бөтен тау итәге җәяүле халык белән тулды. Барлык ырулар, килеп җитеп, үзләренең билгеле урыннарына баскач, Туман каган белән Баргынтай баба җитәкчелегендәге Сөнәнкәләр беренче булып тау башына үрли башлады.

Каган белән Баргынтай баба Изге-тауга көнчыгыш яктан менделәр. Атланып килгән атларын алар аста калдырдылар. Ат урынына алар икесе дә корбан малларын җитәкләделәр: иң алдан атлаган каган үгез тезгенен тотты, Баргынтай бабага алаша бирделәр. Башка корбан малларын көчләрәк, тазарак ирләр җитәкләде. Каты, текә тауда малларның аяклары тайды. Турыга, текәгә менәселәре килмичә алар ничек тә читкә тайпылырга тырыштылар, кычкырдылар, киреләнделәр. Ләкин таза куллы ирләр кыл арканнарны нык тоттылар. Сукмаенча, куркытмыйча, шулай да өзлексез әйдәп, җитәкләп, кирәк булса этеп-төртеп, күтәреп аларны һаман югарыга менгерделәр.

Тау башына менеп җиткәч, барысы да тынып калды. Һәм биеклек

Дәвамы. Башы 3 санда.

тәэсиренә, изге, илаһи бер тәэсиргә бирелеп, сокланып, исләре китеп, озак кынаерактагы киңлекләргә, кара-кучкылланып, тоташ булып күренгән алыс[1] тауларга карап тордылар. Кайсы гына якка борылсаң да, бөтен тирә-як моннан уч төбендәгедәй ап-ачык булып күренә иде. Шул ук вакытта киңлек, иркенлек һәм серле, изге бер тантана хөкем сөрә иде бу кичке кояш нуры төшкән ялгыз калкулык башында! Монда кеше ирексездән үзен күккә, Тәңрегә һәм изге ата-бабаларга якынрак итеп тоя сыман иде.

Тау өстендә, уртада, юан-юан карагай бүрәнәләрдән өелгән сигез почмаклы бура — корбан корымы калкып утыра иде. Киез өй сыман астан өскә таба тарая барган бу биек бураның түбәсе юк. Бураның дүрт ягында ишек кебек дүрт ачыклык калдырылган, шунлыктан анда җәен-кышын, язын-көзен җил-яңгыр, кар-буран уйнап тора иде.

Туман каган белән Баргынтай баба изге бурага берничә адым җитмичә туктадылар, тезләнделәр дә, Сөн бабага атап дога кылдылар. Җил кискән кырыс чырайлы ирләр, тын алырга да куркып, бер читтәрәк басып тордылар. Дога укылгач, каганга төтәсләп торган кисәү башы китереп тоттырдылар. Кисәү башын ул шунда ачык җиргә өеп куелган коры тал чыбык, камыш өеменә якын китерде. Күп тә үтмәде, чыртлап коры камыш янганы ишетелде. Бармак башыдай ут, камыштан-камышка сикереп, чырт-чырт килеп, куе чытырлык арасыннан җитез генә шуыша башлады, югары үрләде, төтен чыгарды һәм бер мәлне кинәт гөлт итеп китте дә, бөтен зур өемне ялмап алып, куанып бии башлады.

Инде караңгыланып килә иде. Кызыллык сүнә барган офык ягына, аста, төн ягыннан далага, иләмсез зур киез кисәгедәй булып, болыт булып, томанлы салкынлык якыная. Изге-тау башында учак яна башлау белән, тау итәгендә дә анда-монда утлар кабынды.

Корбан малларын дөрләп янган ут яктысында, сигез почмаклы бура янында чалдылар. Малның канын аерым савытларга җыеп, бура эченә алып керделәр. Сигез мөгешле изге корылма эчендә, уртада, яртылаш җиргә күмелеп, Сөн-баба кылычы калкып тора иде. Каган тезләнеп изге кылычның бакыр сабыннан тотты. Баргынтай баба, келәү әйтеп, канны кылыч төбенә агызды. Җиргә түгелгән корбан каны, әйтерсең, кылыч тимере буенча каганга күчте һәм ул үзендә искиткеч бер җиңеллек, дәрт тойды һәм шул ук вакытта барлык языклардан-гөнаһлардан арыну-арыклану сыман бер үзгәреш кичерде.

— Бетмәс-төкәнмәс көч-куәт бир, Тәңрем. Илем-көнем бай булсын, терлекләрем күп булсын, дошманнарым аяк астында аунап ятсыннар! — диде Туман каган келәү әйтеп.

Чалынган малны шундук тунадылар, итен-иткә, сөяген-сөяккә аердылар да, сөяген җыеп яндырдылар, итен, эчәк-бавырын түбәнгә, далага алып төштеләр. Каган ыруының — Сөнәнкәләрнең барлык кешесенә корбан ите өләшенде. Кайберәүләр, учак ягып, турыдан-туры шунда Сары-су буенда казан астылар, кайберәүләр — ярлыраклар, күп балалылар, үзләренә тигән өлешне бик кадерләп, өйләренә алып кайтып киттеләр.

Сөнәнкәләр корбан биргәч, тау башына Куяннар менде, Куяннардан соң — Аланнар, Аланнардан соң — Сөйбүләр... Бер ыру икенче ыруны шул рәвешчә алыштыра торды.

Корбан бирү таңга чаклы дәвам итте. Бөтен тирә-якта — далада, тау башында — йөзләгән утлар янды, меңләгән кешеләрнең сөйләшкән, көлгән, кычкырган тавышлары ишетелде. Казаннарда итләр пеште, бурдакларда кымызлар күперде. Әле анда, әле монда җыр-бию, уенкөлке башланып китте.

[1] Алыс — ерак.

Сөн бабага атап корбан бирүдә бары ирләр генә катнашты. Хатын-кызлар, бала-чага барысы да өйләрендә торып калдылар. Өлешкә тигән корбан ите кайтып җитү белән, киез өйләрдә җанлану башланды. Хатыннар шундук тышка чыгарып казан астылар, учак дөрләтеп җибәрделәр. Кул яссуыдай кечкенә өлеш итләренә кушып, казаннарга бөтен куйлар салдылар. Өйләр, учаклар арасында чыр-чу килеп шат күңелле балалар чабышып йөрде. Бәйрәм көн дип өстәлләргә яхшырак, затлырак азыклар куелды. Шулай ук бәйрәм көн дип, һәркем бер-берсенә карата ягымлы, кечелекле булырга тырышты.

Бөтен ил-көн, бөтен урда дөньясын онытып бәйрәм иткәндә бары Күрекле бикәнең генә күңеле борчулы булды. Дерт-мерт килеп ул әледән-әле ишеккә каранды, әледән-әле тыштагы тавышларга колак салды. Туктаусыз тынгысызланып ул өлкән углының кайтып керүен, я булмаса аны алырга җибәрелгән кешеләрнең кайтып җитүен көтте. Барысын да алдан уйлап эшли алмавына ул үкенеп бетә алмады. Башта ук аны карап-күзәтеп кенә торырга кирәк булган, башта ук аны беркая җибәрергә кирәк булмаган. Кечерәк кайгысына бирелеп ул әнә зуррак кайгысын онытып җибәргән! Күренмеш алдыннан беркая бармасын дип ичмасам Туңгак та кисәтеп куярга онытκан. Күренмештә ил башы каганга буйсыну белдермәүнең нәрсә икәнлеген алар әнә икесе дә онытып җибәргәннәр!

Шулай пошынып утырганда, кемнеңдер кереп килгәне ишетелде. Бу каган кешесе булып чыкты. Ул бикәгә корбан ите алып килгән иде. Үзенең өлкән бичәсенә, балаларына каган быел да башка еллардагы кебек түш ите җибәргән иде. Корбан итенең күплегенә-азлыгына, яхшымы, түгелме икәнлегенә игътибар итәргә тиеш түгеллеген белсә дә, йомышчы чыгып киткәч тә бикә итне җентекләп карарга тотынды. Элекке еллар белән чагыштырганда ул бернинди үзгәреш күрмәде.

Бикәнең йөзе яктырып китте, күңеле беркадәр тынычлангандай булды. Корбан итен ул шундук пешекчеләргә бирде, шуңа өстәп тагын йөз кешегә җитәрлек итеп туңдырылган ит алырга кушты да, тыштагы, таган өстендәге зур бакыр казан астына ут дөрләтеп җибәрде. Казанга тутырып су салгач, ит салгач, казанның зур агач капкачын каплап куйгач, калганын пешекчеләргә тапшырып, ул яңадан өенә кереп китте. Ләкин өйдә дә озак тора алмады, нindидер эшлисе эше бар кеше сыман, ул аннан кире чыкты. «Ә!» диде ул кинәт, эшлисе эшен исенә төшереп. Артта, икенче бозрада ул өлкән улына дип өй корган иде. Өйдә аның кырнагы Табылдык булырга тиеш. Никтер аның хәзер менә шул кырнакны күрәсе, аның белән сөйләшәсе килеп китте. Кичәдән бирле ул кызның беркайда күренгәне юк — исәнме ул, юкмы, бер-бер хәл булып авырып-нитеп китмәдеме? Аларга күз-колак булып торганың яхшы.

Шундыйрак уйлар белән ул өлкән углының өенә китте. Өйдә, идән уртасында, сүнәр-сүнмәс кенә булып, учак кызарып ята иде. Өй эче ярым караңгы, шулай да монда кемнәрдер барлыгын шәйләп була. Ләкин бикәне беркем дә каршы алмады. Ул монда үз өенә кергән кебек килде дә керде. Учактан читтәрәк тезләрен кочаклап, башын иеп утырган кырнак аңа бары күтәрелеп кенә карады. Кызның саксызлыгы, салкынлыгы бикәнең кытыгына тиде. Аның күңелендә ачу тойгысы кабара башлады. Шулай да ул үзен тыеп калырга тырышты һәм күзләрен уттай яндырып әдәпсез кырнакка карап торуында булды.

Шул чакны ул түрдә, биек урын-җирдә сузылып яткан нindидер яшь бер ир кешене күреп алды.

— Балам, син түгелме соң?! — диде ул аның кемлеген сизенеп

Ятактагы ир кеше ашыгып башын калкытты, торып утырды һәм чиктән тыш куаныч, курку һәм гаҗәпләнү белән:

— Әни?! — диде.

— Син... кайттыңмени, улым? Кайда очраштыгыз? Атаңны күрдеңме? — диде бикә, улына бер-бер артлы сораулар яудырып.

— Кем белән очрашырга тиеш идем соң мин? — диде Албуга берни аңламыйча.

— Сине куып җитеп, кире алып кайтырга дип мин йөзбашы Җирәнне җибәргән идем.

— Мин үзем кайттым. Күренмеш буласын искә төшердем дә, кире борылдым. Менә... өлгермәдем.

— Әйе, өлгермәдең,— диде әнисе күңелсез генә.

Ике арада кинәт кенә сүз өзелеп калды: Албуганың күңелсез яңалыкны ачыклап торасы килмәде, бикәнең аны шулай ук сөйләп торасы килмәде. Әле генә күргән кебек, ул кол кызга борылып карады.

— Син, балам, ник эндәшмисең? Авырмыйсыңдыр ич? — диде ул аңа кыты гына.

Табылдык, тагын бер күтәрелеп кенә карады да, эндәшмичә башын түбән иде. Аның яшь, дәртле күз карашында, учакта пыскып яткан утлы кузлар кебек, усаллык һәм дошманлык чагылып калды. Бер елдан артык ире Туман каганның башын-күзен әйләндергән, чын мәгънәсендә аны уч төбендә биеткән бу гүзәл кыпчак кырнагын бикә элегрәк тә яратмый иде. Күрәсең, кырнак үзе дә каганның көнчел бичәләрен, үзеннән ямьсезрәк, өлешсезрәк карабашларын яратып җиткермәгәндер. Күрәсең, әле дә ул үзендә шул элекке яратмау, күрәлмау тойгысын саклап утырадыр. Көндәше бикә алдында шулай түбәнсенеп утыруы өчен аның күңеле, бәлки, телгәләнәдер дә.

Бу кырыс, горур кыз янынннан бикә болай гына чыгып китә алмый иде. Олы бәйрәм көнне үзенең барлык ачуын, кире тойгыларын эченә йотарга кирәклеген аңлап, йомшарып ул аның янынарак килде, чүгәләп кызның башыннан сыйпагандай итте.

— Сиңа ни булды, балам? — диде ул тагын пошынып.

— Булмады! — диде кырнак һәм кырт кына читкә борылды.

— Булмагач, ник эндәшмисең: мин — синең бикәң!

— Эндәшәсем килми!

— Син миңа эндәшергә тиешсең! Минем углымның кырнагы минем белән бил бөгеп сөйләшергә тиеш!

— Мин синең углыңның кырнагы түгел! — диде Табылдык, башын горур чөеп.— Мине Кортка-бикәгә озатыгыз. Мин абаларга китәм. Минем монда бер көн торасым килми.

Кызның кискен сүзләре, үз-үзен бәйсез, горур тотуы, аннан да бигрәк, аның тышка бәреп торган ниндидер кайгысы бикәне уйланырга, сагаерга мәҗбүр итте. Кызык, нишләп торасы килми икән аның шундый яшь углан янында?

— Китәсең килсә, китәрсең, балам,— диде ул кызмыйча гына.— Шулай да кычкырып әйтмә ул сүзләреңне — ишетсәләр, хәзер алып китәрләр!

Бикә югарыга, төннеккә ымлады. Яшь, матур аякларын кочаклап, үз-үзенә йомылып, үз кайгысына бирелеп утырган гүзәл кыпчак кызы бикәнең кисәтүен уйлап та бирмәде.

— Мин алардан курыкмыйм. Мин алар янында булдым инде,— диде ул бераздан пошмас бер тынычлык белән.

Бикә ни әйтергә дә белми аптырап калды. Нишләгән бу аңсыз карабаш? Шул ук мәлдә аның күңелен бер сизенү яктыртып җибәрде. Ул шундук улы ягына борылып карады. Углының күз карашында, кыяфәтендә, үз-үзен тотышында бикә аның әз генә дә бу сылу, яшь хатын белән кызыксынмавын күреп алды.

— Улым, нишләп... авызыңа су каптың? — диде ана кеше.

— Нәрсә, әни? — диде углан дәртсез генә.

Ул, ахрысы, бөтенләй башка нәрсәләр турында уйланып утыра иде.

— Нишләп кызыңны кыерсытасың, улым?

— Мин аны кыерсытмыйм, әни.

Бикәнең сизенүе дөрес булып чыкты — Табылдык ачылып, үзгәреп китте.

— Ул минем белән сөйләшми, бикә! — диде ул кинәт күңеле тулып.— Ул мине күрми дә, ишетми дә. Ул мине утын агачы дип уйлый, ахрысы. Мин әле яшь, чибәр, дүрт саным төгәл — ник яратмый ул мине?!

— Әйе, яратмыйм мин аны, әни,— диде углан авырлык белән телен әйләндереп.— Атам каганга кире җибәрсеннәр... я син аны үзеңә ал.

— Минем ни языгым бар?! — диде Табылдык, тыела алмыйча.

Бикә тынып калды. Аңа бик авыр, бик кыен иде. Ул үзенең улын да бик яхшы аңлады кебек, ләкин шул ук вакытта кол кызның да аңламаслык бернинди сере юк иде.

— Чин кызы мине каганнан аерды, ул минем белән тәгин углан арасын бозды. Күземне йомсам мин аны икебезнең арада күрәм! Эт кебек, җылан кебек синең улың янында сузылып ята, бикә!

Күрекле бикә, улына ымлап, аңа якынрак килергә кушты. Яшь углан буйсынып учак янына килде, әнисе алдында тезләнде.

— Бир әле уң кулыңны, улым.

Албуга карышмыйча әнисенә уң кулын сузды. Бикә кол кызның да кулын үз кулына алды да, җиңелчә көлемсерәп, яшьләргә күрешергә кушты.

— Нинди кайнар! — диде ул кыпчак кызының кулын мактап.— Уты бөркелеп тора. Менә ул яшьлек!

Албуга, әллә кызның кул кайнарлыгыннан, әллә әнисенең хәйләсеннән уңайсызланып, җиңелчә генә кызарынып куйды. Аның салкын, дәртсез тәненә исерткеч җиңеллек, җылылык дулкыны йөгереп үтте. Табылдык ирексездән елмайды һәм яшь тамчылары тамып торган сөрмәле матур күзләрен тутырып әле бикәгә, әле угланга карап-карап алды.

— Җүләрләр! — диде ана кеше, ачусыз гына шелтәләп.

— Олуг бикә! — диде кыз тәэсирләнеп.— Әни! Әнием, дип әйтергә ярыймы сиңа, олуг бикә? Минем беркемем юк — әнием дә, әтием дә. Аягың астында туфрак булырмын — «әнием» дип әйтергә рөхсәт ит миңа, олуг бикә!

— Менә... аның аягы астында туфрак бул,— диде бикә көлемсерәп, белексез углына ымлап.— Шундый буем-сыным була торып, шундый яшьлегем-гүзәллегем була торып, су сөлегедәй яшь углан янында борын салындырып утыраммы соң мин?! Курыкма, «әнием», дип әйт, кызым.

— Бай бул, әнием! — диде Табылдык, бикәнең кулын үбеп.

— Менә, татулаштыгыз да,— диде бикә, китәргә җыенып.— Улым, кара аны, корбан ите ашарга кызың белән бергә кил!

— Килермен, әни,— диде Албуга әкрен генә.

XIII

Яшьләрне шулай үзара килештергәч, татулаштыргач Күрекле бикә үз алдына уйланып, сәер бер тойгы белән өйдән чыгып китте. Ник шулай тырышты соң әле ул? Кем өчен? Улы өченме, кырнак өченме, әллә

соң үзе өченме? Ник кирәк булды аның менә шулай яшьләр эшенә килеп кысылуы?

Бераз гына ул үзен алар алдында уңайсыз сизде. Бу аңа үзенең әрсезлеге, тупаслыгы булып та, начарлыгы-яманлыгы булып та тоелды. Ләкин шул ук вакытта ул менә шулай эшләргә тиеш иде сыман. Ул — ана кеше — үз улының, тәгин углының ничек атлавын, ничек тын алуын да белеп торырга, читкә тайпылса — туры юлга чыгарырга, егылса — күтәреп торгызырга тиеш түгелмени?! Ул аны сакларга, якларга, кирәк булса, аның өчен утка-суга керергә тиеш түгелмени?! Аның улы чыннан да барлык кешеләрдән, барлык кешеләргә хас төрле кайгы-борчулардан өстен булырга тиеш түгелмени?! Менә алар үзара якынайсыннар, бер-берсен яратышсыннар, шуннан соң инде ул — аның углы — чин кызын исенә дә кертеп чыгармас!

Янында моңаеп кызы утыра, ул аны яратмый, имеш! Тәнеңә уты үрләсә, яратырсың, углым. Дөньяда әле беркемнең дә яратудан баш тартканы юк. Тәңре безне яратышу өчен, бер-береңә бәхет, куаныч бирү өчен яраткан.

Өлкән улы белән кыпчак кызы турында уйлаганда бикә шулай да үзен, аннан да бигрәк, үзе белән икенче бер ир арасындагы мөнәсәбәтләрне күз алдында тотты бугай. Үзе дә ул моны сизеп алды. Һәм шундук аның уй җепләре чуалып калды.

«Яратмаса, бик шәп!» дип уйлады ул бераздан улы турында. Чин кызын яраткан кебек яратса, бик тиз ул аның... кыпчак кырнагының сүзенә колак сала башлаячак. Менә монысы инде иң яманы булыр! Туман каганның да бер авызы пешә әле ул чин кызы белән. Болай да инде чибәр кызлар аның җилкәсенә менеп утырганнар. Аның углы беркайчан да андый булмас. Ул — ана кеше — моңа юл куймас!

Ул арада бикә үз өенә кайтып җитте. Ләкин ул өенә кереп тормады, казан янына барып, итнең кайнавын-кайнамавын белеште һәм бары шуннан соң гына кире кайтып, авыр өс киемнәрен алыштырды да, чаршау артына узды. Шул вакыт аңа кунак килүе турында әйттеләр.

— Кем? — диде бикә.

Теше төшеп беткән ишек сакчысы кортка шаяртырга ярата иде: елмайган кебек итеп ул сирәк тешле уртларын ачты да, авызын кыйшайтты. Күрекле бикә көлеп җибәрде.

— Исәнтәймени? — диде ул, кем килүен чамалап.

— Шул инде, шул.

— Керсен.

Исәнтәй, килеп керү белән, гадәтенчә баш иде, тезләнде һәм авызын ишек сакчысы кортка күрсәткәнчә дип әйтерлек кыйшайтып елмая-елмая, түргә узды. Күрекле бикә аны, аяк өсте басып торган килеш, учак янында каршы алды.

— Изге бәйрәм көнендә котлыйм сине, олуг ана! — диде Исәнтәй.— Илең-көнең имин, малың-туарың күп булсын.

— Шулай булсын, Исәнтәй,— диде бикә.

«Ни кирәк аңа мондый чакта?» — дип уйлады бикә һәм бу кыек авызлы, кыек уйлы кеше ни генә сөйләсә дә, ни генә әйтсә дә, сак һәм уяу булырга дип алдан ук үз-үзен кисәтеп куйды.

— Барлык ирләр корбанда. Син нишләп торып калдың, Исәнтәй?

— Мин анда булдым, олуг ана,— диде Исәнтәй елмаеп.— Мин сиңа бүләк китердем. Карыйсыңмы?

«Бүләк» сүзен ишетү белән бикә, баштагы кырыслыгын томалап, йөзенә елмаю билгесе чыгарды. Исәнтәйнең бүләгеннән баш тарту ярамый иде, әлбәттә. Ул ак киез өстендәге мендәргә утырды, кунагына урын күрсәтте. Исәнтәй утырды, куеныннан сырлап-бизәкләп ясалган көн савыт чыгарды, савытның капкачын ачып, бүләген бикәгә якынрак китерде. Кан төсле ал ефәккә төренеп әлеге көн савытта нык шомар-

тылган зур ташлы алтын каптырма балкып ята иде. Каптырманың тавык йомыркасы кебек калку-озынча, боз төсле үтә күренмәле яшькелт ташы уртасында сыңар күз булып икенче таш — күк таш, аның уртасында өченче таш — энҗе бөртеге ялтырап ята иде. Мондый гүзәл каптырманы күреп бикә елмаеп җибәрде. Кулы үзеннән-үзе күн савытка үрелде.

— Матур нинди, олуг ана! — диде Исәнтәй, сөенеченнән нишләргә белмичә.

Бикә каптырманы кулына алды, иплән кенә, саклап кына аны төрлечә тоткалап, әйләндергәләп карый башлады.

— Нишләп аны элегрәк алып килмәдең... күренмешкә кадәр? — диде бикә чын күңелдән үкенү белдереп.— Күренмешкә тагып чыккан булсам, бөтенесенең күзе ут булыр иде!

— Теге яктан килде, бикә,— диде Исәнтәй, көньякка ымлап.— Бүген генә килде. Соң түгел. Бүген — бәйрәм, иртәгә — бәйрәм.

— Алам! Бик матур! — диде бикә соклануын яшерә алмыйча.— Бүләгең өчен ни телисең, Исәнтәй?

— Юк, юк! — диде Исәнтәй, кулын селтәп, бик нык хәтере калган кеше сыман.— Мин сатмыйм. Мин сиңа бүләк бирәм, олуг бикә. Каган мине ярата, бикә дә мине яратсын, хе-хе...

— Ярар алайса. Рәхмәт! Йомышың булса, туп-туры үземә кил.

Соңгы сүзләрен ул ничектер уйламыйчарак кына, үзенә яхшылык эшләгән һәркемгә әйткәндәгечәрәк кенә итеп әйтте. Исәнтәй исә, бикәнең нәкъ шундый сүзен генә көтеп торган сыман, кыюланып аңа таба якыная төште һәм кеше-кара ишетә күрмәсен дигәндәй, авызын учы белән каплап, пышылдап:

— Сиңа сүзем бар, олуг бикә,— диде.

— Нинди сүз, Исәнтәй? — диде бикә, бүләктән күзен алмыйча.

— Хатын-кыз сүзе,— диде Исәнтәй көлеп.— Андый сүзне ир кеше әйтми, хатын-кыз әйтә.

— Ир кеше авызыннан хатын-кыз сүзе ишетү кызыграк та ул.

— Теге чин кызы... Сөенеч... — диде Исәнтәй, ы-мы итенеп,— асрау карчык аша әйткән: мин тәгин угланны сагынам, мин тәгин угланны яратам дигән...

— Яратса, шуннан ни булган? — диде бикә гамьсез генә.

— Сөенечнең тәгин угланны күрәсе килә, бикә! — диде Исәнтәй пышылдап.— Очраштырырга кирәк. Беркем белмәс — син дә мин, без дә алар.

«Менә ничегрәк икән эшләр!» — дип уйлады бикә үзалдына. Әле генә ул үз углы белән бер карабашның арасын җайлады, инде менә икенче карабаш белән араларын җайлар. Ярар, ана кеше җайлады да ди. Исәнтәйгә монда ни калган? Ник кысылмакчы була әле ул алар арасына?

Әле генә мактап алган бүләге аңа кинәт бик авыр булып тоелды. Шундук аның күңелендә бу ямьсез, җирәнгеч кешегә карата баягы сагаю, шикләнү тойгысы калкып чыкты. Шул ук вакытта ул Исәнтәйгә кисәк кенә сыртын да кабарта алмады. Аның икеләнүен күреп Исәнтәй янә пышылдарга тотынды.

— Сиңа әйтми ярамый, олуг бикә. Каган карт дип әйтә ди Сөенеч.

— Миңа әйтүең яхшы булган, Исәнтәй. Мин — ана кеше барысын да белеп торырга тиешмен. Шулай да син бернәрсәне оныткансың: тәгин угланның кызы бар, аңа беркем кирәкми. Изге корбан бәйрәме көнендә минем углым андый эшкә катнашмас.

— Шулай, олуг бикә, шулай! — диде Исәнтәй, бик тиз килешеп.— Мин дә шулай уйлыйм. Асрау карчык миңа әйтте, мин сиңа әйттем.

Сөйләнә-сөйләнә ул арты белән ишеккә таба чигенде.

— Тагын шундый сүзләр сөйләнсә, асрау карчыкның телен кистерермен! — диде бикә янап.

— Тәгин углан өйдәме соң үзе?

— Аның янына барып йөрергә киңәш итмим, Исәнтәй.

— Ул өйдәмени?

— Өйдә,— диде бикә, үзе дә сизмәстән.

— Сау бул, олуг бикә, хуш! — диде Исәнтәй һәм ашыгып чыгып та китте.

XIV

Чак-чак кына калышып аның артыннан бикә дә чыкты. Исәнтәйнең ашыгуы аңа бик шикле тоелды. «Кая китәр икән?» дип уйлады ул, ерагая барган карачкыны күздән югалтмаска тырышып. Исәнтәй кызулап төньякка таба юнәлде. «Артыннан күзәтеп барырга берәрсен җибәрергә кирәк» дип уйлады бикә. Ул тиз генә кире өйгә керде. Ләкин Исәнтәй артыннан китәргә тиешле кешесен ияртеп кире чыкканда Исәнтәй инде каршы яктагы икенче бичә Сырга бикә өе артында күздән югалып өлгергән иде. «Күрәсең, аңа да бүләк бирмәкче буладыр» дип уйлады Күрекле бикә, үз-үзен тынычландырып. Өйдән үзе белән алып чыккан хатынны ул шулай да Сырга бикә өе ягына җибәрде.

— Өенә кермә. Читтән генә күзәт — ул шунда булырга тиеш,— диде ул хатынга шыпырт кына.

Бикә әлеге хатынның ярым караңгыда ерагая барганын күзәтеп торды да, яңадан казан ягына китеп барды. «Сырга бикәгә нәрсә бирер икән?» дип уйлады ул Исәнтәй турында.

Бикә бик нык ялгышты. Исәнтәй Сырга бикә өенә кереп тормады— юл яздырыр өчен ул юри шулай анда киткән булды. Өй артына яшеренгәч ул бөтенләй читкә — өченче бөҗра ягына ашыкты. Өченче бөҗра артына чыккач әйләнеп бераз җир килде дә, атына атланып, туптуры Изге-тауга, Туман каган янына ашыкты.

Исәнтәй Сары-су буендагы киң яланга килеп җиткәндә, Сөнәнкәләр күптән инде корбан биреп тау башыннан төшкәннәр иде. Берничә җирдә, кара төнне ярып, ялкынланып учаклар яна, казаннарда корбан итләре пешә. Бер казан белән икенче казан арасындагы ачык урыннарда кешеләр кайнаша, әле анда, әле монда шат күңелле төркемнәр күренә.

Каган өчен яланда үгез тиреләреннән аерым алачык корылган иде. Исәнтәй алачыкны ерактан ук күреп барды. Ләкин алачык янына килеп җиткәч, ишек янындагы торгаклар аны каган янына кертүдән баш тарттылар.

— Каганга минем ашыгыч сүзем бар — кертегез! — диде ул таләп итеп.

Битлек кигән камнар аны, ай-ваена, әрсезлегенә карамыйча, ике куллап әләктереп алдылар да берни әйтмичә читкә алып китә башладылар. Исәнтәй кинәт бар көченә кычкырып җибәрде. Аның ямьсез тавышы колакларны ярып як-якка таралды. Якындагылар тавыш килгән якка борылып карадылар, шул ук мәлдә дип әйтерлек алачыктан ашыгып каган килеп чыкты.

— Ни булды? Кем кычкыра? — диде ул каранып.

Каганны күрү белән камнар туктап калды. Исәнтәй, аларны як-якка җиңел генә селтәп җибәрде дә, каганның аягы астына барып егылды.

— Ник кычкырасың?— диде каган исе китеп.

— Кулымны каердылар,— диде Исәнтәй ялганлап.— Бөек каган, ашыгыч хәбәр бар,— диде ул аннары, тавышын әкренәйтеп.

— Әйдә, кер,— диде каган.

Кысан алачыкка керү белән Исәнтәй як-ягына каранды, аннары суларга тыны җитмәгән кебек ашыгып:

— Колының өйдә, бөек каган! — диде.

— Өйдә?! — диде каган ышанмыйча.— Аны алырга киткән кешеләр очратмый кайттылар.

— Өендә качып калгандыр ул, бөек каган. Анасы әйтмәгәндер,— диде Исәнтәй.— Сылтау бар: күренмештә булмады, буйсыну белдермәде — өендә качып калган! Анасы белән икесен дә хәзер үк кулга алырга кирәк, бөек каган!

Әйе, бу бик яхшы, бик уңай сылтау иде! Ләкин мондый сылтауга таянып эш итәргә Туман каган әлегә күңеленнән әзер түгел иде. Бүген ул, дөнья кайгыларын онытып, тулысынча дин-йола, ата-баба кайгылары белән мәшгуль иде. Аннан соң аның күңелендә тәгин углына карата бернинди дошманлык тойгысы да юк иде. Аның күңелендә бары яман төш тәэсире дә, анасы Кортка-бикәнең әйткән сүзләре генә ике арада киртә булып ята иде. Исәнтәйнең киңәше дөрес сыман булып тоелса да, ул ашыкмаска булды.

— Тырышлыгыңны истә тотармын, Исәнтәй,— диде ул кыек авызлы кешенең баш өстеннән читкә карап.— Бүген минем андый эшкә кулым бармый.

Исәнтәйнең авыр башы аска иелде.

— Тагын бер уйлап кара, бөек каган! Ятып калганчы атып калырга кирәк! — диде ул соңгы бер омтылыш белән.

— Мин уйладым инде,— диде каган коры гына.— Иртәгә дә килеп бил бөкмәсә, анда күз күрер.

Хуҗасы тибеп җибәргән эт кебек, Исәнтәй башын тагын да ныграк аска иде, бөтен гәүдәсе бөрешеп, бөгәрләнеп калды. Әрнеп ыңгырашу сыман бер өн чыгарды да, арты белән чигенә башлады.

— Шулай да син күз-колак бул,— диде каган болай гына.

— Булырмын, бөек каган! — диде Исәнтәй сөенеп.

«Булмаган кая ул!» дип уйлады ул үзалдына.

XV

Бәйрәм шау-шуы, бәйрәм ыгы-зыгысы төн уртасына чаклы дәвам итте. Икенче көнне төштән соң бөтен ил-көн — агай-эне, бәкләр Туман каганның олы җыен вакытларында гына торгызыла торган Күк өенә җыелдылар. Күк өй Ак өйдән биегрәк тә, иркенрәк тә иде. Аның идәннән алып түшәмгә кадәр бөтен эче тоташ күк ефәк белән бизәлгән. Идән уртасына бик зур ак киез җәелгән, киез уртасына — ишектән кергәч тә сул якка алтынлап, сырлап ясалган биек тәхет куелган, тәхетнең ике ягында да каганның якын кешеләре өчен калку урыннар җайланган иде.

Тәхеткә каган иң яхшы киемнәрен киеп чыкты. Аның уң ягына өлкән бичә Күрекле бикә утырды, сул ягына Котлуг бәк утырды. Башка бичәләр, бәкләр барысы да үзләренә тиешле урыннарга урнаштылар. Каганның дүрт бичәсеннән туган балалары бөтен бер оя булып тәхет каршысына, ак киез өстенә утырдылар. Алар арасында бүген дә бары тик уң кул тучи тәгин углан Албуга гына юк иде. Урдадагы хәлләрне якыннан белеп, күзәтеп кенә торган һәм шуңа карап бүген, иртәгә ни буласын алдан юрарга күнеккән кешеләр тәгин угланның юклыгын бик тиз күреп алдылар, үзләренчә фараз кылдылар һәм күршеләре белән пышылдашып, гайбәтләшеп алырга да өлгерделәр.

Барлык кеше җыелып беткәч, каган аяк өсте басып, олы киңәшнең башлануын белдерде. Сары-су буена корбан бәйрәменә җыелыр алдыннан бөтен ил буенча кешеләрнең, шулай ук терлек-туарның сан исәбе алына иде. Кайда күпме кеше, күпме терлек булуына карап каган үзенә буйсынган бәкләрдән салым ала һәм үзенең йорт-җир, хуҗалык эшләрен дә ил-көннең көченә, байлыгына карап җайлаштыра иде. Олы киңәштә сүз иң элек шул турыда була. Бәкләр, ыру башлары монда шулай ук үз ыруларындагы, үзләренә буйсынган төбәкләрдәге төрле эшләрне, бәхәсле мәсьәләләрне кузгаталар, ил белән ыру белән идарә итүгә кагылышлы нәрсәләрне тикшерәләр иде. Барыннан да бигрәк, быелгы кышта кая, кайсы якка яу чабу яисә яу чапмау мәсьәләсе дә каралачак. Каган өендәге олы киңәш башлыча шуның өчен җыела.

Башта каган агай-энене үз ыруындагы, үз урдасындагы хәлләр белән таныштырырга тиеш иде. Бер-берсенә терәлеп, тыгызланып торган һәм бер кешедәй тынып калган ирләр Туман каганның нәкъ шундый сүзләр әйтүен көттеләр. Ләкин сүзне каган бөтенләй икенче нәрсәдән башлады.

— Уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга кичәгенәк күренмештә булмады, бил бөгеп миңа буйсыну белдермәде,— диде Туман каган бөтен өй эченә кычкырып.— Бүген ул мондамы?

Ирләр, барысы берьюлы тыннарын кысып, бер-берсенә карашып алдылар һәм чиктән тыш бер кызыксыну белән көтеп тора башладылар. Нәрсә булыр, Тәңрем — күк күкрәп яшен яшьнәрме, әллә кояш балкырмы?

— Монда, бөек каган! — дип кычкырды Бүзбала бөтен өй эчен яңгыратып.— Ул кичәгенәк авыру булган, шуңлыктан күренмештә була алмаган.

— Монда булса, керсен,— диде Туман каган.

Ишектән тәхеткә кадәр киң ара калдырып ирләр үзара кысыла төштеләр һәм, чак-чак кына башларын борып, уң кул тучи бәк тәгин угланның кергәнен көтә башладылар. Менә ишек ачылып китте, анда җитез атлап, башын югары тотып яшь угланның килеп кергәне күренде. Кыяфәтенә караганда ул бер дә авыру кешегә охшамаган иде. Тук-Сыртлан карачы аны җитәкләп диярлек ак киез янына алып килде. Албуга, ике аягы белән дә ак киез өстендәге үгез тиресенә басты да, башта каганга, аннары ашыкмыйча гына бүтәннәргә карап чыкты һәм бернинди каушау, уңайсызлану сиздермәгән бер тынычлык белән, үзен нык, горур тотып:

— Бөек каган! — диде.— Мин ишетеп тордым: Бүзбала карачы мине кичәгенәк авырып килми калган дип белдерде. Мин авырып калмадым. Мин — тап-таза! Мин, күренмеш буласын онытып, Тарлавыкка китеп барганмын. Ярты юлда исемә төште дә, ашыгып кире борылдым. Тик менә кайтып кына җитә алмадым. Мин үземнең хатамны таныйм. Бөтен ил-көн, агай-эне алдында мин сиңа буйсыну белдереп бил бөгәм, бөек атам!

Мондый сүзләр ишетеп Бүзбаланың йөзе үзгәреп китте. Каганның да, өлкән бичәнең дә йөзләренә гаҗәпләнү һәм чак-чак кына каушау билгесе чыкты. Башкалар да, ни уйларга да белмичә, аптырабрак калдылар. Кайберәүләр мондый нәрсәгә күрәләтә сөенеч белдерделәр, күпчелек исә: «Авырып калса ни дә, авырмый калса ни — барыбер түгелмени?!» — дип уйладылар. Бүзбала авырды дип әйткән икән, шуннан да яхшы сылтауның кирәге дә юк лабаса инде! Ата белән ул үзара килешсә, татулашса, шул җитмәгәнмени?

Кайберәүләр яшь угланның төзәтмәсенә икенче төрлерәк карарга тырыштылар. «Яшь булса да, күз буяганны яратмый» диделәр алар үзара. Шулай ук куркаклардан да түгел — кара, нинди туры, кыю карый атасының күзләренә!

— Мин синең буйсынуыңа ышандым, улым! — диде каган, уңайсыз тынлыкны бозып. Шуннан соң ул шактый кырыс итеп Бүзбалага эндәште: — Син, Бүзбала карачы, моннан соң да миңа ялган сөйләсәң, телеңнән дә, башыңнан да колак кагарсың! — диде.

Бүзбала куркуыннан ап-ак булды.

— Миңа әйттеләр! Килеп әйттеләр, бөек каган! — диде ул калтыранып.

Уң кул тучи бәк тәгин углан үзенә тиешле урынга килеп утырды. Туман каган тагын бер мәртәбә олы киңәшнең башлануын белдерде дә, үз ыруындагы, урдадагы хәлләр турында сөйләргә керешге.

Җир-су, көтү-көтүлек турындагы, ыруларның үзара ыгы-зыгысы турындагы сүзләр гадәттәгечә бик кискен һәм шау-шулы булды. Даладагы талашлар, ызгышлар яңарып, көчәеп, монда да кабатланды. Берәүләр җирнең, суның азлыгына, уңайсызлыгына үпкә белдерделәр, икенче берәүләр күршеләреннән зарланды. Ил башы каган берәүләрне килештерде, икенче берәүләрнең кайбер ирекләрен тартып алды, аеруча усалрак, килешмәүчәнрәк күршеләрнең эшләрен исә яргучылар [1] карамагына калдырды.

Олы киңәш көне буе барды. Бик күпләрнең монда язмышы хәл ителде. Шунлыктан кызыксыну, киеренкелек әз генә дә йомшап тормады. Ләкин бөтен ил кайгысын бер көнне генә хәл итеп бетереплек түгел иде. Күп кенә сораулар, мәсьәләләр башка көннәргә калдырылды һәм Туман каган бүгенгә олы җыенның төкәнүен белдерде. Иртәннән бирле берни ашамаган, көне буена аяк өсте басып торган агай-энеләр җиңел сулап куйдылар һәм ашыгып ишеккә таба агыла башладылар.

Бу вакытта инде кояш җир астына төшеп йокыга талган, кышкы дала өстенә салкын караңгылык җәелә башлаган иде. Бу көннәрдә күктән күзен алмыйча, айның, кояшның, йолдызларның үзгәрешен, хәрәкәтен күзәтеп кенә торган Баргынтай баба, күк гөмбәзендә яшь айның очлы мөгезе күренү белән, Туман каганга хәбәрче җибәрде. Ил башы, иртәнге кояшны котлаган кебек, кичке айны да котлап каршы алырга, келәү әйтергә тиеш иде.

Күк өйнең көнчыгыш ишегеннән кунаклар, көнбатыш ишегеннән каган чыкты. Туң җир өстенә җәелгән киезгә тезләнеп ул яшь айга үзенең изге теләкләрен юллады. Шуннан соң ул Күк өйдән бер ике йөз адым чамасы читтәрәк урнашкан Ак өйгә таба атлады.

Олы киңәштән соң Ак өйдә олы аш-су башланды. Аш-суга каганның барлык бичәләре, балалары, туган-тумачалары һәм шулай ук ил читеннән килгән барлык бәкләр чакырылды. Үзенең меңләгән кунакларын каган иң яхшы ашамлыклар, эчемлекләр белән сыйлады.

Исәнтәй олы туйга дип Таштугайдан үзенең көйче, җырчы кызларын чакырткан иде. Кунаклар ашап туктаган арада Исәнтәйнең курчак кебек итеп төзәндергән, бизәндергән, битләренә кершән яккан, кара чәчләре күпереп торган чибәр кызлары ят җырлар җырладылар, төрле уен коралларында уйнадылар. Кызлардан соң тәхет каршысындагы ачык урынга җиде-сигез яшь ир чыкты. Болар Исәнтәйнең кәмитчеләре иде. Ирләрнең дүртесе дүрт почмакка утырды. Бик каты шаулатып ике ир шул чакны озын чүлмәк сыман барабан төбен дөпелдәтергә тотынды, икенче берсе алдына каплап куелган агач табак төбенә куллары белән алмаш-тилмәш бәрә башлады. Шул ук вакытта берни аңлатмый торган җансыз кыяфәттәге бер ир кеше таяк башына эленгән җиз кыңгырауларны чыңлатып-чыңлатып алды. Алар шулай төрле тавышлар белән шау-шу куптарганда ярым шәрә өч яшь ир бер яктан икенче якка тәгәрмәч булып тәгәрәделәр, бер-берсенең кулына, җилкәсенә басып, каядыр югары менеп киттеләр дә, маймул кебек янә аска сикереп төш-

---

[1] Яргучы — хөкем эшен башкаручы, казый.

теләр, үзләре белән алып кергән озын бамбук таягына уралып, әллә ниләр кыландылар.

Туман каган ашаганда тәхет күрке булып, аның вак-төяк йомышларын башкарып торучы гүзәл Сөенеч үз янындагы икенче бер кол кызга елмаеп нидер әйтеп куйды. Икенче кол кыз, Сөенечнең сүзләрен сөн теленә әйләндереп, каганга пышылдады. Туман каган, аңлаганлыгын белдереп, ым какты һәм, чак-чак кына башын борып Сөенеч ягына карап алды. Шуннан соң ул җырчы кызлар белән кәмитче ирләрне яхшылап сыйларга кушты. Тәхет тирәсендәге бу ымлашуны якын-тирәдәге ирләр, хатыннар барысы да күреп, күзәтеп утырдылар. Тәгин углан, бу якка карамаска тырышса да, караңгы төндә балкып янган утка карамыйча булдыра алмаган кебек, әледән-әле Сөенеч ягына күз төшергәләми булдыра алмады. Ул бары атасының күз карашы белән очрашмаска гына тырышты.

Исәнтәй кәмитчеләре уйнап туктау белән, уртага анадан тума сөн яшьләре чыкты. Алар кылыч белән сугыш биюе биеделәр. Бары дини йола бәйрәмнәрендә генә күрсәтелә торган бу куркыныч биюне кунаклар тын да алмый күзәтеп утырды. Уртада дөрләп янган ут яктысында ялт-йолт килгән кылычларын әле югары күтәреп, әле бер-берсенә каршы чәкәштереп һәм туктаусыз дөпелдәгән барабан тавышларына буйсынып, җитез ирләр төгәл, кискен хәрәкәтләр ясадылар. Шул ук вакытта алар, бию хәрәкәтләренә туры китереп, кычкырып-кычкырып җибәрделәр.

Кызу, дәртле бию, ничек кисәк кенә башланып киткән булса, шулай ук кисәк кенә туктап калды. Барабаннар тынды, күз алдында ялт-йолт килгән кылычлар күренмәс булды, һәм яшь, таза, матур тәнле ирләр, көчле җил аударган камыш кебек, барысы бергә идәнгә егылдылар. Кунаклар, дәррәү кубып, биюче яшьләрне алкышларга тотындылар.

Алар шулай шаулашкан-гөрләшкән арада биючеләр тын алып, хәл җыеп яттылар да, туп кебек атылып яңадан тордылар. Шул чакны өйнең уртасында — тирә-ягын таш белән әйләндереп алган түгәрәк кучкарда гөлт итеп, бик зур булып ут кабынып китте. Моңарчы өстенә киез каплап куелган коры тал-камыш өеменнән өскә төтен белән аралашып ялкын күтәрелде. Ут-ялкын зураеп, бөтен өй эче көндезгедәй яктырып калгач, кинәт тагын барабаннар дөпелдәргә тотынды. Биюче шәрә яшьләр «алас! алас!» дип кычкыра-кычкыра, күз иярмәс тизлек белән ут аша сикерергә кереште.

XVI

Туман каган күп эчсә исерә, исерсә холыксызлана башлый иде. Бу юлы да шулай булды. Җыр-биюләрне ул тыныч кына карап, күзәтеп утырды. Исәнтәйнең кызлары җырлаганда, биегәндә ул әле шактый аек иде. Кәмитчеләр уйнаганда аның инде күз аллары әлҗе-мәлҗе килә башлады. Ул әледән-әле үзенең тучи бәк тәгин углы ягына карап алды. Ул аның да үзенә каравын, аннан да бигрәк, чин кызына күз салгалавын күрми калмады. Бер-ике мәртәбә ул чин кызының да яшь углан ягына карап елмаюын күреп алды. Аның моңа ачуы килде. Ләкин ул моңа берничек тә аркылы төшә алмады — бер-берсенә карашкан өчен генә ул үзенең углын да, кырнагын да берничек җәзалый алмады. Үзалдына үртәлеп ул бары буза гына эчте.

Исереп чыгырдан чыга башлаганда аның күзенә дунху бәге Начин нойон чалынып калды. Начин нойонның ул Сары-су буена соңлап килүен исенә төшерде. Кичәгенәк аңа Начин нойонның тагын бер этлеге турында җиткергәннәр иде. Дунху бәге һәр елны түләнелә торган каланын — җиде мең үгез тиресе алып килгән булган. Ләкин ул җиде

мең тиренең йөзгә якыны бозык булып чыккан. Кичәгенәк Туман каган шуның өчен генә аңа бәйләнеп тормаска булган иде — андый йөзгә якын тиреләрне кайчагында теркәүчеләр үзләре дә юри бозык итеп күрсәтергә тырышалар. Хәзер ул менә шуны исенә төшерде һәм күңелендә җыелып килгән бар ачуы аның берьюлы тышка бәреп чыкты.

Шәрә яшьләр ут аш сикереп туктагач та ул, бөтен өй эченә кычкырып, дунху бәген үз янына чакырды. Начин нойон утыз яшьләр чамасындагы озын буйлы, таза бер ир кеше иде. Үзенең җәенке табак бите белән, кара сызык кына булып күренгән кысык күзләре белән ул башкалар арасында бик нык аерылып тора. Ашыгып, елмаеп, шулай да эчке бер сагаю белән ул тәхет каршысына килеп тезләнде.

— Көпчәк булып тәгәрә! — диде каган аңа.

Начин нойон агарынып китте.

— Эчем авырта, бөек каган! — диде ул, эчен тотып урталай бөгелә-бөгелә.

Өй эчендәге күп санлы кунаклар куркып, аптырап тәхет ягына карадылар.

— Кабатлап әйт — ишетмәдем! — дип кычкырды каган, урыныннан торып.

— Эчем авырта, бөек каган! — диде дунху бәге кызганыч йөз белән.

— Башын чабарга! — дип кычкырды каган ярсып.

Шулай итеп, туйның яме юкка чыкты. Начин нойонны ике яктан ике ир тотып алды. Кычкыртып аны ишеккә таба өстерәделәр.

Каганның исерек чакта бирелгән боерыклары кайчагында җиренә җиткерелми кала иде. Чөнки бу хакта аның «исерек чакта әйтелгән боерыкларны чынга алмаска» дигән сүзләре бар иде. Шуны истә тотып, дунху бәгенең башын чапмадылар.

Икенче көнне, каган йокыдан торгач, аңа кичәге хәлне исенә төшерделәр. Начин нойон турында ишетү белән ул барысын да яңадан күз алдына китерде. Хәзер аның дунху бәгеннән бигрәк, үзенең өлкән углы, чин кырнагы һәм шуларга бәйле уңайсыз бер киеренкелек эчен пошырды. Кызны үзенә тартып алса да, нишләптер ул аны тулысынча үзенеке итеп хис итә алмады. Никтер ул чая, чибәр, шома кыз гел яшь, сылу углан турында гына уйлыйдыр шикелле тоелды. Начин нойонны ул кичерергә булды.

Дунху бәген, кулларын-аякларын бәйләп, тирән базга ташлаганнар иде. Каганның кичерү турындагы боерыгын җиренә җиткерү өчен тоткын янына, Бүзбала үзе китте. Төне буе күзенә йокы кермәгән, кайгыдан ярым үлек хәлгә килгән бәк янына бау-баскыч суздылар. Базга бер ир төшеп, Начин нойонның кулларын, аякларын чиште, аңа баскычтан менәргә булышты. Җир өстенә тартып чыгаргач дунху бәгенә аныңаклануын әйттеләр, өенә кайтып ял итәргә куштылар. Үзенең эчке тойгыларын яшерергә күнекмәгән беркатлы Начин нойон, үлемнән котылуын белгәч, сөенеченнән елап җибәрде. Чәчен-башын тырнап, кычкырып-кычкырып елады-елады да, кинәт тиле сыман күләргә тотынды. Куанычын болай гына белдерә алмагач, җиргә ятып тәгәрәргә керешге, аннары тезләнеп, көнчыгыштан күренеп килгән кояшка:

— Тәңрем! Коткаручым! — дип кычкырды.— Үз аймагыма кайтып җитә алсам, биш яшьлек улымны сиңа корбан итеп бирәм!

Шуннан соң ул карачы Бүзбалага борылды.

— Сиңа, Бүзбала, сөенечкә йөз баш ат, йөз баш сыер миннән. Бөек атам каганга җиткер: мин китергән каланны яртылаш кына дип белсен. Быел мин аңа яңадан дүрт мең үгез тиресе алып киләм!

— Әйтермен, Начин нойон,— диде Бүзбала.

Дунху бәгенә карачының йөзе нишләптер бик кырыс күренде. «Йөз баш ат белән йөз баш сыерны азсынды!» — дип уйлады ул аның турын-

да. Һәм ул бер кызудан өстендәге тупас җирән тукыма белән тышланган тиен тунын салды да, Бүзбаланың кулына тоттырды.

— Ишеттеңме мин әйткәнне, Бүзбала? — дип кычкырды ул аның колагына.— Мә, тунны да ал. Сиңа бүләк.

Бүзбала канәгатьләнү белдереп елмайды, тиен эчле йомшак тунны иңбашына салды да, дунху бәген юатып, аның аркасыннан сыйпап куйды.

— Бар инде, бар, кайтып ял ит,— диде.

Бер кат эчке тун белән генә калган Начин нойон, чатнап торган кышкы салкында алпан-тилпән атлап, елый-елый, көлә-көлә үз авылына юнәлде. Юлда аңа үз кешеләре — ике яшь бичәсе, балалары, ыруғдашлары очрады. Алар аны каршы алырга киләләр иде. Аның коткарылуы турында алар кай арададыр ишетеп тә өлгергәннәр инде. Өсләреннән салып аңа үз туннарын кидерделәр, үзләре белән алып килгән буш атка атландырдылар һәм шулай кадерләп, елашып үз өйләренә алып кайтып киттеләр.

Өенә кайткач Начин нойон ашады-эчте дә, тәмам тынычланып, онытылып каты йокыга талды. Ул көне буе йоклады һәм бары тик караңгы төшкәндә генә уянды. Бүген көндез далада ат, дөя чабышлары булырга тиеш иде. Шул турыда уйлагач аның тагын чәчләре үрә торды. Ат, дөя чабышларында барлык бәкләр катнашырга тиешләр. Аның килми калуын каган тагын буйсынмау дип уйламас микән?

— Мине алырга берәрсе килмәдеме? — диде ул өйдәгеләргә.

— Килде,— диделәр аңа.— Синең уянганыңны көтеп тора.

Начин нойон аңлап җитмәде, аны кинәт тыелгысыз бер калтырау биләп алды.

— Керсенме?— диделәр аңа.

— Кем?! — дип кычкырды бәк, урыныннан сикереп торып.

— Килгән кеше.

— Керсен! — дип кычкырды Начин нойон һәм шундук кынысыннан хәнҗәрен тартып чыгарды.

«Иң элек аны чәнчелдерәм, аннан соң үзем үләм!» дип уйлады ул өметсез бер ярсу белән. Ләкин ул көткән куркыныч кеше урынына өйгә балкып-елмаеп Исәнтәй килеп керде.

— Олуг нойон, тәңре сиңа күп көч, байлык бирсен! — диде Исәнтәй, бишкә бөгелеп.

Дунху бәге хәнҗәрен кире кыныга тыгып куйды. Җайлап кына түрдәге йомшак урынга утырды. Өйдәге кешеләренә ул кымыз китерергә кушты. Зур агач күбәтәгә салынган кымызны ул башта үзе авыз итте, аннары кунагына бирде. Уртак савыттан кымыз эчкәч, ике арада үзеннән-үзе туганлык, якынлык барлыкка килде.

— Син — нойон, тире тун кия,— диде Исәнтәй.— Мин ефәк бар. Сата.

Ул, сөнчә бик яхшы белсә дә, үзенең кем икәнлеген сиздерү өчен кайчагында шулай юри телне бозып сөйләшә иде. Сөннәрне яратмаган һәм үзе дә сөн телендә бик үк яхшы сөйләшмәгән дунху бәгенә бу, аның исәбенчә, бик тә ошарга тиеш иде.

— Нинди төс? Күпме? — диде Начин нойон.

— Ал төс. Каган төс. Ун төргәк. Сиңа сата,— диде Исәнтәй.— Сөн бәк бай киен, дунху бәк яман киен. Каган сине мыскыл. Каган — яман! Сөн — яман!

— Те! Әйе! — диде Начин нойон, күз алдында үзгәреп.

Йодрыкларын йомарлап ул тезләренә таянды, күкрәген киерә төште. Шулай да әлегә ул Исәнтәйгә ияреп каганны, сөннәрне яманлаудан тыелып калды — кичәге куркуы бөтенләй үк чыгып бетмәгән иде.

— Ал ефәк кирәк? — диде Исәнтәй кабатлап.

— Ал төс — каган төсе. Ал тун киеп мин кая барырмын, кемгә күренермен? — диде Начин нойон.

— Алайса, сары, яшел... — диде Исәнтәй.

— Китер! — диде бәк икеләнүен җиңеп.— Минем дә сөн бәкләре кебек ефәк тышлы тун киясем килә.

— Ун төргәк — ун тире,— диде Исәнтәй бәясен белдереп.— Кыйбат имәс.

— Кыйбат түгел! — диде беркатлы Начин нойон, бик тиз килешеп.— Нишләп син минем аймакка килеп чыкмыйсың? Миңа буза кирәк, дөге, корал кирәк. Чибәр кызлар кирәк! Бармы синдә кызлар?

— Кызлар юк,— диде Исәнтәй.

— Сөн бәкләренә син барысын да табасың,— диде Начин нойон үпкә белдереп.— Миңа беркем килми, берни китерми. Мин урманнар, таулар арасында, ат-сыер арасында яшим. Үнда да — сөннәр, сулда да — сөннәр. Миңа чибәр чин кызлары кирәк. Каганның Сөенече кебек! Әйе, те!

Исәнтәй, хуҗаның тынычланганын көтеп, беравык эндәшмичә утырды. Шуннан соң ул яшь, таза нойонга табарак елышты да:

— Нойон теләсә, барысы да була! — диде.

— Ничек?! Кайчан?!

— Начин нойон теләә чибәр кыз, ефәк, алтын, корал, яшма таш — барысы да күп-күп була!

— Күпме кирәк — бирәм, ни телисең — бирәм! — диде аңа дунху бәге ашыгып.

— Миңа кирәк имәс,— диде Исәнтәй серле пышылдап.— Барысын да сиңа... Чин ваны бирәчәк. Буш. Бүләк.

— Чин ваны? — диде Начин нойон ышанып җитмичә.— Миңа? Ник? Ул бик юмартмыни?

— Юмарт. Үзенә буйсын кешедән ул кызганма.

— Берни аңламыйм,— диде Начин нойон, кысык күзләрен челтчелт йомгалап.— Мин каганга буйсынам. Чин миңа ерак. Чин таулар, далалар артында.

— Начин нойон Чин белән якынай кирәк,— диде Банхуа-Исәнтәй иплэп кенә... — Каган сине тала. Сөн явыз, комсыз. Син дунху, шуна килешә.

— Килешмим! — диде Начин нойон, күзләреннән усал очкыннар чәчрәтеп.— Мин аларның бугазын чәйнәп өзәр идем! Тик... дунху көчсез, таркау.

— Тыңла! — диде Исәнтәй, хуҗага тагын да якынрак килеп.— Сөннәрне чәйнәргә сиңа Чин булыша. Үз аймагыңа кайта, теге якка кача, таулар артына.

— Анда минем җирем юк, көтүлегем юк,— диде Начин нойон.— Андагылар мине кырып бетерәчәкләр.

— Тыңла! — диде Исәнтәй тагын да.— Син алардан курка имәс. Син — дунху, алар — дунху. Туган. Син аларны котырта, үз кулыңа ала. Каган Чингә яу киткәч, күп-күп дунху сөнне кыйна! Арттан. Чин кыса, Дунху кыса, Сөн — үлә!

— Те! — диде Начин нойон килешүен белдереп, дулкынланып.— Сөн дә үлә, каган да үлә! Далада дунху кала! Начин нойон кала!

Ярсып ул кинәт урыныннан сикереп торды, тешләрен шыгырдатып, әрле-бирле таптангандай итте, зур агач күбәтәгә кымыз тутырып эчте дә пошкырып куйды һәм кинәт кенә тынып калды.

— Кызыңны китер, ефәгеңне китер. Бушлай бир. Шунсыз ышанмыйм,— диде ул сүрелә төшеп.

Исәнтәй чыгып китте дә икенче бер чин ирен ияртеп керде. Әлеге ир яхшылап төрелгән төрле төстәге ефәк тукымалар күтәргән иде. Күз-

101

нең явын алып торган ал, яшел, сары төстәге ефәк тукымаларны Исәнтәй дунху бәге алдына таратып ташлады.

— Барысын да алам! Алын да, яшелен дә, сарысын да! — диде бәк комсызланып.

— Ал,— диде Исәнтәй.— Кызны иртәгә китерерләр.

— Бүген кирәк! — диде түземсез нойон.

— Иртәгә. Бүген соң,— диде Исәнтәй нык итеп.

— Те! — диде Начин нойон килешеп.— Мин аларны! У-у, мин ул сөннәрне, каганнарны!

XVII

Исәнтәй китеп бераз торгач Начин нойон киенеп өйдән чыкты. Тышта бик салкын иде. Җир өстендәге бөтен нәрсә суыктан чатнап, шыгырдап тора. Әле ныклап кар яумаганга җирнең өсте кап-кара. Нойон унлап сакчы ир алды да, урда ягына карап китте. Читтән генә ул сөннәрнең төнге торгакларын, аерым күзәтчеләрен карап китте. Даланы яхшы белгәнгә ул беркемгә күренмичә барды. Үзенең ни өчен болай каранып, андышып йөрүен ул үзе дә бик үк төшенеп җитмәде бугай. Үз гомерендә беренче мәртәбә ахрысы, ул сөннәрне иң явыз дошманнары итеп тойды һәм, дошман булгач, искәрмәстән басып алу өчен ул аларның кайда ничек урнашуларын белергә тиеш иде бугай. Ләкин ул әлегә мондый нәрсәне — каган урдасын басып алуны башына да китереп карый алмады, ул моның шулай тиешлеген сизенде генә бугай.

Төнге далада иснәнеп, каранып йөри торгач ул шулай да билгеле бер карарга килә алды — тиз генә үз авылына борылды. Исәнтәй җибәргән кызларны көтеп тормаска булды. Аның йөрәге түзмәде, аның үч аласы, талыйсы, җимерәсе һәм, әлбәттә, иксез-чиксез көчкә, байлыкка ия буласы килде. Үз кешеләренә ул, берни сиздермичә, тиз арада күченеп китәргә боерды.

Дунхуларның качып китүләрен сөннәр бары икенче көнне таң аткач кына беләделәр. Баштарак аларның юклыгына беркем игътибар итмәде. Начин нойонның авылы божра эчендә булмаганлыктан, төнге торгаклар аны сакламыйлар иде. Шулай да моңарчы өйләр, арбалар булган урында буш җир күреп, сөн ирләре бөтенесен аңлап алдылар. Дунхуларның качып китүе турында шундук каганга хәбәр ителде.

Туман каганның бик нык ачуы килде. Кара син аны! Изге бәйрәм көнендә, абаларга, каганга, түрәләргә-йолага төкереп, сөннәрне хур итеп качып киткән! Баш күтәргән дунху!

Тиз арада ул каравыл агасы Туңгак алыпны, бүген төнлә кизү торган меңбашларын, йөзбашларын чакыртып алды. Ул аларны шелтәләп тә, куркытып та тормады.

— Тереме, үлеме — табып алып кайт,— диде ул Туңгак алыпка әкрен генә, дәһшәтле итеп.

Туңгак алып, мең кешелек алай алып, качакларны тотарга үзе китте.

Туман каган бер кызудан Котлуг бәкне дә чакыртып алды. Котлуг бәкнең биләмәләре Начин нойон биләмәләренә якын гына иде. Начин нойонда Котлуг бәкнең кол хатыныннан туган кызы кияүдә иде, шунлыктан дунху бәге Котлуг бәкнең кияве исәпләнелә. Начин нойон, бер яктан Туман каганга буйсынса, икенче яктан Котлуг бәккә буйсына. Куяннар дунхулар белән дус-тату яшиләр һәм кайчагында Котлуг бәк үзенең киявен каган алдында яклап та калгалый иде. Әле генә Начин нойонның кулын-аягын бәйләп базга ташлагач та шулай булды — Туман каган барыннан да элек Котлуг бәк сүзенә колак салды. Ләкин

Начин нойон Котлуг бәккә кияү туры килсә, Туман каганга баҗа туры килә иде!

— Синең киявең... син яраткан дунху колым минем йөзгә төкерде, бабай! — диде каган Котлуг бәккә.— Сөн йолаларын, сөннәрнең изге ата-бабаларын санламаска, каганга каршы баш күтәрергә син өйрәтмәдең микән аны, Котлуг бәк?

— Нишләп мин аны сиңа каршы котыртырмын икән соң? Син дә минем киявем лабаса! — диде Котлуг бәк каган сүзләренә бик нык хәтере калып.

— Кияү белән кияүнең аермасы бар, бабай... Котлуг бәк!

— Сүзең хак, — диде Котлуг бәк әлеп алып.— Каган киявемне кол кияүгә алыштырырга минем башыма тай типмәгән!

Дунху бәгенең качып китүе Туман каганның моңарчы ихтыярын буып торган нindidер богауны өзеп ташлагандай булды. Анда бары ау вакытында гына, дошман белән күзгә-күз килеп сугышкан вакытта гына була торган ныклык һәм омтылыш, гайрәт һәм ярсу кабынды. Төрле яктан чолгап алган яман көчләрдән, күзгә күренмәгән һәм күренгән дошманнардан үзен-үзе саклау өчен, үзенең бүгенгесен, киләчәген, мәңгелеген яклау өчен ул аларны — үзенә каршы килүчеләрне анасы Корткa-бикә әйткәч тә инде тар-мар итеп ташларга тиеш иде. Ләкин моның өчен әлегә тиешле сәбәбе, җитәрлек сылтавы булмады. Хәзер менә ул сылтау табылды. Мондый сылтауны кулдан ычкындырырга ярамый иде.

Туңгак алып качакларны кичкырын бер тау итәгендә куып җитте. Дунхулар, артык каршылык күрсәтмичә, ничек тә таулар арасына кереп яшеренергә тырыштылар. Сөннәр аларның күп кенә кораллы ирләрен үтерделәр, атларын-арбаларын кулга төшерделәр. Начин нойонны эләктереп булмады — ул качып котылды. Ул арада караңгы төште. Туңгак алып, көчен таркатмас өчен, эзәрлекләүне туктатырга мәҗбүр булды.

Шулай итеп ычкынды Начин нойон! Таулар, урманнар арасында, караңгыда аны инде Туңгак алып түгел, әллә кем эзләсә дә таба да, тота да алмас иде. Аны ныклап торып эзәрлекләү өчен, тоту өчен күп көч белән таулар аръягына — санап бетергесез дунху аймаклары яши торган җирләргә басып керергә кирәк булачак иде. Ләкин анда күп көч белән басып керү өчен киң үзәннәр дә, тапталган киң юллар да юк. Ике арада биек койма булып таулар, кыялар калкып утырган өчен дә теге яктагы дунхулар, беркемгә буйсынмыйча, үз ирекләрендә яшиләр иде.

Шуларның барысын да уйлап, Туңгак алып урдага кире борылды.

Туңгак алып каганның боерыгын беренче мәртәбә үти алмады. Каган аны караңгы чырай белән тыңлап торды.

— Дунхуларны буйсындыру өчен кимендә илле меңлек көч кирәк, бөек каган,— диде Туңгак алып.— Илле мең көч белән мин аларны бер кышта тез чүктерәм!

— Мин уйлап карармын,— диде каган теләр-теләмәс кенә.— Бар, өеңә кайт. Уйлашырбыз.

Туңгак алып тынычланып ишеккә юнәлде. Бүзбала белән Салчак алып аны ефәк чыбылдык артында сак кына көтеп тордылар. Ул башын иеп, ишек киезен күтәреп азапланганда, икесе ике яктан чыгып алар аның арттан кулларын эләктереп каердылар, тезләрен аркасына терәп идәнгә егып салдылар. Ауга барганда тәгин угланны үз урынына бастырып, барлык алыплар алдында хурга калдырганы өчен Салчак алып каравыл агасына күптән инде теш кайрап йөри иде. Шуңа күрә дә ул эшен бик тырышып башкарды. Бүзбала да чын күңелдән тырышты. Олы киңәш алдыннан каган бик каты янагач, аңа да үзенең турылыклылыгын күрсәтергә кирәк иде. Әле генә үзләре белән бер табактан

ашаган, үзләренең якын дуслары, сердәшләре булган кешене алар берниндн кызганусыз, ерткычларча тукмадылар. Аның көчлелеген, чыдамлыгын, усаллыгын бик яхшы белеп эш ителде — алай-болай ычкынып китә калса, ихтимал, ул аларны изеп ташлаган булыр иде. Ләкин Туңгак алып берничек тә ычкына алмады. Кулларын, аякларын богаулап аны кичә генә Начин нойон яткан тирән базга ташладылар.

XVIII

Биек Ак өйдәге яңалыклар тиз арада бөтен урдага таралды. Изге бәйрәм көннәрендә бу көтелмәгән күңелсезлекләр бик күпләрне борчуга салды. Күпчелек моны яманга юрады. Берәүләр моннан фәлән ел элек тә шундыйрак ызгыш-гаулар булуын, аларның ничегрәк тәмамлануын исләренә төшерделәр. Икенче берәүләр кайчандыр булып узган ай, кояш тотылуларны, койрыклы йолдыз атылуларны, шуннан соң ук корылык, яу-кыран килүләрне хәтерләде. Иртәгәсен көчле җил-давыл чыгуын көткән сыман, бөтен урда төнне тынгысыз бер сагаю, шомлану белән уздырды.

Яңа айның җидесендә — изге бәйрәмнең соңгы көнендә Туман каган Күк өйгә яңадан үзенең барлык туган-тумачасын, бәкләрне, агаларны җыйды. Аш-суга түгел, олы киңәшкә җыйды. Шунда ул бөтен ил-көн алдында үзенең сүзен әйтте.

Йолага, түрәгә туры китереп мин — Сөн иленең башы Туман каган — өлкән бичәм Күрекле бикәдән туган уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга углымны башкаландырырга булдым,— диде ул бөтен өйгә ишетелерлек көчле тавыш белән кычкырып. — Алдан килешү буенча, тәгин углым Албуга Аланнарның Күкәл буыны Елдырым бәкнең Алтын-Бөртек кызына өйләнер. Айак эчелгән, калымның яртысы түләнгән.

Көтелгән яңалыкның иң зурысы иде бу. Ата белән угыл арасында килеп чыккан каршылыкның ни белән бетәсен түземсезләнеп көтеп торган агай-эне каганның мондый карарын ишетеп җиңел сулап куйдылар. Ярый әле, эш алай ук зурга китмәгән икән!

Туман каган дәвам итте.

— Туену өчен уң кул тучи бәк тәгин углыма мең өйлек өлеш чыгарам, миңа каршы баш күтәргән дунху Начин бәкнең Байык суы буендагы җирләрен тәгин углыма бирәм. Начин бәкнең Байык буенда торып калган илен-көнен туену өчен бирелгән мең өй исәбенә кертәм.

Моны әйткәч ул тынып калды һәм өй эчендәгеләргә күз йөртеп чыкты. Байык су буйлары алай начар җирләр түгел иде, шулай да уң кул тучи бәк тәгин углан өчен мең өйлек өлеш... бик-бик аз иде. Сөн илендә бу иң ярлы бәктән дә ярлырак булу дигән сүз!

— Миңа буйсынган дунху бәгенең сөн йолаларына, изге ата-бабаларга төкереп китүе, башбаштаклык күрсәтүе минем күңелемә кара кайгы булып төште,— диде Туман каган яңадан сүз башлап.— Дунху бәге белән Котлуг бәкнең якын туган-тумача булуын истә тотып, Начин бәкне Котлуг бәк котырткандыр дип уйлап, мин Куян ыруы башы Котлуг бәккә үпкәмне белдерәм. Картлыгын, алыплыгын истә тотып, Котлуг бәкне кичерәм. Котлуг бәкнең кызы... өлкән бичәм Күрекле бикәгә, үз артыннан килгән бар байлыгын алып, өлкән углы Албуга белән бергә Байык суы буена күченеп китәргә боерам. Күрекле бикә үлгәнче үз байлыгына — үзе, Албуга — үз байлыгына үзе хуҗа булачак. Күктәге йолдызларның торышын, җилнең, болытларның юнәлешен тикшереп торучы күрәзәчеләрем миңа шуны әйттеләр: өлкән бичәм Күрекле бикә белән углы Албуга минем янда, Ак урда янәшәсендә булганда, Тәңре миңа, ыруыма, илемә-көнемә талау-кыран китерә. Дунху бәге Начинның башбаштаклыгын, таулар аръягына качып китүен күрәзәчеләр

шуннан күрәләр. Ил башы каганга, илгә-көнгә, мал-туарга моннан соң бернинди кыран-талау килмәсен дип мин уң кул тучи бәк тәгин углым Албуга, әнисе Күрекле бикә бүлеп бирелгән биләмәләреннән беркая чыкмасыннар, мин үзем чакыртмыйча торып, Ак урдага аяк басмасыннар дип боердым!

Каган әйтәсе сүзен әйтеп бетерде дә, өстеннән тау-таш ишелеп төшкән сыман, шулай да үзен чиктән тыш киеренке тоткан хәлдә, кырыс ирләргә янә күз йөртеп чыкты. Җил кискән тупас, ачулы йөзләрдә шулай ук соңгы чиккә җиткән киеренкелек һәм сагаю күренде. Шул ук вакытта аларның бу киеренкелегендә бушану, иркенләп тын алу билгесе дә юк түгел иде.

Шулай итеп, барысы да аңлашылды. Димәк, каган үзенең өлкән бичәсен дә, өлкән углын да читкә сөрә. Кем аркасында? Билгеле, гүзәл чин кырнагы аркасында! Шулай да акылсыз бу каган. Сөн илендә аңа әллә кызлар беткәнме?!

Әрнеп-ачынып агай-эне шулай уйлады. Арада ниндидер хатын-кызның мышык-мышык борын тартканы ишетелеп китте. Моңарчы тынлык саклап түзеп торган ирләр ирексездән кузгалып куйдылар, ирексездән гөрелдәргә тотындылар. Таулар арасындагы киң үзәнне хәтерләткән биек иркен Күк өй эчендә менә-менә давыл чыгар төсле тоелды.

Ләкин Туман каган үз өендә давыл чыгуга юл куя алмады. Исәнтәй белән алдан барысын да исәпләп куйганга, ул олы җыенны бик оста алып барды. Аннан да, моннан да өзек-өзек тавышлар ишетелеп, өзек-өзек тавышлар гаугага, тавышка күчәргә генә торганда ул, очарга җыенган кош сыман, йодрыкланган ике кулын да югары күтәреп, кискен бер омтылыш ясады да, бар көченә кычкырып:

— Тыңлагыз! — диде.

Агай-эне, ил-көн тынып калды.

— Боерам: миңа буйсынган барлык бәкләр, ыру башлары, тугызынчы айның егерме җиденче көненнән дә соңга калмыйча, коралланып, өчәр ат белән, азык белән кичү янына җыелалар. Соңга калганнарның башы чаптырылачак, баш тартканнарның оялары таркатылачак, малтуары тартып алыначак, кешеләре коллыкка сатылачак. Чин ягыннан килгән качаклар көн дә хәбәр китерәләр: Җунгода — таркаулык, башбаштаклык. Бөтен көчем белән мин Чин җиренә басып керәчәкмен, мәңгелек дошманнарымны аяк астына салып, барлык җир-суга баш булып калачакмын. Тәңрем, изге атам-анам минем яклаучым, юлдашым булсын. Амин!

Әле генә ярсып кузгалырга, нәрсәдер кырырга-җимерергә әзер булган ирләр күз алдында икенче кешегә әйләнделәр. Куллар йомарланды, күкрәкләр киерелә төште, күзләрдә утлы очкыннар ялтырады. Алар барысы да — сугышчылар. Кереш тарта башлаганнан алып кына түгел, тумыштан ук алар сугышчылар, кыю ирләр. Җирдә кешечә яшәү өчен аларга — тумыштан ук сугышчы булган кыю ирләргә — әледән-әле үләргә һәм яңадан терелергә кирәк иде. Бу аларның канына, миенә сеңгән. Олы яуның байлык, бәхет, дәрәҗә генә булмыйча, кан-яшь, хурлык, коллык, үлем икәнлеген дә бик яхшы аңласалар да, югарыдан боерык булгач, уйланып, тикшереп торырга аларның хаклары юк. Алар бары җиңәргә яисә үләргә генә тиешләр иде.

Бөтен өй эче күз алдында үзгәреп китте. Уң кул тучи бәк Албуга онытылды, Күрекле бикә онытылды. Гүзәл чин кызлары, дунху бәкләре — барысы да кичерәеп, төссезләнеп калды. Һәркемне уртак кайгы — карлы таудай олы, җил-давылдай көчле һәм тормышның, яшәешнең үзе кебек үк серле-куркыныч яу кайгысы биләп алды.

Дүртенче баб

I

Алар белән беркем саубуллашмады, аларны беркем озата бармады. Кичә кичтән үк җыенып божра читенә күченеп чыктылар һәм төнне ачык далада, өсте ябулы арбаларда уздырдылар. Таң атар-атмас борын юлга чыктылар. Мең өйле, түмән өйле киез кала иртәнге томанда ят һәм шыксыз булып, артта торып калды.

Күрекле бикәнең йөрәген, бавырын ачу һәм хурлану тойгысы таллады. Үзен, тәгин углын, башка балаларын иләшкән оядан куалап җибәрүче ире каганга ачулана идеме ул, әллә быел шундый бирешкән, картайган, тешсезләнгән һәм кызын яклап бер сүз дә әйтә алмаган атасына ачулана идеме — моны ул ачык кына төшенә дә алмады.

Туганнарының да, көндәшләренең дә — беркемнең дә үзен юатмаячагын, юата алмаячагын ул болай да алдан ук белде. Аннары ул кемнең дә булса үзен юатуын да теләмәде. Шуңа күрә дә ул менә шулай кеше күрмәгәндә җыенды, кеше күрмәгәндә кузгалып та китте.

Котлуг бәк кызы Күрекле бикә, Туман каганның өлкән бичәсе, шулай итеп, урда өчен кинәт юкка чыкта. Үлде. Тере килеш үлде. Аңа беркем дә булыша алмады — атасы да, яраткан колы да. Ул инде беркемнеке дә — каганныкы да, колныкы да түгел. Каган өчен карт тоелса да, күңеле белән ул әле яшь иде, аның әле тиз генә кабергә керәп ятасы килми иде. Шунлыктан аның һич тә үзенең бу үлеменә ышанасы килмәде. Ләкин аның үлгәнлеген искәртеп, як-якка селкенә-селкенә, тирбәлә-тирбәлә, биек тәгәрмәчле авыр арба каядыр барды да барды.

Бикә утырган арба шактый киң һәм иркен иде. Арбаның өстенә бик зур кабыргалар төсле итеп карама кирәгәләр беркетелгән, кирәгәләр өстенә катлап-катлап киез ябылган иде. Алгы ягында гына ишек сыман ачыклыгы булган, җил-яңгыр үтми торган бу биек арбада җылы һәм рәхәт. Теләсәң, монда аякларыңны сузып җибәреп, йомшак мендәргә терәлеп, йоклап алырга да мөмкин, теләсәң — җәйлап утырган килеш, тәрәзә ярыгыннан тышка карап барырга була.

Ләкин урдадан куылган хатынның күзенә йокы да кермәде, күңелендә тәрәзәдән карап бару теләге дә тумады. Арбаның арткы почмагына сөялгән килеш, битен, ияген йомшак яка йонына көртлек сыман яшереп ул тын гына, оеп кына барды да барды. Аның уң ягында, аяк очында берни белми җиде яшьлек улы йоклады, сул ягында песи баласыдай бөгәрләнеп биш яшьлек кызы йоклады. Башка вакытта балаларының йокы аралаш тын алуларына, төшләнеп авызларын чәпелдәтүләренә, сулкылдап-сулкылдап куюларына сокланып туя алмаган ана бүген аларны, әйтерсең, күрмәде дә, тоймады да. Бер үк вакытта ул үзенең өстенә ишелеп төшкән зур кайгысы турында да, томанлы, күңелсез киләчәге турында да, онытып булмастай шикелле тоелган һәм артта кала барган Ак урда, Ак өй күренешләре турында да уйлады сыман. Шулай ук ул тышка, далага да колак салгандай итте.

— Барысы да беттемени, тәнрем?! — диде ул көрсенеп, үзалдына сөйләнеп.

Күктән аңа берниндн җавап килмәде. Якында гына туң җир өстеннән шакылдап, тәгәрәп барган көпчәк тавышлары ишетелде дә, дөп-дөп баскан, мөңгерәгән, пошкырган, чәрелдәгән терлек-туар авазлары колакка керде.

◆ НУРИХАН ФӘТТАХ ◆ СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

Шул чакны киез ишек-тәрәзәнең бер кырые күтәрелә төште, алда— сәкедә дилбегә тотып утырган Чобан, башын тыгып:

— Ни дисең, бикә? —диде.

Бикә аның сүзен аңлап җиткермәде — эндәшмичә, кымшанмыйча үз урынында утыра бирде.

— Син миңа нидер әйттең бугай, бикә? — диде Чобан кабатлап.

— Әйтмәдем,— диде бикә.

Шулай да тыштагы кеше белән эндәшеп-сөйләшеп алгач аңа ничектер җан кереп киткәндәй булды. «Юк, үләргә әле иртәрәк» дип уйлады ул үзалдына, юану эзләп. Атасы, ыруы, балалары исән, шулай булгач, нишләп әле шул кадәр бетеренергә? Ул әле монда — җирдә, кешеләр, терлекләр арасында. Ул бары күченеп кенә бара. Яшь, чибәр бичәләрен генә, гүзәл кырнакларын гына якын күрә торган каганнан үчен алачак әле ул бер заман! Аның углы — тучи бәк, тәгин углан. Ул — Тәңре углы! Аның хокукын тартып алырга беркемнең көченнән килмәячәк. Исән генә булсын аның олы колыны!

— Чобан, Чобан! — диде ул кинәт, йокыдан уянып киткән кеше сыман.

Чобан ишектән башын тыгып карады.

— Әллә тагын колагыма гына ишетелде инде,— диде ул мыгырданып.

— Колыным... Колынкаем күренәме?— диде бикә.

— Кайсысы?

— Икесе дә.

— Өлкәне күренә.

— Чакыр, күренеп китсен.

Бераз баргач арба янында Албуганың тавышы ишетелде:

— Әни, ни булды? Мин монда.

— Ул-бу юкмы, киләләрме? — диде бикә, тәрәзәдән башын тыгып.

— Киләләр!

— Адай андамы?

— Алдан бара.

— Табылдык ничек... кызың?

— Мин монда, әни! — диде кырнак, бикәнең үзе белән кызыксынуына сөенеп.

— Ярар, ярар, барыгыз,— диде бикә күңеле булып.

Әниләренең урыныннан кузгалуын һәм кем беләндер кычкырып сөйләшүен ишетеп, балалар да уянып киттеләр. Уяну белән алар беравык тыңлап яттылар. Әниләре яңадан үз почмагына килеп утыргач, җиде яшьлек малай, башын калкытып:

— Әни, без кая барабыз? — диде.

— Тозлы күлгә! Шуны да белми! — диде абыйсын үчекләп кечкенә кызый Куянкай.

Балаларның әле ана-кам кушкан чын исемнәре юк иде, аларны Бала дип, Малай, Кызым дип кенә йөртәләр. Шулай да малайга инде Кече-Тай, кызыйга Куянкай дигән исемнәр тагылып өлгергән иде.

— Әле иртә — йоклагыз,— диде әниләре балаларны яңадан йоклатмакчы булып.

— Мин торам, әни,— диде Кече-Тай, ишеккә таба шуышып.— Мин абыкайлар янына чыгам.

— Мин дә! — диде Куянкай.

— Иртә әле, иртә! — диде бикә балаларын тынычландырмакчы булып.

Ләкин ул арада Кече-Тай ишек-тәрәзәдән башын тыкты да, чәрелдек тавыш белән:

— Абыкай! Ат китер! — дип кычкырды.

— Миңа да! — диде Куянкай, кече абыйсы янына килеп.

— Барыгыз алайса, бар! — диде бикә. Балаларга ул җылы киемнәрен табышты, киендерде, чәчләрен сыйпап, рәтләп куйды. Арба янына ат китерделәр. Балалар узышып, төртешеп, ачык ишектән чыктылар, янәшә атлап барган атларга атландылар да, күздән дә югалдылар.

Балалар чыгып киткәч, арбада буш, иркен булып калды.

— Чобан, Чобан! — дип кычкырды бикә. — Кем бар анда — әйт әле, миңа да ат китерсеннәр!

II

Алар сөзәк калкулык итәгеннән бардылар. Сулда — көнбатышта күңелсез караңгылык җәелеп ята, уңда — көнчыгышта бераз гына ачыла башлаган күк чите һәм шундый ук караңгы бушлык барлыгы беленә иде. Инде кыш башланса да, күлләр, елгалар боз белән капланса да, кар әле төшмәгән.

Иң алдан, юл күрсәтеп, як-якны күзәтеп кораллы кылавызлар барды, алардан бераз калышып — каравыллар, каравыллардан да арттарак йөз кешелек коралы алай барды. Коралы алай артыннан утлыйутлый, иренеп кенә, йокымсырап кына көтүләр теркелдәде. Икешәр, дүртәр, алтышар үгез җигелгән авыр арбалар, озын койрык булып, көтүләр артыннан бардылар. Арбаларга бикәнең киез өйләре, кием-салымнары, савыт-сабалары, бөтен бер кышка җитәрлек азык-төлеге — барлык байлыгы, барлык кирәк-ярагы төялгән иде. Арбаларда шулай ук картлар, карчыклар, бала-чагалар, авырулар барды. Корал тота белгән, ат өстендә утыра алган барлык таза кеше — ирләр, үсмерләр — барысы да атка атланган иде. Көтүләрне, арбаларны алар алдан гына түгел, арттан да, ян-яклардан да карап, күзәтеп баралар.

Аларның байлыгы, билгеле, болар гына түгел иде. Бикәнең әле көтү-көтү маллары, меңләгән кешеләре бар. Алар Тозлы күл байларындагы далаларда булырга тиешләр иде. Ак урдадан куылу турында каган боерыгы билгеле булгач та, бикә аларга да тиз арада күченеп китәргә һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә — Байык суы буена таба хәрәкәтләнергә дип кеше җибәргән иде. Өч-дүрт көннән алар барысы да Диңгез-күл буенда очрашырга тиешләр.

Бикә арбадан чыгып атка атлануы белән, әнисе янына Куянкай килеп җитте.

— Абыкайларың кая?

— Мине ияртмәделәр, — диде кызый үпкәләп.

— Әйдә минем белән, — диде бикә үзенең кече кызына.

— Мин сине көттем, әни! — диде Куянкай.

Бикә, кызын ияртеп, арбалар, терлекләр килгән юнәлешкә каршы якка — койрыкка таба китте. Аның барысын да үз күзләре белән күреп, тикшереп чыгасы килде. Каршы яктан килүче арбаларга, кешеләргә, терлекләргә караштырып алар ашыкмыйча гына бардылар. Атка атланган бикәне ирләр, хатыннар сәламләп каршылады. Узып барышлый гына, исәнлек-саулык сорашкан арада гына бикә алардан тегесенмонысын белеште, берәрсенә кыска гына җавап кайтарды, я булмаса берәр киңәш бирде. Кечкенә түгәрәк битен ачып, йомшак тун якасын кайтарып куйган Куянкай әнисенең әле бер ягына, әле икенче ягына чыкты һәм бертуктаусыз тәтелдәп, нигә алай да, нигә болай, дип барды, я булмаса бер дә юктан кычкырып көләргә тотынды.

Кырыс ирләр, хатыннар баш иеп, ым кагып Куянкай белән дә исәнләштеләр. Мактап аңа берәр сүз әйтеп куйдылар, кайберләре көнләшеп, эчләреннән генә: «Бикә кызы шул — анасының итәгеннән төшкәч тә атка менгән. Безнекеләр аның яшендә сарыкка, кәҗәгә атланып йөриләр» дип уйладылар. Чыннан да, арбалар яныннан шыбырдашып,

теркелдәшеп барган тук сарыкларның йомшак сыртына караларның бишәр-алтышар яшьлек балалары атланып утырганнар иде. Арада аталары, аналары алдында — атка атланган балалар да күренгәләп калды. Бикәнең Куянкае масаеп, куанып, үз яшьтәшләренә, танышларына берәр сүз кычкырып китте. Берүзе бер атка атланып килгән кыю бикә кызына яшьтәшләре исләре китеп карап калдылар.

Бикә койрык белән тигезләшкәндә, арттан килүче кораллы ирләрнең үзара кычкырышуларын, ни турындадыр сүз көрәштерүләрен ишетеп калды. Иртәнге эңгердә бикәнең якынлашып килүен сизмичәрәк калдылар бугай. Колагына чалынып калган өзек-өзек сүзләр буенча бикә аларның нәрсә турында кычкырышуларына төшенеп өлгерде. Болар төрле ырудан, төрле төбәктән җыелган ирләр иде. Күпчелеге Куяннар булса да, алар арасында каган биргән ыбыр-чыбыр да җитәрлек. Тәгин угланга өлеш чыгарганда каган үзенә ярамаган төрле холыксызларны, башбаштакларны, я булмаса чирле-морлы, булдыксыз кешеләрне дә биргән иде. Бикәгә бу турыда әйткәннәр иде инде, ләкин урдада ул андый нәрсәләр белән кызыксынып тормады. Моның өчен аның вакыты да, теләге дә булмады. Аннан соң ул каганның ирләрен бөтенләй диярлек белми иде. Каган ирләрен яхшы белгән кеше — Туңгак алып янында булган булса, тәгин угланга ул теләсә нинди ыбыр-чыбырны бирдермәс иде дә соң, менә ул юк. Таяныр кешең булмаганда нинди кыен! Башын ашадылар микән инде аның? Каян беләсең, ничек беләсең аны? Тагын бер-ике көн тоткарланган булса, белә алган булыр иде дә бит — булмады, ашыкты, күзем күрмәсен диде, тизрәк китеп котылыйм диде. Ичмасам өлкән колыны да ислерәк түгел. Аңа таянырга әле иртәрәк. Барысы да үз башыңа калса, җиңел булмас бу башбаштаклар белән.

Үзара әйткәләшүче ирләрнең усал-усал тавышларын ишеткәч, күрекле бикәнең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ирләр кемнең «яхшырак», кемнең «батыррак» булуы, кемгә буйсыну-буйсынмау турында сүз көрәштерәләр. Каган ягыннан кушылган ирләр Куяннар янында борын чөяргә чамалыйлар иде бугай. Куяннар исә, күпчелек буларак, аларның үзләреннән дә яманрак усалланалар.

Ирләр, ниһаять, бикәне күреп алдылар һәм барысы берьюлы диярлек тынып калды.

— Иминлекме, Җирән? — диде бикә, йөзбашына эндәшеп.

— Иминлек, бикә.

— Колынымны күрмәдеңме? — дигән булды бикә болай гына.

— Монда булдылар алар.

— Булдылар да, ары киттеләр,— диеште Куяннар.

— Буран булмагае — бил сызлый,— диде Җирән.— Кызурак барыргае.

— Атлар пошкыра!

— Аяктагы яра сызлый башлады — буран була,— диештеләр ирләр, Җирәннең сүзен куәтләп.

Әлерәк кенә каршы очраган башка ирләр, хатыннар да шундыйрак сүзләр әйткәннәр иде. Бикә үзе дә көндез көчле җил-давыл чыкмагае дип уйлаган иде — барысы да бер үк нәрсәне кабатлагач, ул инде ышанмый булдыра алмады һәм ышыграк җиргә барып җиткәнче кызуларга кирәк дигән карарга килде. Ләкин кая чаклы барырга, кайда тукталырга — бу хакта инде алдан баручы остарак көтүчеләр белән сөйләшергә кирәк иде.

Бикә, койрыкны әйләнеп, олауларның сул ягына чыкты һәм кешеләрне, терлекләрне узып, кызурак бара башлады. Ул тагын да үзенең кешеләрен, арбаларын күздән кичерде, артка таба барганда күрми калган берәрсе белән исәнлек-саулык сорашып алды. Иртәнге салкында ат өстендә тирбәлеп барган саен, кешеләр белән сөйләшкән саен аның кү-

җелендәге авыр уйлар, кайгы-пошынулар, төннектән чыгып киткән төтен кебек, тәмсез ис кебек, каядыр чыгып, таралып бетте. Шул ук вакытта аны үзенең иле-көне белән, малы-туары, байлыгы, балалары өчен моңарчы беркайчан да булмаган авыр, катлаулы бер тойгы — зур җаваплылык тойгысы биләп алды. Элегрәк ул, никадәр авыр һәм кыен булмасын, үзенең өлкән бичә, каган бичәсе икәнлеген аңлап яшәде. Шунлыктан ил-көн, мал-туар турындагы кайгылар, борчулар аңа әллә ни катлаулы булып тоелмады. Хәзер ул менә үзе генә калды. Үзенә буйсынган ирләр киләчәктә дә үзара шулай ызгышып торсалар, кемгә буйсыну-буйсынмау турында баш ватсалар, нишләр ул алар белән? Берәр яктан көтелмәгән кыран килсә, яу килсә, яклармы соң алар аны, әллә, киресенчә, үзенә каршы кул күтәрерләрме? Ниндирәк кешеләр соң алар чынлап та каган биргән ыбыр-чыбыр? Тиешенчә белми торып ничек яшәмәк кирәк алар белән, ничек итеп аларны каравылга, сакка куймак кирәк? Бөтен эшне үз кулыңа алыргамы, тешне кысып олы колыныңа бирергәме? Ах, булсын иде аның янында хәзер теге атаклы Кол!

Әлегә ул берни хәл итә алмады, ул бары уйланды, пошынды гына.

Озакламый көн яктырды. Кара, туң дала өстенә якты кояш балкып чыкты.

— Кояш чыкты, әни! — дип кычкырды Куянкай очынып.

— Чыкты, кызым, чыкты. Читкә тибәрелгән кешеләргә дә кояш бертигез елмаеп карый. Барлык кешеләр аның өчен бер. Тик менә кешеләр үзара талашып, сугышып бүлгәләп алып бетергән бәхет кенә тигез түгел, кызым.

— Бәхет нәрсә соң ул, әни? — диде Куянкай.

— Бәхет ул, кызым, көч-байлык... яшьлек-матурлык,— диде бикә.

— Әнием, син нинди матур! — диде бала чын күңелдән сокланып.

Көтмәгәндә мондый мактау ишеткәч дүрт бала анасы куанып елмайды.

— Әни, син көләсең! Әни, син — бәхетле! — диде Куянкай.

— Бәхетле, кызым, бәхетле,— диде ана кызының күңелен кырасы килмичә.

Аның күзләренә яшь килде.

— Син миннән дә бәхетлерәк, кызым.

— Ник? — диде Куянкай.

— Син — яшьрәк.

Үзалдына ул уйлап куйды: «Син әле дөньяны... кансыз, көнчел дөньяны белмисең. Шуңа күрә дә бәхетле син, балам»,— диде.

III

Албуга кылавызлар артыннан барды. Мөмкин булса ул алардан алгарак та чыгар иде, сакчыларны, олауларны, кылавызларны — барысын да артта калдырып, буш иркен далада үзе генә барыр иде дә барыр иде. Әйе, үзе генә. Аты белән, уйлары белән серләшеп барыр да барыр иде.

Әнисен борчыган уйлар аны да борчыды. Аның да күңелен әрнү, хурлану, өметсезлек тойгылары биләп алды. Билгеле, ул әнисе кебек үк борчылмады, газаплы уйлары, тойгылары да аның икенче төрлерәк булды. Ул үзенең уң кул тучи бәк — бөтен Сөн илендә каганнан кала икенче дәрәҗәдәге кеше икәнлеген әз генә дә исеннән чыгармады, ләкин бу турыда белү генә аның күңелсез уйларын томалый алмады. Ул үзенең өйләнергә тиешлеген һәм шуңа күрә, өйләнгән барлык угланнар кебек, атасы урдасыннан башкаланып чыгарга тиешлеген дә аңлады. Ләкин моны аңлау шулай ук анда юану, я булмаса һич югы үз-үзенә

ышаныч тойгысы бирә алмады. Барыннан да элек ул үзен энисе белән бергә читкә тибәрелгән, урдадан куалап җибәрелгән итеп белде. Уң кул тучи бәк угыллары өйләнеп башка чыккач, үзләрен үзләре туйдыра алсыннар өчен, башкалар арасында аерылып торсыннар өчен элекке каганнар аларга ярым-йорты мең өй түгел, кимендә биш мең, алты-җиде мең өйлек ил-көн биргәннәр. Туман каган аны тулар-тулмас мең өй белән әнә, типкәләп, хур итеп дунхулар җиренә куалап җибәрде.

Нилэр көтә, кемнәр көтә анда аны, тәңрем?!

Шулай үзалдына уйланып барганда, арттан аны энисе куып җитте.

— Нишләп үзең генә? — диде энисе.— Адай кая, Кече-Таебыз кая? Кызың кая?

— Алар... теге якта калдылар,— диде Албуга уйларыннан тиз генә арына алмыйча.

— Абый, мин әни белән килдем! — диде Куянкай олы абыйсына эндәшеп.

— Син зур кыз бит инде,— дигән булды абыйсы Куянкайны мактап.

Бераз җир алар атларын янәшә атлатып бардылар. Бикә олаулар башына килеп җиткәндә көн инде яктырган иде. Ләкин кояш чыгып күп тә үтмәде, сул яктан, көнбатыштан көчле җил исә башлады. Һавада кар бөртекләре күренгәләде. Ачык далада иң яманы менә шушы җил белән каяндыр очып килгән кар бөртекләре иде.

— Әни, буран чыга! — диде Албуга.

— Борылыйк, улым, — диде бикә.

Алар атларын кире бордылар һәм каршыга килүче кешеләргә таба ашыктылар. Тиз арада алар янына кораллы ирләр, көтүчеләр җыела башлады. Олаулардан бер читкә туктап алар тиз генә киңәшеп алдылар. Бу тирәдә буран вакытында көтүләр, җигүле арбалар белән качып-ышыкланып торырлык бер генә уңайлы урын да юк иде. Шуңа күрә, кинәт җил-давыл чыга-нитә калса дип, барысын да алдан уйлап, кисәтеп куярга кирәк иде. Бу як далаларны яхшы белгән карт көтүчеләр туктамаска, киресенчә, ашыгыбрак барырга киңәш иттеләр. Алар исәбенчә, бер ярты көн барганнан соң комлы калкулыклар булырга тиеш иде.

Бикә көтүчеләр сүзенә колак салырга булды. Көтүләр, арбалар кызурак бара башладылар. Төштән соң карт көтүчеләр әйткән комлы калкулыклар янына барып җиттеләр. Бөтен ил-көн туктап калды. Шуны гына көтеп торган кебек кинәт буран чыкты. Күк йөзен тиз арада болганчык тоташ кар каплап алды. Тоз сыман каты, эре бөртекле кар яңгыры, шапылдап-шакылдап, берөзлексез киез түбәләргә бәрде, биткә-аркага бәрде, ат сыртларын камчылады.

Арттан, алдан, ян-яклардан килүче сакчы ирләр, көтүчеләргә әйләнеп, билгеләнгән тәртиптә тезмәләргә бастылар һәм ары-бире чабып, таралышырга гына торган терлекләрне куып йөрделәр. Тәгин углан да көтүчеләргә кушылды һәм тамак ярып кычкыра-кычкыра, әле җилгә каршы чапты, әле аркан барды, төркемнән качып киткән терлекләрнең юлына аркылы төште.

Шулай үз-үзен белешмичә анда-монда чабып йөргәндә ул, җилгә каршы баскан килеш, тыныч кына бер читтә буран тынганын көтеп торган ниндидер ирләр төркеменә юлыкты. Бөтен җирнең-күкнең асты өскә килгән чакта, барлык кеше терлекләр тирәсендә булашканда, берберсенә сыенып тик торган ирләрне күреп ул бик нык аптырап калды. Кемнәр болар? Энисенең ирләреме, аның үзенекеме, әллә бөтенләй чит кешеләрме?

Ирләрнең битлекләре төшерелгән, йөзләре томаланган булганлыктан, ул аларны таный алмады. Кар-буранга каршы күзләрен кысышты-

рып торганлыктан, ирләр дә аны күрмәделәр, сизмәделәр ахрысы.

— Таралсыннар!— диде ирләрнең берсе.

— Качсыннар! — диде икенчесе.

— Кырылсыннар! — диде өченчесе.

Алар, билгеле, көтүләр турында шулай сөйләнәләр иде. Сүзләрен тәгин углан аермачык ишетте, ләкин мәгънәсен тиз генә төшенә алмады. Шуңа күрә ул аларны танырга да, белергә дә тырышмады. Алар кычкырган сүзләрнең мәгънәсен дә, аларның шулай буранда качып торуларын да ул соңыннанрак — буран тынып, үзе дә тынычлангач кына аңлады.

Буран озакка сузылмады. Бу әле бала буран гына иде. Аның «анасы» әле арттарак булырга тиеш иде сыман. Җир өстенең уентыграк, чокырлырак төшләрен, коры үлән төпләрен кар белән тигезләп, тирә-якны агартып-яктыртып, ул кисәк кенә туктап калды.

Буран тыну белән, кешеләр башлыкларын, битлекләрен күтәрделәр, күзләрен зуррак ачып, үзгәргән, яктырган далага карадылар һәм андамонда тулган карларны каккалап-суккалап төшерделәр. Көне буена эчмәгән терлекләр кар яларга тотынды.

Күчмә авыл, калкулыклар арасында беркадәр тоткарланып торгач, яңадан кузгалып китте. Яңадан авыр көпчәкләр әйләнде, көчәнеп камыт баулары, тәртә баулары шыгырдады һәм түбәсе ябулы биек арбалар, диңгез өстендәге көймәләр кебек, җиңелчә генә тирбәлеп-чайкалып, дала дулкыннары өстеннән алга үрләделәр.

Алдан уйланганча, алар бүген төнне Уймак күл буенда кунарга тиешләр иде. Күл буена алар караңгы төшкәч кенә барып җиттеләр. Көндезге буран монда да чокыр-чакырларга, түмгәк, үлән араларына күп итеп кар тутырган иде. Шуңа күрә, терлекләрне сугару өчен күлдә бәкеләр тишеп азапланасы булмады. Арбалар тугарылды. Көне буена авыр йөкләр тартып килгән үгезләр, дөяләр, атлар тибенгә җибәрелде.

Бикә өен, тәгин углан өен тәртәләре югары күтәртелгән арбалар белән әйләндереп алдылар. Арбалардан җыйналган бөҗраның тышкы ягына, капка янына, шулай ук көтүләр янына төнге каравыллар куелды. Тәгин углан, әнисенең әйткәнен дә көтмәстән, торгакларны, каравылларны үзе билгеләде. Үз-үзен белештермичә ул гел очынып-җилләнеп йөрде. Беренче мәртәбә ул үзен унлап егеткә түгел, бәлки бөтен бер ил-көнгә баш итеп, хуҗа итеп тойды.

IV

Үз өенә ул тирә-як тынып калгач, күктә йолдызлар күренә башлагач кына кайтып керде. Җылы, якты өйгә пешкән яшь ит исе чыккан иде. Тыштагы коры салкыннан соң монда тынычта, җылыда искиткеч рәхәт, күңелле иде.

— Бүген мин аерым казан астым! — диде Табылдык аны сөенечле хәбәр белән каршылап.

— Шулаймыни? — диде Албуга елмаеп.

Табылдык аңа чишенергә булышты, авыр киемнәрен, билбавын алып куйды.

— Әнидән сорадыңмы соң? — диде углан, учак өстендәге тимер казанны караштырып.

— Ул үзе әйтте. Ул мине ярата! — диде Табылдык куанып.— Утананы үзе арыклады, итне үзе бирде, казанга үзе су салды.

— Каяле, эчендә ниләр бар икән моның? — диде Албуга, киез өстенә аякларын бөкләп утырып.

— Мин сиңа... бөтен бер тәкә пешердем! — диде Табылдык, казанның капкачын ачып.

— Бөтен бер тәкә! — диде углан төкрекләрен йотып.

Иртәннән бирле ул авызына берни капмаган, ашыйсы килүдән аның инде башлары әйләнә башлаган иде. Ике колагыннан тотып ул учак өстендәге тимер казанны күтәреп алды да эчендәге барлык итне зур агач табакка каплады. Итне ул корыч пычак белән үзе кисте, үзе турады. Башта ул үзе авыз итте, аннары иттән, пычактан күзен алмый елмаеп утырган ягымлы кызына бирде. Итнең ул яхшы, йомшак кисәкләрен генә ашады да, калганын шулай ук Табылдыкка тоттырды. Хуҗасының юмартлыгына күңеленнән бик шат булса да, Табылдык алай комсызлык күрсәтмәде — үзенә бирелгән кисәкләрнең йомшаграк итләрен ул кире углан алдына куя торды.

— Үзең аша. Сиңа көчле булырга кирәк. Бер ашаганда бер куй да ашамагач, нинди алып ир син?! — диде кырнак хуҗасын җиңелчә генә шелтәләп.

— Күп була. Артыгы бармый,— диде Албуга.— Бер ашаганда бер куй ашарга иртәрәк әле миңа.

— Бер дә иртә түгел,— диде Табылдык.— Менә кымыз эчеп җибәр дә тагын ашарсың.

Тәгин угланнан ул бер-ике яшькә өлкәнрәк иде. Шуңа күрә үзен бераз гына тәҗрибәле санап, өйрәтергә хаклы санап, җиңелчә генә аны «кыздырып» алган булды, көлеп-шаяртып аның авыз читләрен сөрткәләде. Мондый вак-төяк шелтәләрне, булышуларны ул угланның ачуын китермәслек итеп кенә, көлештереп кенә эшләде, һәм шулай итеп, ике арада киеренкелек, читсенү дигән нәрсә әкренләп югала барды. Албуга да аңа инде элеккечә сыртын кабартып тормады. Кызның ягымлылыгы, йомшаклыгы, күндәмлеге көннән-көн аның күңелен эретә барды. Кыз салып биргән кымызны Албуга яратып, рәхәтләнеп эчте. Кымыздан соң ул, көчләп булса да, тагын ит ашап куйды.

— Туйдым! Шартлыйм! — диде ул көлеп.

Зурайган шәрә корсагын ул ике куллап сыйпап алды.

— Каяле, тулды микән? — дигән булды Табылдык та, аның таштай каты эченә үрелеп. — У-у, монда әле тагын бер куйга урын бар! — диде ул көлеп.

— Җитәр, кыстама инде,— диде Албуга ашаудан баш тартып.

— Ярар, кыстамам.

Хуҗасының тавышында ул чак кына ризасызлык сизеп алды.

— Үзең аша,— диде углан, табакны бөтенләе белән кызга таба этәреп.

— Ашармын, — диде Табылдык.

Тәгин углан аның сөяк кимерүен караштырып беравык тынып утырды да, аягына басты, киемнәренә үрелде.

— Мин, булмаса, торгакларны тикшереп кайтыйм әле,— диде ул үз-алдына сөйләнеп.

Сөякләрен ташлап Табылдык шундук аягына басты, хуҗасыннан элек аның киемнәрен эләктереп алды да, киендерергә әзер булып, аның каршысында туктап калды.

— Әллә чыкмыйсыңмы? — диде ул угланның күзләренә карап.

— Нишләп алай?

Кыз ни әйтергә белми аптырабрак калгандай булды. Сине сагындым, минем янда гына тор дияргә, үзенең күпмедер дәрәҗәдәге өстенлегеннән файдаланып, аңа нинди дә булса киңәш бирергә аның әлегә кыюлыгы җитмәде.

— Ирләр арасында сиңа аң булырга кирәк,— диде ул.

— Нинди ирләр арасында? — диде Албуга.

— Нинди ирләр икәнлеген белмим. Бүген мин әллә нинди сүзләр ишеттем,— диде Табылдык.

Тәгин угланның үз-үзеннән канәгать, тук, бәхетле йөзе шундук үзгәреп китте. Келт итеп бүген буран вакытында очраган теге ирләр исенә төште, колагы төбендә яңадан аларның өзек-өзек сүзләре ишетелгәндәй булды.

— Нәрсәләр ишеттең? — диде ул сагаеп.

— Берсе әйтә: мин барыбер качам! ди... Икенчесе әйтә: мин талап качам, ди. Тагын берсе әйтә: башкалар Чингә яу чапканда, чин кызларын алып кайтканда, без монда сыер сыгрыйгы иснәп ятабыз, ди. Тагын берсе әйтә...

Табылдык, аның нәрсә әйткәнен исенә төшерә алмагандай, төртелеп туктап калды.

— Нәрсә әйтә?!— диде Албуга, кызының беләгеннән тотып алып.

— Син... миңа ачуланмассыңмы? — диде Табылдык икеләнеп.

— Ачуланмам. Барысын да әйт,— диде углан.

— Алар каган сине урдадан сөреп җибәрде дип уйлыйлар. Сине беркайчан да Ак урдага кайта алмас дип уйлыйлар,— диде кыз.

— Шул гынамы? — диде Албуга.

— Түгел. Берсе әйтә: тәгин углын каган үлемгә җибәрде, ди. Алты йөз-җиде йөз өй белән ничек итеп анда башкаланып яшәмәк кирәк, ди/ Үз җирләренә барып җитү белән дунхулар безне кырып салачаклар, ди.

Албуга, башына суккандай, тынсыз-өнсез калды. Үзенең, энисенең нинди ышанычсыз, тотрыксыз хәлдә калганлыгын ул инде болай да белә иде, шуңа күрә Табылдык әйткән сүзләрдә әллә ни яңалык та юк иде. Бу бары үзең сизенгән, үзең төшенгән куркыныч нәрсә турында чит кеше авызыннан ишетү һәм шуның белән үз шигеңне, үз сизенүеңне ныгыту гына булды. Аның өчен күп нәрсә яңадан ачыкланып калгандай булды, ләкин менә тук, канәгать килеш яңадан шомлы, куркыныч чынбарлык белән очрашу аны каушатып җибәрде.

Аның үзгәргән, бозылган кыяфәтен күреп, яшь хатын чын-чынлап куркуга төште. Ул аңа табарак тартылды, аны кочаклап алды, иркәләп, яратып аның аркасыннан, иңбашларыннан сыйпалады.

— Нишләп болай коелып төштең әле син? — диде ул йомшак кына, гөр-гөр килеп. — Ир кеше усалрак, кырысрак була ул. Син алып ир, син — тучи бәк тәгин углан! Теләсә кем сүзенә колак сала башласаң!

— Колак салмыйча да ярамый,— диде углан.

— Колак салсаң да, каушап калырга кирәкми,— диде яшь хатын аны яклап һәм сиздермичә генә үзенең кинәшен дә кыстырып.

— Мин барында син тыныч бул. Мин сиңа көч бирермен, кыюлык бирермен, яшь богам! Мин үлем тырнагында булдым, мин абалар авызыннан ычкындым. Мин инде беркемнән, бернидән курыкмыйм кебек. Мин бары синнән генә куркам бугай... яратмассың дип, ташларсың дип куркам бугай...

— Курыкма! — диде углан уяну билгесе сиздереп.

Кызын ул кочаклап алды, аның җылысын тоеп, аның дәртле көчен тоеп һәм шул ук вакытта тынычлана барып ул сүзсез генә аңа карап торды. Андагы бу үзгәрешне, эчке борылышны яшь хатын бөтен тәне белән сизде.

— Мин — кырнак. Беркайчан синең бичәң була алмам,— диде ул кайнар пышылдап.— Шулай да мин синең мәңгелек юлдашың булырмын. Миннән алда үлсәң, беренче булып мин синең каберең кереп ятырмын — теге дөньяда мин синең аяк астында йомшак мендәр булырмын. Тик минем әле үләсем килми. Минем үләсем килмәгәч, син дә үлмәячәксең — шуны онытма! Теләсәң, ун кызга, йөз кызга өйлән, тик мине генә читкә тибәрмә!

— Мин сине читкә тибәрмәм. Мин сиңа ышанам! — диде углан тәмам күңеле эреп.

— Инде чыксаң да ярый,— диде Табылдык бушанып, җиңеләеп.— Минем елыйсым килә, сөенечтән елыйсым килә. Син югында мин иркенләп елармын.

— Мин барында ела. Мин тыймыйм,— диде углан.

— Минем сиңа яшьле күз белән күренәсем килми. Син бар. Торгакларны тикшер. Мин сине таңга чаклы көтәргә дә әзер,— диде Табылдык.

Ул ашык-пошык аны киендерергә тотынды. Әле көлде, әле борынын тарткандай итте һәм үзенең кайгысын да, шатлыгын да, үлемен дә, яшәвен дә үз кулында тоткан яшь ирдән — кырыс та, куркыныч та, тәелган олуг ирдән аерылырга теләмичә, ялгыш кына әле аның кулына, иңбашына орынып алды, әле аның күзләренә елмаеп карады.

V

Яшь хатын белән тулы аңлашу, тулы якынлык барлыкка килсә дә, тәгин угланның күңел төбендә үз язмышы, әнисе һәм ил-көн язмышы турындагы борчылу тойгысы торып калды. Кызның кайнар иркәләвеннән аерылып, кара, салкын тышка килеп чыккач, әлеге берни белән бетереп булмый торган борчылу, пошыну тойгысы барлык уйларны, тойгыларны күмеп, яңадан өскә калкып чыкты. Аның хәзер әнисен күрәсе, бик кирәкле нәрсәләр турында сөйләшәсе килде.

Бикә'өендә тагын йөзбашы Җирән белән баш бага Кортага да бар иде. Албуга килеп кергәндә алар нидер киңәшеп, сөйләшеп утыралар иде. Адай белән Кече-Тай да шунда әниләре тирәсенә елышканнар. Кечкенә кыз Куянкай, аякларын, кулларын як-якка ташлап, ястык-мендәр арасында йоклап ята.

Бикә үзенең өлкән углын түргә, үз янына чакырды. Ирләр, тәгин угланга буйсыну белдереп, аның алдында баш иделәр, сүзсез генә читкәрәк тайпылдылар.

— Синең керүең яхшы булды әле, улым,— диде бикә.— Эшләр шәптән түгел безнең. Менә шул турыда сөйләшеп утыра идек.

— Ни булды тагын?

— Әлегә булмады. Йоклап ятсак, булыр,— диде бикә.

— Каган безгә үзенең башбаштакларын, башкисәрләрен биргән,— диде баш бага Кортага.— Алар ачыктан-ачык буйсынмау белдерәләр, телләшәләр, төрле имеш-мимешләр сөйлиләр. Мин үзем дә ишеттем. Менә башкаларга да ишетелгән.

— Ишетү генәме! — диде йөзбашы Җирән.— Нишләргә алар белән? Кире урдага кайтарып җибәрергәме, берсен калдырмый кырып бетерергәме?

— Нәрсә уйларга да баш җитми, улым,— диде бикә дә.— Син менә ни әйтерсең икән?

Барысы да җавап көтеп, тәгин угланга текәлделәр. Аны шулай сынап карау өчен юри генә сөйләнәләр идеме алар, чынлап сөйләнәләр идеме — Албуга моны төпченеп тормады. Бөтенесен үз кулына алырга, бөтенесен үзенчә эшләргә дип ул инде күптән уйланып йөри иде һәм ул инде моңа әзер дә иде бугай. Тик моңарчы ул әнисенең бу эшкә ничегрәк караячагын гына белми иде. Әнә хәзер алар барысы да аннан акыллы сүз көтәләр.

— Сез әйткән башбаштак, башкисәр ирләрне атам каган миңа дип бирде. Алар — минеке. Шулай булгач, аларны мин тыячакмын, — диде

ул әкрен генә сүзгә башлап. — Мин аларны кире дә кайтарып җибәрмәячәкмен, кырып та бетермәячәкмен. Мин аларны буйсындырырга тиешмен!

— Сүзләрең алтын, улым! — диде бикә, улының шундый төпле, акыллы итеп сөйләвенә исе китеп.

— Белеп сөйлисең! — диде баш бага Коргага да.

— Икәүнең — берсе өстен, берәүнең — бүрке өстен, — диде углан. — Бездә әлегә, әни, беркем дә өстен түгел. Мин мал-туарны әйтмим, кораллы ирләрне әйтәм. Башбаштаклык безнең үз арабыздан башлана, әни.

Бикәнең дә, ирләрнең дә кинәт колаклары үрә торды. Яшь угланның сүзләре аларны сөенергә дә, сагаерга да мәҗбүр итте.

— Безнең әле кайгыдан айныганыбыз юк. Без көтүчесез көтү кебек таралып, туарылып, кем ничек тели шулай барабыз, — диде Албуга дәвам итеп.

— Син, углым, менә шул таркау көтүнең көтүчесе була алырсыңмы соң? — диде ана сак кына, ипләп кенә.

— Мин, әни, туганда ук көтүче булып тумаганмын мени? — диде уң кул тучи бәк тәгин углан.

— Шулаен шулай да... — диде әнисе ы-мы итенеп.

— Яшьрәк дисеңме? — диде Албуга әнисенең уйларын сизенеп. — Кайчан да булса дилбегәне мин барыбер үз кулыма алырга тиеш түгел мени?

— Йөзбашы Җирән! — диде бикә, башын калкытып. — Бүгеннән башлап син дә, синең ирләрең дә тулысынча минем углым Албугага буйсынасыз!

— Буйсынабыз, бикә! — диде йөзбашы Җирән, баш иеп. Шуннан соң ул тәгин углан ягына борылды, аңа да баш иде: — Моннан соң мин сиңа буйсынам, олуг тучи бәк тәгин углан! — диде.

— Бай бул, әнием! — диде Албуга әнисенә. — Бүгеннән башлап мин синең кораллы ирләреңне дә, атам каган биргән үз ирләремне дә бер йодрыкка туплаячакмын.

— Бирсен, тәңрем! — диде бикә чын күңелдән сөенеп.

— Мин болай уйлыйм, — диде Албуга йөзбашы Җирәнгә карап. — Безгә башбаштаклар белән Куяннарны аралаштырырга, катнаш алайлар төзергә кирәк.

— Шулай итәрбез, — диде йөзбашы Җирән. — Куяннарның ант бозганнары юк, Куяннар синең иң турылыклы ирләрең булыр, олуг тучи бәк тәгин углан.

— Шуңа күрә, — диде Албуга, аның сүзләрен элеп алып, — төнге каравылга бүген бары Куяннарны гына куярга кирәк булган. Инде соң.

— Соң түгел, тәгин углан, — диде Җирән. — Төнлә ул-бу булмасын өчен без Куяннардан гына өстәмә торгаклар билгелик.

— Төнгә мин дә чыгам! — диде Адай шундук тавыш биреп.

Абыйсы усал гына итеп аның ягына карап алды.

— Моннан соң өлкәннәрдән узып авыз ачмаска боерам! — диде ул кырыс кына.

Башка вакытта абыйсыннан мондый каты сүз ишетмәгән Адайның ике күзе шар булды. Үзеннән-үзе калтырана башлаган иреннәрен көчкә тыеп ул үпкәләп тизрәк читкә китеп барды. Тәгин угланның мондый кискенлеген ошатмыйча, өлкәннәр бер-берсенә карашып алдылар.

— Нинди алып ир килгән дип торырсың! — дип мыгырданды Адай хәтере калып.

— Элеккечә минем белән телләшсәң, үпкәләп авыз күпертсәң, беркая чыкмассың! — диде абый кеше тагын да ныграк үткәзеп.

Адай шып булды. Беравык абыйсына каш астыннан гына карап торды да, килешергә теләвен белдереп, буйсынып:

— Моннан соң алай булмас, — диде.

— Ярар, син дә чыгарсың, — диде Албуга йомшап. — Әни, син тынычлап йокла.

— Болай булгач, улым, мин чыннан да тыныч, — диде бикә елмаеп. — Син үсеп җиткәнсең, олыгаеп киткәнсең. Мин күрмәгәндә генә!

— Мин дә үстем, әни! — диде олыларның сүзләрен йотлыгып тыңлап утырган Кече-Тай.

— Үстең, улым, үстең, Кече-Таем! — диде ана кеше, бәләкәй улының башыннан сыйпап.— Үстегез инде — яклаучыларым бар. Сез барында миңа берни куркыныч түгел, балаларым.

VI

Көтүләр янына, бозраның тышкы ягындагы төрле төшләргә Албуга Куяннардан өстәмә каравыллар куйды. Үзенә иптәшкә ул Адайны да алды һәм алар икәүләшеп ярты төнгә чаклы сакчылар, каравылчылар тирәсендә булдылар. Йөзбашы Җирәнгә ул йокларга кушты. Төн уртасы җиткәч исә уятты да таңга чаклы йокламаска, әледән-әле төнге торгакларны тикшереп торырга боерды. Шуннан соң алар Адай белән өйләренә кайтып киттеләр.

Икенче көнне авыл иртә уянды. Өйләрне җыеп, арбаларны җигеп яңадан кузгалганчы дип, тәгин углан үзенә буйсынган барлык кораллы ирләрне ачык җиргә алып чыгарга һәм сафка тезәргә боерды. Аның йөрәге түзмәде — аның тизрәк үз ирләрен үз күзе белән күрәсе килде. Бармак белән төртеп ул ирләрне үзе санап йөрде. Саный торгач, төпченә торгач, каган биргән ирләр арасыннан ике кешенең юклыгы беленде. Аларның кайчан, ничек юкка чыгуын беркем дә рәтләп аңлатып бирә алмады. Алар, имеш, кичә кичтән үк күренмәгәннәр.

Качакларны эзләргә, тотарга Албуга кеше җибәреп тормады. Киткәннәр икән, китә бирсеннәр — далада әле беркемнең дә җил белән атлы качакны куып тота алганы юк. Инде моннан соң ычкындырырга ярамый. Беркемне дә. Моннан соң инде күз-колак булырга, белеп-тикшереп кенә торырга кирәк булачак!

Тезмәләрдәге ирләрне барлагач, качаклар турында белешкәч Албуга йөзбашы Җирәнгә борылды һәм кызмаска, ачуланмаска тырышып:

— Йөзбашы Җирән! — диде.— Анам бикә сине миңа бирде. Анам алдында син миңа бил бөктең. Моннан соң син кизү чагында минем, бикәнең байлыгыннан ике ат белән ике кеше түгел, ике тун белән ике энә югалса да, мин синең... башыңны чаптырачакмын!

Гомере буена диярлек бикәгә тугрылыклы булган, аның авылында көн-төн каравыл торган, аның азыгын ашап, аның белән якыннан дуслашып беткән һәм бераз гына симерә башлаган, үз-үзеннән канәгать йөзбашы Җирәннең әле беркайчан да мондый куркыныч кисәтү ишеткәне юк иде. Үзлегеннән ул бернәрсә дә эшләмәскә күнеккән, ул бары буйсына, тыңлый, боерыкларны җиренә җиткереп үти һәм шунлыктан үзен буйсынучан, булдыклы, тырыш ир дип исәпли иде. Яшь угланның янавы аңа аяз көнне яшен суккан кебек булды. Ул шаккатты, телсез-өнсез калды. Әле кайчан гына үзе күтәреп йөрткән, атка атландырып йөрткән малай-шалайның, борыны астында ныклап мыек та үсмәгән яшь угланның мондый кырыслыгына каршы ул берни дә әйтә алмады.

Үзенең кискенлегеннән тәгин углан үзе дә каушабрак калды. Ләкин ул инде кире дә чигенә алмый иде.

— Синеңчә булыр, олуг тучи бәк тәгин углан, — диде Җирән мыгырданып.

Үзалдына ул уйланып куйды: «Төне буе анда-монда чабып йөрде дә, әнә йокысы туймаган. Бик авыр булыр бу яшь әтәч белән». Әмма сүз куертып аның ачуын китерәсе килмичә, тизрәк читкә китеп барды.

Ала-кола дала өстенә көндәгечә сыек, салкын яктылык тарала башлады. Бөек кояшның җир астыннан калкып килүен күреп, тезмәдәге кораллы ирләр, изге бер тынлык белән, көнчыгышка таба борылдылар. Тәгин углан да тынып калды, башын калкытты һәм кояш чыкканын көтә башлады. Шул чакны аның кырыс, агарынган йөзенә, кояш нуры сыман булып елмаю балкып чыкты. Тезмәнең ерактагы койрыкларына ул уртага таба бөгелергә, үзенә якынрак килергә боерды. Боерыкны тезмә буена тапшырдылар. Күп тә үтмәде, як-яктан озын койрыклар кыймылдап куйды, якыная башлады. Бөтен тезмә, көнчыгышка йөзе белән борылган хәлдә, дуга сыман булып тынып калды.

Тәгин углан энесе Адайны үзе янынарак чакырды.

— Мине арттан сакла. Сөңгеңне әзер тот! — диде ул аңа.

Шуннан соң ул бөтенесенең күз алдында атыннан сикереп төште, өстендәге тунын салып җиргә җәйде дә, башындагы бүреген салып кулына тотты, тунына тезләнде һәм зураеп, яктырып килгән кояшка карап:

— Тәңрем! Олуг атам! Мәңге юлдашым бул, изгелегеңнән ташлама, — дип кычкырды.

Бу аның Кояшка карап әйткән, барлык кеше ишетерлек итеп әйткән беренче. келәве иде. Үзенең бик тә кирәкле эш, олы, куркыныч эш эшләвен аңлаудан, үзен кыю һәм башсыз итеп тоюдан аның йөрәге атылып чыгардай булып типте. Ашыкмаска-кабаланмаска тырышып ул башына бүреген киде, өстенә тунын киде дә, яңадан атына атланды һәм күрмәс күзләре белән йөзләгән ирләр ягына карап:

— Ишеттегезме минем келәүне? — дип кычкырды.

Ирләр, ни әйтергә белмичә, каушап калдылар. Сөн илендә бары ил башы каган гына иртән — кояшка, кич — айга келәү әйтә, бары ул гына Тәңрегә «атам» дип эндәшә ала иде. Нәрсә бу, йола бозумы, әллә каганга каршы баш күтәрүме? Бу шундый изге, серле нәрсә иде — моны аңларга беркемнең дә башы җитмәде. Башкалар гына түгел, тәгин углан үзе дә моны ныклап торып төшенә алмады. Ул бары үзенең Тәңре углы булуын гына белде дә, үзен танымаган, танымаска тырышкан башбаштак ирләр алдында үзенең кемлеген күрсәтергә кирәклеген генә белде. Аның колаклары шаулады, битләре уттай кызды, күзләре исә якындагы Адайдан башка беркемне дә аера алмады.

— Абый, кузгалырга боерык бир! — диде Адай.

— Нәрсә, нәрсә?

— Арбалар җигелде. Кузгалырга кирәк. Боерык бир! — диде Адай кычкырып.

Албуга аңлап алды һәм тамак ярып:

— Кузгалырга! — дип кычкырып җибәрде.

Тезмә тарала башлады. Һәркем үз урынына ашыкты — берәүләр атларын юырттырып олаулар алдына киттеләр, икенче берәүләр көтүләр янына ашыкты. Бөтен ил-көн кузгалып киткәндә сул яктан ачы җил исә башлады.

Тәгин углан, үз-үзенә урын таба алмагандай, каядыр алга чапты. Аның яныннан, күләгә кебек, Адай барды. Алар шулай юырттырып кылавызлар янына ук барып чыктылар, аның юлын кистеләр дә, каршыга таба килә башладылар. Бу вакытта инде аларның кайнарлыгы сүрелә төшкән иде. Тәгин углан әле генә булган нәрсә турында тынычлабрак уйларга тырышып карады. Ул үзенең бик зур ахмаклык эшләвен аңламый булдыра алмады. Ирләр алдында, бөтен ил-көн алдында

Тәңрегә «атам» дип эндәшергә аның бернинди хокукы юк иде. Бу турыда каган ишетсә, күрәсең, аның башыннан сыйпамас.

Каган! Әти! Нинди якын иде ул кайчандыр! Янында ичмасам атасы урынында булган акыллы, дус, якын Туңгак алып та юк.

«Качып кына карасыннар! Әйтеп кенә карасыннар!» диде ул шундук үз-үзенә җавап биреп. Качакларны, башбаштакларны исенә төшергәч аны чиксез нәфрәт һәм ачу тойгысы биләп алды. Алар аны сабый дип уйлыйлар, ахрысы, шуңа күрә качарга, телләшергә ярый, дип беләләр, ахрысы. Качмый торыгыз әле, телләшми торыгыз! Мине ташлап китеп ирекка чыкмакчы, үлемнән котылмакчы буласызмы? Үлсәк — бергә үләбез, яшәсәк — бергә яшибез!

Ул үзенең егетләрен көтеп алды да, сүзсез генә алар алдыннан китте. Егетләрнең күбесе аның яшьтәшләре иде. Алар аның үз ирләре, җан сакчылары иде. Аларга ул үзенә таянган кебек таяна ала. Егетләр һәрвакыт аның янында булырга, аны төрле бәла-казадан саклап калырга тиешләр иде. Ләкин ул бүген аларга аерым алай булып, олауларның уң ягыннан сакта барырга кушты. Алайны көчәйтү һәм каган биргән ирләр белән якынайту, дуслаштыру өчен ул аларга тагын унлап «башбаштак» яшьләрне өстәде. Энесе Адайны ул көчәйтелгән әлеге алайга унбашы итеп билгеләде.

Бер мәртәбә олауларны, көтүләрне карап әйләнгәч ул тагын үзенең егетләре янына килеп чыкты. Адай шундук абыйсы янына килде. Алар беркадәр тарала башлаган алай алдыннан бардылар.

— Ничек, шаулашмыйлармы? — диде Албуга.

— Куяннарга кушылмыйлар. Бер алайда — ике алай, — диде энесе.

Тәгин углан артына борылып карагандай итте — чыннан да егермеләп кешелек төркем арттан икегә бүленеп килә иде. — Алар әйтә: Сөнәнкәләр Куяннарга буйсынмый, Куяннар Сөнәнкәләргә буйсынырга тиеш, диләр, — диде Адай әләкләп.

— Әйтсеннәр, әйтә бирсеннәр, — диде абый кеше, исе китмәгәндәй.

Шулай атларын әкрен генә атлатып барганда, алда, куаксыман кабарып утырган куе үлән арасыннан ялт итеп ап-ак куян чабып чыкты. Ул да булмады, каяндыр югарыдан, баш өстеннән, канатларын сызгыртып бөркет очып төште. Күз ачып йомганчы Албуга җәясенә ук утыртты, атып җибәрде. Качып барган куянны инде эләктердем генә дигәндә, бөркет кошны тимер очлы ук куып җитте. Таштай авыраеп, бөркет кинәт җиргә төште. Үлем тырнагыннан котылган ана куян кырт кына унга борылды да, үзән буйлап чаба башлады.

Ләкин шулай да ул ерак китә алмады — аны тимер башаклы куркыныч ук куып җитте. Зур ак куян сөрлегеп китте, торды, яңадан чапмакчы булды, егылды һәм җир өстендә тыпырчынып ятты да тынып калды.

VII

Бу шундый көтмәгәндә булды, шундый искәрмәстән булды, — әйтерсең, күктән кинәт яшен ташы төште, әйтерсең, кинәт җир убылды. Куян ыруы кешеләре, котлары алынып туктап калдылар — Куян ыруы кешесе өчен куян үтерүдән дә хәтәррәк нәрсә юк иде. Сөнәнкәләр, башбаштаклар шаркылдап көләргә тотындылар. Тәгин углан ярсып, агарынып шундук артына борылды.

— Кем? — диде ул, үз артыннан килгән егетләргә кычкырып.

Егетләрдән кемнең дә булса «кем» икәнлеген әйтеп өлгергәнче ул «кем»нең кем икәнлеген үзе күреп алды. Бу «кем» башбаштаклар төркеменнән булган бер Төпсә атлы яшь ир иде.

Кыска буйлы, аюдай таза, көчле бер кеше. Башкалардан өлкәнрәк

булгангамы, көчлерәк булгангамы ул ничектер бик тиз күзгә ташлана, гел үзен бәйсез, иркен тотарга ярата иде. Аннары аны чамадан тыш комсыз дип тә сөйлиләр иде. Яуда чагында ул ничек тә үзе генә алга чыгарга, яхшырак, җайлырак нәрсәләрне эләктереп, тизрәк табан ялтырату ягын да карый икән.

Үз төркеме алдыннанрак барган һәм әле генә кереше тартылган җәясен кире җыеп азапланган Төпсәне күреп алу белән, Албуганың күз аллары яктырып киткәндәй булды. Шул кыска гына вакыт эчендә ул әлеге башбаштак ир турында ишетеп белгәннәрен исенә төшереп, шунда ук тиешле карарга да килеп өлгерде. Ул атын кырт кына уңга борды, әле һаман авызы ерык Төпсәнең каршысына килеп басты, кыныдан кылычын тартып алды да бар көченә селтәнеп җибәрде. Үзүзеннән канәгать төс белән елмайган авызлы, зур борынлы кабак баш, ни булганын төшенә алмыйча, юан, таза гәүдәдән аерылып, шапылдап, бәсләнгән ат сыртын кызыл канга буяп, таштай каты җиргә барып төште. Кола-туры ат колакларын шәмрәйтеп, куркып пошкырып җибәрде һәм сыртыннан шуышып ычкына башлаган авыр гәүдәне өстерәп читкә чабып китте.

Боларның барысы да тәгин угланның юлдашлары күз алдында булды. Барысы да, котлары алынып, туктап калдылар. Шул чакны башбаштаклар төркеменнән берәү, башкаларны ырып-ерып, тәгин угланга таба якыная башлады. Ачуы-ярсуы әз генә дә кимемәгән, шул ук вакытта саклык, уяулык тойгысын да югалтмаган Албуга кырын күз белән генә аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торды. «Нишләр икән?!» дип уйлады ул үзенә таба килүчегә каршы юлбарыстай ыргылырга әзер булып.

Аңа таба якынаерга азапланган егет үч иткәндәй угына-җәясенә тотынды. Тәгин угланның белүенчә, бу егет Төпсәнең бертуган энесе Тишек-Таш булырга тиеш. Ул да абыйсы кебек үз таза, явыз, комсыз бер кеше иде. Йола буенча ул абыйсы өчен канлы үч алырга хаклы. Ләкин Тишек-Таш дәһшәтле «Қанга-кан!» сүзен кычкырып өлгергәнче, җәясенә ук утырта алганчы, тәгин углан, беренче булып:

— Тишек-Таш! Ташла коралыңны! — дип кычкырып җибәрде.

Егетләр кузгалып куйдылар, Тишек-Ташның нишләргә җыенуын күреп тиз арада аны төрле яктан чолгап алдылар. Егетләрнең барысы да «башбаштаклар» иде! Тишек-Таш та аптырап тормады — атының сыртына басты да, угын керешкә утыртты да...

Аны чолгап алган иптәшләре моны абайлап җиткермәделәр. Алар бары якыннан гына очып киткән бөркет каурыйлы ук койрыгын гына күреп калдылар. Күрделәр дә барысы да берьюлы тәгин углан ягына борылып карадылар. Анда, аның аты өстендә беркем юклыгын күреп, барысы да аһ итеп җибәрделәр. Аны-моны төшенмичә ярсып, алар коралларына тотындылар һәм, сытып ташларга әзер булып, Тишек-Ташны тагын да ныграк уратып алдылар. Шомланып атлар пошкырды, баш өстендә үткер кылычлар ялтырап китте.

Тишек-Таш ук атканда ияреннән егылып калган Албуга алар шулай шаулашканда яңадан иярено менеп утырды.

— Туктагыз! — дип кычкырды ул үз егетләренә.

Тишек-Ташның күз алдында уйнаган ачулы кылычлар авыраеп түбән төштеләр, кынызарга шуышып кереп тынсыз калдылар. Тишек-Таш, төрле яктан аучылар белән уратып алынган киек кебек, куркып як-ягына каранды да, агарынган йөзен бозып, ямьсез итеп еларга кереште. Әле генә үлемнән исән калуы өчен елый идеме ул, бертуган абыйсының коелган каны өчен үч ала алмавы өчен елый идеме — беркем моны белә алмады.

— Таралыгыз! Җибәрегез аны, — диде Албуга боерып.

Тыгызланып бер тирәгә укмашкан йомгак теләр-теләмәс кенә сү-

тelə башлады. Тәгин углан, Тишек-Ташның тынычланганын күтеп торды да, эчке бер күтәренкелек белән:

— Ирләрем-егетләрем, мине тыңлагыз! — диде.

VIII

Барысы да, бердәй булып, тәгин угланга текәлделәр.

— Мин бүген иртән Тәңрегә келәү әйттем. Ишеттегезме? — диде Албуга.

— Ишеттек! — диделәр егетләр бер авыздан.

— Мин Тәңрегә «атам» дип эндәштем. Ишеттегезме? — диде углан.

— Ишеттек! — диделәр егетләр.

— Син — каган түгел. Син йола боздың, — диде Тишек-Таш.

— Әйе, мин ил башы каган түгел, — диде Албуга Тишек-Ташка җавап итеп. — Шуны онытмагыз: мин — Тәңре углы!

Мондый сүз ишетеп яшьләр тагын да ныграк тынып калгандай булдылар. Хәтта Тишек-Таш та каршы әйтергә сүз таба алмады.

— Шулай булгач, сезнең өчен мин — каган кебек! — диде Албуга дәвам итеп. — Минем сүзем, минем теләгем — сезнең өчен боерык. Күктә кояш балкып торганда мин ант итеп әйтәм: минем егетләрем арасында, миңа буйсынган барлык ирләр арасында моннан соң баш-баштаклар, качаклар, телләшүчеләр булмаячак! Мин, Тәңре углы Албуга, буйсынмаган, телләшкән теләсә кемнең башын чаптырырга боерачакмын. Тотнаксыз, тәртипсез Төпсәнең үлеме сезгә шул турыда искәртеп торсын.

Төпсә исеме чыгу белән, Тишек-Таш ярсып:

— Син аның канын койдың! — дип кычкырды.

— Кан өчен кан койдым! — диде Албуга аңа каршы.

— Син үзең Куяннардан түгел, син — Сөнәнкәдән! — диде Тишек-Таш бирешәсе килмичә.

— Минем әнием, минем дәү әтием — Куяннардан. Сөнәнкәдән мине атам каган куалап җибәрде. Шулай булгач, мин кем ыруыннан булам, Тишек-Таш? — диде тәгин углан.

— Куян ыруыннан! — диделәр егетләр, аны яклап.

Тишек-Таш эндәшмәде.

— Төпсә минем ырудашымның канын койды! — дип кычкырды Адай, абыйсын яклап, ләкин шундук, шүрләп калып, тиз генә аның ягына карап алды.

— Төпсә Куян ыруы абасының канын койды? — диделәр башкалар да, Адайның сүзләрен куәтләп.

— Шулай булгач, йола кем яклы, түрә кем яклы? — дип кычкырды тәгин углан бөтен даланы яңгыратып.

— Йола синең яклы! Түрә синең яклы! — диделәр яшьләр.

Бары тик Тишек-Таш кына авыз ачмады.

— Ник эндәшмисең? — диде аңа Албуга.

— Кичер... тәгин углан, — диде Тишек-Таш әкрен генә, кызарынып.

— «Тәңре углы уң кул тучи бәк»... — диде Албуга аны төзәтеп.

— Аңсызлыгым аркасында сиңа кул күтәреп мин ялгышлык эшләдем. Кичер мине, Тәңре углы уң кул тучи бәк, — диде Тишек-Таш, үкенү белдереп.

— Мине тыңлагыз, Тәңре углы уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга сөйли! — дип кычкырды яшь ир үзенең юлдашларына. — Сез беләсез булыр: комсызлыгы башыннан ашкан Туман каган минем яраткан кызымны тартып алды. Анысы гына җитмәгән, ялганчы төш юраучыларның юравына ышанып ул мине дә, минем әнием Күрекле бикәне дә Ак

127

урдадан читкә сөрде. Сезнең язмыш белән минем язмыш — уртак. Мин тунсам — туңарсыз, миңа җылы булса, сезгә дә җылы булыр. Мин ачыксам, ачыгырсыз, мин тук булсам, сез дә тук булырсыз. Мин кайда гына булсам да, мин кем генә булсам да, сез миңа мәңге турылыклы булырсызмы?

— Булырбыз! — диделәр егетләр дала яңгыратып.

— Син дә турылыклы булырсыңмы, Тишек-Таш?

— Булырмын!

— Барыбыз да! — диделәр Сөнәнкәләр, Тишек-Ташны яклап.

— Антмы? — диде Албуга.

— Ант! — диделәр егетләр, җирне-күкне дер селкетеп.

«Ант» сүзен өч мәртәбә кабатладылар. Албуга кырын күзе белән һаман да Тишек-Ташны күзәтте. Башкаларга кушылып ул да өч мәртәбә «ант!» дип кычкырды.

Яңадан кузгалып китәр алдыннан Албуга Тишек-Ташка эндәште.

— Мин сине кичердем, — диде ул аңа. — Мин сиңа агаң Төпсәнең хатынын, балаларын, үгезләрен, киез өен бирәм.

— Мең яшә, Тәңре углы уң кул тучи бәк! — диде Тишек-Таш каушап һәм куанып.— Үлгәнче колың булырмын, иң кыен чакларында арка таянычың булырмын! Утка каршы су булырмын, суга каршы ут булырмын!

— Кәлтә! — диде Албуга ачык йөзле, озын, таза буйлы чибәр егеткә эндәшеп. — Мин күреп тордым: аңсызлыгы аркасында Тишек-Таш миңа угын төзәгәч, беренче булып син капладың мине. Төпсәнең атын, коралларын сиңа бирәм.

— Моннан соң да сине уктан, сөңгедән саклармын. Кирәк булса, тимер туның булырмын, корыч калканың булырмын! — диде Кәлтә дулкынланып.

Йола буенча Төпсәнең хатыны, балалары, мал-туары — барысы да тәгин угланның үзендә калырга тиеш иде. Әнә ул үзенә берни алмады — барысын да өләште дә бетерде. Йола турында беренче булып Кәлтә искә төшерде.

— Сез соң барыгыз да минем егетләрем түгел мени? — диде Албуга. — Сезгә өлеш чыгару ул минем үземә өлеш чыгару түгел мени?

Сөн илендә әле моңарчы беркемнең дә, бер генә алыпның да, бер генә бәкнең дә үзенә тигән өлештән баш тартканы юк иде. Әнә ул баш тарта. Ник? Усал егетләренең күңелен күрү өченме? Ни генә булмасын, мондый тәгин угланны яклап чыннан да утка да, суга да керергә була!

Кәлтә белән Тишек-Таш та, башкалар да бу мәлдә шулайрак фикер йөрттеләр.

Албуга үзе бөтенләй икенче нәрсә турында баш ватты. Куян белән, Төпсә белән булашкан арада арттан аларны башка алайлар куып җитеп киләләр иде. Аларга берни сиздермичә, тизрәк моннан кузгалып китүдән дә яхшы нәрсә юк. Егетләргә ул үтерелгән куянны, Төпсәнең башын алып тизрәк кузгалып китәргә боерды. Аннары ул Төпсәнең үле гәүдәсен алып качкан атны тотарга, алып килергә, үле гәүдәне, беркемгә күрсәтмичә, берәр аулак җиргә илтеп ташларга кушты. Бу эшне ул Кәлтәгә тапшырды.

— Иртәгә кояш чыкканчы Төпсәнең хатынына, балаларына берни әйтмәскә, — диде Албуга Тишек-Ташка. Аннары ул башкаларга карады. — Төпсәнең кайда, ничек үтерелүе турында иртәгә кояш чыкканчы бездән башка беркем белмәскә тиеш, — диде.

— Тыныч бул, тучи бәк, беркем берни белмәс, — диделәр егетләр бер авыздан.

IX

Бүген көн аяз гына булды. Түбә өстендә кызгылт-алтын кояш эленеп торды, үзәкләргә үтеп көнбатыштан ачы җил исте.

Бүген алар Бәнә дигән күл буенда төн кунарга тиешләр иде. Уймак күлдән Бәнә күлгә чаклы ара бер көннән азрак иде. Күл буена алар кояш баер алдыннан барып җиттеләр. Арбалар бүген иртәрәк туарылды, өйләр иртәрәк корылды һәм учаклар да иртәрәк ягылды.

Төнге торгаклар билгеләүне тәгин углан тулысы белән йөзбашы Җирәнгә тапшырырга булды. Иртәнге бәрелештән соң йөзбашы Җирән сүзсезләнеп, хәтта сулыгып-ябыгып калган иде. Тәгин углан белән алар көне буена диярлек күзгә-күз очрашмадылар. Хәзер менә очрашкач ул тәгин углан янында үзен ничегрәк тотарга белми азапланды. Аның, билгеле, яп-яшь углан алдында түбәнсенәсе дә килмәде, шул ук вакытта ул аңа буйсынмый да булдыра алмый иде.

— Төн уртасына чаклы мин йоклыйм, — диде тәгин углан Җирәнгә. — Мин йоклаганда — торгакларга син җаваплы.

— Шулай итәрбез.

— Минем егетләрне төнгә куйма.

— Тегеләрне дә, үзеңнекеләрнедәме?

— «Тегеләрне» дә, — диде тәгин углан. — Төн матур. Аларның боз өстендә уйныйсылары килә. Мин аларга сүз бирдем.

— Шулай итәрбез, — диде йөзбашы Җирән, бер үк сүзне кабатлап.

Үз өенә, үзенең Табылдыгы янына Албуга бүген күтәренке күңел белән кайтты. Икәүдән-икәү генә сөйләшергә күпме сүз, күпме яңалык бүген! Табылдыкның бүген дә үзен җылы өйдә, ит тулы казан янында якты йөз белән каршы алачагын уйлап ул үзалдына елмаеп куйды. Ләкин үз өе янына җиткәч ул, әнисен исенә төшереп, кырт кына борылды да, каршыдагы биек өйгә таба атлады. Көндез ул әнисен читтән генә күреп китте. Бүген аны ничек тә күрергә, сөйләшергә кирәк иде.

Берничә көн эчендә үсеп, үзгәреп, олыгаеп киткән өлкән углын Күрекле бикә аяк өсте каршы алды.

— Сине бүген мактап телгә алдылар, улым, — диде ул, беренче булып.

— Кемнәр мактады, әни? — диде Албуга, «мактау» сүзенә аеруча күңеле булып.

— Ирләр, — диде бикә. — Күргән кешеләр әйтте: бөтенесен шаккатыргансың син бүген.

— Ә, син аны әйтәсең икән! — дигән булды Албуга гамьсез генә.

— Шуны әйтәм, — диде бикә. — Анысы яхшы булган... ирләр алдында үзеңнең кемлегеңне күрсәтүең. Шулай да син... беренче адымыңнан ук кансыз булсаң, башкалар да качышып бетмәсләрме?

Албуганың куанычлы елмаюы сүрелеп калды.

— Җиткерделәрдәмени, әни? — диде ул төшенке генә.

— Җиткерделәр.

«Димәк, ышанычсыз алар шулай да!» дип уйлады углан ачынып.

— Кемнәр, әни, әйтмәссеңме? — диде ул.

— Кемнәр булсын — Җирән! Минем ышанычлы ирләремнең башларын чаба башласаң, мине кем саклар да кем яклар?

«Җирәнмени? Ул бит берни белми!» — дип уйлады шундук Албуга, җиңел сулап.

— Мин барында, башка балаларың барында сиңа тагын кем кирәк соң, әни?

— Шулаен шулай да, — диде бикә пошынып. — Үзеңне корал белән саклаган, үзеңне туйдырган, карап үстергән кешеләрнең башларын чабарга ашыкма әле син, улым. Чабылган башны кире утыртып булмый.

— Кайгырма, әни! — диде Албуга җиңелчә бер күтәренкелек белән. — Кайчагында шулай куркытып кую да ярый ул! Моннан соң уяурак булыр, йокысын ачыбрак йөрер. Шулай да әйтим инде: аның сиңа килеп әләкләшеп йөрүе миңа ошамый.

— Миңа килмичә, кемгә килсен ул?! — диде Бикә Җирәнне яклап.

— Миңа! — диде Албуга. — Ирләр эше ирләргә генә кагыла.

— Әллә нәрсә булды сиңа, улым, — диде ана кеше аптырап, гаҗәпләнеп.

— Берни булмады. Килештек ич, әни: ирләр эше — миңа, кызлар эше — сиңа, дидек.

— Без алай димәдек бугай, — диде бикә, уйлангандай итеп.

— Әни, минем сиңа үтенечем бар, — диде Албуга. — Минем егетләр бүген кич боз өстенә уенга чыкмакчылар. Кызларыңны чыгармассыңмы — аларга күңеллерәк булыр иде.

Бикә көлеп алды.

— Шуны сорарга кердеңме?

— Шуны.

— Шул да булдымы «ирләр эше!» — диде әнисе. — Яшь егетләр боз өстенә уенга чыкканда кызлар йоклап ятыр дип белдеңме... мин әйткәнне көтеп? Сез аларга бер генә сызгырыгыз — җиде кат сакчыны алдап чыгачак алар!

— Мин үзем чыкмыйм, — диде Албуга.

— Адай сызгырсын, алайса, — диде бикә көлеп.

X

Үзенең хәйләсен Албуга бары Адайга гына әйтте. Беркемгә күренмичә, сиздермичә ул яшьләр арасына чыгарга, аларның, бигрәк тә үз егетләренең нәрсә сөйләшкәннәрен тыңларга булды. Аны: Төпсә турында берәрсе ычкындырырмы-юкмы, дигән нәрсә кызыксындырды. Әгәр дә мәгәр аның егетләреннән берәрсе шул турыда тишкән булса, бүген сүз, аныңча, гел шул турыда гына булачак иде. Төпсәнең үтерелүе турындагы хәбәрнең таралуыннан, таралмавыннан бигрәк, аны бөтенләй икенче нәрсә: егетләрем минем ышанычлымы, юкмы, дигән нәрсә борчыды.

Мондый хәйлә Адайга да ошады. Абыйсына ул хәтта беркая чыгып йөрмәскә кушты, «барысын да үзем эшләрмен, кайгырма!» диде. Ләкин абый кеше барыбер үзенчә итәргә булды.

— Без яшьләр белән уенга чыкмабыз, — диде ул Адайга — Егетләр, кызлар боз өстенә чыккач, беркемгә күренмичә, икебез ике яктан килербез дә, тыңланып йөрербез. Караңгыда безне беркем танымас.

Алар шулай иттеләр дә. Күл өстенә кичке уенга чыгучы егетләргә дә, кызларга да Адай: аягым сызлый, чыкмыйм, диде. Албуганы чакырып килүче булмады. Аның өе, кызы бар лабаса — аңа болай да күңелле!

Күктә тонык кына булып яшь ай балкый, ялт-йолт килеп йолдызлар җемелдәшә иде. Көндез бер үк төсле булып тоелган җир өстенә, куе, озын күләгәләр белән аралашып, көмеш сыман аксыл яктылык таралган. Тигез күл өсте аеруча матур, серле һәм ягымлы. Югарыдан төшкән тонык ай яктысында боз өсте, яхшы шомартылган көзге төсле булып, балкып-җемелдәп ята.

Авыл күл янына килеп урнашу белән, көне буе атта, арбада селкенеп барган бала-чага боз өстенә иң элек сибелә иде. Кечкенәләр арба өстендәге киез өйләренә кайтып йокларга яткач та, боз өстенә олырак балалар, үсмерләр чыгып җыела. Иң ахырда, караңгы төшеп бөтен авыл йокыга талу белән яшьләр чыга. Бикәнең болай да кызларны яшьләр уенына чыгудан тыйганы юк иде. Бүген исә, әл-

кән углының үтенечен истә тотып, кол кызларны тоткарламаска дип, ул бага хатыннарга алдан ук әйтеп куйды.

Бикәнең кызлары да чыккач, боз өстендәге яшьләр күбәеп китте. Күл тирәсендә уен-көлке, күңелле чыр-чу янгырап торды. Кайберәүләр үзләренең якын сердәшләре белән читкәрәк, күләгәлерәк җирләргә елыштылар, кайберәүләр бер тирәдә күмәк уеннар башлап җибәрделәр.

Албуга, капкадан чыгып, туп-туры күл буена юнәлде, кычкырып сөйләшкән, көлешкән егетләрнең сүзләренә еракта ук колак салып, шыпырт кына алар янына барып әйләнде дә, камышлы яр буеннан китте. Ярым караңгыда аңа беркем игътибар итмәде. Никадәр колак салып тыңламасын, шулай да ул беркайда да үзе ишетергә теләгән сүзләрне ишетмәде.

Юк, ышанычлы, бик ышанычлы, ахрысы, аның егетләре. Ант иттеләр бит — шул җитмәгәнмени? Юкка йөри, ахрысы, ул болай әллә нилэр уйлап, кычытмаган җирен кычыттырып. Әнә алар... якында гына. Үзенекеләр дә, «тегеләр» дә. Аларда хәзер Төпсә кайгысы түгел. Яннарында яшь кызлар булганда, ник кирәк аларга Төпсәләр, Тишек-Ташлар... уң кул тучи бәк тәгин угланнар?! Бар нәрсәнең — бар кайгының, бар шатлыкның... яшәүнең, үлемнең төп чыганагы шул ук кызлар, бичәләр, аналар түгелме соң, тәңрем?! Шулар аркасында — ызгыш-талаш, шулар аркасында — яулар... шулар аркасында — бәхет, куаныч... Тормышның, дөньяның бар тоткасы алар түгелме соң, тәңрем?!

Кинәт кенә ул тынычланып калгандай булды. Тик шулай да ул бары үзенең егетләре өчен генә тынычланды бугай. Кызлар, бичәләр, аналар турындагы уйлар аңа икенче нәрсәне — йөрәк итенә ук тимере булып кереп утырган һәм беркайчан да онытылмый, югалмый торган нәрсәне исенә төшерде. Караңгыда үзенә елмаеп карап торган гүзәл Сөенеч турында хәзер аның һич тә уйлыйсы килмәде, ләкин ул — сихри күк кызы — уйлыйсы килү-килмәүгә карамастан, һаман үзен искә төшереп торды, һаман арттан, алдан — бөтен яктан, тирә-юньне нурга күмеп торды.

Өстендәге тире киемнәре ике кат иде, аңа бернинди салкын үтәрлек түгел. Ул туп-туры боз өстенә сузылып ятты да, күккә — айга, йолдызларга карап тынып калды. Элек тә ул, җиргә чалкан сузылып яткан килеш, күкне, болытларны, айны, йолдызларны күзәтергә ярата иде. Күпме генә күзәтсә дә, аңа анда һәрвакыт ниндидер серлелек, яшерен көч һәм ниндидер башка тормыш бар сыман тоела иде. Әнисе белән ачыктан-ачык сөйләшкән теге көннән соң — үзенең Тәңре углы икәнлеген белгән көннән соң — ул күккә, йолдызларга бөтенләй икенче хисләр белән, икенче төрле уй-теләкләр белән карый башлады кебек. Үзе белән күк арасында, ай һәм йолдызлар арасында ул уртаклык, якынлык, туганлык табарга тырышты. Ләкин, күпме генә тырышса да, күпме генә баш ватса да, чынында ул бернинди якынлык, туганлык таба алмады, төпсез күк дөньясының тамчы да серенә төшенә алмады.

Шулай уйланып, онытылып ята торгач ул якындагы камышлыкка таба килгән кемнеңдер аяк тавышларын ишетеп калды. Күккә, бушлыкка омтылган уй җепләре шундук өзелде һәм ул, башын сак кына борып, аяк тавышы килгән якка карады. Алар икәү иде. Монда камышлык арасында үзара серләшү өчен киләләр иде. Менә алар аннан бер ун адым чамасы җирдә туктап калдылар. Озак кына кочаклашып, бер-берсенә сыенып тордылар. Бераздан әкрен генә сөйләшкән тавышлары ишетелде.

— Бикә бирмәсә, мин сине тәгин углан аша соратырмын, — диде егет.

Тавышы таныш сыман тоелды. Бу теге Кәлтә булырга тиеш иде.

— Син — кол түгел, син ирекле. Кол кызны сиңа бирмәсләр, — диде кыз.

— Яраткач бирерләр, — диде Кәлтә, үз-үзенә ышанып.

— Кемгә тели, шуңа бирәчәк бикә, — диде кыз.

Кызы да таныш иде. Артык чибәр дә түгел. Шулай да ягымлы. Түбет кырнагы.

Әллә боз өстендә сузылып яткан карачкыны күреп алдылар, әллә башка сәбәптән, алар монда озак тормады — ашыкмыйча гына каядыр читкә китеп бардылар. Башкалар парлашып, сөйләшеп йөргәндә үзенең шулай качып-посып ятуы, кеше сүзен тыңлап ятуы Албугага бик оятлы, вак һәм кирәксез нәрсә булып тоелды. Аның торасы, тизрәк үз өенә кайтып, үзенең Табылдыгын күрәсе килде.

Аның да кызы — кырнагы бар лабаса! Кол кыз, Кыпчак кызы. Ул да кемнеңдер якыны, яратканы булгандыр. Нинди дәртле, нинди кайнар йөрәкле ул. Яуда арканга эләккән дә, менә хәзер кулдан-кулга йөри. Терлек кебек, кием-салым кебек. Үлгәнче шулай, мәңгегә. Аның да кешечә яшисе киләдер, үз малы-туары, бала-чагалары белән яшисе киләдер.

Бу вакытта аның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Үзенең кызы турында ул чын-чынлап әрнү һәм кызгану белән уйлады. Кайчандыр үзе күз атып йөргән, кайчандыр чын күңелдән яраткан Табылдыгына аның ниндидер яхшылык, изгелек эшлисе килде. Үзен керфек какмый көтеп утырган кызы янына ул ашыгып-ашкынып кайтты.

XI

Сары-су буеннан кузгалып китүгә дүрт көн булды дигәндә алар Диңгез-күлгә якынлаштылар. Уңнан ике, сулдан ике елга килеп кушылган бу күл Сөн җирендә иң зур күлләрдән санала иде һәм шуның өчен дә ул Диңгез-күл дип атала иде дә. Җәй уртасында иртәнге кояш белән бергә кузгалып китеп, көне буе атта чабып барсаң да, кузгалып киткән җиреңә бары кояш баеганда гына килеп житәргә мөмкин. Каршы яктагы ярлары аның күк белән тоташкан һәм, күл өстенә озаклап карап торсаң, бөтен дөньяда судан башка берни юктыр сыман тоела иде. Шундый зур, шундый киң, иркен иде ул Диңгез-күл!

Куе таллыклар, камышлар белән капланган яр буйларында, елга үзәннәрендә, беркемнән, бернидән курыкмыйча киекләр, ерткычлар яши, суларда — күлнең үзендә, елгаларда балыклар мыж килә. Яз көнендә, су өсләре боздан әрчелү белән, бөтен тирә-як монда кош тавышларыннан шау-гөр килеп, яңгырап тора. Бу вакытта Диңгез-күл көньяктан төньякка күченүче кошларның туктап ял итү урынына әйләнә. Кыр казлары, аккошлар, үрдәкләр, һәр төрле су кошлары, оя-оя булып, көтү-көтү булып, бөтен су өстен, бөтен яр буйларын каплап алалар, бер-берсе белән танышып, дуслашып китәләр, я булмаса, киресенчә, көтмәгәндә талашып-ызгышып алалар. Шулай да монда яз көннәрендә күбесенчә дус, тату тавышлар, моңлы-сагышлы тавышлар яңгырый. Бер көтү кош күккә күтәрелү белән, алар урынына ук диярлек, икенче яктан икенче кошлар килеп төшә. Шулай итеп,кошлар базары монда ай буена — төнен-көнен дәвам итә.

Яз көне генә түгел, көз көне дә шулай була. Яз көнендә алар җылы яклардан салкын якларга ашыксалар, көз көнендә салкын яклардан җылы якларга ашыгалар. Бу вакытта инде алар тагын да күбәйгән, ишәйгән булалар, салкын якларда чыккан балалары үскән, канатлары ныгыган була. Алар хәзер ят, яңа җирләргә барып җитәргә ашкыналар — балалар һәрвакыт түземсез була бит.

Кошлар гына түгел, кешеләр дә шулай: яз җиттеме, салкын якка

күченәләр, көзгә таба, киресенчә, җылы эзләп, ышык-аулак урыннар эзләп, көн ягына юл тоталаар.

Бары тик алар гына менә — туган җирләреннән куылган-сөрелгәннәр генә — барлык кошлар, барлык киекләр юнәлешенә каршы якка, кире якка кыймылдыйлар. Ник баралар алар анда — җылы, якты эзләпме, әллә бозлы буранныммы?

Күрекле бикә арбадан төшеп атка атланды. Куянкаен да атка атландырып ул аны башка балаларга тагып җибәрде. Бу якларда — Диңгез-күл буе үзәннәрендә аның үзе генә уйланып барасы килде. Ул, арбалардан, сакчы ирләрдән — барлык күчмә олаулардан уңгарак каерылып, комлы үзәннәр, калкулыклар арасыннан китте. Монда аңа бар нәрсә таныш, якын иде. Бу сулар, үзәннәр, таллык-камышлыклар Туман каганның саклау җирләре исәпләнелә. Ул монда язның беренче көннәрендә балык тотарга, аккошлар, кыр казлары атарга килә дә бөтен урдасы белән, бөтен ил-көн белән монда ике айга якын тора иде. Шуннан соң елның-ел буена бу тирәгә беркем якын китерелми, беркемгә балык тоту, кош-корт ату рөхсәт ителми иде.

Һәр елның яз айларын шушында — куе таллар, камышлар янында кыр казлары, аккошлар шау-шуы арасында уздырганга күрә дә бу тирәләр бикәгә аеруча якын, кадерле. Диңгез-күл буйлары аның күңелендә мәңге яз булып, туктаусыз шаулаган дулкыннар булып, очар кошларның сагышлы авазлары булып сеңеп калган иде.

Олаулардан аерылып бикә шулай да ерак китә алмады — арттан аны йөзбашы Җирән куып җитте. Ул, ахрысы, аны күптән инде күздән югалтмыйча килә иде.

— Безнең арттан кемнәрдер якынлашып килә, бикә, — диде ул, бикәгә кыюсыз гына якынлашып.

Бу вакытта Күрекле бикәнең күңел күгендә яңгыраган аккош тавышларыннан, дулкын шауларыннан башка берни дә ишетәсе килми иде.

— Белештеңме — кемнәр? — диде ул, артына әйләнеп карамыйча гына.

— Белешмәдем,— диде Җирән.

Күндәм, сүз тыңлаучан, шулай да йомшак холыклы йөзбашына бикәнең ачуы килеп куйды. Элек тә шундый булдыксыз иде микән ул, әллә соң Албуга котын алгач кына шундыйга әйләнде микән? Күрәсең, элек тә шундый булгандыр. Кушкан һәр нәрсәне җиренә җиткереп үтәгәне өчен генә ул аңа — бикәгә — яхшы ир, яхшы каравыл башы булып тоелгандыр. Ир, имеш! Симерә башлаган андый ирнең булганыннан булмаганы мең артык.

— Албугага әйттеңме? — диде бикә янә дә артына борылып карамыйча гына.

— Иң элек сиңа әйтим дидем, бикә, — диде йөзбашы Җирән, алгарак чыгып. Аның тавышында кирәгеннән артык серлелек, ягымлылык сизелде.

— Андый хәбәрне иң элек уң кул тучи бәк угланга әйтер идең, Җирән. Өлкән углым белән минем арага чөй кагарга җыенмыйсыңдыр ич син?

— Мин синең белән тәгин углан арасына чөй кагарга җыенмыйм, бикә. Мин, бикә, синең белән икебезнең арадагы чөйне... шырпыны алып ташлар идем.

— Анысы тагын ни була инде? — диде бикә, берни аңламаган булып.

— Анысы, бикә, шул була, — диде йөзбашы Җирән көттеребрәк. — Син миңа суындың кебек, мине читләштерә башладың кебек. Шуны әйтмәкче идем мин.

Бикә беравык эндәшмичәрәк барды. Ул аның нәрсәгә ишарәләвен

сизенми булдыра алмады, шулай да берни сизенмәгән булып күренү яхшырак булыр дип уйлады. Элегрәк йөзбашы Җирән үзенең бикәсе белән мондый нәрсәләр турында сөйләшергә батырчылык итми иде. Күрекле бикә — каганның өлкән бичәсе иде, аның тагын якын кешесе бар иде. Менә хәзер аларның берсе дә юк: каганы да, якын дусты да. Шуңа күрә әрсезләнә дә бу йөзбашы Җирән!

Шулай да бикә үзенә буйсынган алып ирнең бер-ике сүз белән авызын томаларга ашыкмады. Кем белә киләчәкне — аның хәлендәге тол хатынга бик үк кырыс булу да килешеп бетми кайчагында!

— Нинди суыну, нинди читләшү турында сөйлисең син, Җирән? — диде ул уйчан гына. — Минем сиңа суынганым да, җылынганым да юк. Кайгым башымнан ашкан чакта... кайчагында тупас күренәмдер. Өлкән углыма мин әйттем. Шулай да син аның үзе белән килешергә тырыш.

— Мин ул турыда әйтмим, бикә! — диде Җирән.

— «Яратам» дип әйтмәкче буласыңмыни соң, Җирән? — диде бикә бик җиңел генә һәм тук, шома битле юан ирнең күзенә карап, көләргә керешеп китте.

Бикә, бала-чаганың берәр ипсезлегеннән, йомшаклыгыннан көлгән кебек, дусларча шаяртып көлде. Ләкин ир кешегә бу мыскыллы көлү булып тоелды.

— Көлмә, бикә! — диде ул хурланып, мескенгә сабышып.

— Көлмичә! — диде бикә. — Минем яшьтә, синең яшьтә... нинди ярату инде ул? Мин сиңа яшь кыз бирермен.

— Ярар, мин китим әле, — диде Җирән, атын кырт кына борып. — Мин, бикә, ялганладым. Котлуг бәк куып килә безне арттан.

Бикә дә атын кырт кына кире борды.

— Син, йөзбашы, нишләп аны башта ук әйтмәдең? — диде ул, гаҗәпләнү катыш ачу белән.

— Курыктым, бикә, — диде Җирән чын күңелдән: — Куркак та түгел кебекмен. Шулай да менә курка башладым... синнән.

— Күрәсең, чыннан да яратасыңдыр син мине, Җирән! — диде бикә, янә дә көлгәндәй итеп.

«Ярату» сүзен ул тагын да бернинди хиссез-тойгысыз әйтте, яратуга катнашы булмаган бөтенләй чит нәрсә турында сөйләнгән кебек кенә итеп әйтте. Ләкин Җирәнгә шул да җитә калды.

— Яратмаган кая ул, бикә!

— Бикәңне яратуың яхшы, Җирән, — диде бикә, җиңелчә шелтә белән.— Котлуг бәк турында нишләп башта ук әйтмәдең — менә анысы аңлашылмый.

— Урдадан үпкәләшеп киткәнгә, күңеленне кырасым килмәде, бикә, — диде йөзбашы Җирән.

— Үпкәләшсәк, килешербез! Туган атам ич ул минем!

— Нишлик соң, бикә, берни булмагандай бара бирикме, каршыларга алай җибәрикме? — диде Җирән.

— Тәгин углан белән киңәш. Ул ничек әйтә, шулай эшләрсез.

— Тагын «тәгин углан!» — диде Җирән ризасызлык белән. — «Яратам» дигәндә дә син иң элек аның белән киңәшерсең төсле, бикә!

— Киңәшми дә булмас, йөзбашы Җирән... «яратам!» дип әйтергә туры килсә... — диде бикә елмаеп. — Минем бар тоткам — углым.

— Беләм, беләм! — диде Җирән ашыгып. — Әйтсәм — әйтим, бикә: мин аннан ныграк куркам. Ул бик кансыз күренә.

Сүзне озайтасы килмичә ул, атын куалап, бикәдән ерагая башлады. Аның шулай китеп барышлый гына Албугага карата «кансыз» дип әйтүе ана кешенең өстенә салкын су койгандай булды. Аңың үз улын яклыйсы килде, ләкин аны яклардай сүз дә табылмады. Өлкән углының кырыслыгы, кискенлеге аның үзенә дә бик ошап җитмәде. Үз го-

НУРИХАН ФӘТТАХ ◀ СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР ◀

мерендә урдада, далада ул һәртөрле кырыслыкларны, кансызлыкларны күп күрде, тик шулай да ул үз углының хәзердән үк, шундый яшьтән үк кансыз, кырыс булуын теләмәде.

Бикәнең күңеле урыныннан купты. Аның инде баягыча үзе генә уйланып та барасы килмәде, Җирән артыннан да ияреәсе килмәде. Атын әкрен генә атлатып ул ерактагы олауларга таба китте. Күп тә үтмәде, аңа каршы ике атлы чабып килгәне күренде. Бу аның Куянкае белән Кече-Тае иде.

— Әни! Әни! — дип кычкырдылар балалар ерактан ук, бер-берсен уздырырга тырышып.

Балаларның үзе янына килеп җитүләрен бикә елмаеп көтеп торды. Аларның шат, тере кыяфәтләрен күрү белән, шат, көр тавышларын ишетү белән аның күңелендәге борчулы уйлары шундук юкка чыкты.

— Әни, безнең олы абый Җирәннең башын чаба язган! — диде Кече-Тай сер итеп.

— Чапкан инде! — диде Куянкай.

— Аныкын түгел, Төпсәнекен чапкан ул! — диде малай.

— Ни сөйлисез сез?! — диде бикә коты алынып.

— Чапкан, чапкан! Бәлкә-абый үзе әйтте — ишетеп тордым, — диде малай мактанып.

Бикә, иреннәрен кысып, сүзсез калды. «Булыр. Әйтәм чыш-пыш киләләр үзара! Барысы да булыр аннан!» — дип уйлады ул каушау һәм шомлану белән.

XII

Ак өйнең ишеге янында кыйнаганда Туңгак алыпның кулын имгәттеләр, базга ташлаганда ул ялгыш басып аягын тайдырды. Авыртуга түзә алмыйча ул бик каты итеп кычкырып җибәрде. Ул көнне ул арыганчы, тамагы карлыкканчы кычкырды. Базның тар авызы ике-өч кат калын киез белән капланган иде. Аны хәтта якындагы сакчылар да ишетмәделәр.

Кычкырып бары үзенең хәлен генә бетергәнлеген ул бик соңлап аңлады һәм, тешен кысып, шундук тынып калды. Моннан берничек тә чыгып та, качып та булмаганлыгын ул бик яхшы белде, шуңа күрә ул түзәргә — барлык газапларны, барлык авыртуларны онытып түзәргә дигән карарга килде.

Ул үзен тамчы да гаепле санамады. Каганга ул турылыклы хезмәт итте. Аның тынычлыгын, аның иминлеген саклап, аның йокысы тыныч булсын дип, авызына капкан сыныгы аркылы утырмасын дип, үз-үзен аямыйча хезмәт итте. Аның турылыклы, булдыклы булуын каган үзе дә белмәде түгел. Шуңа күрә дә ул аны беркайчан да кыерсытмады. Ул аны өйләндерде, өй бирде, мал-туар бирде. Яуда аңа телем чыгарды. Күңеле аеруча күтәренке чакларда ул аңа үзенең кол кызлары янына барырга да ирек куйды. Менә шуңа күрә ул әлеге эштә берничек тә каганны гаепли алмады.

Юк, бөек Туман каганны гаепләргә бернинди сәбәп юк иде. Барысын да ул Исәнтәйдән күрде. Исән-сау котыла алса, чыга алса шушы баздан, иң әлек ул аның бугазын чәйнәп өзәчәк, иң әлек аны изеп ташлаячак. Аннан соң инде үлсәң дә, терелэй җиргә күмелсәң дә үкенечле булмаячак!

Сөн түрәләрен ул яхшы белә иде. Түрә буенча, гаепле дип уйланылган бер генә кешене дә яргуламыйча — хөкем итмичә мәңге базда калдырмыйлар иде. Аны да кайчан да булса бер чыгарырга, яргуларга тиешләр иде. Чыннан да, ике тәүлектән соң аны да баздан тартып алдылар. Бу ике тәүлек эчендә аңа ашарга да, эчәргә дә бирелмәде.

Якты дөньяга чыкканда ул танымаслык булып үзгәргән — ябыккан, хәлсезләнгән иде.

Үзенең кирәгеннән артык кызып китүен аңлаган каган атаклы алыбының хәтерен калдыруы өчен үкенә дә башлаган иде. Ул инде аны аклау, яңадан үз урынына кую турында да уйлаштыра башлаган иде. Ләкин таш кыядай таза, көчле ирнең ябыгып, шешенеп, ямьсезләнеп калуын, җитмәсә бер аягына аксаклавын, уң як санының йөрмәвен күреп, аның шундук күңеле кайтты. «Эше беткән моның. Бу инде бернигә яраксыз», — дип уйлады ул. Мәгез, теләсәгез нишләтегез, дигән сыман ул аны яргучыларга тапшырды.

Сөн илендә иң зур хөкем — яргу эшен ыру башлары — Куян ыруыннан Котлуг бәк, Алан ыруыннан Барыс бәк, Сөйбү ыруыннан Тук-Тимер бәк башкара иде. Яргучылар аны барлык шартларына туры китереп хөкем иттеләр. Сорашу-белешү өчен таныклар чакырттылар, җентекләп үзеннән, таныклардан сораштылар. Иң ахырда яргучыларның өчесе дә аны — Туман каганның каравыл агасы Туңгак алыпны дунху бәге Начин нойонның качып китүендә гаепсез дип таныдылар. Туңгак алыпка буйсынган кораллы торгаклар бары тик боҗра эчендәге кешеләрне, өйләрне генә сакларга тиеш иде. Дунху бәгенең авылы боҗрадан бер ук чамасы читтә, ялан кыр уртасында ялгыз утырганлыктан, аның качуында-качмавында каравыл агасы Туңгак алыпның бернинди катнашы була алмый иде. Инде дунху бәген куып тота алмаган икән, монда шулай ук аны гаепләп булмый. Дунхуларны ул җиңеп, мал-туарларын, кешеләрен кулга төшереп кайткан, — шулай булгач, үз бурычын намус белән үтәгән. Начин нойонның качып котылуы — Туңгак алып эше түгел, анысы — Тәңре эше.

Туман каган яргучыларның карарына каршы берни әйтмәде.

— Аклануың белән котлыйм, Туңгак алып, — диде ул атаклы колының күзенә карап. — Тик мин сине кая куйыйм хәзер? Мин сине өлкән бичәм Күрекле бикәдән алган идем. Биргәнен кире алсын. Син, Котлуг бәк, илтеп тапшыр кызыңа. Өстеңдәге киемнәрең үзеңә булыр. Коралларыңны да кире кайтарып бирерләр. Мин биргән хатының, хатыныңның балалары, мал-туар, атың, өең — барысы да монда калыр.

Туман каган шулай диде. Бөек Туман каган шулай боерды. Аяк астына егылып еласаң, күз яшьләреңне түгеп ялварсаң, бәлки, ул аны кызганган да булыр иде — аты белән хатынын, балаларын, бәлки, үзенә дә бирер иде. Ләкин ул — бөтен Сөн илендә атаклы алып, каганның арка таянычы булган Туңгак алып елый да, ялвара да алмады. Тешен кысып, әрнегән, кан тамган йөрәген йөгәнләп ул үз-үзен ташка, агачка әйләндерде.

Кызы Күрекле бикәнең бу батыр колны яратуын Котлуг бәк белә иде. Ул аны үзе дә якын күрә иде. Каган кушкач ул аны бик теләп үзе янына алды. Юлга чыкканда Туңгак алып атка атланырлык хәлдә түгел иде. Котлуг бәк аны ике тәгәрмәчле җиңел арбада алып бармакчы булды. Туңгак алып, Исәнтәйнең ике тәгәрмәчле, түбәсе ябулы арбасын күз алдына китереп, арбада юлга чыгудан баш тартты. Аның өчен ике атны парладылар да, атлар арасына бишек сыман итеп киез тарттырдылар — сугышта авыр яраланган ирләрне шулай йөртәләр иде. Юл буена ул киез бишек өстендә тирбәлеп килде.

Коточкыч ябыккан, агарынган, бетеренгән ярым-йорты ирне — үзенең яшерен ирен, икенче ирен күреп бикә телсез калды. Янындагы атасыннан, балаларыннан, ырудашларыннан тартынмыйча, бар нәрсәсен онытып ул кайгысыннан еларга тотынды. Ул аның салкын, хәлсез күкрәгенә капланып елады, җансыз ит сыман салынып торган гарип кулын тотып карый-карый, очлы, сөякчел яңакларын сыйпый-сыйпый елады.

Туңгак алып үзе берни эндәшмәде. Кызганыч йөз белән ул, иреннәрен кысып, телсез кеше сыман тик басып торды. Үзе турында ул шулай

ук берни сөйләмәде. Аның турында барысын да Котлуг бәк сөйләде.

Бүген кичкә Диңгез-кул янына барып җитәргә ашыкса да, Күрекле бикә шунда — Туңгак алып белән, әтисе Котлуг бәк белән очрашкан җирдә авыл корырга боерды.

XIII

Котлуг бәк үзенең кышлавына ашыга иде. Аның үзе белән мең кешелек алае бар. Аңа әле кайтып ун меңләп кораллы чиру җыярга һәм тиз арада кире юлга да чыгарга — каган билгеләгән вакыттан да соңга калмыйча, Урта кичүгә барып җитәргә кирәк иде.

Күрекле бикә атасын, ырудашларын яхшылап сыйларга, кунак итәргә булды. Ул үзенең зур өен корды, күп итеп ит суярга кушты. Үзенен ак өенә ул бары атасы Котлуг бәк белән аның атаклы алыпларын һәм үзенең якын туган-тумачаларын гына чакырды. Башка ырудашларын бүтән өйләрдә сыйладылар.

Бикәнең ак өендә аштан соң ата белән кыз, туган-тумача озак кына сөйләшеп-киңәшеп утырдылар. Киңәштә уң кул тучи-бәк тәгин углан белән Туңгак алып та катнашты. Тик алар, бернигә кысылмыйча, тыңлап кына утырдылар. Чынында бу алай олы киңәш тә булмады, бу бары ата белән кыз арасындагы бер сөйләшү-аңлашу гына булды. Алар бер-берсенә үзләренең үпкәләрен әйттеләр, моңарчы кузгатылмаган нәрсәләрен искә төшерделәр һәм әйтешә-әйтешә, чак-чак кына бозылышып китмәделәр. Бикә атасын каган белән ныграк: катырак була алмауда, өлкән кызының урынын-дәрәҗәсен саклап кала алмауда гаепләде. Котлуг бәк исә үзен акларга мең төрле сылтау тапты, иң ахырда картлыкка, тегесенә-монысына зарлана башлады. Шулай да алар үзара уртак фикергә килгәндәй булдылар — киләчәктә нишләү, кайда, кайчан очрашу турында килештеләр. Котлуг бәк яуга китәр алдыннан Байык буена — кызы белән тәгин угланның яңа кышлавына сугылып китәргә булды. Ике арадагы килешү шуннан ары узмады.

Ашап туйгач, кызы белән шулай бер иркенләп сөйләшкәч, Котлуг бәк, кичкә каршы булуына да карамастан, юлга чыгарга булды. Үзләренә кирәкле азыкны алар алдан көтү итеп куалап алып бармыйлар иде. Биш көнгә җитәрлек азык-төлекне алар капчыкларга салып, үзләре белән алганнар иде. Шуңа күрә алар бертуктамый төнен-көнен юлда була алалар иде.

Өлкән бичәсеннән туган өлкән кызыннан Котлуг бәк күптән аерылган иде инде. Аның да, Туман каганныкы кебек, дүрт бичәсе, йөзләгән кырнагы бар. Аларның балалары, балаларының балалары үзләре генә дә бөтен бер ыру, бөтен бер гаскәр булырлык. Ул аларның барысын да ярату-кайгырту түгел, күбесен инде онытып та бетергән иде. Шулай булса да, Керүлән буендагы урдасында аның барлык бичәләреннән, барлык кырнакларыннан, кызларыннан ныграк яраткан кол кызы бар иде. Кем белә, бәлки, ул да шуның янына, бәлки чыннан да яуга... үзенең үлеменә ашыгадыр?

Чәчләре агарган, тавышы карлыккан, шулай да үзен элеккечә батыр, киң күңелле һәм яудан-сугыштан башка, аттан-коралдан башка бар нәрсәгә карата үзен өстен тотарга тырышкан атасын озатканда Күрекле бикәгә бераз гына моңсу булып калды. Аңа алар соңгы кат очраштылар һәм соңгы кат саубуллаштылар шикелле тоелды.

Үзенең уллары белән, кызы Куянкай белән бергәләп бикә атасы Котлуг бәкне һәм ырудашларын бик озак җир озата барды. Аларга Туңгак алып та иярде. Уң як саны бөтенләй диярлек йөрмәсә дә, ул атка атланырга теләде. Иярга аны ике яктан да тотып атландырдылар. Бер җайлап утыргач ул ат өстендә әйбәт кенә барды.

131

Котлуг бәкне озатып куйгач алар җыйнаулашып кайтыр якка борылдылар. Балалар, бер-берсен узарга тырышып, алдан чапты. Бикә белән Туңгак алып арткарак калдылар. Икәүдән-икәү генә калгач, бикә, кызгану белдереп:

— Авыртынмыйсыңмы? Бик кыен түгелме? — дип сорады.

— Синең янда миңа яңадан канат үскәндәй булды, — диде Туңгак алып.

Бу аның очрашканнан соң бикәгә авыз ачып әйткән беренче сүзе булды.

— Мин сине телсез дә калгансыңдыр дип уйлаган идем — ялгышканмын икән!

— Минем бары шул телем генә исән калды да инде.

— Башың да, йөрәгең дә исән түгелмени?

— Башымны ашадылар, йөрәгемне аяк астына салып таптадылар.

Элек тә ул кайчагында шулай усал, төртмә телле була торган иде. Хәзер исә аның сүзләрендә усаллык кына түгел, әрнү дә, көчсез ярсу да һәм агулы зәһәр дә бар иде. Ләкин бикәнең хәзер бер дә алай сөйләшәсе килмәде. Ул аңа җавап кайтармады һәм, аның тынычлануын көтеп, бераз җир эндәшмичә барды.

— Яшьлек менә шунда үтте инде! — диде ул бераздан, ерактагы су буйларына, таллыкларга күрсәтеп.

— Безнең яшьлек әле башлана гына, бикә, — диде Туңгак алып, ачы елмаеп.

Ул әле тынычланмаган иде бугай. Аның усаллыгы бикәнең ачуын китерә башлады.

— Миннән үч алырга уйлыйсың, ахрысы, син, — диде ул, чак-чак кына үртәлеп.

«Син» дигәч ул тагын нидер әйтмәкче булды — әйтмәде, ләкин, аның ни әйтергә теләвен чамалап, Туңгак алып шундук эләп алды.

— ... кол! — диде ул бикә булып.

— Әйе, кол! — диде бикә ачу белән.

— Үлемнән баш тартып булмаган кебек, мин үземнең коллыктан да баш тарта алмыйм, бикә,— диде Туңгак алып.

— Син мине елатырсың, ахрысы, — диде кинәт бикә йомшап. — Урдадан куылганда да, юлда да мин гел сине уйладым. Очрашкач менә сөйләшеп тә булмый.

— Сөйләшик, — диде Туңгак алып.

— Нәрсә дидем әле мин? — диде бикә шундук җанланып. — Яшьлек шушында узды дидем бугай. Нинди тын монда! Кышын минем бу якларда булганым юк. Яз көннәрендә нинди күңелле монда! Менә шул инде ул яшьлек — аккош тавышыдай моңлы, сагышлы, яңгыравыклы яшьлек...

— Шулай да мин ул яшьлеккә кире кайтмас идем,— диде Туңгак алып. — Минем өчен яшьлек — тамуг булды. Синең яшьлек белән минем яшьлекне чагыштырып булмый. Яшьлекне генә түгел, бөтен тормышны. Синең көнең байлыкта-муллыкта үтә, минеке...

— Синең белән бөтенләй сөйләшеп булмый!

— Сөйләшмик, — диде Туңгак алып.

— Сөйләшеп тә булмагач, нәрсәгә генә кирәк соң син миңа? — диде бикә, Туңгак алыпның үзе кебек төртмәле итеп.

Мондый ачы сүзләр күңеле китек ирнең шундук кытыгына тиде. Ул бөтенләй йомылып, сүзсезләнеп калды.

— Үткәннәрне искә төшермик, бикә, — диде ул бераздан, үтенеч тә, килешү дә сиздергән бер йомшаклык белән. — Элеккеләр әле бетмәгән, яңасы башланмаган.

— Син холыксыз бала кебек, — диде бикә ачусыз гына.

— Бала... балалар,— диде Туңгак алып көрсенеп.

Ул үзенең тегендә калган балаларын, хатынын исенә төшерде. Аңа тагын күңелсез булып китте. Нәрсә генә уйлама, нәрсә турында гына сөйләшмә — күзгә күренмәс очлы шырпы булып, тупас сөңге булып, һәрбер сүз, һәрбер уй сулкылдап торган яралы күңелгә барып төртелде.

— Балалар турында ишетәсең килмимени? — диде бикә аның «бала, балалар» сүзен үзенчә аңлап.

Алып ир эндәшмәде. Элек ул бикәнең балалары турында яратып тыңлый торган иде. Аеруча ул аның өлкән углы белән — аның сөйләгән сүзләре, эшләре-кыланышлары белән кызыксына иде. Җае чыкканда, тәгин углан белән икәүдән-икәү генә калганда ул аңа төрле яулар турында сөйли, аны ук-җәя, сөңге белән эш итәргә өйрәтә һәм әледән-әле аңа киңәшләр бирә торган иде. Күптән инде алар арасында нык-лы бер дуслык, якынлык урнашкан иде.

— Балалар турында сөйлә, бикә, — диде ул бераздан.

— Үзгәрде минем өлкән колыным, — диде бикә. — Колын түгел, тайга әйләнде. Кире, үзсүзле тайга әйләнде. Субашы булгач та, беләсеңме, нишләгән ул?

— Нишләгән? — диде Туңгак алып кызыксынып.

— Җирәннең башын чабам дип янаган!

— Кара син?!

— Мин курка башладым әле аннан. Җирәнгә янап кына калган, икенче бер ирне... Төпсә дигәнен чабып үтергән!

— Шулай укмыни?!

— Тегесе кырда куян аткан булган. Шуның өчен, — диде бикә, тизрәк углын акларга ашыгып. — Нишләргә дә белмим. Үз баласын ашаган эт кебек... Юк-бар өчен үз ирләрен үзе үтерә торган булса, нишләр ул киләчәктә? Ярый әле син... кайттың. Ул сине генә тыңлый, ахрысы.

— Тыңлый, — диде Туңгак алып, эчке бер сөенеч белән.

— Син аңа әйт, Туңгак. Баш чабу белән шаярырга ярамаганлыгын үткәзеп, сеңдереп әйт!

— Баш чабарга мин өйрәттем аны, бикә, — диде Туңгак алып тыныч кына.

— Үз ирләрен чабып үтерергәме? — диде бикә шаккатып.

— Баш бирми торган, буйсынмый торган ирләрне! — диде Туңгак алып. — Йолага, түрәгә каршы килүче, тәртип бозучы ирләрне бернинди кызганусыз юк итәргә мин өйрәттем. Киләчәктә каган буласы, ил башы буласы кешенең күңеле — йомшак, кулы — каты булырга тиеш, дип мин тукыдым аңа, бикә! Илдәге бар башбаштаклык, бар бозыклык каганның үзеннән башлана. Бәкләр, аксөякләр, каралар барысы да каганнан, үзен Тәңре углы дип атаган кешедән үрнәк алалар, аның яман якларын да, яхшы якларын да кабатлыйлар. Син өлкән углыңның Туман каган кебек булуын теләмисеңдер ич, бикә?

— Теләвен теләмим... Шулай ук мин аның сиңа ошавын да... сиңа кирәгеннән артык ышануын да теләмәс идем.

— Алай булса, мин аны бөтенләй күрмәскә, аның белән очрашмаска тырышырмын. Мине ерактагы берәр авылыңа көтүче итеп җибәрсәң, миңа шул җиткән, — диде гарип ир тирән бер төшенкелек белән.

— Сине кая кую — анысы минем эш! — диде бикә дә ачулы итеп.— Көтүче итеп куярмынмы мин сине, юкмы, әлегә үзем дә белмим. Ни генә булмасын, мин сиңа уң кул тучи бәк тәгин углымны котыртырга, аны яманлыкка, кансызлыкка өйрәтергә моннан соң юл куймам дип уйлыйм.

— Кайчагында... кирәкмәгәндә бик изге син, бикә! — диде Туңгак алып мыскыл белән. — Каган сине аерып, куалап җибәрде, уң кул ту-

чи бәк тәгин углын читкә типте, мине менә кулсыз-аяксыз калдырды. Кем кансызрак соң? Минме, каганмы?

— Син каган белән минем углымны бутама! — диде бикә, чын-чынлап ачулана башлап. — Туман каган кансыз булган өчен генә мин үз углымның да ерткыч булуын теләмим! Сөйләмә син миңа юк-бар нәрсә!

— Ярар, сөйләмәм, — диде Туңгак алып, ясалма бер күндәмлек белән.

Алар, үпкәләшкән балалар кебек, шактый озак эндәшми бардылар.

— Без юкка кычкырышабыз, ахрысы, — диде Туңгак алып бераздан, тынычлана төшеп. — Мин дә аның кеше үтерүче булуын теләмим. Шулай да Төпсәнең башын чабып ул дөрес эшләгән! Ул аны бүтәннәргә сабак булсын өчен эшләгән! Син менә шуны аңлый алмыйсың, бикә!

— Аңлыйм да кебек мин аны, — диде бикә дә, тынычлана төшеп.— Аңласам да... куркам. Ак урдада тәхеткә утырасы углыннан үз анасы курка торган булгач...

— Мин дә куркам, бикә,— диде Туңгак алып, аның сүзен бүлеп. — Мин аның кансызлыгыннан курыкмыйм. Мин аны тәхеткә утыра алыр микән, юк микән дип куркам!

— Сөйләмә юкны! — диде бикә кызарынып.— Ул — уң кул тучи бәк тәгин углан. Йола, түрә[1] аның ягында.

— Йола, түрә — каган кулында. Тәңре дә аның яклы, — диде Туңгак алып.

Бикәне иң куркытканы, иң өркеткәне, барлык тынычлыгын, барлык өметен-ышанычын какшатып, туктаусыз эчен тырнап торганы нәкъ менә шул нәрсә — тәхет мәсьәләсе иде. Шуңа күрә дә ул бу турыда авыз ачып сөйләү түгел, хәтта уйларга да курка иде. Туңгак алып, аның күңел ярасын бик яхшы белсә дә, сүзне әнә туп-туры шуңа китереп терәде.

Бикә караңгы йөзен кая куярга белмичә, бик озак эндәшми барды.

— Син инде... бетте дип уйлыйсыңмыни? Ул да, мин дә беркайчан да кире урдага кайта алмабыз дип уйлыйсыңмыни? — диде ул янәшә барган иргә карамыйча гына, эчке бер өметсезлек белән.

— Бөтенләй үк бетмәгәндер дә... — диде Туңгак алып. — Көчне көч белән генә җиңеп була. Каганда — көч, тәгин угланда көч юк. Көч миндә бар, бикә!

— Синдә?!

Туңгак алып күз алдында үзгәреп китте. Аның ябык, ачулы чыраенда дәрт һәм омтылыш чагылды. Ул бикәнең мыскыллы сүзләрен бөтенләй ишетмәде дә.

— Миндә, бикә, тау-ташларны актарып ташлардай ярсу бар, көч-куәт бар! Миндә, бикә, бер бөртекне мең бөртеккә әйләндерә алырдай осталык бар!

— Каганны җиңү өчен ярсу белән осталык кына аз,— диде бикә кырт кисеп.

— Әнә анда тик яткан көчләр бар! — диде Туңгак алып каядыр сулга, караңгы таулар ягына күрсәтеп.

— Син саташа башладың бугай, Туңгак алып. Анда бернинди көч юк, анда — таулар да урманнар, — диде бикә.

— Юк, саташмыйм, бикә! — дип кычкырды Туңгак алып ярсып. — Таулар, урманнар артында күп санлы, таркау дунхулар бар. Җир йөзендә Сөн каганын җиңсә алар гына җиңәчәк. Бары алар гына — таланган, кыерсытылган, түбәнсетелгән дунхулар, кыпчаклар, хакаслар,

---

[1] Түрә — борынгы төркиләрдә билгеле тәртип кагыйдәләре. Закон.

түбетләр — барлык каралар, коллар гына, бикә! Мин аларны изге яуга күтәрәчәкмен, алар булышлыгында мин синең өлкән углың Албуганы Ак өйдәге алтын тәхеткә утыртачакмын!

XIV

Төнне алар Диңгез-күлдән биш-алты чакрым читтә уздырдылар. Икенче көнне иртүк юлга чыктылар — һәркемнең тизрәк күл янына барып җитәсе, таныш, кадерле җирләрне күрәсе килде.

Албуга, Адайны һәм үзенең егетләрен алып, барлык кешедән алдарак китте. Бикә белән балалар, Туңгак алып һәм башка ирләр бераз алардан калышып чыктылар. Туңгак алып бүген атта яхшырак утыра сыман. Шулай да әлегә аның караңгы йөзендә бернинди куаныч чаткысы күренми иде. Ул, ахрысы, бик нык авыртына. Бикә белән бергә, аның янәшәсендә генә барса да, бүген ул үзен чит кеше, артык кеше кебек тотты.

Күл буена барып җитәргә бер-ике чакрым кала каршыга килүче ниндидер атлылар күренде.

— Кемнәр соң болар? Күл сакчылары микән? — диде бикә, атын тыя төшеп. — Җавап көткән сыман ул Туңгак алыпка карап алды.

— Болар бездән алда киткән угланнар, — диде Туңгак алып. — Мин әле синнән яхшырак күрәм, бикә.

Аның бу кечкенә мактануында кичәге кебек төртмәлек, эчке бер зәһәрлек сизелде. Бикә эндәшми калды.

Чыннан да, Туңгак алыпның күзләре яхшырак күрә булып чыкты. Якынаеп килүче Албуга белән Адайны танып, бикә гаҗәпләнми булдыра алмады. Менә алар килеп җиттеләр, икесе дә баш иеп, башта әниләре белән, аннары Туңгак алып белән исәнләштеләр. Албуганың йөзе караңгы иде. Алсу йөзендә балаларча шатлык нуры балкып торса да, Адай да, абыйсына охшарга тырышып, калын иреннәрен кыскан һәм йөзенә кайгы билгесе чыгарырга тырышкан иде.

Бикә тыела алмыйча көлде.

— Бүген ирләрнең барысының да йөзләре чытык. Ни булды сезгә? — диде ул.

— Минеке чытык түгел, әни, — диде Адай акланып.

— Сакчылар күл буена бер уктан да якынрак килмәскә кушалар,— диде Албуга, әнисеннән бигрәк Туңгак алыпка карап.

— Син нишләргә булдың соң, улым? — диде бикә.

— Мин синең сүзеңне көтәм, әни, — диде Албуга.

— Башларын чабарга кирәк булыр, улым, — диде бикә шаяртмакчы булып.

— Кирәк булса, чабармын, әни,— диде Албуга әнисенең шаяртуын ошатмыйча.

— Син дәме? — диде бикә уртанчы улына карап.

— Яу булса, мин абый яклы, — диде Адай.

— Син... яу остасы, кем яклы? — диде бикә беркемгә катнашмыйча бер читтәрәк торган алып иргә эндәшеп.

— Мин угланнар яклы, бикә, — диде Туңгак алып.

— Мин әлегә угланнарның нәрсә яклы икәнлекләрен белмим, — диде бикә көлеп.

— Шуңа күрә киңәшергә кирәк, — диде алып ир.

— Киңәшик, — диде Албуга.

— Мин дә! — диде Адай ашыгып.

— Мине катнаштырасызмы соң? — дигән булды бикә.

— Яу эше ирләргә генә кагыла. Киңәш таркалмасын өчен өч кеше дә җитә, — диде Туңгак алып.

— Минем балык ите ашыйсым килә! — диде бикә. — Күл уртасына алачык корып, балык тотып, балык итен ашамыйча мин Диңгез-күл буеннан кузгалып китмәячәкмен!

— Минем дә балык ите ашыйсым килә! — диде Адай.

Албуга түземсез энесенә ачулы күз карашы ташлап алды.

— Күл сакчыларын без бер селтәнүдә юк итә алабыз, — диде ул «киңәшә» башлап.— Шулай да мин ул балык өчен ун кеше каным коярга киңәш итмим.

Ул әле энисенә, әле Туңгак алыпка карап сөйләде.

— Син дөрес әйттең, олуг тучи бәк тәгин углан! — диде Туңгак алып. — Кеше каны балык каныннан кадерлерәк.

— Сез шулай да минем теләкне искә алмыйсызмыни, «киңәшче»-ләр? — диде бикә ашыгып.

— Синең теләкне дә искә алабыз, бикә,— диде Туңгак алып.— Олуг бикәнең балык ашыйсы килә. Балыкны каганның кораллы ирләре саклый. Кораллы ирләр белән сугышырга ярамый. Мондый чакта нишләргә кирәк, олуг тәгин углан?

— «Дошман» белән сөйләшеп карарга кирәк. Илче җибәрергә, — диде Албуга.

— Дөрес! Үзем илче булам. Сез мине озата барырсыз, — диде Туңгак алып угланнарга.

— Мине кая куясыз? — диде бикә.

— Бикә түрдә генә утырырга тиеш. Балык китергәнне көтеп, — диде Туңгак алып, атын кузгатып.

— Без үзебез, әни! Син борчылма! — диде Албуга.

— Үзебез генә, үзебез генә! — диде Адай, барысыннан алгарак чыгарга тырышып.

XV

Диңгез-күлнең һәр ягына, бер-берсеннән билгеле ара калдырып, унике өй утыртып куелган иде. Унике өйдә үзләренең хатыннары, балалары, мал-туарлар белән кораллы ирләр-сакчылар яши. Күлнең изгелеген, аннан да бигрәк, бу җирләрнең каганныкы икәнлеген яхшы белгәнгә, беркем дә бу тирәгә тора салып терлек сугарырга да тукталмый, киек ауларга да килми иде. Шулай да берәр аңсызы, я булмаса анда берәр үчлеклесе килеп үлән таптамасын, суны пычратмасын дип, әлеге сакчылар көненә бер мәртәбә булса да, үзләренә билгеләнгән җирне караштырып әйләнгәлиләр иде. Күл сакчыларының барысына да унбашы Ябалак карт баш.

Ябалак карт — Туңгак алыпның иске танышы. Күптәнге танышлар буларак алар шактый дусларча, туганнарча исәнләштеләр. Ләкин күл буенда авыл корып, төн куну турында сүз чыккач, Ябалак карт кинәт тынып калды. Өлкән бичә Күрекле бикә белән аның өлкән улының урдадан куылулары һәм Байык буена барышлый, ихтимал, күл яныннан узып китәчәкләре турында аңа инде алдан хәбәр ителгән иде.

— Бикәнең Диңгез-күлдә балык тотасы, балык ите ашыйсы килә,— диде Туңгак алып.

Нурсыз күзләре төпкә батып, тешләре төшеп беткән Ябалак карт йокыдан уянып киткәндәй булды.

— Балык тотасы киләме? Хе-хе?! — диде ул күңеллеләнеп.— Бикәгә каршы киләмме соң! Беренче колыны... тучи бәк тәгин углан шушында Диңгез-күл буенда, Манас тугаенда туды. Быел язга чыксак, унсигез ел тула. Оныткандыр дисеңме, Туңгак алып? Таптың онытыр кеше! Барысы да истә, Туңгак алып, бары да истә, угланнар. Язгы бозда, алачык эчендә каган балык тотып утырганда үзем барып әйттем: улың

бар, бөек каган! дидем. Сөенечтә өстемдәге менә шушы тунны бирде. Кыршылган дип исегез китмәсен — мин аны унсигезенче кыш киям. Кайчагында гына. Куанычлы көннәрдә генә.

Ябалак карт, җирән төстәге ефәк белән тышланган төлке тунының чабуын күтәреп, аның эчке ягын күрсәтте. Кунакка килгән, я булмаса йомыш белән килгән ят кешеләр алдында ул шулай каган бүләге белән мактанырга ярата. Туңгак алыпка гына да инде аның бу бишенчеме-алтынчымы мактануы иде.

— Яз көнендәгечә, күл уртасына алачык корып, бикәгә балык тотарга булышсаң, мин сиңа каган бүләгеннән дә яхшырак бүләк бирермен, — диде Туңгак алып.

— Каган бүләгеннән дә яхшырак бүләкнең булганы юк! Булмас та! — диде Ябалак карт кызып. — Йөрмәгез! Якын килмәгез! Каганнан башка миңа беркемнең дә сүзе үтми.

Билен аеллы, бизәкле киң каеш белән буып куйган, бер ягына — җәя, икенче ягына ук савыты аскан, кулына исә шома саплы, сөяк башаклы сөңге тоткан борынгы карт, тәбәнәк буйлы атын кырт кына борды да, үпкәләп-тузынып, «илчеләрдән» читкә китеп барды.

«Илчеләр» уңайсыз елмаешып аның артыннан карап калдылар.

— Их, боздым эшне! — диде Туңгак алып үкенеп.

Албуга шул чакны, берни әйтмичә, карт артыннан куа китте.

— Ябалак баба, мине тыңлале! — диде ул карт белән тигезләшкәч.

Ачулы карт үзе яныннан барган яшь угланга кырын күзе белән дә карамады.

— Мин ун кул тучи бәк тәгин углан Албуга булам — таныйсыңмы? — диде углан.

Ябалак карт атын тыя төште.

— Теге... Манас тугаенда туган тәгин угланмы? — диде ул бик үк ышанасы килмичә.

— Шул инде, шул! — диде Албуга.

— Унсигез ел элек булганны каян хәтерләп бетермәк кирәк?! — дип мыгырданды ачулы карт. Әлерәк кенә үзенең яхшы хәтерле булуы белән мактануын ул, ахрысы, онытып җибәргән иде.

— Әни дә монда. Күрекле бикә. Аның сине бик күрәсе килә, Ябалак баба! — диде Албуга ярарга тырышып.

— Әниең? Бикәме? Өлкән бичәме? — диде Ябалак карт, нидер исенә төшереп.

— Әйе, әйе, минем әни! Бикә! Өлкән бичә!

— Ник аны башта ук әйтмәдең? — диде Ябалак карт ачуланган булып.

— Монысы минем энем Адай, — диде Албуга үзе артыннан килеп җиткән Адайны күрсәтеп.— Ел саен яз көне без монда булабыз, сине күрәбез. Онытмагансыңдыр әле?

— Яшьләрне каян хәтерләп бетермәк кирәк! — диде Ябалак карт, чын күңелдән кеткелдәп.

— Без сине онытмадык, Ябалак баба! — диде Адай.

Эшләр болайга киткәч, Ябалак карт, күрәсең, яшьләр сүзенә генә ышанып җитмичә, борылып яңадан Туңгак алып янына килде.

— Бикә дә монда мени? Өлкән бичә? — диде ул, «баштарак әйтмәүләренә» бик нык хәтере калганлыгын сиздереп.

Туңгак алып аңардагы бу үзгәрешкә ышанырга да, ышанмаска да белмәде — Ябалак карт элегрәк бер дә андый килделе-киттеле түгел иде.

— Моннан ун сигез ел элек, өлкән бичәнең беренче углы туган елны син, Туңгак алып, яшь арыслан кебек идең! — диде Ябалак карт, аның уйларын сизенгән сыман, кеткелдәп.

— Читлектәге арыслан идем мин, Ябалак баба.

— Без барыбыз да читлектәге арысланнар кебек, Туңгак алып.

— Читлектәге арысланнар бер-берсе белән җиңелрәк килешергә тиешләр иде дә...

— Тагын нәрсә килешеп торасы? Языгы — үзегезгә! Миңа күп кирәкми. Бүген бар, иртәгә юк мин.

— Языгын тулысынча үземә алам, — диде Туңгак алып.

— Авылларын күлдән бер ук ераклыгында корсыннар. Мал-туарны ярга якын җибәрмәсеннәр. Яр буендагы камышларны, талларны малдан таптатмасыннар! Киекне атмаска! — дип кычкырды Ябалак карт чәрелдәп, шома саплы сөңгесе белән селтәнеп.

XVI

Ябалак картның теләген бикә җиренә җиткереп үтәргә тырышты. Арбалар күлдән бер чакрым чамасы җирдә туктап калдылар. Көтүләр күлдән, елга буйларыннан тагын да арырак — комлы калкулыклар арасында калдырылды. Маллар таралмасын, күл янына килмәсен өчен көтүчеләргә булышка сакчы ирләр бирелде.

Төштән соң Диңгез-күлгә Күрекле бикәнең төньяктанрак хәрәкәтләнгән иле якынайды. Аларның җигүле арбалары да, мал-туарлары да күбрәк иде. Бикә аларга монда бөтенләй туктап тормаска, ары китеп, төнгә каршы елга буенда авыл корырга кушты.

Яңа урында авыл кору белән, иң элек бикә үз өендә аш-су ясады. Ашка ул олы кунак итеп карчыгы белән унбашы Ябалак картны чакырды. Үзен атап чакырганга картның бик тә күңеле булды. Бикәгә дә, тәгин угланга да кирәкле кеше икәнлеген белгәнгә күрә, табын янында ул үзен шактый иркен тотты. Ашагач-эчкәч әледән-әле киткелдәп көлгән булды, элеккеләрне искә төшереп, моңаеп җырлап та алды.

— Углан! Балам! — диде ул Албугага эндәшеп. — Яз көне үрдәк артыннан кереп, суга батып үлә язганың исеңдәме? Сигез-тугыз ел элек. Үрдәк яраланган да, камыш арасына кереп качкан. Бу бала, күп уйлап тормаган, бозлы суга ташланган. Ярый әле мин туры килдем шунда.

— Бераз исемдә, — диде Албуга.

— Син соң, бикә, онытмадың микән — шул елны каган аткан беренче аккошны сиңа китереп бирдем. Үз кулым белән. Син миңа аккошның тәпиен бирдең. Кичен каган мине буза белән сыйлады. Менә шул, оланнар.

— Бары да истә, Ябалак баба, — диде бикә моңсу гына. — Каган янында балык тотканны карап тормакчы булгач, син миңа кычкырган идең, анысы да истә.

— Истә булмыйча! — диде карт сөенеп. — Син анда авырлы идең... беренче балаң белән, ахрысы. Анысы кыз иде бугай. Үлде дидең. Урыны оҗмахта булсын сабыйның. Авырлы хатын суга караса, судагы балыкны күрсә, баласы балык кебек телсез була дигәнне син белмәгәнсеңдер, бикә. Шуңа үлмәде микән әле синең беренче балаң?

— Исемдә, исемдә! — диде Күрекле бикә. — Син әйткәч мин карамадым ул чакта. Кызымны юкка искә төшердең, Ябалак баба. Арбадан төшеп калган ул. Җәй көне. Йоклап калганмын, сизмәгәнмен. Авырлы хатынга тирән суга карамаска, балыкка карамаска дип беренче мәртәбә син әйттең. Исемдә, исемдә...

— Менә шул! Ярамаганын да беләсең, шулай да карамакчы буласың, — диде карт сүзне кинәт үз ягына борып.

— Миңа инде ярый. Барысы да ярый, Ябалак баба, — диде бикә күңелсез генә.

— Хе-хе. Алай икән, — диде Ябалак карт. Алдындагы кымызны эчте дә, корышкан каты кулы белән авыз читен сөртеп куйды. — Илең-

көнең имин булсын, малың-туарың күп булсын, бикә. Син безне сыйладың, инде мин сыйларга тиеш сезне.

Шулай сөйләнгәләп ул урыныннан торды. Бүтәннәр дә кузгалыша башладылар. Бикә картның тел төбен аңлады. Киенеп алар өйдән чыктылар. Бөтен җир өстен, киң даланы аксыл яктылык белән сыеклатылган караңгылык каплан алган иде. Күктән, көндәгечә елмаеп, йолдызлар карый, йолдызлардан бик нык аерылып, китек табак сыман ай балкый иде.

Яр буена кадәр алар атта бардылар. Яр читенә җиткәч, атларыннан төштеләр дә җәяүләп боз янына килделәр. Күлгә аяк басар алдыннан Ябалак карт кычкырып дога укыды, күл иясенә йолыкка дип алып килгән бер чүлмәк кымызны боз өстенә түкте дә, күңеле белән котылу, җиңеләю тоеп, сөңгесенә тотынган көе, шома боз өстеннән атлап китте. Башкалар аның артыннан иярделәр.

Ярдан ярты ук чамасы ераклыкта боз өстенә киез өй утыртып куелган иде. Киез өй эченә керер алдыннан Ябалак карт янә кычкырып дога укыды, күл иясенә йолык бирде. Өйгә кереп ул зур гына чүлмәктәге майлы чүпрәккә ут төртеп җибәрде. Ут-анага да йолык биреп, өйне арыклагач кына ул бикәне үз янына чакырды.

Киез өйнең тач уртасына түгәрәк бәке тишелгән иде. Су белән бәке төбе арасында юка гына боз әлпәсе калдырылган. Ябалак карт, сөңге башагына майлы чүпрәк бәйләп, чүпрәгенә ут кабызды һәм чыртлап янган чүпрәкне бәке турысынарак китерде. Шул ук вакытта ул, ымлап кына, бикәгә якын килергә кушты. Ут яктысына төптән, боз астыннан кара сыртлы балыклар килеп чыкты. Кайберләре уттан куркып тиз генә читкә тайпылдылар, кайберләре әрсезләнеп борыннары белән астан юка бозга төртеп-төртеп алдылар. Бөреҗен[1] ике куллап тоткан бикә, тынын кысып, «үз балыгын» көтте.

— Әйдә! — диде карт, пышылдап.

Бәке авызында бикә шома сыртлы, тәңкәле зур балык күреп алды. Ул тимер башлы бөреҗен шул тере, шома нәрсәгә бар көченә тондырды. Чатнап боз ватылган, су чайпалган тавыш ишетелде. Һәм авыр бөреҗне кемдер үзе белән өстерәп китә башлады. Бикә каушап бөреҗ сабын ычкындырып җибәрде.

— Эх! — диде Ябалак карт.

Кулындагы утлы сөңгесен ычкындырмыйча ул бер очы бөреҗ сабына, икенче очы өй кирәгесенә бәйләнгән кыл арканны тотып алды. Су астына киткән арканны ул иләп кенә, тыеп кына учыннан шудыра башлады. Иң ахырда ул аны, ныгытып кыскан килеш, җибәрмичә аяк терәп тотып тора башлады.

— Булды! Әллә кая китә алмый инде ул! — диде канәгать төс белән пышылдап.

Утлы сөңгесен ул аягы астына куйды, арканга ике куллап тотынды да, ух-вах килеп авыр балыкны бәке авызына тартып китерде. Арканга шундук бикә килеп тотынды. Ул тотыну белән, Ябалак карт бауны ычкындыргандай итте. Балыкны боз өстенә бикә тартып чыгарды.

Алачык тирәсендә алай-болай боз ватылып китә күрмәсен дип, ирләр таралып читтәрәк торалар иде. Бикә беренче балыкны тоткач, Ябалак карт үз янына Албуганы чакырды. Икенче балыкны Ябалак карт белән бергәләп Албуга тотты. Аннары өченчесен тоттылар. Анысын Адай тартып чыгарды. Адайдан соң бәке янына җиде яшьлек Кече-Тайны чакырдылар. Куянкай өйдә йоклап калган иде. Кече-Тайдан соң киез өйгә Туңгак алып керде.

Бәке янына ул теләмичә генә атлады, солсыз сул кулына бөреҗне

---

[1] Бөреҗ — боз вата торган (агач саплы тимер) корал. Сөймән, лом. Романда бөреҗ «гарпун» мәгънәсендә алынды. Гарпун — балык аулаучылар коралы.

теләмичә генә алды. Беренче кизәнүдә ул балыкка тидерә алмады — бөреҗе чак-чак кына кулыннан ычкынып китмәде. Үзенең булдыксызлыгына, гариплегенә ачудан аның маңгаена салкын тир бәреп чыкты.

— Ашыкма! Ул сиңа, теге, яуда кеше үтерү түгел,— диде Ябалак карт өйрәтеп.

Туңгак алып ашыкма дигән саен ашыкты, кабаланды һәм суга берничә мәртәбә төртеп алгач кына бер кечкенә балык тартып чыгарды. Аның тәмам күңеле кырылды.

— Булмый! Миннән булмый, — диде ул ачынып. Бөреҗен ташлады да, ашыгып алачыктан чыгып ук китте.

Ул төнне алар бик күп балык тоттылар. Тотылган балыкны, йөккә төяп, үзләре белән авылга алып кайттылар. Төнге эштән соң арып-алҗып, шулай да әчке бер канәгатьләнү, тынычлану белән татлы йокыга аудылар.

Ул төнне бары Ябалак карт кына йоклый алмады.

XVII

Икенче көнне далада буран купты.

Кояш иртән әз генә күренеп торды да каядыр килеп чыккан һәм ашыгып көнчыгышка таба агыла башлаган болытлар арасында күмелеп калды. Сөякләргә үтеп исә торган ачы җил ярма сыман каты кар катыш ком бөртекләре алып килде. Көннең бозылачагын терлекләр алдан ук сизенделәр — борчылып кычкыра, тынычсызлана башладылар. Бар яктан да ачык, шыр далада, шыр калкулыклар арасында меңләгән мал-туарны җил-бураннан качырып, саклап калырлык бер генә җайлы урын да юк иде. Андый җайлы урын моннан еракта — көньяктагы таулар ягында гына бар. Анда барып җитү өчен елга аша чыгарга, яр буйларындагы талларны, камышларны таптап үтәргә кирәк булачак. Төнлә кизү торган көтүчеләр, буран чыгасын күреп, ашыгып бикә янына килделәр.

Бикә әле йокыдан тормаган иде. Аны шундук уяттылар. Уятучының шомлы тавышы буенча, өй артында җил ыжгыруы буенча бикә дөньяда ниндидер күңелсез нәрсә булганлыгын аңлап алды. Ул өстенә-башына ашык-пошык киенде дә, көтүчеләрне өенә кертергә кушты. Уллары Албуга белән Адайны, йөзбашы Җирәнне, баш бага Кортаганы, туганнарын чакыртып кеше җибәрде. Туңгак алып якында гына иде.

Күп тә үтмәде, өйгә күшеккән, борчулы көтүчеләр кереп тулды. Ашыгып Албуга белән Адай килеп керде. Барысы да җыелып бетеп, киңәшергә-сөйләшергә генә торганда, ут чыккандай тыны бетеп, агарынып Ябалак карт килеп җитте.

— Бикә! — дип кычкырды ул килеп кергәч тә, исәнлек тә алып тормыйча. — Бикә! Балыклар исәнме?

— Исән! — диде бикә.

— Исән булса, илтеп бир тизрәк. Үз кулың белән, — диде Ябалак карт.

— Кемгә? Ник?

— Әйткәнемне тыңла — илтеп бир! Күл иясе безгә ачулы. Мин, карт дивана, сезнең сүзгә карап...

— Күл богауда. Ул тик ята, Ябалак баба. Күл иясе түгел, Җил иясе ачуланган — буран куба!

— Өйрәт Ябалак картны, — диде карт, кулын селтәп. — Илтеп бир диләр сиңа. Җил иясе күл төбендә ята. Кичә ул бәкедән чыгып калган. Карт дивана, туң баш! Шуны истән чыгарганмын.

— Ярар, илтеп бирербез, Ябалак баба.

— Буран чыкканчы! Тизрәк! — дип кычкырды Ябалак карт, ашыктырып.

— Көтүләрне нишләтергә, Ябалак баба? Таулар арасына ничек булыр? — диде Албуга, картның юлына аркылы төшеп.

— Куыгыз, ку! Таулар ягына куыгыз!

— Ишеттегезме? — диде бикә көтүчеләргә, Ябалак карт чыгып киткәч.

— Ишеттек.

— Әни, көтүчеләргә булышка мин дә барам. Барлык ирләрне көтү куарга җибәрәм, — диде Албуга.

— Мин дә! — диде Адай, абыйсы артыннан ашыгып.

— Туктагыз, — диде бикә улларына. — Балыкларны илтеп бирик. Шуннан соң.

— Сез балыкларны алып китегез. Көтүчеләр янына үзем барырмын, — диде Туңгак алып.

Бикә аңа күтәрелеп карады — алып ирнең кыяфәте бер дә шәптән түгел иде.

— Сиңа... авыр булыр,— диде бикә.— Ятып торасыңмы әллә?

— Мондый чакта ятып торган ирне син ир дип әйтерсеңме соң? — диде Туңгак алып сер сынатасы килмичә.

— Юк, син йөрмә! — диде бикә кырт кисеп. — Менә Җирән барыр көтүчеләр янына.

— Барырмын, бикә,— диде Җирән дәртсез генә.

Урдадан Туңгак алып килеп кушылгач ул бөтенләй сүлпәнләнеп, үз эченә йомылып калды. Элек ул Туңгак алыптан курка, көнләшә иде, хәзер ул аны — гарип ирне күрәлми башлады. Бикә янында үзенең артык кеше икәнлеген күреп ул тизрәк моннан чыгып китү ягын карады.

Җирән чыгып киткәч Туңгак алып та җыена башлады. Бикә, аның мин-минлегенә кагылудан куркып, кал дип артык кыстап тормады. Күзколак булырга, кирәк булса булышырга дип аңа Адайны ияртергә шулай да бикәнең башы җитте. Алар ашык-пошык җыенып, аяк өсте генә капкалап барысы да берьюлы диярлек өйдән чыктылар.

Адай барысыннан да ныграк җитезлек күрсәтте. Өйдән читтә моңаеп, хуҗасын көтеп торган юаш алашаны ул Туңгак алып янына китереп туктатты. Аңа ияргә атланырга булышты. Туңгак алып ияргә җайлап утыргач, яшь углан үз атына атланды һәм алар калкулыклар ягына китеп бардылар. Юлда аларны уңнан да, сулдан да ашыгып баручы ирләр узып китте. Адай да алардан калышмаска тырышып караган иде дә булдыра алмады — Туңгак алыпның калышуын күреп аңа тыелырга туры килде.

— Бар әйдә, бар, тоткарланма, — диде Туңгак алып.

Адай тыңламады. Әле аны узып китеп, әле көтә-көтә, алар, ниһаять, зур калкулык өстенә килеп менделәр. Җил каршы яктан исә иде. Калкулык өстендә ул көчлерәк, усалрак тоелды. Алар, туры бәргән җилдән битләрен, күзләрен саклап, түбән төштеләр. Чак-чак кына башларын калкытып, тирә-якка күз ташлап алдылар. Бөтен тигезлекне каплап алган көтүләр инде тузыша башлаган иде. Шул ук вакытта андамонда көтүчеләрнең җан ачысы белән кычкырган тавышлары, үгез үкергән, атлар кешнәгән тавышлар ишетелә. Димәк, ирләр көтүләрне бүлеп өлгерә алмаганнар. Димәк, җилгә каршы якта, көтү алдында булучылар җитәрлек түгел. Ни караган Җирән? Кая аның ирләре?!

Туңгак алыпның күңеленә шундыйрак сораулар килде. Калкулык астында, аларның яныннан гына диярлек, көчле җилгә артларын куеп, бик кызу чабып, елкы көтүе узып китте. Шомлы пошкырып, каты тояклары белән каты җиргә дөп-дөп басып каядыр ыргылган атлардан соң, арт саннарын сикертә-сикертә, башларын чайкый-чайкый чапкан сыер көтүе күренде. Сыер көтүе арасында бүленеп калган дөяләр йөгерде,

алар артыннан тупырдашып, бер-берсенә сыенып, җил очырып йөртә торган тере йон төргәкләре кебек, куйлар-сарыклар тузышты.

Бу көтүләрне кем дә булса куалап, билгеле бер юнәлештә алып бара идеме, әллә соң аларны бары җил-давыл гына йөгертә идеме — Туңгак алып аера алмады. Ул арада җил кинәт көчәеп китте, буран чыкты. Бөтен җир-күк тоташ болганчыкка әйләнде. Әле менә якында гына күренгән Адай, кар-буран белән буталып, күздән югалды. Баш өстеннән ниндидер кара-мора нәрсәләр, төбе-тамыры белән йолкынып чыккан үлән төргәкләре очып үтте, каты кар, ком бөртекләре белән бергә каяндыр ваграк ташлар очып килде. Асты-өсте кузгалган бөтен җир-күк дер селкенеп, калтыранып, гүләп торды. Өзлексез шау-шу, сызгыру, ыңгырашу арасында, ярсып кычкырган, үкергән, чинаган тавышлар арасында ниндидер ят, сәер дөбердекләр ишетелеп китте — әллә җир читендә шулай таулар-кыялар ишелде, әллә Тәңре үзенең языклы бәндәләре өстенә ачу белән югарыдан уклар, сөңгеләр ыргытты.

Далада менә шулай кисәк купкан көчле җил-давылдан да куркынычрак берни юк иде. Мондый чакта кеше, бер-берсенә булышудан элек, үзенең терлек-туарына булышырга, ничек тә аны үлемнән коткарып калырга тиеш. Терлек-туарны үлемнән коткарып калу исә үз-үзеңне ач үлемнән коткарып калу дигән сүз иде.

Тигезлек өстеннән җил уңаена ташкын-ташкын булып узып киткән көтүләрне күзәткән бер мәлдә Туңгак алып үзенең җылы өйдән чыгып бик зур ялгышлык эшләвен аңлагандай булды. Бар көченә котырынган мондый җил-давылга каршы ялгыз башы ул берни эшли алмый иде. Ул ялгышты. Ул соңга калды. Ләкин шул ук вакытта ул бер урында катып та тора алмый иде. Үзенең гариплеген дә онытып ул, кемнәргәдер ярдәм итәргә кирәклеген исендә тоткан хәлдә, тыелгысыз җил артыннан иярде. Бу вакытта алар инде Адай белән бер-берсеннән аерылганнар иде.

XVIII

Анысын анда орып, монысын монда орып, тиешенчә үз көчен күрсәткәч, җил-давыл кисәк кенә тынып калды. Тире бүрекләрнең озын колакчыннарын чишеп җибәргәч, ком тулган күзләрен ертып, як-якка карагач, кешеләр беравык үзләренә үзләре ышанмый тордылар. Дөнья искиткеч тын иде, якты иде — һавада бер генә тузан бөртеге дә, бер генә чүп, кар бөртеге дә юк. Чатнап торган салкын, коры, аксыл күктә, бер гөнаһсыз сабый бала кебек, ягымлы, елмаеп, алтын-сары кояш карап тора. Көнбатыштагы шәрә ком таулары, көнчыгыштагы Диңгез-күл, күл буендагы камышлыклар — барысы да элеккечә тыныч һәм серле. Дөньяда бернинди үзгәреш булмавына ныграк ышандырырга тырышкан шикелле, баш өстендә генә каркылдап каргалар оча, киез өйләр, арбалар тирәсендә чыпчыклар тибенә иде.

Җил куалап киткән көтүләр елга буендагы таллыкка кадәр бардылар да, көтелмәгән каршылыкка очрап, яр буенча үргә — ачык җирдән көньякка таба ыргылдылар. Көтүчеләр һәм шулай ук ашык-пошык җыенган башка ирләр тузынган малларны туктата да, елга аръягындагы таулар арасына куып кертә дә алмадылар.

Атлар, дөяләр, сыерлар елга үзәне буенча югарыга бик озак чаптылар һәм күлдән ерагайгач, ниндидер урман алдында үзләре туктап калдылар. Шактый соңлап килеп җиткән көтүчеләр аларны көч-хәл белән кире борды. Буран тынганда инде алар барысы да бергә тупланган иде. Сарык көтүенең бик аз өлеше генә елга үзәне буенча китте. Сарыкларның күбесе, таллыкка килеп төртелү белән, шунда кереп

буталып бетте. Кайберләре агачлар арасында кысылып калды, кайберләрен эре терлекләр таптап киттеләр.

Балыкны кире күл иясенә илтеп бирергә дип киткән бикә белән тәгин углан давыл купканчы яр буена барып җитә алмый калдылар. Алар җигүле үгезләрен җилгә каршы бордылар да, давыл тынганчы арба эчендә утырып тордылар.

Югалган, таралган терлек-туарны ирләр көне буе барлап җыеп йөрделәр. Тапталып үлгән сарыкларны, егылып аягын сындырган бер дөяне каргалар сыман килеп җыелган ярлы чиннәргә бирделәр. Кайдадыр шушы тирәдә генә — урман, таулар арасында чин качакларыннан оешкан авыллар бар иде.

Авылда көне буена елаган, шыңшыган, ыңгырашкан авазлар ишетелеп торды. Хатын-кызлар ертылган, сүтелгән өйләрен рәтләделәр, көтү куып ерак киткән ирләрен, балаларын көттеләр. Җил чыкканда бер-ике кечкенә бала күл буенда булган — җил аларны боз өстеннән шудырып бик еракка алып киткән. Аларның үле гәүдәләре яр буендагы камышлыклар арасыннан табылды. Бер көтүчене атлар таптап үтергән булып чыкты.

Бикәнең өлкән углы үзе янында иде. Куянкае белән Кече-Тае өчен дә ул бөтенләй диярлек борчылмады — җил чыкканда алар өйдә калган булырга тиешләр. Бикә бары Туңгак алып белән Адай өчен генә борчылды. Җил тынып, балыкны капчыгы-ние белән боз өстенә аударгач, ул тизрәк өенә ашыкты. Анда кече улы белән кызының исән-имин икәнлеген күреп ул яңадан атка атланды да көтүчеләрне эзләп китте. Албуга да әнисенә иярде. Адай белән Туңгак алыпны алар көтүчеләр янында гына булырга тиеш дип уйладылар. Авылдан бер чакрым чамасы китеп өлгермәделәр, каршыга очраган ирләрнең берсе Туңгак алыпны елга буенда ярым үлек хәлдә таптык, дигән хәбәр әйтте.

Бикә белән Албуга ашыгып елга буена чаптылар.

Алар килеп җиткәндә Туңгак алып әле исән иде. Ләкин ул инде аңын югалткан, күзләре йомык иде. Аның янындагы Кәлтә бикә белән тәгин угланга Туңгак алыпны кайчан, ничек табуы турында сөйләргә тотынды. Бикә аны тыңлап тормады. Иелеп, җирдә яткан ирнең йөзенә карады, тын алуын тыңлады, тәнен тоткалады. Туңгак алыпның тәне җылы, тын алуы тигез иде. Бикә ялт кына башын калкытты, өлкән улына боерып:

— Бар, тиз бул! — диде.

— Кая?

— Теләсәң кая бар! Киез китер, кешеләр китер!

Елга аръягында, тәбәнәк калкулык өстендә ялгыз өй утырганын Албуга монда килгәндә үк күреп алган иде.

— Әни, шунда гына илтик! — диде ул, әлеге өйгә күрсәтеп.

— Әйдәгез! — диде бикә.

Кәлтә өстендәге бер кат тунын салып җиргә җәйде. Туңгак алыпны шул тун өстенә яткырдылар. Тунның бер як чабуыннан Албуга, икенче як чабуыннан Кәлтә тотты. Бикә арттан аның аякларын күтәреште. Таллык аша чыгуы бик кыен булды. Таллыкны узгач, ялгыз өй ягыннан кемнеңдер ашыгып каршыга килгәне күренде. Бу күл сакчысы Ябалак карт булып чыкты. Дүртәүләшеп алар авыр гәүдәле ир кешене өйгә алып керделәр. Учак янына киез өстенә сузып салдылар. Күтәреп барганда да, өйгә кергәч тә Туңгак алып әледән-әле ыңгырашып куйды, нидер әйтергә теләгәндәй иреннәрен кыймылдатты.

— Эчәргә сорый, — диде Ябалак карт һәм шундук бурдактан кымыз агыза башлады.

Туңгак алып янына Ябалак картның үзеннән элек аның корткасы килеп җитте. Яралы ирне ул җайлабрак яткырды, авыз эченнән генә дога сүзләре укып, аның битен, ияк асларын сыйпалады, изүен чишеп,

тунын ычкындырып ташлады. Карты китергән кымызны ул яралының авызына көчләп диярлек агызды.

— Кайгырма, бикә, минем кортка тотынгач, терелтми куймас. Ул аның телен белә,— диде Ябалак карт карчыгын мактап.

Карчык исә, идәндә сузылып яткан яралы ирдән башка беркемне күрмичә-ишетмичә, туктаусыз укына-укына, бик озаклап, җентекләп капшанды-капшанды да, башын чак кына калкыткандай итеп бикәгә:

— Бөтенләй чишендерергә кирәк, бикә,— диде йомшак, ягымлы бер тавыш белән. — Беләге шешкән, җиңенә сыймый. Тунын ярмый булмас.

— Булышыргамы? — диде бикә.

— Яңа суелган үгез тиресенә төрербез, ана эт сөте эчертербез, — дип сөйләнде карчык бикәне тыңламыйча. — Утлы куз өстендә дә тотарга туры килмәгәе. Каны чыкмаган. Бозык каны эчтә җыелып калган. Шул чыкмыйча савыкмас.

— Болай булгач, тиз генә савыкмый әле ул! — дип куйды Ябалак карт.

Ничектер серле генә итеп ул бикәнең җиңеннән тотты да, ишеккә таба ымлады. Алар, тәбәнәк ишек башына орынмас өчен яртылаш бөгелеп, бер-бер артлы өйдән чыктылар. Тәгин углан белән Кәлтә кызулап атлары янына китеп бардылар. Бикә өлкән углына Адайны эзләп табарга кушты.

— Син миңа үпкәләмә, бикә, — диде Ябалак карт яшьләр ерагайгач. — Сиңа моннан тизрәк кузгалып китәргә кирәк.

— Аны калдырыпмы? — диде бикә, өй ягына ымлап.

— Алып китсәгез, юлда ул бүген үк аяк сузачак,— диде Ябалак карт.

— Уйлап карармын, — диде бикә, икеләнгәндәй итеп.

— Уйлыйсы юк, бикә! — диде карт. — Мин барып карадым — балыкны да яр буена гына ташлап киткәнсез. Күл иясе сиңа ачулы. Кит тизрәк, кит моннан, юкса, барлык малыңнан, иленнән-көнеңнән колак кагарсың.

— Куркытма әле, Ябалак баба, — диде бикә ыңгырашып.

— Мин куркытмыйм сине — иярләр куркыта! — диде Ябалак карт.

— Шул көенчә ничек ташлап китим мин аны?! — диде бикә өзгәләнеп.

— Аягына баскач үзе эзләп табар, я килеп алырсыз, — диде Ябалак карт, бикәне юатырга кирәк табып. — Минем кортканың кулы алтын. Терелтер. Бер дә хафаланма, бикә.

XIX

Адай исән иде. Көтү ташкынына эләгеп ул башка ирләр белән бергә ерактагы таулар, урманнар ягына барып чыккан. Уртанчы улын исән-сау күргәч бикәнең күңеле бераз үз урынына утыргандай булды. Шулай да Ябалак картның кисәтүе аның йөрәген туктаусыз бозып торды. Үзенең иң якын кешесен шул килеш, ярым үлек килеш ташлап китү аңа башка сыймастай нәрсә булып тоелды. Үзе генә бер карарга да килә алмагач, ул уллары белән киңәшеп карарга булды. Алар: ни булса да бүген көтәргә, иртәгә таң белән юлга чыгарга, дигән фикер әйттеләр.

Кичкә таба Туңгак алып телгә килде. Ул үзенең бикәне, тәгин угланны күрергә теләвен белдерде. Бу вакытта бикә үз авылында, үз өендә иде. Ябалак карт, атына атланып, бикә белән тәгин угланны алырга китте.

Өлкән углын ияртеп бикә Ябалак картның елга буендагы өенә бик тиз килеп җитте. Иске киезләрдән җыйнаштырылган тәбәнәк, кысан

өйдә Туңгак алып бөтен түрне иңләп-буйлап ята иде. Өстендәге киемнәрен салдырып, аны баштанаяк чи үгез тиресенә төргәннәр иде. Җирән үгез тиресе арасыннан аның бары киң яңаклы чандыр бите генә агарып күренә.

Бикә аның уң ягына, тәгин углан сул ягына тезләнде. Икесе дә сораулы караш белән аның күзләренә текәлделәр. Туңгак алып әле бер якка, әле икенче якка күзләрен генә йөртте.

— Килдегезме? — диде ул аларның икесенә дә эндәшеп.

Ул моны бик тыныч итеп, берниндн сызланусыз, пошынусыз әйтте. Гүя ул яралы да түгел иде, әлерәк кенә аңын да югалтып ятмаган иде.

— Хәлең ничек? — диде бикә, аның йөзенә үк иелеп.

— Хәлем... яхшы, — диде Туңгак алып.

Ул елмаерга тырышып карады. Булдыра алмады. Карт белән карчык күләгә сыман читтән генә, аларның сөйләшүләрен тыйнак кына тыңлап тордылар. Туңгак алып аларны күреп алды.

— Бикә, тәгин углан... сез генә калыгыз, — диде ул.

— Ярар, ярар, — диде Ябалак карт кабаланып, чыгарга җыенып. Кортка да ашыкмыйча гына киенә башлады.

Өйдә өчәү генә калгач, Туңгак алып ымлап, бикә белән тәгин угланга якынрак килергә кушты. Үзенең колак төбендә генә аларның тын алуларын тыңлап ятты да, бар батырлыгын җыеп сүзгә башлады.

— Минем икегезгә генә әйтәсе сүзләрем бар,— диде ул, ярым пышылдап. — Мин... күчәм.

Бикәнең кашлары сикерешеп куйды, авыз читләре ямьсез булып сузылып калды һәм ул үзе дә сизмәстән борынын тарта башлады. Албуга, бозылган йөзен күрсәтмәс өчен, тиз генә читкә борылды. Туңгак алып аларның тынычланганын көтеп ятты.

— Бүлдермәгез. Тыңлап кына торыгыз, —диде ул. — Киткәнче мин сүземне сезгә әйтергә булдым. Мин, Туңгак алып, Туман каганга биргән антымны бозам сезнең алда. Үлгәч мине... антын бозган кешене... киезгә төреп, куыш агач эченә салып, багана башына элеп куйсыннар.

— Әллә әйтмисеңме, Туңгак? — диде бикә ялыну катыш үтенеч белән.

— Әйтми ярамый, — диде Туңгак алып. — Мин күп уйладым. Сезгә аны әйтми ярамый. Син, бикә, курыкма. Тәгин углан, син дә курыкма. Курыксаң, яшәргә дә кирәкми. Яшәү ул — куркуны җиңү, үлемне җиңү.

— Үлемне!? — диде Албуга.

— Үлемне, тучи бәк тәгин углан. Сине, тәгин углан, җир өстендә адым саен үлем сагалый. Каган урдасы әйләнәсендә сине... дүрт җирдә дүрт үлем сагалый!

— Саташмыйсыңдыр ич син, Туңгак?! — диде бикә, коты алынып.

— Саташмыйм, бикә, — диде Туңгак алып, тыныч кына. — Туман каган тәгин угланның дүрт курчагын ясатты. Урда туктаган бер җирдә ул курчакларны җиргә күмдерәчәк.

Албуга агарынып китте.

— Туңгак?! — диде бикә ярдәм сорагандай, кулын күтәреп.

— Бу эшне ул Исәнтәйгә тапшырды. Ана-кам кушуы буенча. Алардан саклангыз,— диде Туңгак алып, бераз тынып яткач.

— Ул мине чыннан да үтермәкче буламыни? — диде Албуга, кинәт хәлсезләнеп.

— Әйе, ул сине үтермәкче була, — диде Туңгак алып.

— Шулмы синең әйтәсе сүзең? — диде бикә.

— Шул, — диде Туңгак алып.

— Син, Туңгак, минем өлкән углымны коткару өчен...

— Минем тагын сүзем бар, — диде Туңгак алып, бикәне бүлде-

реп. — Мин Кортка-бикәдән белештем: җиргә күмелгән курчакларның сихерен бетереп булмый. Аларга якын барырга ярамый.

— Анысын мин дә беләм, — диде тәгин углан.

— Тыңлап бетер! — диде Туңгак алып. — Дүрт курчакның сихер көчен бетерү өчен сиңа дүрт үлемне җиңәргә кирәк. Әйттемме сине адым саен үлем сагалый дип?! Монысын да мин Кортка-бикәнең үзеннән белдем. Ант эчеп.

Ярым караңгы, кысан өй эчендә авыр тынлык урнашты.

— Аңлашылды, — диде бикә көрсенеп.

— Сезнең алда мин берьюлы ике антымны боздым. Берсе тотмаса берсе тотачак. Шуңа күрә минем теләкне үтәми калмагыз, — диде Туңгак алып бөтенләй чит кеше тавышы белән. — Тагын сүзем бар. Монысы болай гына, йөрәк янганнан гына. Исәнтәй котыртуы буенча каган Чингә каршы бөтен көче белән яу чапмакчы. Мәкерле Исәнтәй корган тозак куркыныч. Миннән башка сөннәр җиңеләчәк. Салчак алып куркак, кара эчле. Яуда ул каушап калачак. Туман каганның субашы булырдай башка ире юк. Бар ышаныч синдә, уң кул тучи бәк тәгин углан... Албуга... Алаб Буга!

Яратып, эченә, күңеленә кереп ул яшь угланга карады һәм, үзенең бу яратуыннан курыккан сыман, тизрәк күзен читкә борды да тынып калды.

XX

Юл буена бикә уйланып кайтты. Шулай итеп, Туңгак алып та юк. Күпме яуда булып, күпме яра алып, күпме үлем белән якалашып исән калган ир. Карусыз, кыю ир. Якын дус, сердәш. Күпме истәлекләр... татлы да, сагышлы да, көлке дә, куркыныч та истәлекләр аңа барып тоташа. Шулай итеп, чыннан да китәр микәнни? Үзенең истәлекләре белән, әйткән сүзләре, күз карашлары, дәртле кайнарлыгы белән артта калып, онытылып, мәңге юкка чыгар микәнни? Никтер ышанасы килми. Кичә генә җир җимертеп, бар нәрсәгә хуҗа булып яшәгән кешенең бүген булмавына ышанасы килми. Ул да китеп барса, бу дөньяда кемгә таянырга, кемгә эч серләреңне сөйләп юанырга, кемнең җылы куенында күңеленә юаныч табарга? Балалар үсә, түл җыя, ләкин алар беркайчан да сине кул очында йөрткән, иркәләгән ирең булмас.

Күрәсең, чыннан да китәр ул. Берьюлы ике антын бозган кешене җир күтәрә алмас. Антын бозган кешенең тамыры корый, кулы-аягы корыша, күзләре сукырая. Монда инде аңа беркем дә, берни дә ярдәм итә алмаячак.

Туктале, андый нәрсәне кире кайтара торган берәр төрле им-том юк микән? Булырга тиеш. Ләкин аны белсә бары шул Кортка бикә генә белер. Куяннарга ул мәңгелек дошман. Куяннарга ул беркайчан үзенең андый серләрен әйтмәячәк.

Әйе, язмышы шундыйдыр Туңгак колның. Бәхетле дә, бәхетсез дә язмыш. Тугин угланны, аны — бикәне, бөтен ил-көнне коткару өчен ул үз-үзен корбан итте. Әле генә. Күз алдында. Аның шундый изгелеген ничек онытмак кирәк? Соңгы кат, соңгы мәртәбә булса да, аның өчен берәр төрле изгелек — күз күрмәгән, колак ишетмәгән берәр яхшылык эшлисе иде, тәңрем!

Өенә кайтып сүнә язган учакны дөрләтеп җибәргәч ул, балаларын җыеп, ашарга утырды.

— Аның бит бер нәрсәсе дә юк! — дип сөйләнде ул әле һаман тынычлана алмыйча, уйларын дәвам итеп. — Бер нәрсәсе! Аты да, өе дә, каккан казыгы да!

— Әни, син аңа бер-ике ат калдыр, арба белән дөяләр калдыр, — диде Албуга киңәш итеп.

— Мин аңа, улым, яңа киездән кышкы өй калдырам, кырык-илле баш сарык, ике сыер, бер-ике дөя белән бер-ике ат калдырам, — диде бикә.

— Ул үлсә, аның мал-туарын Ябалак карт алыр, иеме әни? — диде Адай.

— Тсс! — диде бикә, белексез углына ысылдап. — Алай кычкырып әйтмә андый сүзләрне. Як-ягыңа төкер!

— Әйттем исә кайттым! — диде Адай шундук, як-ягына төкеренеп.

— Мин аңа ярты байлыгымны калдыра алам, — диде бикә моңсу гына. — Монда ул аның белән нишләсен?! Терелгәнче, аягына баскан-чы туенып торырлык булса, шул җиткән. Картларга булышка бирәр кыз да калдырмый булмас.

Соңгы сүзләрен бикә бераз гына икеләнеп әйтте. Туңгак алып гарип булса да, үзе ялгыз булгач, ул инде аны бөтенләе белән үземнеке дип уйларга күнеккән иде. Аның янында кырнак кыз калдырырга дигән уй анда кинәт көнчеллек сыман бер нәрсә кузгатып куйгандай булды. Шулай да ул андый тойгыга көчәергә ирек бирмәде. Терелсен генә, аягына гына бассын — аның янында ул үзенең иң яшь, иң матур кызларын да калдыра ала.

— Әйе шул, чынлап та, әни! — диде Албуга, әнисенең фикерен куәтләп.

Бикә ашагач шундук өйдән чыгып китте. Аның кол кызлары, хезмәтче хатыннары якындагы өйдә генә торалар иде. Бераздан бикә таза гына, сылу гына бер яшь кызны ияртеп керде. Куе кара чәчле, чем кара күзле, матур тавышлы бу кыз түбәтнеке — теге кичне камышлыкта Кәлтә белән серләшеп торган Кара-Тут исемле кыз иде.

— Без аңа менә... Кара-Тутны калдырырбыз, улым,— диде бикә, үзенең тәгин углы белән киңәшкән сыман сөйләнеп. — Эшчән, сүз тыңлаучан, ягымлы. Авыру ир кешегә шундый кыз кирәк тә. Инде алай-болай була икән, малның яртысы Ябалак картка, яртысы кызга калыр. Шул мал-мөлкәте белән Кара-Тутны үзем кияүгә бирермен. Ичмасам күңелем тынычланыр.

— Әни! — диде кинәт Албуга.

— Нәрсә «әни»? — диде бикә, башын иеп торган кызны караштырып.

— Әни, калдырма аны! — диде Албуга. — Без аңа... теге... Табылдыкны бирик.

— Нишләп алай? Син аны яратасың түгелме соң? — диде бикә.

— Әни! — диде Албуга дулкынланып. — Үлем түшәгендә яткан колыңа, өй, мал-туар белән каралар калдырмакчы булып син бик күп бәкләрдән, аксөякләрдән өстен икәнлегеңне күрсәттең. Кем ул сиңа Туңгак алып? Мин моны беләм. Кем ул миңа Туңгак алып? Анысын мин белмим. Ул миңа туган атам кебек булды. Ул мине беренче булып атта йөрергә өйрәтте. Ул мине кылыч, сөңге тотарга өйрәтте, ул мине суда йөзәргә өйрәтте. Ул мине корычтай нык куллы, юлбарыстай кыю йөрәкле, даладай киң күңелле булырга өйрәтте! Аның өчен мин соңгы атымны, соңгы тунымны бирә алам. Аның өчен мин шулай ук яраткан кызымнан да баш тарта алам. Әни! Барлык кешеләрдән, барлык вактөяк кайгылардан өстен булырга дип син миңа үзең әйттең. Синең сүзләреңне мин гел истә тотам. Атам кебек кешегә яраткан кызымны калдырам икән, син каршы килмәссең дип уйлыйм. Аннан соң, Байык буенa барып урнашкач, мин болай да өйләнергә тиешмен.

— Шулай шул, — дип куйды бикә килешкәндәй итеп. — Ярар, синеңчә булсын, алайса. Бу түбет кызы да ягымлы, югыйсә.

— Түбет кызын бүген генә миннән... минем аша ялынып Кәлтә сорады, — диде Албуга. — Синнән сорарга дип үтенде. Алар бер-берсен яраталар. Кәлтә минем иң ышанычлы егетем. Аның яраткан кызын тартып алсам, кемгә охшар идем соң мин, әни? Мин атама охшамаячакмын, мин беркайчан да Туман каган эзеннән китмәячәкмен!

— Бирсен, тәңрем! — диде бикә җиңел сулап.

Дәвамы киләсе санда

Нурихан Фәттах

СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

РОМАН

Беренче китап

Бишенче баб

I

Алар яңадан кузгалып киттеләр. Алдан күзәтчеләр барды, ян-яклардан, арттан коралы алайлар барды. Тигез җиргә җәелгән язгы ташу кебек, аяк астыннан ашанып, күп санлы көтүләр барды. Озын олаулар булып, биек түбәле арбалар шыгырдады. Көндәгечә далада атлар пошкырды, бияләрен көнләп, яшь айгырлар үзара сугышты. Җирне-күкне яңгыратып, үгезләр үкерде. Көндәгечә, баш өстеннән каркылдашып, каргалар очып үтте. Югарыдан, җирнең өстен яктыртып, кышкы кояш көндәгечә балкып торды.

Күрекле бикә Туңгак алыпны Диңгез-күл буенда үлем түшәгендә калдырып киткәннән соң кинәт кенә басылып, боегып калды. Ул яңадан үзенең җил үткәрми торган иркен арбасына кереп утырды да почмакка посты һәм йомшак якасына чумып, беркем белән сөйләшмичә, берни белән кызыксынмыйча барды да барды.

Туңгак алыптан аерылгач, Албуга элеккегә караганда да нығрак сүзсезләнеп, кырысланып калды. Аның күңелендә нindидер зур, әһәмиятле үзгәрешләр барлыкка килде сыман. Ул нидәндер котылып, бушанып, нindидер иреккә чыккандай булды, ләкин шушы ук вакытта, бөтен киләчәген каплап, аның өстенә яңа борчулар, яңа сораулар ябырылып килгәне дә сизелде.

Иртән кояш җир астыннан чыгып, кич яңадан җир астына кергән кебек; яз көнендә барлык үлән, барлык бөҗәк туып, үсеп, кыш көнендә үлгән кебек, үзенең дә кайчан да булса бер үләчәген; үз күбәләгенең, тәннән чыгып, тәңре катына очачагын ул белмәде түгел. Җир йөзендә барлык нәрсә шулай: туа, яши, үлә. Яңадан туа, яңадан яши, яңадан үлә.

Ләкин кояш төшлеккә дә җитми туктап калса, күктән егылып төшсә, кире артка таба тәгәрәсә, җирдәге үләннәр, бөҗәкләр — бар тереклек нишләргә тиеш соң? Алай булса, ул чагында җирнең өстен каран-

---

Ахыры. Башы 3—4 саннарда.

гылык каплар иде, дала өстендә бертуктаусыз җил дә буран уйнап торыр иде, барча тереклек үлеп бетәр, кешеләр ачтан кырылыр иде.

Шулай ук Тәңре углы, тәгин углан, әле ныклап яши дә башламыйча, гомереңең әле бер күлемен дә үтмичә, таза-сау килеш, яшь айгырдай куәтле килеш, көтмәгәндә үлеп китсә, үтерелсә, аның иле-көне нишләргә тиеш соң?! Алар да, тәңре биргән сихри көчтән мәхрүм калып, үлеп-кырылып бетәчәк түгелмени?

Төшлектәге таза, яшь кояшның түбәдәге айның, йолдызларның кинәт җиргә төшеп үлеп-кырылып бетүләре башка сыймас нәрсә булган кебек, аның да — яшь, таза тучи бәк угланның үлеме дә башка сыймас нәрсә булмас иде мени? Инде шулай да берәрсе аның юлына үлем тозагы корып куйган икән, барлык җаны-тәне белән, бар тырышлыгы белән, бар осталыгы белән ул әлеге тозакны юк итәргә тиеш түгелмени? Тиеш!

Кортларның-бөҗәкләрнең, ташларның-агачларның яшисе килгәне кебек, Туман каганның, Котлуг бәкнең... — барлык башка җанлы-җансызның яшисе килгәне кебек, аның да яшисе килә. Ул яшәргә тиеш. Бер көн эчендә кояш җирне әйләнеп чыккан кебек, ул да үзенә тиешле гомерне яшәргә, үз төшлегенә, үз биеклегенә күтәрелергә тиеш.

Туңгак алып! Антыңны бозып син миңа куркыныч сереңне ачтың, син минем күңелемдә яшәү дәрте, көрәш дәрте кабыздың. Син миңа сак булырга, уяу булырга кисәттең.

Ләкин дала киң, далада юллар күп — ат юллары, арба юллары, тычкан юллары... Шуларның кайсыннан китәргә? Кирәк юлны сайлаганда ялгышмаммы, Туңгак алып? Бутамаммы арба юлы белән тычкан юлын?

Сорау артыннан сорау туды, борчу артыннан борчу туды. Әлегә бер сорауга да җавап таба алмады. Шулай да ул кайгырып-уфтанып кына да яши алмый иде. Күп нәрсәдән хәбәрсез, белексез булса да, әле бик үк җитлекмәгән, ныгымаган булса да, ул үзенең кем булуын, кем булырга тиешлеген онытмады. Әнисе, энеләре, туганнары, каралар — ирләр, хатыннар — барысы да аны үзләренең башы дип, якчысы дип беләләр. Барыннан да элек ул аларның ышанычын акларга тиеш. Киң далада терлек куган оста көтүче кебек, ул да аларны үлемсез, кыран-талаусыз тигез юлдан, туры юлдан алып барырга тиеш.

Бармы җирдә шундый тигез юл? Бар көтүен бергә туплап, таратмыйча, имгәтмичә, барып җитә алырмы ул үзенең агылына[1] тикле?

II

Икенче көн инде менә аның күңелен шундый уйлар талый. Әнисенең үз кайгысы башыннан ашкан, Адай әле яшь. Теләсә дә, теләмәсә дә аңа менә бары үзенә таянырга кала.

Албуганың бер ягыннан — Адай, икенче ягыннан Кәлтә бара иде. Алар, тирән уйга баткан кайгылы тәгин угланның алай-болай кытыгына тиеп, ачуын китермәс өчен, икесе дә читтәнрәк, арттанрак киләләр. Тәгин углан иелгән авыр башын күтәреп, башта сул ягына, аннары уң ягына карады. Адай белән Кәлтә, аңа нидер кирәклеген аңлап, шундук атларын кызулый төштеләр, аның һәрбер сүзен тартып алырга әзер булып, аның күзләренә карап бара башладылар.

— Без монда, абый! — диде беренче булып Адай.

— Минем янга йөзбашы Җирән килсен, — диде Албуга.

— Ул койрыкта. Үзем алып килермен, абый,— диде Адай.

— Бар.

Кәлтә, тагын берәр сүз чыкмасмы дип, тәгин угланның авызына

[1] Агыл — мал-туарны ябып кую, бергә туплау өчен махсус корылма. Утар.

карап барды, ул эндәшмәгәч, сиздермичә генә артка калды. Албуга исә, Кәлтәне күрү белән, түбет кызы Каратутны исенә төшерде. Бикә кызны Кәлтәгә берсүзсез бирде. Бүген Кәлтә кыз куенында булды. Түбет кызыннан соң уй җепләре шундук Табылдыкка, Табылдыктан Сөенечкә барып ялганды. Яшь угланның йөрәге сыкрап куйды. Кызлар турында аның уйлыйсы килмәде. Аңа хәзер ничек тә андый нәрсәләрне онытып торырга кирәк, аңа хәзер ныклык кирәк.

— Кәлтә! — диде ул, үзе дә искәрмәстән.

— Мин монда, олуг тучи бәк! — диде Кәлтә, үзенең кирәге чыгуга сөенеп.

Ләкин аның белән сөйләшергә сүз табылмады. Алар эндәшмичә, сөйләшмичә беравык янәшә бардылар.

— Кызыңны яратасыңмы, Кәлтә?

— Яратам, олуг тучи бәк! — диде Кәлтә, никтер каушый калып.

— Син инде гел аның турында гына уйлыйсыңдыр?

— Ыы... — диде Кәлтә төртелеп. — Юк, синең янда булганда уйламыйм, олуг тучи бәк!

— Ялганлыйсыңмы? — Албуга ялт кына юлдашына карап алды.

— Юк, ялганламыйм.

Тавышы, күз карашы буенча Албуга аның чыннан да ялганламавын аңлады.

— Мин менә булдыра алмыйм — гел искә төшә, — диде ул, күңел йомшаклыгына бирелеп.

Кәлтә, әдәп саклап, эндәшмичә калды. Ике арада уңайсыз тынлык урнашты. Шул чакны арттан Адай белән йөзбашы Җирән килеп җитте. Туңгак алып Дингез-күл буенда торып калгач, Җирәннең йөзе ачылып киткән иде. Ул үзен хәзер бик кирәкле кеше, бәхетле кеше итеп сизә иде бугай. Моның шулай икәнлеге аның һәрбер хәрәкәтендә, һәрбер сүзендә, бөтен кыяфәтендә сизелеп тора иде.

— Кулына ук-җәя тота алырдай ничә ирем бар минем? — диде Албуга йөзбашы Җирәнгә.

Бәхетле Җирән бөтенләй мондый сорау көтмәгән иде, ахрысы. Исенә төшерә-төшерә ул үзалдына кычкырып санарга кереште.

— Минем кул астында өч йөз сиксән... — диде ул, санының очына чыгып.

— Синең кул астында түгел, — минем кул астында күпме? Бөтенесе?! — диде тәгин углан.

Башка вакытта Җирәннең тук, тыныч йөзе аның ачуын китерсә, бүген аның кирәгеннән артык шат, ягымлы йөзе саруын кайнатты.

— Синең кул астында, олуг тучи бәк тәгин углан, бер мең чамасы... — дип башлады яңадан Җирән.

— Төгәле, төп-төгәле күпме? — диде Албуга, янә дә аның сүзен бүлдереп.

Шат кыяфәтле Җирән, авызына суккандай тынып калды, як-ягына тырпаеп торган матур кара мыек чылгыйлары мескенләнеп салынып төште, йөзен шундук кара кайгы басты. Чынында ул тәгин угланның үзеннән нәрсә соравын да төшенеп җитмәде. Моңарчы ул бикәнең ирләрен генә белде һәм алар тулысынча аңа буйсыналар иде. Башка ирләр турында ул рәтләп берни белми иде. Ул ы-мы итте, тирләп чыкты һәм иң ахырда, нәрсәдер аңлатмакчы булып, тәгин угланның сөйләргә рөхсәт итүен үтенде.

Албуга туктады, атын кире борды. Башкалар да туктап калдылар. Тәгин углан үз янындагы кечкенә төркемнән алдарак бара иде. Туктагач, ул өч кешелек төркемгә каршы якта булып чыкты. Җирән өч кешелек төркемнең уртасында — аның бер ягында Адай, икенче ягында Кәлтә иде. Җирән үзенең көтмәгәндә камалышта калуын бик тиз шәйләп алды.

— Сез ммине... нишләтмәкче буласыз? — диде ул агарынып. Калтыранган кулы белән ул шундук кылыч сабына тотынмакчы булды.

Тәгин углан, тынычлыгын саклап, иреннәрен кысып, аның шул калтыранган кулына карап торды. Адай белән Кәлтә шулай ук аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп тордылар.

— Мин сине исән калдырам, Җирән! — диде Албуга, олы бер киң күңеллелек белән.

Җирәннең кулы, калтыравыннан туктап, җансыз нәрсә кебек салынып калды. Матур мыеклы йөзе тартышып куйды.

— Мең яшә, олуг тучи бәк! — диде ул.

— Мин синнән төгәл сан сорыйм — син калтырап төшәсең. Мин борылып, синең йөзеңә карыйм — син коралга тотынасың,— диде Албуга, шелтә белән.

— Кичер мине, олуг тәгин углан! Мин аңлап җитмәдем, — диде Җирән, үзенең хатасын танып.

— Аңламасаң, сора,— диде Албуга.— Тыңла, йөзбашы Җирән, мин янадан аңлатам: корал тота алган, кереш тарта алган... алтмыштан алып уналтыга чаклы булган барлык ирләрнең төгәл санын белергә. Шулар арасыннан алып ирләрне, яхшы атучыларны барларга. Бүген кич, авыл булып туктар алдыннан, йөзбашларын, унбашларын, алыпларны, яхшы, төз атучыларны бергә җыярга. Инде аңлашылдымы?

— Барысы да син әйткәнчә булыр, олуг тучи бәк, — диде Җирән, җиңел сулап.

— Сиңа Кәлтә булышыр, — диде Албуга һәм Кәлтәгә карады.

Булышырмын! — диде Кәлтә шундук.

— Мин үзем генә дә булдырырмын! — диде Җирән, ашыгып.

Ул моны Кәлтәдән баш тартасы килгән өчен түгел, тәгин угланга ярарга тырышудан әйтте бугай. Ләкин мондый ялагайлыкка тәгин угланның бер генә керфеге дә селкенмәде.

— Мин аңлаешлы итеп әйттем: сиңа Кәлтә булышыр, — диде ул коры гына.

Кичкә таба әйтелгән җиргә йөзбашлары, унбашлары, алыплар, сугыш осталары җыелгач, тәгин углан аларга үзенең беренче боерыгын житкерде.

— Иртәгәдән алып... корал тота алган барлык ирләр ук атарга, аркан, сөңге ыргытырга, кылыч белән чабарга өйрәнә башлыйлар, — диде ул кычкырып. — Ун кешелек алайда бер өйрәтүче була. Алай башы алып ир, оста сугышчы булса, үз ирләрен үзе өйрәтә. Алай булмаса, унбашына ярдәмгә бер оста бирелә. Сугыш уеныннан беркем читтә калмый — көтүчеләр дә, олаучылар да, ашчылар да... төнгекөндезге торгаклар, аерым сакчылар... беркем дә! Берәүләр иртәнге күлемдә күнексәләр, икенче берәүләр — кичке күлемдә. Кемнең кайчан күнегүен меңбашы... Кәлтә...

— Кәлтә?!

— Меңбашы?! — диештеләр ирләр, исләре китеп.

Тәгин углан, иреннәрен нык кыскан хәлдә, ирләрнең тынычланганын көтеп торды. Аның эндәшмәвен күреп, ирләр, киресенчә, ныграк шауларга тотындылар. Тәгин угланның боерыгы беркемнең дә күңеленә хуш килмәде. Өлкәнрәк ирләр үзләрен болай да оста сугышчылар дип исәплиләр иде, шунлыктан белгән нәрсәне янадан өйрәнеп тору аларга көлке тоелды. Яшьрәкләр исә күбесенчә үз көчләренә, житезлекләренә исәп тоталар һәм шулай булгач, аларга да ук атарга, сөңге ыргытырга өйрәнеп торуның бернигә кирәге юк иде.

Сөн ире — тумыштан ук сугышчы. Сөн малае дүрт-биш яшьтән сарык, тәкә сыртына әләгеп китә, биш-алты яшьтән юашрак атка атлана. Шул ук вакытта ул өлкәннәр ясап биргән кечкенә ук-җәя белән тычкан, йомран ише вак җәнлекләр аулый башлый. Унөч-ундүрт яшь-

тә инде ул чын атка атлана һәм үлгәнче аттан төшми. Сөн ирен сугыш эшенә чынында беркем өйрәтми — ул үзе өйрәнә — башта өлкәннәрдән күреп, аннары төрле яуларда катнашып Тумыштан сугышчы булса да, шулай да аны менә дигән сугышчы дип әйтеп булмый. Кайчагында аның угы читкә оча, сөңгесе тиешле җиренә барып җитми яисә кылычы йомшак булып чыга. Үзе ул, Төпсә кебек, еш кына башбаштаклык күрсәтә һәм Төпсә кебек үк бөтенләй кирәкмәгәнгә башсыз кала.

Ләкин арада менә дигән алыплар да бар! Туңгак алыптай турылыклы батыр ирләр бар, Кәлтәдәй кыю, карусыз ирләр бар. Аңа, тәгин угланга, нәкъ менә шундый ирләр кирәк. Берәү, икәү генә түгел, барысы да шундый булган батыр, кыю, турылыклы ирләр кирәк!

Төрле яктан кычкырган, көлгән тавышлар ишетелде.

— Син безне яуга җибәр, улым. Без сиңа шунда күрсәтербез осталыкны!— диделәр өлкән ирләр, күрәләтә мыскыл белән.

— Төне буе керфек какмый сакта тор да, көндез яңадан ук атарга тотын, имеш! — диделәр таза ирләр, ачыктан-ачык ризасызлык белән.

— Яшьләр өйрәнсен. Кереш тартып безнең бармак битләре каешка әйләнгән! — диделәр картраклар.

— Укны җилгә очырырга ярамаганлыгын гына беләбез! — диделәр яшьләр, өлкәннәр сүзен куәтләп.

Шау-шу көчәя башлагач, тәгин углан, берни әйтмичә, башта Кәлтәгә, аннары Адайга карап алды, үзеннән артта йөзбашларына, унбашларына, алып-ирләргә капма-каршы якта зур бер төркем булып торган егетләренә күз салды. Егетләр арасында сүз кайтаручы, остаручы кешеләр күренмәде. Төпсәнең башы чабылган теге көннән соң аның элекке егетләре генә түгел, алар арасындагы «башбаштаклар» да үзләренең тәгин угланнары тирәсенә ныграк туплана төштеләр. Алар аның күзенә генә карап тордылар.

Менә әле дә егетләрнең үзенә эттәй турылыклы булуларын күреп-тоеп, яшь угланның үз-үзенә ышанычы арта төште. Күп яулар күргән, күп яралар алган таза, батыр ирләргә ул тыныч кына карап торды да, сүз башларга җыенып кулын күтәрде.

— Бүгеннән башлап Кәлтәне меңбашы итеп билгелим! — диде ул өзелгән сүзен ялгап.

Ләкин аны тагын бүлдерделәр. Кәлтәнең меңбашы булуына яшьләр сөенеч белдерделәр — алар шундук тилереп шауларга, кычкырырга тотындылар. Бары өлкәннәр, картлар гына артык куанырга ашыкмадылар. Йөзбашы Җирән көнләшүеннән, хурлануыннан кара янып чыкты. Тәгин углан кемне дә булса меңбашы итеп куя икән, иң элек, билгеле, ул аны — атаклы йөзбашы Җирәнне куярга тиеш иде! Аның якыннары, коралларын баш өстенә күтәреп селки-селки, ризасызлык белдерделәр.

Кырын күзе белән генә тәгин углан янә үзенең егетләренә карап алды. Тавыш басылганын аңа тагын көтеп торырга туры килде. Ул, берни булмагандай, сүзен яңадан ялгап алып китте:

— Минем кул астындагы барлык ирләр сугыш уенында менбашы Кәлтәгә буйсыналар. Кемнең кайчан уенга чыгачагын, кемнең кайчан сакта-каравылда торачагын — барысын да меңбашы Кәлтә белән киңәшеп эшлисез. Минем уң кулым — Адай, сул кулым — Кәлтә. Аларның боерыгы — минем боерыгым. Минем боерыкны...

— Аңлашылды!

— Шулай булыр! — диделәр яшьрәк ирләр, шау-гөр килеп.

— Ярар, ярар! — диделәр өлкәнрәк, шомарганрак ирләр, таралыша башлап.

Аларның шулай сүзне әйтеп бетерергә дә ирек бирмичә, әледән-әле үзен бүлдерүләре һәм гомумән санга сукмагандай кыланулары Албу-

ганың кытыгына тиде. Үз-үзен никадәр тыярга тырышмасын, шулай дадул түзмәде — агарынып, калтыранып:

— Мин сезгә таралырга кушмадым! — дип кычкырды.

— Тыңлыйбыз, тыңлыйбыз — тагын ни бар? — диделәр шома ирләр, урыннарына кире килеп.

— Тыңласагыз, шул: минем боерыкларны җиренә җиткереп үтәргә!

— Үти алмасак, нишләтерсең, улым? — диде Җирән янындагы бер алып ир тыныч кына.

Төпсәнең үтерелүе һәм аннан да бигрәк Җирәннең куркытылуы өлкән буын ирләрдә ачу һәм үртәлү тудырган иде.

— Боерык аңлашылмаса, сорарга — ирек. Аңлашылган боерыкны үтәмәгән өчен... кемнең кем булуына карамастан, башы чаптырылачак!

— У-о!

— Мондый эшкә кем өйрәтте сине, балам!

— Кем булсын — Туңгак алып!

— Ул инде теге дөньяда — өйрәтсен күрмәсләрне![1] — диештеләр төрле яктан алып ирләр.

Кайберәүләр көлеп куйды, кайберәүләр сызгырып җибәрде. Шулай да күпчелек, бигрәк тә яшьләр, тып-тын торды. Утны-суны кичкән, үлемнең үзе белән якалашкан кырыс ирләр, алып ирләр — унбашлары, йөзбашлары, билгеле, аның теге «башбаштак» егетләре кебек кенә түгелләр иде. Алар белән саграк, уйлабрак сөйләшергә кирәк. Сөйләшкәндә яшь углан булып түгел, уң кул түчи бәк углан булып сөйләшергә кирәк булачак. Шунсыз аларны, күрәсең, барыбер бөгеп, үзеңә кирәк якка аударып булмас иде. Аларны бөгеп, үз ягыңа аударып булмый икән, яшәү турында, үлемне җиңү, көч туплау һәм үлем белән көрәшү турында хыялланырга да кирәкмәячәк иде.

— Язмыш сезне — миңа, мине — сезгә бәйләде, — диде ул, алып ирләргә карап. — Безнең бүгенге көнебез караңгы, киләчәгебез якты. Минем киләчәк сезнең кулда, сезнең киләчәк минем кулда. Якты киләчәкне яулап алу өчен миңа көчле куллар, кыю йөрәкләр кирәк. Алар — сез! Бер кулым бер якка, икенче кулым икенче якка тартса, дошман алдында йөрәгем калтырап төшсә, мин беркайчан да үлемне, кара язмышны җиңә алмаячакмын. Миңа йөз ук атып, йөзен дә дошманның күкрәгенә туры тидерә ала торган төз атучылар кирәк. Миңа эттәй ышанычлы, ач бүредәй усал, юлбарыстай кыю ирләр кирәк. Бармы сезнең арада шундый ирләр?

— Бар! — диделәр төркемдәгеләрнең күпчелеге бер авыздан.

— Булырмы шундый ирләр! — диде Албуга.

— Булыр! — диделәр күпчелек, шулай ук беравыздан.

III

Сугыш уеннары икенче көнне иртән иртүк башланды. Кәлтә белән, үзенең егетләре белән тәгин углан уенчыларны карап-тикшереп йөрде. Калкулык артларында ирләр өчаяк таганга куелган карачкыларга ук аттылар, сөңге ыргыттылар. Тәгин углан ирләрне читтән генә күзәтеп торды. Эленке-салынкы кыланганнарга бер сүз әйтмәде — яннарыннан узып кына китте. Тырышып, чын күңелдән аткан ирләргә, аларның алай башларына, өйрәтүчеләренә мактау сүзләре әйтте. Төркемнәр янынннан ул бер мәртәбә узып китте, ике мәртәбә узды, хәтеренә алган кешеләрен кайтып-кайтып күзәтте. Шул рәвешчә ул кемнең нинди сугышчы, нинди кеше булуын белергә тырышты.

---

[1] Күрмәс — явыз рухлар.

Кич, көтүләр, арбалар туктап, бөтен ил-көн авыл булып утыргач, ул яңадан үзенең йөзбашларын, унбашларын, алыпларын җыйды. Чын күңелдән тырышучыларга мактау сүзләре әйтте, булдыксызларга кисәтү ясады.

Икенче көнне карау-тикшерү эшен ул тулысынча Кәлтәгә тапшырды. Адай белән, егетләре белән ул үзе дә башкалар кебек далага сугыш уенына чыкты.

Шулай итеп, тәгин угланның теләге тормышка аша башлады: барлык ирләр, чын яудагы кебек, көннең-көне буена диярлек көреш тарттылар, сөңге, аркан ыргыттылар, кылыч уйнатып чаптылар. Бик күпләрнең уен азагында телләре аркылы салынып төште. Кичкә таба далада, авыл тирәсендә яшьләрнең шат тавышлары ишетелмәс булды. Олылардан күрмәкче балалар да тынып калдылар.

Ачыктан-ачык каршы килгән, ризасызлык белдергән ирләр, ачуларын йотып, шулай ук дәшмәс булды. Бары хатыннар гына тынарга, авыз йомып торырга теләмәделәр. Җыйнаулашып алар бикә янына килделәр, аңа үзләренең зарларын белдерделәр. Сөн хатыны болай да барлык авыр эшне үзе башкара иде. Сыер саву, өй сүтеп өй кору, ашарга пешерү, бала-чага карау, кием тегү — барысы да аның өстендә. Ирләрнең корал тотып ат өстендә чабудан башка күзгә күренгән эшләре дә юк иде. Шулай да иртә-кич алар хатыннарына әз-мәз булышкалыйлар. Инде алар көн дә таш кискәндәй арып-алҗып кайта башлагач, хатыннарның моңа, билгеле, ачулары килде.

Улларының үзгәрүләрен, ябыгып, тартылып калуларын бикә үзе дә күрде. Ябыгудан, ару-алҗудан бигрәк алар юкка-барга үртәлә башладылар. Энесе Адайга әз генә дә якты йөз күрсәтмәде — башкаларга карата ничек булса, аңа да шулай ук кырыс, таләпчән булды. Адай баштарак берни эндәшмәде, ләкин соңыннанрак бер-ике мәртәбә әнисенә абыйсын яманлап алды. Бикәнең моңа шулай ук эче пошты. Өлкән углы белән ул ачуланмыйча, тыныч һәм олыларча сөйләште.

— Углым,— диде ул аңа уйчан гына.— Кызыңнан аерылгач, синә күңелсез. Йөрәк януыңны басмакчы булып, син үзеңне дә, ирләреңне дә юкка интектерәсең. Сөн илендә беркайчан да ирләр бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы бушка ук атмаганнар. Сөн ирен ук атарга, атта йөрергә өйрәтәм дип көлкегә генә калмассың микән соң?

Соңгы сүзләрен ул чын күңелдән кайгырып әйтте. Ләкин мондый сүзләр яшь угланның йөрәгенә пычак белән кадагандай тәэсир итте. Әнисе аңа үз сүзләрен түгел, Төпсә кебекләр, Җирәннәр һәм башка барлык башбаштаклар, булдыксызлар сүзен сөйли кебек тоелды.

— Әни!— диде ул агарынып.— Килешү буенча, ирләрне син тулысынча миңа тапшырдың.

— Минем аларны кире алырга җыенганым юк.

— Шулай булгач, син миңа каршы килмә!

Ул болай ук дип әйтергә теләмәгән иде, ләкин менә кирәк чагында теленә тиешле сүз килмәде һәм ул үзенең тупаслыгыннан үзе үк кызарынып китте.

— Мин инде сиңа каршы сүз дә әйтә алмый башлармын микәнни?— диде ана, бик нык хәтере калып.

— Алай түгел! Тыңлале, әни!— диде Албуга.— Сөн ире атта да яхшы йөри, уктан да төз ата. Тик менә яу вакытында ул аткан ун укның сигезе-тугызы җилгә оча. Ник? Ул бары яу алдыннан гына, ярышлар алдыннан гына үзенең ничегрәк атканлыгын тикшереп карый. Минем кул астында меңгә якын кораллы ир бар. Кыек-мыек аткан, боерык тыңламаган шул бер мең чамасы ир белән сине, үземне, туганнарымны, бар байлыгымны мин ничек сакларммын да ничек якларммын? Минем бер ирем — ун иргә, ун ирем йөз иргә торырлык булганда

гына мин теләсә нинди дошманны аяк астына сала алачакмын. Менә ул ничек, әни!

Бикә өлкән углының хаклы икәнлеген аңламый булдыра алмады. Шул ук вакытта ул икенче бер нәрсәне дә белде: аның өлкән углы көннән-көн үсә бара, үзгәрә бара. Иң аянычлысы шул: ана белән угыл арасында күзгә күренми торган бушлык барлыкка килгән иде, һәм ул бушлык көннән-көн зурая.

— Диңгез-күл буенда торып калган ир дә шундыйрак сүзләр сөйли иде, — диде бикә уйчан гына, улы белән килешкән сыман итеп.

Диңгез-күл буенда торып калган ирнең кемлеге, исемен әйтмәсәң дә, билгеле иде. Күз алдында булмаган кешенең исемен гомумән телгә алмаска тырышалар. Телгә аласы кеше авыру яисә яралы булса, аның исемен кычкырып әйтү бөтенләй тыела. Үлгән кешене, терeләргә яманлык эшләмәсен өчен, бөтенләй телгә дә алмыйлар, аның турында читләтеп тә сөйләмиләр иде.

— Ул өйрәткәндә мин күп нәрсәне төшенеп җитмәгәнмен, әни, — диде Албуга, әнисенең «теге ирне» искә төшерүенә сөенеп. — Үз башыма төшкәч менә барысын да аңлый башладым.

— Бар нәрсәне бутап, бозып бетермәсәң ярый инде, — диде әнисе.

— Төне буена мин аның белән киңәшеп чыгам, әни,— диде Албуга.— Ятсам да, торсам да, көндез дә... кайда да ул мине күзәтеп кенә тора кебек.

— Мин дә күрәм аны төштә, — диде бикә көрсенеп.

— Хәлләнсә без аны алып кайтыр идек, иеме, әни? — диде Албуга.

— Әйе шул, — диде әнисе, ничектер икеле-микеле итеп.

— Миңа киңәш кенә биреп торса да нинди яхшы булыр иде! — диде тагын углан, хыялланып.— Әллә барып алабызмы соң, әни?

— Юк, юк! — диде бикә куркып, кулын селтәп. — Аягына бассын. Кирәк булса, үзе эзләп табар.

— Әни! Ни сөйлисең син?! — диде Албуга гаҗәпләнеп.

— Антын бозган кеше мантымый. Ул барыбер исән калмаячак, — диде әнисе, дәһшәтле пышылдап. — Онытыйк аны, углым, онытыйк!

IV

Ак урдадан кузгалып китүләренә ун көн булгач, төш урталарында алар Байык буе үзәненә килеп җиттеләр. Бар яктан да ачык, шәрә дала артта калды. Алда — еракта, уңда да, сулда да, бер-берсе артына посып-яшеренеп, очлы, биек таулар калкып утыра иде. Далага якынрак тау итәкләре монда да әле шәп-шәрә иде, арырак, бигрәк тә тау араларында, уенты җирләрдә сирәк-сирәк куаклар, әрәмәләр күренгәли. Куаклы, әрәмәле калкулыклар артында исә тоташ кара урман белән капланган һәм кайбер тау сыртларында, кыя башларында пычак йөзедәй шома ташлар ялтырап күренгән киртләч-киртләч биеклекләр башлана.

Шул таулар, урманнар арасыннан агып чыккан Байык суының киң үзәннәре җәй көнендә ямь-яшел үлән белән каплана иде. Хәзер монда ап-ак булып юка кар катламы ята. Моннан сулда төньяк-көнбатыш юнәлештә — Котлуг бәк, Котлуг бәктән болайрак, көньяктарак аланнарның Күкәл буыны агасы Елдырым бәк кышлавы булырга тиеш. Үзенә дигән кызны Албуга менә шул авылдан барып алырга тиеш иде.

Бөтен ил-көн, таулар арасындагы үзәнлекләргә кереп тормыйча, өстен боз каплаган елганың сул ягында, ике шәрә калкулык итәгендә туктап калды. Бу тирәдә үлән тапталмаган, ашалмаган иде — аяк астында терлекләргә әле биш-алты көнлек азык бар. Кешеләр оя-оя бу-

лып, таралып, билгеле бер тәртиптә өйләр кордылар, арбаларын җайлап куйдылар. Мал-туарны тирә-як болыннарга көтүгә кудылар.

Яңа җирдә өй урыны сайлау һәм арыклау, өй торгызу эшләрен — барысын да бикә үзе башкара. Шуңа күрә мондый эштә улларының булышлыгы аңа бөтенләй диярлек кирәкми иде. Тәгин углан, көтүләрне саклау һәм шулай ук сугыш уеннарым дәвам итүне меңбашы Кәлтәгә йөкләде дә, үзенең яңа җирләрен — биләмәләрен карарга китте.

Кайдадыр шушында, Байык суының уң ягында, карурманлы таулар арасында дунхуларның биш йөз өйлек Харасун буыны булырга тиеш иде. Харасуннар — Начин нойон кешеләре. Качып киткән Начин нойонның менә шул Харасун буыны, җирләре-биләмәләре белән, каган боерыгы нигезендә, Албугага күчәргә тиеш иде.

Начин нойонның язмышын беләләр микән мондагы дунхулар? Белсәләр, үзләрен ничегрәк тотарлар да, белмәсәләр ничегрәк тотарлар? Тәгин угланны, барыннан да элек, шундыйрак сораулар кызыксындырды. Белексез бәкләре сыман алар да киреләнеп маташмаслармы? Ни генә булмасын, үзенә буйсынган халык янына барганда Албуга үзенең егерме дүрт егетеннән, Адайдан башка беркемне дә алмады. Ул монда яуларга килмәде, ә үзенә тиешлене алырга килде!

Ул шулай дип уйлады һәм, бернинди өстәмә саклык чарасы күрмичә, елга үзәне буенча, ашыкмыйча гына үргә таба күтәрелүендә булды. Биш-алты чакрым чамасы җир киткәч алар сул яктан, әле бер тау, әле икенче тау арасыннан килеп, төп үзәндә бергә кушылган күп санлы терлек эзләре күрделәр. Эзләр шундый күп иде — җир өстендәге тигез кар юрганы, йөзләгән, меңләгән ат, сыер, сарыкларның тоякклары белән тишкәләнеп беткән, кайбер урыннарда исә тапталып, боздай тыгызланып калган иде. Төртке-төртке тояк эзләре арасыннан тасма-тасма булып, шулай ук көпчәк эзләре сузылган иде. Барлык эзләр елга буенча үргә, карурманлы таулар ягына таба китә. Димәк, кемнәрдер күченеп киткән. Көнчыгышка, куе урманнар арасына яисә бөтенләй таулар аръягына ук!

Тәгин углан эзләр буенча барды. Юлда сынган ук сабы, күмер, кимерелгән сөяк, тире кисәкләре кебек нәрсәләр күренгәләде. Кичкә таба алар өч-дүрт өйлек авыл урынына тап булдылар. Түгәрәк өй урыннары ап-ак җир өстендә кара тап булып ята. Түгәрәк тапларның уртасындагы учаклар инде сүнгән, көлләре суынган иде.

— Абый, әйдә артларыннан куа китәбез! — диде Адай кайнарланып.

— Алар инде ерак киткәннәрдер. Куып җитә алмабыз.

— Җитәрбез, абый.

Аның шулай бер дә юктан җилкенүе абый кешенең ачуын китереп куйды.

— Миннән узып, юк-бар киңәшең белән буталып йөрисе булма! — диде ул аңа усал гына.

Адай, үпкәләп, авызын турсайтып, иптәшләре янына китеп барды. Бераздан егетләр дә, Адай фикерен куәтләп, төрле яктан киңәш бирә башладылар. Тәгин углан туктап калды. Болай булгач ныклап сөйләшми ярамый иде.

— Мин сорамаганда миңа киңәш бирмәскә! — диде ул, егетләргә карап. — Урынсыз киңәш бирү — шул ук буйсынмау белән бер. Буйсынмаган, боерыкны үтәмәгән кешенең башы чаптырылачак — моны беләсез. Инде шуны да белегез: харасуннар киткән икән, китә бирсеннәр! Үзләре белән алар терлекләрен, арбаларын, балаларын, хатыннарын алып киткәннәр. Көтүлекләрне, тауларны-урманнарны, Байык суын алып китә алмаганнар. Безнең җир безгә калган. Шулай булгач сез — егерме дүрт кеше мең кешегә каршы барабыз дип, кая ашкынасыз?

— Үлемгә! — диде Тишек-Таш.

Егетләр тып-тын булдылар. Тәгин углан аларга кире борылырга боерды.

Кире кайтканда алар уң якта, кара таулар-урманнар арасында нечкә генә булып күккә күтәрелгән ике-өч төтен баганасы күреп алдылар. Вакыт инде соң булса да, алар шул төтеннәр ягына карап киттеләр. Кемнәр икән алар? Әллә урманнар арасында качып калган кешеләр дә бармы монда? Таулар арасыннан сузылган сукмак буенча алар шактый озак бардылар, чокыр-чакырлар, чытырманлыклар аша үтеп, көтмәгәндә нindидер чишмә буендагы кечкенә бер яланга килеп чыктылар. Каршыда, ялан уртасында, кыргый хайван тиреләре катыш агач кабыклары капланган очлы башлы алачыклар тырпаеп утыра иде. Алар күреп килгән төтен баганалары нәкъ менә шул алачыкларның түбә тишекләреннән бөркелеп чыга. Мондый очлы түбәле кайры-тире алачыкларда кыргый җәнлекләр аулап көн күрүче урман кешеләре яши иде.

Көтмәгәндә атлы-коралы ирләр килеп чыгу белән, яланда кинәт ыгы-зыгы купты. Ят кешеләргә каршы ярсып өрә-өрә этләр ташланды. Алачыклар арасында булашкан кешеләр, киресенчә, куркып, кычкырып, каядыр качып китәргә тырыштылар. Арада бер-ике чәрелдек хатын-кыз тавышы ишетелеп китте, кайдадыр балалар елаша башлады.

Тәгин углан үз егетләренә ары бармыйча, ялан кырыенда туктап калырга кушты.

— Качмагыз, качма! — дип кычкырды ул урман кешеләренә.

Аның кычкыруын ишетеп һәм шулай ук коралы ирләрнең бернинди яманлык эшләмәүләрен күреп, качучылар туктадылар да бераз вакыттан кире килделәр. Урман кешеләренең берсе — бөтенләй диярлек шәрә хатын — күкрәгенә кысып яшь бала тоткан иде. Коты алынып, күзләрен зур ачып ул ялан аяк килеш туп-туры кар өстендә басып тора. Алачыктан чыгып йөгергәндә ул, күрәсең, өстенә киенергә дә оныткан иде. Ул, ахрысы, хәзер дә җылы кием турында түгел, бәлки исән калу-калмау турында гына уйлый. Үз гомере, баласының гомере өчен курку кышкы салкыннан куркуга караганда көчлерәк тә, дәһшәтлерәк тә иде бугай.

Агач арасында ирләр нindидер киек тунап яткан булганнар ахрысы — аларның канга буялган кулларында таш пычаклар бар иде. Арадан берсе ярсып, абалап өргән этләрне кире чакырды да, килүчеләргә каршылык күрсәтергә нияте юклыгын белдереп, кулындагы пычагын җиргә ташлады. Башкалар да пычакларын аяк астына теләр-теләмәс кенә ташладылар. Шәрә хатын нидер мыгырданып, яшеренгәндәй итенеп, шулай да ят кешеләрдән күзен алмыйча, алачыкка кереп китте.

Тәгин углан атыннан төште, коралларын Адайга биреп, әлеге кешеләр янына килде. Ымлыклар белән, кул-баш хәрәкәтләре белән ул аларга бернинди начарлык эшләргә җыенмавын аңлатты. Ирләрнең өлкәнрәге дусларча елмайды да бай киемле яшь ирне үзләренең алачыгына керергә өндәде. Тәгин углан хуҗа артыннан тар, кысан өйгә керде. Учактагы чи утын дөрләп китә алмый азаплана иде — шунлыктан өй эче шактый караңгы һәм төтенле. Сирәк сакал-мыеклы, кысык күзле хуҗа таш савыттагы майлы чүпрәккә ут кабызды. Яктырып киткәндәй булды. Хуҗа сөн телен яхшы гына белә иде. Дөрләп китә алмаган учак янында аякларын бөкләп утырган килеш ул Албугага үзе белгәнне сөйләп бирде.

Харасун дунхулары кичә генә иртүк кузгалып киткәннәр. Өлкән бичә белән тәгин угланның монда күченеп киләсен дә, Начин нойонның теге якка качып китүен дә алар алдан ук белеп торганнар. Бу арада нindидер чин качаклары килеп, аларны — Харасун дунхуларын — котыртып йөргәннәр. Сөннәр сезнең хатыннарыгызны, мал-туар-

ларыгызны тартып алачак, үзегезне кырып бетерәчәк, дигәннәр; Начин нойон янына, таулар аръягына качыгыз тизрәк дигәннәр. Дунхуларның бу яктагы яхшы көтүлекләрне ташлап китәселәре килмәгән, аннан соң алар таулар аша үтеп булмас дип тә курыкканнар. Ләкин таулар арасында урман кешеләре генә белә торган юллар, сукмаклар бар икән. Дунхулар, кылавыз итеп берничә урман кешесен үзләре белән алганнар да, бөтенесе берьюлы кубып, теге якка качып киткәннәр.

Тәгин углан хуҗаны бүлдерми генә тыңлап утырды. Хуҗа сөйләп бетергәч тә ул аңа берни эндәшмәде.

— Моңарчы ничек яшәгән булсагыз, шулай яши бирегез. Дунхуларга ни түләгән булсагыз, миңа да шуны түләгез, — диде ул урман кешесенә.

Киткән чакта ул хуҗага көмеш саплы тимер пычагын бүләк итеп бирде. Ит тунаучы ирләрнең таш пычагы аңа бик тупас күренгән иде. Чыннан да, бүләккә хуҗа бик сөенде. Аның, билгеле, үзенең дә бу юмарт, бай угланга бирәр нәрсә бүләк итәсе килде. Ул агач ботагына эленгән һәм бөтенләй диярлек туналган боланның бер як арт санын тиз-тиз генә чабып төшерде дә Албугага тоттырды.

— Урманда киек күп. Тагын кил, куна кил, — дип сөйләнде ул, бертуктаусыз кабаланып.

Кич караңгыда алар авылга кайтып җиттеләр. Тәгин углан үзе өчен корылган ялгыз өйдә кунды.

Иртән ул әнисе янына керде. Элеккерәк чактагы кебек алар — әнисе, балалар бергәләп, күңелле итеп аш ашадылар. Ашагач-эчкәч бикә белән өлкән углы арасында сөйләшү-киңәшү булды. Сүз күбесенчә быел кышны кайда, ничек кышлау турында барды. Бикә үз улының кичәгенәк кайларда булуы, ниләр күрүе белән кызыксынды. Харасун дунхуларының күченеп китүләренә ул бөтенләй кайгырмады. Тәгин угланга ул соңгы көннәрдә кирәгеннән артык тыныч һәм пошмас булып күренде. Мондый үзгәреш аңа бик үк ошап җитмәде. Бер ирне — унга, ун ирне — йөзгә әйләндерәм дип кара тиргә батып азапланганда, кимендә биш-алты йөз таза ире булган Харасуннарның кул астыннан ычкынып китүләренә аның әз генә дә борчылу белдермәве тәгин угланга бөтенләй аңлашылмады.

— Урда өчен урын карадыңмы соң, улым?

— Өлгермәдем, әни. Бүген тагын йөреп кайтмакчы булам.

— Син инде быел үзеңә аерым урда корырсың, улым. Яшь бичә алып кайткач аерым торырсың.

Аның тавышында бераз гына моңсулык, бераз гына көнчелек һәм үпкә сизелгәндәй булды. Албугага әнисе алдында ни өчендер уңайсыз булып китте.

— Әни, бер-беребезгә без якын гына торырбыз, — диде ул, аның күңелен табасы килеп.

— Мин бу якларны беләм, синең белән урын карарга дип барып йөрмәм, — диде бикә, сүзне икенчегә борып. — Яланда, далада кешеләр бер-берсеннән читтә яшиләр. Таулар арасында ачык җирләр, көтүлекләр тар, кысан. Теләсәң дә, теләмәсәң дә бер-береңә якын утырасың. Тау аралары кышлау өчен генә яхшы. Даладагы иркенлеккә берни җитми, улым. Җир өчен, көтүлек өчен талаш, ызгыш күбесенчә кыш көне таулар, үзәннәр арасында була. Шуңа күрә, улым, җирне үзең генә бүлмә. Үзеңә яхшырак урынны сайлап ал да, калганын ил агаларына, аксакалларга тапшыр.

— Ярар, шулай итәрмен, әни.

— Харасуннарның китүенә кайгырма син, улым, — диде бикә, улының уйларын аңлагандай. — Көн-кунган тауларның бу ягы гомер-гомергә сөннәрнеке булган. Дунхулар — теге якта. Бу яктагы дунхуларның барысы да яуда бөлгенлеккә төшкән әсирләр, коллар алар. Ачык

җирдә, далада яши алмаганга, каганнар аларны шунда — таулар арасындагы үзәннәрдә калдырганнар. Теге яктагы дунхуларда бернинди түрә юк, тәртип юк. Алар теге син күргән урман кыргыйларыннан әллә ни аерылмыйлар. Кем көчле, алар шуңа буйсына. Үзенә кыенлык килсә, дунху бар нәрсәсен ташлап кача, үз көчен сизсә, шундук борынын күтәрә. Дунхудан беркайчан яхшы сугышчы чыкмаячак.

— Теге... алып ир миңа бөтенләй икенче төрле сөйләгән иде, — диде Албуга, әнисенә каршы килеп. — Алар юлбарыстай көчле, сабый баладай юаш дигән иде.

— Теге ир... дунхулар турында сиңа тагын нәрсәләр әйтте? — диде бикә әкрен генә, сак кына.

— Алар таркау. Бер йодрыкка тупласаң, алардан сөңге дә ясап була, ук та ясап була дип әйтте.

— Әй! Сөңге-ук дигәннән, сиңа әйтәсе сүзем бар икән әле, улым,— диде бикә, нидер исенә төшереп. — Кичәгенәк корал ясаучы осталар килде. Алар монда Байык буенда яхшы каенлыклар бар диләр. Ук сабы, сөңге сабы ясарга шул яхшы каенлыктан каен кисәргә рөхсәт сорадылар. Мин синнән башка берни белмим дидем.

— Мин дә синнән башка берни белмим, әни!

— Юк, сиңа белмичә ярамый, — диде бикә, җитди итеп. — Мин юри «белмим» дидем... синең сүзне өстен чыгару өчен. Барысы да аңласын — мондагы җир-суга, урманнарга, тауларга, киекләргә, агачларга — барысына да син баш, син хуҗа.

— Мин нишләргә тиеш соң, әни?

— Син аларга рөхсәт бирергә тиеш.

— Минем исемнән син рөхсәт бирсәң ярамасмы, әни? — диде тәгин углан, китәргә җыенып.

— Алай да ярар, — диде бикә теләр-теләмәс кенә. — Син ашыгасың бугай, улым?

— Ашыгам. Ук атарга чыкканнармы — шуны беләм дә...

Тәгин углан сүзен әйтеп бетерә алмады, — шул чакны бикә янына ашыгып ишек сакчысы кортка килеп җитте. Ул кемнәрнеңдер килүен әйтте. Килгән кешеләр йөзбашы Җирән белән бер-ике аксакал булып чыкты. Шуннан соң күп тә үтмәде, әнисе әйткән осталар килеп җитте. Җирән белән аксакаллар көтүлекләр турында сүз кузгаттылар, корал ясаучы осталар — агаччылар, кырмачлар — әнисе әйткән теге яхшы каенлык турындагы үтенечләрен кабатлады.

Күрекле бикә, тиешле сүзеңне әйт дигән сыман, өлкән углына мәгънәле генә күз карашы ташлап алды. Тәгин углан түргәрәк килде, әнисе янына биеккә, йомшак мендәргә утырды.

— Мин әле үзем өчен җир карамадым,— диде ул аксакалларга җавап итеп.— Үземә, әнием Күрекле бикәгә урда урыны, көтүлекләр билгеләгәч, мин сезгә әйтермен. Җирне бөтен ил-көн белән бергәләп булерсез.

Яшь бәкнең мондый карарын ишетеп, аксакаллар канәгатьләнү белдерделәр. Алар чыгып киткәч, Албуга осталарга борылды.

— Сез әйткән каенлыкны минем үз күзем белән күрәсем килә, — диде ул. — Зурмы ул, нинди рәк? Ук сабы белән сөңге сабы ясарга гына яраклымы ул, әллә арба ясарга дамы? Безгә ук та, сөңге дә кирәк, күп кирәк. Безгә шулай ук яхшы арбалар да, урын-җир, ятак, савыт-саба да кирәк.

— Шулай, шулай, олуг тучи бәк тәгин углан! — диештеләр агаччылар, кырмачылар күңелле шаулашып.— Урман монда күп, теләсә нәрсәгә җитәрлек. Кирәк булса, без сиңа менә дигән карагай бүрәнәләрдән ике кат буралы итеп, биек, иркен кышкы сарай салып бирәбез. Бер дә каганныкыннан ким булмас. Яшь бичә белән рәхәтләнеп торырсыз кышкы суыкларда.

— Кышкы сарай, бүрәнә өй... — диде тәгин углан үзалдына сөйләнгәндәй итеп.— Шәп булыр иде ул ике колач юанлыгындагы карагай бүрәнәләрдән иркен сарай салып куйсагыз.

— Салабыз, салабыз — боерык кына бир! — диделәр осталар күңеллеләнеп.

— Юк, быелга ашыкмыйк әле без, — диде тәгин углан, үзенә үзе каршы килеп. — Безгә башта күп итеп корал, арба җитештерергә кирәк.

— Үзеңә карыйсың, олуг тучи бәк тәгин углан. Кыш озын — сөңге сабына да, ук сабына да агачны таудай өеп куярбыз.

— Сез тау-тау өеп куйган ук, сөңге сапларына ярый ла тимер җиткереп булса!

— Тимер генә им түгел! Тимер җитмәсә, таш, сөяк куярлар, — диде өлкән яшьтәге бер оста.— Бозылды халык — ук башына да тимер, сөңге башына да тимер, пычак та тимер. Элек бер дә тимер дип аптырап тормаганнар.

— Бу якларда тимер ташы чыга торган иске каналар[1] бар дип сөйлиләр, олуг тәгин углан, — диде Җирән сүзгә катышып.

Бикә өенә килеп кергәннән бирле бу аның Албугага карап әйткән беренче сүзе булды. Моңарчы ул үпкәләп, хәтере калып һәм шул ук вакытта бераз гына шүрләгән кыяфәттә, ничек тә аның ягына карамаска, аның күз карашы белән очрашмаска тырышты. Хәзер аның тавышы бераз гына кысылып, карлыгып чыкты. Үз-үзен тотышында, тавышында аның яшь бәк белән татулашу, аңа ярарга тырышу нияте дә бар иде.

Албуга боларның барысын да күреп, тоеп утырды. Аннары ул шуны да күрде: озын мыеклы, шома битле, тук кыяфәтле таза йөзбашы Җирән шулай беренче мәртәбә авыз ачып сүз әйткәч, энисе ялт кына аңа — үзенең өлкән улы ягына карап алды. Энисенең бу җитез күз карашында ул сагаю-шикләнү дә, курку һәм ялвару да сизгәндәй булды. Ул анда шул ирне якларга, кирәк булса, аның өчен бозылышырга да әзер бер тәвәккәллек күрде. Эчке бер сизенү ярдәмендә ул энисе белән йөзбашы Җирән арасында бикә белән кол арасында була торган мөнәсәбәттән дә зуррак, әһәмиятлерәк мөнәсәбәт барлыгын аңлап алды. Шул ук вакытта ул чи үгез тиресенә төренгән килеш, ярым үлек килеш еракта торып калган теге ирнең беркайчан да тук, шома битле булмавын, киресенчә, аның бераз гына шадра булуын, яралы, җөйле булуын да исенә төшерде.

«Антын бозган өчен генә түгел, тагын башка нәрсәләр өчен дә онытырга теләми микән ул тегендәге гарип ирне?» — дип уйлады Албуга энисе турында. Күрәсең, шулайдыр. Нинди кансыз була кайчагында бу өлкәннәр!

Җираннең сүзләренә каршы тәгин углан тиз генә җавап кайтармады. Ул аның ике арадагы — бәк белән осталар арасындагы сүзне бүлдерүен һәм шуның белән сөйләшү йоласын санламавын бик яхшы аңлады. Ләкин ул әлегә үзен чын бәкләрчә, каганнарча тота белми иде. Шуңлыктан ул Җирәннең әдәпсезлеген күрмәмешкә салынды.

— Безнең тимер ташы эретүчеләребез бармы соң? — диде ул көттеребрәк, беркемгә дә туры карамыйча.

— Бар, олуг тучи бәк тәгин углан! — диде Җирән ашыгып.

— Менә дигән тимерчеләребез бар безнең, углым! — диде бикә, йөзбашы Җирәнне яклап.

Аның тавышында куаныч сизелде.

---

[1] Кана(кан) — таш, руда казып ала торган тирән баз, чокыр.

V

Әнисе янынннан чыккач Албуга, сугыш киемнәрен киеп, коралларын алып, Адай белән, егетләре белән далага — ук ату өчен билгеләнгән урынга юнәлде. Шуннан соң ул таулар арасына җир-урын карарга туры китмәкче булды.

Кояш әле ерактагы таулар арасыннан чыгып өлгермәгән иде, шулай да инде көн якты. Атларның шаулатып тын алуы да, ияр каешларының бер-берсенә тиеп ышкылуы да аермачык булып ишетелә торган тып-тын бер вакыт. Артта калган даладагыга караганда монда кар күбрәк, шунлыктан салкыны да йомшаграк, аграк, күңеллерәк сыман иде.

Тәгин углан үзендә искиткеч бер күтәренкелек тойды. Беренче мәртәбә ул каралар белән биектә, түрдә утырып сөйләште. Бәк булып, хуҗа булып сөйләште. Олы булып, акыл иясе булып сөйләште. Аксакалларның, осталарның йөзеннән ул күреп торды — алар аңа олылап, хөрмәт белән карадылар, аның сүзләреннән канәгать булып калдылар. Җирән белән дә араны җайлады — анысы да начар түгел. Дошманнар кими торсын. Әнисе дә канәгать калды.

Әйе, барысын да ул... тәгин углан җайлады. Аның күзенә генә карап тордылар. Моннан соң гел уйлап сөйләргә, кирәкле сүзләр генә сайларга тырышырга кирәк. Киләчәктә каралар белән турыдан-туры сөйләшергә ярамас. Каган кебек, олы бәкләр кебек, карачылар, ишек сакчылары булдырырга кирәк. Өйләнгәч, үзенең урдаң — өч кат бөҗра белән әйләндереп алынган, кораллы торгаклар саклый торган биек Ак өең булгач, барысы да булыр. Булмый калмас! Тәңре углы гомер буена әнисе өендә, әнисе түрендә генә утырмас.

Аның күңеленә шундыйрак масаюлы уйлар килде. Әнисе өеннән ерагаеп, ачык далага килеп чыккач аңа ары-бире юырткан кешеләр, анда-монда туктап калган арбалар, ялгыз өйләр, терлек-туарлар очрады. Көн дә күреп гадәтләнгән өйләрне, арбаларны, терлекләрне ул әле яңа гына күргән кебек булды. Каядыр ашыгучы җайдаклар, кемнедер көтеп утырган арбалар, ялгыз өйләр белән, аяк астында җәелеп яткан җир белән үзе арасында ул ныклы бәйләнеш барлыгын тойды. Якындагы калкулыклар, ерактагы биек таулар, өстең боз каплаган Байык суы — барлык җанлы-җансыз нәрсә аны — яшь, бөек, акыллы хуҗаны олылыйлар һәм аннан ниндидер яхшылык, изгелек көтәләр иде сыман.

Шулай татлы да, дәртләндергеч тә уйлардан бераз гына башы әйләнеп, күз аллары томаланып барганда аның каршысына каяндыр меңбашы Кәлтә килеп чыкты. Кәлтә аны зурлап, олылап баш иде, сәлам бирде.

— Тотындыгызмы?

— Тотындык, олуг тучи бәк тәгин углан! Бүген иртәнге күлемдә атачак алайларга мин таң атканчы җыелырга боердым. Яктырта башлау белән атарга да керештек.

— Озак сөйлисең, меңбашы Кәлтә, — диде Албуга, шелтәләп түгел, аңлатып-төзәтеп. — Моннан соң сүзләрең кыска булсын, аңлаешлы булсын!

— Булыр!

Меңбашының шулай тиз отып алуына күңеле булып, тәгин углан көлеп куйды.

— Безгә таба ниндидер алай килә.

— Аңлашылып җитмәде.

— Күзәтүчеләр килеп әйтте: кемнәрдер якынлашып килә, — диде Кәлтә кабатлап, бераз гына «кыскартып».

— Кемнәр, күпме — белергә! — диде тәгин углан.

Меңбашы Кәлтә үзе янындагы ирләрнең бер-икесенә ым гына как-

ты, алар шундук китеп тә бардылар. Албуганың күңелле, татлы уйлары, суык җил суырып алган өй җылысы кебек, күз ачып йомганчы юкка чыкты. Чынбарлык — ачык дала, җир-күк күңелдәге хыяллардан кырысрак иде. Кемнәр булыр алар? Качып киткән дунхулар кире килеп арттан төшмәкче булалармы, әллә бөтенләй башка төрле ягылармы?

Албуга үзенең тынып, сагаеп калган егетләренә күтәрелеп карады.

— Тишек-Таш! — диде ул.— Кире авылга чап. Йөзбашы Җирәнгә әйт: андагы барлык ирләр коралланспн, тиз арада минем янга килсеннәр.

Тишек-Таш, аткан уктай томырылып, авыл ягына чапты. Албуга меңбашы Кәлтәгә борылып карады.

— Ату уеннарын туктатырга! Тупланырга боерык булганны көтеп торырга.

— Торырбыз!

Кәлтә үзенең егетләре белән атучылар янына китеп барды. Тәгин углан урыныннан кузгалмыйча шунда торып калды. Берникадәр вакыттан соң Кәлтә ашыгып кире аның янына килде.

— Мең кешелек алай белән Салчак алып килә, — диде ул.

Бу бөтенләй көтелмәгән, дунхуларның арттан төшүләре ихтималына караганда да көтелмәгәнрәк һәм гаҗәбрәк хәбәр булды. Албуга нәрсә уйларга да белмәде. Ник килә ул монда Салчак алып? Изге ният беләнме, явызы беләнме? Ни генә булмасын, ул сак, уяу булырга кирәк, дигән карарга килде.

Салчак алыпны ул үзенең тулысынча коралланган, атка атланган меңләп ире белән каршылады. Алар арбалардан, өйләрдән, көтүләрдән читтә, тигез далада очраштылар.

— Мин Сөн йортының башы бөек Туман каганның боерыгын алып килдем, олуг уң кул тучи бәк тәгин углан, — диде Салчак алып, аттан төшеп, аның алдында бил бөгеп.

— Нинди боерык?

— Бөек каган боерыгын бикә дә тыңларга тиеш, — диде Салчак алып туры гына җавап бирмичә.

Каган илчесенең үзенә бил бөгүе, «олуг уң кул тучи бәк тәгин углан» дип эндәшүе Албуганың күңелен тынычландыра төште. Тик менә әнисе турында аның «бикә» генә дип әйтүе эчен тырнап куйды.

— Коралы ирләрең туктаган җирләреңдә калырлар,— диде тәгин углан. — Өлкән бичә Күрекле бикәдән кеше килгәнче үзеңә дә көтеп торырга туры килер.

Салчак алыпның кемлеген белгәнгә күрә, Албуга аның белән шулай юри коры сөйләште. Яшь угланның үзен көттереп торырга ниятләвен белгәч, Салчак алыпның йөзе бозылып китте.

— Мин ашыгам, олуг уң кул тучи бәк тәгин углан, — диде ул. — Каган илчесен болай көттерү килешмәс кебек.

— Мин көттермим. Мин сине тыңлыйм, Салчак алып, — диде тәгин углан тыныч, дәрәҗәле итеп.

Каган илчесе телен тешләп тынып калды. Бикә янына җибәрелгән кеше әйләнеп килгәнче шактый вакыт узды.

Кеше бикәнең рөхсәтен алып килде. Тәгин углан белән Салчак алып бергәләп авылга юнәлделәр.

VI

Каган боерыгын тыңларга бикә белән тәгин угланнан тыш, өлкән бичәнең барлык балалары, туганнары чакырылды. Шулай ук меңбашы Кәлтә, йөзбашы Җирән, бүтән йөзбашлары, унбашлары, аксакаллар,

агалар килде. Боерыкны Салчак алып үзе түгел, аның исеменнән сүз остасы — чәчән әйтте.

— Мин — Сөн йортының башы Туман каган боерам: өлкән бичәм Күрекле бикәдән туган уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга үзенә буйсынган мең ире белән, кирәк-ярагы, өч аты, кораллары, азыгы белән, тугызынчы айның егерме җиденче көненнән дә соңга калмыйча, Урта кичү янына килеп җитсен. Минем боерык үтәлергә тиеш. Үтәлмәсә, баш тартучының башы чаптырылачак, бар байлыгы тартып алыначак.

Чәчән боерыкны ашыкмыйча, ачык итеп, кычкырып әйтте. Барысы да, каган исеменә хөрмәт йөзеннән, баш киемнәрен салып, аяк өсте тыңладылар. Чәчән әйтеп бетергәч, өйдә бик озак тынлык сакланды. Барысы да, авызларына су капкан кебек, миңгерәүләнгән кебек, нәрсә уйларга да, нәрсә әйтергә дә белми тик тордылар.

— Тагын кабатласынмы? — диде каган илчесе, өйдәгеләргә күз йөртеп.

Эндәшүче булмагач ул чәчәнгә тагын кабатларга кушты. Чәчән шул ук сүзләрне яңадан әйтеп чыкты.

Күрекле бикә кинәт битен каплап еларга тотынды.

— Яраткан колымны тартып алды, имгәтеп ташлады! Инде бердәнбер таянычымны да тартып алмакчы,— диде ул яшь аралаш.

— Яудан беркем читтә кала алмый, бикә, — диде Салчак алып.

— Әни! — диде тәгин углан.

— Синең яраткан колың масая башлады, шуңа җәзасын татыды, бикә, — диде Салчак алып тупас кына.

Ул болай да тупас, шөкәтсез бер кеше иде каган илчесе булу өчен ул бөтенләй яраксыз иде. Шундый кайгылы вакытта аның кирле-мырлы сөйләнүе өйдәгеләрнең күрәләтә ачуын китерде.

— Салчак алып, илче булсаң да, бу өйдә син — кунак. Кунакка тыйнак булу килешә, — диде Албуга кызарынып, әнисен яклап.

— Сезнең колыгызны имгәтүдә минем бер гаебем дә юк, олуг уң кул тучи бәк тәгин углан, — диде Салчак алып түбәнчелек белән.

Туңгак алыпның имгәтелүендә үзенең катнашы булуын ул мондагылар беләләр дип, бикә дә шуңа ишарәли дип уйлады, ахрысы. Мондагылар исә бу турыда берни белмиләр иде.

— Без сине гаепләмибез, Салчак алып, — диде тәгин углан.

Мондый сүз ишетеп Салчак алып авызын ачты да калды. Бөек далада каганның тугы теләсә нинди чирүдән дә көчлерәк булса да, монда Байык буена ул шулай да шүрләбрәк килгән иде. Шундый киң күңеллеме соң бу тәгин углан, әллә соң алар чыннан да берни белмиләрме?

— Урдадан чыгып киткәндә ул исән булган, бикә, — диде Салчак алып, баштагы тупаслыгын йомшарта төшеп.

— Ул анда үлеп ята! — диде бикә.

— Кайда үлеп ята, бикә? — диде Салчак алып, бөтенләй ягымлы итеп.

Аның шулай кинәт үзгәрүендә тәгин углан яшерен мәгънә тотып алды.

— Әни! — диде ул тагын әнисенә. — Каган илчесе белән сүз көрәштерү урынсыз. Боерык үтәлергә тиеш. Боерыкны мин үтәрмен, Салчак алып.

— Менә моны мактыйм! — диде илче, ачу китергеч бер өстенлек белән.

— Миңа синең мактавың кирәкми, Салчак алып, — диде тәгин углан. — Атамның — бөек каганның боерыгын мин сөенеп үтәячәкмен. Ул миңе олы яуга чакыра. Уң кул тучи бәк тәгин угланның элеккечә яратуына ул чын күңелдән ышана. Минем өчен, әни, туганнарым, илем-

кенем, моннан да зур куаныч юк. Бүген мин көне буе юлга җыеначакмын, иртәгә таңнан кузгалып китәм.

Өлкән углының бу күтәренке, тантаналы сүзләренә бикә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ул аны бары каган илчесе алдында гына шулай тантаналы итеп сөйләде дип уйлады. Өлкән углының барысын да шулай тиз чамалап алуы, иң кыен чакта каушап, коелып төшмәве, анда Албугага карата янә дә ышаныч тойгысы тудырды.

— Салчак алып, мин сиңе кунак итә алмыйм — кичер мине, — диде ул кинәт хәлсезләнеп, урынына утырып.— Углым, ирләрем яуга җыенганда... мин генә кул кушырып утырмам ләбаса!

Каган илчесе чыгып киткәч Албуга әнисе каршысына тезләнде, аның тез өстенә салынып төшкән хәлсез кулларын үз кулына алды.

— Әнием! — диде ул яратып, иркәләп. — Мондый боерыкны мин күптән көттем. Бөтен ил-көн яу чабарга җыенганда, минем генә читтә калуым гел күңелемне тырнап торды. Бөтен ил-көн яуда чагында минем дә алып ирләр белән бергә буласым килә. Атам каганның күңеле йомшаган — ул мине үз янына чакыра. Менә күрерсең — яуда батырлык, кыюлык күрсәтсәм, ул безне яңадан Ак урдага тарттырып алачак! Ул чагында сиңа ялгыз башың кайгырырга туры килмәячәк.

— Ышанмыйм, — диде әнисе, хәлсез пышылдап.

— Мин барыбер аның боерыгына каршы килә алмыйм, әни, — диде Албуга, нык итеп.

— Әүвәл син аның беренче боерыгын үтәргә тиешсең, улым.

— Нинди беренче боерык ул тагын?

Бикә йомшак кулларын углының маңгаена куйды, сукыр кеше сыман аның битләрен, колакларын сыйпап-капшап карады, беләкләренең ныклыгын, тазалыгын чамалагандай итте.

— Улым! — диде ул йөрәк түреннән чыккан бер җылылык, якынлык белән. — Син Елдырым бәк кызы Алтын-Бөртеккә өйләнеп китәргә тиешсең. Ул синеке булып калырга тиеш. Яудан... кайтмасаң... улыңны сөеп юанырмын.

— Әни, мин!.. — диде шул чакны Адай, нидер әйтмәкче булып.

Кулын күтәргәндәй итеп әнисе аңа эндәшмәскә кушты.

— Адай синең урынга калыр, — диде бикә аның ни әйтергә теләвен белгән кебек.

— Әни, мине дә абый белән җибәр! — диде Адай.

Албуга күкрәген киерде, аягына басты.

— Адай, мин сиңа боерам: әни... туганнар, ил-көн — барысы да синең карамакка кала.

— Абый! — диде Адай, каршы килмәкче булып.

— Каган боерыгы гына түгел, минем боерык та үтәлергә тиеш, — диде тучи бәк тәгин углан коры гына.

VII

Шулай итеп, яңа җирдә кешеләр иркенләп, тынычлап урнаша да алмадылар.

Яу чабуга, иксез-чиксез даланың бер читеннән икенче читенә тиз арада күченеп китүләргә, сугыш-талашларга кешеләр инде күптән күнеккәннәр иде. Аерылышу, озатышуларны да алар инде үз гомерләрендә күп күргәннәр. Яуларның-сугышларның берәүләргә байлык, бәхет, икенче берәүләргә үлем, коллык һәм мәңге кайгы-хәсрәт китерүен алар шулай ук бик яхшы беләләр. Шуңа күрә, яу турында хәбәр килгәч, тыштан алар гамьсез-тыныч калдылар, эчтән исә һәркемнең йөрәге янды. Берәүләр сөекле иреннән, сөекле баласыннан аерылды, икенче берәүләр карт ата-анасын ташлап китәргә тиеш булды. Берәүләрнең

коралы, каты киемнәре бик үк яхшыдан түгел, икенче берәүләрнең юллык азыгы җитешсез иде. Һәркемнең кайгысы — хәл ителмәгән олы һәм кечкенә борчуы, мәшәкате бар.

Эссе җәйдә кинәт күктән китереп койган яңгыр кебек, кыш көнендә томалап яуган тоташ кар кебек искәрмәстән килеп төшкән каган боерыгы бар нәрсәне үзенчә хәл итте. Бөтен ил кайгысы алдында вак-төяк кайгы-мәшәкатьләр, кар астында тигезләнеп калган җирнең кутырлары, кирәксез агач-ташлары сыман, томаланып, тигезләнеп калды.

Алар көне буе юлга әзерләнделәр. Әзерлек төнгә дә калды. Китәсе ирләр коралларын, тәңкәле каты киемнәрен, ат кирәк-яракларын барладылар, каласы кешеләр юлга төенчекләр төйнәде, ирләрнең тегелеп бетмәгән киемнәрен тегеп бетерергә тырыштылар. Сугымчылар ал-ял белми терлек суйды — туңдырып юлга ит әзерләделәр.

Ирләрнең һәркайсына бер айга җитәрлек азык-төлек, өчәр ат, ун кешегә бер казан, ике кешегә бер өй — күтәрмә алырга кушылды. Шуның өстәвенә һәрбер сугышчы ат карау, корал ташу, өй кору, ашарга пешерү өчен үзенә бер кушчы — булышчы алырга тиеш. Кушчыларның беркадәре коллар, каралар иде. Ярлырак сугышчылар исә кушчы итеп үзләренең хатыннарын, үсмер малайларын, я булмаса турыдан-туры сугышта катнаша алмаган элекке сугышчыларны — яралы аталарын, улларын алдылар.

Төн урталарына барысы да әзерләнеп бетте. Тәгин углан Албуга әнисе өендә туганнарын, ил агаларын, аксакалларны, йөзбашларын, унбашларын җыеп үзенең саубуллашу сүзләрен әйтте.

— Оясыннан очып китәргә талпынган яшь бөркет кебек, канат кагарга өлгермәдем — буран чыкты! Анасыннан аерылмаган колын кебек, тояк ныгытырга өлгермәдем — давыл купты! Минем үз өем дә, үз бичәм дә булмады. Сөеклемнең күзләренә карый алмадым, йомшак чәчләреннән сыйпый алмадым, үз углымны күкрәгемә кысып, ата булып куанмадым. Әнием! Мин синең яшь бөркетең, мин синең яшь колының, мин синең яшь бозавың! Туганнарым, энеләрем-сеңелләрем! Илем-көнем! Сезнең кебек мин далада — көтү арасында тудым, сезнең кебек ит-сөт ашап үстем. Мине бөек атам Туман каган яуга чакыра. Мин үлемгә каршы яу китәм. Кире яныгызга кайталмасам, мине мәңге онытмагыз. Әнием! Учагыңа ягып казан асканда минем өлешемне дә салырга онытма. Сезнең өчен, җирем-суым, илем-көнем өчен каным коеп, тәңре катына очсам, мине дә яныгызда дип белегез. Яз көнендә төннек аша бер күбәләк кереп, битеңә, кулыңа кунса — куалама, ул мин булырмын, әни!

Аның саубуллашу сүзләрен бикә күз яшьләрен агызып тыңлады. Башка хатыннар да мышык-мышык борыннарын тарттылар. Бары ирләр генә кырыс, тантаналы бер тынлык саклап, ирлек дәрәҗәләрен саклап, таш кыядай, басып тордылар.

Саубуллашу сүзеннән соң тәгин углан агач күбәтәдән кымыз эчте. Кымызлы күбәтә өй эчендәге барлык кешеләрнең кулында йөреп чыкты. Шуннан соң Албуга үзенең соңгы боерыкларын әйтте. Беренче булып ул Җирәнгә эндәште:

— Җирән! Син минем әниемне саклаячак чиргә баш булып каласың. Әниемне, туганнарымны, илемне-көнемне моңарчы ничек саклаган булсаң, моннан соң да шулай ук сакла. Мин сиңа карата кырыс булдым. Онытт аларны. Мин синең кичерүеңне үтенәм.

— Минем сиңа бернинди үпкәм юк, олуг тучи бәк тәгин углан.

— Кәлтә! — диде углан үзенең меңбашына. — Син минем белән яуга барасың. Син хәзер үк тугыз йөз кешелек алай белән Диңгез-күл ягына китәсең. Мин үземнең егетләремне, йөз-иремне алып Елдырым бәк кышлавына юл тотам. Ярәшелгән Алтын-Бөртеккә өйләнеп, анда

бер өчне кунып, мин туп-туры Диңгез-күл буена юнәләчәкмен. Мине шунда көтеп торырсың.

— Көтеп торырмын!

— Адай! — диде Албуга, энесенә эндәшеп. — Син минем белән кияү-егет булып барырсың. Мине Диңгез-күлгә чаклы озатып куярсың. Шуннан кире монда эни янына кайтырсың. Диңгез-күл буенда торып калган теге алып ирне дә белеп китәрсең.

— Юк, юк! — диде кинәт бикә каршы килеп. — Белешмәсен. Ул инде күчте — төшемдә күрдем.

Албуга, әйтәсе сүзен онытып, тәртелеп калды. Әнисеннән ул бөтенләй мондый сүз көтмәгән иде. Салчак алып алдында «имгәтелгән кол»ны исенә төшергәч, тәгин углан әнисен һаман аны исендә тота дип уйлаган иде.

— Төштә күргәннең газабын без менә өндә татыйбыз, эни, — диде ул бераздан күңелсезләнеп, аңа каты бәрелмәскә тырышып. — Син дә, башкалар кебек, төштә күргән өчен генә аны читкә тибәрсәң, бу кансызлык булыр иде.

— Куркам, улым, куркам.

— Төштә күчкән өндә күчми — син аны беләсеңдер, эни? Ул күчмәгән, ул исән, эни!

— Мин берни әйтә алмыйм, балам... балаларым, — диде бикә ыңгырашып.

— Синең белән миңа, эни, куркуны гына түгел, үлемне дә җиңәргә кирәк. Мин үлемгә барам. Мин үлемне җиңә алмасам, безгә яшәү юк! Имгәтелгән алып ир безгә шул турыда кисәтте түгелме соң?!

— Мин синең теләгеңә каршы килә алмыйм, улым. Тик анда... Диңгез-күл буена Салчак алыптан алданрак барып җитәргә кирәк. Ул монда каган боерыгын гына алып килмәгән, — ул аның... тегенең кайдалыгын да аңдышып килгән. Күңелем шулай сизенә.

— Мин дә сиздем аны! — диде Албуга.

— Без, бикә, Салчак алыпны монда бер-ике көн буза белән сыйлап тоткарларбыз, — диде Җирән, күрәсең, үз гомерендә беренче мәртәбә тапкырлык күрсәтеп.

— Мин, бикә... олуг тучи бәк, Салчак алыпка сиздермичә генә, хәзер үк... менә төн уртасында юлга чыгармын, — диде Кәлтә.

— Мин, эни, теге алып ирне таза-сау килеш синең яныңа алып кайтырмын! — диде Адай.

— Мин, эни, яудан җиңеп, бик күп байлык төяп кайтырмын! — диде Албуга.

— Ак юл сезгә, балаларым! — диде ана, ике як күкрәгенә капланган ике улының аркаларыннан сөеп.

VIII

Елдырым бәккә түләнәсе калымның инде яртысы бирелгән иде. Ике якның да килешүе буенча, кыз янына Албуга быел кышкы олы җыеннан соң барырга тиеш иде. Калымны тулысынча түләргә, каганның байлыгы җитәрлек булса да, калган өлеш турында сүз бары бер елдан соң гына булачак иде. Бер ел эчендә — быелгы кыш башыннан алып киләсе кыш башына кадәр — тәгин углан Елдырым бәктә кияү булып яшәргә, ягъни кызның ата-аналарына көтү көтәргә тиеш иде. Аның шул бер ел буе көтү көтүе түләнмәгән калым исәбенә суктырылачак иде. Кияү кеше көтү көтмәгән очракта, калымның калган өлеше мал белән, кием-салым, алтын-көмеш, савыт-саба белән түләнәчәк иде.

Үзенең булачак беренче бичәсен Албуга берничә мәртәбә генә күреп калды. Башка елларны Елдырым бәк урдага төрле җыеннарга,

олы бәйрәмнәргә килгәндә үзе белән һәрвакыт балаларын да алып килә иде. Быел да ул Сары-су буена ялгыз башы гына килмәде. Тик быел Алтын-Бөртек атлы кызы кияүгә чыгарга тиеш булганга, анасы белән, угланнары белән аны үз урдасында калдырды. Албуганың кызны инде бер елга якын күргәне юк.

Үзенеке буласын алдан ук белеп торганга, ахрысы, беркайчан да ул Елдырым бәкнең Алтын-Бөртек кызын уйлап сагышланмады. Ак урдадагы үзенең үги сеңелләренә, апаларына яисә яшьтәш кыз туганнарына нинди мөнәсәбәттә булган булса, аңа да ул шундый ук дусларча, туганнарча мөнәсәбәттә булды. Бүләккә дип алган йөз баш ат, кырык баш дөя белән, кием-салым, алтын-көмеш, савыт-саба белән, кодалар, кияү-егетләр белән караңгы таңда төн ягына — Елдырым бәк кышлавы ягына кузгалып киткәч, ниһаять, ул аны исенә төшерде, күз алдына китерде. Ләкин ул аны үзе белгәнчә итеп түгел, нишләптер Сөенеч кебек гүзәл итеп, читләштерелгән итеп һәм Табылдык кебек якын, ягымлы итеп күз алдына китерде. Аннары ул аның турында бик озаклап, татлы итеп хыяллана да алмады. Матур уйларын кысрыклап, шундук аның күңелен башка төрле уйлар — яу турындагы, әнисе, туганнары, туган җир турындагы бетми дә онытылмый да торган сагышлы, куркыныч уйлар билəп алды.

Кояш чыгып, җил уянганчы алар шактый ара китеп өлгерделәр. Елдырым бәк кышлавы Байык буеннан ике көнлек ераклыкта булырга тиеш иде. Урта кичүгә соңгармыйча барып җитү өчен, менә бу ике көнлек юлны кимендә бер көнгә кыскартырга кирәк иде. Шуны истә тотып алар туктаусыз чабып бардылар, бер ат арыгач, янәшәдән барган икенче атка атландылар, икенче атлары да арый башлагач, өченче атка күчеп утырдылар. Шулай күчеп атлана-атлана алар көне буе юлда булдылар.

Кичкә таба, кояш җир астына кереп баер алдыннан, алар өч өйлек бер авылга килеп җиттеләр. Бу Елдырым бәкнең Күник атлы карасы булып чыкты. Туктап алар Елдырым бәк авылын сорадылар. Өстенә озын тун киеп, билен киң каеш белән буган, сирәк сакаллы, озын, чандыр Күник карт аларга юл өйрәтте. Көне буе атта чабып килгәнгә, арыган, йончыган яшь угланнарның кемлеген, кая баруларын белгәч, Күник карт кинәт кабаланырга тотынды. Тиз генә өй ишеген ачып, ул карчыгына нидер эшләргә, нидер әзерләргә кушты. Шуннан соң, чаккак кына титаклап, якындагы өйләрнең әле берсенә, әле икенчесенә барып әйләнде. Күп тә үтмәде, әлеге өйләрдән томырылып балалар, хатыннар, ирләр чыкты. Барысы да, күрмәгәндәй исләре китеп, бай киемле, баштанаяк кораллы тәгин угланга, аның яшь егетләренә карап тордылар. Күник карт юлчыларны ашап-эчеп, кунак булып китәргә кыстый башлады.

— Без күп. Туктап сездә кунак булсак, көтүегездә бер сарык калмас, өегездә бер бөртек ярма калмас, — диде Албуга, китәргә ашыгып.

— Безнең күңел киң, — диде Күник карт. — Үзебезнең бәкнең булачак киявенә мин бүген берне бирсәм, иртәгә ул миңа уны белән кайтарыр. Синнән каршылык булмаса, мин хәзер бөтен көтүемне пешереп алдыгызга куям!

— Безгә барып җитәргә кирәк.

— Ашыкма, улым. Изге юлга чыккансың. Узган төнне таң алдыннан киленем ир бала китерде. Җиремә аяк басып, учагыма йолык бирсп, онывым исәнлегенә иттән авыз итми китсәң, каргармын, — диде Күник карт.

Эшләр болайга киткәч, тәгин углан атыннан төшми булдыра алмады. Үзе белән ул Адайны, Тишек-Ташны гына алды. Алар ит исе, аш исе чыккан җылы өйгә килеп керделәр. Өйдә урта яшьләрдәге тагын бер хатын да ярым-шәрә ике-өч бала бар иде. Күник карт олы кунак-

ларны түргә, үзе янына утыртты. Башта ул аларны кымыз белән сыйлады, аннары казаннан алып кайнар ит куйды. Шул чакны өйгә тагын бер ир уртасы белән яшьрәк егет килеп керде. Алар икесе дә төсләре-битләре, буйлары-сыннары белән аталары Күник картка охшаганнар иде.

— Монысы минем өлкән углым Көчек. Шунын малае бар инде, — диде ата кеше, ир уртасына күрсәтеп.

— Улыгыз таза-сау үссен, — диде Албуга атаны котлап. — Анасына әйтегез: мин аның тизрәк савыгуын телим. Бәби күчтәнәче итеп миннән бер түтәрәм койрык мае бирерләр. Малаеңа миннән — яше тулмаган бер тай булыр.

— Бай бул, олуг тучи бәк! — диде бәхетле ата куанып.

— Менә монысы төпчек улым. Өйләнмәгән, — диде Күник яшь егетне күрсәтеп. — Бавыр! Атлан да, чап урдага! Кияү килә, каршы алыгыз, диген.

— Ярый, эти, — диде оялчан егет.

Тәгин углан нәрсә дә булса уйлап, әйтеп өлгергәнче ул өйдән чыгып та китте.

— Күрдеңме?! — диде Күник карт үзенең олы кунагына, күрәләтә мактану белән.— Баскан урынында торалмый. Бер-ике көннән яуга китә. Монысы да... Көчек тә китә. Быел менә ике улымны җибәрәм. Исән кайтырлармы, юкмы — бары да тәңре кулында...

— Бавыр углың ошады миңа. Минем аңа да берәр бүләк бирәсем килә. Ни бирим?

— Син аңа яхшы җәя бүләк итеп бир. Анын яу өчен яраклы яхшы җәясе юк,— диде Күник карт.

— Синең үзеңә, карчыгыңа ни бирим? — диде булачак кияү юмартланып.

— Миңа бер садак[1] тулы ук бирсәң, шул җиткән. Карчыгыма — тун, менә өлкән углым Көчеккә — бер яхшы ат бирерсең,— диде Күник карт тартынып тормыйча.

— Тагын? — диде тәгин углан.

— Менә... балаларга,— диде карт, өй эчендәге балаларга күрсәтеп.

— Мин аларга уенчыклар, таш савытлар, уенчык җәяләр бирермен. Боларның барысы да миннән кияү бүләге булыр. Минем өчен, минем ирләрем өчен изге теләктә торыгыз. Мин дә кыз куенынннан туры яуга китәм!

— Шулай мени? — диде Күник карт, аптырап, гаҗәпләнеп.

Өй эчендәгеләрнең барысы да, беренче күргән кебек, тәгин углан белән анын егетләренә күтәрелеп карадылар. Моңарчы берни эндәшмичә, башын иеп нидер эшләп булашкан урта яшьләрдәге хатын да, исе китеп башын калкытты.

— Үзең яшь, үзең кияү булып барасың... нинди яу ди ул сиңа? — диде ул кызганып. — Кызың җылап калыр инде, мескенкәем.

— Бу минем икенче хатыным,— диде Күник карт. — Беренчесен моннан ун ел элек җирләдем.

— Берни эшләп булмый — боерык! Каган боерыгы! — диде тәгин углан, хатынга җавап итеп.

— Боерык булмагае, әлләни булсын — син кияү ич! — диде хатын тынычлана алмыйча. — Бәк кияве була торып!

— Ул үзе уң кул тучи бәк тәгин углан! — диде Көчек, үги анасына кычкырып аңлатып.

Хатын бераз гына чукрак иде ахрысы — Көчекнең ничек кычкыруыннан Албуга шундый фикергә килде.

— Кит әле, ташка язмаганны! — диде чукрак хатын ышанасы килмичә.

[1] Садак — ук савыты.

— Язган инде, язган, анасы,— диде Күник карт өлкән углын яклап.— Ни күрәсебез барысы да маңгайга язып куелган. Без аны укый гына белмибез. Ике улым, өч энем яуда үлеп калды. Быел менә соңгыларын озаттым. Ике улымны да. Сезне дә кушсам, өч улым, биш улым була. Бишектәге оныгымнан башка беркемем калмады. Исән-сау кайтыгыз, улларым.

— Шулай булсын, ата! — диде Албуга, урыныннан торып.

Өч өйлек авылның бөтен халкы аларны озатып калды. Көчек үзе теләп Елдырым бәк авылына кадәр кылавыз булып барырга булды.

IX

Елдырым бәк урдасы Күник карт авылыннан әллә ни еракта түгел иде. Урдага барып җитәргә бер-ике чакрым кала юлчыларны Бавыр көтеп алды.

— Хәбәрне әйттем, сезгә шушыннан ары бармаска кушылды,— диде ул кияү буласы кешегә.

Албуга үзенең алаена шунда туктап авыл корырга боерды. Туктау белән берәүләр төргәкле киезләрен сүтеп җиңел өй торгыза башладылар, икенче берәүләр атлар белән булашты. Туктаусыз чабып килгән атлар бик өшәнгәннәр иде. Аларны тиз генә утларга җибәрмәделәр, — кисәк кар ашап эчләренә салкын төшмәсен, авырмасыннар өчен, өсләренә киез эчмәкләр каплап, шактый озак суытып тордылар. Ике-өч сәгать ач тотып суыткач кына аларны, кешәнләп, аяк астына тибенгә җибәрделәр. Атлар ашыгып куе үлән катыш кар кимерделәр — суы да, азыгы да бергә булды.

Йола буенча кыз ыруы җире кияү өчен, аның юлдашлары өчен «дошман» җир исәпләнелә иде. «Дошманнарга» үзләренең «яу» белән килүләрен сиздермәскә тырышып, өйләрдә учаклар тергезелмәде, кычкырып сөйләшү, шакылдау, тавышлану шулай ук тыелды.

Кияү бүген кыз янына урлап туйга бара иде. Туктау белән ул салкын өйдә юл киемнәрен алыштырды, аннан соң үз егетләренә бүләкләр өләште. Елдырым бәк кызына хәбәр алып барган, далада үзен каршы алган Бавырга кияү беренче бүләкне бирде. Бер савыт ук белән яхшы җәя күреп Бавыр куанычыннан телсез-өнсез калды. Юка сөякләр белән ныгытылган, үгез сеңере, балык җилеме белән катырылган алыплар җәясен ул соңгы көннәрендә инде төшләрендә күрә башлаган иде.

Кыз янына барганда Албуга үзе белән егетләрнең бары уникесен генә — өйләнмәгәннәрен генә алды. Монда авылда калачак егетләргә, ирләргә баш итеп Тишек-Ташны билгеләде. Атларны, өйләрне бүген төнлә бик уяу сакларга кирәк булачак иде. Ник дигәндә, «дошман» яшьләре бүген аларга каршы теләсә нинди этлек ясарга мөмкиннәр.

Елдырым бәк урдасыннан бер чакрым чамасы читтә, бар ягы да ачык дала уртасында ялгыз өй корып куелган иде. Әлерәк кенә — кияү килере турында хәбәр алынгач кына куйганнар. Кияүне, кияү-егетләрне Бавыр туп-туры менә шул өйгә алып барды. Еракта өй күренү белән, кылавыз кире борылды. Ул кияү егет түгел иде, шунлыктан анда барырга ярамый. Кире озатканда Албуга аңа тагын ук тулы бер садак бирде.

Бавырдан аерылгач, як-ягына карана-карана ул үзе генә китте. Кияү-егетләр, кияүдән бераз калышып, шулай ук як-якларына каранып, әкрен генә арттан бардылар. Бу тирәдә кияү кешегә аеруча сак, уяу булырга кирәк иде.

Албуга Бавырдан аерылып бер йөз адым чамасы да китәргә өлгермәде, аты кинәт өркеп читкә сикерде. Албуга, ияреннән ычкынып, чакчак кына җиргә мәтәлеп төшмәде — ярый әле аяклары өзәңгегә эләгеп

калды. Иярдән инде егылып төштем дигәндә генә ул җир өстендә ниндидер карачкы күреп калды. Карачкы, бик җитез ыргылып, атның тезгенен тотып алды. Кияү, ияренә кире җайлап утырды да, бар көченә тезгенне тартты. Ләкин карачкы да ычкындырырга уйламады. Албуга аңа камчы белән сыдырмакчы булган иде, шулай да вакытында тыелып калды. Ачуын йотып ул бил каешындагы янчыгына үрелде. Аннан ефәк чүпрәккә төрелгән ниндидер каты нәрсә — таштанмы, алтыннанмы ясалган бизәнү әйбере алып, карачкыга:

— Мә, ал да шуны, юлыңда бул! — диде.

Атның тезгенен тотып алган карачкы көлүгә охшаш ниндидер өн чыгарып читкә тайпылды. Ул китү белән Албуга артыннан аның егетләре килеп җиттеләр. «Ярый әле, җиңел котылдым!» дип уйлады яшь егет. Ләкин шул ук мәлдә, каяндыр аяк астыннан дәррәү кубып, бер төркем кызлар килеп чыкты. Казлар сыман кыйгаклап кычкырган яшь кызлар, чыр-чу килеп, көлешеп, шаулашып, кияүне иярдән үк тартып төшерделәр — шаярып, әрсезләнеп аның беләгенә асылындылар, бил каешына тотындылар, бүләкләр салган янчыгын чишмәкче булып азапландылар. Кызларга әсир төшкән кияүне кияү-егетләр араламакчы булып карады, ләкин кызлар күбрәк, шаянрак, чаярак иде — кияү-егетләрне дә алар берәм-берәм атларыннан өстерәп төшерделәр. Атларны исә камчы белән сыдырып, һай-һулап далага кудылар.

Авылдан, урдадан читтәге ялгыз өйне, ата-анага «әйтмичә», «качып-посып», яшь кызлар, яшь хатыннар корган иде. Киезләрне, кирәгәләрне, өй өчен кирәк булган барлык нәрсәне алар үзләре күтәреп алып килгәннәр. Хәзер алар менә шуның өчен кияүдән бүләк дауладылар. Билендәге авыр янчыкын кияү кулына алды. Кызларның берсенә ул беләзек, икенчеләренә муенса, каптырмаише нәрсәләр бирде. Бүләген биргәндә кызларның әле кулына, әле беләгенә орынып алды, кайберсен шаяртып кочып алды, кайберсенең тун чабуын күтәрде. Кызларның шаярулары- на кияү үпкәләмәгән кебек, аның шулай кул озайтуына да кызлар үпкә белдермәделәр. Киресенчә, кияүдән бүләк алган, тәненә кияү кулы тиеп киткән кызлар, ышану буенча, быел ук кияүгә — һичшиксез, бай кияүгә! — чыгачаклар иде.

Егетләрдән бүләк сорамадылар. Аларга бары икеле-микеле шаян сүзләр генә әйттеләр. Кияүгә дә шундый ук икеле-микеле сүзләр әйттеләр, четрекле сораулар бирделәр. Үзенең бер дә төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтәсе килсә, кияү теләсә нинди сорауга оста, тапкыр җаваплар кайтарырга тиеш иде. Албуга баштарак чак кына каушап калды. Аның йомшаклыгын шундук сизеп алдылар һәм шаян кызлар, яшь хатыннар төрле яктан:

— Ояла, ояла!

— Ир түгелдер бу, кыздыр!

— Каяле, кая! — дип кычкырыштылар.

Бу кызларның, хатыннарның барысы да Алтын-Бөртекнең апалары, сеңелләре һәм җиңгиләре иде. Элеккерәк елларда күргән чакларда алар бер дә алай шаян-усал түгел кебекләр иде. Баксаң, әнә нинди икән алар!

Кызлар җитәкләп, көлеп-шаярып, кияүне ялгыз өйгә алып килделәр, ишекне ачтылар да, барысы да як-якка тайпылдылар. Өй эче караңгы иде. Албуга, керергәме-кермәскәме диебрәк торганда, кемдер шунда арттан төртеп җибәрде. Кияү, кыюланып, серле караңгылыкка атлады. Ләкин беренче адымыннан ук ул аяк астындагы нәрсәгәдер абынып китте, чайкалып алды. Егылмас өчен ирексездән ишек яңагына тотынды.

— Ух, үләм! — диде аяк астындагы кемдер бик каты ыңгырашып.

Тиз генә иелеп кияү аны күтәреп торгызмакчы булды.

— Ни булды? — диде ул.

— Үләм! Башыма таш төште! — диде идәндә, ишек төбендә ятканниндидер хатын-кыз.

— Нинди таш?! — диде кияү шаккатып.

Якында гына тыңлап торган кызлар, яшь хатыннар бөтен даланы яңгыратып көлеп җибәрде. Шул ук мәлдә «үләргә яткан» хатын-кыз ике куллап кияүнең тун чабуыннан эләктереп алды.

— Бүләк! Бүләгеңне бир! — диде ул усал ысылдап, тешләрен шыгырдатып.

«Тагын «бүләк!» дип уйлады кияү, шундук янчыгына тотынып.

— Саранланма, кыз янына җиңел генә керә алмассың!

Албуга бүләк биреп түргә узды. Ул арада өйгә кызлар кереп тулдылар, учактагы утны дөрләтеп җибәрделәр. Өй эче яктырып китте. Идәңгә ак киез җәелгән, киез өстенә, түргә биек агач ятак куелган иде. Ятак өстендә, кабартылган ястык, мендәрләр арасында, яшел ефәк бөркәнчек бөркәнеп, кемдер тып-тын гына утырып тора иде. «Алтын-Бөртек!» дип уйлады кияү, әледән-әле шул якка каранып. Аның тизрәк кызның бөркәнчеген ачасы, кәләшенең тулган айдай сылу йөзенә карап сокланасы килде. Ятак янына сакка баскан кызлар аны якын да җибәрмәделәр.

— Уф! Үтерәсез инде сез мине, кызлар! — дигән булды кияү зарланып.

Кызлар аны үтермәделәр, киресенчә, үлмәсен өчен аш-су әзерли башладылар — шундук киез уртасына ашъяулык җәйделәр, күп итеп табак-савыт китереп куйдылар. Аулак өйдә хәзер урыйн туй башланырга тиеш иде.

Кияү өчен түргә, ятак янына калку, йомшак урын җайланды. Кияү утырасы урынның сул ягына, киезгә тезелешеп кызлар утырды, уң ягына аның егетләре урнашты. Үзара такмаклар, тапкыр сүзләр әйтешеп яшьләр бер-берсен күзәттеләр, көлделәр, шаярдылар. Кияү ишектән кергәндә бусагада сузылып яткан хатын-кыз яшьләр арасында иң өлкәне иде. Табын әзерләү, утырышу — барысы да аның җитәкчелегендә, аның күзәтчелегендә башкарылды.

Табын әзерләнеп беткәч, гел елмаеп торган кысык күзле, ачык, ягымлы йөзле бу өлкән хатын Албуга янына килде. Бу вакытта кияү, үзе өчен җайланган урынга да утыра алмыйча, кәләшенең йөзен дә күрә алмыйча, бер читтәрәк таптанып тора иде.

— Кияү! — диде хатын, Албуганың кулыннан тотып алып.

Барысы да тынып, түр якка — кияү белән әлеге җиңги ягына карадылар.

— Ерак юл килеп син бик ачыккансың — эчең эчкә ябышкан, хәлсезлектән әнә кулларың калтырый, — диде җиңги, кысык күзләре белән генә елмаеп.

— Минем кулым хәлсезлектән калтырамый, җиңги. Минем йөрәгем атлыгып тибә — шуңа калтырыйдыр ул,— диде кияү, оста телләнеп.

— Шулаен шулайдыр да, табындагы азыкларга ач бүре кебек карыйсың, кияү.

— Сүзең хак, җиңги: мин ач бүре кебек сусадым, зарыктым. Бер кашык суга салып йотардай булдым Гүзәл-Бөртегемне!

Шулай дип әйтү белән ул җиңгинең сузылган ак, матур кулына алтын алкалар салды. Ул шулай ук ятак янында «сакта» торган кызларга да бүләкләр бирде дә, чак-чак кына каушап, кызарып, үзенең Алтын-Бөртегенә якынайды, Җиңги белән кызлар читкәрәк киттеләр.

— Яшь танамны бер ел күргәнем юк, байталымны бер ел тотканым юк! Аккошымны кемнәр ябып куйган? Ватам-кырам читлекләрен — чык иреккә, ташлап минем кочагыма, тутый кошым! — дип сөйләнә-сөйләнә кияү калтыранган куллары белән ефәк бөркәнчекне ачып җибәрде.

Ачып җибәрде һәм... чак-чак кына артына авып китмәде. Ефәк бөркәнчек астында аның «тутый кошы», «аккошы», Гүзәл-Бөртеге түгел, ә йөзен җыерчык баскан, тешләре төшеп, ияге шөшледәй очлаеп калган бер кортка утыра иде.

Шаян җиңги кияүне шундук арттан кочып алды, аны юри шап иттереп артына утыртты. Яшь кызлар, киресенчә, сикереп торып аны аягына бастырдылар. Кияү, ятак ягына борылып карарга да җирәнеп, якякка сүзсез генә күз йөртеп чыкты. Әллә шунда берәр җирдә посып торамы соң аның ярәшелгән кызы?

— Эзлә, эзлә! — дип кычкырдылар усал кызлар көлә-көлә.

Бөтен өй эче ду килеп торды. Кызлар, егетләр, бар нәрсәләрен онытып, бөгелә-сыгыла, эчләрен тота-тота көлделәр. Ятак өстендә тыйнак кына утырып торган тешсез кортка да кеткелдәде. Яшь чакларын искә төшереп көлдеме ул, әллә соң башкаларга күңелле булган кебек, аңа да бу аулак өйдә бик күңелле идеме икән?

X

Албуга, түгәрәк өйне бер-ике мәртәбә әйләнеп чыкты да, башкалар кебек үк көлә-көлә түргә, калку урынга килеп утырды. Алтын-Бөртек әле монда булмаска тиеш иде. Кинәт ул шуны төшенеп алды. Үзенең җиңел генә алдануы өчен аңа бик уңайсыз булып китте. Ләкин шул чаклы яшь, чибәр кызлар янында аңа һич тә күңелсез түгел иде.

Ашаганда шау-шу басыла төште. Кызлар «урлап» өйләреннән төрле тәмле азыклар, эчемлекләр — ит, каймак, эремчек, көлчә, кымыз ише нәрсәләр алып килгәннәр иде. Егетләр чыннан да ач бүреләр кебек ашадылар — алларына куйган бар нәрсәне ялт иттереп кенә торды. Кызлар үзләре бөтенләй диярлек ашамады — бары кияү белән егетләрне генә сыйларга тырыштылар. Шулай бераз тамак ялгап алгач, барысы да дәррәү кубып, шаулашып өйдән чыктылар. Албуга учак янында утырып, берүзе өйдә калды.

Кызлар, Алтын-Бөртекне «урларга» дип, Елдырым бәк урдасына киттеләр. Кызны «урлау» кыен булмады. Ата-анасына «сиздермичә» күзен бәйләп, баштанаяк бөркәндереп аны туп-туры бәкнең биек ак өеннән алып чыктылар да капка каравылы яныннан үттеләр һәм, «кача-кача», «курка-курка», ачык даладагы аулак өйгә таба йөгерделәр. Өйгә килеп җитәрәк кызларга кияү егетләре «һөҗүм итте». Алтын-Бөртек өчен ике арада кыска гына «яу» булып алды. Кызлар җиңелде, кәләшне егетләр әсир төшерделәр. Кечкенә дүрткел киезгә утыртып, киезнең дүрт ягыннан күтәреп тоткан хәлдә, Елдырым бәк кызы Алтын-Бөртекне егетләр үзләренең бәкләренә алып килделәр. Ялгыз өйдәге кияү янына кызны шулай кул очларына күтәргән килеш алып керделәр. Алып кереп, аның каршысына, йомшак киезгә утырттылар да, шундук кире чыгып та киттеләр.

Аулак өй янында яңадан күңелле шау-шу башланды. Төне буе далада яшьләрнең шат тавышлары, җырлары, такмазалары ишетелеп торды.

Кызга кияү үзе алып килгән бүләкләрен бирде. Кыз исә аны моннан бер ел элек чит ил сатучыларыннан алып калган һәм бары шушы көн өчен генә сакланып тотылган ят җимешләр белән, ит, кымыз, каймак белән сыйлады.

Алтын-Бөртек бар нәрсәгә исе китеп карый торган зур күзле, ак битле, таза, буйчан бер кыз иде. Күрешми торган бер ел арасында ул тагын да тулыланып, матурланып киткән. Кияү аның кара кашларына, ак кулларына тартынып кына карады. Кызның бар җире килешле,

ягымлы һәм тансык иде. Юка йон киемнәреннән татлы исләр килә. Тик шулай да кияү кешегә бу таза гәүдәле, эре сөякле кыз янында бераз гына кыен, уңайсыз булды. Бик якын утырса да, ул аңа ничектер чит тоелды. Анда чин кызы Сөенечтәге кебек бер күрүдә бөтен тәнгә ут кабыза торган эчке дәрт тә, ялкын да юк иде кебек.

Аулак өйдә беренче очрашу, танышу бик кыска булды. Сиздермичә генә ишек ярыгыннан күзәтеп торган җиңги, яшьләрнең үзара сөйләшер сүзләре беткәч тә, кояштай балкып, җилләнеп өй эченә килеп тә керде. Килеп керде дә, әле кияүгә, әле кәләшкә иплән кенә сүз кушкан булды,— ашарга-эчәргә кыстаган булды. Мондый эштә тәҗрибәле кеше буларак, яшьләрнең сүзсез-хәрәкәтсез утырып, бер-берсенә карата суынуларына ул юл куя алмый иде, билгеле. Чыннан да, җиңгәсе кереп уңайсыз тынлыкны бозгач та, Алтын-Бөртек җанланып китте.

— Кайтыйк инде, эти-әни югалтып ятадыр,— диде ул җиңгәсенә эндәшеп.

— Кайтырбыз. Таң атканчы утырмассың монда чит кеше янында,— дигән булды җиңги дә җиңелчә генә, артык хафаланмыйча гына.

— Нинди кайту ди ул! Кайтмагыз әле! — диде Албуга, кызның кулыннан тотып.

Кыз, йомшак кына каршылык күрсәтеп, кулын тартып алды, аягына басты. Кияү дә торды, кызның юлына аркылы төшмәкче булды. Җиңги кеше, икесенең дә арасына керде дә, бик тә ягымлы итеп, күңелләргә төшеп:

— Бүгенгә җитеп торыр! — диде.

Кызлар Алтын-Бөртекне атасы өенә алып кайтып киттеләр. Кысык күзләре гел елмаеп торган ягымлы җиңги, табак-савыт җыештырган булып, өйдә калды. Сиздермичә генә ул кияү-балакайны күзәтте. Нинди рәк ул? Кызны яратамы, яратырмы? Холкы нинди — артык җебегән яисә, киресенчә, усал, холыксыз түгелме?

Албуга аның үзен күзәтүен бөтенләй сизмәде. Ул башын иеп сүзсез генә утырып торды. Аның бик нык сөмсере коелган иде.

Хәйләкәр җиңги, табак-савытларын җыештырды да, китәргә әзерләнә башлады.

— Тыныч йокы, тәмле төш, кияү-балакай! — диде ул ярым шаяртып.

Бары шунда гына кияү-балакайның йокысы ачылып китте.

— Туктале! — диде ул, җиңгинең кулыннан тотып алып. — Ни... ничек соң? Нишләп болай булды әле бу?

— Ни мени? — диде җиңги көлеп.— Башта ук шулай диләр аны! Җиңгәң белән бер сердә булсаң, уңмый калмассың.

Бүләкләр тутырылган зур гына капчыгыннан Албуга хатын-кыз туны тартып чыгарды. Кеш тиресеннән тегелгән юка, җиңел тунны ул җиңгинең иңбашына салды.

«Качып-посып» кына алар Елдырым бәк урдасына киттеләр. Анда, бәкнең зур, биек өендә, ишектән кергәч тә уң якта, калын киез белән бүлеп куелган бүлмәдә кияү белән кыз өчен күптән инде урын җәелгән иде. Ят өйнең бусагасын атлап кергәндә ишек сакчысы кортка «йоклап» калды, ләкин кияү аның янына үзенең бүләген куеп калдырды. Өй эчендә ата-ана шулай ук берни белми «йоклап» ятты.

Кияүне таң атканчы уяттылар. Ата-ана күргәнче, аны тизрәк өйдән чыгарып җибәрделәр дә даладагы аулак өенә озатып куйдылар. Боларның барысын да шул ук җиңги башкарды.

Таң атып көн тугач Елдырым бәк янына кияү ягыннан кодалар китте. Алар арасында Адай да бар иде. Кодалар белән Елдырым бәк, Алтын-Бөртекнең әнисе калым турында, бүләкләр турында сөйләштеләр. Шунда ук туй турында да сүз булды. Кияүнең, каган боерыгы буенча яуга баруын истә тотып, туйны киләсе елга кичектерергә дип килеште-

ләр. Ашагач-эчкәч, ата белән анага кияү бүләкләрен тапшыргач кодалар кайтып киттеләр.

Төштән соң Елдырым бәк яшьләр өчен ат чабышлары, төрле уеннар, узышлар ясады. Яшьләр күбесенчә көч сынаштылар — ук аттылар, сөңге ыргыттылар. Ярыш башлыча ике ыру яшьләре — Куяннар белән Аланнар-күкәлләр арасында барды. Албуганың егетләре барлык төр узышта җиңеп чыктылар һәм бәк билгеләгән бүләкләрнең барысы да аларга тиде. Аланнарның кызлары гына түгел, Елдырым бәк үзе, аның батыр ирләре дә мондый нәрсәгә таң калдылар.

— Әллә алдан юри килешеп куйдыгызмы? — диде Елдырым бәк, үз яшьләрен чакыртып.

— Берниндиг килешү булмады, бәк.

— Әллә ниндй алар! Аларның уклары икенче төрледер, — диделәр Аланнар, кунак егетләрен хурламакчы булып.

Ләкин кунакларны ачыктан-ачык хурларга беркемнең дә теле бармады. Кияүнең егетләре, ирләре чыннан да «әллә ниндиләр» иде: аларның аткан бер уклары, ыргыткан бер сөңгеләре карачкыга тия торды; алар барысы да кыюлар, җитезләр, өлгерләр. Елдырым бәк моңа сөенде дә, бераз гына көенде дә. Киявенең оста, булдыклы булуын ул бөтен күңеле белән тойды. Ләкин яшь киявенең — тучи бәкнең осталыгы, булдыклылыгы янында үзенең кайдадыр артта калуын аңлау, тою аңа, әлбәттә, күңелсез иде.

Кич Елдырым бәк кодалар өчен аш-су ясады. Кияү, боегып, зарыгып, өендә ялгыз утырып торды. Аңа аннан беркая чыгарга ярамый иде. Бары тик караңгы төшкәч кенә аның янына яңадан кызлар килде, җиңги килде. Шулай ук үзләре далада корган авылдан кияү егетләр килеп җитте. Аулак өйдә кичәгечә җыр-бию, уен-көлке башланып китте. Төн уртасында җиңги яшь кияүне тагын бәк өенә, кыз янына алып китте.

Икенче көнне иртән кияүне кыз яныннан чыгып килгәндә «угрылыкта тоттылар». Шундук аны далага, Алтын-Бөртек атасының малларын көтәргә җибәрделәр. Өченче көнне ул Елдырым бәкнең болындай өен җылыту өчен, аркасына капчык асып, далада коры тизәк җыеп йөрде. Шуннан соң учакка утын, чыбык-чабык ташыды. Өйдә бәк белән, бикә белән очрашканда, ничек тә аларның күзенә карамаска, буйсыну белдереп, баш иеп, бил бөгеп торырга тырышты. Иң ахырда ул, алтын таста су җылытып, бәкнең аякларын юарга булышты.

Шулай итеп, бабай-эби йортында кияү, йола кушканча эшләргә тиеш кара эшләрнең барысын да эшләп чыкты. Шуннан соң кодалар белән бәк арасында яңадан сөйләшү булды. Елдырым бәк яуга китүче киявенә, кызының бирнәсе итеп, тулысынча коралланган, өчәр аты, кушчысы булган йөз илле кешелек алай бирергә булды.

— Кызым үз өемдә калыр,— диде бәк.— Калымның калган өлешен түләп бетергәч, яудан исән-сау кайтса, үзенә алып китәр. Яудан кайтмаса...

— Алтын-Бөртек үземә булыр! — диде Адай ашыгып һәм, кирәкмәгән җирдә кысылуын шәйләп, үзе тагын кып-кызыл булды.

Елдырым бәк озын буйлы, киң күкрәкле алып бер ир иде. Аның янында Адай әле бала гына. Шулай да «бала»ның сүзен беркем дә уенга алмады. Елдырым бәк яшь угланга өстән, югарыдан иелеп бер карады да, зур кулына кысып тотып аңа алтын кәсә белән буза бирде.

— Айак эчәбезмени, кода? — диде ул аңа.

— Эчәбез, кода бабай! — диде Адай батыраеп.

XI

Кияү иртәгә китә дигән кичне Алтын-Бөртекне кызлар даладагы ялгыз өйгә алып килделәр. Беренче өй янына икенчесе — биегрәк, иркен-

рәк өй корылды. «Авылдан» кияү-егетләр дә килде. Иркен өйдә кызлар, егетләр ашадылар-эчтеләр, төрле уеннар уйнадылар. Бүген инде алар арасында җиңги дә, башка хатыннар да юк иде. Бүген яшьләргә тулы ирек бирелде. Борынгы йола шулай куша. Кияү ыруы белән кыз ыруы, яшьләрнең яшерен кавышуы аша, татын да ныграк дуслашырга, туганлашырга тиеш иде. Аннары, кияүнең кыз ыруындагы бер кызны кочарга хакы булгач, ул аны кочкач, үзенә алгач, аның шулай ук башка кызларны да кочарга хакы бар иде. Шулай ук кияү егетләренең дә, кияү белән бер ыру кешеләре буларак, кыз ыруындагы кызларны кочарга тулы хаклары бар иде. Шуның өчен дә алар кияү-егетләр дип аталалар да. Алар тәгин угланның мәңгелек сакчылары, якыннары һәм туганнары иде. Алар аның белән бер табактан бер үк азыкны ашыйлар, бер үк эчемлекне эчәләр иде. Шуның өчен яуда алар аны уктан-сөңгедән саклыйлар, кышкы суыкта — салкыннан, җәйге кояшта — эсседән саклыйлар. Ләкин хуҗалары алай-болай үлеп китсә, аның артыннан шулай ук тере килеш җир астына да керәләр иде. Менә шундый нык туганлык белән туган иде алар үзара.

Ул төнне егетләр, кызлар — зуррак өйдә, кыз белән кияү — кечерәк өйдә кундылар. Төн урталары узгач, кайдадыр якында гына ачы итеп сызгырган тавыш ишетеп, яшь кияү кинәт урыныннан сикереп торды. Астындагы мамык түшәге йомшак, өстендәге юрганы җылы, янындагы яшь кәләше кайнар иде. Менә шулай рәхәтләнеп йоклап ятканда, көнләшкән, үчлекләшкән сыман, кемнеңдер сызгырып җибәрүен аңлап та, аңлатып та булмый иде.

Ул сикереп торды. Бөтен тәне белән калтыранып, нишләргә, кая барырга белмичә, урынында басып калды. Ул арада аның яшь хатыны да уянды. Ул да, аны-моны аңламыйча сикереп торды. Кайнар тән җылысы, назлану сиздергән йокылы тавыш белән куркып:

— Ни булды? Ә? — диде.

Караңгыда ул үзенең яшь ирен күрә алмады. Ул аны тойды гына — җылысыннан, тәненнән килгән таныш, якын истән тойды. Баскан килеш ул аны кочаклап алды. Кайнар, тыгыз беләкләре белән, калтыранган тәне, дымлы озын чәчләре белән ул аңа елан кебек сарылды.

— Ник тордың? — диде яшь хатын үпкәләп.

Аның шулай үз итеп, якын итеп, куркып-каушап әйтелгән сүзләре аша йокылы-уяулы иргә ярату һәм дәрт тойгысы бирелде. Бөтен күңеле белән ул аның үзенеке булуын төшенде. Ике арада ирексез омтылыш, бердәмлек, туганлык тойгысы тудырган куәтле бер көч барлыкка килде. Ләкин тулы шатлык-куанычны бозып, шул ук мәлдә яшь йөрәккә агу булып «яу» дигән куркыныч уй тамды. «Байлык эзләп, бәхет, дан эзләп нигә җир читенә китәргә соң, тәңрем?» диде яшь ир гаҗәпләнеп. Шушы үзе түгелмени байлык, бәхет?!

Биленә, муенына аркан булып уралган чиксез бәхет, шашкын бәхет аны котылгысыз ирексезләп аска, төпсез бушлыкка тартты. Шул чакны яңадан ачы итеп сызгырган тавыш ишетелеп китте. Тышта, ишек артында кансыз-шәфкатьсез чынбарлыктан усал, көнчел тавыш яңгырады. Бу юлы икесе дә дерт итеп сискәнеп киттеләр — кемдер арттан, әйтерсең, шәрә кайнар тәннәрен камчы белән көйдереп алды. Дәрт, омтылыш, сихри көч сүнде, бәхет-байлык күз алдында чәлпәрәмә килде. Әйе, аны, күрәсең, чыннан да җир читеннән эзләп табарга кирәк иде.

— Миңа сызгыралар,— диде кияү, телгә килеп.

— Китәргәме?! Китәсеңмени? Китмә! — диде яшь хатын өзгәләнеп.

— Китмичә булмый.

— Китмә! Мин теләмим! Үзләренә булсын яулары!

Яшь хатын тавышында күз яше сизелде. Ирләрне яуга озатканда күз яше чыгарырга ярамаганлыгын ул белә иде. Үз-үзен тыелырга мәҗбүр итте.

— Мин кайтуга... икәү булып торыгыз,— диде яшь ир.

— Кал! Китмә! — диде Алтын-Бөртек үтенеп, таләп итеп.

Сызгыру тавышы өченче тапкыр яңгырады: моннан соң да өйдә калырга ярамаганлыгын аңлап, кияү киенә башлады. Ул арада Алтын-Бөртек үз киемнәрен актарып аннан бөти тартып чыгарды. Йомшак күн белән тышланган, нечкә каешка тагылган өчпочмакны ул иренең муенына такты.

— Бу безнең Аланнарның абасы,— диде ул.— Аны минем дәү әнинең әтисе тагып йөргән — яудан исән кайткан, әнинең әтисе таккан — исән кайткан. Минем әти тагып йөртте — ул гел җиңеп кайтты. Сиңа дип әни бирде. Ул сине үлемнән саклар. Югалтма.

— Югалтмам,— диде Албуга.

Алтын-Бөртек аны ишек төбенә чаклы озата килде. Баштарак ул аның белән шулай җиңелчә генә саубуллашып калырга уйлаган иде бугай. Ләкин иренең чынлап торып кулдан ычкынуын, китүен, ерагая баруын күреп, аның кинәт башына суккандай булды. Ул яңадан аның муенына сарылды.

— Китмә! — диде ул, хәлсез бер өметсезлек белән.

Яшь ир күндәм генә туктап калды. Аерылышу аның үзенә дә әйтеп бетергесез авыр иде. Яшь хатын тавышсыз гына сулкылдап еларга тотынды.

— Калдырма! Үзең белән алып бар,— диде ул иң ахырда.

— Киен, көтәрмен,— диде кияү.

Алтын-Бөртек ашыгып киенергә тотынды. Ул әллә чыннан да ире белән яуга китәргә җыена идеме, әллә өенә, урдага кайтырга ашыга идеме — Албуга моны аңлый алмады. Ул аны көтеп торган арада тышта кемдер ишек киезен кайтарып карады.

— Исәннәрме? Тордыгызмы? Тиз булыгыз! — диде тынгысыз җиңги, яшьләрне ашыктырып.

Өйдән алар икәүләп чыктылар. Чыгу белән, тыннарны куырып, кышкы салкын өтеп алды. Кайнар каннар суына төште, тиле уйлар сүрелә төште.

Көн әле тумаган, шулай да инде җирнең өсте агара, ачыклана башлаган иде. Кияү егетләр дә, кызлар да — барысы да инде торганнар, киенешеп тышта җыелганнар иде. Беркадәр читтәрәк иярле атлар да, ят ирләр, хатын-кызлар күренгәли.

— Ерак юлга чыгар алдыннан ашап алыгыз,— диде җиңги.

Култыклап — җитәкләп диярлек ул аларны якындагы икенче өйгә алып китте. Анда инде яшьләргә табын әзерләнгән, кайнар аш куелган иде. Итне күп итеп бәк авылында пешереп алып килгәннәр.

Кияү белән кәләшне парлап түргә утырттылар. Егетләр — кияү ягына, кызлар кәләш ягына тезелешеп утырды. Иртәнге аш вакытында берчинди тавыш, шау-шу ишетелмәде. Беркемнең дә әле бу вакыттан ашыйсы да килми иде. Җиңги белән бер-ике өлкән хатын яшьләрне, аеруча егетләрне, туктаусыз кыстап тордылар. «Көне буена җитәрлек ашагыз, ике көнлек итеп ашагыз»,— диделәр.

Алар туенып чыгуга, өй тирәсенә шактый күп кеше җыелып өлгергән иде. Боларның барысы да Алтын-Бөртекнең туганнары, якыннары иде. Арада аның әтисе белән әнисе дә бар, тик аларга йола буенча, кияү күзенә күренергә ярамый иде, шунлыктан алар арттарак, башкалар арасындарак качып тордылар.

Беренче булып атка Албуга атланды, аннан бераз калышып егетләр атланды. Соңгы сүзләр, саубуллашу сүзләре әйтелде, күз төбенә килгән яшьләр сөртелде. Кияү яшь бичәсенең кайнар кулын соңгы кат кысты, тезгенне кагып җибәрде. Ул кузгалып кына киткән иде, Алтын-Бөртек аны тун чабуыннан чытырдатып тотып, бар көченә тарта башлады — Албуга атны тыя төште.

— Калдырма! Китмә! — диде яшь хатын буынсыз булып.

Шундук җинги белән өлкән хатыннар килеп җитте. Үзен-үзе белештермәгән Алтын-Бөртекне алар кочаклап, як-ягыннан култыклап алдылар. Яшь бичә, башын артка ташлап, авызын ачып, тавышсыз гына еларга тотынды.

— Үз башына булгыры! — диде хатыннарның берсе ачуланып, артык шауламыйча гына.

Кияү, ияреннән яртылаш иелеп, ике кулын бичәсенә сузды. Алтын-Бөртек шундук аның кулына тотынды. Арттан аңа хатыннар булышты, һәм ул күз ачып йомган арада ат сыртына — иренең алдына менеп тә утырды.

— Бераз җир барсын әйдә. Тынычлангач төшерерсең,— диде җинги.

Алтын-Бөртектән күрмәкче дигәндәй, башка кызлар да иярдәге егетләр янына менеп кунакладылар. Яшьләр, ниһаять, кузгалышып китте. Бераз калышып аларны Елдырым бәк кешеләре озата бардылар.

Бер-ике чакрым чамасы баргач, төшәргә Алтын-Бөртек үзе сорады. Атлар туктады. Алтын-Бөртек тә, кызлар да барысы да җиргә коелдылар. Кияү белән егетләр яңадан кузгалып киткәч, ачуланган булып алар арттан таш, балчык бәреп калдылар, төрле мыскыл сүзләре әйткән булдылар. Ләкин, йоланы онытып, кайберләре чамадан тыш кычкырып көләргә тотынды, кайберләре исә күз яшьләрен сөртте.

Китте яшьләр. Яуга киттеләр. Үзләре белән, әйтерсең, өйләрдәге учак җылыларын, күңелдәге барлык татлы тойгыларны алып киттеләр. Төнге караңгыдан арынып бетә алмаган туган җир — туң үзәннәр, бозлы сулар, тәбәнәк калкулыклар мескенләнеп, ятимләнеп калган сыман булды.

XII

Озакламый арттан Албуганың йөз кешелек алае куып җитте. Бераз баргач, алдан килешенгән урында, Елдырым бәкнең бирнәгә дип биргән йөз илле кешелек алае кушылды. Алар арасында өлгер егет Бавыр белән абыйсы Көчек тә бар иде.

Аланнар белән очрашкач, тагын углан үз алаена туктарга боерды. Туктагач ул Аланнарның йөзбашы, унбашлары, алыплары белән танышты. Аларга ул үзенең котлау сүзләрен әйтте, аннары боерыкларны җиренә җиткереп үтәү турында кисәтте. Аланнар яшь кияүнең холкын белмиләр иде әле, шунлыктан алар аның боерык турындагы сүзләрен артык исләре китми генә тыңладылар. Сүзләренә колак салудан бигрәк, алар аның үзен күзәттеләр: кияү аларга яшь, чибәр һәм кызу канлы тоелды. Елдырым бәкнең ирләре барысы да утны-суны кичкән, таза, нык ирләр — сугыш осталары иде.

Яшь хатыны турындагы сагышлы уйларының үзен артка, кирегә өстерәвеннән курыккан кебек, тагын углан бабасы җирләреннән тизрәк ерагаерга тырышты. Туман каган белән очрашуның ничек булырын тулысынча күз алдына китерә алмаса да, шулай ук ул очрашуның күңелле булмаячагын алдан ук чамалап, белеп барды. Атасы алдында, илкөн алдында сынатмас өчен, Урта кичүгә ничек тә иртәрәк барып җитәргә, барып җиткәндә дә, ирләрен, атларын югалтмыйча, әрәм-шәрәм итмичә барып җитәргә кирәк иде. Аңа ничек тә каганның мактау сүзен ишетергә кирәк! Кем белә, бәлки инде ул элекке уйларыннан кире дә кайткандыр, бәлки инде аның күзе ачылгандыр, төрле коткычыларны, ялган күрәзәчеләрне, бәлки, янынннан ук читләштергәндер. Шулай гына булсачы, тәңрем!

Тагын угланның күңеленә шундыйрак өметле уйлар килде. Шул ук вакытта аны икенче төрле уйлар да борчыды. Ул Диңгез-күл буенда

торып калган алып ир турында уйлады. Аңа Салчак алып инде анда барып җиткәндер дә, урыныннан да кузгала алмаган гарип иргә берәр төрле явызлык, яманлык эшләгәндер шикелле тоелды. Атасы Туман каган алдында ул үзен аңа бәйле итеп һәм шулай ук нахакка рәнҗетелгән итеп тойса, алып ир алдында ул үзен никтер бурычлы итеп тойды. Бурычлы булганга, ул һәрвакыт аны юксынды һәм аның киңәшенә, мактавына, җылы сүзләренә мохтаҗлык тойды. Зур яу алдыннан, атасы каган белән очрашыр алдыннан аңа аның белән бер иркенләп сөйләшергә кирәк. Күңелендә аның күптән инде шундый зур бер теләк өлгереп җиткән иде.

Шуңа күрә дә ул Диңгез-күл буена барып җиткәнче, ашау-эчү, йокы турында уйланмыйча, булдыра алган кадәр тизрәк барырга, төн-көн барырга дигән карарга килде. Бу турыда ул үзенең йөзбашларына, унбашларына да җиткерде һәм боерык булмыйча торып туктамаска, диде.

Көндез алар бик кызу бардылар һәм җил туктап, караңгы төшкәнче шактый ара уздылар. Караңгы төшеп, күз бәйләнә башлагач, Аланнар туктап ял итәргә, төн кунарга теләк белдерделәр.

— Мин сезгә ни боердым? — диде тәгин углан Аланнарның йөзбашына.

— Боерык белән генә булмый. Кирәгеннән артык йөк төясәң, дөя дә аягын суза. Без дөя түгел, кияү, — диде Аланнарның йөзбашы.

Аланнарның йөзбашы бер ашаганда бер сарык ашап бетерә ала торган аттай таза алып ир иде. Шуның өстәвенә ул үзсүзле, кире һәм холыксыз да. Беренче очрашуда ук ул тәгин угланга никтер ышанычсыз булып тоелды. Үз-үзен тотышы, салкын күз карашы, сүзләре, кыланышлары белән ул яшь угланга буйсынмаячагын, ни булса да барыбер үз иреген, бәйсезлеген саклап калачагын һәм ни генә кушсаң да, гел каршы киләчәген сиздергәндәй булды.

Менә хәзер дә ул үзен кыю, бәйсез тотты. Тәгин угланга ул хәтта бераз гына баласытып карагандай да булды. Аның мондый өстенлегенә тучи бәкнең җен ачулары килде. Ул кып-кызыл булды.

— Мин боермыйча туктамаска, йөзбашы Этимчәк! — диде ул ничек тә кычкырмаска тырышып.

— Без туктыйбыз. Сез теләсәгез нишләгез,— диде Этимчәк аның сүзләренә әз генә дә исе китмичә һәм, калкандай киң аркасы белән борылып, китеп тә барды.

Шул калкандай киң аркага Албуганың соңгы тондырасы килде. Ул ялт кына үзенекеләргә карап алды. Аланнардан алар азрак иде. Ерагая барган арка берәү булса, бер арканы саклап йөз илле киң күкрәк карап тора.

Күрәләтә каршы килеп, Куяннар белән Аланнарны дошманлаштырып монда берни кырып булмаячак иде. Ләкин шул ук вакытта кире беткән бу Этимчәкнең буйсынмавына юл кую да чиктән тыш хәтәр нәрсә иде.

— Тукта! — диде ул, бар көченә кычкырып.

Этимчәк, буйсыну белдереп, туктарга кирәк тапты. Озын торыклы, озын муенлы тулпар атын кире борып ул тәгин углан янына килде.

— Килештекмени, кияү?

— Килештек, йөзбашы Этимчәк.

Этимчәк, берни әйтмичә, борылып үзенекеләр ягына китеп бармакчы булды.

— Туктале,— диде Албуга.— Моннан соң миңа «кияу» дип эндәшмәскә! Мин синең киявең түгел — Елдырым бәк кияве, йөзбашы Этимчәк!

— Анысы шулай.

— Миңа «олуг тучи бәк» дип эндәшерсең моннан соң,— диде Албуга.— Каган боерыгын үтәп без яуга барабыз. Минем боерыкка буйсынмау белдереп син үз ирләреңә яман үрнәк күрсәтәсең, йөзбашы Этимчәк. Олы яу алдыннан ирләрне туарылдырырга түгел, тагын да ныграк тупларга кирәк. Яуда да мин — бер якка, син — икенче якка тартсаң, дошман безне аерым-аерым тукмап юк итәчәк.

— Кыл өзәр хәлең калмаса, боерык белән тун тегеп булмый,— диде Этимчәк киреләнеп.

Албуга җавап биреп тормады. Юк-бар нәрсә тыңлап торасы килмәгәнлеген сиздереп, ул Аланнарның йөзбашы яныннан беренче булып үзе китеп барды. Барлык ирләргә туктап ял итәргә боерды.

Көне буе ат өстендә килеп арыган ирләр куанышып җиргә төштеләр, аякларын яздылар. Кушчылар тиз арада җиңел өйләр-күтәрмәләр кордылар, учак якмый гына, коры-сары белән генә ашарга әзерләделәр. Атларны суынганчы, тирләре катканчы бер тирәдә туплап тоттылар. Атларга, ачык далада калкып чыккан кирмәнгә[1] көчле сак куелды.

Бик арыган булса да, ашагач тәгин углан йокыга китә алмый азапланды. Аның үзенә бер күтәрмә корылган иде. Йоклый алмый як-ягына әйләнгәләп ятканда янына Адай килеп керде. Тышта тагын кемнәрдер бар иде.

— Кемнәр алар? Ник кермиләр? — диде Албуга.

— Керсеннәрме соң? Берсе — Тишек-Таш, берсе — Бавыр,— диде Адай.

— Керсеннәр,— диде тәгин углан, урыныннан торып.

— Олуг тучи бәк! — диде Тишек-Таш ашыгып, пышылдап.— Аланнарны акылга утыртырга кирәк! Йоклаганда Этимчәкне, алыпларын кырып салырга кирәк.

— Болай калдырырга ярамый, абый! — диде Адай.

— Этимчәктән котылмасаң, сиңа бик авырга туры килер, олуг тучи бәк,— диде Бавыр да, сүзгә катышып.

— Сез шуңа килдегезмени? — диде Албуга, егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап.

— Шуңа,— диде Адай.

Тәгин углан, берни әйтмичә урыныннан торды, җылы киемнәрен киенә башлады.

— Чыкканчы монда уйлашырга кирәк, олуг тучи бәк,— диде Тишек-Таш кабаланып.

— Нәрсә уйлашырга? — диде Албуга, берни аңламаган сыман.— Син котырттыңмыни, Адай?

— Юк, без — барыбыз да! — диде Тишек-Таш.— Бу эшне болай калдырырга ярамый.

— Син, Бавыр, нишләп монда? Син дә Алан ич,— диде Албуга, Бавырны әле яңа гына танып алган кебек.

— Мин — синең яклы, олуг тучи бәк,— диде Бавыр.— Син мине егетең итеп ал. Мин сиңа эттәй турылыклы булырмын.

— Ярар, алырмын,— диде Албуга. Шуннан соң ул Адай белән Тишек-Ташка борылып карады.— Мин сездән киңәш сорамадым. Булды бер. Аланнар — батыр ирләр. Алар бердәм. Булды — ике. Аларны сез әйткәнчә акылга утыртырга ярамый. Булды — өч.

Егетләрнең өчесе дә тынып калды.

— Әйдәгез, алайса, төнге торгакларны карап кайтыйк, барыбер йокы килми,— диде тәгин углан, үзенә яхшылык эшләргә атлыгып торган яшьләргә карата йомшарырга кирәк табып.

— Абый, булмаса, син ятып тор. Без үзебез карап, тикшереп чыгарбыз,— диде Адай.

[1] Кирмән — ныгытылган торак һәм шулай ук хәрби лагерь.

— Болай булгач, син ят,— диде абый кеше тыныч кына.

— Мин ат өстендә килгәндә йоклап алдым,— диде Адай.

— Мин... боерам,— диде абыйсы тавышын үзгәртмичә.

Адай, үзенең олуг абыйсы янында тагын хата ясавын аңлап, шып булды. Аңа берсүзсез буйсынудан башка чара калмады.

«Йөз кеше — йөз төрле уй, йөз төрле холык, йөз төрле омтылыш»,— дип уйлады тәгин углан. Менә шул йөз якка тарта торган йөз кешене, мең кешене бер йодрыкка тупларга кирәк. Борынгы каганнар, атаклы субашлары һәрвакыт шул турыда хыялланганнар. Ләкин беркайчан да беркем дә теләкләренә тулысынча ирешә алмаган. Тынычта алар... сөн ирләре — күндәм, буйсынучан. Яуда, куркыныч алдында — таркау. Һәрбер йөзбашы, меңбашы үз ягына тарта, үзе генә өстен чыгарга, үзе генә җиңүче булырга тырыша. Моннан соң киресенчә булырга тиеш. Тынычта алар үзләренчә яшәсеннәр, үзләренчә куансыннар, яуда, куркыныч алдында бергә туплансыннар. Бер йодрыкка! Карусыз, кыю, чыдам сөн иренә бары шул чагында гына бернинди дошман да каршы тора алмаячак.

Кем әйткән иде соң әле мондый сүзләрне? Әйе, теге алып ир әйткән иде! Ул әледән-әле әйтә торган иде. Белеп әйткән ул. Күрергә иде аны тизрәк!

Төнге торгакларны, көтүләрне бер мәртәбә карап әйләнеп чыккач, ул, бик нык йокысы килеп, кире өенә таба борылды. Өе янында аны ниндидер җәяүле карачкы көтеп тора иде. Бу теге йөзбашы Этимчәк булып чыкты. Тучи бәк белән әйтешкәннән соң аның да тынычлыгы качкан иде, ахрысы.

— Баягы тупаслыгым өчен кичер мине, олуг тучи бәк, — диде Этимчәк, үкенү белдереп.

Албуга, аның сүзләрен аңлап житмәгән сыман, эндәшмичәрәк торды.

— Боерсаң, мин хәзер кузгалып китәргә әзер, олуг тучи бәк.

— Син үзең ни киңәш итәсең, йөзбашы Этимчәк?

— Минме?.. Мин... — диде Этимчәк, көтелмәгән сорауга тиз генә җавап таба алмыйча.— Бер туктагач, ял итсеннәр. Атлар да хәл алсын. Шуннан соң туктамабыз. Диңгез-күлгә җитмичә!

XIII

Төн уртасы авышкач, алар яңадан юлга чыктылар. Таң атканчы бардылар, көне буе бардылар. Атлар арыды, кешеләр йончыды. Шулай да зарланучы, шыңшучы булмады. Кичәгечә күз бәйләнә, атлар сөрлегә башлагач, тәгин углан Этимчәкне чакырды.

— Нишлибез — туктыйбызмы?

Яшь тучи бәкнең үзе белән киңәшүе өчен Этимчәкнең күңеле үсеп китте.

— Боерсаң — туктарбыз, боермасаң...

— Син — әйт! — диде Албуга, аны бүлдереп.

— Туктарга кирәк, олуг тучи бәк,— диде Этимчәк.— Диңгез-күлгә ерак калмады. Шулай да минем бер киңәшем бар.

— Нинди киңәш?

— Синең икенче йөзбашың Тишек-Таш бар. Минем белән генә киңәшеп туктарга боерсаң, ул үпкәләячәк. Аның белән дә киңәшсәң, ул тыныч булачак.

— Менә монысы иң яхшы киңәшең, йөзбашы Этимчәк!

Тишек-Ташны да чакыртып, алар яңадан киңәштеләр дә туктарга булдылар. Төн урталарына чаклы йоклап алгач, яңадан кузгалып киттеләр. Диңгез-күл буена бер тын бик каты чаптырып барганнан соң, икенче төн башланыр алдыннан гына барып җиттеләр.

Күлнең төньяк ярьы буенда туктап, авыл кордылар. Тәгин углан, үзенең Байык буеннан килә торган төп көчләре белән шушы тирәдә очрашырга тиеш иде. Ирләр, авыр юлдан соң тынычланып, шундук йокыга талды.

Иртән аларны ниндидер коралды ирләр уятты. Барлыгы унлап кеше иде. Аз санлы булуларына да карамастан, алар үзләрен хуҗаларча тоттылар. Болар Дингез-күл сакчылары иде. Йокыларыннан көчләп уятылган ирләр сакчыларны Албуга өенә алып килделәр. Күзен рәтләп ачмаган йокылы-уялы тәгин углан аларны баштарак теге Байык буеннан килгән үз ирләре дип уйлады, ләкин шулай булса да ул аларның берсен дә рәтләп танымады.

— Сез кемнәр? — диде күл сакчыларының берсе, Албугага усал гына эндәшеп.

Ул да аны бик үк белми иде, ахрысы.

— Син үзең кем? — диде аңа каршы Албуга.

— Без — каган кешеләре,— диде күл сакчысы.

— Сез каган кешеләре булсагыз, мин каганның өлкән углы... уң кул тучи бәк Албуга,— диде тәгин углан, үзе белән сөйләшкән усал унбашына якынрак килеп.

Ат өстендәге унбашы шундук атыннан төште, буйсыну белдереп, тәгин углан алдында бил бөкте.

— Танымадым, кичер, олуг бәк,— диде унбашы.— Безгә боерылган: күлгә беркемне якын җибәрмәскә, диелгән. Син инде беләсең булыр.

— Байык буеннан чиру килгәне ишетелмәдеме? — диде Албуга аны тыңламыйча.

— Ябалак картны ат койрыгына тактылар — син әле белмәдеңмени, олуг тучи бәк? — диде унбашы шулай ук үз уйлары белән мавыгып.

— Кемнәр? Ник? — диде Албуга.

— Ярлы чиннәрнең берсе шымчы булган. Шул барып әйткән Исәнтәйгә,— диде алай башы.— Исәнтәй анда Ак өйдә каганның уң кулына әйләнде — аның урыны түрдә!

— Шымчыны нишләттегез?

— Без нишләтик аны — Исәнтәй янындадыр. Аңа безнең кул җитми. Ябалак кызганыч. Бөтен гомерен шушында уздырды — яуга йөрмәде, күченмәде. Кендеге бәйләнгән кебек, корткасы янында, күл буенда бер рәхәтсез гомер кичерде. Мәетен далага чыгарып ташладылар, өен яндырдылар, корткасын куалап җибәрделәр.

— Кайчан?! — диде Албуга әле һаман ышанасы килмичә.

— Кайчан булсын — моннан бер атна элек бугай.

— Кем? Исәнтәй үземе?

— Салчак алып,— диде күл сакчысы.

Албуганың кинәт күз аллары яктырып китте.

— Яралы ир исәнме? Яралы арыслан исәнме?! — диде ул, саңгырау кеше белән сөйләшкән сыман кычкырып.

Алай башы кем турында сүз барганын, билгеле, аңлады. Күзен читкә борып ул көрсенеп куйды.

— Белмим,— диде.

— Нәрсә белмисең — исәнме, юкмы?! — дип кычкырды Албуга.

— Белмим.

— Аны да... үтерделәрмени? — диде тәгин углан, тынын кысып, әкрен генә.

— Берни белмим,— диде аңгыра алай башы, бер үк сүзне тукып.

Ләкин менә шул «белмим»ендә аның нидер белгәнлеге сизелде. Үзенең ирләреннән уңайсызлана идеме ул, әллә башка нәрсәдәнме — шулай да аның нидер яшергәне күренеп тора иде.

Аяк буыннары йомшап калган тәгин углан күл сакчысы алай башын үз өенә чакырды. Учакка коры тизәк өстәп җибәргәч, ул киез өстенә

аякларын бөкләп утырды да кунагына да утырырга кушты. Утыргач, алар бер касәдән кымыз эчтеләр.

— Ни сорыйсың: атмы, тунмы, коралмы? — диде тәгин углан, туптуры сүзгә күчеп.

— Үзеңнеке кебек озын торыклы тулпар ат бирсәң, аны миннән барыбер тартып алырлар,— диде кунак.— Үзем сыман тәбәнәк буйлы, юаш, чыдам атым болай да бар. Өстемдәге туным иске, иске булса да, җылы. Җәяне, укны мин үзем ясыйм — урман ерак түгел.

— Кызмыни? — диде тәгин углан, яшь алай башының тел төбен аңлап.

— Әйе, кыз, — диде кунак.

— Яудан алып кайтсам, теләгәнеңне алырсың,— диде Албуга.

— Юк,— диде кунак.— Миңа кыз син яуга киткәнче кирәк. Көн дә кирәк. Тун мине көндез җылыта, төнлә — суык.

— Каян алыйм мин сиңа хәзер генә кыз? — диде тәгин углан, мондый сату-алуга үртәлә башлап.

— Аны син алмассың, мин үзем алырмын, олуг тучи бәк,— диде кунак. — Миңа кыз өчен түләргә байлык кирәк. Мин аны сатып алам. Моннан өч көнлек ераклыкта, таулар арасында, бер ярлы чин картының гүзәл кызы бар. Шуңа күзем төште. Менә ул кайда кыз! Карт ярлы. Аның җигәренә бер дөя, бер-ике ат, туенырына иллеләп сарык кирәк.

— Булыр,— диде тәгин углан.— Инде сөйлә. Берни калдырмыйча сөйлә.

— Сөйлим,— диде кунак, яңадан кымыздан авыз иткәч.

— Мин аңа ант та бирмәдем, сүз дә бирмәдем. Сөйләмәскә кирәклеген без үзебез генә беләбез. Шымчының Исәнтәй янына киткәнен ярлы чин качаклары сизенгәннәр дә борчыла башлаганнар. Шунда әлеге гүзәл кызның атасы да ишетеп алган моны. Шул килеп әйтте. Җәяү килгән. Аты да, дөясе дә юк. Ничек юлда аюга, бүрегә юлыкмаган! Сөйләде бу. Без куркуга калдык. Нишләргә? Ябалак карт әйтте: урдадан тикшерергә килсәләр, бар гаепне үз өстемә алам, диде. Болай да инде миңа күптән вакыт җиткән теге дөньяга китәргә, диде. Безгә ничек тә яралы ирне коткарырга кирәк, диде. Менә шул, олуг тучи бәк. «Арысланның» үзенә без берни әйтмәдек. Яткан килеш арбага чыгарып салдык. Атлар җиктек тә, терлекләрен куалап, бар байлыгын төяп, шул ук төнне таулар ягына алып киттек. Мин дә, абый белән эти. Сер чыгарлык түгел. Без аны шул чин карты янына, таулар арасына илтеп куйдык. Шунда мин аның кызын күрдем.

— Табылдыкнымы? — диде Албуга кинәт балкып.

— Юк. Чин картының кызын. Табылдыкны яралы ир янында калдырдык. Ул батыр, уңган кыз икән. Яралы ирнең баш очында гына утырды, дип сөйләде Ябалак карт.

— Табылдык... — дип куйды үзалдына яшь углан, сагышланып, гүзәл кыпчак кызын күз алдына китереп.

— Чин карты анда таулар арасында Исәнтәйдән качып ята икән. Анда аларны беркем табарлык түгел. Бездән соң бер көн уткәч тә күл буена Салчак алып килеп төшкән. Аннан ул әнә Байык буена китте.

— Алар... әле дә анда таулар арасында микән? — диде Албуга.

— Белмим,— диде кунак.— Чин карты әйтте: тыныч булыгыз, мин аларны беркем таба алмастай җиргә яшерермен, диде. Кызын алырга барсам, мин барысын да белермен.

— Менә нәрсә, Җидекул... синең исемең Җидекул бит әле?— диде Албуга, кунакның йөзенә җентекләбрәк карап.

— Әйе, Җидекул, олуг тучи бәк! — диде унбашы, Албуганың үз исемен белүенә сөенеп.

— Менә нәрсә, Җидекул. Бу турыда башка беркемгә дә тишмәсәң, үлгәнче минем дустым булырсың.

— Ант! Ант! Ант! Мәңге колың булырмын, олуг тучи бәк.

— Яудан кайткач, мин сине эзләп табармын. Шунда без бергәләп алар янына барырбыз.

— Мин башкаларга сиздермичә генә белешеп торырмын, кирәк булса, берәр нәрсә белән булышырмын,— диде Җидекул.

— Булышу дигәннән, Ябалак картның корткасы кайда икән хәзер?

— Ярлы чиннәр янында булырга тиеш.

— Син аны берәр ничек минем әни янына, Байык буена илтеп куй. Минем әнигә барысын да сөйләп бир. Син сораган терлекне дә сиңа ул бирер.

— Барын да син әйткәнчә эшләрмен, олуг тучи бәк,— диде Җидекул.

— Онытма: теге таулар арасындагы ирне ничек тә сакларга, аякка бастырырга кирәк. Минем өчен, әнием Күрекле бикә өчен бөтен Сөн илендә иң кирәкле кеше ул, Җидекул! — диде тучи бәк Албуга.

Алтынчы баб

I

Шулай итеп, Банхуа-Исәнтәй Туман каганның уң кулына әйләнде куйды. Урдадан Туңгак алыпны кысрыклап чыгаргач, ул аның урынын җиңел генә биләп алды. Хәзер инде каган бер генә эшен дә кыек авызлы, ләкин туры сүзле, тик шулай да кара йөрәкле тылмачы белән киңәшмичә эшләми башлады. Элегрәк Туңгак алып белән каган күбесенчә ирләргә, атка, коралга, яуга-сугышка катнашы булган нәрсәләр турында киңәшә торган булса, хәзер ул Исәнтәй белән башлыча хатынкызга, кием-салымга, йорттагы төрле ыгы-зыгыларга кагылышлы нәрсәләр турында киңәште. Мондый катлаулы, четерекле эшләрдә исә Банхуаны һич тә тәҗрибәсез кеше дип әйтеп булмый иде. Кешеләр белән, аеруча хатын-кыз белән ул ничектер бик җиңел генә уртак тел таба белә. Моның шулай икәнлегенә каган инде берничә мәртәбә ышанырга мәҗбүр булды.

Урдага китертелүенең беренче көннәрендә гүзәл чин кызы Сөенеч каганга карата шактый салкын булды. Яшь кыз белән үзе арасында бернинди якынлык булмавына алып ирнең, билгеле, ачуы килде. Сөенеч урынында башка берәр кыз шулай ачуын китергән булса, ул аңа икенче әйләнеп тә карамас иде — шундук аны урдадан куаларга, я булмаса, иң яхшысы, берәр колга кияүгә бирергә боерыр иде. Бу юлы ул алай итә алмады. Бу юлы аңа түзәргә һәм гүзәл кызның холыксызлыгын, тәкәбберлеген татып, ярыйсы ук хурланырга туры килде.

Бөек ирнең хәлен яхшы аңлаган Исәнтәй чин кызы белән үзе сөйләшеп карарга булды. Сөйләште һәм бер сөйләшүдә барысын да җайлады да куйды.

— Сөенеч үзенең абыйсын сагына, аның өчен борчыла. Шуңа күңелсез,— диде ул каганга.

Каган кызның абыйсын урдага китерергә боерды. Мондый боерыкны Исәнтәй бик теләп үтәде — Чәнсинең тегендә, Таштугайда «хуҗа булып» ятуына аның инде күптән эче поша башлаган иде. Аннан соң, каган урдасына Чәнси үтеп керергә тиеш булып та, ул читтә торып калгач, тегендәгеләр, бик ерактагылар моңа ничегрәк карарлар икән?, дигән уй да аңа тынгылык бирми иде. Күңелләре булсын — әйдә, урда кешесе булсын аларның ышанычлы Чәнсиләре!

Чәнсине Исәнтәй каган кырнагы Сөенечнең ат караучысы итеп кую-

га иреште. Төнге салкында йомылып торып та, иртән кояш жылыта башлау белән ачылып киткән алсу чәчәк кебек, гүзәл кырнак кинәт бар көченә балкып китте һәм моннан соң инде беркайчан да үзенең бөек хакименә салкынлык, дәртсезлек күрсәтергә батырчылык итмәде.

Кыздагы мондый үзгәрешкә каган сөенеп бетә алмады. Яз көнендә күз карашын иркәли торган беренче яшел үлән кебек, жылы кояш, якты күк йөзе кебек күңеленә һәрвакыт бәхет-куаныч тойгысы өстәп торган кызны ул яратканнан-ярата барды. Яраткач, билгеле, аның кимчелекләрен дә күрми башлады.

Кимчелекләр исә юк түгел иде! Гүзәл чин кызының башкалар күзенә күренеп тә, бары каган күзенә генә күренмәгән кимчелекләре шул булды: башта ук ул үзенә түрдән урын даулады. Каган каршы килмәде. Чин кырнагы каган янында «табын күрке» булып кына түгел, тулы хокуклы бичә кебек, сул якта, биектә утыра башлады. Бары тик аңа башкалар — туган-тумачалар, агай-энеләр, бичәләр алдында баш игән кебек баш имәделәр дә, бил генә бөкмәделәр. Каганның ата-баба йоласын бозуы көн кебек ачык иде, ләкин яшьлек, гүзәллек һәм аның янындагы көч-куәт һәркемнең күзен томалады.

Башкалар чин кырнагының икенче кимчелеген дә бик тиз күреп алдылар. Алар аның абыйсы Чәнси белән кергәннән артык еш очрашуына игътибар иттеләр. Кайбер очлы күзләргә абый белән сеңелнең үзара мөнәсәбәте бик шикле тоелды. Ләкин бу хакта да сүз кузгатырга беркемнең йөрәге житмәде. Мондый нәрсәләр турында каган алдында сүз кузгатырга батырчылык итәрдәй ике генә кеше бар — икенең берсе Кортка-бикә булса, икенчесе Баргынтай баба. Кортка-бикә читтә иде, турыдан-туры ул бернигә катнашмый, Баргынтай баба исә авыру иде.

Чин кырнагының кимчелекләрен Исәнтәй дә күрде. Күрде, ләкин төзәтергә ашыкмады. Аны әлегә аннан да зуррак нәрсәләр борчыды.

Туңгак алыпны читкә тибәреп, ул бик зур жиңүгә иреште. Тик шулай да бу әле тулы жиңү түгел иде. Бер кызганда аны — Туңгак алыпны — бөтенләй юк итә алмавына ул үкенеп бетә алмады. Каравыл агасы Салчак алыпны шундый ук үкенү газаплады, һәм алар — Исәнтәй белән Салчак алып — үзара бик тиз уртак тел таптылар. Котлуг бәк белән киткән алыпның бары тик Күрекле бикә янында гына булырга тиешлеген алар бик яхшы белделәр. Алар шулай ук аны Күрекле бикәдән жиңел генә тартып алып булмаячагын да аңладылар. Аны аннан йолкып алу, йолкып алгач, юкка чыгару өчен я аларның барысын да юкка чыгарырга, яисә берәм-берәм бүлгәләп, аерым-аерым юкка чыгарырга кирәк булачак иде. Бикәгә, уң кул тучи бәк Албугага каршы алар ачыктан-ачык корал күтәрә алмадылар һәм мондый эшкә каганны да котырта алмаячаклар иде. Өлкән бичә белән уң кул тучи бәккә каршы алар бары таулар аръягындагы дунхуларны гына котырта алалар. Ләкин дунхулар һичшиксез жиңәрләр, дип уйлау да бик үк ышанычлы нәрсә түгел иде.

Үзе өчен бик катлаулы, четрекле тоелган нәрсәнең бар ягын да уйлап карагач, бер көнне Исәнтәй сакланып кына каганга үзенең кайбер фикерләрен әйтергә кирәк тапты.

— Уң кул тучи бәкне яуга алып барырга кирәк, бөек каган,— диде ул.

— Яуга? Нинди яуга ул тагын? — диде каган.

Бу көннәрдә, Сөенеч белән эшләре жайлангач, Туман каган ил-көн, яу-сугыш кебек вак-төяк нәрсәләр белән бөтенләй кызыксынмый башлаган иде.

— Чингә каршы, бөек каган! — диде Исәнтәй, андагы бу үзгәрешкә исе китеп.— Син яуга киткәч, артыңда уң кул тучи бәк кала. Ул сиңа ачулы. Күрекле бикә ачулы, Котлуг бәк ачулы.

— Уң кул тучи бәк тәгин угланның көче юк, Исәнтәй,— диде каган.

— Көче булмаса, аның янында атаклы Туңгак алып бар, бөек каган!
— Син Туңгак алыпны яратмадың — шуңа куркасың аннан. Туңгак алыпның кулы да, аягы да юк. Карачкы итеп бастырып куеп, ул бары ук атарга гына ярый.
— Туңгак алып шул карачкы килеш тә куркыныч, бөек каган! — диде Исәнтәй.
— Курыкканга — куш, ботагы белән — биш! — диде каган, көлеп.
— Байык буеның теге ягында, таулар артында сугышчан дунхулар бар, бөек каган! — диде Исәнтәй бирелергә теләмичә.
Туман каган көлүеннән туктап калды. Дунхулар, Начин нойон аны уйланырга мәҗбүр итте.
Икенче көнне ул Салчак алыпка үзенең уң кул тучи бәк Албуга турындагы боерыгын җиткерде.
Исәнтәйнең түбәсе күккә тиде. Салчак алып Байык буеннан үзләренең төп хаталарын төзәтеп кайтканчы ул үзе монда Сөенечнең «кимчелеген» төзәтеп куярга булды. «Абый» кешенең кыланышлары беренче көннән үк аның саруын кайнатты. Монда, урдада, бераз аның белән янәшә торып карагач, үзе өчен ул аның артык кеше икәнлегенә төшенде. Кирәгеннән артык саксызлана торган яшь «абый»ның бөтен эшне бозып куюы бар. Аны ничек тә тизрәк моннан озатырга кирәк иде.
Җайлап кына ул тагын каганга үзенең кайбер фикерләрен әйтте.
— Синең яраткан кырнагың Сөенечнең бертуган абыйсы бик күңелсезләнә, бөек каган,— диде ул.— Сөенечнең абыйсы әйтә: тегендә мине көтеп торалар, ди. Сөннәр Чингә каршы яу чабалармы, юкмы? Кайчан, каян кузгалырга уйлыйлар — Чжао аксөякләре шул турыда белергә телиләр, ди. Аларга алдан әзерләнеп торырга кирәк, ди.
— Син аңа ышанасыңмы? — диде каган, Исәнтәйнең күзләренә туры карап.
— Бертуган сеңлесе синең куеныңда булганда ышанмаска көчемнән килми, бөек каган,— диде Исәнтәй.
— Миңа ул шикле тоела.— диде каган.— Ярар, китә бирсен.
Соңгы өч сүзенең мәгънәсе хакында уйлап бетердеме ул, юкмы...

II

Мондагы хәле икеле-микеле булуына да карамастан, каган урдасыннан Чәнси теләмичә генә китте. Мондагы буш даланы, туң даланы ул яратмады. Тамырдагы кайнар канны бозга әйләндерә торган таштай суыкны, сөякләргә үтә торган ачы җилләрне яратмады. Мондагы киез өйләрне, арбаларны, кешеләрне яратмады. Ярата алмады. Тик шулай да аның бу яктан, бу кешеләр, мал-туарлар арасыннан беркая дә китәсе килмәде.
Туң даланы эретә торган язгы кояш та, Күк асты иленең хуш исле чәчәкләре дә, таллы елга буйлары да — барысы да, барысы да — монда, аның янында гына иде. Аның сөеклесе Йуй атлы кыздан аңа монда һәрвакыт җылылык, яктылык таралып тора. Монда шул Йуй булганга күрә дә тормыш аңа ямьле, күңелле һәм мәгънәле тоела иде.
Билгеле, аңа монда да салкын, бик салкын булган чаклар булды. Банхуаның таулар арасындагы таш оясында чагында ул сагышыннан, кайгысыннан акылдан шашар дәрәҗәгә җитеп калды. Бары менә монда урдага күченеп килгәч кенә аңа яңадан җан кереп киткән иде.
Менә аны тагын аердылар. Җылыдан, яктыдан, бәхет-куаныч чыганагыннан аердылар. Монда килгәндә ул кая баруын да, ник баруын да бик яхшы аңлап килде. Монда килгәндә ул кемнәрнеңдер теләген, боерыгын үтәгәннең соңында яраткан кызыннан аерылырга, кире әйләнеп кайтырга тиешлеген дә аңлап-белеп килде. Тик шулай да аның менә

хәзер аннан аерыласы да, кире туган җиренә әйләнеп кайтасы да килмәде.

Соңгы тапкыр очрашканда Банхуа аңа әйтте:

— Тегә яктан боерык килде: сиңа бөек эш йөкләтелә,— диде.— Син бер угланны күрергә, аны ныклап исеңдә калдырырга тиешсең. Берәр җирдә яңадан очрашырга туры килсә, син аны танырга тиешсең.

— Мин аны кайда күрермен соң? — диде Чәнси.

— Ул сине Тарлавыкка чаклы үз алае белән озатып куяр, шунда күрерсең,— диде Банхуа.

Юлга чыгар алдыннан аның сул колагындагы алкасын салдырып алдылар, тамгалы яшма ташын — ышанычь билгесен кире бирделәр. Шуннан соң аны баштанаяк чин киемнәренә киендерделәр. Ләкин чин киемнәре белән кышкы далада мең адым да китеп булмаячак иде. Шуңа күрә, юка киемнәр өстеннән аңа тагын калын, тупас тире киемнәр кидерделәр.

Урдадан алар таңга таба, яктылы-караңгылыда чыгып киттеләр. Капка аша чыкканда ул соңгы кат артына — таудай калкып утырган биек Ак өйгә карады. Җылылык, яктылык чыганагы шунда булырга тиеш иде. Ул аны күз алдына китерде. Ләкин менә хәзер шунда, яктылык чыганагы янында, икенче бер кешенең, чит, ят, дошман кешенең булуы турында уйлагач, аңа кинәт чиркангыч булып китте. Шундук аның йокысы качты һәм шул ук мәлдә кемдер арттан пычак белән китереп кадагандай булды.

Әллә соң ул үзенең шулай тегеләргә — үзенең юлдашларына арттан пычак белән кадавын исенә төшерде микән? Кем өчен кадады соң ул теге вакытта? Ник кадады? Әлбәттә, аның өчен, гүзәл Йуй өчен кадады. Үзенә булсын өчен. Барыбер булмады. Бетте. Менә хәзер аның үзен бәреп ектылар. Аңа... биек Ак өйдәге яктылык, җылылык чыганагына хәзер менә күңелледер, рәхәттер. Аңа... аның ишеләргә берни булмый. Алар көләләр, шаяралар. Аларга кем белән дә күңелле!

Юл буена ул караңгы чырайлы булды. Юл буена ул үзенең бәхетсез язмышы, билгесез киләчәге турында уйлады.

Аны озата килүче йөз кешелек алай төштән соң бер сөзәк калкулыкның җилсез ягында туктап калды. Монда, сирәк урман белән капланган калкулык буенда, аларны башка кешеләр көтеп торалар иде. Алар бирегә иртәрәк килеп туктаганнар һәм, атларын тибенгә җибәреп, җиңел өйләр корырга өлгергәннәр. Озатып килүче алай башы аны шушы кешеләргә тапшырды. Аны озата килгән яшь ирләр урда ягына кире борылдылар.

Банхуа әйткән угланны ул беренче күрүдә үк таныды. Таныды һәм шактый гаҗәпкә калды. Ул аны белә иде. Бу аны чик буеннан Банхуа торагына кадәр озатып куйган ирләрнең яшь алай башы иде. Әйе, бу теге ул ишетеп тә, күреп тә белгән уң кул тучи бәк тәгин углан иде. Ул үзе генә түгел, аның монда кайбер егетләре дә аңа таныш сыман күренде. Уртадан озын буйлы, киң маңгайлы, киң күкрәкле бу таза яшь угланны ул бер мәртәбә күргәч, икенче мәртәбә теләсә каян, теләсә кем арасыннан аерып ала алган булыр иде. Ул үзеннән-үзе истә кала торган, күзгә бәрелеп тора торган кеше иде. Теге вакыттагы белән чагыштырганда ул ярыйсы ук үзгәргән дә.

Банхуаның коткылы сүзләрен истә тотып, ахрысы, аннан соң Йуй язмышында аның да күпмедер катнашы барлыгын белгәнгә күрә, Чәнси аны җентекләп, сәер бер тойгы белән күзәтте. Аның бу тойгысында чиксез нәфрәт тә, дошманлык та һәм шул ук вакытта аннан курку катыш җирәнү дә бар иде. Бу тойгыда шулай ук аны ничек тә түбәнәйтергә, аны бары начар итеп, ямьсез итеп күрергә тырышу да бар иде.

Яшь углан үзе аны беренче караштa ук таный алмады, ахрысы. Шулай да күз карашлары очрашкач, Чәнсине ул шундук исенә төшерде.

Җил кисеп карайган, кырысланган йөзендә аның, ихлас бер гаҗәпләнү билгесе булып, балаларча елмаю балкып китте. Әле генә Чәнсигә ач бүренеке сыман усал, комсыз булып күренгән күз карашында янә дә балаларча беркатлылык, эчкерсезлек чагылып калды.

— Синмени әле бу?! — диде тәгин углан элекке танышын очратуына чын күңелдән сөенеп.— Алып килгәч, менә илтеп тә куярга туры килә сине. Мине хәзер Ак урдага якын да җибәрмиләр. Каршыга чыгып әйттеләр: каган боерыгы, диделәр, Тарлавыкка кадәр озатып куярга, диделәр.

Ул үзенең шул кадәр күп сөйләп ташлавын, җитмәсә, сөнчә аңламаган кешегә сөйләп ташлавын чамалап, кинәт тынып калды. Әллә соң ул аның — шикле чин качагының күңел түрендә үзенә карата бөтенләй кире хис-тойгылар барлыгын сизенеп алды микән? Ни генә булмасын, ул да, Чәнси кебек үк, үзенең булачак юлдашын җентекләп карарга тотынды.

Чәнси аның сүзләрен яхшы аңламаса да, үзенә карата анда бернинди усаллык юклыгын сизенми калмады һәм шул чакны аның күңелендә нидер сынган кебек булды. «Әйе, әйе!» дигән сыман баш кагып, ул елмаеп куйды.

Икенче көнне кич, караңгы төшүгә аны таулар арасындагы ялгыз өйгә китереп куйдылар. Уң кул тучи бәк тәгин углан белән ул беренче мәртәбә очрашкан төштә аерылышты. Аерылышканда алар «Сау бул!» дигән шикелле бер-берсенә карашып алдылар, елмайгандай иттеләр. Озын туны аяк очына кадәр җиткән яшь, чандыр чин ире ялгыз өй янында торып калды, өстенә сугышчы киемнәре кигән яшь сөн ире атына атланып таулар арасыннан төньякка таба китеп барды. Аның артыннан озак кына тояк тавышлары ишетелеп торды.

III

Чәнсинең этисе Чәни түбәннән күтәрелгән кеше булган. Яшь чагында ул үзләре авылында гына түгел, бөтен тирә-якта иң батыр, куркусыз башкисәр саналган. Яше җиткәч, аны гаскәргә алганнар, чик буена җибәргәннәр. Анда да ул үзенең кыюлыгы, башсызлыгы белән танылып өлгергән. Сөннәр белән сугышларда ул берничә мәртәбә батырлык, тапкырлык күрсәткән. Аңа игътибар иткәннәр, мактаганнар, бүләк биргәннәр һәм югары үрләткәннәр. Югары үрли-үрли ул субашы дәрәҗәсенә ирешкән. Моннан җиде-сигез ел элек ул Йәнмынь янында Чин гаскәрләренә каршы сугышта батырларча һәлак булган. Чин угы туп-туры аның уң күзенә килеп тигән. Ул укны ярсып тартып алган, ләкин ук тимеренә ияреп аның күзе дә ите-каны белән актарылып чыккан. Үләр алдыннан ул акылдан шашкан. Үлгәнче ул бертуктаусыз «Чжао! Чжао!» дип кычкырган. Шундый турылыклы булган ул үзенең туган иленә!

Бу турыда соңыннан Чәнсигә этисенең элекке дуслары сөйләде. Аның хакында алар тагын күп нәрсәләр сөйләделәр. Әтисе атаклы сугышчы булганга һәм бөтен гомере чик буе шәһәрендә, сугышчылар арасында үткәнгә, бала чагыннан ук ул батырлар, батырлыклар турында берсеннән-берсе мавыктыргыч хикәяләр ишетеп үсте. Шул рәвешчә ул Чжао йортының иң атаклы сугыш осталары Лэнпо белән Лиму турында да күп кенә нәрсәләр ишетте.

Менә шундый хикәяләр, җанлы тарихлар тәэсирендә, ахрысы, Чәнси дә яшьтән үк батырлык, дан һәм дәрәҗә турында хыялланды. Ләкин аның батырлыгы шул коры хыялланудан ары узмады. Кулына кылыч, ук-җәя тотып, аңа сугышырга насыйп булмады. Ул үсеп буйга җиткән-

дә анын туган иле — Чжао йорты инде аяк астына салып тапталган, беткән, үлгән иде. Анын әтисе Чәни шундый яраткан Чжао җирләре инде Чин биләмәләре булып исәпләнелә иде.

Меңләгән Чжао аксөякләре белән бергә аларны, туган җирләреннән, туган йортларыннан аерып, Чин башкаласына күчерделәр. Өйләнгән бер абыйсы шул ук елны, корал асып, сугышка китте, сеңлесе Йуны Чин йортының ваны Инчжән сарайларының берсенә кырнак итеп алдылар. Ире батырларча сугышта үлгән үги әнисен шулай ук сарайга алдылар. Кырнак итеп түгел, тукучы, тегүче итеп. Ул әле яшь иде, шулай да Чин ванының күзе төшәрлек чибәр түгел иде. Ә менә анын бертуган сеңлесе Йу искиткеч матур иде! Яңа тулып, буйга җитеп килгән чагы иде анын.

Чәнсине дә, абыйсы Жу кебек итеп, кулына корал тоттырып, каядыр көньякка сугышка җибәрмәкчеләр иде. Шул чакны көтмәгәндә аңа әтисенең элекке дусты Дунто ярдәм кулын сузды. Башкаланың көнбатыш капкасы янында сакта торучы алай башлыгы ярдәмчесе Дунто аны үз янына битекче итеп урнаштырды.

Хәзер дә анын, бала чагындагы кебек, бөтен вакыты иртәннән кичкә чаклы кораллы ирләр-сугышчылар янында үтте. Ул туктаусыз язу-сызу белән шөгыльләнде. Өлкәнрәк башлыклары кушса, тегендә-монда барып килгәләде, кайчагында исә, рөхсәт сорап, ялгыз әнисе янына кайтып әйләнгәләде. Кайткан саен аңа әнисенең бетмәс-төкәнмәс моң-зарын тыңларга туры килде.

Шулай бер көнне үзләренә кайтып кергәч, әнисе серле генә итеп:

— Кызым Йудан хат бар! — диде.

— Күрсәт әле! — диде Чәнси коты алынып.

Сарайлардагы кызларга туганнары, ата-аналары, дуслары белән аралашу, хат-фәлән алышу тыела иде. Кемнең дә булса сарай кызлары белән аралашуын сизсәләр, гаепле кешене шундук хөкемгә тарттыралар иде.

— Кемдер койма аша менә бу таякны ташлап китте,— диде әнисе.

Улына ул бер буын озынлыгындагы нечкә генә бамбук таягы бирде. Таяк урталай ярылган иде. Чәнси, ике кисәкне бергә беркетеп бәйләгән җепне сүтте дә, таяк эченнән нечкә генә итеп төрелгән ак ефәк тартып чыгарды. Ефәккә кара белән шундый сүзләр язылган иде:

«Без монда биш йөз кыз. Барыбыз да яшь, чибәр. Инде ике ел булды — минем әле бер генә ир кеше дә күргәнем юк. Без ерткыч оясына азыкка дип ташланган корбаннар кебек. Кайгыдан, сагыштан мин үләрмен ахрысы. Абый! Коткар мине! Үлгәнче сезне, тауларны, елгаларны күрәсем килә. Йу».

Өйдә болай да кайгы-хәсрәт баштан ашкан иде. Төрлесе төрле якка таралган балаларын уйлап, карт ананың йөрәге инде болай да теткәләнеп беткән иде. Мондагы, иректәге тормыш белән чагыштырганда оҗмах булып тоелган тормышта — хуанди сараенда яшәп ятучы Йу турында инде әнисе дә, Чәнси дә, башкалар да ничектер онытыбрак торалар иде сыман. Ван сараенда булгач, аңа анда күңелледер, һич югы, тамагы туктыр, өсте бөтендер сыман тоела иде. Бу көтелмәгән хат-хәбәр андый гамьсез уйларның барысын да чәлпәрәмә китерде! Гомере буена иренең колы булып, бар кайгысын эченә йотып барган карт ана шул көннән башлап бөтенләй диярлек сөйләшмәс булды.

Шул көннән башлап абый кеше дә күзгә күренеп үзгәрде. Ул уйланды. Язмыш турында, көндәлек тормыш, кансыз, шәфкатьсез дөнья турында элеккегә караганда башкачарак итеп уйланды. Үзе белән бергә уйнап-көлеп үскән сеңлесе бик кызганыч булып, моңлы-сагышлы булып күңеленә керде дә утырды. Сеңлесе аңа хәзер элеккегә караганда да якынрак, кадерлерәк тоелды. Ул аны коткарырга тиеш иде. Бернигә карамыйча ул аны ерткыч оясыннан тартып алырга тиеш!

Лэкин ничек итеп? Ничек?!

Бу турыда ул энисеннэн башка беркем белэн дэ киңэшә алмады. Энисе белэн киңэшеп торуның исә кирәге дә юк иде — ул барыбер берни аңламаячак, ул бары күз яше генә түгәчәк. Абый бары үзе генә уйланды. Уйланды һәм тапты.

Ул чәнсән Лисының төп Чин кешесе булмыйча, Чу йортында туган, түбәннән күтәрелгән кеше икәнлеген белә иде. Ул шулай ук аның—Лисының — чыгышына, байлыгына карамыйча, башлы, булдыклы яшьләргә якты йөз белән каравы турында да ишеткәләгән иде. Бик озак баш ваткач, ул туп-туры Лисының үзенә ялварырга булды. Моның өчен ул Чин йортын баету, Чиннең, бөек Шихуандиның көчен арттыру буенча бик кыю киңәш уйлап тапты. Үзенең кыю уйларын-фикерләрен бамбук таякларына күчереп, ул шуны Лисы кулына тапшырырга дигән карарга килде.

IV

«Олуг чәнсән, синең бөек акылың, шәфкатьлегең турында мин күп ишеттем,— дип язды ул Лисыга тапшырылачак бамбук таякларына.— Шуңа күрә дә мин, элекке Чжао биләмәсенең Йәнмынь каласында су-башы Чәни гаиләсендә туган уртанчы бала Чәнси, сиңа шушы битек белән мөрәҗәгать итәргә батырчылык иттем.

Олуг чәнсән! Чин йорты элек — син Чингә килеп, Чин ванына хезмәт итә башлаганчы, бик кечкенә булган. Аннан да элегрәк, ишетүемчә, аның чикләренең озынлыгы мең лидән артык булмаган. Үзеңә буйсынган кешеләр белән идарә итүдә сәләтле һәм акыллы булуың аркасында, син, олуг чәнсән, үз тирәңә булдыклы яшьләрне тупладың. Хөрмәткә лаек кешеләргә бүләкләр биреп, аларның күңелен күтәрдең. Шунлыктан синең кул астындагы кешеләр, икеләтә тырышлык белән, тугрылык белән хезмәт итеп, Чин йортының, Бөек Шихуандинең көчен, байлыгын арттыралар. Шуның өчен сине бөтен Күк асты илендә чын күңелдән хөрмәт итәләр һәм сиңа ун мең еллык гомер телиләр.

Бөек Чин йортының данын, биләмәләрен арттыру өчен синең жаныңны да кызганмый тырышуың аркасында, Чин йорты үзара туктаусыз сугышып, талашып яшәгән вак биләмәләрне берләштерде һәм бердәм, бөек дәүләт төзелде.

Лэкин ил берләшсә дә, аның читләрендә төрле кыргый халыклар яши. Үзләренең аңсызлыклары, томаналыклары аркасында алар Күк углы алдында бил бөгәргә, Чин йорты урнаштырган гадел тәртипләргә буйсынырга теләмиләр. Кыргый халыкларның иң оятсызлары, иң явызлары — сөннәр. Башка кыргыйлар арасында алар үзләренең ныграк оешкан булулары, көчләре, кораллары белән аерылып торалар. Үзләренең житез атларына атланып, кечкенә-кечкенә алайларга бүленеп алар талау өчен бер туктаусыз Чин җирләренә һөҗүм итәләр. Алар кыргый єрткычлар кебек, кыргый кошлар кебек. Аларны яхшылык белән генә тәртипле итеп булмый. Аларны шулай ук көч белән дә җиңеп булмый. Аларны бары хәйлә белән генә җиңәргә мөмкин!

Моннан берничә еллар элек минем якташым, Чжаоның сугыш остасы Лиму, сөннәргә каршы хәйлә кулланып, аларның йөз меңнән артык кораллы ирен юк иткән, шунда ук даньлән кабиләсен кырып бетергән, дунхуларны пыр туздырып, линху кабиләсен бирелергә мәҗбүр иткән.

Лимуның бу җиңүе турында Чин йортында, күрәсең, белмиләр яисә, белсәләр дә, күптән инде аны онытып бетергәннәр. Бик кызганыч!

Лиму төньяк кыргыйларны җиңә, лэкин ул аларны кырып бетерә алмый. Бу аның хатасы!

Олуг чәнсән! Күк асты илендә мәңге тынычлык, ирек һәм бәхет ур-

нашсын өчен, төньяк хуларның берсен калдырмый юк итәргә киңәш бирәм. Моның өчен Лиму хәйләсен яңадан кулланып, сөннәрнең кереш тарта алган барлык ирләрен ачык яуда үтереп бетерергә кирәк. Ирләрен юкка чыгаргач, далага басып керү, аңдагы хатын-кызны, бала-чаганы, мал-туарны кулга төшерү авыр эш булмас.

Сөннәрне ничек кенә булса да барлык көчләре белән сугыш башларга мәҗбүр итәргә кирәк. Һәм тозакка эләктерергә. Монысы иң кыены!

Олуг чәнсән! Мин болай киңәш итәм. Мин, Чжао кешесе, Чжао гадәтләрен, йолаларын яхшы беләм. Чжаоның элекке аксөякләре турында минем күп нәрсәләр ишеткәнем бар. Чжаоның элекке аксөякләре исеменнән мине ялган илче итеп җибәрсәгез, сөннәрне Чингә каршы яуга кузгалырга котырта алыр идем. Ләкин мин үзем генә барсам, алар миңа ышанмаслар дип уйлыйм. Чингә каршы янәсе астыртын эш алып барган һәм, сөннәр чик аша чыксалар, монда корал тотып баш күтәрергә әзер торган Чжао аксөякләре исеменнән мин үземнең бертуган сеңлем Йуны бүләк итеп алып бара алам. Сеңлем минем яшь, матур, нәзакәтле. Җырлый, бии, уен коралларында уйный белә. Ул хәзер изге Шихуанди сарайларының арткы бүлмәләрендә яши.

Олуг чәнсән! Ни өчен мин үземнең бертуган сеңлемне кыргый хуларга илтеп бирергә, үземнең язмышымны шундый куркыныч астына куярга уйладым соң? Моның сере шунда: минем карт, ялгыз әнием бар. Аның ачлыктан, кайгыдан саргайган йөзен күреп минем йөрәгемә кан сава. Үземә тапшырылачак авыр, куркыныч эшне уңышлы башкарып чыга алсам, картлык көнендә мин туган анамның күңелен күрә алыр идем һәм шулай итеп аның алдында үземнең изге бурычымны үти алыр идем дип өметләнәм. Ата-анага игътибарлы булу, бу дөньяда аларга терәк булу — балаларның изге бурычы.

Менә шулар турында уйлап каравыңны үтенәм, олуг чәнсән».

V

Үзенең Лисы янына үтеп керергә теләге барлыгын ул бары әтисенең элекке дустына гына әйтте. Бу турыда Дунто чәнсән сараен саклаучы ирләрнең берсенә — үзенең күптәнге якын танышына җиткерде. Шулай итеп, байлык, дәрәҗә һәм көч иясе Лисының меңләгән сакчылары, хезмәтчеләре аша үтеп, битекче Чәнсинең үтенече тиешле җиренә барып ирешә.

Көннәрдән бер көнне бөтен Җунгода иң атаклы кешеләрнең берсе Лисының өч кат таш койма белән уратып алынган, капка баганаларына чаклы алтын-көмеш калайлар белән бизәлгән биек сараена чакырдылар. Эчке капкадан алып таш болдырга кадәр булган утыз-кырык адым чамасы җирне Чәнси, як-ягына башын калкытып карарга да кыймыйча, яртылаш бөгелеп барды. Болдырга аяк баскач, ике ягында да шомартылган таш баганалары, чигүле ефәкләре булган бүлмәгә чаклы түше белән шуышты.

Беренче килүендә ул олуг чәнсәннең багасына үзенең кемлеген әйтте дә, язулы бамбук таякларын калдырды. Икенче килүендә аны Лисының үзе янына алып керделәр.

— Мин синең таякларыңны укып чыктым,— диде түрдә аякларын бөкләп утырган симез, шома битле, зур корсаклы карт, ияк очыннан сузылып төшкән сирәк сакал төкләрен сыйпаштырып.— Син дөрес язгансың — төньяк хуларны юк итәргә кирәк. Без төньяк кыргыйларның кайда күпме кешеләре, күпме терлекләре барлыгын, кайчан кая күченеп китүләрен, башлыкларының үзара мөнәсәбәтләрен — барысын да белеп торабыз. Ләкин безгә белеп тору гына аз.

— Болай булгач, Лиму... — диде Чәнси ашыгып, башын калкытып.

— Лиму үз урынында, Лисы үз урынында! — диде олуг чәнсән. — Дошманның күп көч белән ябырылып килүен Лиму еллар буе коймы эчендә көтеп яткан, шуңа күрә аны куркаклыкта гаепләп урыныннан алганнар. Изге Шихуанди алай көтеп ята алмый. Безгә аның урдасына, киез өенә үтеп керергә, аның ышанычын яулап алып, аңа тиешле киңәшләр бирергә кирәк.

— Мин барысын да аңладым, олуг чәнсән! — диде Чәнси түземсезләнеп.

— Сөннәрне кырып бетергән очракта да, урман араларында, далаларда теләсә кайда таралып яшәүче хулар калачак. — диде Лисы дәвам итеп. — Без кыргыйларны кыргыйлар кулы белән юк итәргә тиешбез. Ике юлбарыс сугышып хәлдән тайса, аларны берәм-берәм үтерүдән дә җиңел эш юк. Синең якташың Лиму да, башкалар да менә бу турыда ныклап уйламаганнар.

— Синең акылың, зирәклегең искиткеч! — диде Чәнси сокланып.

Бай киемле, горур, тәкәббер карт, күзенә туры карап әйтелгән мактау сүзләреннән күңеле булып, ахрысы, кинәт тынып калды, сакалын сыйпаштыргалап беравык утырды да, ягымлырак, җылырак бер тавыш белән ялгап алып китте.

— Анда чыккач, син Банхуа дигән сатучыны эзләп табарсың,— диде ул Чәнсигә.— Банхуа — безнең кеше. Барысын да аның белән киңәшеп, килешеп эшләрсең, уйлаганыңны башкарып чыга алсаң, башыңнан алтын-көмешкә, ефәккә күмелерсең, карт анаң соңгы көннәрен рәхәттә үткәрер, туганнарың җылы, түшәмле урыннарга үрләр. Күк асты илендә ун мең ел буена исемең яңгырар. Сеңлең Йуны бирерләр. Калганын барысын да багалар аңлатыр.

Алтын-көмеш белән, ялт-йолт килеп торган шома ташлар, чигүле ефәкләр белән бизәлгән иркен бүлмәдә менә шундыйрак сөйләшү булды. Җиңел генә, үзеннән-үзе генә диярлек ачылып киткән биек капкалардан Чәнси исерек кебек алпан-тилпән атлап чыкты. Ул үз бәхетенә үзе ышанмады. Үзенең чиктән тыш батырлык эшләвен, үзенең шәп кеше булуын аңлаудан аның күз аллары томаланды. Бу вакытта ул сеңлесе Йуны да, карт анасын да нишләптер исеннән чыгарып ташлаган иде.

Сеңлесе Йуны ул бары берничә көннән соң гына исенә төшерде. Башкалада аңа әйттеләр: сеңлеңне түбәсе ябулы арбада чик буена озаттык, ул анда синнән алдарак барып җитәчәк, диделәр. Ул, берсүзсез ышанып, чик буена ашыкты. Тиешле җирдә тиешле кешеләрне эзләп тапкач ул чик аша бергәләп чыгачак юлдашлары белән таныштьь. Шунда ук аңа сарай тоткыныннан котылган сеңлесе Йуны күрсәттеләр.

Баштарак ул аны ничектер танымыйчарак торды — шундый нык үзгәргән иде аның бертуган сеңлесе! Шулай да, күпме генә үзгәрсә дә, ул аны барыбер танырга тиеш иде лабаса! Ләкин ул аны һич кенә дә таный алмады. Үзенең бик каты алдануын күреп ул кинәт артына авып китә язды. Аның каршысында ул белгән, ул күрергә, ул коткарырга теләгән туганы Йу түгел, бәлки бөтенләй башка кыз, ят кыз басып тора иде!

— Йу! Йу кая, Йу?! — дип кычкырды ул үз-үзен белешмәстән.

— Мин Йу түгел, мин — Йуй! — диде кыз уңайсыз елмаеп.

— Сине кем җибәрде? Каян килдең син? — диде Чәнси.

— Шуннан... сарайның арткы бүлмәләреннән,— диде кыз.

— Шулай булгач, син минем сеңлем Йуны белергә тиеш. Кая ул?— диде Чәнси.

— Юк, мин аны белмим,— диде кыз никтер кызарып.

Ул вакытта Чәнси аның кызарынуына бөтенләй игътибар итмәде.

Ул вакытта аның күңеле кырылган, зиһене таралган иде, аның өчен бар нәрсәнең асты өскә килгән иде.

Шулай итеп, үзенең бертуган сеңлесе Йу урынына бөтенләй күрмәгән-белмәгән ят бер кызны алып, икеі юлдашы белән ул хәтәр юлга чыкты. Йуй дигән бу кыз, чит булса да, бераз гына әрсез-оятсыз күренсә дә, шулай да чибәр иде. Һәм иң куркынычы да аның менә шул чибәрлеге иде.

Чәнси аңа гашыйк булды. Билгесезлек ягына атлаган беренче адымыннан ук ике ир кеше — үзен һәм «сеңлесен» саклап барырга, Банхуага илтеп тапшырырга тиешле ир кешеләр аңа артык булып тоела башлады.

VI

Караңгы тарлавыклар, шәрә кыялар аша чыгып, туган җир туфрагына аяк баскач та, күз алдында якын күренешләр ачылгач та, бөтенесе яңадан аның хәтеренә төште. Монда, туган якта, җылы иде, кышның якынлашуы бөтенләй диярлек сизелми иде. Кешеләр җиңелчә киндер киемнәр кигәннәр. Сулар әле туңмаган — шаулап инешләр ага, су өстендә тезелеп үрдәкләр йөзә. Су буйларында — яхшылап эшкәртелгән саргылт туфраклы уңдырышлы җирләр, камыш түбәле балчык өйләр, балчык коймалар; ишәккә, карт үгезгә ике тәгәрмәчле арба җигеп, коры-сары утын төяп таулар ягынннан кайтып килүче ярлылар. Еракта — җир белән күк арасында, тигезлек өстеннән калкып утырган зәңгәрсу биеклекләр; юл буенда очраган атлылар, кораллы ирләр — болар барысы да Җунго иде, туган җир иде.

Кораллы ирләр... Монда, чик буе җирләрендә, алар аеруча күп. Берәүләр каядыр үзәннәр ягына, көньякка ашыга, икенче берәүләр, киресенчә, каршыга, төньякка, караңгы таулар ягына баралар. Юл буйларында беркая бармаган, ашыкмаган кораллы кешеләр дә очрый. Алар, узган-барган юлчыларны туктатып, кемнең кая, ник баруын тикшерәләр.

Мондагы күренешләргә, мондагы кешеләргә яңадан күнеккәнче Чәнси шактый җир уйланып, хыялланып барды. Ул үзенең төрле сынаулар аша, куркыныч хәлләр аша исән-имин котылып чыгуы турында, юлда очраган кешеләр белән — ярлы игенчеләр, үзен озата баручы кораллы ирләр белән чагыштырганда, бәхетле, бик бәхетле булуы турында уйланды. Инде ул беркайчан теге якка чыкмаячак, беркайчан Банхуаның җирәнгеч, ерткыч йөзен күрмәячәк. Билгеле, ул инде гүзәл Йуйны да күрә алмаячак. Күрмәсә күрмәс. Җунгода чибәр кызлар бетмәгәндер. Лисы аны алтынга күмәчәк. Байлыгың булса, сине яклардай ышанычлы кешең булса, калганы чүп кенә. Гүзәл кызларны ул кирәк кадәренчә сатып алачак. Иң элек ул үзенә яхшы сарай салдырачак. Өч кат коймалы итеп, Лисыныкы кебек биек капкалы итеп. Капка баганалары буялган, бизәлгән булыр. Капка түбәсендә кораллы сакчы өчен кечкенә бүлмә булачак. Аның сакчысы килгән-киткән кешеләрне шуннан тар ярыктан күзәтеп кенә утырачак. Аның иллеләп аты-арбасы, йөзләп хезмәтчесе булачак. Байлыгы булса, яши белер иде Чәнси!

Киткәндә Лисы аны ошаткан кебек. Кайткач ни әйтер, нинди күз белән карар? Бөтенесе аңа бәйле, бөтенесе аннан тора. Ошатса ул аны үз янына киңәшче, булышчы итеп алыр, битекче булса да ярый. Көчле ул Лисы! Теләсә ул бөтенесен булдыра ала. Чин йортындагы барлык эшне шул Лисы башкара, диләр. Хәтта Шихуанди да, имеш, бары аның сүзенә генә колак сала, диләр.

Ташлы юлда арба бик каты дөбердәп, шакылдап барды. Чәнси тәгәрмәчләр шакылдавын да, тупас арбаның як-якка авып-түнеп китүләрен дә сизмәде. Бөтен күңелен татлы хыяллар биләп алганга, ташлы

юлдан дыңгырдап барган арба да аңа су өстеннән җиңел генә шуышып барган көймә сыман тоелды. Шулай бара торгач ул җайлап кына, рәхәт кенә йокыга китте.

Яңадан күзләрен ачып караганда ул үзенең һаман да шул ук арбада селкенгәләп баруын шәйләп алды. Якында гына ниндидер тавышлар ишетелде, кайдадыр ямьсез итеп ишәк кычкырды, кемнеңдер шулай ук ямьсез тавыш белән кычкырып җылаганы яңгырап торды. Төштәге кебек булып, йокы белән бергә татлы хыяллар да артта кала барды. Ямьсез тавышлар белән кычкыра торган, үкереп җылый торган ямьсез чынбарлык аны әкренләп үз кочагына ала барды. Ул теләсә дә, теләмәсә дә, тәрәзә ярыгыннан як-ягына карап-карап алды.

Якында гына, юл буеннан гына, бер-берсенә тотынып барган хәлсез карт белән хәлсез карчык күренеп калды. Карт әнисен исенә төшереп Чәнси шундук тәрәзәдән читкә борылды. Шактый озак баргач ул, яңадан тәрәзәгә үрелде. Юл читендә аунап яткан яшь бала мәете чалынып калды. Аның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Ниндидер биек агач күперне чыгып, яшел үзәнлек уртасыннан бара башлагач, читтә, кечкенә чокыр янында олы кеше мәете күренде. Күмеп тә тормыйча, аны шунда чокыр сыман җиргә ташлап кына киткәннәр иде, ахрысы. Шунда ук шикле кыяфәттә сары, кызыл этләр иснәнеп йөри иде.

Бу күрүендә аның эче жу итмәде. Аның эче ташка әйләнде, ташка әйләнде дә бугазына килеп тыгылды. Аның җылыйсы килде, кычкырасы килде. Ул бөрешеп арба кырыена посты һәм шуннан соң бер генә мәртәбә дә юл читенә күз ташламады. Болай да барысы да билгеле иде, барысы да таныш һәм җирәнгеч иде.

VII

Бер көнне кич караңгы төшәр алдыннан арба туктап калды. Кайдадыр якында гына шаулап су акканы, атлы ирләрнең кычкырып үзара сөйләшкәне ишетелде.

— Җиттекмени? Кайтып җиттекмени башкалага? — дип кычкырды ул тыштагы ирләргә.

— Җиттек. Төш инде,— диделәр аңа ирләр.

Нәнси түбәсе ябулы арбадан иелештереп чыкты да җиргә сикереп төште. Озак утырып килгәнгә аның аяклары оеган, тәне авырайган иде. Төшкәч ул беравык җирне ныклап тоя алмыйча торды. Әле бер аягын, әле икенче аягын язгалады. Шул чакны аны ике яктан ике ир кеше култыклап алды. Нык куллы ирләрнең берсе аның билендәге хәнҗәренә үрелде, икенчесе зур учы белән бугазына тотынды.

«Юлбасарлар!» дип уйлады Чәнси, тынсыз калып. Ул үзен озата килгән кораллы ирләргә кычкырмакчы булды, ләкин аңа кычкырырга ирек бирмәделәр — шундук авызына юеш чүпрәк тутырдылар. Як-ягында бик күп кораллы ирләр күреп ул кинәт шиңеп калды. Аны озата килүчеләр каядыр юк булганнар иде. Болары ниндидер башка төрле ирләр, ят ирләр. Тик шулай да алар да юлбасарлар түгел иде, ахрысы.

Этеп-төртеп аны каядыр алып киттеләр. Олы юлдан беркадәр читтә, каршыда ул озынча балчык өй күреп алды. Арырак биек коймалар сузыла иде. Аны койма белән әйләндереп алынган ниндидер ишегалдына алып кергәннәр иде. Юк, монда юлбасарлар оясы түгел, ниндидер дәүләт йорты булырга тиеш иде. «Башкала капкасыннан кергәнче яхшылап тикшерергә уйлыйлар микәнни?» — дип уйлады Чәнси, үз-үзен тынычландырып. Ул тикшерүдән курыкмады — тамгалы яшма ташы аның үзе белән иде.

Аны озынча балчык өйгә алып керделәр. Керделәр дә ниндидер ка-

раңгы, салкын бер бүлмәгә ябып куйдылар. Кулларын артка каерып бәйләделәр, аякларына богау салдылар. Ул берни аңламады. Ул беркемнән берни сораштыра алмады. Төне буена ул ыңгырашып, бәргәләнеп-суккаланып чыкты. Арып-алҗып, хәлдән таеп бары таң алдыннан гына онытылып китте һәм, эт кебек бөгәрләнгән килеш, как, юеш идәндә газаплы йокыга талды.

Күп тә үтмәде, кемдер типкәләп, якасыннан тотып аны аягына бастырды. Йокысы ачылып җитмәгәнгә ул чайкалып китте. Шулай да аңа егылырга ирек бирмәделәр — ике яктан култыклаган килеш, өстерәп диярлек, каядыр алып киттеләр.

Аны кинрәк, иркенрәк икенче бер бүлмәгә алып керделәр. Шул чакны ул үзенең хөкемче — олуг яргучы алдында басып торуын аңлады.

Камыш чыпта өстендә аякларын бөкләп утырган, башына салам эшләпә, өстенә керләнеп беткән ефәк халат кигән хөкемче зур башлы, зур йодрыклы һәм куркыныч күз карашлы бер кеше иде. Шулай да ул дәүләт вәкиле иде. Чәнсинең эченә җылы йөгерде — ни әйтсәң дә, юлбасар түгел, яргуласа да, түрә буенча яргулаячак, дөреслекне белгәч, бер сүзсез чыгарып җибәрәчәк, дип уйлады ул.

Хөкемче каршысына китергәч аның авызындагы чүпрәген алдылар, аякларын, кулларын чиштеләр. Үзен иректә сизеп ул иң элек эчәргә су сорады. Зур агач чүмеч белән җылымса су бирделәр. Эчкәч ул, ешеш тын алып, хәл җыеп торгандай итте, авыз читләрен сөрткәләде. Ямьсез, куркыныч карашлы яргучы аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп, сүзсез генә көтеп торды.

— Мин Чәнси...— дип сүз башлады тоткын, яргучының өметсез күзләреннән өмет көтеп.

— Беләм.

— Минем тамгалы яшма ташым бар иде. Аны монда алганнар.

— Анысын белмим,— диде яргучы, кырт кисеп.

— Мин бөек чәнсән йомышын йомышлап, башкалага кайтып барам.

— Мин дә аның йомышын йомышлап утырам,— диде яргучы, тоткынга сөйләргә ирек бирмичә.— Мине монда ул җибәрде!

— Минем тамгалы ташымны, коралларымны кире кайтарып бирергә боерыгыз! — диде Чәнси, кыза башлап.

— Андый боерык алдыннан мин сиңа берничә сорау бирермен, йомышчы Чәнси,— диде яргучы тыныч кына.

— Мин тыңлыйм, олуг хөкемче,— диде Чәнси, үз-үзен кулга алып.

— Син, йомышчы Чәнси, Янан, Хаоши дигән ирләрне беләсеңме? — диде яргучы мәкерле елмаеп.

Чәнси сискәнеп китте. Ул аңлап алды. Ул барысын да аңлап алды. Аның аяк астында кинәт җир убылып киткән кебек булды, аның күз аллары караңгыланып калды.

— Мин аларны беләм, олуг хөкемче,— диде ул төшенке генә.

— Белгәч, алар кайда?

— Алар тегендә калды, олуг хөкемче.

Тезләнгән җиреннән Чәнси кинәт сөрлегеп китте һәм балаларча кычкырып еларга тотынды.

— Мин гаепле түгел! Мин гаепле түгел! — диде ул такмаклап.

— Алар үзләрен үзләре кадап үтерделәрмени? — диде яргучы.

— Алар... мине үтереп, кызны көчләмәкче булдылар,— диде Чәнси кыюсыз гына.

Бу турыда ул инде күптән уйлана иде. Акланыр өчен аның бернинди дәлиле юк. Шулай да иң ышанычлысы, иң дөресе аныңча менә шундыйрак булырга тиеш сыман иде. Аннары бу хакта ул беркем белмәс, белсәләр дә, төпченеп тормаслар дип, төпченсәләр: алар качып киттеләр, шунда торып калдылар, дип әйтермен дип уйлаштырган иде.

— Шулай да булсын,— диде яргучы аның белән килешкәндәй

итеп.— Син, үзеңә тапшырылган кызның намусын саклап, аларны бербер артлы кадап үтердең. Шулаймы?

— Шулай,— диде Чәнси.— Алар мине үтергәнче, мин аларның үзләрен берәм-берәм аркаларына кадап үтердем.

— Шул сүзләрен язып куегыз,— диде яргучы үзенең ике ягында утырган ике битекчегә эндәшеп.

Битекчеләр Чәнсинең сүзләрен язып куйгач, яргучы яңадан сораулар бирә башлады.

— Хулар башлыгы өчен дип җибәрелгән кызны бөек Шихуанди сарайларының арткы бүлмәләреннән алдылар. Син аны белдеңме? — диде ул тоткынга.

— Белдем.

— Бертуган сеңлең Йуны хулар башлыгына бүләккә алып барам дип, олуг чәнсәнгә син битек яздыңмы?

— Мин яздым,— диде Чәнси, шыбыр тиргә батып.

— Сеңлең Йу кайда?

— Бөек Шихуанди сарайларының арткы бүлмәләрендә булырга тиеш,— диде тоткын теләр-теләмәс кенә, тагын да яманрак нәрсә сизеп.

— Сеңлең Йу урынына син Йуй дигән кызны алып бардың. Аны беләсеңме?

— Беләм. Йуй миңа үзенең каян алынуын, кем кызы булуын әйтмәде, олуг дали.

— Ул әйтмәгәнне мин әйтәм! — диде яргучы кинәт күк күкрәгән тавыш белән кычкырып.— Йуй дигән кыз синең бертуган сеңлең Йу белән янәшә бүлмәдән алынды. Син бөек Шихуандинең кырнагы Йуй атлы кызны тиешле кешесенә илтеп тапшырмыйча торып, аңа кул салгансың. Бу — угрылык!

— Мин аңа кул салмадым, олуг хөкемче.

— Сине үз өеңдә... Банхуа тоткан! — диде яргучы үтергеч итеп.

Банхуа исемен ишетү белән, Чәнси урыныннан сикереп торды. Аны кинәт ярсу, нәфрәт биләп алды. Кемнең кемне кочуында, кемнең кемне яратуында ни эшләре бар аларның?! Шихуанди сарайларында ун меңләгән, йөз меңләгән яшь кызлар сөйгән егетләреннән аерылып, кайгыдан-сагыштан саргаеп яталар. Ун меңләгән, йөз меңләгән яшь ирләр, сөекле хатыннарыннан аерылып, чит җирләрдә кан коялар. Нинди тигезлек бу?! Ни эшләре бар аларның, ни эшләре бар?!

— Ялган бу, ялган! — диде ул яргучыга, ярсып, йодрыкларын төйнәп.

Яргучы кораллы сакчыларга керфек какты. Тузына башлаган тоткынны сакчылар шундук эләктереп алдылар, көчләп, төрткәләп ишеккә таба әйдәделәр.

— Ялган бу, ялган! — дип кычкырды Чәнси бөтен өйне яңгыратып.

VIII

Икенче көнне аны тагын яргучы янына алып керделәр. Яргучы яңадан сорау алырга керешге.

— Син Дунто дигән кешене беләсеңме, Чәнси? — диде ул дәртсез генә.

— Белмим. Күргәнем дә, ишеткәнем дә юк.

Яргучы эндәшмәде, бары башын гына калкытты. Шул ук мәлдә дип әйтерлек Чәнсинең артында кемнеңдер ишектән килеп кергәне ишетелде. Керүче кеше түргәрәк узды да, Чәнси каршысында туктап калды. Чәнси керүче кешегә күтәрелеп карады. Шаккатып, куркып йөзен тиз генә читкә борды. Аның каршысында теге Көнбатыш капка янындагы

сакчы алай башлыгының ярдәмчесе, атаклы Чәнинең элекке дусты Дунто басып тора иде! Ул Чәнсидән тазарак, калкурак буйлы. Аннан өлкәнрәк тә, чыныкканрак та иде. Ләкин аны хәзер танырлык та түгел. Күрәсең, бик нык кыйнаганнар иде. Нindидер каты нәрсә белән сугып сул як яңагын ярганнар, күз төпләрен күгәртеп бетергәннәр. Аягында ул көчкә басып тора.

— Менә бу Дунтоны беләсеңме син?— диде яргучы Чәнсигә күтәрелеп карамыйча гына.

Чәнси эндәшмәде.

— Юк, олуг хөкемче, мин аны белмим,— диде ул яргучының үзе кебек үк тыныч, гамьсез булырга тырышып.

— Ялган сөйли башладыңмени, Чәнси? Дөресен сөйләсәң, үзеңә яхшырак булыр.

— Мин аны бөтенләй белмим, олуг хөкемче.

— Әйе, ул мине белми,— диде Дунто, сүзгә катышып.

Аның тавышы каяндыр тамак төбеннән гыжылдап чыкты. Чәнси белгән Дунто — аз сүзле, кырыс, ләкин яхшы күңелле Дунто чынында андый түгел иде.

— Нәрсәне белми соң ул? — диде яргучы, Дунтога карап.

— Ул мине белми.

— Син, Дунто, Чәнсинең атасы Чәни кулы астында хезмәт итмәдеңмени? Атасын ятратканга, углын кызганып, син аны үз яныңа битекче итеп урнаштырмадыңмыни?

— Мин аны үз яныма урнаштырдым,— диде Дунто буталып.

— Шулай булгач, ул нәрсәне белми соң, Дунто? — диде яргучы.

— Ул минем Шихуанди сараеның арткы бүлмәләрендә яшәүче Йу атлы кызны коткарырга тырышуымны белми.

Менә нәрсә өчен китергәннәр икән аны монда! Менә кем китереп ташлаткан икән теге бамбук таягын! Әйе, әйе, ул аңа үзенең гүзәл сеңлесе Йу турында сөйли торган иде шул. Йу турында сүз чыктымы, урта яшьләрдәге, кырыс, аз сүзле, ләкин яхшы күңелле Дунто кинәт тынып кала торган иде. Элекке сугышчан дустының балаларын кызгандымы микән ул, әллә соң аның күңелендә башка төрлерәк уй-хисләр дә булды микән? Хәзер инде каян беләсең аны?!

— Ул тагын нәрсәне белми?— диде хөкемче.

— Ул минем Йу белән хат алышуымны белми.

— Йу атлы кырнак синең белән түгел, абыйсы Чәнси белән хат алышкан. Кем арадашчы булган?

— Мин! — диде Дунто, башын югары күтәреп.

— Языгыз,— диде яргучы ике ягындагы ике битекчегә.

— Улым! — диде шул чакны Дунто, Чәнсигә карап.— Алар мине барыбер үтерәчәкләр. Синең гаебең юк. Бөтенесен Йуй дигән кыз бутаган. Йу белән алар серләшкән булганнар. Йуй синең сеңлең Йуны күзәтче хатынга әләкләгән. Сеңлеңне... Йуны...

Ул әйтеп бетермәде, тотлыгып-тынып калды һәм ике куллап битен каплады.

— Йуны нишләткәннәр?! Йуны нишләткәннәр?!— дип кычкырды Чәнси, Дунтога таба омтылып.

Дунто өчен яргучы җавап бирде:

— Җинаятьче Йуны, тере килеш кайнар суга салып казанда кайнаттылар. Җинаятьне ачарга булышкан өчен, Йуй атлы кыз, үз теләге белән, хулар башлыгына бүләк итеп озатылды. Аны син алып бардың, Чәнси! Синең ялганчы йөзең фаш ителде, синең изге Шихуандигә, Чингә каршы җинаять эшләрең тулысынча расланды. Сине шулай ук үлем көтә!

— Мин Шихуанди өчен, Чин йорты өчен бик кирәкле хәбәрләр алып кайттым! — дип кычкырды Чәнси, аягүрә басып. — Йуның үлеме өчен

гаепләләр җәзасын татырлар әле! Минем монда тоткында ятуымны олуг чәнсән белсә, синең үзеңә дә бик каты эләгер, олуг хөкемче!

Тоткынның ярсый башлавын күреп, коралды сакчылар урыннарында кымшанып куйдылар һәм икесе дә берьюлы диярлек яргучы ягына карап алдылар. Яргучының бер керфек кагуы белән алар, аны, икесе ике яктан эләктереп алып, ерткыч сыман йолкып-ботарлап ташларга әзерләр иде. Ләкин яргучы корбанны сакчылардан ботарлатмады — ул аны үзе ботарлап ташлады.

— Синең карт анаң, барлык туганнарың коллыкка сатылды, Чәнси. Өегез, мал-туарыгыз, барлык байлыгыгыз тартып алынды,— диде ул бер-бер артлы санап. — Син олуг чәнсән җилкәсе артына яшеренеп калмакчы буласың. Ул эш барып чыкмас. Шулай ук теге яктан алып кайткан серле хәбәрләреңә дә өмет баглама. Син инде соңга калдың, Чәнси! Моннан өч көн элегрәк килеп җиткән икенче бер кеше син әйтәчәк хәбәрләрне түкми-чәчми сөйләп бирде. Сиңа Банхуа белән килешеп эшләргә кушылды. Син аны да алдамакчы булдың. Банхуа ахмак түгел — ул барысын да уйлап-белеп эшли.

— Банхуа! — диде Чәнси, тешләрен шыгырдатып. — Мин аны үз кулларым белән буып үтерәчәкмен!

— Йуйны да! Сеңлең өчен, минем өчен! — диде Дунто кан баскан күзләреннән утлар чәчеп.

— Теге дөньяда, теге дөньяда! — диде яргучы дәһшәтле көлемсерәп.

IX

Чин йортының ваны Инчжән адәм балаларының кайберләре генә ирешә алган бик күп теләкләренә ирешә. Унөч яшендә ул тәхеткә утырды һәм, егерме биш ел буена күршеләре белән сугыша-сугыша, җиңә-җиңә, бер-бер артлы алты йортны басып алып, үзе кебек үк ваннарның җирләрен, байлыкларын үз йортына кушты. Арадагы киртәләрне яндырып, йортларын җир белән тигезләп ул бөтен Җунгоны Чин дәүләте ясады. Аның даны Күк асты җирендәге борынгы биш патшаның данын берьюлы күмеп китте, аның көче, байлыгы дөньяда булган барлык ваннарның, патшаларның көченнән, байлыгыннан күп тапкырлар артып китте.

Шундый байлыкка, данга, көч-куәткә ирешкән патша үзенең һаман да башка бик күп бөҗәкләр — ике аяклы, ике куллы адәм балалары кебек үк адәм баласы булып калуы өчен бик хурланды, әлбәттә. Ләкин ул, бик нык теләсә дә, үзенә өченче кул да, өченче аяк та үстерә алмады, шулай ук башкалар кебек каты җир өстеннән йөрмичә, җир белән күк арасыннан йөзеп тә, очып та йөри алмады. Мондый нәрсәләр инде берничек тә аның теләгенә буйсынмый иде! Шулай да, башка бик күп бөҗәкләрдән аерылып тору өчен, ул иң элек үзен Күк углы, алла углы дип игълан итте һәм үз-үзен берлектә «мин» дип түгел, күплектә «без» дип атый башлады. Аннары ул үзен элеккечә Инчжән ван дип түгел, Шихуанди дип атарга боерды. Бу исә бөтен дөньяда беренче патша — беренче Күк углы дигән мәгънәгә туры килә иде.

Шихуанди басып алганчы аның күршеләре — Чжао, Хань, Вэй һәм башкалар гел явызлык, бозыклык белән шөгыльләнделәр. Алай-болай Чин гаскәре берәр ныгытылган шәһәрнеме, авылнымы, иген яхшы уңа торган берәр елга үзәнлегенме сорап килсә, комсызланып ничек тә бирмәскә тырыштылар. Анысы гына җитмәгән, үз җирләрен, калаларын, хатыннарын-балаларын саклап алар хәтта Чингә каршы корал күтәрергә дә батырчылык иттеләр!

Ләкин алар барыбер җиңелде. Гаделлек, тигезлек өстен чыкты!

Шулай да әле алар бик озак Инчжәннең бөеклеген, изгелеген күрмәскә, танымаска теләделәр. Әле булса алар үз сарайларында яшәделәр, үз киемнәрен киделәр, үз көйләрен тыңладылар, үз җырларын җырладылар. Бик зур яманлык, бозыклык иде бу! Караларны — бөҗәкләрне юлдан яздыру, аларны Чин ванына каршы котырту иде бу. Югарыдагы Күк-алла билгеләгән туры, изге, дөрес юлдан читкә тайпылу иде бу!

Күк углы Шихуанди һич тә мондый нәрсәгә түзеп тора алмады. Җир йөзендә ул яңа тәртип — гадел, шәфкатьле тәртип урнаштырырга булды. Бу хакта Күктән изге боерык иңдерелде. Яңа тәртипкә каршы килгән, каршы килергә уйлаган яисә каршы килүе, каршы уйлавы мөмкин булган барлык аксөякләр, кара сөякләр юк ителде, каршылык оясы булган сарайлар җимерелде, элекке кораллар ватылды, элекке тәртипләр үзгәртелде, элеккечә сөйләү-җырлау катгый тыелды.

Бөек Шихуанди бар нәрсәне үзенчә эшләде, үзенчә яңартты һәм үзе керткән яңа тәртипләрнең Күк асты илендә үтәлешен төн-көн үзе тикшереп, күзәтеп кенә торды. Үзенең бер-ике ялагаеннан башка ул дөньяда беркемгә ышанмады. Аның баштанаяк коралланган сакчылары-ялчылары ары-бире чабып яңа тәртип урнаштырып йөрделәр. «Бөҗәк»ләрнең бер өлеше аның өчен иген кырларында, сазлыкларда бил бөктеләр, икенче өлеше чит җирләрдә кан койдылар, калган өлеше — коллар, җинаятьчеләр — тирән коелардан, тау-таш арасыннан тимер, бакыр, тоз чыгарды.

Күк асты иленең иң ерак почмакларыннан аңа тизрәк хәбәр китерү өчен, тауларны кисеп, үзәннәрне киңәйтеп, елгаларга күперләр салып, туры-тигез юллар суздылар. Ул, анда-монда барып, аңа башкаладан читтә төн кунарга туры килсә дип, илнең төрле почмакларында аның өчен җиде йөздән артык сарай салдылар. Сарайдагы бүлмәләргә, аның күңелен күрү өчен, чибәр кызлар тутырдылар, пәрдәләр, чаршаулар кордылар, кыңгыраулар, барабаннар куйдылар. Башкала янындагы Эпангун сарае үзенең зурлыгы, байлыгы, гүзәллеге буенча дөньяда кеше кулы белән торгызылган барлык сарайларны күмеп китәргә тиеш иде. Вэйшуй елгасының көньяк ягы буенда Шанлин урманында төзелә башлаган бу сарайның көнчыгыштан көнбатышка сузылган буе — биш йөз бу, көньяктан төньякка сузылган аркылысы — илле чжан[1] булачак иде. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән Эпангун сараен салуда көне-төне җиде йөз мең җинаятьче эшли. Үзенең бөеклеген, изгелеген мәңгеләштерү өчен Күк Углы Шихуанди — Көнчыгыш диңгез, Көньяк диңгез ярларына, биек тау башларына үзен-үзе мактап, язулы ташлар куйдырды.

Әйе, бу дөньяда аның барлык теләкләре, барлык хыяллары тормышка ашты. Аның боерыклары тулысынча җиренә җиткереп үтәлде. Өстендә аның иң яхшы, иң затлы киемнәр булды, өстәлендә иң яхшы, иң затлы ризыклар булды, ятагында аны иң сылу яшь кызлар көтеп ятты. Бөтен Күк асты иле аның күзенә генә карап, аның авызына гына карап, кан калтырап торды. Түрәләр-багалар бары ул кушканны гына, ул кушканча гына эшләделәр; галимнәр, фикер ияләре, дога итеп, аның сүзләрен кабатлады.

Дөньядагы ике куллы, ике аяклы адәм балалары арасында Шихуанди, әлбәттә, иң бәхетле кеше иде. Ләкин шулай да аңа мондый бәхет кенә аз тоелды. Чиндәге барлык бәхетлеләрнең, бәхетсезләрнең язмышын үз кулында тоткан бу бәндә үзен чынлыкта бик бәхетсез дип исәпләде. Озын, юка борынлы, озынча кысык күзле, тар күкрәкле бу чирле-

---

[1] Эпан яисә Эпангун сараеның аркылысы хәзергечә — 170, буе — 800 метр булырга тиеш була. Бу һәм чжан — озынлык үлчәү берәмлекләре.

кәш Күк углын җир угылларыннан беркем дә яратмады. Аннан бары куркалар гына иде.

Адәм булып туганлыктан, кайчагында аңа да башкаларның — үзе кебек ике аяклы, ике куллы кешеләрнең, бигрәк тә хатын-кызның ягымлы күз карашы, чын күңелдән иркәләве кирәк иде. Үзенеке дип исәпләнелгән ун меңләгән, йөз меңләгән чибәрләр арасында ул беркемнең дә чын яратуын, чын якынлыгын тоймады. Аның сизгер күңеле моңа бик кимсенде, хурланды, аның моңа хәтере калды, йөрәге яраланды. Ул моны беркемгә сиздермәде, һәм бу анда дөньядагы үзеннән башка барлык терегә-үлегә карата чиксез нәфрәт һәм кансызлык тойгысы гына уятты. Иң якын кешеләренең дә үзенә куркып, чит итеп карауларын сизенгән саен ул тагын да алардан өстенрәк булырга, кул җитмәслек биеклеккә ерагаерга һәм алардан тәмам аерылырга тырышты.

X

Күк углының нечкә тойгыларын бары беренче киңәшче — чәнсән Лисы гына яхшы аңлады һәм таштай каты куллы, ерткычтай комсыз, кансыз бу бәндәнең барлык яшерен уйларын-теләкләрен тормышка ашыра барды. Моның белән ул аңа әледән-әле үзенең турылыгын исбат итә алды һәм шул ук вакытта, Күк углының ышанычыннан файдаланып, үз байлыгын туктаусыз арттыра барды.

Шулай бер вакыт ул — олуг чәнсән Лисы — изге Шихуандинең үлем турында сөйләгәнне яратмавына игътибар итте. Күзәтә торгач ул аның — бөек Күк углының үлемнән куркуын аңлап алды. Хатын-кыз тычканнан, таракан ише нәрсәләрдән ничек курка торган булса, Шихуанди дә үлемнән шундый ук чиктән тыш бер курку, кот алыну белән курка булып чыкты.

— Күк асты илендә бик күп галимнәр, күрәзәчеләр бар. Алар кешене мәңге үлемсез итә торган ниндидер серле үлән барлыгын беләләр,— диде Лисы бер көнне бөек Шихуандигә.— Синең кебек изге патшаны мин мәңге яшәргә тиеш дип уйлыйм. Әгәр син теләк белдерсәң, галимнәрдән, күрәзәчеләрдән белешеп, мин әлеге серле үләнне эзләп таптыру җаен карар идем, бөек хуанди!

Мондый сүзләр ишетеп Шихуандинең йөзләре балкып китте. Мәңге яшәү, мәңге үлемсез булу һәм мәңге хакимлек итү — аның күптәнге һәм яшерен бер теләге иде.

Лисыга ул Күк асты җирендәге барлык галимнәрне, күрәзәчеләрне, сихерчеләрне җыярга кушты. Галимнәрнең, күрәзәчеләрнең, сихерчеләрнең һәркайсы үзе белгәнне, үзе ишеткәнне сөйләде. Берәүләр әйтте: кешене үлемсез итә торган тере сулы серле үлән юк ул, диде. Икенчеләре әйтте: борынгы китаплардан язылган — булырга тиеш! — диделәр.

Тере сулы серле үлән юк дигән галимнәрне Шихуанди терeләй җиргә күмәргә боерды, тере суы бар дигәннәрне үз янында сарайда калдырды. Шуннан соң аларны яңадан бергә җыеп, яңадан төпченә башладылар.

Элекке Чу йортында туган Сүйши әйтте: еракта, көнчыгыштагы тирән диңгез уртасында Пенлай, Фанҗан, Инҗоу дигән утраулар бар, диде. Шул утрауларда изге Күк кешеләре — гаиб ирәннәр яши, тере суының серен белсә алар гына белергә тиеш, диде. Өч мең яшь кыз углан белән яшь ир угланнар алып, тиешенчә ураза тотып, арыкланып мин шул утрауларны эзләп кайтыр идем, диде.

Күк углы Шихуанди Сүйшинең теләген үтәргә булды. Ул аңа бик күп акча, ярдәмче кешеләр — кораллы ирләр бирде һәм, диңгез буен-

дагы биләмәләреннән кирәк кадәр яшь кызлар, яшь ирләр җыеп алырга кушып, изге теләкләр, өметләр белән аны билгесез юлга озатты.

Сүйши китеп бер ел үтте, ике ел үтте. Изге сәфәргә киткән кешеләрнең берсе дә кире әйләнеп кайтып тере сулы серле үләнне тоттырмады. Күк углы сизелерлек дәрәҗәдә борчыла башлады.

Былтыр, көзге караңгы бер төндә, Шихуанди үзенең коралллы дүрт сакчы ирен алып, киемнәрен алыштырып, яшерен рәвештә урамга йөрергә чыккан иде. Ул төнге башкала урамнарын, өйләрен күрергә теләде. Әкрен генә, тавыш-тынсыз гына барганда, Ланьчи буасы янында аларга кораллы юлбасарлар очрады. Бөек патшаның коты алынды — куркудан ул хәтта телсез-өнсез калды һәм үзенең җан сакчыларына нинди дә булса боерык та бирә алмады. Җан сакчылар, билгеле, боерык көтеп тормадылар — шундук юлбасарларга каршы ташландылар. Юлбасарларның берничәсе качып котылды, берничәсе, урталай туракланган хәлдә, җир өстендә ятып калды.

Шушы вакыйгадан соң Күк углы үзенең тормышы турында элеккегә караганда да ныграк уйлана башлады. Бернигә карамыйча аның тере суын таптырасы килде. Серле утраулардагы гаиб ирәннәрне табарга дип ул яңадан көнчыгышка бер төркем галимнәр белән кораллы гаскәр җибәрде.

Нәкъ менә шул чагында моннан өч ел элек Сүйши белән бергәләп диңгез уртасындагы серле утрауларны эзләргә дип киткән күрәзәче-галим Лүшән кайтып төште.

— Өч мең яшь кыз, яшь углан белән бергәләп без өч мәртәбә диңгезгә керергә тырышып карадык,— диде Лүшән.— Беренче мәртәбәсендә, ярдан биш йөз ли чамасы ераклашкач, бик каты җил чыгып, давыл купты. Күп кешебезне югалтып, кире борылдык. Икенче мәртәбә кергәч, Пенлай утравына барып җитә яздык. Ләкин шул чакта бик зур балыклар юлыбызга аркылы төште. Өченче мәртәбә чыгуыбызда ниндидер диңгез еланнары, койрыклары белән сугып, ике көймәбезне капландырды. Пенлай утравына барып җитәргә була, тик көймәләрне балыклардан, еланнардан саклау өчен, безнең белән бергә ике мең көчле укчы ир барырга тиеш.

Лүшәннең сүзләренә Шихуанди бер сүзсез ышанды. Көнчыгыш диңгез буена бару өчен ул куш-мылтык белән коралланган көчле укчылар җыярга боерды. Шул ук вакытта ул Лүшәнгә «Сызымлы күрәзә китабына» карап фал ачарга кушты: Төньякта яшәүче сөннәрне акылга утыртырга кирәк иде. Ләкин бу эшкә алла ничек карар икән?

Фал китабында: «Чинне ху харап итәчәк», дигән сүзләр чыкты.

Анда нәкъ шундый сүзләр чыгачагын Лүшән үзе дә, Лисы да алдан ук белеп тордылар. Хуларның Чинне харап иткәнен көтеп ятмыйча, аларга каршы үзе сугыш ачса, Шихуанди өч-дүрт ел буена тере суы табам, серле утрауларга барып җитәм, дип акча туздырып йөргән Лүшәнне, Сүйшине, алардан да бигрәк, бу хакта беренче булып киңәш биргән Лисыны күпмедер вакытка исеннән чыгарып торачак иде. Бу вакыт эчендә исә, казнадан акча каерып, берәз тагын типтереп яшәргә һәм үзеңнең кайбер эшләреңне җайлап куярга булачак иде.

Бөек патша, никадәр сизгер, оста һәм башлы булмасын, беренче ярдәмчесе Лисының да, ялганчы галим Лүшәннең дә хәйләсенә төшенә алмады. Хакимлегенең утыз икенче елында, тугызынчы айда ул гаскәр башлыгы Ментйәнгә өч йөз меңлек чиру белән Сөн җиренә басып керергә боерды.

XI

Лисы тарафыннан бик оста оештырылган мәкерле коткыга бирелеп төньяк «ху»лар да Чингә каршы яу чабарга әзерләнделәр. Аларның да,

билгеле, тынычта, рәхәттә, муллыкта яшиселәре килде, ләкин тынычта, рәхәттә, муллыкта яшәү алар өчен таштан, балчыктан өеп биек сарайлар салу да түгел, тауларны, кыяларны кисеп, үзәннәрне үстереп, ике кырыена биек коймалар утырткан туры юллар сузу да түгел иде. Алар өчен бай, рәхәт тормыш шулай ук бар илдәге яшь кызларны җыеп, аларны ефәк чаршаулар артында, кыңгыраулар, барабаннар янына ябып яткыру да түгел иде. Ир угланны алар яу өчен туган дип, кыз угланны — ир углан өчен туган дип исәплиләр.

Ат-сыер белән бергә үскән сөннәргә башкасы кирәкми дә. Диңгез уртасындагы серле утраулар да, серле үләннәр дә кирәкми иде! Аларның җирләре — җитәрлек, сарайлары — далалары иркен иде.

Моннан утыз ел чамасы элек Чжаоның гаскәр башлыгы Лиму сөннәрнең бик күп кешесен харап итеп, дала җирләрне басып алгач, сөннәр бик нык хәлсезләнеп калганнар иде. Сөн илендә йөз мең, ике йөз мең сугышчыны бергә җыю ул барлык халыкның иң таза, иң яшь, булдыклы өлешен бергә туплау дигән сүз иде. Шул кадәр күп кеше — халыкның иң таза, эшчән, булдыклы өлеше алай-болай яуда җиңелеп, кырылып бетсә, дошман ягында калса, бу инде Сөн иленең тамыры кору белән бер булачак иде һәм Сөн иленең беркайчан да аякка баса алмавы мөмкин иде.

Лиму белән канлы сугыштан соң нәкъ шулай булды да. Ләкин бу хәл инде күптән булып узганга, күпчелек аны онытып бетерә язган иде. Лиму белән сугышта катнашкан ирләрнең күбесе инде үлеп беткән, исән калганнары исә — хәлсез картлар. Ул чакта Туман каган да, аның субашлары, алыплары да, күп кенә бәкләр дә — барысы да балалар иде. Аның бүгенге көндәге атаклы ирләренең күпчелеге шулай ук хурлыклы җиңелүне үзләре күргән, үзләре татыган кешеләр түгел. Лиму турында, җиңелү турында алар бары ишетеп кенә беләләр. Шуның өстәвенә алар моннан җиде-сигез ел элек Туман каган җитәкчелегендә элекке Сөн җирләрен — Лиму басып алган Аръякны яңадан яулап алуда катнашкан кешеләр иде. Шунлыктан алар үзләрен җиңелүчеләр дип түгел, бәлки җиңүчеләр дип исәпләргә күнеккән иде.

Менә шуңа күрә дә сөн ирләренең күпчелеге яуга олы туйга, ярышка барган кебек атлыгып, ашкынып бардылар да. Куанкының сул ягында, Урта кичү янындагы тау аралары — тын үзәннәр, якындагы комлы далалар берничә көн эчендә атлар, кешеләр белән тулды.

Барлык бәкләр билгеләнгән вакытка, билгеләнгән урынга килеп җиттеләр. Ләкин елга аша әле чыгарлык түгел; Куанкыны тулысынча боз тотмаган иде — бөек елганың кичү турысында, уртада, кап-кара булып, җанлы булып су агып ята иде. Чин җирләренә керү өчен иң элек менә шушы кичү аша чыгарга һәм Аръяк далаларында таралып, анда бераз атларга, кешеләргә ял бирергә кирәк. Күп санлы атлар, кешеләр белән Аръякка бары боз өстеннән генә чыгып булган кебек, сугыш вакытында чигенергә туры килсә дә, елганың сул ягына шулай ук боз өстеннән генә чыгарга кирәк булачак иде. Чин ягына башка юл юк.

Кичүгә килеп җитү белән, Туман каган үз өенә барлык бәкләрне, субашларын олы киңәшкә җыйды. Аның елганы тулысынча боз тотканын көтеп торасы килмәде. Бу якта алты йөз меңләп ат, дөя өчен көтүлекләр өч-дүрт көннән артыкка җитәрлек түгел. Шул кадәр күп терлек-туарны бары тик Аръяк далаларында гына исән-имин саклап калып булачак иде. Атлар хәлсезләнә, кешеләр йөгәнсезләнә башлаганчы, мөмкин кадәр тизрәк теге якка, куе үләнле болыннар ягына чыгарга, олы яу алдыннан тиешенчә көч тупларга кирәк иде.

Күрәзәчеләр әйтте: елгага аяклары бәйләнгән җирән үгез корбан итеп бирергә кирәк, диделәр, шулай итсәң, иртәгә үк суны боз тотар,

диделәр. Өлкәнрәк сугышчылар әйтте: мондый чакта суга элекке заманнарда камыш, чыбык-чабык көлтәләре бәйләп ташлыйлар иде, диделәр.

Туман каган күрәзәчеләрне, карт, тәҗрибәле сугышчыларны да тыңларга булды. Күрәзәчеләр, су иясенә багышлап, аяклары бәйләнгән җирән үгезне корбан иттеләр. Шул ук вакытта барлык ирләргә берәр көлтә бәйләргә дигән боерык бирелде.

Бер көн эчендә Урта кичү тирәсендә, елга ярьг буенда, камыш, чыбык-чабык көлтәләреннән таулар өелде. Елганың бер ягыннан икенче ягына, биш-алты турыдан кыл-аркан суздылар. Камыш, чыбык көлтәләрен, югары менеп, агым уңаена агызып җибәрделәр. Җиңел көлтәләр арканнарга эләгеп калды. Суга чыланган чыбык-чабыкка, камышларга боз сарылды. Бер кат көлтә күпере өстенә тигез итеп икенче кат көлтә җәйделәр, су сибеп аларын да туңдырдылар да, атлар таймасын өчен, көлтәләрне өченче кат түшәделәр.

Елга аша аркылысы илле адым чамасы булган шундый өч күпер салынды. Боз күпернең ныгыганын, калынайганын көтәр-көтмәстән, әзәзләп кешеләрне, терлекләрне икенче якка чыгара да башладылар.

Өч ягыннан — көнбатыштан, көнчыгыштан һәм төньягыннан бөек елга белән чикләнгән, аркылысы-буе өч йөз чакрым чамасы булган Аръяк далаларында вак-вак күлләр дә, елгалар-инешләр дә һәм терлек аягы басмаган яхшы көтүлекләр дә җитәрлек. Чин белән чиктәш булганга һәм моннан торып яу чабарга уңай булганга, бу яктагы көтүлекләр гаскәр өчен дип саклап тотыла, каганнарның кышлау җирләре санала иде.

XII

Аръяк далаларында сөннәргә буйсынган бәйди, ләүфән кабиләләре яши иде. Чин белән чиктәш җирләрдә, көньяктарак сөннәрнең чик сакчылары тора. Монда шулай ук чин качакларыннан оешкан кечкенә авыллар да бар. Чин авылларының күбесе елга буйларына урнашкан иде. Алар анда, көтүлек өчен уңайсыз сазлы, ташлы җирләрдә, дөге игеп, яшелчә үстереп, балык тотып көн күрәләр. Менә шундый һәрбер авылда диярлек чиннәрнең ышанычлы үз кешеләре — шымчылары, озынколаклары бар иде. Сөннәр ягындагы һәр яңалыкны, һәр үзгәрешне алар теге якка җиткереп кенә торалар.

Бөтенесе җентекләп уйланылган яшерен хәйлә буенча эшләгәнгә күрә, Туман каганның кичүгә кайчан киләчәген дә, күпме көч белән киләчәген дә Ментйән алдан ук белеп торды. Сөн чирүе, елга аша чыгып, Аръяк далаларында тарала башлагач, шулай ук аларның һәрбер хәрәкәтен ул ерактан ук белеп, күзәтеп торды.

Ментйән башлы, сак һәм кыю субашы иде. Ул сугыш турындагы борынгы китапларны биш бармагы кебек белә, ләкин шулай да китапларда язылганга сукырларча ябышып ятмыйча, шартына, урынына карап, һәр нәрсәне үзенчә хәл итәргә тырыша иде.

Төньяк чик буеннан башкалага эш белән килгәч, бервакыт олуг чәнсән аны үз янына чакырып алды. Ул аңа теге битекче Чәнси язган киңәшне укып чыгарга кушты.

— Син Лимуны беләсеңме, субашы? — диде аңа Лисы.

— Белмичә! Чжаоның атаклы гаскәр башлыгы Лимуны тар-мар итүдә катнашкан кеше ләбаса мин! — диде Ментйән.

— Юк, син аның әнә анда язылганча, хуларны ничек алдап җиңүе турында беләсеңме? — диде Лисы.

Ментйән бу юлы җавап бирергә ашыкмады.

— Мин анысын да беләм, олуг чәнсән,— диде ул бераздан уйла-

нып.— Чжао ваны, Лимуны куркаклыкта гаепләп, урынынннан гына алган. Лиму кебек мин чик буена сөннәрне алдап китерәм дип, балчык коймалар эчендә бикләнеп ятсам, мине җинаятьтә гаепләячәкләр, башымны чаптырып, базар мәйданында казыкка элеп куячаклар.

— Мин сине коймалар эчендә бикләнеп ятырсың дип өметләнмим,— диде аңа Лисы.

— Мин уйлап карармын, олуг чәнсән,— диде Ментйән туры гына җавап бирмичә.

— Синең өчен алдан барысы да уйланылган инде, субашы! — диде аңа каршы Лисы.— Сиңа бары ныклап торып сугышка әзерләнергә генә кирәк булыр. Калганын барысын да мин үзем җайлармын.

Бу сөйләшү моннан ярты ел чамасы элек булды. Лисы янында Ментйән Лиму белән булган вакыйгага исе китмәгән булып күренергә тырышса да, сөнгә каршы сугышка әзерләнергә дигән яшерен боерык алгач, ул аның белән ныклап торып кызыксына башлады. Барыннан да элек ул элекке Чжао ирләрен эзләтеп таптырды, алардан Лиму турында, моннан бик күп еллар элек булган атаклы сугыш турында, сөннәр турында сораштырырга тотынды. Сөннәр елга янына якынлашып килгәндә, ул инде күптән барысын да уйлаган, барысын да әзерләгән иде. Ул бары алар белән очрашуны гына көтә иде.

Озакламый сөннәр елга аръягына күпләп-күпләп чыга башладылар, чыкканнары бере Аръяк далаларына тарала барды.

Ментйән, Лиму тәҗрибәсен исендә тоткан хәлдә, барына күз йомып карарга, бернинди тынычсызлану билгесе күрсәтмәскә боерды. Бары күзәтү манараларындагы ирләр генә төне-көне дала ягын күзәттеләр дә, офыкта караеп атлы төркемнәр күренү белән, кипкән бүре тизәге яндырып, күккә төтен үрләттеләр. Һәм бик тиз арада чик сызыгы буенча сөн атлыларының якынлашуы турында шомлы хәбәр таралып өлгерде. Ментйәннең нык өйрәтелгән батыр ирләре, тыннарын кысып, каерылып капкалар ачылганны көттеләр. Ә сөннәр берни аңышмый иделәр. Ментйән сөннәрнең бер кешесе калмыйча бу якка — бөек елганың уң ягына чыгып бетүен генә көтте. Сөннәр исә нишләптер кичү аша чыгуны озакка суздылар.

Кичүдә сөннәр өчен көтелмәгән тоткарлыклар килеп чыкты. Үзәктәге күперне уң кул белән сул кулдагы күперләрдән бераз кичегебрәк салдылар. Бу турыда боз тотмаган су да киңрәк, агым да көчлерәк иде. Бер яктан икенче якка кыл-аркан тартканда, көймәгә утырып икенче якка ишә-ишә түбәнгә таба агып барган ирләрнең берсе, аягы таеп, суга егылды. Аны коткара алмадылар, ул шундук су төбенә китте. Мондый хәлне күреп, башкалар каушап калды һәм, башланган эшләрен җиренә җиткерә алмыйча, икенче якка, боз өстенә чыктылар. Боз ватылып анда тагын өч кеше су төбенә китте.

Бу хакта белгәч, каганның сул күз кабагы тартыша башлады. Су иясе күпер салуга каршы иде! Су иясенә багышлап ул тагын аяклары бәйләнгән бер үгез белән бер кара тәкә бирергә боерды. Икенче көнне күрәзәчеләр суга зурлап корбан бирделәр, күпер салынуын сорап, тәңрегә келәү әйттеләр. Туман каганга бу да бик аз тоелды. Ул комсыз ирләр төнлә Чин ягыннан әсир итеп алып кайткан ике чинне сугыш алласына корбан итеп бирергә кушты.

Бары менә шул эшләрне башкаргач кына каганның күңеле бер урынга утыргандай булды. Төнлә бик каты суытып җибәрде. Шундый нык суытты — якындагы урманнарда шартлап агачлар ярылды, кыя башларыннан ташлар ычкынып төште. Иртәнчәк, туң җир өстендә үлеп яткан берничә атны күреп, беркем дә моңа кайгы белдермәде. Киресенчә, суыктан атлар туңып үлүен изгегә юрадылар. Димәк, су иясе дә, сугыш-яу алласы да аларның теләгенә колак салганнар! Димәк, Чингә юл ачык!

Ул төнне елганы аркан сузып көлтәләр ташламаган төшләрдә дә тулысынча боз тотты. Ләкин шулай булуга да карамастан, Туман каганның икенче якка чыгарга нишләптер һаман аягы тартмады. Ул яңа ай башын көтәргә булды.

Гаскәренең бер өлешен чыгарып та каган үзе бу якка чыкмагач, Ментйән дә, теләсә-теләмәсә дә, көтәргә мәҗбүр булды. Аннан соң ул кичү ягына үзенең махсус кешесен җибәргән иде. Кеше билгеләнгән вакытка кайтып җитмәде. Яңа ай башына кадәр ике көн вакыт калды. Чик буйларында сөннәрнең зур-зур төркемнәре күренгәли башлады. Чик буе халкы куркып көньякка качыша башлады. Күзәтү манараларының әле берсеннән, әле икенчесеннән бөркелеп күккә төтеннәр күтәрелде.

Яңа ай башына бер көн калды. Кичүгә җибәрелгән кеше әле булса кайтып җитмәде. Ментйән өчен артык көтеп торуның кирәге юк иде. Тугызынчы айның утызынчы көнендә, салкын бер иртәдә барлык чик буендагы таш, балчык коймаларның киң капкалары ачылды, капкалардан дала ягына ташкын булып гаскәрләр ыргылды.

XIII

Чин гаскәрләре Сөн җиренә йөзәр мең, йөзәр мең булып өч яктан басып керделәр. Сөннәрнең аз санлы чик сакчылары һәм шулай ук далада анда-монда очраган вак-төяк алайлары шундук юк ителде. Шулай да аларның беркадәр өлеше, чиннәрнең зур көч белән ябырылып килүләрен күреп, төньяк далаларга качып киттеләр.

Төп көчләрнең капма-каршы килеп очрашуы сөннәр өчен бөтенләй диярлек көтмәгәндә булды. Алар әле ял итәләр, күктә яңа ай урагы күренгәнен көтәләр иде. Чиннәрнең шул кадәр көч белән, шул кадәр ябырылып килүләрен алар бөтенләй көтмәде.

Ментйәннең күп көч белән берничә урында чик аша үтүе турында ышанычлы хәбәрләр алынгач, Туман каган, барлык икеләнүләрен җиңеп, яңа ай тууын да көтеп тормастан, үзәкне тәшкил иткән үз чирүен дә елга аша чыгарды. Тәбәнәк, чыдам атларында нык утырган, җилдавылның карлысын да, комлысын да, уклысын да күп күргән сөн ирләре ярсып яуга ташландылар.

Елгадан бер көнлек ераклыкта, бар яктан да ачык шыр далада, тигез җирдә чиннәрнең алгы алайлары белән сөннәрнең алгы алайлары капма-каршы килеп очраштылар. Бар яктан да ачык шыр далада, юка гына кар каплаган туң далада беренче канлы сугыш булды.

Ул көн кояшлы иде, җилсез иде. Сугыш иртәге күлемдә, кышкы кояш аксыл җир өстеннән ике сөнге буе күтәрелгәч башланып китте. Беренче булып чиннәр һөҗүм иттеләр. Кояш яктысы аларга аркан иде— алар, күрәсең, шул уңайлыктан файдаланып калырга тырыштылар. Үзләренә каршы яктагы сөннәрне алар яхшырак күрде. Аларның уклары турырак очты, күбрәк яралады, күбрәк үтерде. Әле анда, әле монда туң җиргә шапылдап ирләр егылды, шакылдап авыр кораллар, калкаңнар төшеп китте; ачы чинап-кешнәп яралы атлар тәгәрәште. Сугышчыларның бакыр, тимер, сөяк-таш белән ныгытылган каты киемнәренә шык та шык килеп уклар тиеп китте; тимәгәне, куркыныч сызгырып, баш өстеннән очып үтте. Сөннәрнең алгы тезмәсе тиз арада сирәкләнеп калды. Арттагылар, чиннәрнең бик каты кысрыклавын күреп, чигенә үк башладылар.

Ләкин чигенә башлаган сөннәргә вакытында арттан ярдәм килеп җитте. Сөннәргә яңадан җан керде. Хәзер инде чиннәр каушап калдылар. Дошман өстенә яңгыр булып уклар яуды. Чиннәр ягында үлүчеләр, яраланучылар күбәеп китте һәм бер мәлне, туктаусыз очкан ук

яңгырына чыдый алмыйча, Ментйән гаскәрләре борылып качыша башладылар. Рухлары күтәрелеп киткән сөн ирләре, бар көчләре белән ябырылып, качучылар артыннан ыргылдылар һәм туктаусыз ук атаата, дошманны бер өзлексез кысрыклауларында булдылар. Алгарак узып киткәннәр, чиннәр арасына кереп, кылыч, сөңге сугышы башлап җибәрде — качып баручыларны кылыч белән чаптылар, сөңге белән кададылар. Туктаусыз дөпелдәп, ташкын булып барган меңләгән ат тояклары астына, җир өстенә иярләреннән аерылып, авыр гәүдәләр барып төште, сынган сөңгеләр, каешы өзелгән ук-җәя савытлары төшеп калды. Тояклар таптап бозга әйләнгән карлы җир өстендә, әле анда, әле монда кызыл кан таплары җәелеп калды. Елан сурәте төшерелгән яшел байракларын, алтын бүре, бөркет башы беркетелгән озын тугларын югары күтәреп, тезгеннәрен иреккә җибәреп, ярсып, куанып сөннәр Ментйән гаскәрен шактый озак кудылар.

Бервакыт алар сугыш башланып киткән языдан бик нык ерагайдылар. Качып баручы чиннәр төркеме сирәгәйгәннән-сирәгәйде. Инде аларны бөтенләй куып җитеп, тәмам турап, чәнчеп ташларга да күп калмаган иде сыман. Ләкин шул чакны алда сирәк урман белән капланган калкулык күренде. Качып баручы чиннәр ничек тә шул калкулык артына җитәргә тырыштылар. Сөннәргә исә анда җиткәнче ук аларны турап, юкка чыгарып бетерергә кирәк иде.

Ләкин куучылар кирәгеннән артык мавыгып киттеләр. Калкулык артында тагын бер кечерәк калкулык күренде. Тирә-як шикле рәвештә үзгәрә башлады. Менә шундый калкулыклар, әрәмәләр артында чиннәрнең яшеренгән көчләре булуы ихтималы турында куучылар башларына да китереп карамады. Сирәк урман белән капланган калкулыкка якынлашкач та, тыелгысыз ташкын булып бар көченә чабып килгән, бөтен тирә-якны кара болыттай каплап килгән сөннәр өстенә кинәт уңнан да, сулдан да куркыныч уклар ява башлады. Калкулык итәгендәге куаклыкларда, урман араларында, чокыр-чакырларда чиннәрнең нык өйрәтелгән укчылары яшеренеп яткан икән.

Сөннәрне әлеге калкулык тирәсенә алдап алып килгән чин алайлары корал тота алган, атта утыра алган төрле җинаятьчеләрдән оештырылган иде. Ментйән аларны алдан ук шулай алдавыч итеп әзерләде. «Хуларны җиңсәгез, сезгә ирек биреләчәк», диде ул аларга. Шуңа күрә дә алар баштарак сөннәр белән шулай бик каты сугыштылар да.

Сөңгедән кечерәк авыр уклар белән яисә, киресенчә, кечкенә сөңгеләр белән ата торган чин мылтыклары дала җайдаклары өчен иң куркыныч корал исәпләнелә. Чиннәр аны әле күптән түгел генә куллана башлаганнар иде. Керешен аяк терәп тарта торган бу куркыныч мылтыкның ук-сөңгесе бик еракка оча һәм теләсә нинди каты киемне, теләсә нинди калканны үтә-сүтә тишеп чыга ала иде.

Сөн ирләренең күпчелеге җиңелчә киенгән, җиңелчә коралланган иде. Кайбер ярлырак сугышчыларның катырылган үгез тиресеннән, я булмаса киң тояклардан, сөякләрдән, юка ташлардан теркәп тегелгән киемнәреннән, агач калканнардан башка бернинди саклану чаралары юк. Бары тик бәкләрнең, алып ирләрнең генә өс-баш киемнәре, калканнары тимер, бакыр белән ныгытылган иде.

Төрле яктан очкан сөңге-уклар туп-туры атлылар арасына килеп төште. Кот очыргыч бер дәһшәт белән, көч-куәт белән очып килгән чин уклары берсенең күкрәгенә килеп тиде, икенчесенең яңагын җимереп китте, өченчесенең атын бәреп екты.

Чиннәрне таптап үтәбез, сытып бетерәбез дип очынып-җилкенеп барган сөн ирләренең куркусыз йөрәкләренә кинәт шом йөгерде. Ташкын читендәгеләр, эшнең болайга китүен күреп, тизрәк табан ялтырату ягын карадылар. Алдагылар, уртадагылар, бер кая да борыла алмыйча, чигенә алмыйча, туп-туры үлемнең авызына барып керделәр.

Алдагыларны чин мылтыкчылары кырган чакта, арттагылар кинәт борылып кача башладылар. Шул чагында Ментйән якында гына яшеренеп яткан төп көчләрен чыгарды. Качып барган, таралган, каушап калган сөн гаскәрен ачык далада тар-мар итү чиннәргә әллә ни авыр булмады.

Кечкенә бер елга буенда качучылар шулай да тоткарланып калдылар һәм борылып дошманга каршы сугыш башлап җибәрделәр. Ләкин киң далага җәелгән качучы гаскәрнең күп өлеше, тишек савыттан ага башлаган кымыз кебек, сугышка катнашмыйча, берән-сәрән елга аша чыгып, кичүгә таба элдерде. Чин мылтыкчылары котларын алган сөн ирләрен инде берни дә, беркем дә тоткарлый алмас кебек иде.

Качучыларның беренче төркемнәре кичүгә караңгы төшкәндә килеп җиттеләр. Беренчеләр артыннан икенче төркемнәр килеп җитте, икенчеләре артыннан өченчеләре кысрыклады. Берьюлы меңләгән, ун меңләгән атлар, кешеләр килеп тыгылгач, боз өстендә буталыш, ыгы-зыгы башланды. Шома бозда атларның аяклары тайды, әле анда, әле монда атлар егылды, атлары белән бергә боз өстенә кешеләр барып төште. Караңгыда бик күпләр, көлтә җәелгән күперне аермыйча, туп-туры шома боз өстеннән киттеләр. Уртада боз тотып җитмәгән ачык урыннар калган булып чыкты. Кешеләр, атлары-ниләре белән, авыр кораллары белән, ургылып аккан суга барып керделәр һәм, җан ачысы белән кычкыра-кычкыра, мәңгегә юкка чыктылар.

Елга ярына якын бер уңай җирдә сөннәр тагын бер мәртәбә чиннәргә каршы торырга тырышып карады. Ләкин тулы җиңелүдән аларны инде берни дә коткарып кала торган түгел иде. Куып килүче Ментйән ирләре, кичүгә якынлашкач, атларыннан төштеләр дә янә куркыныч мылтыклардан ата башладылар. Бу исә сөннәр арасындагы буталышны тагын да ныграк арттыра төште. Күзләренә ак-кара күренмәгән кешеләр, котылу эзләп, үзләренең туган якларына — иксез-чиксез далага омтылдылар.

Аръяк далаларында тау-тау үлеләр калдырып, елганың уң ягында, күпердә — боз өстендә кычкырган, ашыккан, коты алынган сугышчыларын калдырып, Туман каган төньякка элдерде. Аның янында нибарысы ун мең чамасы ирләре калган иде.

Караңгы төшү сәбәпле, Ментйән елга аша чыгарга батырчылык итмәде. Чиннәр, төзәп-нитеп тормыйча, кораллары беткәнче кичү ягына аттылар-аттылар да, елганың уң як яры буена таралып, арып-алҗып йокыга талдылар. Икенче көнне таң ату белән алар сул якка чыкты. Анда торып калган бик күп арбаларны, терлек-туарларны, яралы, гарип, хәлсез кешеләрне кулга төшерделәр.

Ментйән Туман каганны куа китте. Каганның артына җитмәкче булып ул сөннәрне бер айга якын куып барды. Ләкин иксез-чиксез буш далада чиннәр туңып үлгән атлардан, анда-монда аунап яткан кеше мәетләреннән, анда-монда туктап калган, күчәре сынган, тәртәсе каерылган арбалардан башка берни тапмадылар. Далада әрле-бирле буталып йөргәннән соң чиннәр, ашарларына бетеп, кире көньякка борылдылар.

XIV

Түрә буенча каганның өлкән бичәсеннән туган өлкән углы уң кул тучи бәк яу вакытында уң кул чирүгә субашы булырга тиеш иде. Ләкин Туман каган бу юлы түрә белән исәпләшмәде — уң кулның җитмеш меңлек чирүен ул шикле углына ышанып тапшыра алмады. Уң кулга Туман каганның бертуган энесе Кара-Тире би җитәкчелек итте.

Чәнсине Тарлавыкка илтеп тапшыргач Албуга Урта кичүгә көчкә

киләп җитеште. Юлда тагын берәр ничек тоткарланган булса, күрәсең, аңа башы белән саубуллашырга туры килгән булыр иде.

Үзенең мең кешелек чирүе белән ул Кара-Тире би кулы астында сугышты. Кичүне чыгып, Аръяк далаларында урнашкач, Кара-Тире би аны үз янына чакырып алды. Кара-Тире би туры сүзле, тик бераз кискенрәк, тупасрак кеше иде.

— Олуг уң кул тучи бәк! — диде ул Албугага эндәшеп.— Агам каганның сине читкә тибәрүен мин өнәп бетермим. Мин сине туры ук астына җибәрмәячәкмен. Син үзең кайда булырга телисең?

— Син кая куйсаң, мин шунда булачакмын! — диде уң кул тучи бәк Албуга күп уйлап тормыйча.

Аның ачык җавабы бигә ошады.

— Син артта булырсың,— диде ул аңа.

— Юк, мин иң алда булырмын, Кара-Тире би! — диде Албуга.

— Син бер генә төрле сөйләш, олуг уң кул тучи бәк,— диде би.— Башта уйла, аннан әйтерсең.

— Мин инде уйладым: мин яуга беренче булып ташланачакмын, Кара-Тире би! — диде яшь углан кайнарланып.— Минем батырлык күрсәтәсем, атам каганга турылыклы булуымны белдерәсем килә! Яуда дошман башын чабып алып, атам каганның аягы астына китереп ташлыйсым килә, атам каган кулыннан буза эчәсем килә!

— Синең теләгеңне мин истә тотармын, олуг уң кул тучи бәк,— диде Кара-Тире би, аның мондый теләгенә артык куаныч белдермичә.

— Минем турыда атама яхшы яктан гына сөйлә, Кара-Тире би,— диде яшь углан.

— Мин синең сүзләреңне каганга җиткерермен,— диде Кара-Тире би.

Менә бу сөйләшү турында Албуга соңыннан кайта-кайта уйланды. Бу сөйләшүдә аңа нәрсәдер ялган булып, кирәксез булып тоелды. Кара-Тире бинең аны алдан ук никтер кисәтергә теләве ялган идеме, әллә соң үзенең би алдында кирәгеннән артык атлыгып торучы булып күренүе ялган идеме?

Ни булса булды, Кара-Тире би аның теләген аяк астына салмады. Ул аны туры маңгайга куйды. Яуга уң кул тучи бәк беренче булып ташланды. Ләкин ана әллә ни батырлыклар күрсәтергә туры килмәде, шулай ук этисе каганның аягы астына үтерелгән дошман башын китереп ташлап, аның кулыннан буза эчәргә дә насыйп булмады. Сирәк урман белән капланган калкулык янындагы куркыныч үзәнгә аның мең кешелек алае ташкын уртасындарак барып керде. Чин уклары аның кешеләре арасына килеп төшә башлаганда, аларга инде артка борылырга да, читкә чыгып, дала ягына таярга да мөмкинлек юк иде. Алар, язгы ташу агызып алып киткән чүп-чар кебек, агач ботаклары кебек, тыелгысыз рәвештә туры упкынга барып керделәр. Каршыдан, як-яктан очкан сөңге-уклар аның иң якын егетләрен егып салды. Куркыныч ук-сөңге иң элек Кәлтәнең атланган атына тиде, аның муенын тишеп чыкты. Кәлтә җиргә егылып калды. Икенче ук бер егетнең эчен тишеп чыкты — ул шулай ук егылып калды. Өченче ук Бавырның атын чөйлектерде. Боларның барысы да Албуганың күз алдында булып үтте. Үз егетләренең ул кинәт кычкырып җибәрүләрен ишетте, җан-фәрманга чабып барган атларыннан ычкынып-ычкынып калуларын, ямьшәйгән кызганыч йөзләрен үз күзләре белән күреп калды. Бер мәртәбә куркыныч ук аның яңагы яныннан гына ыжгырып үтте. Ул ярсып: «Алас! Алас!» дип кычкырып җибәрде. Шул ук мәлдә Тишек-Ташның бар көченә кычкыруын ишетеп ул ялт кына уң ягына әйләнеп карады — куркыныч ук Тишек-Ташның күкрәгенә килеп кадалган иде, ул арты белән атыннан төшеп, авып бара иде.

Үлем угы аның үзенең атына да тиде — тимерле маңгаена шап итеп

кадалды. Албуга хәтта маңгай тимеренең, маңгай сөягенең шытырдап ватылганын да ишеткәндәй булды. Бичара ат, авыртуга чыдый алмыйча, кызганыч итеп чинап, кешнәп җибәрде һәм, маңгайдагы ук тимерен селтәп-алып ташларга теләгәндәй, башын каты чайкап, кинәт тигезлеген югалтты, сөрлекте һәм авыр гәүдәсе белән, өстендәге кешесе-ние белән каты җиргә барып төште.

Ул егылды. Аның сул аягы атның корсагы астына туры килде. Аның яныннан, өстеннән корсак асларын күрсәтеп, башка атлар чабып үттеләр. Аның битенә, күзенә тояклардан ычкынган каты кар, балчык кисәкләре килеп тиде. Бер заман аның янына яралы ат гөрселдәп килеп төште. Якында гына кычкырган, елаган, йөрәк өзгеч тавышлар белән кешнәгән авазлар ишетелде. Меңләгән тояк тавышларының каты җир күкрәгенә тибеп барабан кагулары, көчле, дәһшәтле булып яңгырап торды-торды да, кинәт барысы да тынып калды.

Шуннан соң ул башка берни ишетмәде, берни күрмәде. Аны үле ат гәүдәләреннән дә авыррак, куркынычрак булып, ниндидер караңгылык, томанлык каплап алды.

XV

Күпмедер вакыт үткәч, ул айнып-уянып киткәндәй булды. Каяндыр астан, ян-яктан салкын бәрә иде, аннары өстенә һаман да ниндидер зур, иләмсез нәрсә басып тора иде. Уянгач ул үзенең кайдалыгын чамаларга тырыша башлады. Тирә-як тып-тын иде, караңгы иде. Ул капшанырга, үзенең аяк-кулларын барларга тотынды. Куллары, аяклары исән иде, тәнендә яраланган җире дә юк иде бугай, тик менә бер аягы гына нишләптер бик каты авырта сыман.

Үзен басып, кысып торган нәрсәне кузгатудан курыккан шикелле ул иплән кенә, сакланып кына кыймылдый башлады. Капшана, кыймылдый торгач ул үзенең ике ат арасында кысылып калуын аңлап алды. Атларның икесе дә инде үлгән, тик икесе дә әле туңып катарга өлгермәгәннәр. «Мин исән! Исән!» диде ул үз-үзенә кыргый бер куаныч белән. Ул үзенең бик күп атлар, кешеләр белән каядыр чабып баруын, егылып калуын исенә төшерде. Ләкин менә хәзер ул кайда — үзләре ягындамы, чиннәр ягындамы, даладамы, елга буендамы — моны инде ул берничек тә белә алмады. Башта ук егылган төштә — далада булса, никтер аңа һаман да якында гына коточкыч тавыш, шау-шу ишетелеп торырга тиеш кебек тоелды.

Ул, кыймылдаудан, каядыр чыгарга азапланудан туктап, уйлаштыра башлады. Әгәр дә мәгәр алар җиңгән булсалар, аны бу килеш калдырмаслар — барыбер эзләрләр, табарлар иде. Эзләмәскә, тапмаска аларның хаклары юк! Кая аның ышанычлы егетләре, кая аның коралдашлары?

Аның кычкырасы килде. Ләкин ике ат гәүдәсе арасына кысылган килеш ул берничек тә кычкыра алмады. Ярсып ул яңадан кыймылдарга, каядыр шуышырга тотынды, һәм өзәңгедә килеш ат астында калган сул аягын көч-хәл белән тартып чыгарды да, хәрәкәтен тоткарлаган ук-җәя савытларының каешларын ычкындырды. Бушанып, җиңеләеп һәм терсәкләре белән этәләп-төрткәләп ул, кыймылдый-кыймылдый, ниндидер ачыграк урынга килеп чыкты. Иркенләп, күп итеп ул тын алды һәм сагаеп тыңлап тора башлады.

Бик якында гына ниндидер ыңгырашкан, шыңшыган, хәтта кычкырган тавышлар ишетеп ул аптырагандай итте. Бу ни бу?!

Ул моның ни икәнлеген ачыклый алмады — каядыр якында, бик якында, ашыгып пышылдашкан икенче төрле тавышлар ишетелеп китте. Ул әлеге пышылдашучыларның кайдалыгын да чамалый алды,

тик аларның ни сөйләгәннәрен генә аңлый алмады. Алар ниндидер ят телдә пышылдашалар иде! Алар, ахрысы, чин кешеләре иде! Әйе, ыңгырашмый торган, сызланмый, кычкырмый торган ул таза кешеләр монда бары чиннәр генә булырга мөмкин иде.

Әле генә гөлт итеп кабынган сөенеч тойгысы гөлт итеп шундук юкка да чыкты. Димәк, чиннәр җиңгән. Димәк, ул — чиннәр ягында.

Ул кинәт тынып калды. Кычкыру, кемне дә булса ярдәмгә чакыру уе үзеннән-үзе истән чыкты. Инде нишләргә? Шушында ат үләксәләре арасында кысылып калган килеш мәңге юкка чыгаргамы, әллә соң таң атканчы берәр ничек качып котылыргамы? Кая, ничек качарга?

Ул берни дә уйлап таба алмады. Кузгалырга, тын алырга куркып һаман тып-тын ята бирде. Ләкин аңа кинәт болай хәрәкәтсез яту үлем белән бер булып тоелды. Ул яңадан каядыр үрмәли, шуыша башлады һәм искәрмәстән үле ат гәүдәләре өстенә килеп чыкты.

Кышкы төн серле һәм караңгы иде. Бик еракта, каракучкылланып торган төпсез күктә кар бөртекләредәй генә булып йолдызлар җемелдәшә, кар бөртекләредәй җемелдәшкән йолдызлар арасында сызылып кына чыккан яңа ай балкып күренә. Яңа ай, яшь, көчле ай. Сөннәрнең атасы, сөннәрнең алласы... Менә ул — аның углы Албуга, уң кул тучи бәк дошман ягында, ат үләксәләре арасында җирдә аунап ята. Нишләп бер көнгә иртәрәк чыкмадың соң Тәңрем, Атам?

Әйе, ул менә дошман ягында. Чин ягында. Моңа әле ышанасы да килми, ләкин моңа ышанмый да булмый. Чиннәрнең явызлыгы, кансызлыгы турында аның күп нәрсәләр ишеткәне бар. Үз кулларына төшкән «ху»ларны алар я кол итәләр, я тереләй җиргә күмәләр, я булмаса, текә яр янына китереп, чүп-чар түккән кебек, шаулап аккан елгага коялар дип сөйлиләр.

Тәңрем, олуг Атам! Нишләтерләр алар мине? Тереләй җиргә күмәрләрме, шаулап аккан елгага ташларлармы, әллә соң бакыр ташы, тоз ташы казырга дип кеше кире кайтмый торган тау-таш араларына озатырлармы? Мине... синең изге углыңны шулай җиңел генә юкка чыгарырлармы? Мөмкинме бу, олуг Тәңрем? Минем анда — туган даламда — изге анам калды, бичәм Алтын-Бөртек, туганнарым калды. Анда минем җирем-суым, анда минем илем-көнем. Шушы яшьтән мине үз янына алып, син аларны ятим калдырырсыңмыни?! Коткар мине бу тозактан, Тәңрем!

Күңеленнән шулай ялваргач ул үзендә көч артуын тойды һәм тагын бер мәртәбә омтылыш ясап карарга булды. Аягының авыртуын онытырга тырышып, ниндидер үле гәүдәләргә, җансыз аякларга басып ул ары үрмәләде. Якында гына тагын да чит телдә пышылдашып сөйләшкән тавышлар ишетелеп китте. Болар мәет талап йөрүче угрылар иде, ахрысы.

Ат, кеше мәетләре өстенә менеп баскан бер кешене алар күрмәделәр бугай. Ләкин Албуга аларның бер яралыны күсәк белән сугып үтергәннәрен аермачык күреп калды. Куркып, ул яңадан мәетләр арасына егылды. Бераз тыңлап, тынып ятты да, канга сусаган чүл бүреләре сыман иснәнеп, капшанып йөргән шикле бәндәләрдән ерагаерга тырышып, түше белән читкә шуыша башлады. Уң кулына ул мәетләр арасында тапкан саллы, яхшы сөңге тотты, сул кулына билендәге хәнҗәрен алды. «Башка күсәк белән китереп тондырганны көтеп ятмыйбыз әле!» диде ул үзенә-үзе, күңелен күтәреп.

XVI

Шуыша-шуыша ул шактый җир китте. Угрылардан ераклашкач ул башын калкытып каранып торды да, аякларына басты һәм авыртына-

авыртына булса да, аксаклап булса да, иелә-бөгелә бара башлады. Мәетләр белән тулы үзәннән читтә, яланда аңа иясез атлар булырга тиеш сыман тоелды. Аты булса, аны инде беркем дә тота алмаячак!

Читкәрәк китә барган саен җир өстендә аунап яткан мәетләр дә сирәгәя башлады. Җир өстендә калкып, кап-кара булып яткан үле атларга елышып, кача-поса ул һаман дала ягына китә барды. Шулай барганда ул бер үленең ук тулы садагын чишеп алды, икенчесенең җәясен алды. Шул чакны ул колак төбендә генә кемнеңдер: «Су!» дип кычкыруын ишетеп, сискәнеп туктап калды. Тыңлый башлагач, тагын да әле аннан, әле моннан ыңгырашкан тавышлар ишетелде. Берсе, саташыпмы, соңгы сулышы җитүен сизепме, еракта калган сөекле хатынын ярдәмгә чакыра, икенче берсе тәңрегә ялвара, өченчесе кемгәдер ләгънәтләр укып, балаларча үксеп елый.

«Су!» дип ыңгырашкан кешенең тавышы Албугага таныш сыман тоелды. Кызыксынып, куркуын онытып ул аның янына килде.

— Син кем? — диде ул пышылдап кына.

Су сораган ир шундук аның тун чабуыннан эләктереп алды.

— Су бир, туган, су! — диде ул аның соравын ишетмичә.

— Кем соң әле син? — диде Албуга һич кенә дә хәтерли алмыйча.

— Аягым сынды! Ах, аягым сынды! — диде яралы кычкырып.

Таза кешегә тотынып ул ничек тә аягына басмакчы булды.

— Этимчәк ич син! — диде кинәт Албуга, яралының йөзенә якынрак килеп.

— Йөзбашы Этимчәк! — диде яралы.

— Тотын миңа. Әйдә! — диде Албуга аны култыклап алып.

Этимчәк аягына җиңел генә басмакчы булды, ләкин, авыртуга түзә алмыйча, гөрселдәп кире ауды. Авыр гәүдәгә ияреп Албуга да аның белән җиргә егылды.

— Булмый, ташла! — диде Этимчәк, кинәт еларга тотынып.

— Шаулама! — диде Албуга, яңадан аягына басып. — Ат тотарбыз. Әйдәле яңадан киттек!

Этимчәк яңадан аягына басты. Албуга аңа таянырга кулындагы сөңгесен бирде. Алар яңадан кузгалып киттеләр. Шул чакны ниндидер карачкының дала ягына йөгереп китеп барганы күренде. Ул ялгыз иде, тап-таза иде.

— Бавыр! Тукта! — дип кычкырды Албуга йөгерүчене ерактан ук танып.

Карачкы туктады, якынрак килде.

— Мин Бавыр түгел, мин — Сөмәтәй,— диде карачкы.

— Сөмәтәй булсаң да... Бавыр,— диде Албуга, үзенең ялгышуына эз генә исе китмичә.— Бу йөзбашы Этимчәк. Тот кулыннан!

Сөмәтәй йөзбашының бер кулыннан, Албуга икенче кулыннан тоттылар. Алар шулай өчәүләшеп ары китеп бардылар. Үлекләрдән читтәрәк чыннан да иясез калган атлар күренде. Ашыгып шул атлар янына киттеләр. Иясез атларга атланып качарга чамалаган кешеләр бер алар гына булып чыкмады. Монда инде унлап кеше бар иде. Аларның кайберләре ат тотарга азаплана, кайберләре ияреп, коралын рәтләп азаплана иде. Бер-икесе, мәетләр ягыннан якынлашып килүче карачкыларны күреп, тиз генә атландылар да, караңгыда юк та булдылар.

— Ашыкмагыз! — дип кычкырды Албуга, башкаларның да тизрәк табан ялтыратырга чамалауларын күреп. — Мин — уң кул тучи бәк Албуга! Йөзбашы Этимчәк тә монда, Сөмәтәй дә...

Атлар тирәсендә булашкан ирләр туктальп, килүчеләргә борылып карадылар.

— Уң кул тучи бәк! Син нишләп безнең белән?! — диде ирләрнең берсе, чын күңелдән гаҗәпләнеп.

— Мин — Кәлтә! — диде икенче берсе куанып.

Кәлтә инде атланган иде. Ул шундук атыннан төште, Албуга янына килде.

— Коткар безне!

— Алып кайт далага! — диештеләр ирләр шаулашып.

Кемдер шунда озын торыклы тулпар ат житәкләп килде.

— Сиңа, олуг тучи-бәк! — диде.

— Тавышланмагыз! — диде Албуга, үз тирәсенә җыйналган ирләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап.— Кораллырыгыз бармы?

— Бар!

— Каты яралылар бармы?

— Юк!

— Атлар җитәрлекме?

— Җитәрлек!

— Аты булган, коралы булган сөн ирен далада кем тота алсын? — диде тәгин углан. — Без — үз җиребездә, үз далабызда. Туган җир безгә юлдаш булыр, туган күк безгә бөркәнчек булыр. Без котылырбыз. Минем боерыкларны гына тыңларга!

— Тыңларбыз. Алып кайт!— диделәр ирләр бертавыштан.

Барысы да тотып алган атларга атландылар. Уң аягы тездән түбән сынып чыккан Этимчәкне күтәреп диярлек шулай ук атка атландырдылар. Үзен ат өстендә тоеп, яралы йөзбашы тынычланып калгандай булды. Тучи бәк аңа булышырга, ярдәм итәргә дип Сөмәтәйне билгеләде. Кәлтәгә ул үзе янындарак булырга кушты. Барлыгы унбишләп кеше җыелды. Кузгалып китәргә генә торганда, мәетләр үзәне ягыннан тагын ашыгып килүче өч-дүрт кеше күренде. Аларның да ат тотып атланганнарын гына көтеп тордылар да, төн таңга авыша башлаганчы дип, ашыгып китеп бардылар.

Далада төне буена яралы ирләрнең кычкырган, ыңгырашкан тавышлары ишетелеп торды. Тазарак ирләр, әледән-әле мәетләр арасыннан чыгып, ачык җиргә үрмәләделәр. Берәүләр шуышты, берәүләр йөгереп китте. Үзәннең төрле җирендә, ач бүреләр кебек, мәет талаучылар йөрде. Тазарак ирләрнең качып барулары, йөгереп китүләре аларны бөтенләй кызыксындырмады. Алар бары каршылык күрсәтүчеләрне генә я булмаса өстендә бай киеме булган яралыларны гына үтерделәр. Ике аяклы бүреләрдән читтәрәк дүрт аяклы чын бүреләр йөрделәр.

Таң алдыннан далада буран чыкты. Кешеләрнең шул кадәр кансызлыкларына, явызлыкларына ачуы килгән буран ярсып-ярсып кар ташыды һәм күз ачып йомган арада мәетләрне ак юрган белән каплап, күмеп китте. Тавышлар тынды. Иясез калган исән атлар, хуҗаларын кызганып, туганнарын кызганып, сузып-сузып кешнәделәр.

XVII

Уң кул тучи бәк җитәкчелегендәге егерме бер кеше төньякка карап барды. Аларның иле, аларның төп җирләре-сулары, аларның маллары-туарлары шунда. Арьякны чиннәр басып алган булсалар да, каганның калдык көчләре бары шунда гына — төньякта гына булырга тиеш иде. Каган анда булмаган очракта да, дала беркая китмәячәк. Далада сөннәрдән башка беркем хуҗа була алмаячак, дала мәңге аларныкы! Кем белә, бәлки әле сөннәр бөтенләй үк җиңелмәгәннәрдер дә, ике арада, бәлки, кайда да булса каты сугыш барадыр.

Албуга шулайрак уйлады. Юлдашларына да ул шулай диде. Караңгыда бик үк кызу барып булмады. Бераз җир киткәч, алда бик күп учаклар күреп, алар туктап калдылар. Учак тирәсендә күренгәләгән

берән-сәрән кешеләрнең киемнәре сөннәрнекенә охшамаган иде. Болар чиннәр булырга тиеш сыман иде.

Алар шундук кире борылдылар һәм, күп санлы утлардан ерагаеп, кырт кына көнчыгышка борылдылар. Алар учаклар янындагы чиннәрне читләтеп, яңадан кичүгә таба хәрәкәтләнергә булды. Шактый озак бардылар һәм тирә-якта шикле берни дә күренми башлагач, атларын яңадан төньякка бордылар.

Менә озакламый уң кул якта — бөек кояш йокысыннан уянып җир өстенә күтәрелә торган якта — ирек һәм тереклек вәгъдә итеп, ягымлы яктылык тарала башлады. Кара төн, шомлы күренешләр, үлем һәм чиннәр белән бергә артта кала барды. Күз алдында күңелгә якын күренешләр — дулкын-дулкын җир өсте, түгәрәк күлләр, камышлыклар, комлы калкулыклар беленә башлады.

— Котылдык!— диде Этимчәк беренче булып.

Башкалар эндәшмәде. Бу әле чын мәгънәсендә котылу түгел иде. Тулысынча котылу өчен кичүне чыгарга, тарлавыклар аша үтеп, таулар өстендәге иксез-чиксез тигезлеккә менеп җитәргә кирәк иде.

Албуга ирләргә туктарга боерды.

— Без әле котылмадык,— диде ул Этимчәккә карап.

— Юк, котылдык! — диде Этимчәк.

Аның тавышында ярсу, өметсезлек һәм холыксызлык сизелде. Ул бик йончыган, күрәсең, үзен-үзе бик нык мәҗбүр итеп кенә бара иде.

— Мин шушында торып калам! — диде ул күрәләтә үртәлеп.

Албуга аңа әрнеп, сыкранып карады. Этимчәкнең сынган аягы җансыз нәрсә булып салынып тора, бәйләнгән ярасы аша кан саркып чыккан һәм боз булып каткан. Ат өстендә ул көчкә утырып тора иде.

— Кичүгә әле ерак. Безгә тагын да төньяккарак борылырга кирәк,— диде Албуга.

— Сез мине юри йөртәсез! — диде Этимчәк тагын үртәлә төшеп.— Мин калам. Үзем табармын юлны!

— Кузгалырга кирәк! Яктыра! — диде Кәлтә Албугага карап.

Этимчәк аркасында тукталып торуга аның гына түгел, башкаларның да эче пошкандай булды. Тап-таза кебек күренгән йөзбашының шулай ярсуы, холыксызлануы тучи бәккә бик кызганыч тоелды. Аның белән нишләргә дә белмичә ул каушап калгандай булды. Куеныннан алып ул аңа бер кисәк пешкән ит бирде.

— Эчәргә бирегез! — диде йөзбашы, итле кулны бәреп җибәреп.

— Бирәрегездә кымыз юкмы? — диде Албуга ачусыз гына.

Кымыз беркемдә дә юк иде.

— Кар алып бир,— диде тучи бәк Сөмәтәйгә.

Сөмәтәй ялт кына сикереп җирдән учлап кар алды да йөзбашына бирмәкче булды. Этимчәк карны да бәреп кенә җибәрде.

— Улым, балам! Кил әле яныма! — диде ул кинәт Албугага эндәшеп. — Мин башка бара алмыйм. Мин барыбер аттан төшеп калырмын. Тоткарланма. Мине үтерегез. Башымны хатыным Талчыбыкка кайтарып бирегез. Хатыным, малым, балаларым сиңа булыр. Син — үлмә. Син — уң кул тучи бәк углан. Син үлсәң, Сөн юкка чыгар. Чин җиңмәде... Ышанмыйм. Булмый ул, булмый!

Ул бик авырлык белән сөйләде — әле кычкырып, әле гыжылдап, пышылдап сөйләде.

— Кәлтә! Сөмәтәй! — диде Албуга ирләренә эндәшеп. — Берегез уң ягыннан, берегез сул ягыннан барасыз. Егылтмаска, югалтмаска.

— Улым! Энем! — диде Этимчәк ялварып, аңа тагын нидер аңлатмакчы булып.

Албуганың икеләнүе тиз арада юкка чыкты.

— Кичүгә җитмичә туктатмаска! — диде ул ныклы бер карарга килеп.

Алар тагын кузгалып киттеләр. Шул вакыт далада җил чыкты, буран купты.

XVIII

Буран чыгуга алар сөенделәр генә. Даладагы буран аларның күптәнге танышлары, күптәнге дуслары, юлдашлары иде. Алар бернигә карамыйча кичүгә таба хәрәкәтләнделәр. Җил аларга каршыдан, сул яктанрак исте. Алар дөрес бардылар. Җил көчәйгәннән-көчәйде. Болай булгач алар, һичшиксез, котылачаклар! Бөтен җирне-күкне каядыр ашыгучы, ыжгыручы болганчык кар-буран каплап алды. Төн караңгылыгыннан котылып җитмәгән кешеләрне бар яктан да аксыл караңгылык чорнап алды.

Алар, адашып, таралышып бетмәс өчен, бер-берсенә якынрак килделәр һәм, шулай бергә укмашып, бергә тупланып туктаусыз алга бардылар да бардылар. Мондый чакта иң яхшысы берәр ышык җирдә буран тынганны көтеп тору булыр иде дә, каян табасың хәзер монда ышык, аулак урынны?!

— Туктарга кирәк, туктарга! — дип кычкырдылар ирләр.

Тучи бәк Албуга башын чак-чак кына күтәргәндәй итеп як-ягына караса, каршыда агач сыман ниндидер карачкылар күреп алды. Ниндидер әрәмә буена килеп чыкканнар иде бугай. Алар туктадылар, җиргә төштеләр. Җилгә каршы каратып, атларын бер-берсенә якын тезеп куйдылар. Качышмасыннар өчен аларның тезгеннәрен бер-берсенә бәйләделәр. Үзләре, кочаклашып, бер-берсенә сыенып, атлары арасына бастылар. Монда аларга җил көчсезрәк тоелды.

Тавышы-тыны бетә башлаган Этимчәкне бик авырлык белән генә шулай ук җиргә төшерделәр. Күтәреп, култыклап аны Кәлтә белән Сөмәтәй җанлы койманың уртасына ук алып килделәр. Аны шулай ике яктан тоткан, култыклаган килеш басып тордылар.

Буран бик озак котырды. Бер урында кымшанмый торган кешеләр туңа, калтырана башладылар. Кайберәүләр тынычланып йоклап китте. Йоклаучыларны тарткалап-төрткәләп шундук уятырга тырыштылар. Бары тик Этимчәкне генә уятып булмады. Ул Кәлтә белән Сөмәтәй арасында басып торган килеш катып үлде.

— Сөмәтәй, аның башын кисеп алып, хатынына тапшыр,— диде Албуга, йөзбашының соңгы үтенечен исенә төшереп.

— Тапшырырмын,— диде Сөмәтәй, телен көчкә әйләндереп.— Минем үз башымны кем алып кайтып тапшырыр икән — анысын да әйтмәссеңме, олуг тучи бәк?

— Үзеңнекен — үзең! — диде Албуга ачуланып.

Буран бары кичкә таба гына тынды. Атларына, бер-берсенә сыенып торган, бөтенләй диярлек хәрәкәтсез калган, бил тиңентен карга күмелгән ярым үлек ирләр мона ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Туңа язган аякларын көчкә кыймылдатып, кар ерып тучи бәк үзенең ирләрен барлап чыкты. Өлкән яшьләрдәге бер ир, атының арт аяклары арасына кысылып, бөгәрләнеп үлгән иде. Бер-икесенең хәлләре шулай ук шәптән түгел. Бары Кәлтә белән Сөмәтәй дә, тагын берничә яшь, таза ирләр генә сәламәт-көр күренәләр. Алар өлкән кешеләрнең аяккулларын удылар, көчләп диярлек аларны урыннарыннан кузгаттылар. Шуннан соң, шулай ук бик нык тырышлык белән, атларның тезгеннә-

рен чиштеләр дә, бер-берсенә булышып, иярләргә атлана башладылар. Кәлтә белән Албуга иң азактан атланырга булды.

Алар шулай көчкә кыймылдашып яңадан юлга чыгарга җыенып ятканда, як-якта ниндидер атлылар күренде. Барысы да берьюлы диярлек башларын калкытып, аптырап, ышанмыйча ят кешеләргә карап тордылар.

Болар чиннәр иде. Алар да бик нык йончыганнар, күшеккәннәр иде. Алар да кайдадыр шушы тирәдә генә буран тынганын көтеп торганнар бугай. Ләкин алар күп иде, бик күп иде.

Албуга да, башкалар да шундук ук-җәя савытларына тотындылар. Әмма туңган кулларның инде ук-җәя тотар хәлләре калмаган иде. Сөннәр ук-җәя белән булашкан арада чиннәр, бик каты шаулашып, аларны төрле яктан уратып алдылар. Сөн ирләренең башлары өстендә, үлем белән янап, озын саплы балта-сөңгеләр күтәрелде.

Башкалардан аерылып торган бай, таза киемле тучи бәккә чиннәр шундук игътибар иттеләр. Җансыз нәрсә күргән кебек, төртеп күрсәтә-күрсәтә, аның турында алар нәрсәдер сөйләнеп алдылар. Башындагы алпагы — каты бүреге аның көмештән, биленә бугач кин каешына алтын тәкә, бүре, болан сурәтләре төшерелгән иде. Өстенә ул юка тимер калайлар тегелгән каты күбә кигән иде.

«Алтынга кызыктылар микәнни?» дип уйлады ул аларның шулай үзенә төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләнүләренә хурланып. Ул аларның үзен чишендереп, яхшырак нәрсәләрен талап алуларын көтте. Һәм аларның кайчан да булса үтерәчәкләрен белгәнгә күрә, күңеленнән: хәзер үк үләргә — барлык юлдашлары алдында берничә дошманны юк итеп, батырларча үләргә, дигән карарга килде. Күңеленнән чиннәр кызыгырлык әйберләрен хәтерли башлагач ул Алтын-Бөртек биргән борынгы бөтиен исенә төшерде. Аңа бик кыска вакытка гына җылы, рәхәт булып китте. Бөти аны сакларга тиеш! Юк, ул әле үлмәячәк!

Ул көтә башлады. Аңа беркем якын килмәде. Ул, ахрысы, чынлап та исән калды!

Аларга чиннәр үзләрендә булган барлык коралларын ташларга боердылар. Башта ук ташланмаган коралларны — пычак, хәнҗәр ише нәрсәләрне ташлагач, аларга атларына атланырга кушылды. Аларның кулларын артларына каерып бәйләделәр дә, ат тезгеннәрен үз атларының койрыкларына тактылар.

Шул рәвешчә аларны каядыр көньякка алып киттеләр. Юлда, далада сөннәрнең адашкан, я булмаса качып котыла алмаган берән-сәрән вак төркемнәре очрады. Чиннәр аларны да кулга алдылар, баштагы зуррак төркемгә куша тордылар.

Әсирләрне Чин ягына ике көн, ике төн кудылар. Ашарга, эчәргә бирми бирелмәде. Бары ачыккан атларны гына тибенгә җибәрделәр. Ачлыктан, хәлсезлектән күпләр ат өстеннән төшеп егылып калдылар. Әсирләр үткән юл буйларында җылы туннары салдырып алынган шәрә мәетләр торып калды.

Таштан, балчыктан өеп мендерелгән чик буе манараларын үтеп, Чин җиренә килеп кергәч, аларны биек коймалар белән әйләндереп алынган иркен генә бер ишегалдына ябып куйдылар. Аякларында көчкә басып торган сөн ирләре тапталган пычрак кар яладылар, бил каешларын, каты кием куннәрен, сөякләрен кимерделәр.

Төнне кешеләр ачык ишегалдында кундылар. Бик күп ирләр туң җир өстендә, койма буйларында ятып калды. Исәннәрне ишегалдының икенче башына алып килделәр дә, ниндидер тар аралыкка куып керттеләр һәм, тегендә, далада, сөннәр терлек-туар санаган кебек, саныйсаный шул аралыктан үткәрә башладылар.

Менә шунда, бер генә кеше сыешлы тар аралыктан үткән чакта, уң кул тучи бәк тәгин углан Албуга санап-карап торучылар арасында таныш сыман бер кешене күреп калды. Ул, үзе дә сизмәстән, гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде. Санап торучы чин ирләре шундук аның ягына борылып карадылар. Албугага таныш сыман күренгән ир дә борылып карады. Ул да аны таныды. Ләкин гаҗәпләнмәде. Ул көлеп җибәрде. Сөенеп-куанып көлде. Тик аның бу сөенечле көлүендә дусларча эчкерсезлек түгел, бәлки тантана сизелде. Искәрмәстән корбанын эләктереп алса, ач шакал да, күрәсең, күңеленнән шулай тантана итәдер.

Бу кеше Чәнси иде. Хөкемче аны үлем җәзасына хөкем итте. Ментйән аны үзенең җинаятьчеләр гаскәренә алды. Атасы Чәни кебек, ул да сөннәргә каршы сугышты, бик каты сугышты, җиңде һәм исән калды. Әсирләр арасыннан аңа Туман каганның өлкән углы уң кул тучи бәк тәгин угланны эзләп табу бурычы йөкләтелгән иде. Менә ул тапты! Ул сөенми кем сөенсен... Җиңүчедән дә бәхетле беркем юк дөньяда.

Беренче китап бетте